ISSN 0206-4189

# Казан утлары

1.1995



# Мөдәррис Әгъләм

* * *

Өр-яңа ел, дибез, өр-яңа ел —
Чынлап яңа булса икән ул:
Кояш кебек һәммә илләргә дә
Тигез көлеп торса икән ул.

Төрле еллар күргән өчен — безгә
Яңа да ул үзе,
Иске дә...
Кеше бит ул Өмет өммәтеннән —
Иң соңыннан өмет киселә...
Ә без киселмәдек... Яңа Елга,—
Үти-үти намус кушканны,—
Киләчәккә өмет белән төреп
Алып кердек Татарстанны.
...Тик беразга онытылып торсын,
Артка чиксен кайгы-борчулар...
Элеккечә утлар — янып торсын,
Балкып торсын шулай чыршылар.
Сабыйлар да һаман элеккечә
Әйләнсеннәр — әйләнмәләрдә.
Нигә яшәү — кайгы, куанычлар
Бер-берсенә бәйләнмәгәндә?
...Авырлыклар искә төшкән икән,
Китәчәкбез аны бер алып...
Ә Яңа Ел — өр-яңа ел булсын,
Без яманга аны юрамыйк,—
Өр-яңа ел булсын!



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1**

**(867)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Х. КАМАЛОВ. Түләнмәгән күз яше. *Роман* ..... 3
Р. ӘХМӘТҖАН. Яңа шигырьләр ..... 67
Р. ФӘИЗОВ. Телсез. *Хикәя* ..... 80

ЭДУАРД МОСТАФИНГА 50 ЯШЬ

Э. МОСТАФИН. Төрле еллардан. *Шигырьләр* ..... 74

ОСТАХАНӘ

Ч. ЗАРИФ. Зәңгәр кыялар. *Шигырьләр* ..... 91

ДРАМАТУРГИЯ

Т. МИҢНУЛЛИН. Хушыгыз! *Ике пәрдәле драма* ..... 95

ҖӘМИТ РӘХИМОВКА 60 ЯШЬ

Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Кыялагы чәчәкләр ..... 113
Җ. РӘХИМОВ. Эскерттәге энә. *Эссе* ..... 115

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. ХАФИЗОВ. Башкортстанда татар әдәбияты ..... 138

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Х. МИҢНЕГУЛОВ. Алтын Урда әдәбияты ..... 147

ТЕЛЕБЕЗ ХӘЗИНӘСЕ

Г. САТТАР-МУЛИЛЛЕ. Ономастика һәм энциклопедия ..... 154

ШӘЕХЗАДӘ БАБИЧНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

М. ӘГЪЛӘМ. Татарның танылмаган мәшһүр заты ..... 160
ЗӨЛФӘТ. Бабичны юксыну. *Шигырь* ..... 165
Ш. БАБИЧ. Халкым өчен. *Шигырьләр* ..... 165

ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Олуг исемене зурлыйлар. *(Г. Бәширов, И. Юзеев, Ш. Галиев, Х. Камалов истәлекләре)* ..... 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Шәркый рухыбыз тамырлары ..... 178

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Т. КАМАЛ, Р. ӘМИРХАН. Фикри юл. *(Яхъя Абдуллин — фәлсәфә тарихчысы.)* ..... 181

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

М. ӘМИРХАН. Чиллә бабай фатихасы. *Хикәя* ..... 183
Җ. НУРАНИ. Мәкерле көндәш. *Хикәя* ..... 185

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 188

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнен адрес 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа Х. КАМАЛОВА «Нерасплаченные слезы»; рассказ Р. ФАИЗОВА «Немой»; стихи Р. АХМЕТЗЯНОВА, Э. МУСТАФИНА, Ч. ЗАРИФ.
«Драматургия»: драма Т. МИННУЛЛИНА «Прощайте!».
«К 60-летию Дж. РАХИМОВА»: статья Р. ТУХВАТУЛЛИНА «Цветы на скале», эссе Дж. РАХИМОВА «Иголка в скирде».
«Литературная критика»: статья С. ХАФИЗОВА «Татарская литература в Башкортостане».
«К истории литературы»: статья Х. МИННЕГУЛОВА «Литература Золотой Орды».
«Сокровище языка»: статья Г. САТТАРОВА «Ономастика и энциклопедия».
«К 100-летию Ш. Бабича»: статья М. АГЛЯМОВА «Неизвестный татарский знаменитый поэт», стихи ЗУЛЬФАТА и Ш. БАБИЧА.
«К 90-летию Ш. Маннура»: воспоминания о поэте Г. БАШИРОВА, И. ЮЗЕЕВА, Ш. ГАЛИЕВА, Х. КАМАЛОВА.
«Книжное обозрение»: Ф. ГАЛИМУЛЛИН рецензирует книгу Х. Миннегулова «Татарская литература и Восточная классика».
«К истории культуры»: Т. КАМАЛ, Р. АМИРХАН рассказывают о жизни и деятельности доктора философских наук Я. Г. Абдуллина.
«На наших обложках»: «Современники» — картина художника И. Давлетова; писатель Г. Сабитов.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the beginning of Kh. Kamalov's novel «Unpayed Tears», R. Phaizov's story «The Dumb», the verses of R. Akhmetzyanov, E. Mustafin, Ch. Zarif.
«The Drama»: T. Minnullin's drama «Adiew!».
«To the 60 Anniversary of D. Rakhimov»: R. Tukhwatullin's article «The Flowers on the Rock», D. Rakhimov's essay «The Needle in the Stack».
«Literary Critique»: S. Khaphizov's article «The Tatar Literature in Bashkortostan».
«To the History of Literature»: Kh. Minnegulov's article «The Literature of The Golden Horde».
«The Treasure of Language»: G. Sattarov's article «Onomastics and Encyclopaedia».
«To the loo Anniversary of Sh. Babich»: M. Aglyamov's article «The Unknown Eminent Tatar Poet», the verses of Zulphat and Sh. Babich.
«To the 90 Anniversary of Sh. Mannur»: the recollections of G. Bashirov, I. Uyziev, Sh. Galiev, Kh. Kamalov about the poet.
«Book Review»: Ph. Galimullin reviews Kh. Minnegulow's book «The Tatar Literature and the Onental Classics».
«To the History of Culture»: T. Kamal and R. Amirkhan tell about the life and work of Ya. G. Abdullin — the doctor of philosophy.
«Humour and Satire»: the stories of M. Amirkhan, Z. Nurani.
«The Diary of the Social and Cultural Life».
In our corvers: the picture of I. Davletov «Contemporaries», the writer G. Sabitov.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 2.12.94 ел. Басарга кул куелды 20.01.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 576. Заказ А-579.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Хисам Камалов**

# ТҮЛӘНМӘГӘН КҮЗ ЯШЕ

РОМАН

## I

Эштән кайтышлый Зәй Фаизов вахта машинасыннан базар чатында төшеп калды. Соргылт кожан курткадан, башында калын кепка, аягында кирзалар. Какча битле, уртача буйлы, тирән чокырлы күзләре моңсу карыйлар. Нияте симезрәк ит юнәтү иде. Кибет итенең бер дә тәме юк. Әмма базар бүген иртә таралган икән, лавкалар буш! Аяк астында сукбай мәчеләр уралып йөри. Шулай да бер почмакта иске плащ кигән карт күренә иде. Зәй шуның янына атлады. Өстәл өстендә чистартылган тавык түшкәләре ята.

— Бу синең үтергән тавыклар инде, ә? Ни хак?— дип, уенлы-чынлы бергә кушып дәште Зәй.

— Юк, энем, болар суйган,— диде карт мактарга теләмичә.— Суймаганы төсе үк башка була...

— Суюе шул үтерүдер инде?

— Аермасы зур аның, энем, әмма хәзер барыбер, әйдә-давай гына. Талымлану бетте...— Карт канәгатьсез генә кул селтәде. Аның бу ымы ышаныч уяткан кебек итсә дә, түшкәләрнең зәңгәрсуланып торуы Зәйнең гайрәтен чигерде. Майсыз ит — салам инде ул, дип уйлады һәм алмады.

Чыгып барган чакта, суймыйча эшкәртелгән ит авыруларга сәбәпче була, имеш, дигән кайчандыр ишеткән сүзләр хәтеренә килде. Уе шунда ук үз баласына күчте. Ул да авырый иде. Башта ук рәте-юне булмады. Тапкач, ике атнадан Рәмиләнең сөте бетте. Ул арада бала тудыру йортыннан чыгарга, ди башладылар. Шәфкать туташы Фалия ярдәм итмәсә, эш харап иде. Баш врачка гариза язып, Рәмиләне беразга калдырып торырга үтенделәр. Баланың һаман тернәкләнеп китә алмавы моңа ныклы нигез иде. Хәлгә керделәр. Тагы Фалия булышты: «сөте күп

---

Хисам КАМАЛОВ (1926) — *әдип. «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым» романнары авторы. Татарстанның Г. Тукай премиясе лауреаты. Казанда яши.*

хатыннардан саудырып ала да безнең балага бирә. Рәмилә үзе сорарга ояла иде. Фалия хәйләкәр, башка палатадагы хатыннардан алып кердә. Шулай ике атна дигәндә бала күзләрен ача башлады. Әмма Рәмиләгә сөт төшмәде. Больницада бүтән калу мөмкин түгел иде.

Чыккач өчәүләп газап чигә башладылар. Бала ясалма сөтне имми иде. Күкрәк сөте булсын, ә аны һаман саен табып җиткереп булмый. Ач бала елый да елый. Йөрәккә төшә торган ыңгырашу белән елый. Зәй моңа чыдап тора алмый, күкрәк турын учы белән ышкый-ышкый бүлмәдән чыгып китә. Аннары тагы әйләнеп керә. Баланы чиксез кызгану тартып кертә аны. Җанга нинди якын ул! Бәгырьдән өзелеп төшкән тере җимеш шул! Аңа үз җаныңны бирердәй буласың.

Дон урамы почмагына җиткәндә Зәйгә күптәнге бер танышы очрады. Себердә хезмәт иткәндә сукмаклары туры килгән иде. Соңыннан ул Бөгелмәдә эшкә урнашты. Туган җире Ленинградка кайтырга рөхсәт итмәделәр, ди. Мәшһүр 58 нче статья корбаны. Хәзер горисполкомда диннәр белән идарә итү бүлегендә эшли. Фамилиясе дә сәер генә: Казан.

— Менә Печмән чиркәвен нефтьчеләр ваттырганнар, понимаешь,— дип сөйләп китте ул.— Хәчтерүш кенә бер таш корылма булган. Фураж амбары итеп тотканнар. Ул чагында дәшәргә курыкканнар. Хәзер Үзәккә жалоба җибәрделәр. Скандал. Ә хәчтерүшне яңа шәһәр уртасында калдырып булмый бит! Әнә төзелеш ничек бара! Безнең җирләр миллиард тонна нефть бирә, дип язганнар. Шуның белән йөрим әле. Әмма бер җавап бирүчене табып булмый...— Казан сөйләүдән шып туктады, чөнки Зәйнең ашыгуын сизеп алган иде.

— Карале, балагызның хәле ничек соң?— дип гафу сораган тавыш белән тагы сөйли башлады ул.— Теге көнне Бөгелмәдә әйтеп торган идең?

— Алга китү чамасы юк әле, юк,— диде Зәй теләмичә генә.

— Бездә бик тәҗрибәле педиатор бар, шуңа күрсәтеп карасак, ә?

— Рәхмәт, Андрей Андреич...

— Рәхмәтне куй, баланы терелтү мөһим... Кайчан мөмкинлегең була, туры безгә кил. Кара аны, сузма... Ярый, хуш, мин киттем...

Ул Зәйнең беләгеннән тотып саубуллашты да, адымнарын тизләтте...

Зәй, башын ия төшеп, борылышта юлны аркылы чыга башлады. Кемдер тагы арттан кычкырды: «Туктале, нигә качасың?»— диде. Зәй борылып карарга мәҗбүр булды.

— Ә-ә, Надир, ни хәл?— диде Зәй үзе башлап. Алар буровойда бер вахтада эшлиләр. Надир Алкин җәнҗалчырак холыклы, шуңа күрә бер төштә генә ябышып эшли алмый. Моннан өч ай элек буровойдан киткән иде, менә тагы әйләнеп кайтты. Башлы егет, русчасы да әйбәт, әмма дөреслек дәгъвалап, җитәкчеләрнең теңкәсенә тия.

— Юк, кул бирмим мин сиңа,— дип, Надир бер адым читкә тайпылды.— Теге вакытта синең бер сүзең җитә иде, шуны әйтергә шүрләдең. Ә артта дөреслек дип сөйләнәсең, син провокатор икән...— Надирның кашы, борыны җыерылган, үзенең хаклы булуы кыяфәтенә чыккан. Зәйнең дә эчендә ачу кайнап йөзенә менде, тик ул кычкырышмас өчен үзен тыйды. Араны начарайтырга теләми. Менә шулай нахак исемнәр дә күтәрергә туры килә. Ачуга ачу белән җавап кайтару төшемсез, мәгънәсез эш.

— Напрасны рәнҗетәсең, парин,— диде Зәй араны йомшартырга теләп. Җиңелү ачысын үз өстенә алды. Әйдә, Надир кинәнсен. Нахак сүзләрен дә кире кагуны кирәк тапмады.

— Артта батырланып дөреслек, дөреслек дип тукынасыз, ә дөреслек алга килгәч, шуны якларга куркасыз...— Надир тавышын күтәрде, юка иреннәре ишарәле елмаю белән җәелде.

— Надир,— диде Зәй шулай ук төрттерүле итеп.— Үзең башлы кеше, гади бер нәрсәне аңламыйсың. Синең квартирың бар, хатының ашханәдә, балалар тамагы өчен кайгыртасы юк. Ә бүтәннәрнең ул кайгы җилкәләрендә камыт кебек кысып тора. Нәрсәгә дип синең дөреслегең өчен

балаларын сыныктан аерсын, фатир юлын киссен, ә? Турысын әйткәндә, синең өчен дәреслек дигән нәрсә, бүтәннәргә нуль ул. Нульне якларга башыма тай типмәгән. Ике-икең дүрт кебек тормыш арифметикасын белмисең, брат! Ташла шул гадәтеңне!

— Тьфу! Нинди уты сүнгән бәндәләр белән яшәргә туры килә,— диде Надир бер йөрәге белән сүгенеп һәм каргана-каргана баракларга таба китте. Зәй аны йомшак җәеп катыга утыртырга, ягъни сүз белән җиңәргә исәпләгән иде. Теге шуны тиз сизенде.

Әйе, Надирда начальникларга карата ниндидер начар фикер була. Каян килә бу? Надирның әтисен теге елларда утырткан булганнар. Алар шәһәрдә яшәгән, әтисе мастер булып эшләгән. Менә шул чакта аны кулга алганнар. Начальниклары корткычлыкта гаепләп язып биргән. Хәзер әтисен аклаганнар. Ул лагерьда үлгән, кайда, ничек — билгесез. Ләкин адәм баласыннан нәрсә булса да кала. Үлеләр тереләрнең чабуларына ябыша, дигән борынгылар. Надир мине Тугаевка каршы котыртырга теләп бик тырышты. Аның төрле кимчелекләрен әйтеп, менә кем ул синең Тугаевың, карьера артыннан гына куа, ди-ди яманлый. Мин Надир салган кармакка чиертмәдем, шуңа бик каты ачуы килгән иде.

Зәй баракка керә торган баскычтан ук ишетте, бала елый иде. Озын коридор буйлап атлаганда шул аваз аның йөрәген телем-телем телгәләп әрнетте. Сулыш юлларын кысты. Бу Рәмилә дә бигрәк бичара булып чыкты, дип, хатынына ачуы килә башлап уйлады ул. Чөнки Рәмилә бер эшнең дә җаен белми иде. Бер гади генә эшкә тотынса, юньләп башкарып чыга алмый. Аш пешерергә керешсә, йә тозлы, йә тозсыз итә, түгеп-чәчеп бетерә. Шулардан чыгып бер нәтиҗәгә килелә: димәк, ул бала багуның да рәтен белми... Ишекне ачып керүгә, борынга таныш ис килеп бәрелде. Ул ишек каршына элгән пәрдә арасыннан әчкә башын тыгып карады. Рәмилә баланы караватка куйган да, үзе бала өстенә иелеп утырган, ике битеннән күз яшьләре агып төшкән. Әллә минем кайтканны да сизмәде инде? Бала елавы тәмам зиһенен алган шикелле. Нишләргә соң? Моның бер азагы булырмы?..

Тиз-тиз өстен алыштырып, ишек төбендәге юынгычта чистарынып алды да эчкә узды. Бала елый-елый тәмам хәлдән калып, ыңгырашып ята иде. Рәмилә башын борды:

— Әз генә «смесь» имде, ләкин имезлекне кире чыгара да, еларга тотына,— дип тезде ул үзенең сүнек, гаҗиз тавышы белән.

— Врач килдеме?

— Карады, авыруы юк шикелле, ди. Тамагы ачка елый ул,— дип, кухняга язу калдырды. Күкрәк сөте табыгыз, ди.

— Ансын врачтан башка да беләбез лә!— Зәйнең врачка өмет итүе, аңардан балага ярдәм көтүе әз генә дә акланмады. Ул кулын өметсез селтәп куйды, балага озак карап торудан йөрәге телгәләнә башлап, карашын тәрәзәгә борды. Эчендә бүреләр тырмашкан шикелле итә, өзелеп ашыйсы килә. Билгеле, ашарга әзер түгел. Хәзер ашарга пешерергәме, әллә күкрәк сөте эзләп чабаргамы? Ничек үзең турында уйларга мөмкин, ахмак, дип, үзен тирги-тирги киенергә тотынды. Өстәлдән колбаса һәм ипи телеме эләктерде.

Тудыру йорты 1 — поселокта иде. Зәй, башын аска игән килеш, кызу-кызу атлый. Борчылудан гына башын түбән имәгән ул, ә бәлки танышлар очрап хәлне сорашмасыннар өчен дә шулай итә иде. Ана аңлатырга кирәк, ә ул икейөзләләнеп ах-ух килгән булыр, ялганлар, ниндидер булмас ярдәм белән өметләндерер. Адәм баласы бүтәнгә булышу кирәк булганда гомуми сүзләргә бирелә, шул сүзләр артына поса. Синең балаң аның өчен нуль. Передача бүлмәсендә тәрәзә ябык иде. Бер-ике ир-ат кына көтеп утыра. Ул тәрәзәне үз кеше кебек кенә шакыды. Фалия апа шуннан бер кечкенә шешә ана сөте биреп җибәрә иде. Билгеле, Зәй дә буш кул белән килми, ул тикле үк мәнсез түгел. Әмма бүген тәрәзә

ачылмый да ачылмый. Тик бераздан гына тәрәзә тактасы кырыйга шудырылды, анда бүтән шәфкать туташы иде.

— Фаля кайтып китте,— диде Зәйне танып, сораганны да көтмичә. Башына суккан кебек итте бит, шайтан. Зәй ни әйтергә белмичә күзен текәп тора иде. Сөт... дип авызын ачуга:

— Юк, калдырмады,— дип, икенче кешегә күчте.

Типте бия тәртәгә, авызын корт чаккыры!.. Зәй Фалия яши торган баракка чапты.

— И минем азапланучым,— диде Фалия аны ишектә күреп.— Сөт арттыра торган хатын бүген чыкты. Бүтәннәренең артык сөтләре булмады. Бәла, бик кирәктер инде...— Аның йөзендә йөдәтеп бетердең, дигән чалым сизелмәде. Ул баланы түгел, Зәйнең үзен жәлли сыман иде.

— Әйдә, хатынның өенә киттек, бәлки бәхетең булыр,— диде Фалия ишегендәге инглиз йозагын бикли-бикли.— Ышаныч әз әзен... Фалия тиз кузгалып, кызу йөрүчән иде. Зәй аның артынан иярде. Алар озын бер баракка барып керделәр. Коридор буенча ишек төпләрендәге чиләкләргә абына-сөртенә иң кырый бүлмә ишегендә туктадылар. Эчтән ачы-ачы кычкырган тавышлар ишетелә иде. Зәй Фалиягә биш сум акча сузды, сөте булса, шуны бирерсең, диде. Бик озак шакыгач кына ишек ачылды. Фалия керде. Зәй калды. Йөрәге дөп-дөп тибәргә кереште: буламы, юкмы?

Фалия бик тиз әйләнеп чыкты. Аның йөзеннән сөтнең булмавы күренде. Шулай да ата кеше аңа ничектер механик рәвештә иярде. Алар тудыру йортына килделәр. Зәй эчтән генә бу кызны бимазалавына уңайсызлана, ояла башлады. Ләкин бала хакына оятыңны да югалтасың икән. Безгә кем инде ул, ә кайчаннан бирле ярдәм итеп килә. Авырыксынуын сиздергәне юк. Әллә ул бик сирәк очрый торган, элек кенә булган берәр изге жанмы? Хәзерге вакытта мондый затларның булуына ышанмас идең, әмма менә күз алдында.

Подъездда Фалия кулыннан кечкенә сөтле шешә алганда Зәй куенынннан чыгарып аңа тартмалы шоколад конфет сузды, рәхмәтләрен яңгыр итеп яудырды.

— Кирәкмәс, житәр инде,— диде Фалия карышып. Ул бүләкне алмас өчен һәрчак тартыша, Зәй һәрберсенә бер сәбәп уйлап чыгарырга мәжбүр була. Юкса сөтнең файдасы булмас, дип шүрләтә, йә араны бозмыйк, мин чын күңелдән,— ди-ди, кызны чигенүдән туктата. Бүген нәрсә диярга инде?

— Алайса бүтән килмәсен дисеңмени?— диде Зәй рәнжи башлаган төстә. Бу сүзләр кызга тәэсир итми калмады.

— Ну үзең дә мине какшатыр жай табасың,— дип тартманы алып редикюленә салды. Алар I-поселок белән яңа шәһәрне тоташтырган дамбага кадәр бергә бардылар. Фалиянең бит-күзләреннән нур бөркелә, һәр сүзе шул нурларга төренә иде. Ул нурлар ирексездән жанга үтеп керәләр һәм зиһенне чуалталар. Әй, адәмдә хисләр тотрыксыз да инде! Утка омтылган күбәләк кебек, шул нурга тилпенеп куя.

— Больницага сорагыз, болай авыр бит?— диде Фалия.

— Врачка туры килә алмыйм, Рәмилә сорадым, ди, урын юк дип әйтте, ди.

— Ул бик йомшак, кыюсыз күренә, әллә авылныкымы?

— Шәһәрнеке...

— Ә нишләп юньләп русча белми, житмәсә, институт бетергән? Шәһәрдә яшәп инде...

— Яңа бистәдә гел татарлар гына бит. Мәктәпләренең дә рәте булмагандыр.

— Нишләп сөте бик тиз беткән, шуны һич аңламыйм. Ишеткәнем юк иде.

— Сәбәпләре күп инде, төгәл әйтүе читен.

— Әллә эчтә берәр авыруы бармы? Яисә элек булганмы? Аннары азыкның да тәэсире булмый калмыйдыр.

— Гәүдәгә таза, ашау-эчү нормаль... Гаҗәп...

Фин йортлары тезелеп киткән урамнан атлаганда бер биек рәшәткә артыннан Фалиягә дәштеләр. «Нихәл, кер әле?»— диде ягымлы бәрхет тавыш. Фалия тар капкадан эчкә үтте. «Исәнмесез, Рита Халитовна?»— ди-ди шатланып исәнләште. Зәй рәшәткә ярыгыннан күрде: бу контор директоры Тугаев хатыны лабаса. Ул чәчәкләр түтәлендә, кулында шланг. Шушы особнякта яшиләр, димәк. Кайчандыр урамда очрап, Тугаев Зәйне хатыны белән кыска гына таныштырган иде. Уртачадан калкурак буйлы, киң иңле, аксыл тулы битле, һәр төшеннән мөлаемлек, затлылык бөркелеп тора. Йөз чалымнары аның кул җитмәс горур булуын искәртә. Тик ни хикмәттер, чыраеннан, озынча күзләреннән әйтеп биреп булмый торган моңсулык саркый. Нәрсәдән икән ул? Ике медичка икы-чыкы килеп сөйләшә.

Күп тә үтми, Фалия чыкты. Рита Халитовнаның пациенты бездә ята, шуның хәлен белеште, дип аңлатты Фалия. Бераз баргач ул туктады. Анда, диде, бүген генә тудыру йортыннан чыккан хатынның хәлен белергә кирәк, баласы тернәксезрәк иде. Ни өчендер чыгарга бик ашыкты. Ирем җилбәзәк, дип борчылды... Фалия тыкрыкка кереп китте. Ул күмелсә дә, аның нурлары Зәйгә ияреп бара иде. Нигә икән Фалия белән очрашкан саен, кызның күз сирпүләре, елмаюлары аның күңеленә серле ефәкләр булып урала. Өйгә кайтып Рәмиләгә, балага күренергә уңайсыз була башлый. Фалиянең ире бар микән, үзен шактый бәйсез тота шикелле? Фалия аңа нигәдер бик ягымлы, ниндидер өмет күзгата торган итеп карый? Тиле бәрән, сиңа гына шулай тоеладыр. Юк, юк! Андрей Казан әйткәне бар: һәрбер ир-атның яшерен йөрәк сере була, имеш. Сер — шул үзе хыял иткән хатын-кыз. Адәм баласы хыял белән дә яши. Тормыш аны бәргәләсә-суккаласа, хыялда ул рәхәт чигеп ала. Хыялда аны беркем кыйнамый, теләгәнчә ярата-сөя...

Йа хода, бала төне буе бер уянмый йоклады. Нинди рәхәт икән. Менә күкрәк сөтенең хикмәте. Тамагы туйгач, изри дә изри. Эче дә күпми. Йокы зур дәва икән. Баланың төсе үзгәрә. Ана сөте һәр нәрсәгә шифалы шул. Нишләп Рәмиләгә һаман сөт төшми икән? Хәер, врачлар укол ясый башладылар, булыр дип өметләндерәләр...

Бүген вахтага чыгасы көн түгел, Зәй бала янында булганда Рәмилә уколга барып, башка эшләр эшләп кайтты.

Читкә куеп яки соңартып булмый торган бер хәл бар иде. Зәй шуның буенча йөри, дәресрәге, йөрергә мәҗбүр. Хикмәт шунда, аның туганнан туган абыйсы Сәлимне шәһәрдән ерак түгел Вәли хуторы дигән төштә үтереп киткәннәр. Көпә-көндез. Экскаватор белән торба өчен траншея казып ятканда. Тракторның кайбер частьларын алганнар. Бүтән бер нинди эз юк, күрүчеләр дә юк. Ничек болай, дип баш вата Зәй, кеше энә түгел бит төшәргә дә югалырга? Менә нинди әйбәт кеше кинәт юк булды. Милиция эзләнде-эзләнде дә берни таба алмады. Аларның тырышлыгында формаль эшләр бик нык сизелә иде. Зәй ачуланышты, үҗәтләнде. Җинаять эзе табылмады дип «дело»ны япмакчы булгач, тавыш чыгарды, прокурорга жалоба язды. Шуннан соң «дело»ны тикшерүчегә бирделәр. Ефимов фамилияле өлкән лейтенант. Үзе керәшен икән. Бик әкрен кыймылдый торган кеше кебек тоела. Әллә Зәйгә генә шулай күренә инде? Әллә берәр нәрсә төртүне өмет итәме, белмәссең. Маңгай астыннан гына мәче кебек күзләрен кысып карый. Бер дә җинаятьне ачар төслегә охшамый, әллә ни омтылышы да сизелми. Берсендә әйтеп куйды: татарлар эше бу, төгәл шулай, диде. Татар бер-берсен аяп тормый, чөнки кан кардәш бит. Ә керәшеннәрнең шундый эшен ишеткәнең бармы? Юк, конечно! Теге заманда Иван патша барча татарларны чукындырып бетергән булса, наять буласы иде...

Нигә миңа шундый сүзләр әйтә?— дип уйлады Зәй аңа җавап таба алмыйча. Рәсми фикер шулайдыр дисәң, ул бит рәсмине белгертмәскә тиеш?

Зәйнең келт итеп исенә төште: «Ә теге Федотовкада бер рекрут эчеп, үзе кебек бер егетнең эченә пычак тыккан, күргәзмә суд ясадылар», диде, Ефимовның ачуын китермәслек итеп, йомшак кына. Анда бөтән мәсьәлә, диде Ефимов калын иреннәрен әкрен генә кыймылдаткалап, көнләшүдән кызып киткән. Көнләшү бик хәтәр нәрсә, үз башына төшмәгән белми. Көнләшү кешенең зиһенен ала, күзен томалый, адәм баласы үз-үзенә хуҗа була алмый. Шуңа күрә статьясы да башка. Йомшаграк статья... Кеше психологиясен исәпкә алалар.

Зәй аның бу сылтавына каршы берни дә әйтә белмәде. Тикшерүче яхшырак хәбәрдар иде, билгеле.

Ефимов өч бүлмәле фин йортында, «особняк»та яши иде. Өйгә кил, дип чакырды. Ул, ахры, Зәйнең гади, беркатлырак кеше булуын сизеп алган булса кирәк. Аның янына шактыйдан бирле килеп йөри иде. Башта рәсмилек рамкаларында гына сөйләшү-аңлашулар барды. Берсендә эштән кайтышлый очрашканда юл өстендә, ресторанга кереп утырдылар, Зәй сыйлады. Шуннан соң арада бер-берсен аңлау мөнәсәбәтләре барлыкка килә башлады. Әлбәттә, якынаю мөмкин түгел. Ул закон кешесе, моны гына Зәй аңлый. Шулай да ышанычны ныгыта торган мөнәсәбәт булсын иде...

Өй тирәсендә бакча. Һәр төштә пөхтәлек, эшчәнлек сизелеп тора. Хатыны өйдә юк шикелле. Шуңа Зәй үзенең тартыну киеренкелегеннән арына төште. Шешәне дә куеныннан курыкмый чыгарды. Һәм Ефимовның йөзенә текәлде: ничек кабул итәр? Ләкин Ефимовның таш йөзендә бер җыерчык сызыгы да тартылып карамады, шулай да күзләренә җылылык әсәрәте чыкты. Ул бакчадан редискә, суган кыяклары өзеп алып керде. Шул мәлдә әллә каян гына бүлмәдә 7—8 яшьлек сары малай пәйда булды.

— Әти, ашыйсы килә,— диде ул маңгаен җыерып, ничектер туры карамыйча.

— Әниең калдыргандыр бит?— Ефимовның йөз-төсеннән бу өйдә хатын баш икәнен чамаларга булыр иде.

— Бикләп киткән...— Малайның сүзеннән Ефимов уңайсызлана башлаган кебек итте, тизрәк кесәсеннән алып, аңа вак акчалар сузды. Малай, җәйгән учында акчаларны күңеленнән санап:

— Морожныйга да бир,— диде кыюланып. Хәйләкәр нәрсә, кунак алдында әтисе баш тарта алмаячагын белеп сорый ул.

— Ярар, тагы «самоделка» сатып алыргамы?

— Юк. Алайса кинога?

— Мә, энем, әйбәт картина бара,— дип, Зәй малайга берлек сузып маташа иде, теге ярты юлдан тартып алды да ишеккә атылды.

— Минем асрамага алган пацан,— дип аңлатты Ефимов, берәр рюмка салып куйгач.— Ну бандит булып бара, һич тыңлатыр хәл юк. Ачулансаң, чыга да кача, шәһәр бетереп эзлибез. Просто бәла! Хатын белән тыныч яши идек, хәзер көн дә шуның аркасында тавыш. Син аны узындырасың, дип телә.

— Алганга үкенәсезме әллә?

— Соң икебезнең дә нервыларны мунчала итеп бетерде ләбаса. Ул өмет өзгән мәгънәдә кулын селтәде дә рюмкасына үрелде.

Аннары эш турында сөйләшә башладылар. Җинаять булган басуда шул көнне элемтәчеләр эшләгән дигән версия бар иде. Ефимов шуның буенча тикшереп караган, контордагы нарядларны актарган.

— Барысы да ялган булып чыкты,— диде ул, редис кетердәтә-кетердәтә.

— Ну? Ничек алай?

— Элемтәчеләр ул якка барып та карамаганнар. Вахта путевкаларын тикшердем.

— Нарядны премия өчен тутырганнармы?

— Шайтан белсен, эт баш, сыер аяк... Син тегендә бара алмассыңмы?— Ефимовта Сәлим эше белән кызыксыну, җинаятьне ничек тә ачарга омтылу чалымы беленеп калды. Ул беркөн Зәйдән үтенгән иде: Тимәш поселогына бар, «иснәнеп» йөр, дигән иде. Җинаять эшләнгән җир авылга якын, кем дә булса, нәрсә дә булса белми, күрми калмас, дигән иде. Зәй анда барып, үзләренең элеккеге танышларында тәүлеккә якын торып кайтты. Урамда очраган һәр кешедән сорашты, белеште. Ләкин беркем дә берни әйтми, белмим, дип, тизрәк сүзен өзеп, Зәй янынан китәргә ашыга иде. Бәладән башаяк. Милициядән курку кешеләрнең канына сеңгән.

— Минем ике-өч шикле кешем бар, шуларны кысмыйча да булмас. Трактор частьларын колхозга илтеп сатмагайлары. Эх, элек әйбәт иде, хәзер курыкмый башладылар.

— Үткәннәр кешегә әйбәт булып тоела, ди...

— Курку зур нәрсә,— диде Ефимов,— курку булмаса, адәм баласы ерткычка әверелер иде. Курку гына аны рамкаларда тота. Юк, әллә син «сознательность» дип әйтмәкче буласыңмы? Нинди беркатлылык!— Ефимов елмайды, битендә җыерчыклар пәйда булды, эре, сары тешләре күренде.

— Адәмне куркуда тотарга кирәк: курку идарә итә,— диде Ефимов йодрыгын төйнәп.— Тезгенне бушаттылар да менә нәрсә килеп чыкты...— Ул ниндидер үртәлү белән рюмкасын күтәреп куйды. Хәзерге иркенлекләргә тискәре караган бер генә кешене дә күргәне юк иде Зәйнең. Киресенчә, тормышның яхшыруына, кешегә мөнәсәбәтнең йомшаруына һәркем сөенә, дәрт белән эшли. Һәр тармакта эшләп чыгаруның бермә-бер артуы әнә шул элеккеге куркыту әсканҗәсеннән ычкынуның туры нәтиҗәсе бит. Ә баксаң, аның икенче яклары да бар икән....

Яңа долото куеп, колонна төшерделәр. Механизмнар тигез генә эшли башлады. Зәй тормозда басымны әз генә арттырган иде, колонна дерелдәргә тотынды. Токым артык каты иде, басымны киметергә туры килде. Әллә насос басымын әз генә арттыра төшәргәме? Алай итсәң, шарошкалар нык кызып, тиз ашалып бетәрләр. Зәй тормоздан тоткан кулы белән сизә: долотоның тешләре токымны ничек кимерүен, турбобурның нинди киеренкелек белән эшләвен, токымның кай төше каты, кай төше йомшаграк булуын чамалап бара. Һәр чыжылтау яки тыну, яки ритмның әкренәюе, ешаюы аны сагайта. Шуңа күрә бер минут дикъкатьне читкә юнәлтергә ярамый. Фәкать шундый әмәлләр белән генә төрле күңелсезлекләрдән качарга мөмкин. Билгеле, күпме генә барча хәлләрне исәпкә алып эшләсәң дә, көтелмәгән нәрсәләр сагалап кына торалар... Шулай уйлап бетерергә өлгермәде, кинәт насос басымының кимүен сизеп алды. Үзе ышанмыйча индикатор шкаласына күз төшерде — әйе, дөрес шул. Өскә караган иде, битенә измә сыекчасы яңгыры килеп бәрелде. Кожан башлыгын киеп, сузылып карый башлады. Әһә, насос көпшәсе тишелгән икән. Зәй, тормозны предохранительгә куеп, станок янынан алга үтте һәм тышта муфталар майлап маташучы ярдәмче Сәяхка кычкырды. Ул эшнең нәрсәдә икәнен тиз күреп алды, тимер шкафтан кирәкле инструментлар эләктереп, баскычтан менеп китте. Насос көпшәсенең тишелгән төшенә тимер атлама кигертеп, шөреплә тә куйды. Молодец, Сәях, дип кычкырды Зәй, инструмент янә тигез генә эшли башлады.

Культбудка янына брезент өсле «газик» килеп туктаганы күзгә чалынып китте. Тугаевныкына охшамаган ниндидер яңа машина. Кем булыр бу? Әллә милициядәнме?

Бераздан кешеләре күренде. Культбудка артындагы чишмәдә биткулларын юып, кульяулыклар белән сөртенә-сөртенә киләләр. Какча гәүдәле, нурлы чырайлы, зәңгәрсу плащ, галстуктан, җиңел адымлысы контор директоры Тугаев, икенчесе — трестның баш геологы Байкин икән. Ул түгәрәк төксе йөзле, юаш кыяфәтле. Күзлеге түгәрәк кысалы. Эш шунда, Зәй эшли торган бригадада геология лабораториясе тикшерү-

тәҗрибә уздыра. Икенче төрле әйткәндә, план-проходкага зыян китермичә, геологларга булыша. Токымнар алырга ярдәм итә, аларның кайбер таләпләрен үти.

Зәй, басымнарны бер җайга көйләде дә, тормозны Сәяхка биреп, тегеләргә каршы китте. Бередә өстән гел тамып тора иде, өсләрен пычратырга ярамас... Буровой ишегеннән чыгуга кояш нурлары көлтәсе күзләрен чагылдырды. Ул күз кабакларын кыса төшеп карады, Тугаевның сузган кулын тотты.

— Ничек, тәртипме?— диде ул. Зәй баш какты да Байкин белән кул кысышты. Тугаев сөйләп китте:

— Бер бик таза гәүдәле егет кечкенә буйлы, какча кызга өйләнгән, ди. Кешеләр аптырашып калганнар һәм сораганнар: мондый әзмәвердәй гәүдәң белән ничек шундый чикерткәне алдың, дигәннәр. Егет тегеләргә: мин явызлыкның кечерәген сайладым, дип җавап кайтарган. Шуның шикелле, мин дә, геофизика лабораториясен тагарга иткәннәр иде, менә геологияне сайладым...

— Явызлыкның кечерәген димәкчесең инде,— дип елмайды Байкин һәм күзлеген рәтләгән итте.

— Гомумән, явызлыктан башка гына яшәү мөмкин түгелдер, ахрысы. Нишлисең, дөньяны без кормаган. Менә фәлән эшне үтә, дип хуҗа боера. Тырышып шуны башкарасың. Бераздан беленә, бу эш ялгыш булган икән! Кем гаепле? «Козел отпущение» ясарга кирәк. Кемне? Әначальникның гаепле булуы мөмкин түгел. Системада каралмаган. Номенклатур шәхес партия белән персонлаштырыла... Стрелочникка шелтә, ягъни миңа...

— Беләм,— диде Байкин ихлас сүзләргә күңеле булып.— Ә бит гаеп судка бирерлек, миллион сумнар... Номенклатур шәхеснең гаебен сиңа сылтаганга күрә, җазаның да шелтә кебек бернигә тормаслыгы гына бирелә... Бүре дә тук, сарык та исән...

— Түгел шул, бүре дә ач, сарык та беткән.

Алар күперчектән төшеп, машина янына килделәр.

— Сезнең аякка бәйләнгән таш булмабыз,— диде Байкин.— Түләүне әзсенәсезме?

— Шулай сөйләшик, Байкин, синекеләр тәүлегенә икеме-өчме, ансы үз эшегез, пробалар алып тора, шуңа күрә өстәмә колонналар төшермәсәгез иде?...— Тугаев эшлекле, кайгыртучан сөйләшә иде, тегенең йөзендә килешүчән сызыклар чыкты...

— Бер дә шәмнәр төшермичә генә булмас, ләкин сезнең белән дә санашырбыз. Бер мичәүгә җигелгәч, үзара тарткалашудан файда юк,— дип, Байкин Зәйгә таба борылды.— Бүген проба токымы алырга килделәрме?

Зәй, юк дигәнне аңлатып, баш селкеде һәм кесәсеннән бүген забойдан чыккан вак ташларны учына алды. Елык-елык килеп торуларына кызыгып, кесәсенә салган иде. Байкин бер ярчыкны кулына алып, бик кызыксынып карады.

— Бу аронит дигән кальцит, бередә 700 метрда, шулаймы?

— Точно,— дип сөенде Зәй.— Әллә нефтькә ишарәле торган нәрсәме? Нефтьнең юлдашы?..

— Нефтьнең юлдашы булмый,— дип, Байкин ярчыкның кырларын күзенә якын ук китереп тикшерде.— Ул үзенә табышмак, серле «шәхес», каян, ничек яралганын төгәл генә белмиләр.

— «Терро инкогнето» алайса, нәсел-нәсәпсез?— дип кеткелдәде Тугаев.— Җилдән туган, ә? Шуңа күрә дә нефть дөньяны тота торган аждаһага әйләнде.

— Ләкин нефть мәңгелек түгел, киләчәге чикле, диләр...

— Ансы җирдә берни дә мәңгелек түгел.— Тугаев кабина ишегенә тотынды, үзе культбудка ягына карый, Байкин рульгә утырды да, стартерга басты. Шулчак культбудка янына ПАЗ машинасы килеп туктады.

Тугаевның йөзе карангыланып китте һәм ул, башын ия төшеп, машинага таба борылды. Машинадан төшкән берәү аңа юнәлеп килә иде.

— Житмеш өчтә авария,— диде теге зур гәүдәле сары чәчле кеше.— Поглощение...— Кул кысышкач дәвам итте:— Цементка дип килгән идем.

— Складта юкмыни?

— Кайтып тормадым, беркөнгедән калган монда бар иде,— дип, сары чәчле ашыккан шикелле тиз-тиз таптанды. Кинәт культбудка ишеге ачылды, аш пешерүче апаның чәрелтек тавышы яңгырады. Тугаевны телефонга дәшәләр иде. Ул кәефе кырылган төс белән шунда юнәлде. Байкинның да чырае сытылды, ул рульдән төште һәм сары кедрәлегә текәлеп карап тора иде, теге аның карашын тотып алды, ничектер мондый чакта була торган ясалма елмаю чыкты йөзенә.

— Әллә Байкин инде?— дип, ниндидер юргалый торган адымнар белән якынлашты ул. Байкин исә аңардан йөз чөерергә уңайсызланып, хисләрен эчкә яшергән, берни булмаган кебек тора.

— Ә-ә, утта янмас, суда батмас Тартакиев,— дигән булды ул.

— Сине үлгән дигәннәр иде, озак яшәрсең...— Тартакиев дусларча елмаеп кулын сузды. Байкин әдәп өчен генә аның бармак очларына учын тигезеп алды. Алар танышлар, ләкин араларыннан кара мәче үткәнлеге күренеп тора. Теге сугыштан соң ук елларда бергә эшләгәннәр һәм бик нык дошманлашып аерылганнар иде. Тартакиев дошманлыкны эченә йота белә торган шикелле тоела, Байкин исә рәнжетүне тиз онытa белми кебек, һаман очрашудан йөзе яктырмый. Дошманлашуга ничә еллар үткән югыйсә. Тартакиев, үзенең гаебен таныгандай, Байкинга ничектер куштанлык күрсәткән сыман иде.

— Без синең белән илледә аерылышкан идек, хәзер алтмыш дүрт. Байтак гомер. Ничек биредә?— дип сорады ике арадагы уңайсызлык сызыгын үтү өчен.

— Язмыш уйный кеше белән... Кайда кушсалар шунда...— Тартакиев маңгаенда сары чәч алкаларын селкетә-селкетә кеткелдәп алды. Чыннан төп гаеп әллә аңарда булганмы? Тартакиев рәнжетүче, ә Байкин исә рәнжетелүчеме?

— Ни кушсалар, шуны үтәүче, ә?

— Сорап торасың тагы, кем шулай түгел соң?— Тартакиевнең тигез ак тешләре күренеп китте, зәңгәр күзләре кысылыбрак ишарәле карады. Байкин уйлап алды: ул үзен тамчы да гаепле санамый бугай. Намусында берниндн тап юк шикелле җиңел сөйләшә.

— Ай-бай, теге чагында «гроза» идең, ә?— Байкин аңа бер шырпы кадап алырга булды.

— Заман ничек булса, адәм баласы да шулай. Менә хәзер заман йомшарды, ләкин хәерлегәме ул?— диде Тартакиев ничектер зурдан фикер йөртергә хакы бар төстә. Аның интонациясендә теге заманнарны юксыну ишетелеп калды. Әйе, үзенең кырыс холкы белән Тартакиев ул заман кешесе иде. Заман усал булганда, аңа усал холыклы кешеләр кирәк шул.

— Нинди эштә?

— Мастер, аварияләр буенча...— Тартакиев элеккеге танышы алдында югарырак дәрәҗә белән күренергә теләр иде, ләкин булмаганны әллә каян алып булмый.

— Син бик үсәргә тиеш идең, әллә берәр эш белән яндыңмы?— диде Байкин аның югары күтәрелмәвенә ышанып җитмәгәндәй...

— Булды инде, булды,— дип мыгырданды Тартакиев машинасы ягына карап һәм ашыгу хәрәкәте ясап...— Без түң агачларга ярый инде, син укыган кеше, син дә күтәрелә алмагансың кебек, ә? Якладыңмы хет?

— Мин андагы икейөзлелеккә, әшәкелеккә чыдый алмадым, провинциягә качтым, натурага, табигатькә...— Байкин хәзер гаепле кеше кебек кулын селкеп куйды. Йөзендә нур яктылары күренде. Хәзер икесе дә тигезләшкән төсле булды.

— Без үзебезнең уңышсызлыкны акларга күп сәбәпләр табабыз. Намус тынычлыгы өчен сәбәпләр артына посу адәм баласына хас сыйфат.

— Әйе, хак әйтәсең, шайтан алгыры!— диде үртәлеп Байкин, үз-үзенә ачуы килгәндәй. Ул арада Тартакиевны шофер дәште. Цемент пакеты күтәргән иде. Тартакиев аяк кагып саубуллашты да иптәшенә булышырга ашыкты. Ул исә Байкинның хәтеренә Платон Никитичны китерде. Артык намуслы кеше иде, мәрхүм. Үзе мине өйрәтә: намус ул комачау итә торган сыйфат, аңа әһәмият итмәскә тырыш, ди иде. Хәзер адәм балалары намус ише иске режим калдыгы белән санашмый һәм дөрес эшли. Без патша заманы кадрлары, намус саклаган булып, үзебезне чикләп яшәдек. Ә бу чикләү прогресска зыян гына китерә иде. Без совет чорында да намус дигән нәрсәне ташлый алмыйбыз, чөнки ул ана сөте белән кергән. Намуска ябышып ятканда без үсә, күтәрелә алмыйбыз... Үзе шулай миңа наставление бирә, үзе һәрчак намуслы булып кала. Шуның өчен үзен-үзе тирги, үзенә ачу итеп, көннәр буе бер сүз дәшмәс иде... Көньяк Уралда аларны эш бергә китереп бәйләгән иде. Эш барышында нигәдер Тартакиев Платон Никитичка карата аерата рәхимсез булды. Шактый үчекте дә, һаман ирештерә иде: сез укыган кешеләр, укыган кеше имансыз кеше ул, дип әйтә-әйтә каргана, эчендәге ачуын аңарга түкәндерә иде.

Платон Никитичның фаҗигале үлеме өлешчә Тартакиев өстендә бит? Ул шуны танымый, таныргa теләми, үзен чиста дип белә. Берни булмаган төсле сөйләшә. Бәлки шул таләп ителәдер. Көнкүреш, яшәү ыгы-зыгысында кемдер начарлыкларны үз намусына алырга һәм ул хакта бервакытта да үкенмәскә һәм дәшмәскә тиеш, диләр. Дөресме бу кагыйдә? Шулай булмаса, алга китеш юк, имеш...

* * *

Кечкенә генә бер өмет тә кешене әллә ниләр эшләтеп йөртә. Зәй белән Рәмилә, шундый өмет алгысытуына бирелеп, авыру баланы Бөгелмәгә алып килделәр. Андрей Андреич һәм аның белән бергә яши торган апасы аларны теләп каршы алдылар. Ике катлы таш йортта, бар уңайлыклары булган бүлмәләрдә яшиләр. Апасы Ленинградтан сугыш вакытында шушында эвакуацияләнгән булган һәм бүтән китмәскә ниятләгән. Андрей Андреичка сөргеннән соң бу шәһәрдә яшәргә билгеләгәннәр. Ул да йөрәк яралары белән бәйләнгән Ленинградына бөтенләй кайтмас төсле сөйләнә.

Табын әзерләп чәй белән сыйладылар, бала да, нидер сизенгән кебек, борчылмады, йоклады да йоклады. Өйләдән соң Андрей Андреич атаклы врачны алып килде. Ул да Ленинградныкы икән.

Зәй Андрей Казан белән (борынгы нәселләре Кырым грекларыннан булган. Ул бик еракта калган, тәмам руслашып беткәннәр. Сәер фамилия калган) Себердә солдат хезмәтен үткәндә, гадәти булмаган шартларда танышкан иде.

1949 елда Бөгелмә педучилищесы бетерелде. Зәй ике курс тәмамлаган көе калды. Аларны Минзәлә училищесына күчерделәр, ләкин Зәй анда бара алмады. Бердән ерак, икенчедән, матди як начар иде. Торырга өйләре юк, бүтәне дә юк. Бабаларыннан калган таш келәткә мич чыгарып, шунда тереклек итәләр. Колхозда күпме генә эшләсәң дә өй әмәлләрлек мая туплап булмый. Шуның өстенә әтисе — җил баш — эчкәли дә иде. Зәй үзләренең бүрәнә өйләре булмавына, әтисенең былагайлануына бик ояла иде. Укырга керүенә дә сәбәп шул нәрсәләр булды. Ләкин, хәерчегә җил каршы, диләр. Укуга төбәгән ук ташка тиде. Җиткән егеткә бер нәрсәсез авылга кире әйләнеп кайту, шулай да бик уңайсыз. Шулчак аңа военком очрады. Военкоматтан килеп, «военное дело» дәресләре

үткәрә, зачетлар ала иде. Ул әйтте: «Барыбер армиягә китәсе, хәзер әйбәт җиргә набор бара»,— диде. Зәй берсүзсез ул ташлаган таякка тотынды.

Аларны Свердловскидан ерак түгел Аять станциясенә китереп төшерделәр. Беренче булып һәр тарафта бу якларның кырыс булуы күзгә ташланды. Һәм Зәй, ачынып, военком аны алдаганлыгын аңлады. Кемгә ышанасың, шуңардан алданасың, диләр иде, хак икән. Ярый, булган эш булган, кире кайтарып булмый, мать якасына!

Станциядән китеп, сары таулар арасыннан бардылар, ниндидер Сатра поселогы кырыннан үттеләр, сөргенчеләр яши торган җир, диде кемдер. Шуннан үргә күтәрелеп берничә иске бараклар торган мәйданга килеп туктадылар, взводлап баракларга тутырдылар. Анда ике катлы нарлар иде. Тәрәзә өлгеләре ватылып беткән. Зәй төне буе күз йома алмады, барча тишекләрдән әллә нинди салкын җил ыжгырып тора иде. Яңа җиргә ияләнү болай да бик кыен иде.

Күбрәк эшләтәләр, әз генә хәрби-политик занятиеләр дә була. Шунысы яңалык иде, эш өчен түләнә икән. Эшчеләрнең уртача эш хакы, чамасында дип аңлаттылар. Билгеле, авыр эшкә күбрәк түләнә, җиңеләнә — әз. Сверхсрочный прораблар бик кырыс — ике сөйләшмиләр. Егетләр әйбәт түләнә торган эшне сайлыйлар, өйгә акча белән кайтырга ниятләре. Тик түләү белән генә булмый. Үз-үзеңне тотышыңа, политзанятиеләрдә катнашуыңа карыйлар. Һәр төштә сынау үтәсең. Кызыл сүз сөйләүче активистларга эшнең акчалысын һәм җиңелрәген бирәләр. Колхозда да шулай иде, бирергә дә. Ләкин Зәй кызыл сүз сөйли белми, чөнки кызыл сүзләр ялган, шуңа күрә аның бәхете гел авыр эштән булды. Шул тикле чынбарлыкны боза торган ул кызылялган сүзләрне ни өчен сөйлиләр, һич аңламый. Сөйли-сөйли ул ялганнар әллә чынга әйләнәме? Моны мин генә үземнең үшән башым белән аңлый алмыйм ахрысы? Юк, чынлап та мин ниндидер бик мөһим нәрсәне белмим шикелле, дип йокыга ятканда үртәлеп уйлый ул. Газеталар, радио: бездә муллык, туклык, дип дөреслеккә һич туры килми торган ялган сөйлиләр. Бөтен союз сөйли, кабатлый. Бөтен СССР сөйләгәч, бу ялган чынлык төсенә керәдер шул, дигән уй килә Зәйнең башына.

Зәй эшләгән һәм эшләячәк акчаларын чутлап ята да очына чыга алмый. Өйгә җибәреп торса, әтисе эчеп бетерер. Юк, монда книжкәгә җыелып барсын. Ничек активист булырга да ничек командирларга ярый белергә, шулай итеп төшемле эш эләктерергә? Акча өчен йөз ертсак да гөнаһ саналмас иде, юк, булмагач булмый инде. Чиләндерә торган авыр эш аның өлеше, язмыш биргән өлеше. Аннан котылу юк ахрысы, кара сакалың кая барсаң да, үзеңнән калмый...

Көтмәгәндә аның акча турындагы исәп-хисапларына каты гына зарбы булып алды. Бер активист айлык зарплата күләмендә заемга яздырып йөри иде. Дөресрәге, ведомость исемлегенә кул куйдырып. Зәй язылырга теләмәде. Шул көнне үк аны замполит чакыртты.

— Фаизов, син нәрсә саботаж ясыйсың? — дип тотынды ул тынкыш борын тавышы белән. Зәй үзенчә тәфсилләп сәбәпләрен аңлатты: торырга өй юк, әти эчә, гаилә зур, өсләре шәрә, тамаклары ач, диде.

— Син нишләп миңа капиталистик картина сурәтлисең, понимаешь? Мондый сүзләрдән беләсеңме ни исе килә? Өсләре шәрә, тамаклары ач, имеш! Бездә алай булуы мөмкин түгел...

— Мин чынны әйтәм, иптәш замполит, ни бар шуны! — Зәй ышандырырга теләп елап җибәрер дәрәҗәгә җитте. Теге һаман ышанмый, башын як-якка чайкый, әллә юри шулай итәме? Иң авыры — синең ихласлылыкка ышанмаулары.

— Ялганламыйм, булганны гына әйтәм, — диде Зәй күзеннән яшь атылып чыгуын үзе дә сизмичә.

— Булган фактка бәя бирә белергә кирәк! — дип кычкырды замполит.

Зәй аның сүзләренең мәгънәсен аңламады, үзен бик каты гаепләү дип белде. Нигәдер шунда үҗәтлеге чыкты, киреләнергә булды. Нишләтә ала ул мине, дип, беркатлы уй йөртте, үзенең маңгаеннан шыбыр-шыбыр каушау тирләре түшенә тамды. Замполит әрле-бирле йөренде, яңа хром күнитеге һәм бил каешы, портупеялары шыгырдады. Карарга кыла алмыйча йөриме, әллә Зәйгә нинди җәза бирергә дип уйланамы? Зәй курка башлады, моны политика белән үлчәп утыртып куймас дип ничек ышана аласың...

— Бар, уйла,— диде аңа китәргә кулы белән ишарәләп. Зәй теге исемлек тоткан активист килер дип көтте, ләкин ул күренмәде. Шуның шаукымы булгандырмы, аны әз акча төшә торган эшкә куйдылар. Баракларны ремонтлаганда чыккан чүп-чарларны мәйданнан читкә ташырга һәм яндырырга. Менә ул бер тәгәрмәчле тачкага төяп бик күп иске такталар, йомычкаларны бараклар артына чыгарды, корыракларын бергә өеп ут төртеп җибәрде. Учак янында ни сәбәптәндер эчеңне тырнаган борчулар тагы да җитерәк, үткенрәк булып хәтеренә килә һәм бәгыреңне телгәләп ала. Бу эшкә күчерүләре очраклымы, әллә җәзамы, дигән уй тынгы бирми аңа.

Кичке уңайда учак янына таудан төшеп баручы ике кеше туктады. Өлкәнрәгенең кулында озын саплы чүкеч, яңа шинель кигән яшь чырайлысының җилкәсендә нииндидер каты авыр әйбер тутырылган биштәр иде. Геологлар, ахрысы, дип беренче карашка бәяләде Зәй. Ләкин гаҗәп нәрсә, бу ике кеше бер-берсеннән тышкы кыяфәтләре белән генә түгел, күз карашлары, төсләре белән дә нык аерылалар. Ничектер аларны янәшә бергә эшләүчеләр итеп күз алдына китереп булмый иде. Алар, тәмәкеләренә ут алып, йотлыга-йотлыга тарта башладылар.

— Солдат, үзең кайсы яктан?— дип кызыксынды яше. Зәй әйткәч, теге: мин дә шул тарафтан — Урыссудан,— диде.

— Анда электр станциясе бар, ди...— Зәй моны бик мөһим нәрсәне белгән, кызыксынган төсле итеп әйтте.

— Сугышка хәтле үк сала башлаганнар иде,— дип юлчы төпчегән учакка ыргытты.— Башта торфка исәпләнгән, хәзер мазутка көйлиләр...— Ул иптәшенең тартып бетерүен көтә башлады. Тегесе бер дә ашыкмый иде, тагы берне кабызды.

— Андрей Андреич, киттек...— Яше авыр биштәрне иңенә алды, бавын җайлады, өлкәне чүкечне, кыр сумкасын элэктереп, аңа иярде.

Бу кешеләр ничектер серле тоелалар иде. Иртәнчәк тауга менеп барганда тагы учак янына елыштылар. Яңгыр тамчылап тора иде, бераздан яварга тотынды. Барысы да барак артына килеп сыендылар. Яңгыр өйләгә чаклы туктамады. Шунда Зәй боларның кемнәр икәнен һәм ни эшләп йөрүләрен белде.

Андрей Андреич Казан сәяси тоткын икән. Моннан ерак түгел, элеккеге монастырьдагы лагерьда тора. Ә яшьрәге Тугаев, демобилизацияләнгән офицер, тау институтында укый. Хәзер менә практикада. Шушы кыя, тау, үзәннәрдә беренче эзләнү эшләре башларга кушканнар. Ә сәяси тоткынны аңа ярдәмгә билгеләгәннәр. Аның токым тулы капчыгын көне буе күтәреп йөрергә тиеш икән. Менә сиңа кирәк булса! Андрей Андреич үзе Ленинградның Көнчыгыш институтында күренекле галим булган. Аны сәяси яктан гаепләгәннәр. Сәясәт дигән нәрсә адәм балаларынниләр генә эшләтми! Исәпләсәң исең китәр. Арысланны мәчегә әйләндерә, мәчедән куәтле арыслан ясый. Зур галимне түбәнәйткәннәр, илгә, фәнгә файдалы эшкә тотасы урында, мәгънәсез таш тутырган капчык күтәреп йөрергә мәҗбүр иткәннәр. Моны ничек аңларга? Юк, аңлап та, аңлатып та булмый. Галимне лагерьдан Тугаев имза биреп үз җаваплылыгына алып китә, кичен имза белән кире тапшыра. Билгеле, барча студентларга да сөргенчеләрне беркетмиләр. Тик ышанычлыларына гына. Тугаев ышанычлы, сугыш вакытында, аннан соң да «смерш»та хезмәт иткән. Галимне сәяси яктан тәрбияләү эшен дә аңа йөкләгәннәр булса кирәк.

— Ил эчендә һәр нәрсәгә, һәр эшкә политика куллану дөрес түгел,— дип сөйләнә Андрей Андреич. Тугаев маргарин ягып биргән ипине чәйни-чәйни. Көн саен учак янында Тугаев аны ипи белән сыйлый, үзе дә ашый...— Политиканы халыкара эшләрдә генә кулланырга кирәк. Юкса бу нәрсә үз кадрларың арасында ышанычсызлык тудыра. Кадрлар берберсенә ышанмыйлар — бу бит коточкыч хәл!

— Көфер сүз сөйлисең,— дип каршы төшә Тугаев.— Крамола!

— Политика — шикләнү, кешегә тамчы да ышаныч калдырмау бит. Намус белән эшлисең, иленне сөясең, ләкин сиңа беркем дә ышанмый. Шулай дөресмени? Совет кешесе — горур яңгырый, диләр, ә ул кешегә берәрсе ышанамы? Юк! Беркемгә беркем ышана алмый...

— Андрей Андерич, валлаһи, сине белеп утырткannaр,— дип уенынчынын кушып әйтеп куя Тугаев.

— Үзем дә шулай уйлыйм, шайтан алгыры!— диде ул үртәлеп, йөрәк ачысы белән.— Маркс әле теге заманда Бакунин, Нечаевларның казарма коммунизмына каршы көрәшкән. Моннан йөз ел элек.

— Алар террор аша эш алып барырга иткәннәр түгелме?

— Әйе, Маркс шуңа күрә аларның идеяләрен тар-мар итеп ташлый. Диктатурада террор булырга тиеш түгел, дип аңлата. Билгеле, диктатура үзенең яшәүчәнлеген якларга тиеш. Анысы хак. Ләкин гаепсез кешеләргә сәяси гаеп тагып лагерьларга ябу белән түгел, ә аңлату һәм тәрбияләү юлы белән...

— Менә сине, Андрей Андреич, тәрбияләп буламыни?— дип көлеп җибәрде Тугаев.

— Көн-төн без яхшы, без иң алдынгы, бездән дә әйбәт юк, дип язалар, сөйлиләр. Бертуктаусыз. Ә чынлыкта яхшымы соң без? Яхшы шулай буламыни? Кешеләрнең тамагы тукмы? Өс-башлары бөтенме?.. Шундый хәлдә адәм әхлаклы була аламы?

— Юк, Андрей Андреич, син төзәлмәс кеше, чынлап та!— Тугаев үртәлеп һәм гаҗизләнеп, башын як-якка чайкый.— Теге «Фома Неверующий» бар бит әле, син нәкъ шуның кебек.

Алар шулай сүз көрәштерсәләр дә, фикерләре капма-каршы килсә дә, «син», «мин»гә күчмиләр. Галим сүзләрен куркып сөйләми, эчендә кайнаганны әйтә кебек. Тугаев сагаеп кына аның кире сүзләрен үзенчә төзәтә, юк, ул нәрсә менә болайрак, дип үз каланчаңнан торып кына хөкем итәргә ярамый, дия-дия, ипләп кенә сөйли. Йомшак кына сурәттә галимнең фикерләрен уңайга борып бетерә. Зәй, барча сөйләгәннәрне аңлап җитмәсә дә, сүзнең тормыштагы гаделсезлекләр турында барганын сиземли. Зиһене ихтыярыннан тыш газетада язылган һәм радиодан сөйләнгәнне чынбарлык белән чагыштырып бара, бик күп аермалар күрә. Сүз белән гамәл арасында чыгып булмаслык упкын ята. Юк, явыз ниятле түгел Зәй, әмма ми тартмасында каршылыклы уйлар бәргәләнәсуккалана, ни өчен диген сорауга җавап эзли, таба алмый.

Юлчылар таудан бик арып төшәләр, учак янында сөйләшергә кайчак хәлләре калмый. Тәмәке тарталар да кайтырга кузгалалар. Ә иртән яңгыр сибәләп юлларын туктатканда, бәхәсләшәләр. Андрей Андреич үртәлә, гаҗәпләнә:

— Хөкүмәтнең иң яратмаганы крестьян булды, ул аны ниләр генә эшләтеп бетермәде, ис китмәле. Кара инде моны: без сөргенчеләр, зекләр көненә 500 грамм ипи алабыз, ә көн-төн җирдә казынган крестьянга берни бирелми. Шулмы тәртип, көлсәң көл, еласаң ела! Шул ук вакытта тугандаш социалистик илләргә күпме китә! Бушка бит! Ватанны сакларга кирәк чакта кем күкрәген куя. Шул ач үскән крестьян балалары түгелме соң?!

— Андрей Андреич, әйтәләр: «Что действительно, то разумно» диләр...— Тугаев аңа карап хәерхаһ елмая.

— Әйе, гегелянчылар әйтә. Ләкин ул тынычлану лозунгысы, аның белән яшәп булмый. Хөкүмәт крестьянның бар нәрсәсен алып бетерә, шул «разумно»мы?

— Юк, Андрей Андреич, син мине провоцировать итмә, мин «атылганнан калган чыпчык»...

— Мин провоцировать итәргә уйламыйм, фикерләрең чыныксын дим.

— Минем фикерләр утырган инде, какшатырга исәпләмә!

— Каршы фикер дә адәмгә кирәк, берьяклы гына булмас өчен. Берьяклылык катастрофага илтә ул.

— Борчылма, өстә мудрый башлар утыра,— дип, бирешми Тугаев.

Зәйне икенче эшкә күчерделәр. Шуннан соң ул юлчыларны күрмәде. Салынып бетмәгән котельный бинасы бар иде, шуны ашыктырып төзетә башладылар. Зәй, бер солдат белән тачкага салып, өскә измә ташый. Оста гына кирпеч салучылар бар икән, алар смена ярым эшлиләр. Акча да нык төшә иде. Әмма политзанятиеләр теңкәгә тия. Чыгыш ясарга кушалар. Зәй русча сөйләргә ояла, кайбер сүзләрне дөрес әйтми, ә рус егетләре көләләр, ирештерәләр. Сөйләгәндә солдатлар күп сорау бирәләр. Бер Нуникин дигән ефрейтор сорау белән каныга иде. Колхоз турында сүз чыккач, сезнең колхоз эш көненә күпме бүлде, дип сорадылар. Зәй ялганлый белми, замполит күзенә карап, ни әйтергә дип торды да: 300 грамм, диде. Аны җәй көне эшләгәндә ашап бетерәсең, әле өстенә чыга, ә кыш ни белән тукланып торасың?—ди-ди аңардан фикер суыралар. «Бәрәңгесе бары — бәрәңге белән,— диде Зәй.— Ә бәрәңгесе уңмаса, «голод» инде,— дип әйтеп салды Зәй ачуланып...

— Нинди «голод»?— дип, кинәт йөзе тартылып торып басты замполит. Ул һәр сәяси чатаклык туып өлгергәнче үк аңа балта чаба торган кеше.

— Кем әйтте «голод» дип, ә? Эчке дошман коткысымы? Фаизов кем котыртты сине колхозга каршы, ә? Понимаешь, мин сезнең баш миләрегезне турыйлармын. Ул сүзне син әйтмәдең, мин ишетмәдем...— Тавышы янаулы, бик кырыс иде.

Ләкин Зәйнең сүзен әллә кайларда ишеткәннәр. Стеналарның колагы бар, дип юкка әйтмиләр. Зәйне особый отделга чакырдылар. Анда бик җентекләп биографиясен сораштылар. Күп төрле сораулар бирделәр, гел 58 нче статья белән куркытып сөйлиләр иде.

Шуннан соң Зәйне әллә тагы да сынар өчен, әллә җәза итеп төнге сакка куйдылар. Моңарчы казармалардагы төнге дежур да җитә иде. Территориядә бер кеше урлар әйбер юк, ләкин, эчке дошманнар корткычлык эшлиләр, дип төнлә сак куялар. Зәй көндезен бераз йоклый, төнгә часовой булып постка баса. Карабинын җилкәсенә элгән көе территория буенча йөри. Төнге бердә аны үзе кебек үк җәзага дучар булган солдат алыштыра. Икенче взводныкы, сәяси хата ясады микәнни? Ялганлый белмәсәң, бер төштә дә рәт юк, шайтан алгыры...

Шундый бер хәл булды. Котельныйга кирпеч ташу, бушату, торба салу, чокыр казу өчен зекләрне китерә башладылар. Алар үзләренә аерым эшли. Надзирательләре кычкырып кына тора. Солдатларга берәрсе якын килә башласа, аны шунда ук куып җибәрә. Әшәке сүзләр белән кимсетеп сүгә.

Зәй төнге постта иде. Такыраеп беткән һәм караңгыда аксылланып беленеп торган сукмактан территориянең бер почмагыннан икенче почмагына атлый. Вакыт бик озак үтә. Караңгыда күз алдына китерергә, уйларга ансат. Зәйнең күңелен нурландыра торган рәхәт уйлары бар. Ул — Нәҗия. Педучилищеда укыганда рус әдәбияты түгәрәгендә танышып-сөйләшеп киткәннәр иде. Кызлар, егетләр аерым укыйлар, ә түгәрәкләрдә — бергә. Ул кыз һич көтмәгәндә аның җан түренә үтте дә керде һәм аны хыялый уйларга батырды. Теле үзе дә сизмәстән: Нәҗия, Нәҗия дип кабатлый. Нинди ягымлы исем. Шундый нур чәчеп торган исем Нәҗия генәдер, бүтән юктыр сыман. Ул кызның җанны биләп алуы шундый кинәт һәм көчле булды ки, Зәй бер мәл исәңгерәп, аңын җуйган кеше кебек йөрде. Йокысы качты, күз алдында җылы зәңгәр томан һәм

Нажия. Нәрсә бу? Зәй моңа әзер булмаган, шуңа күрә хисләрнең гөлт итеп кабынуыннан зиһене таралган. «Нәрсә бу?» — дип үз-үзенә сорау бирә ул. Һәм тагы Нажия күз алдына килә. Өлгергән карлыгандай чем-кара күзле, кыйгач кашлы, төз борынлы, леперләп торган биек күкрәкләре... аларын аңлатырга тел житми. Сөйләшүе бик мөлаем — үзенә бертөрле, күңелгә яктылык иңдерә... Ә язуы тагы да ягымлырак, матуррак: каян сүзләрен таба диген. Хатларын унар мәртәбә укыйсың, укыган саен нинидер яңа мәгънә табасың... йөрәклелегән әйт син, укуын дәвам итәргә Минзәләгә бармаган, районнарындагы урта мәктәпкә экстренно имтиханнар тапшырып, аттестат алган һәм Казан пединститутына читтән торып укырга кергән. Хәзер нефть шәһәре Акташта укытучы булып эшли... Постта Зәй гел Нажия турында уйлый һәм шулай хыялда йөзеп киңәнә.

Зәй котельный бинасы янынннан атлап барганда нинидер кеше авазы ишетеп, туктап калды. Нәрсә булыр бу? Стена буена подставка — платформалар, кирпечләр өелгән. Шулар артыннан теге аваз бик ачык булып ишетелде.

— Солдат, чыгар мине, коткар? — диде көчсез, басынкы тавыш. Басылып калган, дигән уй Зәйне тиз-тиз хәрәкәт итәргә кыстый иде. «Шулай да кем булыр бу?» — дигән сорау баш миен бораулый. Ул кирпечләрне, тачкаларны читкә алып юл ярды. Платформа сәндерәсе астыннан бер гәүдә башын сузды, кысыла-кысыла чыга башлады.

— Надзирательдән качып черем иткән идем, уркалар, сволочьлар, мине томалап калдырып киткәннәр. Имансызлар! Алар башны бетерергә дә күп сорамыйлар. Кәрткә оттырсалар, беттең! — дип, ул торып басты. Зәй шунда ук таныды: бу теге Андрей Андреич иде. Якынрак килгәч, ул да танып, сөенде: «Ә-ә, син мени әле, парин,— диде.— Рәхмәт сиңа, молодец! Әле бераз булса, ишетмәгәнгә салышып, китеп барыр иде. Беркемнән шәфкать көтеп булмый, парин...»

Зәй аңа мүк тәмәке бирде. Андреичның түбәсе күккә тигән кебек булды. Тик иркенләп тарта алмады, акыра-бакыра ике надзиратель килеп җитте, аны тирги-тирги алып кайтып киттеләр. Шуннан соң Андреичныерактан гына күргәләде Зәй. Ә котельный эшләнеп беткәндә зэкларне траншея казырга китерә башладылар...

Шулай Нажия төннәрен постта Зәйне эчтән генә җылыта, хыял канатларында йөртә, вакытның узганын сизмичә дә каласың. Ул аның авыр хезмәтен җиңеләйтә, караңгы төннәрен яктыртып тора.

Әмма бераз вакыттан хат килү тукталды. Нәрсә булды икән бу Нажиягә,— дип борчылды Зәй. Тизрәк хат язып салды. Җавап булмады. Зәй тагы язды. Кечкенә блокнотына: «Бүген Н-гә хат яздым»,— дип числосын куеп билгеләп бара иде. Күпмедер үткәч, санап карады. Н-гә сигез хат язган икән. Шуларның берсенә дә җавап килмәде. Зәй төрле уйларга төште, җаны үртәлде, егетлек горурлыгы бәреп чыкты. Ни кылырга белмәде, тагы хат язды. Ул хәзер генә Нажияне яратуын аңлаган кебек булды. Әдәм баласының мәңгелек сыйфаты: югалткач кына әйбернең кадерен белү, аңлау. Сөю предметы кулдан ычкынгач кына аңа карата өчләтә-бишләтә хис арту. Зәйнең хисләре ташыды. Элек ул хисләр аны җылыталар гына иде, хәзер көйдерәләр. Үртәлеп тә ярата икән кеше. Шунсы гаҗәп, мондый үҗәтләнеп яратканда хисләр тиз генә сүрелмиләр, көчәйгәннән-көчәя баралар. Ләкин элеккеге талгын хисләргә нинидер ачылык, әрнү, шелтә чалымнары өстәлә бара.

Учак ничаклы гына дөрләмәсен, аңа утын өстәп тормасаң, ул әкренләп сүрелә, сүнә. «Мәңге сүнмәс утлар булмас, сүнәр әле бервакыт»,— дип җырлыйлар җырда да. Йөрәктәге ут турында сүз бара... Бик күп хатларына җавап булмады, кире дә кайтмады. Шуннан соң Зәйнең башындагы зәңгәр томаннары тарала башлады. Шулай да янган учакның көле астында утлы күмерләр пыскып тора әле. Чыбык-чыбык җыеп салсаң кабынып та китәр иде. Юк шул, бар алдавыч өметләр бетә бара шикелле.

Нәрсә булды икән? Кияүгә чыкты микәнни? Нишләп бер хат та кире кайтмады? Кияүгә чыккач та минем хатларны ире белән бергәләп укыйлар микән? Күзле-башлы булгач, егетләрдән килгән хатларны уку кызыктыр инде ул. Менә минем өчен үлеп йөргән егет яза, оныта алмый бичара, дип ире алдында абруен күтәрергә була...

Алар шитовой бараклар төзеделәр, котельныйга ялгау өчен күп торак корыла иде. Ничек булса булды, кыш узды, җәй җитте. Шунда Зәйгә телеграмма килеп төште. Әтисе үлгән! Берничә көн отгул алып, авылына кайтып китте. Юл бик җайсыз иде. Ул кайтып җиткәндә әтисенең өчесен уздырып яталар. Зәй әтисе киткәнгә әллә ни уфтанмады. Шулай да аңа тормыш биргән кеше. Бик эгоист булды, балалар өлешен эчеп бетерер иде... Әнисенә әзрәк акча калдырды да, Зәй юлга ашыкты. Юлы — яңа салынып килә торган нефтьчеләр шәһәре — Акташка иде. Ул китеп торган арада бу яклар танымас дәрәҗәгә килгән. Кая карама анда буровой вышкалары утыра, факеллар яна. Төнлә бөтен горизонт зур янгындагы кебек кызарып-ялкынсулап тора.

Акташта беркемне дә белми. Нәҗия адресы белән I-поселокта Гафиятуллин урамындагы өченче номерлы баракка барып керде. Ишек шакыганда йөрәге дөп-дөп типте. Нәрсә булыр, Нәҗия аңа ни йөз белән күренер? Әллә качып та өлгергәнме югыйсә? Ишекне бер мөлаем генә түгәрәк йөзле кыз ачты.

— Сез Зәйме, әйдә, узыгыз, узыгыз! — дип кабатлады ул — Нәҗия биредә юк, ул кияүгә чыкты. Утырыгыз, утырыгыз.— Кыз өстәл янындагы урындыкны ишек төбенәрәк куйды. Зәй үзенең күнитекләренә карады.— Юк, борчылмагыз, зинһар!

Икесе дә ни әйтергә белми тынып калдылар.

— Кемгә? — Зәй көчкә авызыннан сүзләрен этеп чыгарды. Аркасыннан кайнар елдырым пешереп узды да битләрендә туктады.

— Үзе белән институтта укый торган Баулы егетенә. Ул сезнең хатларны миңа да укыта иде, шуңа мин сезне беләм, бер күрү белән таныдым.

— Күптәнме?

— Ә-ә, ел буладыр инде,— диде Рамилә. (Кызның исеме шулай иде.) Мич артын пәрдә белән кухня итеп көйләгән иде, Рәмилә шуннан тиз генә кайнаган чәйнек һәм өлеш тәлинкәләренә тураган колбаса, сыр алып чыгып өстәлгә тезде. Эшнең болай борылыш алуын көтмәгән Зәй бик уңайсызланды, нишләргә икән,— дип тәрәзәгә карады. Кич булып килә иде. Машиналар туктагандыр, станциягә өлгереп булмас микәнни? Рәмилә аны өстәл янына кыстады. Зәй шөбһәле-кайгылы уйларыннан арына алмый икеләнә иде. Рәмилә, шуны сизеп, тагы да ныграк кыстый, гозерләнә. Янында бөтерчек кебек йөренә. Зәйгә уңайсыз була башлады. Кара, нинди кыргый, куркак, дигән тәэсир калуы мөмкин иде.

— Курыкмагыз, чәй генә эчәрсез,— ди-ди Рамилә өтәләнә. Аның бу ихлас хөрмәт итәргә теләвенә таш та йомшар. Нәрсә нәрсәгә, әмма хөрмәткә, яхшылыкка каршы торып булмый. Нәҗия турында төгәлрәк беләсе килү дә аны бу бүлмәне ташлап чыгып китүдән тыя... Нәҗия ни сәбәпле шундый хыянәтчел адым ясаган? Сәбәбен беләсе килә. Сәбәпсез, нигезсез берни дә булмый. Кинәт булган бу зарбыдан күкрәгенә әллә нинди каты нәрсә утырды. Сулышын кыса кебек иде. Күңелдә ачу, үч кузгалды, үзенең көчсезлегенә әрнү, рәнҗү басып китте. Нәрсәдер эшлисе, ачуны чыгарасы килде. Шулай да үзенә эчтән генә: сабыр, сабыр, дип әйтергә ничектер аңы җитте. Кискен моментта шулай аң җыярга аны Андрей Андреич Казан өйрәткән иде.

Чәй эчкәндә Зәй, һаман ышанып җитмәгәндәй, Нәҗиянең кияве хакында төпченде. Ниндиерәк кыяфәттә, уңганмы, әллә болай гынамы? Гүя аны үзе белән чагыштыра. Аның үзеннән өстен якларын белеп, күңелен тынычландырмакчы буламы — белмәссең. Йөрәге үртәлә, горурлыгы кимсенә. Ул ничә чынаяк чәй эчкәнен дә чамалап бетермәде. «Шушы

бүлмәдә яшәделәрме?» — дип кызыксынды ул. Рәмилә ияк какты, мин отпускага Казанга кайтып киткән идем, диде. Егет, мөгаен, аны бик нык кысkандыр, ялынгандыр. Нажия җәлләгәндер, берни эшли алмагандыр, бирелгәндер, дигән уйлар үтте Зәйнең башыннан. Кызны сындыру авырмени? Мин укымаган, тинсенмәгәндер дә. Әти-әнисе дә укыган кешене чамала дип тукый торса...

Чәйдән соң Зәй китәргә кузгалды. Рамилә аны артык кыстамады, шулай да әйтте:

— Вокзал идәнендә аунаганчы, монда раскладушка бар?

— Юк, мин аэропортка...

— Соңгы автобус сигездә китә, хәзер унынчы. Юк, анда бүген эләгә алмыйсыз,— диде Рамилә, ихтыярыгыз тагын дигән төстә.

— Автовокзалга барып карыйм әле,— диде Зәй.— Бер-ике адымда гына бит. Булмаса, кире кайтырмын.

Зәй беркая да китә алмады. Рамилә бүлмәсенә әйләнеп кайтканда уникe тулып узган иде. Рамилә ишек төбенә раскладушка куеп урын әзерләде. Караңгы бүлмәдән мендәр алып салды. Аннары үзенең чыбылдык-пәрдәләр эчендәге урынына китте.

Зәй утны сүндерде, чишенде һәм яңа урынга сузылды. Раскладушка бик нык шыгырдады, ул артык хәрәкәт ясарга да уңайсызланды. Бик тын гына булып ятса да күзенә йокы керми иде. Нажиянең аны ташлавы миенә каты суккан икән шул. Бу көтелмәгән яңалыктан һич тынычланып җитә алмый. Ләкин һәр начарның бер яхшы ягы чыга, дигәндәй, Нажиянең вафасызлыгы аны ниндидер бурыч чылбырыннан азат итте дә куйды. Әдәп-тәртип чылбыры тотрыксыз бит ул. Чылбырның бер башы өзелгән, бернигә дә ярамый. Эчтә алдануга каршы тойгы күтәрелә, нәрсәнедер өзгәләп ташлыйсы килә. Әмма болай үзенә генә начар эшлисең. Иң шәбе, моңа артык әһәмият бирмәскә, чынбарлыкны ничек бар, шулай кабул итәргә.

Шундый уйлар уйлаганда Зәйнең колагына чыбылдык эчендәге кыштырдаулар чагылып китә. Димәк, Рамилә дә йоклый алмый борсалана. Зәй, кыюланып, аңа сүз кушты. Хәл-әхвәл, тормыш-көнкүреш турында сөйләшә башладылар. Зәйнең сүзгә чослыгы бар иде. Бер-ике мәзәк тә кыстырып җибәрде. Рамилә көләргә генә тора торган кыз икән. Әллә Зәйнең күңелен табыйм дип шулай эшли? Шаян сүз, көлүләр кешеләрне бер-берсенә тиз якынайта. Чөнки көлү-шаянлык кешенең гадилеген, тәкәббер түгеллеген белгертә. Аралашучан холыклы икәнен күрсәтә. Әмма артык күп көлү абруйны да төшерә, сине очсызлый да. Рамиләнең һаман көлеп кенә торуы ниндидер кыюлык өстәде. Ул читләтеп-читләтеп кызның бик күп кылларын тартып карады. Барысыннан да Рамиләнең тыйнак, инсафлы икәне беленә иде. Сүзнең кай төшендәдер:

— Безнең авылда кызлар белән егетләрнең бергә куну гадәте бар,— дип әйтеп ташлады Зәй.

— Ул гадәт турында Яңа Бистәдә дә сөйлиләр иде,— диде Рамилә.— Ләкин безгә андый уеннар уйнарга туры килмәде.

— Алайса без ул уенны хәзер уйныйк,— дип, Зәй урыныннан торды да, чыбылдыкка таба атлады. Ни булса ул, беткән баш беткән, дип уйлады. Яңакка берне кундырса да түзәрмен...

— Юк, юк, син мине алдарга киләсең! — диде кыз һаман шул шаярулы тавыш белән һәм торып утырды. Зәй аның иңенә кулын куйды, кыз исә юрганына төренеп бетте. Толымы — башы гына калды. Зәй карават кырыена гына сузылды. Шул килеш шаярып сөйләшүне дәвам иттерделәр. Егет җитди тонга күчеп, Рамилә белән кызыксынды, дуслык урнаштырасы килүен сиздерде. Чын, син миңа ошап торасың әле, дип тә ычкындырды. «Ә мин сиңа?» — дип Рамиләнең кылын тартты. Белмим, белмим, диде кыз юрганнан гәүдәсен чыгара төшеп. Балалар шикелле кул хәрәкәтләрен худка җибәрделәр. Зәй кочмакчы булды. Рамилә читкә

тартылды. Әмма берсендә ычкына алмады, Зәйнең кочагында калды. Кызның нечкә челтәрләргә төренгән хуш-исле тәне тоташ ут иде. Шундый кайнар булыр икән! Нindидер мизгелдә иреннәр бер-берсенә ялганып торды. Зәй шәрап эчкәндәй исәнгерәде. Кызны да хисләр биләп алды кебек. Аң каядыр аерылды, хисләр генә бер эшкә баш һәм юнәлеш бирә иде. Шунда тәннәрдәге көчле хисләр электры ниндидер мизгелдә аларны кушты да куйды. Үзләре дә сизми калдылар. Бары эш эшләнгәч кенә аларга аң кайтты. Ләкин инде соң иде. Шайтан алгыры, кыз янына ятканда бернинди андый нияте юк иде. Валлаһи юк иде. Ниндидер хисләр ташыган мизгелдә иблис икесен дә рәхәтлек упкынына ташлады. Уеннан уймак чыгу шулай буладыр, мөгаен... Зәйнең аңы сүнгән иде, колагына кызның нәрсәдер кайнар пышылдавын да ишетә алмады. Үлгән кебек кинәт йоклап киткән иде.

Иртән ул кемдер пышык-пышык борын тартып елаган тавышка уянып китте. Бераз исен җыеп, аңын туплап ятты. Кичәгеләр хәтеренә килде. Ялгыш эш эшләнгән, шуны аңлау йөрәген телеп үтте. Үкенү һәм булган эшне кире кайтара алмау ачысы күңелен әрнетте. Менә бер дә уйламаган, теләмәгән эш эшләп ташланылды. Җинаятьләр дә шулай аң «отключенный» моментта эшләнәдер инде. Ул Рамиләнең елаганын белде. Бик авыр һәм күңелсез хәл туу миен кисеп кергәндәй итте.

— Рамилә, нигә елыйсың, ә? — диде Зәй чалбарын һәм күнитеген кия-кия. Нишләргә? Тизрәк биредән качарга иде. Елауны ул һич тә күтәрә алмый.

— Нигә икәнен үзең дә беләсең... — Рамилә үзе өстәлгә ризыклар куя, чокырга чәйләр ясый, үзе үксепме-үкси иде.

— Йә, бетте, Рамилә, — дип Зәй юынгычта юынып килде дә кызның иңенә учын куйды. Кичә ничек шаярып көлешкәннәр иде, көлү артыннан елау килә икән. Зәй сәгатенә карады да бик ашыга башлады. Бер кулы белән чәй эчте, икенче кулы белән адресын язды, ышандыра, өметләндерә торган сүзләр сөйләде.

— Йә, йә, мин сине алдамыйм, юләр! Барысы да үз урынында булыр, Рамилә! Соңгы елым. Бәлки бер ун көнгә отпускага да җибәрерләр...

Зәй тагы сәгатенә күз төшерде, тиз-тиз киенде. Чемоданын кулына тоткач, елап утырган Рамиләнең башыннан учы белән сыйпарга тотынды.

— Курыкма, алдамыйм! Хәзер ашыгырга кирәк?! Ярый, сау бул! Юлдан хат язармын... — Ул ишеккә таба атлады, Рамилә күзен дә күтәрмәде, сагышлы кыяфәттә елавында булды.

Рамилә, елап, үзәкне өзеп калса да бик ошады аңа. Күпме юл буе аңардан алган кешелекне, рәхәтлекне тоеп бара. Ул бит Рамилә аркасында төн эчендә бөтенләй икенче кешегә әйләнде шикелле. Ә бит арада бернинди ярату юк иде. Алар бергә туры килүдән ярату кинәт кабынды да китте. Яратумы соң бу? Әллә теләсә нинди хатын-кыз белән якынайсаң да, шундый кинәт кабыну булырмы? Башкаларның ничек була икән? Китапларда кичерешләрне язган булалар, ялганлыйлар, ахрысы? Ә шулай да Рамилә ошый аңа... Тик ул мине белергә өлгермәде: мин бит алдарга сәләтсез кеше. Бүген үк аңа хат язармын. Тынычлансын, югыйсә бигрәк мәхлүкләрчә мескен кыяфәттә яшь түгә. Кешеләргә ышанмаудан бу. Әдәм баласына ышаныч бетеп бара. Без бер-беребезгә ышанмыйбыз? Менә мин Нажиягә ышанган, өметләремне аның белән бәйләгән идем. Ә ул нишләде? Мине алдап, икенче кешене сайлады. Барча таянып торган өметләремне җимерде. Шуннан соң кешеләргә ничек ышанасың, ничек таянасың?

Кем дә булса төпсез көймәгә утыртып калдыргач, мин-минлегең үчегә, гарьләнә һәм үзеңне югалтмас өчен икенче чиккә ташланасың. Мөгаен хак, ахрысы, бу эчке пружина. Рамиләгә ябырылып, аның белән кушылуымны юньләп сизми дә, аңламый да калдым бит! Шайтан алгыры, әнә шул Нажиянең мине алдавына җавап рәвешендә нинди тәвәккәл адым ясалды. Ярым аңсыз, нәрсәгәдер үч итеп, үзеңне үзең алдында

күрсәтәсе килеп. Хәер, үкенмим, өйләнергә шүрләбрәк йөри идем, көтмәгәндә үзеннән-үзе килеп чыкты. Рамилә ярамаслык түгел. Тулы, тыгыз гәүдәле, мөлаем гына ачык чырайлы. Уйласаң, бик сәер, егет белән кыз шулай ихтыярларыннан тыш кушылалар микәнни? Миндә бит Рамиләне ярату юк иде, аның янына яткач, кочкач тойгылар кинәт кабынды да китте. Ул ялкын икебезне дә кинәт чолгап алды һәм безне кушып та ташлады. Электр тогы ике чыбыкны бергә эретеп ябыштырган шикелле.

Зәй юлда Рамиләгә ике хат язып җибәрде. Ул инде анык, табылган гаип хәзинәсе кебек. Аны ахыргача үзенеке, фәкать үзенеке генә итәсе килә.

Частька кайтуына канцеляриядә аңа 5—6 телеграмма килгән иде. Зәй моны көтмәгән иде, бераз кәефе дә кырылды. Әмма телеграммаларны укыганда эчтән генә көлде ул. «Кадерле киявебез, сезне законлы... Таныш түгел киявебез, сезне законлы... Барча телеграммаларда закон сүзе кулланылган. Алдый алмассың, закон безнең якта, ди телеграммаларның аскы мәгънәсе. Закон белән куркытып, коерыкны бозга катырырга исәп тоталар. Болар барысы да ышанмаудан, куркудан билгеле...

## II

Андрей Андреич Казан үзенең җимерелгән тормышы турында ачынып уйлана иде. Уйларга теләмәсә дә заяга узган гомере исенә төшә дә йөрәген лезвие белән сызып алган шикелле итә. «Кем гаепле?» — дип үз алдына сорау куя ул. Ләкин җавап таба алмый. Гаепне үзеннән эзләргә тотына. Күбрәк өметкә алданып яшәлде. Йомшак кешеләрнең бәласе ул өмет дигән нәрсә, булдыксыз кешеләрнең бәхетсезлеге. Әллә миндә куркаклык күбрәк булдымы? Юк, куркаклык бүтәннәрнекеннән артык түгелдер, ә менә яраша, ипләшә алмау миндә артыгы белән иде. Кайбер затлар гомер буе үзләренең балалыкларыннан чыга алмыйлар? Шул минем гомерлек бәлам булдымы? Әллә каһәр суккан үшән уйлаулылыкмы? Софа ни өчен Платон Никитичтан китте дә миңа килеп ябышты? Мин аны кире кага алмадым, чөнки ярата идем. Юк, мин Софаны Платонга чыккач кына ярата башладым түгелме? Горурлыгым рәнҗегәннән генә? Платон белән Софа өч-дүрт ай чамасы гына яшәделәр, ни өчен килешмәделәр, аерылуларына ни сәбәп? Билгесез. Софа бераз резина сузып маташты да миңа килде. Ни өчен болай «таркалдыгыз» дип сораганым булды, Софа серле итеп: белмим, дип әйтә иде. Ялганлый, билгеле. Ничек инде белмәсен? Ә менә хәзер, еллар үткән, икенче төрле уй килә: әйе, белмәве дә мөмкин. Ул нигәдер Платон турында бер кыек сүз әйтмәде. Монысы да гаҗәп иде. Ул Платонны минем алда бик нык яманларга, бөтен начар якларын фаш итәргә тиеш иде. Ә Софа «белмим»нән башка бер сүз әйтми. Әллә аларның элемтәләре өзелмәде микән? Әллә Платонның бер-бер ярамаган ягы белендеме? Шуны икәүләп яшерделәрме? Ә бит Платон белән якын дуслар идек, бер ишек алдында уйнап үстек. Соңыннан гына сукмаклар аерылды. Платон бик серле чырай белән йөри иде. Ул бервакытта да көлмәс, бары мыек астыннан елмаер гына. Шул тикле түзем, тыныч холыклы, әллә пошмас җанлы булдымы икән ул? Янагына суксалар да гарьләнми, чыгырдан чыкмый, җиргә төшкән бүреген алып кияр иде дә юлын дәвам итәр иде. Платонның шундый булуына аның өчен әзлә идем. Ә миңа үзем өчен оялырга кирәк булган. Платонның холык-фигыле сракка китә торган, аны югары баскычка күтәрә торган икәнен мин бары сөргендә чагында гына аңладым. Софа белән бәйләнгәнче без ихлас күңелдән ачылып сөйләшә торган идек. Ничектер, һич ялгансыз, алга-артка карамыйча бер-беребезгә эчләрне бушата идек. Софа арага килеп керде дә бөтенесен бетерде. Платон йомылып калды. Мин дә үзгәрдем шикелле.

Ир-ат тормышына хатын-кыз килеп катнаштымы, ни дә булса булмый калмый. Ул ир-атта борылыш ясый, аны танымаслык итә.

Әле арага хатын-кыз кергәнче Платон белән бер әңгәмә корып утыру хәтердә. Утызынчы еллар. Тирә-юньдә курку-шом. Кайдадыр бүкәй яшеренгән, шул курку тарата. Кешеләр бер-берсеннән шикләнәләр. Институтта бер доцентны кулга алдылар. Бик әйбәт укытучы иде. Ни өчен, нилектән дигән сораулар баш миен бораулый. Җанны бик нык тетрәтте бу вакыйга. Күпләр үз эчләренә чумып, читкә карамый йөри башладылар. Доцентны, бер сүз өчен харап булды, дип җәлләп сөйләделәр... Ничек инде бер сүз өчен? Шулай булуы мөмкинме? Бик көчле пропаганда аппараты тоткан хөкүмәт ни өчен кеше фикеренә шул тикле дикъкать бирә? Гаҗәп. Нинди сүз сөйләде икән соң?

— Берәр дөрес сүз ычкындыргандыр,— дип куйды Платон.

— Сүздән курыккан хөкүмәт нигә инде ул? Безнең дәүләт бит йомшак түгел. Үзен яклый, саклый алырлык, минемчә? Шулай булгач...— Андрей дустының ачык йөзенә карап ала. Әйе, Платон эчендәген бер дә кыйшатмыйча, бу минутта аңында нинди уй туса, шуны әйтә. Андрейның ихласка ихлас буласы килә.

— Еланны аждаһага әверелгәнче бетерергә кирәк? Ә сәяси сүз — идея ул. Менә хикмәт нәрсәдә. Сүз-идеянең елан кебек бик тиз аждаһага әйләнүе мөмкин.

— Ярамаган хак сүз өчен Рим империясендә дә башларын кискәннәр...— Андрей филолог буларак шул турыда сөйләп алды.

— Ни өчен алайса ул империя таркалган, һаман яшәмәгән?

— Артык каты режим көтмәгән җирдән сүтелә башлый. Империяләр җимерелми калмыйлар. Наполеон француз империясе төзи, ул да тиз бетә...

— Юк, сәбәбе тирәндәрәк, аерым бер милләт халкының үз аңы күтәрелүдә, үзен милләт итеп билгеләү хисе тәрбияләнүдә! Милләтпәрвәрлек барлыкка килүдә...

— Милләтләрнең үзбилгеләнүе мәдәниятнең бер баскычка югары менүе дигән сүз. Шунсыз бер милләт тә үзен дөньяга белгертә алмый, эссез югала. Ә кемнең эззез югаласы килсен... Без төп фикердән читкә киттек. Әйе, дәүләт үзен эчке хәвефтән сакларга мәҗбүр. Һәр производствода хәвефсезлек хезмәте бар. Бу — халыкның үзе өчен кирәк...

— Җәза бирү эше халык исеме белән эшләнә дә,— диде Платон кинаяле елмаеп. Шулай кинаяләгәндә аның өске ирене әз генә ачылып китә.— Доцентны халык дошманы, диләр. Каршы килеп кара, янәсе, халык үзе аны дошман итә, син безнең тормышка яраксыз, ди...

— Ә бит бу процесста халыкның бернинди катнашы юк, мәгәр халык дигән исем астында спекулировать итү генә бар.

— Хикмәт тә шунда шул.

— Сизгерлек күрсәтү һәркемнең патриотик бурычы дип язалар. Кешеләр сизгерлек күрсәтәләр, үз иптәшләрен чагалар. Шулмы патриотизм? Ватан хисеннән түгел, бары үч алу өчен чагалар. Менә фаҗига кайда. Безнең доцентның көнчеләре булгандыр. Башлы кеше иде!..

— Карьера эшлисең килсә, иптәшеңне чак. Дәрәҗә, урын өчен көрәш сизгерлек күрсәтү аркылы бара. Донос — социализмга тугрылык, дип бәяләнә. Эш, тырышлык билгеләми кешенең бәясен, ә уяулык, бүтәннәрне фаш итүе билгели. Тугры булып кызыл сүз сөйләве бик мөһим санала.

— Тукта, Ленинның сүзләре хәтергә килде, ул кем беләндер бер әңгәмәдә: сәясәт күп булган җирдә кешеләр бәхетле була алмыйлар, ди түгелме?

— Әле уң, әле сул тайпылыш, аңлап бетерер хәл юк. Нигә ул сәясәт? Практик эш белән гамәл итәргә кирәк?! Политика тормышка читтән китереп тагылган инструмент. Кемнәрдер ерткычларча шул инструментны эшкә җигеп югары үрлиләр.

— Юк, уяулык кирәк ансы,— диде Андрей бернинди әчкерсез. Уяулыкның ил иминлеге өчен кирәк булуын аңлатырга тотынды.

— Уяулык артыкка китсә, үзенең киресенә әйләнә бит. Шуны бераз чамаламыйлар микәнни?

— Каршы фикергә урын юк, аны дошман дип кенә атыйлар һәм яптырып куялар. Каршы фикерсез дөрес юлны белеп булмый. «Обратная связь» дигән нәрсә бозыла. Моның һәлакәткә китерүе мөмкин...

— Һәлакәткә таба барабыз, йа, Алла! — дип Платон, башын ике учы белән йомарлап кыскан хәлдә, аска төбәлеп тынып калды. Андрей да бүтән сүз әйтә алмады. Эченә шом, курку төште, нинди́дер авыр билгесезлек күңелен тырнап тора башлады.

Алар төрле факультетларда укыйлар иде. Сукмаклары да аерым йөри. Андрей филология-тарих белән кызыксына. Платон җир серләренә, геологиягә мөкиббән иде, математика белән бәйләнгән гыйлемнәр аңа бик җиңел бирелә. Әмма Андрейның татарча белүе дә үз ролен уйнады. Алар коммуналкада өч семья булып, икесе күп балалы татарлар иде. Монысы да язмыш эше булгандыр инде. Кәнчыгыш бүлегендә «недобор» килеп чыккач, Андрейны шунда күчерделәр. Төрле өстенлекләр вәгъдә иттеләр. Рус кешесенең чит милләт телен, тарихын өйрәнүе аңа объектив бәя бирү өчен кирәк, ди. Милләт вәкиленең үз теленә, тарихына булган бәяләүләре күп вакыт берьяклы була. Милли төсмергә буялып, ориентирны адаштырырга мөмкин.

Утыз алтынчы елны яздан ук Платон Көньяк Уралга практикага китте. Софа да аңа иярде. Ике егетнең башларын әйләндереп йөрде-йөрде дә, ахырда Платонны сайлады. Хәер, Софа төрле көтелмәгән хәлләр китереп чыгарырга ярата. Аның холык-фигыле шактый җилбәзәк, нишләгәнен үзе дә аңлап житкерми шикелле. Ул бер көнне болай, икенче көнне бөтенләй башкача.

Андрейның Софага тартылган хисләре чын булган икән, ул Платонга ияреп киткәч, шуны аңлаган кебек булды. Йөрәге өзелеп-өзелеп авыртып куя иде. Барысы да эчтә генә яна, тышка берни чыгармады. Эчке яну ничектер авыр рәхәтлек тә бирә кебек иде. Башында нинди́дер зәңгәр томан, томан эчендә Софа үзенең һәрчак көләч йөзе белән нурланып тора. Йөрәк сулык-сулык килеп тибә, сулыш алуы читенләшкән кебек, күкрәк тыгызлана. Йөрәк яна дигән сүзнең мәгънәсе шулай була, ахрысы.

Көз көне бервакыт шакыганга ишекне ачса, Софа басып тора. Кояшта чуен кебек булып каралган, шуңа тешләре энҗе сыман җем-җем итеп тора. Софа рөхсәт тә сорап тормады. Андрейның юашлыгын белә, кабул итәсенә нык ышана иде. Башта Андрей аны тагы шаярта дип белгән иде, әмма Платон белән аралары тәмам беткән икән. Платон Орск шәһәре янындагы Сара станциясендә институтның яңа оешкан базасында бер-ике айга калган...

Софа Андрейга килеп тора башлагач, Платон белән ел буе диярлек сөйләшмәделәр. Нәрсә турында гәпләшергә мөмкин шундый хәлдә?! Баш кагып кына исәнләшеп йөриләр иде. Платон аңардан йөзен борып китсә дә урынлы булыр, әмма ул вакчылланмый, киң күңеллелек күрсәтә.

Бер гомуми танышларда «вечеринка»да бергә туры килеп ничектер сөйләшеп киттеләр. Тавышын әкренәйтеп, Платон сөйләнде: Софа матурлыгы белән масая, диде, әле моны ал, әле тегене ал, ди. Бәгырьгә тия. Акча җитми, шул хакта тавыш чыгара. Өстәмә эш ал дип, кич эшли торган урын белеште. Мин әйтәм, мин ишәк түгел, дим. Бигрәк тә кичкенә генә ирекне кысуы нервыны игәүли: кая булдың, кая бардың, анда нишләдең? Өй прокурорына әйләнде чистый... Шуннан кул селтәдем. Нәрсә ул ярату? Постельме? Софа шуннан башкасын белми дә...

Платон моны нигә әйтә икән дип уйлады Андрей. Миннән Софа турында берәр нәрсә ишетер өчендер, мөгаен. Әллә горурлыгы үртәләме, үзен булдыклы итеп күрсәтергә телиме? Әйе, Платон бик уңган, эшлекле

егет. Шуңа күрә дә Софаның аңардан китүе сәер күренеш. Булдыклы бит булдыксызны бик тиз таный. Софада булдыклылык ягы алай ук түгел, үзенең чибәрлегенә исәп тота һәм шуңа таяна. Кемдер аны син чибәр дип ышандырган. Ләкин ялганлаган. Ул урта чибәрлектә генә. Хәер, кемгә ничек күренәдер. Кайберәүләргә кире кагып булмый торган матур булып тоелуы мөмкин. Хатын-кызның төсе, кыяфәте бик спекулятив нәрсә. Андрей янына килеп яши башлауга күп тә үтмәде, Софа авырга уздым дип борчылырга тотынды. Врачларга, тагы кемнәргә күренеп бетте. Ахырда Андрейны язылышырга загска өстерәде. Андрейның күңелендә бераз шик булса да эндәшмәде. Чөнки Софа ачуланып берәр җиргә барып әйтүе мөмкин иде. Әгәр шулай эшләсә — беттең. Софадан бары-сын да көтәргә мөмкин... Софа аксыл чәчле малай тапты. Андрей анда үз чалымнарын һәм Платонга охшаган сызыклар күргән кебек булды. Софа баланы озак тотмый күкрәктән аерып, әнисенә илтеп бирде.

Бер хәл бик нык уйландыра Андрейны. Эш шунда, Софа Платонны ташлап аның белән яши башлагач, Андрейның хезмәт урынында күңел-сезлекләр күбәйде. Ә Платонның эшләре уңайга китте, ул югарыга таба адым ясады. Аны аспирантурага алдылар, ә Андрей аспирантурага имтиханнар биреп йөргән чакта, аның штатына югарыдан кыскарту килде. Ничек шулай килеп чыкты бу? Хәлләрнең бергә килеп чарпалышуымы, әллә астан берәр кул уйныймы? Бүтән елларда булган штат нигә быел гына кыскартыла? Ни сәбәптән? Андрей төпченеп маташты, аңа нинди беркатлы кәбестә син дигәндәй елмаеп карадылар. Ул күлүләренә чыдап, җавап көтеп басып торды. Берсе өскә төртеп күрсәтте, аннан әмер төшкәч, без нишли алабыз? Без кечкенә кешеләр, диде. «Кечкенә кеше» формуласы яшеренер өчен җайлы кыса. Бераз зиһенен җыйгач, кафедра мөдиренә керде. Аннан директорга сугылды. Бар төштә дә карашларын яшерергә тырышып, өскә төртеп күрсәттеләр һәм җилкәләрен җыер-дылар.

«Ничек бу?» — дип, Андрей юлда кинәт җимерелгән өмет кыйпылчык-ларын җыярга тырышты. Ул һаман сәбәпләр эзләде. Нәрсәм белән ярамадым икән? Әйе, уйланырсың, кодагый! Җыелышларда кадрларны бик каты «эшкәртү» бара. Кайберләрен тегендә сорау алырга төннәрен чакыралар икән. Якын арада гына кулга алынучы ишетелгәне юк-югын. Шулай да Алла йоклаган чагында Иблиснең әллә ниләр эшләп ташлавы мөмкин?

Өйдә бу хәбәрне ишеткәч, Софа бераз телдән калып торды. Бер агарып китте, бер кызарды. Аннан Андрейга тотынды: син бәхетсез кеше икәнсең, диде. Мин сине беләм, каршы килеп, гаделлек яклы булып маташкансыңдыр. Әйе, әйе, син, имеш, намус саклыйсың, порядочный кеше! Пычагымамы намуслылыгың? Намуслылык хәзер тискәрелек дип бәяләнә һәм аңа җәза бирелә! Бу шуның җәзасы! Хәерче тәкәббер!..

Софа шулай дулады да, чемоданына әйберләрен тутырып, бик каты янаган кыяфәттә чыгып китте. Андрей аны туктатмады. Софа шуны көткән иде бугай. Аспирантура белән бергә барча планнары җимерелгән. Софага вәгъдә иткән нәрсәләр бөтенесе дә беткән. Нәрсә белән тотып кала алсын ул аны. Софаның исәпләгән нәрсәләре Андрейның аспиран-турасына бәйләнгән иде.

Хәлнең тамырын дөрес чамалый Софа, шайтан алгыры! Моннан берничә вакыт элегрәк, Андрейны аулак бүлмәгә чакырып, үзе белән эшләүче берәү турында (алар архивта эшлиләр иде. Андрей институтны тәмамлаганчы ук шунда урнашкан иде) информация бирүне сорадылар. Ул риза булмады. Аннан да элегрәк Платон турында язып бирүен үтенгәннәр иде. Ул синең хатыныңны тартып алмакчы, дип котырт-тылар. Андрей кискен каршы килде, бу бернинди моральгә дә сыймый, диде. Ярар, мораль белән яшәп кара, дип янадылар аңа.

Андрейның җене кузгалды. Япсалар ябарлар, дигән уйга килде ин-станцияләргә йөрергә тәвәккәлләде. Смольныйга барып приемга языл-

ды. Тиешле көнне аны бүлек мөдире кабул итте. Башта Андрейны итагать өчен генә тыңлады, архивта эшләвен белгәч, кызыксынуы артты. Соңрак беленгәнчә, аның үзенә архивтан материаллар кирәк икән. Аның бигрәк тә, штатны өстәгеләр кысты, дип, кафедра җитәкчеләренең әйтүе ачуын китерде. Үзләре бутыйлар да безгә сылтыйлар, диде, анда бик нык кода-кодагыйлык тамыр җәйгән. Ул тамырны корытырга кирәк...

Мөдире янынннан Андрей өмет белән китте. Бераздан тагы килде. Мөдир кафедра җитәкчесен бик каты яратмый икән. Тегенең ниятенә каршы эшләргә тырыша иде. Ике карчыга сугышканда тузган йон-мамык каргага була, ди. Биредә дә шулай килеп чыкты. Штатны заочно итеп калдырдылар. Кафедрада Андрейга бик өнәмичә карадылар. Шулай да, өстә кулы бар ахры, дип куркып, укуын дәвам иттерергә мөмкинлек бирделәр.

Әмма явызлыкларын эчкә яшергән булганнар. Тема аяктан ега торган, ачыктан-ачык уңышсызлыкка исәпләнгән иде. «Мәскәүнең Казан ханлыгына карата дипломатик эшләре». Менә сиңа тема! Кем башына килгән бу сәеф фикер. Иван Грозный һәм дипломатия. Бу абсурд түгелме? Юри батырыр өчен һәм баш тарттырыр өчен эшләгәннәре сизелеп тора. Баш тартсаң, шунда ук аспирантурадан чыгаралар. Тагы жалоба белән йөрсәң, барча бәяң бетәчәк. Җалобщик дип атыңны пычратачаклар.

Ярар, бер җае табылыр әле, дип, үзен юатты ул. Һәм нииндидер үҗәт дәрт белән материал туплау хәстәсенә керешге. Материал бары махсус фондларда гына. Ул эшли торган архивта спецфонд бар. Тик биредә совет чорында тыелган һәм алып куелган нәшерләр, халык дошманнары, ак эмигрантларның китаплары, кульязмалары. Патшаларның кәгазьләре дәүләт архивында. Андрейның анда булганы бар. Материаллар тимер рәшәткәләр тимер ишекләр артында. Сер итеп саклана. Дәреслек язучы академикларны да кертмиләр, имеш. Барысын да беренче чыганаклардан алып язган Татищев һәм Карамзин китапларына таянырга кала. Анда бу темага бары берничә җөмлә белән кагылып үтелә. Аннары бүтәннәр хезмәтеннән файдалану күңелдә канәгатьсезлек тудыра. Әз генә булса да беренче чыганак табасы иде. Ярты бит кенә чын чыганак, язма материал. Ләкин төпчеңү, казыну да куркыныч. Башны сузарга, җираф булырга ярамый. Кемдер сиңа дикъкать итүе мөмкин. Бәладән башаяк. Шуның өчен сукыр тычкан кебек астан гына бик шыпырт хәрәкәт итәргә мәҗбүрсең.

Җан биргәнгә юнь биргән, дигәннәр. Андрей күп ышкылып йөри торгач, дәүләт архивындагы махсус фонд мөдире, урта яшьләрдәге ямьсез генә хатын белән танышып китте. Хатын, йозакларга сургучтан пломба салып архивтан иң соңгы булып чыга. Андрей да утларны сүндергәнче утыра. Тышкы ишекне кайчак бергә биклиләр. Кайту юлына таба бергә юнәләләр. Сөйләшәләр, шаян сүзләр дә хатынга сыя икән. Караңгырак кичләрне хатынны өенә хәтле озатып куйгалады. Каретная урамында яши икән. Ә бер кичне өенә керергә рөхсәт итте. Бүлмәсе озын коридорлы коммуналканың ишеккә якын башында иде. Хатын кисәтте: шыпырт булырга, сөйләшмәскә. Кечкенә, тар гына бүлмә. Биредә дә сөйләшергә ярамый иде. Тик пышылдап кына бер-ике сүз әйтешеп алалар. Күзләр, ымнар белән аңлашалар. Электр плитәсендә чәй кайнатып эчтеләр. Хатын идәнгә урын җәйде, ике мендәр ташлады. Ул төскә ямьсез булса да, тәнгә бик бай иде. Ир-ат назына шул тикле ачыккан булган. Тәне ут кебек кайнар. Кочагыннан һич чыгармый. Тагын, тагын, дип ялвара...

Иртән Андрей көчкә аякларын өстерәп кайтып китте. Үз-үзеннән оялды. Үзен-үзе тиргәде. Үзен караклык эшләгән кеше сыман хис итә иде. Шунда үзе тирәсендәге танышларын исенә төшерде. Институтның хөрмәтле доценты үзенең аспиранткасын сөяркә итеп тота. Фәлән профессор яңа килгән кече преподаватель хатын белән борчак пешерә. Бергә

институтта укыган, хәзер горкомда эшләүче кыз инде икенченең мәгъшукасы булып киткән... Шулар белән үзен янәшә куеп карагач, Андрей тынычлана төште. Софа алдында үзен хыянәтче итеп тоймады. Тирә-як мохитның кеше психологиясенә тәэсире зур шул. Кешеләр теге яки бу эшне бер-берсеннән күрмәле эшлиләр. Начарын да, яхшысын да.

Бу сәер төннең әҗәре дә хикмәтле булды. Хатын Андрейга бик яшереп кенә патша архивыннан кайбер беренче нөсхә кәгазьләр китерде. Андрейны шкафлар артына бикләп, документ тулы папка бирә. Нигәдер Андрейга туры карамый, күзләрен читкә ала. Куркамы, нәрсәгәдер уңайсызланамы кебек иде.

Андрей бар дөньясын онытты. Бу чын эш иде. Эшнең уңышсыз булуы ихтималын да сизә ул. Әмма аңа нindидер чынлык булсын. Ул чынлыкта аны соңыннан күтәрәме, әллә киресенчә, түбән тәгәрәтәме — барыбер. Менә нindидер чын, булган хәлләргә кулы тиде. Бу искиткеч куаныч китерде.

Кәгазьләр эченә кергән саен гаҗәпләнү арта. Бу ни хикмәт, Сафагәрәй свитасында мәскәүлеләргә авышкан морзалар, эш башкаручылар була. Алар мондагы хәлләрне яхшы белеп торалар. Русча грамоталы махсус язып торучылар сарайда ни булганын мәскәүлеләргә көне-сәгате белән җиткерәләр. Яшерен шымчылык һәм элемтә әйбәт эшләгән. Сөембикә янында шулай ук мәскәүлеләр мәнфәгате өчен эшләүчеләр бар. Тыштан барысы да Сөембикәгә гаять тугрылыклы булып йөриләр. Шундыйларның берсе Гөлсаф тумачи. Ул Сөембикәгә йогынты ясый ала. Теге яки бу эшне эшләргә этәрә яки кире дүндерә белә. Сөембикә болай кыю, гайярь булса да, язмышка буйсына торган холыклы итеп тәрбияләнгән.

Кемдер бик тәфсилләп мәскәүлеләргә язып җибәргән: бер көнне Сафагәрәй хан яшь җарияне ярата-ярата һушын җуя. Каршыдагы яшь җария өеннән бу хакта Сөембикәгә килеп әйтәләр. Ул ах-вах итеп асраулары белән килеп җитә. Сафагәрәйне тирегә төреп, өйгә күтәреп алып кайталар. Сөембикә ирен төрле шифалы үлән-дарулар белән исенә китерә. Көн-төн янында китми дәвалый. Аякка бастыра. Әмма мунчадан кайткач, бер төнне Сафагәрәйнең авыз-борыныннан кан китә һәм ул һушына килә алмыйча җан тәслим кыла.

Ханның үлү хәбәре мәскәүлеләргә бик тиз барып җитә. Һәм хан тәхете тирәсендәге интригаларны активлаштыруга этәрә. Сөембикә, магнит кебек, төрле яктан кияүләрне тартып торачак. Әгәр берәр көчле орда башлыгы Сөембикәне үзенә каратса, эшләр тагы да катлаулана. Кан коюга форсат ачыла. Моңа юл куярга ярамый. Мәскәү дипломатлары, Сөембикәне Казаннан кая булса да озатырга кирәк, дигән фикергә киләләр. Һәм ничек тә тизрәк һәм ничек тә әдәплерәк, ихтирамлырак итеп.

Ләкин моны турыдан-туры куярга кирәк түгел. Беренче итеп ханлыкның сугышсыз, кан коюсыз мәскәүлеләргә кушылуын таләп итәргә. Бу таләп кире кагылган очракта, Сөембикә мәсьәләсен алга чыгарырга. Берсе булмаса икенчесе. Дипломатиянең хасияте шундый.

Шундый ниятләр белән мәскәүлеләр мәһабәт кыяфәтле кнзне хан сараена сөйләшергә җибәрәләр. Князьнең бирелә булганы, торганы бар. Татарча да аңлый, сОөйләшә. Яхшы, итагатьле дигән даны таралган. Ул тышкы кыяфәте белән дә нур чәчеп тора торган бик мөлаем кеше. Татарларны ярата, җәлли кебек. Аның янына иң баш вәзирләр җыела. Князь тәкәллефле мөнәсәбәте белән казанлыларны аек акылга килергә этәрә. Үчләрне, ачуларны онытырга кирәк, ди. Чөнки үч, ачулар һаман тирәнгә китеп, бер-беребезнең канын коюга илтә... (Бу утырыш-сөйләшү турында бер дипломат бик тәфсилләп язып җибәргән.)

— Без моны гына беләбез,— ди аңа каршы баш вәзир Атнагол, ак сакалын учы белән сыпыра-сыпыра.— Мәскәүлеләр намус белән эш итмиләр: җир биреп, өмсендереп, безнең морзаларны яшертен генә сатып алалар. Үз якларына авыштыралар. Мәскәүлеләр әнә шулай мәкер белән араны начарлаталар.

— Юк, юк,— ди князь үзенең нур түгеп торган күзләре белән тагы да нурланып елмая-елмая.— Кайбер морзалар бит үзләре теләп мәскәүлеләр ягына күчтеләр. Падишаһтан дингә тимәскә дип үтенделәр һәм ул риза булды.

— Әйе, кайберәүләр сатылды,— ди Атнагол, тавышы калтырый.— Падишаһ сүзендә тормаячак: бераздан чукындырырга тотыныр.

— Ул морзалар сатылмады,— ди князь.— Алар аек фикер йөртәләр. Сез географияне санга сукмыйсыз: җирләрегезне күз алдына китерегез— дингез уртасында калган кечкенә утрау кебек. Дүрт якта да славяннар, бүтән милләтләр. Аңлыйсызмы? Бар ягыннан дингез белән әйләндереп алынган утрауны дулкыннар әз-әзләп ашап-кимереп бетерәләр. Бу — табигать яисә Алла законы. Дингез үзе теләмәсә дә, барыбер утрау ярларын ашамыйча тора алмый. Йә, төшенәсезме? Менә сез дә, мәскәүлеләр дә гаепле түгел!

Князь сүзләреннән залның караңгырак башында утыручылар арасында чыш-пыш, ниндидер кыштырдау булып ала. Бу князь сүзләрен хупламау билгесе иде шикелле.

— Без мәскәүлеләргә тимәбез, алар да безне тынычта калдырсыннар,— ди Сөембикә. Аның тавышы ягымлы. Ул бер кырыйда югарырак урында утыра. Түгәрәк кара тут йөзле, озынчарак күзләре чаткыланып йолык-йолык итә. Әмма чыраенда тирән эчке моңсулык чалымы да сизелә. Әллә үзенең киләчәк язмышын эчке тоем белән чамалыймы?

— Тынычта калдырмаячаклар,— ди вәкарь белән бик абруйлы Кормаш морза, югары даирә әгъзасы. Ул князьгә мәгънәле караш ташлый.

— Кардәшләр, сер түгел, без мөстәкыйль мәмләкәт тота белмибез,— дип сүз башлый Камай морза эшлекле сүз әйтә торган кыяфәттә. Ул таза имән муенлы, зур башлы, кыска гына кара сакаллы, сажин җилкәле. Үзен тотышында ниндидер бәйсезлек, үз сүзендә торучан ихтыярлылык тоела.— Без сугышырга гына беләбез. Бездә властьны тота торган ныклык, катгыйлык юк. Халык турында бөтенләй уйлап каралмый. Мәскәүлеләрнең халыклары бай яши. Гәрчә җирләре безнекеннән начар булса да, чөнки мәмләкәт башлыклары иген игүчеләр турында кайгырта. Бездә сугыш чыгымнары халыкны тәмам аяктан екты...

— Мәскәүлеләр эчәргә яраталар,— дип бүлдерә аны кайсыдыр.— Әгәр мәскәүлеләргә бирелсәк, безнең халыкны эчертеп,бозып бетерәчәкләр?

— Коръән бар! Безне бозылудан коръән саклаячак! — дип, тагы берсе өстәп җибәрә.

— Эчкән кешегә аңа коръәнең ни дә, милләтең ни, аңа ике дөнья — бер кәнди?!

— Бездә төпле власть, акыллы идарә юк,— дип сүзен ялгый Камай.— Һаман сугыш ягына йөз тотабыз...

— Әйе, әйе,— дип аны куәтли тагы могътәбәр морза Кормаш. Бу да эре сөякле, зур гәүдәле, киң мәһабәт чырайлы, биек маңгайлы. Әллә каян борыннан килгән зыялы нәселеннән икәне беленә.— Мәскәүлеләр көчле мәмләкәт булып җиткәннәр. Ә без көчле мәмләкәт кору турында баш ватмадык. Көчебезне төрле вак нәрсәләргә әрәм-шәрәм иттек. Инде менә нәтиҗә: мәскәүлеләр көчле, без көчсез. Ә кем көчле, шул хаклы. Әнә харитага карагыз: Без Русиянең иң үзәгендә! Башында мие булган кайсы мәмләкәт үз үзәгендә дошман асрасын, ди. Юләрмени ул?! — Ул Сөембикәгә карый, әмма ул карашын читкә ала. Йөзендә исә, эчендә чиксез ачу тыгызлануын сиздерә торган чалымнар. Иреннәре турсайган, кашкүз кабаклары салынган. Үзендә югалып калу, таркаулану, зиһене таралу беленә. Кара, минем якын дип йөргән морзаларым барысы да мәскәүлеләр яклы икән. Әллә фетнә корганнармы? Ничек мин моны бер дә чамалый белмәдем? Шымчыларым, астан эш йөртүчеләрем булмады шул! Җәсүсләрсез власть булмый, дип Гөлсаф тумачи күпме әйтте. Ул

русча укыган, белә икән. Ә мин коръәнгә, дингә, кылычка гына ышандым. Власть өчен кансызлык, катгыйлык зарури бугай шул. Мәскәүлеләр көчле, минем якыннарым барысы да көч ягына авышканнар. Көчле җиңәчәк икәне мәгълүм нәрсә. Нишләргә соң, нишләргә? Язмыш кулына үзеңне тапшырыргамы? Сугышырга? Мәскәүлеләр җиңүе көн кебек ачык бит. Шулай бетәрбез микәнни, ходаем?!

— Уйлап-уйлап торам да тагы уемны борам, кордашлар,— дип, Сөембикәнең уйларын гөлдерәп чыккан калын тавыш бүлдерә. Юан кара чутыр битле, тәбәнәк маңгайлы, сирәк төкләр баскан киң иякле, елгыр күзле кеше тезләрен учы белән чәбәкли-чәбәкли сөйләп китә: — Солтан канатына керә алмыйбыз, чөнки аның канаты безгә бик ерак, безгә җитмәячәк, бу тәгаен шулай. Ә терәлеп торган күршебез мәскәүлеләр канатына елышсак, динебездән, иманыбыздан язачакбыз. Нишләргә, кая барырга? Бик кыен мәсьәлә. Кайсын сайласак та без өтелербез, кителербез? Ә кайсы якка авышсак, исән-имин калырбыз? Коточкыч хәл...

— Шуның өчен ашыгырга ярамас, җиде кат үлчәп, бер кат кисәргә кирәк, җәмәгать! — диде тагы бер абруйлысы.— Солтанда олтан, Мәскәүдә — мәчкәү булырбыз...

Шуннан тынлык урнаша. Сөембикәнең озынчарак күзләре үз орбитасында, әле бу, әле теге якка йөгерешә. Күз аклары ялык-йолык килә. Ачуы куба башласа, шундый халәткә керә ул.

— Кайсы якка елышсак та, кордашлар, безгә имин яшәү булмаячак. Дүрт ягыбыз да кяферләр белән әйләндереп алынган, ә без кечкенә бер атау. Князь әйткәнчә, кяфер дулкыннар атауны һәрдаим ашап тора. Дулкын ашамыйча булдыра алмый. Бу котылгысыз, безнең хәл дә шуның кебек котылгысыз! — дип куя икенче бер зыялы.

— Атаян, авызыңны чамалап ач! — ди аңа таба башын бора төшеп Сөембикә.— Тел өчен баш белән түлиләр!

— Әгәр минем баш мәсьәләне хәл итә икән, рәхим ит, бер җәлләүсез бирәм, ханым-солтаным мәгез, чабыгыз! — ди Атаян, иелгән муенына учының кырые белән тиеп алып.

— Син фетнәче икәнсең, Атаян,— дип кычкыра Сөембикә.— Үзең минем яклы булып сөйләшә идең, аеры телле кеше миңа кирәкмәс! Кураучы, алың Атаянны! — Боерык тавышы мәҗлеснс дер селкеткән кебек итә. Ике яктан кылычлы ике кураучы атылып килеп, Атаянның күкрәгенә кылыч очларын териләр.

— Артка! — дип кычкыра баш вәзир Бәйраш кураучыларга.— Артка!

Кураучылар нишләргә белмичә әле Сөембикәгә, әле Бәйрашка таба карашларын йөртәләр, Атаян иелгән башын алгарак суза төшкән килеш бернинди курку-өркү сиздермичә утыра бирә. Тик йөзенә генә әче елмаю сызыклары чыгып, чыраен бераз чалшайткан. Кинәт Сөембикә торып баса, билендәге кыннан кылыч тартып чыгара.

— Вәзирем миңа хыянәт юлына баскан, аңа җәза бик хаклы! — ди ул, тавышын күтәреп.— Кяферләргә сатылдыңмы? Ә? Йә? — Ул алга атлый. Яшел атлас чапанының чабуы ачылып китеп, зәңгәр ефәк шаравар кигән юан аяклары нәфис йомры булулары белән күзгә бәрелә. Аңа каршы ак сакаллы, алсу чырайлы Бәйраш сикереп аякка калка һәм кылычын тартып чыгара.

— Ханым-солтаным, тынычлан, бернинди хыянәт юк! Атаян чын хәлебезне бәян итә,— ди ипле, баштан сыйпап тынычландыра торган тавыш белән. Сөембикәгә бу сүзләр кулга ияләштерүченең чыбыркысы җәнлекне кинәт тыйган кебек тәэсир итә. Ул бер адым артка чигенә дә урынына утыра. Кураучылар да икесе ике якка китеп тораташ каталар. Сөембикәнең күз акларыннан чәчелгән очкыннар яшен чаткылары кебек ялтырап-ялтырап китә, кылыч сабы тоткан сул кулы тезе өстендә сикереп-сикереп куя.

Князь-илче тыңлап утыра, нәрсә хакында сүз барганын аңлый һәм гаҗәпкә кала. Бер дә дипломатлык итмичә чит ил вәкиле алдында

ачыктан-ачык барын ачып салалар. Юри шулай итәләрме, әллә сер тотарлык чамалары калмаганмы? Юк, бу юри кылану түгел, бүтән чаралары юк, асларына су кергән инде. Татарларны бердәм халык, диләр иде, әмма бирелдә аның исе дә юк шикелле. Бер-берсенең якасына ябышырга гына торалар. Әллә бу мәскәүлеләрнең астан яшертен генә эш алып баруы нәтиҗәсеме? Әнә күп җир биләүче аксөякләр Мәскәү ягына каералар. Чөнки патша чиновниклары аларга яңа биләмәләр бүләк иткән. Ә милләт, дин — андый байлык каршында көчсез аргументлар. Милләт, диннән байлык килми. Ә тормыш байлык белән генә бара. Адәм баласы өчен байлык кадерлерәк. Ул дингә, милләткә түгел, ә байлыкка, җир биләмәләренә тартыла. Милләт, дин хисе икенче планда. Бигрәк тә хәзерге өметсез елларда. Бәйраш аек фикер йөртә: төрекләр татарларга ничек ярдәм итә алсыннар? Җәһәннәм дәрьясы артында нинди генә көч булмасын, бу салкын якларга берничек тә тәэсир итә алмый. Алар җылы як өчен җайлашкан, кар, боз ягы өчен яраклы түгел. Бер әтрафтан да...

Бәйраш тагы сөйли башлый һәм, Төрек солтанына йөз тоту ахмаклык, һавадагы торнага алдану, дип раслый. Бик гыйбрәтле мисаллар китерә, кире какмаслык фактларны алга тезеп сала.

— Алайса кяферләр тырнагына биреликмени, нәрсә сөйләгәнеңне колагың ишетәме, Бәйраш? — дип тагы тавышын күтәрә Сөембикә.

— Кяферләргә бирелергә димим, Сөембикә, әмма язмыш безгә ни бирә, аны күрмичә калу ярамый. Ләүхелмәхфүзгә ни язылса, шул булачак. Язмыштан узмыш юк. Хәзер безне язмыш китереп кысты. Бер чарасына керешергә тиешбез...

— Син милләтне яратмыйсың, Бәйраш! — дип тагы әче тавыш белән каршы төшә Сөембикә. — Имезгән ананнан ваз кичәсеңме? Шуннан соң синең ак сакалың ни дә, сөйләгән сүзләрең ни? Үз милләтеңнән баш тарту сине тудырган ананнан баш тарту ул. Күрә торып үз анаңны шакаллар авызына бирү. Хәләл канын агыза-агыза ач шакаллардан өздереп бетерү... Юк, ышанычымны бетердең, Бәйраш, бетердең!

— Сөембикә, — дип ничектер рәсми тонга күчеп, Бәйраш бәхәсне дәвам итә. — Милләтне сөймисең, диюең дөрес түгел. Мин мәскәүлеләргә дә сатылудан ерак торам. Алар минем тау ягы биләмәләремне тартып алдылар. Казан гаскәрләре җирләремне ышыклый алмады. Димәк, безнең гаскәрләр туган җирләрен сакларга көчсезләр. Туган җирне саклый алмау, димәк, милләтне саклый алмау ул. Хәзер безнең алга милләт һәм баш мәсьәләсе килеп басты. Кем өчен милләт кыйммәт, кем өчен баш кыйммәт. Йә бусы, йә тегесе. Әлбәттә, әдәм баласына баш-җан кадерле инде, сүз дә юк. Һәркем үз башын саклау ягын караганга күрә менә шушы хәлгә калдык...

— Казан гаскәрләре үз җирләрен саклый алалар, Бәйраш, — ди Сөембикә. — Тау ягы морзаларының мәскәүлеләргә сатылуын каплап калдырма!

Моңа каршы Бәйраш бер сүз дә әйтми, чалмалы башын ия биреп, уйланып утыра. Бераз киеренке тынлык хөкем сөрә. Кормаш селкенеп куя, башын күтәрмичә идәндәге паласка төбәлеп, сүзләрен чат-чат китереп әйтә:

— Мәсьәләдән читкә тайпылдык, җәмәгать, — ди. — Безгә Мәскәү падишасы үзенең илчесен җибәргән. Ул белергә тели: Казан иле мәскәүлеләр канаты астына керергә телиме, юкмы? Без илчегә катгый җавап бирергә тиешбез. Шулай бит, илче галиҗәнапләре? — Ул князь ягына таба башын ия. Тегесе аңа җавап итеп икс учын да күкрәгенә куеп, әз генә алга таба бөгелеп ала.

— Безнең сүзебез шул: Мәскәү падишаһы безгә тимәсен, безне көчләмәсен, без аңарга тимәскә ант эчәбез! — ди Бәйраш. Князь ягымлы йөзен күтәрә биреп, бик нык дикъкать тә калып тыңлый: әһе, әһе, дип үзе өчен әйткәләп куйгалый. Ул, фикерне дөрес аңлаганын белгертеп, бер кулын бармак шартлаткандагы кебек итеп ала. Башын як-якка чайкый-чайкый:

— Юк,— ди кабаланмыйча салмак кына, аның үз дәрәҗәсен яхшы белгәнлеге, шуның белән горурланганлыгы һәм бу чалмалы татарлардан әз генә дә шүрләмәве сизелеп тора. Үзен хуҗаларча иркен тота. Ул татар сүзләрен сайлый-сайлый җыеп сөйли: — Сезнең кәгазьдә, сүздә биргән антларыгыз күп булды, сез ул антларның берсен дә тотмадыгыз. Шулай бит, тотмадыгыз бит, картлар! Шулай булгач, бу чираттагы антка ничек ышанып булсын? Сез үзегез дә ышанмас идегез. Кешене бер алдасаң, ул сиңа ышанмый. Ә сезнең алдауларны санап китсәң... Шуның өчен Бәйраш морзаның сүзләре җитди түгел...

— Илче галиҗәнапләре ни тәкъдим итә?— ди, тавышын күтәрә төшеп Атаян.

— Мәскәү падишаһы үз кул астына күчәргә боера. Кан коймаска, бер-береңә каршы яуны туктатырга куша...— ди ул җитү чәчләрен бармаклары белән тарый-тарый.

— Безнең милләтебезне, динебезне нишләтә? Әнә тау ягы ханы Янакайның биләмәләрендә динне сакларга Мәскәү падишаһы вәгъдә иткән, шул дөресме?

— Дөрес, Янакай, Сөенбер җирләрендә үз диннәре белән калалар. Алар үзләре олуг падишаһ катына барып баш ордылар.

— Падишаһ безне кабул итмәячәк,— дип аваз сала Сөембикә.— Казанлыларга каны каткан аның...— Ул, фикеренең расланауын, расланмавын аңарда көтеп илче ягына карый. Илче раслап башын алга таба ия төшә дә төзәя һәм уйлый: болар барысын да яшермичә ачыктан-ачык сөйләшәләр. Тик гаскәр башлыгы котлы гына берни дәшми. Селәүсән кебек астан гына карый. Сүз әйтергә шүрләп утырамы? Ә аның гаебе бар. Ул кырымлыларга, нугайларга таяна. Аларга чапкын җибәреп, хәбәрләшеп тора. Бу эшне ул патшабикәгә, мәҗлес әһелләренә дә әйтми. Астан гына эшли. Мәскәүлеләр моны күптән белә. Ул дәүләтнең эчке, яшерен дәүләт эшләре мәҗлестә сизелми барысы да өстә ята. Татарларның беркатлылыгыннан киләме бу. Һәр эшләре көне-сәгате белән дигәндәй мәркәзгә җиткерелеп тора. Моны бары татарлар үзләре эшлиләр. Моның өчен аларга әллә ни түләү дә эләкми, әмма куштанлыктанмы, бер-берсенә дошманлыктанмы, Мәскәү патшасына хезмәт итәргә генә торалар. Әллә бу татарларның мөстәкыйль дәүләт булып ныгый алмаулары алар хакындагы әнә шундый куштанлык, кеше кул астына сөмәрергә омтылучан булуларыннан киләме? Халык характерындагы сыйфатлар дәүләт идарәсендә һәм дәүләт эшләрендә чагылмый калмый. Шундый көчле ханлык булган, әмма ныгып абруй казана алмаган. Эчке эшләрне яшерен, астыртын алып бара белмәгәнлектәндер, бәлки? Эчке эшләрне кискен итеп, яшерен акыл белән йөртү дәүләтне көчәйтүгә ярдәм итә торган чара. Татарларда дәүләт аппараты сыек булган, ахры. Шуңа бөтен мәмләкәтләр арасында күзгә күренерлек дәрәҗәгә күтәрелә алмаган. Ханнарының да гаремда ятып, миләре сыегайган, билгеле. Теге яки бу эшкә карар иткәндә алар мәсьәләгә дөрес бәя бирә белмәгәннәр. Аннары Казан ханнары җылы яктагы кардәш ырулар яклавына исәп тотканнар. Шуларга таянып алданганнар. Җылы яктагы гаскәрләр кыш көне бирегә хәтле килә алмыйлар. Бу бик хәлиткеч нәрсә. Алардан ярдәм килер вакыт бик кыска — бары өч ай гына. Бу вакыт исә тулысы белән юлга чыгып бетә. Кырымнан яз көне чыккан гаскәр Казанга бары көзгә таба гына килеп җитә ала. Тик бу бер мәгънәсез эш кенә булып кала. Шул тикле гаскәрне биредә тотарга күпме азык-төлек таләп ителә. Ханлык барча халыгын көн-төн эшләтеп тә мондый азык-төлекне әзерли алмаячак...

Мәскәүлеләргә теләп согынучы болгар татарлары мәсьәләнең әнә шул ягын уйлый алганнардыр, бәлки? Җылы яктагыларга өмет сузуның буш икәнен тәҗрибә аша сынаганнардыр? Тагы шунысы бик кызыклы: йөз елдан артык хөкем сөргән ханлык чорында урындагы халыктан бер генә зат та тәхеттә утырмаган. Һәрбер хан читтән килеп тәхетне алган.

Йә Кырым ыруыннан, йә Әстерхан якларындагы нугай нәселләреннән. Бар төштә дә Чыңгыз канына өстенлек бирелгән. Ә болгар татарлары исә аларга дошман итеп караганнар. Килмешәкләр дип кенә йөрткәннәр. Килмешәккә бил бөккәнче, аларга иркенрәк караган Мәскәү падишаһына йөгенүне артык күргәннәр булыр....

Үзара чәкәләш кыза башлаган чакта кинәт дөбер-шатыр килгән тавышлар ишетелә. Зур ишек ачыла һәм аннан берничә кысык күзле кыпчак килеп керә. Болар чапкыннар икән. Котлы сискәнеп, алар янына ашыга. Тегеләр, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, сөйләргә керешәләр:

— Сарытауга юл ябык, Камышлыда мәскәүлеләр, беркемне теге якка да, бу якка да уздырмыйлар!

— Тозлыкүлне мәскәүлеләр биләгән, нугай урдаларына юлны бикләгәннәр.

— Кура шәһәре мәскәүлеләр ягына чыккан. Кырымнан бу якка таба бернинди җайдакны да, җәяүлене дә җибәрмиләр...

Котлы өметсез төстә кулын селти дә чапкыннарга чыгып китәргә ымлый һәм, тәмам ярым үлгән кыяфәткә кергән килеш уфтана-уфтана, үз урынына барып утыра. Мәҗлестә тагын бер мәл авыр тынлык урнаша.

Менә бу чапкыннарны кабул итүне дә алар Мәскәү илчесенә күрсәтми эшләргә тиешләр иде. Бу шәрә баш татарлар чынлап та бер нәрсәләрен дә яшерә белмиләр, ахрысы. Идарә өчен акыл өстенә һәм мәкер дә кирәк шул. Шәрә башларда шул нәрсә житешми бугай. Ә Сөембикә, нинди генә акыллы хатын булмасын, бу кимчелекне бетерә алмый, билгеле. Ул Сафагәрәйне өнәп бетермәгән, сай акыллы булганы өчен. Гамәлдә бит аның бар эшен Котлы һәм бүтән вәзирләр башкарып килде, яңадан тәхеткә менүе дә Котлы фидакарьлеге аркасында гына булды. Бар нәрсәне дә аңа бүтәннәр эшләргә тиеш дип өйрәнгән... (Мәскәү илчеләре катнашында булган бу утырыш мәҗлес турындагы язма шушында өзелә.)

Моңардан соң илче кайтып китә һәм бер атна-ун көннән ультиматум белән янә килә. Иван патшаның әмере катгый: берсүзсез мәскәүлеләргә кушылырга, гаскәрләрне таратырга!.. Әгәр тыңламасагыз, бик начар булачак. Свияжскида йөз мең гаскәр туплана, алар сезнең көлегезне күккә очырачаклар...

Казанлылар бик нык шүрләп, телсез калалар. Куллары дер-дер килә, түшләренә төшкән сакаллары калтырый. Чарасыздан Иван патшаның: Казан тәхетенә Шаһгалине меңгерергә, Сөембикәне улы белән бергә мәскәүлеләр ирегенә тапшырырга, дигән боерыгын үтәргә риза булуларын белдерәләр.

Бу вакытта Сөембикә сарайда түгел, Колсәет утарына улы янына киткән була. Баласын һаман шунда тота ул. Юлда Бәйраш морзаны очратып, аңа каты гына бәрелә: Син, Бәйраш, ди Сөембикә, малайларың өчен ертлачланасың, шулар өчен милләтеңне сатасың. Сөембер җирләрен мәскәүлеләр синең ике малаеңа бүлеп биргәннәр икән? Әйтәм җирле мәскәүлеләрнең артын ялыйсың?.. Әй, Сөембикә, ди Бәйраш, балалар хакына әллә ниләр ярарсың. Милләтем дип тә тормассың. Көч бит алар ягында, Сөембикә... Юк, мин, ди Сөембикә ачуланып, балам хакына да милләтемне сатмам, юк! Сөйләмә, ничек кенә сатарсың әле, үзең дә абайламый калырсың, Сөембикә! Тормыш ул адәмне кырыкка бөгә!..

Сөембикә үзенең ышанычлы яраннарының бик күбесе яшерен генә мәскәүлеләр яклы булуын белә. Шуңа бик пошынып, кайгырып уйлана. Әнә, Бәйраш та сатылган, ниш.лисең, көч алар ягында, дип уфтана. Эчендә нәрсәләр бар, әйтергә курка кебек. Афәтне алдан чамалапмы, кайбер ушлылар шәһәрдән шыпырт кына таялар. Нәрсә бу, көймәнең батуын сизәләрме? Нишләргә, Ирбәк тә кайтып житми ичмаса...

Улы яныннан сарайга кайткач, Сөембикә үзенә карата ниндидер салкын мөнәсәбәт тоя. Асрау кызлар, хатыннар ничектер үзгәргәннәр.

Барысында томса, чытык чырай, турсайган иреннәр. Ә Гөлсаф тумачиның ике-өч көн күренгәне юк. Бик начар фал бу. Менә ике хатын нәрсә өчендер талашып, Сөембикә янына килә. Кем хаклы, кем хаксыз, янәсе. Сафагәрәйнең ике җариясе бер күлмәк өчен сугышып, тагы аның хөкемен көтәләр. Кайбер ахирәтләре аның белән көрешергә килмәде. Күрешкәндә сүз әйтергә шүрлиләр, як-якларына каранып тизрәк китү ягын карыйлар. Яисә күрмәмешкә салышып үтәләр. Гомердә булмаган хәл бу! Моны астан гына Гөлсаф тумачи оештыра. Сарайдагылар барысы да аңардан куркып торалар. Ул мәкерле хатын. Үз кулы белән берни дә эшләми. Шуңа кеше күзендә чиста, абруйлы булып йөри. Ниһаять, бер көнне Гөлсаф тумачи елый-елый аның бүлмәсенә килеп керә. Һәм Сөембикәнең беләкләреннән кочып: «Беттек, Сөембикә, беттек, синең идарәче морзаларың безне кяферләр кулына бирергә ризалашканнар. Иван патша барча кавемебезне суеп бетерү белән янаган!..» — ди-ди үкереп еларга тотына. Ул арада барча асрау кызлар, хатыннар килеп, Сөембикәгә сыенып елый, каргана башлый. Сөембикә кинәт кызып, читкә тайпылмакчы була. Тик тыгыз җанлы божра аны кысканнан-кыса бара. Бер мәлдән нинди бәла булганы Сөембикәнең аңына барып җитә һәм ул һушын җуя...

Бу хактагы язмалар шушында бетә. Ләкин моңардан соңниләр булганы тарихта билгеле. Үзенең асраулары һәм улы белән бергә Сөембикәне көймәләргә төяп, мәскәүлеләргә алып китәләр. Һич курыкмый кылыч айкап дошманга каршы ташлана торган Сөембикә берни кыла алмый, язмышына буйсына. Киткәндә әйтә: моннан соң бервакытта да ирегегез булмас! Кяферләргә кол ителерсез! И, бәхетсез халкым!..— ди.

Бераз вакыт үтә. Казанлылар һаман аек акыл белән уй йөртә алмыйлар. Үзләренең тискәрелекләрен куалар.

Аннары руслар тарафыннан Казанны яулау сугышы башлана. Кремль стенасы шартлау. Каршы торуның иң хәлиткеч мизгелендә казанлылардан кемдер кальга капкасын ача. Татарларны ерткычларча үтерү, сую башлана. Кремль стенасының бу ягындагы ачык урында киселгән башлардан чүмәлә кебек тау өелә. Шәһәр янындагы авылларда татарларны көчләп чукындыру башлана. Чын мәгънәсендә тәре походы. Биредә шулай урыс шовинизмы тантана итә...

Андрей көн-төн баш күтәрми эшләде. Язды, сызды. Машинкада да үзе басты. Язманың беренче өлеше йөз егерме биттән артып китте. Моны кемгә булса да биреп укытып карыйсы иде. Эшләгән эш турында сүз ишетәсе килә, ә җитәкче галим авырый. Әллә авыруга салышамы? Андыйлар күбәеп китте. Чөнки һәр төштә әллә нинди шомлылык, гаять каты киеренкелек хөкем сөрә. Кешеләр караңгы чырайлы, читләшүле. Ике кеше бергә сөйләшә башласа, өченче әдәм килеп баса. Нәрсә турында гәп коралар икән дип. Шундый шартларда бер гаебең булмаса да, үзеңне гөнаһлы санаган кебек йөрисең.

Иван Грозный чорын яхшы белүче, шул тема буенча тикшеренүче Крушинский фамилияле галим бар иде. Аны яһүд диләр. Ләкин үзе урыс булып кылана. Ике сүзнең берендә: «Наша русская душа»,— дип сөйләнергә ярата. Андрей кулъязмасын шуңар бирде, укып чыгып, фикер әйтүен үтенде. Крушинский теләп риза булды, минем өчен честь бу, диде.

Аның фикерен көтеп йөргәндә, бер көнне Андрейны кафедра утырышына дәштеләр. Нәрсә бар икән, дип, Андрей курка-курка гына килде. Чакырулар берсе дә юньлегә булмый. Сыналган нәрсә.

Андрей ишектән керү белән утырышны башлап җибәрделәр. Гүя аны гына көтеп торганнар. Ул утырыштагыларга күз йөртеп чыкты: кызыл сөйләп, ялагайланып, карьерага омтылучылар җыелган иде. Андрейның эченә салкын йөгерде, аркасын кайнар елдырым пешереп үтте. Крушинский сөйли башлады. Тукта, аның кулъязмасы турында төкерек чәчә

түгелме соң?.. Безнең кафедрада җитлекмәгән фикерле, иптәш Сталин тәгълиматларын үзләштерә алмаган кешеләр бар, имеш... Мисал итеп Андрейны китерә. Ул диссертация өчен әзерләгән язмасында Иван Грозныйның Казанны яулап алгач татарларны чукындыруын шовинизм күренеше дип атый. Иптәш элементарь нәрсәне аңламый: татарларны, башка милләтләрне христианлаштыру дәүләтне ныгыту максаты белән эшләнә. Христианлаштыру өчен вак милләтләр русларга рәхмәт әйтергә тиеш. Үз канаты астына алып таланудан, хәерчеләнүдән коткарган өчен. Әйе. Бу эш Грозныйның даһи алдан күрүе. Чөнки безгә, русларга, ул эш белән тагы йөз еллар буе шөгыльләнергә туры киләчәк. Вак милләтләр моны үзләре телиләр...

Андрей үз колакларына үзе ышанмыйча тыңлый. Дөресрәге, Крушинскийның сүзләре бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга шикелле. Ул бигрәк тә кешеләрнең шундый хыянәтчел булуына таң калды. Крушинскийга чын күңелдән ышанган иде юкса...

Крушинский мишеньне күрсәтте, атучылар күп булачак. Сунарчыларга атарга гына булсын. Андрей нигәдер Крушинскийга күз төшерде: теге орден алган кебек шатланып, ябырып утыра иде. Эчендәге агуларын чыгарып кеше өстенә ташлагангамы, үз колгасын сазга батырганга күрәме шулай күтәренкеләнгән? Чит илләрдә кеше кешегә — бүре дип язалар. Ә менә бу нәрсә соң, кеше кешегә — бүре күренеше түгелмени?

Икенче, өченче сөйләүчеләр Крушинский фикерләрен куәтләделәр. Рус халкына яла ягa, диделәр. Вак халыкларны берләштереп, ул киң күңеллелек күрсәтте... Рус халкына карата начар фикер йөрткән кеше совет вузында булырга тиеш түгел. Аны чүп үләне шикелле йолкып ташларга кирәк!

Андрей баш очында болытлар куеруын сизде һәм яшен чаткыларының йөрәгенә китереп сугуын бик авыр кичереп утырды. Ишеккә күз төшергәләде, алырга килмиләрме? Андый хәлләр дә хәзер гаҗәп түгел иде.

Сүз бирелгәч, Андрей иң элек үз хезмәтеннән баш тартты. Ялгышканмын, дип тәүбә итте. Миндә бернинди начар ният булмады, диде. Крушинскийга аның ялгышларын күрсәткән өчен рәхмәтләр әйтте. Башка үзен талкучыларга, кимсетүчеләргә яки егучыларга да рәхмәтләрен белдерде. Аларны үзен коткаручылар, түбән тәгәрәүдән тотып калучылар, дип бәяләде. Шулай итмәгәндә үз хәленең хәрти булачагын яхшы аңлый иде ул.

Гаҗәпкә каршы, Андрейны өнәмәүче бер абруйлы гына галим аны яклап чыкты: аспирант үзенең ялгышын тирән таныды, диде. Ялгышу һәркемдә була, ялгышу гаеп түгел, ялгышыңны танымау гаеп, дигән борынгылар. Андрей: беттем, беттем, дип утырганда хәл кинәт уңай якка борылды да куйды. Аны урыныннан кумадылар. Ләкин күпмегә? Бу көтелмәгән зарбыдан соң Андрей бик озак исен җыя алмыйча йөрде. Чынлабрак уйлаганда, шаккатарлык әллә ни юк. Кафедра берничә галимне үз хезмәтләреннән, фикерләреннән ваз кичәргә мәҗбүр иттеләр. Андрей бернинди яңалык эшләмәде, теге галимнәр салган сукмактан барды. Шулай да үзең хак дигән фикерләреңнән баш тарту авыр икән. Ә бит барча мәгълүматлар тик фактларга гына нигезләнгән иде. Фактлар шулай бит, дигәч, бер галим: «Фактка яра — үз файдаңны кара», — дип әйтеп куйды. Тыштан җаныңны саклар өчен үз мәсләгеңнән баш тартасың, ә эчтә ми тартмасында: юк, алай түгел, минемчә, дигән уй бөтерелә. Нәкъ теге Галилей хәлләтендә ул хәзер, тик кечерәк масштабта. Галилейне чиркәү карагруһчылары «Кояш тирәсендә Җир әйләнә» дигән ачышыннан ваз кичтергәннәр. Ә Галилей эчтән генә: «Ә Җир әйләнә, барыбер әйләнә», — дип кабатлаган. Шуның шикелле Андрей да үҗәтләнеп: «Юк, мин хаклы, әйе, хаклы!» — дип эчтән тәкърарлап йөри. Һәрбер кеше шулай икегә аерылырга мәҗбүр. Башын саклар өчен

Рәсмилек кушканча икейөзләнергә, ялганларга тиеш. Шунсыз яшәү мөмкин түгел. Юкса, халык дошманы дип атыйлар, тормыштан сызып ташлыйлар. Әнә шулай бер шәхес ике төрле булып тереклек итә. Нигә бу шулай?

Бик күп шик-шөбһәле уйларыннан башы тубал булды. Берничек тә очына чыгып булмый иде. Бер очрашкач, ул кулъязманы Платонга бирде. Бөтенләй чит өлкәдә эшләүче кеше ни дә булса әйтер. Дөреслек кайда, нәрсәдә? Әмма Платон Андрейны тагы да ныграк гаҗәпкә калдырды. Шовинист булмаса, бер милләт тә үз дәүләтен төзи һәм ныгыта алмый. Телисеңме, теләмисеңме, әмма тарихи практика шулай...

Тукта, Платон теге аны баш тарттырган, үз дошманнарын мактарга мәҗбүр иткән җыелыштагыларча сайрый бит? Нишләп, каян бу? Гаҗәп, гаҗәп!

Шактый кызып, фикерләрне чарпалаштырып алгач, Андрей тынычрак булырга тырышып әйтте:

— Хөкүмәтнең вак милләтләрне бетерүгә көйләгән Иван Грозный сәясәтен дәвам иттерүе мине чыгырдан чыгарды. Уйлап кара, канлы Грозный һәм Советлар?..

— Вак милләтләрне берләштереп, ул империя төзегән. Шуннан соң гына Россия белән санлаша башлаганнар. Бу начармыни?

— Дөресе, Грозный чит җирләрне басып алган,— диде Андрей кызмаска тырышып.— Болгар-татар үз җирләрендә мөстәкыйль дәүләт булып яшәгәннәр. Грозный аларның җирләрен, мөлкәтләрен алып, үзләрен аскан-кискән, чукындырган...

— Кыргый азиатлар белән тагын нишләр идең? Яу белән рус иленә янап торганнар...— диде Платон, бу дәлилгә җавап таба алмас дигәнрәк төстә.

— Алар кыргый булмаган, чөнки кою аларда безгә караганда элегрәк барлыкка килгән.

— Үзләрен Европа цивилизациясенә якынайткан өчен вак милләтләр русларга рәхмәтле булырга тиешләр!

— Нинди якынайту! Вак милләтләрне, аеруча болгар-татарларны рәхимсез изгәннәр, аларны бетерү сәясәтен тормышка ашырганнар. Бер акыл иясе әйткән: әгәр минем халкым икенче милләтне изеп яши икән, мин үземне иң бәхетсез кеше саныйм, дигән. Төшенәсеңме, мине әнә шул нәрсә җитәкләде...

— Синең бәлаң бу, Андрей,— диде Платон үзен өстен тойган кыяфәттә, аңа чәнчеп.— Син идеалист, бәхетсез кеше!

— Аңлыйм да бит,— дип килеште Андрей гаепле кебек.— Ахмак тәрбия алганмын. Бар нәрсәдән хаклыкны өстен күрәм шул.

— Империя булмыйча торып, бер милләт тә халыкара аренага ирешә алмый. Империя булмаса русларда Толстой, Достоевский, Чайковский, Менделеев, Репин кебек дөньяви даһилар туа алмас иде, минемчә.

— Сүзләреңдә дөреслек бар кебек. Германиядә — Гете, Шиллер, Һейне, Франциядә — Бальзак, Гюго, Англиядә — Доккенс, Киплинг... Бу дәүләтләр империя булып дан тоткан чорда туганнар. Империя таркалгач, андый даһилар юк. Без читкә тайпылдык. Даһи туу өчен бу закончалык була алмыйдыр... Кыскасы, зур милләт кечкенә милләтнең үрчү, яшәү хокукын бетермәскә тиеш!

— Ә табигый ассимиляцияне кая куясың? Тарихи процесс.

— Әмма зур милләт кечкенә халыкның мәнфәгатен сакласын. Аңа яхшылык эшлим дип бетерү, аны йоту шартлары тудырмасын. Башка милләтләрне көчләп юк итү вәхшилек түгелмени?

— Нигә аның өчен синең башың авырта? Дурак! — диде Платон, хәтәр кыза башлап.

— Әх, аңламыйсың, Платон Никитич,— дип Андрей гасабиланып күкрәк турын учы белән ышкырга тотынды.— Мин рус халкын кайгыр-

там бит. Әнә чит илләрдә русларны бер дә яратмыйлар, варварлар дип атыйлар? Ни өчен? Вак милләтләрнең яшәү хокукын кыскан өчен!

— Юк, Советлар булган өчен!..

— Ансы да бардыр. Күбрәк вак милләтләрне бетерү сәясәте алып барганга күрә яратмыйлар.

— Юк, килешмим. Ахмак син! — Платон капылт кына калкынды да, кулын өметсез селтәп, тап-топ килеп бүлмәдән тышка атылды. Алар шулай бозылышып аерылыштылар. Шуннан соң очрашырга да, сөйләшергә дә туры килмәде.

Тагы шунысы кызык, Андрейны кулга алгач, аның эше белән шөгыльләнүче инспектор сүзне нәкъ шул эз белән йөртте, гүя алар Платон белән фикерләшкәннәр кебек иде. Андрейны көн саен берүк төрле сорауларга әллә ничә тапкыр җавап ала-ала җәфалап бетерделәр.

Тикшерүче чигәләре көмешләнә башлаган, какча озынча битле, тирән баткан кечкенә чепи күзле тәбәнәгрәк бер адәм иде. Буе белән чагыштырганда башы зур булып тоела иде. Сүзен кычкырып сөйли, кычкырганда борын яфраклары селкенеп-селкенеп китә.

— Син бер мәкаләңдә Грозныйның вак халыкларны яулап Россиягә кушуын прогрессив дип язган булгансың, аннары фикерең үзгәргән. Ни сәбәптән?

— Юк, фикерем үзгәрмәде, — диде Андрей. — Грозный эшләрен прогрессив дип язарга мине мәҗбүр иттеләр.

— Кем мәҗбүр итте?

— Тема җитәкчесе. Тормыш кануннары кешедән көчлерәк.

— Тарихтан билгеле, вак халыкларны русларга кушып Грозный аларны кыргыйлыктан чыгарган...

— Вак халыклар берсе дә кыргый булмаган, руслар дәрәҗәсендә булган. Татар исә кайбер өлкәләрдә алгарак та киткән булган. Мәсәлән, чуен кою һөнәрен белгәннәр...

— Ялганлыйсың, проститутка! — дип җикерде инспектор, сеңерле муенындагы тамырлар чыбыркы сабы юанлыгы булып кабардылар. — Татарлар әшәке, кыргый булганнар...

— Юк, кыргый булмаганнар, үз культуралары булган, — диде Андрей тыныч кына.

— Тем хуже для тебя! Ахмак, кыргый дисәң, үзеңә җиңел була иде! Бүреләр кебек кыргыйлармы?

— Юк, руслар дәрәҗәсендәге кешеләр!

— Дурак. Үзеңә хуже ясадың! Төп-төгәл төрек шпионы син! Мә, сорау алган протоколны укып чык та кул куй...— Инспектор аңа бер бит кәгазь төртте. Сораулар машинкада басылган, җавапларны бу кансыз язып барган. Андрей укып чыкты да имзасын салды. Теге исә протоколны тизрәк тартып алды. Кире уйлый күрмәсен дигән кебек иде.

Андрей, үз башыннан кичкән бу хәлләрне сөйләп, бер көнне Зәйгә дә ачылды. Сакта торганда Зәй аны үлемнән коткаргач, алар якынаеп киткәннәр иде. Надзирательләр йомшаграк булганда траншея чокырына качып сөйләшеп алгалыйлар. Ләкин арестантлар белән кечкенә генә контактка керү дә бик каты тыела. Тәмәкеләренә ут бирү җинаять санала һәм ротада «чепе» буларак тикшерелә иде. Үз иптәшләрең сата, йә күршең барып әйтә. Бирелә нинди дер, «круговая порука» яшн. Әз генә кыек эшләнсә, шунда ук фаш итүчеләр табыла.

Ә Зәйнең күңеле нидер белергә, аңларга омтыла һәм тыелган нәрсәләргә аеруча нык тартыла торган чагы иде. Ул тартылу шундый көчле, янап торган куркуларны да җиңә. Җаны хаклыкны белергә сусап кына тора. Ә Андрей Андреич кызыклы нәрсәләр турында фикер йөртә. Зәйнең күз алдын каплап торган пәрдәне ача барган кебек итә иде. Зәй сорау бирми, сорау бирсәң, Казан шикләнеп, уйланып кала. Һәр кешедән шикләнергә ачы тәҗрибә өйрәткән аны. Гаеп итәргә күңел базмый. Шулай да Казан фәлсәфәгә бирелеп, томанландырып сөйләргә ярата. Әллә уйлау рәвеше шундыймы?

...Бөек Гаделлек идеясен тормышка ашырырга ниятләп революция ясаганнар. Бик яхшы, хаклы һәм зарури. Тышкы дошманнарны бетерү дә бик кирәкле чара. Аннары эчке дошманнар... Идеяне чынбарлыкка әйләндергәндә бер дә корбаннарсыз мөмкин түгел. Чыгымнарсыз гына берни дә таба алмыйсың. Ләкин менә шул чакта идеягә артык зур власть бирелә. Идея үзен контролировать итә алмый. Анда ни буласын белми идея, теге яки бу эштән ни килеп чыгуы турында хисап бирми, һаман көрәшне бер юнәлештә генә көчәйтә. Бу инде берьяклылык һәм зур хата. Идеяне чынбарлыкка әверелдергәндә практик тормыш белән чагыштыра барырга кирәк. Кешеләр тормышына нәрсә бирә, аларны нәрсә эшләтә?.. Ләкин андый контроль юк һәм идея үзен-үзе бетерү юнәлешендә эшли башлый. Идея житәкчелегендә торган кеше акыл белән эш итәргә тиеш, идеягә генә ышанып, аңа гына артык күп ирек бирелсә, чыгырдан чыгара. Идеянең күзе юк, акылы да юк. Идея дигән инструмент белән эшләүченең акылы, күзе, гоманы булу зарури. Ә ул юк. Һәм идея үзен тормышка ашыру юлында казганган, көч түккән, кан койган адәмнәрне кырырга, бетерергә керешә. Идея үзенең улларын, үзен тормышка ашыручыларны ашый башлый. Милләтләрнең чәчәге саналырлык кешеләрне лагерьларга яба, сөргеннәргә сөрә, җәзалый, юкка чыгара. Кешеләргә гаделлек китерергә тиешле идея аларны җәзалау, газаплау коралына әйләнә. Идея хәтәр нәрсә, аны акыл белән куллана белмәсәң, ул җимерә, бетерә. Шешәдән чыгарылган гыйфрит кебек. Идеяне гуманлы эшләр өчен җигәсе урында, идея адәмнәрне начар эшләр эшләргә җигә. Ә идеяне практика белән сыный-сыный бик саклык белән генә чынга ашыра бару тиешле. Бездә исә ул кабалану, сикерүләр белән бара. Идеяне практикага якын китерергә куркалар. Әллә безнең идея конкрет практикада үзен саклый алмыймы? Конкрет тормыш өчен ярап бетмиме? Әллә конкретлыкка килеп бәрелүгә, ул коелып төшеп, чәлпәрәмә киләме? Идеяне конкрет эшләрдә сынау үткәрәсе урында һәр җирдә мәҗбүр итү, көчләү методы кертелә. Ә һәр эшнең үз җае, хәрәкәт итә торган юлы, фасылы бар. Кояш чыга, көне буе нурларын Җиргә коеп тора да бата. Шуның кебек, һәр эшнең табигать белән, кешеләр тормышы белән аерылмас бәйләнгән җае, әмәле бар. Менә шушы җай хәрәкәтенә көчләп нидер тагалар, кертәләр һәм барча җайлар бозыла, буксовать итә башлый. Яки кире нәтиҗә бирә.

Иртән үк яңгыр яварга тотынды, төзелештәге солдатлар һәм сөргенчеләр төрлесе төрле ярыкларга кереп ышыкланган иде. Надзирательләр дә постылар. Бер тынгысыз надзиратель генә поскан җиреннән үзенең арестантларына кычкыргалый иде. «Казан, сволочь, син кайда, нигә эндәшмисең, сука!» — дигән ерткыч тавышы яңгыр пәрдәсен ерта-ерта яңгырап китә. Беренче дәшкәндә Казан юри җавап бирми, авыз эченнән генә каргана, сукрана. Менә ул идеянең ерткыч тавышы, дип, Зәйгә аяк кагып куя. Аннары гына надзирательгә җавап кайтара... «Син кем белән анда?» дип төпченә надзиратель. Казан башын як-якка чайкый, армаеның бер минут ирек бирмәгәненә аптырый һәм әйтә: Мин Декабрист белән бергә,— дип ялгандый ул, үзе янында булырга тиешле арестантның фамилиясен кычкырып. Биредә бернинди арестант юк, билгеле... «Кара, идея ничек тикшереп кенә тора,— дип пышылдый Казан Зәйгә таба иелеп.— Мине күзәтеп торырга Декабристка беркеттеләр, аны мин күздән ычкындырмаска тиеш. Идея заданиесе».

— Ә сиңа нинди задание бирде Идея, ә? — дип, Казан кашларын хәтәр җимереп Зәйгә төбәлде.— Минем сөйләгәннәрне йотып торып, тиешле җиргә җиткерергәме, ә? Ялганлама, сине генә заданиесез калдырмаганнардыр?

— Юк, Андрей Андреич, миңа беркем дә задание бирмәде,— диде Зәй ничектер кимсенә башлап.

— Ярый, ышанам,— дип елмайган итте Казан һәм туган җир, ватан турында җанга үтә торган тәгъбирләр сипте. Адәм баласы туган җиренә

күзгә күренми торган чылбыр белән бәйләнә. Һәм туган теленә шулай ук һич тутыкмас алтын чылбыр бәйли аны. Семьясына да бәхет чылбыры белән тоташа ул. Менә өч чылбыр. Гомере буе шушы чылбырлар тартуын тоеп яши. Бу чылбырларны өзсәң, кабат бервакытта ялгап булмый. Ялгасаң да, ялганган төштә сызлау тоене кала. Һәм ул тоен гомер буе сызлавык шикелле җанны бимазалап тора. Изге чылбырлар адәм затына борын-борыннан бирелеп килгәннәр, канына, аңына сеңгәннәр. Аны кеше заты югарылыгында тоталар. Идея ул изге чылбырларга кагылырга тиеш түгел, әмма кагыла, семьяны боза. Ата белән баланы дошманлаштыра. Син кемне, әтиеңнеме, әниеңнеме яратмый идең, ә? Ялганламыйча гына әйт әле?

— Әтине,— диде Зәй ихластан.

— Нигә, әгәр сер булмаса?

— Тапкан акчасын эчеп бетерә, балалар ач, ялангач...

— Ник эчә ул? Татарлар, гадәттә, эчемлек кулланмыйлар?

— Кайгыдандыр, мөгаен. Дөресе: акылы җитмәүдән...

— Сезнең семьяга да идея үзенең кулын тыккан,— диде Казан һәм тирән итеп уфылдады.

— Эшлисең-эшлисең, бер нәрсә түләмиләр,— дип куйды Зәй.

— Әйе, колхозның абруен төшерделәр. Төрмәдә дә һәр зек үзенең көнлек биш йөз грамм ипиен ала. Әллә нәрсә, һич аңлашылмый. Корылыктан иген булмый, әйтик. Гаепләне эзлиләр, председательне эштән алалар. Корылыкка каршы чара күрелде. Икенче елны тагы корылык, тагы председатель оча... Ләкин председательне алмаштыру белән янгыр яумый. Шундый мәгънәсезлек. Ә бит корылыкка каршы чара бүтән: корылыкта уңыш бирә торган яңа сорт арыш, бодай чыгарырга кирәк. Яңа сорт чыгару генетик юл белән генә була. Ә генетиканы буржуаз фән дип хөкем иттеләр. Монда да шул идея эшкә аяк чалды. Фәнгә идея тыгылырга тиеш түгел! Механика, физика нигезләре — константлар, диалектикага буйсынмыйлар.

Боларны Зәй аңлап та бетерми, шулай да йотылып тыңлый. Аның яшь аңы губка кебек теләсә нәрсәне үзенә сеңдерә бара. Зәй кешеләрне милләткә аермый, аның ни икәнен дә белми иде. Барча кешеләр дә бертөсле тоела иде. Алар арасында аерма булуы турында башына да килгәне булмады. Баксаң, милләтләр мәсьәләсе бик мөһим нәрсә икән. Кеше тормышында хәлиткеч рольне уйнавы мөмкин, дип сөйли Казан. Һәр милләт бер-берсеннән ниндидер сыйфатлары белән аерыла. Ул сыйфатлар, гореф-гадәтләр милләт әгъзасына анасының күкрәк сөте белән керә, канына күчә, хисләренә сеңә. Һәм теге яки бу нәрсәгә, дөньяга карашы шул сыйфатлар нигезендә формалаша. Гадәтләр, холык-фигыль сыйфатлары аңа изге, кагылгысыз булып тоела, аңына шулай төенләнә, берегә. Милли билгеләргә әйләнә. Шунлыктан бер үк нәрсәгә ике милләт ике төрле караулары мөмкин, бер үк нәрсәне ике төрле бәяләве ихтимал. Бу начар, билгеле. Бер илдә, бер союзда яшәгәч, безнең бәяләүләр, карашлар бертөрле булуы әйбәт. Ләкин моңа карап кына, милләтләрне ассимиляцияләп, яисә бүтән юллар белән бетерергә ярамый. Милләтләр бетмәскә, милли аерымлыкларын җуймаска тиешләр. Ни өчен? Чөнки һәр милләт бик борынгыдан килә, һәр милләт үз-үзенә кадерле. Аның буыннан-буынга тупланып килә торган үзенең әхлак фонды, рухи фонды барлыкка килгән, формалашкан. Бу нәрсә шул милләт әгъзаларының психологиясендә, фикерләвендә, аңында. Милләтне бетерү әнә шул кеше рухын тәшкил итә торган бермлекләрне җимерү ул.

Икенче яктан шунысы бар: нинди милләт исемендә яшәсәң дә барыбер түгелмени? Рус булдың ни, татар булдың ни, асылда бер үк гомерне, әйтик, бер үк шартларда яшисең. Минем борынгы бабалар грек булган, шуннан руслашып киткән. Миңа хәзер барыбер, мин — рус милләте әгъзасы. Кайчандыр «переходной» буынга гректан рус теленә күчү авыр

булгандыр, билгеле. Ул инде бик еракта калган. Голланд миндә берни дә юк. Хәер, галимнәр арасында эшләгәндә борының грек борыны дип әйтәләр иде әйтүен...

Хәзер милләтләрнең хәле хакимлек итүче күпчелек милләттән — руслардан тора. Руслар азчылык милләтләрне бетерә алалар һәм аларны яшәтү дә алар ихтыярында...

Инде өйлә житкән иде. Яңгыр һаман ява. Солдатларга әбәдкә тезелергә боерык булды. Зәй арестант янында утыруын белгертмәс өчен мүкәләп кенә әллә күпме читкәрәк китте, гел икенче төштән барып, башын калкытты һәм тураеп, тиз-тиз адымнар белән китеп баручы сафка кушылды.

Тагы заемга язылу исемлегенә кул куйдырып йөрделәр. Зәй тагы имза бирмәде. Шунда ук замполитка чакырдылар.

— Фаизов, әллә син кулак малаемы? — дип тотынды замполит һәм чүт кенә халык дошманы итеп күрсәтмәде, һаман шул сүз белән янады. Фаизов, өйдәгеләрнең ашарына, кияренә юк, дип, шуларга ярдәм итмәкче идем, ди-ди зарын аңлатты. Замполит аны юньләп тыңлап та тормады, совет властена каршы кеше икәнсең, диде. Шуннан соң Зәй берни әйтә алмады.

Аңа карата командирларның, иптәшләренең карашы начарланды. Аның һәр кимчелеген көтеп кенә торалар, исәпкә алалар һәм шелтә белдерәләр иде. Бер көнне отбой алдыннан бәдрәфтә аңа «темный» ясадылар. Иптәшләре эштә, занятиедә булсын, аны түбәнсетүне, кимсетүне гадәт иттеләр. Зәй үз эченә бикләнергә мәҗбүр булды. Күптән каптеркадагы егеттән бер пачка мүк тәмәкегә хэбэ гимнастерка юнәтеп өйгә салырмын дип уйлаган иде. Хәзер инде салу мөмкин түгел, беләчәкләр һәм туры судка бирәчәкләр. Зәй аны бер көнне кирзы итеге кунычына урап барды да бер аулакта яшереп кенә Казанга бирде. Тегенең күлмәге бик беткән иде, багы күккә тигәндәй булды.

Бер тере җан күрмәгән шикелле иде, икенче көнне кич белән Фаизовны махсус бүлеккә чакырттылар. Кемдер күргән бит, шайтан, дип, үз гөнаһын кичерә-кичерә уйланды Зәй. Әллә стеналарның да күзләре бармы?

Үз-үзенә нык ышанган лейтенант бик каты яный-яный тиргәде аны, аполитичныйлыкта гаепләде. Моның өчен бүтәннәр булса, статья чәпеп сине утыртырлар иде, ярый, миңа, яхшы кешегә туры килдең, бар, бүтән алай кыланма, диде...

## III

«Җыелышларны ни өчен җыялар икән?» — дип уйлап утыра Зәй. Чехословакиядә булган бер инженер сөйләгән иде: анда җыелышлар бик сирәк була, ди, чөнки мондый чарага киткән вакыт эчендә бик күп нәрсәләр эшләп чыгарырга мөмкин. Ә кемнең кемгә дә булса әйтер сүзе бар икән, ул шул кешегә бара да әйтә. Чөнки җыелышта гел гомуми нәрсәләр генә сөйләнелә. Үзара гәпләшкәндә алай гомуми сөйләргә син ояласың, ә җыелышта бата. Ни өчен гомуми, чөнки шактый нык ялган кушып сөйләнелә. Күзгә-күз сөйләшкәндә син сүзләреңә су куша алмыйсың, ә җыелышта теләсә күпме су катнаштырырга мөмкин. Әнә шулай су кушып сөйләргә мөмкин булсын өчен генә җыелыш ясыйлар шикелле тоела башлый.

Аннары җыелыш — сөйләргә, авызларыннан куык очырырга яратучылар өчен бик җай нәрсә. Биредә шулай үзләренең эшлекле вә тугрылыклы булуларын тәкърарлыйлар. Шул чара белән сәяси капитал туплана, карьера баскычыннан күтәрелергә җай чыга. Нәчәлникның сине уңай

яктан хәтерендә калдыруы бик мөһим нәрсә. Бер кирәкле моментта ул сине исенә төшерүе ихтимал. Кадрлар һәр төштә алмашынып тора. Тормыш барышы үзе сайлый аларны. Шушындый җыелышлар аша сайлый, әзерли. Сөйли белмәгән кешене беркайда да түрә итеп куйганнары юк әле. Зәй әнә сөйли белми, ул бервакытта да нәчәлник була алмаячак. Хәтта нәчәлникның шәүләсе дә була алмас ул. Менә авариядәр буенча мастер Тартакиев кая да булса омтыла. Аны Тугаев урынына була дигәннәр иде, ләкин хатыны белән аерылу һәм хатынының горкомга шикаятьләр язып йөрүе аның алга тәгәри торган тәгәрмәченә таяк тыкты. Хатыннар сүзенә бик нык колак салалар. Фәкать хатыннарының җалобасы аркасында гына харап булган уңган егетләр бар. Хатынга каршы көрәшеп булмый, ахмакланып, кемдер каршы барып маташса, барыбер җиңелеп кенә кала. Кайберәүләр андый хатыннан аерылып котылмакчы була. Ләкин асат кына котылыйм димә, хатын сине тәмам эштән чыгарып бетерә. Күпләр бу хәлне күреп, белеп, агу йоткан җендәй хатыннарына буйсынырга мәҗбүр булалар. Ирлеген, шәхесен расларга теләп аерылса да, инде биография тапланган була. Пычранган биография белән сине кем дәрәҗәле урынга утыртсын?!

Күпләр хатыннары басымы астында яши. Күп очракта теләп алынган басым бу, рәхәт изелү. Адәм баласы нәрсәләргә генә күнекми! Аннары адәм затының бер бөек сыйфаты бар: ул бер өйрәнгән, күнеккән сызыгыннан чыгарга теләми. Күнеккән нәрсәсе гадәткә әйләнә, ә гадәт кешедән өстен була. Күнеккән гадәтен җиңә алмый адәми зат, юк, моңа ихтыяры җитми аның.

Тугаев үзенең чыгышында, гомуми сүзләр сөйләгәннән соң, конкрет эш процессын да беразанализлап үтте. Теге айда Зәй вахтасында авария булган иде. Төнге смена иде. Зәй — бурильщик, станок тормозы аның кулында. Аңа Алкин һәм Малайчук булышалар. Буровой эшчесе бар иде элек, хәзер аны кыскарттылар. Бар эшләрне шушы өч кеше башкара. Зәй үзенең ниндидер сиземе белән турбобурга су бирүне туктатып, измә насосын вертлюгка ялгаттырды. Чөнки шушы тирәнлектә, тәҗрибә күрсәткәнчә, «йотулар» еш була иде. Су белән бораулаганда йота торган тишекне каплап булмый. Ә куерак измә кулланган йоту авызын әкренәкрен капларга мөмкин. Бигрәк тә цементлы измәне әзер тоту отышлы була... Зәй измә насосыннан шәмгә измә акканын һәм турбобур механизмнарын хәрәкәткә китергәнен тормоз тоткан кулы аша сизеп, тынычлангандай булды. Бик эчәсе килә иде. Бер-ике стакан чәй эчеп җибәрсәң иде дип, хыялында кинәнеп торды да, Алкинны чакырып алып, тормозны аңа тоттырды. Үзе культбудкага йөгерде. Аш пешерүче хатын бәрәңге әрчеп утыра иде. Чәе дә суынмаган икән. Зәй утырып та тормады, өстәл янына баскан көе генә стаканга чәй бүлеп, шуны шикәр кисәкләре капкалап эчте. Апа белән бер-ике гомуми сүз алышкан булды да буровойга чапты. Барысы күп булса унбиш минут вакыт үтте микән? Килсә, ни күрсен, Алкин газ биреп, станокны дыр-дыр китереп маташа. Артык көчәнүдән станок шулай дерелдәргә тотына. «Ни булды?» — дип кычкырды Зәй. Тормоз янына елышты. Менә сиңа мә! Ничек шулай булды? Бик тиз арада? Әйе, обвал булган да токымнар инструментны кысканнар, җибәрмиләр. Суырып алып кара... Авызын корт чаккыры!

— Ник шәйләмәдең? — дип җикеренде Зәй Алкинның йөзенә.

— Сизми калдым, кинәт дырт итте дә аска китте! Ничек тотып калып булсын аны?

— Тормоз салырлар, гөмбә!

— Соң, инструмент катлам белән бергә убылды...

— Каян беләсең бергә икәнен?

— Кулым белән тойдым...

— Менә хәзер алып кара! Мә, үзең ясаган авария, үзең төзәт!

— Ай-йай, асат кына минем өскә аударырга нинди оста! Нинди мастер! — Алкинның ачуы купты. Андый чагында аны бәхәс, сүз белән җиңә алмыйсың. Ул сүзгә оста, сүз белән җиңә ул. Бар төштә дә сүз белән өстен чыга. Гаепне дә сүз осталыгы белән бүтәннәргә ябыштыра ала. Зәй дәшми генә эшли башлады. Запас дизельне дә эшли торганына тоташтырып, шәмне, инструментны суырырга җикте. Әмма юк, катлам үзе кыскан нәрсәсен бүре капканы кебек җибәрми иде. Бүре дигәннән, бүре капкынга эләккән аягын үзе тешләре белән яргалап өзә дә, яртысын шунда калдырып, кача диләр. Бирелә дә катлам капкынына долотаны калдырырга туры килмәгәе. Долота гына калса, садакасы гына дияр идең әле. Турбобурны калдырырга туры килсә, баш бетә инде. Алайга китсә, эштән дә куулары бар.

Таң белән Тартакиев килеп җитте. Ул да газ биреп суыртып-тарттырып карады. Индикатордагы кызыл сызыкны уздырырга курка иде. Дөрес курка. Батырланып бирелә берни дә кыра алмыйсың, тагы да хәтәррәк авария ясавың мөмкин. Тали тросы өзелеп, эшчеләрне харап итеп ташлаган очраклар булды. Ул исә судка китә торган эш. Тартакиев ул яктан тәҗрибә туплаган, бик белеп сагая иде. Бераз азаплангач, мастер яңа карарга килде. Шәмне ротор квадратына кертергә һәм кирегә — сүтү ягына әйләндереп, долотадан аерып алырга.

Яңа вахта килде. Алар аварияне күреп сүгенергә, тузынырга тотындылар. Зәй вахтадан китмәде, аварияне бетергәнче эшләде. Аварияне бетерү тактикасы Тартакиев әйткәнчә булды. Шәмне турбобур белән бергә роторда кирегә сүттеләр. Бәхет, турбобурның әз генә өлеше кысылуга дучар булган. Долотадан сүтеп алгач, ул каршылык күрсәтмәде диярлек. Хәзер капкында калган долотаның кырыеннан бораyларга, шуннан юл ачарга кирәк иде. Моны ничек эшләргә? Юлны ерактанрак сабаргамы? Күмелгән долота комачаулаячак бит? Зәй моңарчы мондый хәлгә төшкәне юк иде, бу бәладән ничек ычкынырга белмәде.

Шәмне, турбобурны күтәрттеләр. Менә турбобур буровой идәненә бума елан кебек булып сузылып ятты. Тишекләреннән яшькелт төстәге измәләр ага иде. Тартакиев аның һәрбер буынын җентекләп тикшерә башлады. Шөрепләрне сүтеп карарга туры килә иде. Тәмам пычранып, юешләнеп беттеләр...

Бу авария проходкага бик нык сукты. Ниндидер бер кискен моментка туры килде. Контора проходка буенча планын өзер-өзмәс кыл өстендә дип әйтерлек бара иде. Бер генә метр запасы юк иде. Шуңа күрә әлеге авария барча җиргә бик тиз ишетелде. Бригадада калмады, конторга хәтле барып җитте. Югыйсә бораулау эшендәге мондый гына кимчелекләр бригада эчендә бетә торган иде. Ә моны элеп алдылар, бар җыелышларда төрләндерә башладылар. План өзелү алдында тора. Аның сәбәпләрен дәлилләргә кирәк иде.

Җыелышта Зәйгә тагы аңлатма бирергә туры килде. Инде ничәнче мәртәбә бу хакта сөйли ул. Президиумда утыручы местком председателе Холодец аңа кисәтү ташлады:

— Фаизов, син кеше гаебен үз өстеңә алма, — диде шактый рәсми корылык белән. — Аварияне Алкин ясаган, ул җавап бирергә тиеш. Дустыңны ышыкламакчы буласыңмы? Әллә яхшы кеше аты алырга омтыласыңмы? Андый юл белән абруй яуламыйлар...

Аның хаклы сүзләреннән Зәй кимсенеп утырды. Аварияда минем гаеп тә бар бит, ди ул һаман эчтән генә. Билгеле, формаль яктан дөрес. Бораулаучыны ярдәмче алыштырырга, үзе мөстәкыйль эшли белергә бурычлы. Әмма бирелә ситуация бүтәнчә. Берничә хәлләрнең бергә туры килеп тоташуы бик куркыныч хәл тудырган.

Холодецның болай Зәйне Алкиннан аерып куюының ниндидер сере бар шикелле. Алкин җыелыш саен диярлек чыгыш ясый. Русчасы бик шәп, сиптерә генә. Болай да сүзгә сәләтле кеше. Аңарда ниндидер үҗәтләнү дә үзен нык сиздерә. Бер дә сүзен бирә торган түгел ул. Һәм

чыгышы саен диярлек нәчәлник яки местком эшендәге теге яки бу кимчелек турында әйтмичә калмый. Менә бик дөрес кенә булырга тырышкан тәнкыйтьченең дә гаебе килеп чыкты. Моны болай шома гына уздырып җибәрергә ярыймы соң? Бу астан гына эшләнә торган нәрсәдә Тугаевның катнашы да юктыр. Әмма нәчәлник тирәсенә елышкан куштан-ялагайлар һәрчак була һәм алар нәчәлник өчен нәчәлникның үзеннән дә ныграк кайгырткан булып йөриләр. Нәчәлник исә куштаннарының тырышып чабуларын, суны болгатуларын белеп, күреп торса да эндәшми. Эндәшмәү белән үзенең ризалыгын белдерә. Дәшмәү ризалыгы белән астан гына күп нәрсәләр эшләнә.

Алкин үзенең чыгышын нәкъ элеккегеләре кебек башлады:

— Безне руслар кеше итте һәм хәзер дә безгә булышалар. Карусыз рус халкына рәхмәт... Без рус иптәшләргә бурычлы...— Бу аның бисмилласы, аннан төп темага күчте.— Мин үземне якларга җыенмыйм, әвариягә китергән кимчелекләрне йомып калдырганга борчылам,— диде ул.— Колоннага тормоз салмагансың дип гаеплиләр. Мин тормоз бирдем, ләкин ул эшләмәде, лебедка барабанына трос чорналмады. Дефектлы ул. Аннары насос эчәгесе берничә җирдән тишелеп акты, басымны саташтырды. Ни өчен безгә шундый брак запчастьлар бирәләр? Бу исә нәчәлникларның тәэминатчыларга таләпчән булмауларында, җинаятьчел килешүчәнлекләрендә. Бурильщикларның брак инструментлар белән ничек газапланып эшләүләрендә Тугаевның бер гаме юк. Эшчеләрне түгел, бары үзен кайгырта: тәэминатчылар белән әчелешле булудан курка ул. Таләп итми, конфликтка керми. Аңа үз гаме гамь. Әгәр эшчеләр өчен тырышса, өстәге нәчәлникләр белән ачуланышырга туры килә. Бүтәннәрдә үзе турында начар фикер калуы бар. Бу нәрсә Тугаевның планына керми. Аның яхшы булып кына каласы килә. Бигрәк тә өстәге нәчәлникләр каршында... Ә авариядә минем гаебемә килгәндә, мин геолог Байкиннан белештем. Ул әйтә, монда бурильщикның гаебе юк, чөнки җир катламы түбәнгә ишелгән. Тормозы төзек булган очракта да ишелү колоннаны аска өстерәп төшәр иде, дип аңлата. Бу яктан да гаепне бер кеше өстенә ташлау гаделсезлек! Кемнедер наказать итәргә кирәк булган өчен генә мине «козел отпущения» ясарга ярамый. Бу житәкчелекнең, бигрәк тә Холодец иптәшнең башбаштаклыгы! Бездә ничектер бар нәрсәгә бер Холодец баш шикелле. Конторда, менә Виктор Михайлович ни әйтер, дип аның каршында куркып торалар. Виктор Михайлович үзен демократ, халыкчан итеп таныта да, дөреслеккә күз йома. Аеруча нәчәлникларның кимчелеген күрмәскә, белмәскә өйрәнгән. Ә манма тиргә, суга батып эшләүче эшче әз генә бер хата җибәрдеме, шуны бишләтә күпертеп тәрләндерергә оста. Шуның аркасында гына җылы урында әйбәт утыра ул...

Алкин киңәшмәнең киеренкелеген арттырып җибәрде. Бәлки кискенрәк әйтеп ташлагандыр, әмма Холодецка карата беренче мәртәбә дөрес сүзләр яңгырады. Ләкин Виктор Михайловичның исе китмәде. Таянычлары күп һәм нык икәнен белә ул. Ә Алкинның бер ышанычлы терәге дә булмавын яхшы сизә. Ул, чыннан да, кая барса да «җәмәгать җаны» булырга тырыша һәм була да. Авыр вакытларда аңа гозер белән килгән кайберәүләргә булыша да ул. Беркемгә дә ярдәм итмичә генә халыкчан булып булмый. Бер кешегә, перспективасы булган кешегә, булышканын унга кабатлап күрсәтә белә. Кыскасы, елгыр кеше. Төсе-кыяфәте дә аның үтемби икәнен чамаларлык төсмерләр белән тулы. Юка чәчен бер якка эз калдырып тарап куйган, киң маңгай, кылыч борын, елмаюы җәелергә генә торган юка иреннәр. Маңгай эченә батып торган кечкенә күзләрниндидер эчке сер белән карыйлар.

Холодец чыгышын врач биргән белешмә укудан башлады. Алкин, эшкә чыкмый калгач, шул көгазьне китергән икән. Врачтан барып белештем, диде Холодец. Яшь кенә врач кыз миңа елый-елый сөйләде: Алкин аның янына килә-килә интектереп бетергән. Врач авыруын тапмаган, теге

әллә ниләр белән янаган, симулировать иткән. Врач аннан котылу өчен генә шушы белешмәне язарга мәҗбүр булган. Менә, иптәшләр, Алкин бүтәннәрнең кимчелекләрен күрергә бик маһир, әмма үзен нигәдер бер дә күрми. Үзеңне күрү шактый авыр нәрсә, кайбер адәмнәр, гомумән, бары бүтәннәрне генә күрүчән. Менә белешмә Алкинның чын йөзен күрсәтә, аны сурәтләп торасы юк. Нинди генә эштә дә эленке-салынкы эшләвен күреп торалар. Авария дә аның салкын каравыннан. Юкка гына Байкин аны яклап маташа. Алкинны икенче эшкә — электрик итеп күчердек. Анда да чатаклыклар китереп чыгарды. Һәр төштә сүз белән алдырмакчы була, алай гына булмый, кулың да эшли белсен... Менә ул безнең тәэминат мәсьәләсенә кагылып үтте, Тугаевны гаепләде. Ләкин биредә шундый механизм: менә запчастьлар кайткан, әмма Тугаев аларның дефектлы икәнен яхшы белә. Алырга мәҗбүр, әгәр алмасаң, башкалар алалар да бетерәләр, сакалыңны учлап каласың...

Аның сүзе бүленде. Президиум өстәле каршында бала күтәргән бер хатын-кыз пәйда булды. Баласы шактый зур. Болай юрамалый, күрсәтү өчен күтәргән шикелле иде. Үзе ирләр пинжәге кигән, башын ак яулык белән бәйләгән. Нишләптер аны беркем дә тыймады, монда җыелыш бара дип әйтмәде.

— Минем ирем Мурасов Әсгатьне беләсез,— диде чак ишетелерлек татарчасы белән.— Моннан бер ел элек буровойда авариядә үлде. Контора фатир вәгъдә иткән иде, чөнки Мурасов һәрчак коммунистик хезмәт ударнигы булды. Шул вакыттан бирле менә местком председателе Холодец вәгъдә итеп йөртә. Тагы исемлеккә теркәмәгән...

Хатын сүзләрен тын калып тыңладылар. Холодец трибунадан президиум ягына борылып, Тугаевка төбәлде. Тугаевның яңак тамырлары тартышканы күренде, битенә көрән тимгелләр дә типкән иде. Ул Холодецка күзләренең агы белән карап алды да торып басты.

— Иптәш Мурасова,— диде ипле тавыш белән.— Бу — квартира мәсьәләсен хәл итә торган урын түгел. Без аны местком утырышында карарбыз, хәл итәрбез. Өлегә кайтып торыгыз.

— Сез барыгыз да алдыйсыз! — дип хатын үксеп җылап җибәрде. Кемнәрдер урыннарыннан кузгалып, аны ике ягыннан култыклап алдылар да ишеккә таба әйдәделәр.

Холодец исә берни булмагандай сүзен дәвам итте:

— Алкин безнең штатный тәнкыйтьче булып китте. Эшләргә дисәң, ташка үлчим, тәнкыйтьләргә аннан өстен чыгучы юк. Нинди максатны алга сөрә торгандыр, аңлашылмый...

— Мин дөреслек дәгъва итәм, бүтән максатым юк,— дип кычкырды Надир. Төрле яктан аны тыйган тавышлар ишетелде. Холодецның да ялагайлары күп иде.

— Синең үз дөреслегең, безнең үзебезнең дөреслек. Дөнья шулай корылган. Син, мин аны үзгәртә алмыйбыз. Шуның өчен гамәлдәге тәртипләр белән килешеп яшәргә кирәк...— дип гайрәт чәчте Алкинга каршы берсе.

Халык эндәшми, башын иеп тыңлап утыра. Күбесе русча белми торган татар егетләре. Алар эшләргә генә осталар, сөйләргә, бирәр нәрсә дәгъваларга булса — юк, берни әйтмиләр. Арттан килеп колакларын кисеп алсалар да, борылып карарга кыймаслар. Бу халык белән теләсә ни эшләп була һәм, тагы да аянычы, аны теләсә нишләтеп була... Алар шундый карусызлар, күндәмнәр. Күп авырлыкларны бер сүз дәшми үз җилкәләрендә алып баралар. Таләпчән түгелләр. Укымаганлыктанмы? Анысы да бардыр, билгеле. Кара эш авыр әле, үзеңне-үзең агартырга вакыт та, көч тә калмый шул. Шуның өстенә авыр тормышта үсү күбесенә үзенең пичәтен салган. Хәзер менә чагыштырмача әйбәт шартларга эләккәч тә элеккеге кыерсытылганлык үзен нык кына сиздереп тора.

— Ни өчен Соня Валеевага квартира бирдегез? — дип әйтеп куйды кайсыдыр. Холодец бу көтелмәгән сораудан аптырап калгандай булды, Тугаевка карады, аның карашын көтте, теге реакция белгертмәде.

— Ул методист, кирәкле кадр, — диде Холодец ничектер төшенке тавыш белән. Бит очларына нигәдер сизелер-сизелмәс алсулык типте. Ничектер эш биредә бик үк чиста түгел шикелле тоела иде. Масус белемле яшь белгечләрне торак белән тәэмин итү турында хөкүмәт указы бар, аны беләсез...

Ә халык арасында бу бик купшы киенеп, бизәнеп йөрүчән хатынмы-кызмы турында бүтәнрәк сүз йөри иде. Конторадагылар Сонядан арынмакчы, ягъни аны эшеннән икенче төшкә күчермәкче булганнар. Соня шуны белгән дә әйткән ир-атларга: барыгыз да мине файдаландыгыз, хәзер ярамый башладыммыни? Ә? Ә? Менә сезгә дип, күкиш күрсәткән. Мин беркая да китмим, дигән. Бәлки квартира биреп аңардан котылмакчы булганнардыр? Сөйлиләр, контордагы һәр ир-атка аның козырьлары бар, ди һәм берсеннән дә куркып тормый, имеш. Кулдан-кулга йөрткәннәр дә хәзер аткармакчы булалар...

— Бәлки, Алкинны конторга тәнкыйтьче итеп күчерергәдер, чыннан да, Виктор Михайлович, ә? — дип шаяртып башлады сүзен Тартакиев. Шунда кемдер сүз кыстырды:

— Конторга күчкәч, тәнкыйть итми башлаячак ул!

Арттагы рәтләрдә дымык кына көлешеп куйдылар.

— Ә бит Алкин хак сүзләр сөйләде, иптәшләр. Юк, уйнап әйтмим. Шул ук запчастьлар турында. Җитәкчелек бу мәсьәләдә бик булдыксыз, эшне үз агымына куйган. Алма пеш, авызыма төш, дигәндәй, биргәнне көтеп яталар. Буровой станоклар тузган, зур нагрузканы күтәрә алмыйлар... Буровойда геология хезмәте юк дәрәҗәсендә, бөтенләй сукыр килеш бораулыйбыз. Киңәшмәдә геология службасы Байкин утыра, моны аның колагына әйтүем...

— Аның колагы каты булырга тиеш, — дип әйтеп сүз кыстырды кемдер һәм тыенкы гына көлеп куйдылар.

Чыгыш ясаучы тагы күп кенә хәл ителмәгән, һаман сузылган мәсьәләләр турында сөйләде. Ул һәрбер мәсьәләдә җитәкчелеккә шырпы кадап үтә иде. Моны ничектер әдәпле итеп, тегеләй дә, болай да аңларга мөмкин формада үткен сүзләр белән әйтә. Әче-әче чеметтереп ала, астан гына. Бик итагатьле рәвештә генә. Ләкин үзенең бик яшерен, хәтта үзенә икърар итәргә базмаган максатын сиздереп куя. Эшне кайгырту белән бергә, һәр адәм заты үзен дә кайгырта. Тартакиев чыгышында тыштан андый нәрсә беленмәсә дә, мөнәсәбәтләр механизмына якын кешеләр астарны сизмичә калмыйлар. Тартакиевның да дәрәҗәгә күтәреләсе килә булыр. Бораулау конторын аның җитәкчелегенә бирсәләр, ул эшне наять итеп көйләр иде. Башлык булырга данныйлары да саллы аның.

— Мин җитәкчелекне аңлап җитмим, — дип сүзен дәвам итте Тартакиев. — Ул горкомнан коты чыгып, куркып тора. Аннан шалтыраткалар, калтырап төшәләр. Горком кешеләренә тәлинкә тоту шулкадәр нык, контора машиналары горкомга хезмәт күрсәтә. Миңа ашыгыч аварияне бетерергә барырга кирәк иде, машинаны горкомда эшләүченең шәхси хаҗәте өчен бирделәр. Эш шактый тоткарланды. Теләсә нинди горком кешесе контор эшенә тыгыла. Эш процессына уңайсызлык тудыра...

Тартакиев шәбәйде, тыңлаучылар үзләренең ымнары, чырайлары белән аның сүзләрен тулысынча хуплыйлар иде. Әллә ул Тугаевның горкомга омтылуын, дәрәҗә баскычыннан тагы бер күтәрмә өскә күтәрелергә теше-тырнагы белән тырышуын чамалый иде микән.

Җыелышка йомгак ясап сөйләгәндә Тугаев тәнкыйтьнең кайберләрен генә дөрес дип тапты. Күреләә торган чараларны әйтте. Киная беләнрәк сөйләүчән ул. Холодецка шулай бер-ике шырпы төртеп узды, ләкин йомшак кына итеп. Чөнки Холодецтан яшерен шүрли иде. Холодец су

астында ут яндыра ала торган зат. Тугаевның эчке принцибы йомшаклык күрсәтмәү, коллектив аның идарәчел кулын сизеп торырга тиеш. Юк, ул куркытмый, әмма шулай да.

Һәркемнең үзе генә белгән яшерен теләге, максаты бар. Тугаев бер күзәнәкле гади генә кеше түгел, җилнең кайдан кая таба искәнен тиз сизеп ала торган зат. Бер очракта да төшеп калырга теләми ул.

Тугаев — күндәм, тыңлаучан, горкомлылар шул сыйфатыннан файдаланалардыр. Күндәм атка ике камыт кигертәләр, дип юкка әйтмиләр. Ул килешүчән дә, соңгы вакытларда аның бу чигенүчәнлеге нык кына үзен сиздерә кебек. Ул алай ук йомшак түгел иде, мөгаен хатынының йогынтысыдыр. Хатыны врач, шактый көчле ихтыярлы шәхес. Горкомдагыларның хатыннарын дәвалый. Хатын-кызның бер-берсенә сүзе үтә. Ә хатын сүзе ир-атка сеңә. Кайберәүләр әнә шундый юл белән дә күтәреләләр. Тормышта еш була торган хәл. Ләкин Тугаев андыйга нәфрәт белән карый иде. Ул дөреслек ярата, җаны шуңа авышкан аның. Әмма адәм баласы көн дә үзгәреп тора. Фикерләре дә шартларга карап үзгәрә. Бүген болай, иртәгә тегеләй. Фикер-уйлары үзгәрсә дә, җаны бик тотрыклы. Ялганны бер дә күтәрә алмый Тугаев. Хатыны аны шул мәсьәләдә һаман тәрбияли. Рәсмилектә, рәсми сферада ялгансыз булмый, дип исбат итә ул. Тугаев ни әйтергә аптырап кала.

Ялганның каян башланганын бервакыт чамаларга туры килде аңа. Казанга киңәшмәгә килгәч, накладной буенча насос эчәгеләрен эшләп чыгара торган СКА-1 заводына барды. Цехларга да керттеләр аны. Кайнар цехта да булды, кырык градуслы эсседә эшлиләр. Барысы да ялангач, әледән-әле чәй эчеп кенә торалар. Аннары складка чыкты. Штабель итеп өелгән сырлы-сырлы озын эчәкләр. Унике метрлы да сигез метрлы. Сынау үткәч сортларга бүленгән. Иң яхшы югары сортлылар чит илгә — тугандаш илләргә китә икән. Алардан калганы гына без фәкыйрьләргә. Ә валовой планда барысы да үзебезнең ил эчендә тотылган булып языла. Менә ялган каян башлана икән, дип шаккаткан иде Тугаев. Бар запчастьлар буенча вал арттырып үтәлә, ә турбобурны, дизельләрне ремонтлый алмыйча иза чигәсең. Безнең берничә мастер Иранга барып эшләп кайтты. Үзебезнең җиһазлар белән. Андагы җиһазларның сыйфаты, чыдамлылыгы өч мәртәбә артык, диләр. Биредә бер долота белән дүрт-биш метр җир тишәсең, андагылар исә ун-унөч метр тишәргә җитә. Катламның катылыгы шул, бер чама...

Юк, горкомда эшләргә бераз шүрли ул. Анда бит бер дә мөстәкыйль фикер йөртеп булмас, дип уйлаганы бар аның эчтән генә. Дөреч, үсәсе килә аның, югарырак постка менәсе килә. Тик менә үзең теләмәгән, җанга каршы килә торган сүзләр сөйләргә туры килер дип шикләнә. Тыңлап утыра андагыларның сөйләгәннәрен. Ничә ел инде һаман бер үк нәрсәне кабатлыйлар. Тик цифрлар гына бераз үзгәргән була. Сөйләүчене гаепләп булмый. Барча газеталарда шул ук сүзләр. Бөтен Союзда шулай булып чыга. Үзәк газетада басылган докладка һәр өлкә, һәр тармак кирәкле графага үз саннарын куеп чыга да бер үк сүзләрне сөйли. Ичмаса берсе әз генә үзгәртсен иде. Ичмаса абзацларын алмаштырып куярга иде. Әйе, менә шундый хәл. Нужәли бу шулай барыр икән? Кеше үз эчендә кайнаган туры сүзен әйтә алмасын, имеш. Тормыш тудырган сүзләр, борчулар, канәгатьсезлекләр исәпкә кертелми, читтә кала. Димәк, тормыш мәшәкатьләре диктовать иткән фикерләр тормышны яхшыртуда, мөкәммәлләштерүдә катнашмый. Практика, тәҗрибә чутка алынмый. Ә тормыш бит бары практика, тәҗрибә белән бара, шуңа таяна. Элек-электән тормыш шул рәвешле тәҗрибә аша гына барган. Табигый барышы, үзенчәлеге шулай ул тормыш дип атала торган нәрсәнең. Хәзер тәҗрибәне исәпкә алу бетте, бары өстән төшкән приказлар, боерыклар белән бара тормыш. Шунлыктан урындагы хәлләр игътибардан читтә кала. Әмма кешеләрнең нормаль яшәве урындагы шартларга бәйле. Барча боерыклар кешеләр бәхете өчен дигән лозунгасы белән

бирелә. Бар эшләр кешеләр әйбәт тормышта яшәсен өчен эшләнә кебек. Өстән төзелгән план үтәлә, әмма кешеләрнең тормыш-көнкүреше һаман җайланып җитмәгән. Кешеләрнең яшәү шартларын яхшырту шул валовой формада гына эшләнә. Валовой шартлар, валовой-абстракт бәхет. Бәхет дигән нәрсә конкрет булмаса, димәк, юк, дигән сүз ул. Аерымлык килеп чыга: валовой план буенча яхшы шартлар бар, ә конкрет алган чакта исә ул шартлар юк! Менә шундый гаҗәп-сәер хәл. Тормышны өстән торып кына идарә итүнең аяныч очракларын һәр төштә күрергә мөмкин. Әйтик, бу төбәктәге һәр авыл басуында газ факеллары янып тора. Миллионнар җилгә очып, әрәм була. Әмма шул газны авыл йортларына кертү мөмкин түгел. Гәрчә бу һәр яктан файдалы булыр иде: колхозчыларны утын әзерләү ише авыр эштән коткарыр, бик кадерле урманнарны саклап калыр иде. Тик өстәгеләр моны исәпкә алмыйлар, чөнки алар урман беткән өчен, газның бушка януы өчен дә җавап бирмиләр. Менә колхоз фермасыннан 200 метрда гына бик көчле факел янып утыра, һәм шул ук таш фермага ягылмаганлыктан яшь бозаулар анда туңып үләләр. Ике йөз метр торба юкмы? Бар, бөтен төштә әллә күпме аунап яталар. Хикмәт нәрсәдә? Өстән төшкән рөхсәт юк. Чөнки өстәгеләр бу хәлне белмиләр, күрмиләр. Рөхсәт алырга йөрү өчен берәр батыр Дон-Кихот табылса да, инстанцияләргә чаба-чаба хәлдән таячак. Беркем аңа рөхсәт бирә алмый. Бары бу эш өстән планлаштырганда гына эшләнә ала. Планда каралмаган бер шөрепне дә бору мөмкин түгел. Коточкыч формализм һәр төштә нык тамыр җәйгән. Тормышка, илгә бик зур зыян китерә ул. Без — шул формализм, уйсызлык җәтмәсенә килеп эләккән кешеләр — бәргәләнәбез, суккаланабыз. Тырышабыз, тырмашабыз, эшли-эшли тир түгәбез. Һәм төннәрен йоклый алмыйча каян килә соң бу хуҗасызлык, җитмәүчелек, нигә соң без шулай? — ди-ди баш ватабыз.

Аек акылга туры килмәгән, аңа каршы эшләнә торган бик күп нәрсәләр бар. Шундый хәлләр белән адым саен йөзгә-йөз киләсең. Әмма син анализларга тиеш түгел, бары кушканны эшләргә генә тиеш. Бу ник болай соң? — дип каршы килергә уйласаң шул минутта ук сине юлдан алып ташлыйлар.

Главкадан инспектор килгән иде, аны озатып йөрергә горком Тугаевка кушкан иде. Ул гынамы, аны ашатырга-эчертергә кирәк. Өйгә алып кайтканны, билгеле, ошатмаячак, шуның өчен ресторанның аулак бүлмәсендә сыйларга туры килде. Ул инспектор үзе генә түгел, аңа горкомнан чибәр, яшь хатын-кызны билгеләгәннәр. Моныҫы инде ресторан сыйларыннан соң рухи сый өчен. Инспектор да кеше бит, аның күңелен күрмичә һич ярамый. Бу шулай гадәткә кергән инде.

Ике тәүлек буе кунакны һәм аның кунагы теге сиртмә койрыкны сыйлар өчен шактый чыгым тотылды. Беразын үз кесәсеннән каплар, ярый әле хатыннан яшереп тоткан, сейфта гына саклана торган акча бар иде. Ә калганын Холодец белән җайларга туры килер. Холодец ниндидер техничкалар исеменнән матди ярдәм сорап гаризалар язар. Һәм үзе үк шул гаризаларга һәрберсенә кыеклатып: «Выдать 50 (пятьдесят) рублей» дип кызыл кара белән резолюция салыр. Аннары шул тәсъдыйкланган гаризаларны җирле комитет утырышы аша уздырыр. Утырышта тиешле беркетмә язылыр һәм кирәкле кешеләрнең имзалары куелыр. Шул иләкләрдән үткәч, гаризалар кассирга килеп җитә. Ул үз имзасын сала да акча санап бирә. Бу процесста катнашучылар бу гаризаларның ялган икәнен белеп торалар. Электән үк шулай эшләнеп килгән, хәлдән чыгарга кирәк. Башлыклар кушалар икән, димәк, дөрес, дип уйлый һәркем һәм үзен тынычландыра.

Югарыдан килгән кунакны һәм аның иярченнәрен сыйлар өчен контора акчаны шул юл белән таба. Документлар теләсә нинди ревизор да чокчынып гаеп табарлык түгел. Бернинди шик тә уянмый. Һәркемгә мәгълүм, җыештыручыларның эш хакы бик аз. Өстәвенә баласы белән

ире ташлап киткән ялгыз хатын ул. Без менә шул ятим бала өлешенә кереп, кәеф-сафа сөреп йөрибез булып чыга. Тормыш каршылыкларга корылган. Бу хәлләргә беркем дә гаепле түгел. Берәүләр бар яктан житеш тормышта яши, икенчеләр әнә теге ятим малай кебек тишек ботинка белән йөри...

Шушындый уй-фикерләр, гаделсезлеккә үтә сизгер холык-фигыль белән горкомда эшләп буламы соң? Эчендәген күпме генә яшерсәң дә, барыбер күз карашың, кул хәрәкәтең белән үзеңнең чын йөзеңне белгертеп куярсың. Жаныңда яткан гаделлек холыгыңны ничек итеп һәрчак эчкә йомып кына асрарга мөмкин? Горкомда эшләүчеләр күңелләрендә уянган асыл уй-фикерләрен бик яшерергә тиешләр. Алар рәсми пост билиләр һәм уйлары, хәрәкәтләре фәкать рәсми рамкаларда гына булсын. Моңа ничек чыдамак кирәк? Һәрвакыт киеренкелектә, кыл өстендә. Үзеңне бер кысада тотарга. Бу инде михнәт чигүгә тиң. Ә шулай да күңел, үзеңнән яшереп булса да, карьера тели. Үзең дә аңламастан шуңа омтыласың. Менә минем дә горкомда эшлисем килә. Эшне алып бара алуыма шикләнмим. Иң кыены үзеңнең чын тойгы-уйларыңны белгертмичә «подпольеда» тоту. Шунысын булдырып житкерүемә ышанып бетмим. Айсберг шикелле, жиһедән бер өлешең генә судан өстә күренә. Күп өлешең барысы да су астында. Айсберг булып яшәп буламыни? Ә бит кешеләр яшиләр, айсберг булырга бар жаннары белән омтылалар. Чөнки горкомга эләгү — бар яктан да тәэмин ителү дигән сүз. Үзең генә түгел, гаиләң, балаларың да. Менә нәрсәдә хикмәт. Шуны син аңларга һәм бары рәсми сүзләр сөйләргә, авырыксынмаска тиеш. Ә рәсми сүзләрдә исә берне ике дип әйтелә, юкны бар дип әйтелә. Һәм моны әйтүчеләр ялганнары өчен бернинди намус газабы тоймый... Анда бик кырыс эш итәләр. Тоткан жирдән сындыралар...

Әнә минем дус Максуд нишләде, гыйбрәтле хәл кичерде ул. Эчкерсез, division беркатлы егет, кешегә ярдәмчел. Ярашучанлыгы көчле. Карьера баскычыннан күтәрелеп, горкомга житте. Анда көн саен сынап торалар икән. Моның исә эчендәге тышында. Хис кешесе. Берәүгә булышкан бу. Тегеңә диләнкәдән бүрәнә жибәрегез дип, лесхоз башлыгына боерык биргән. Әмма ул бүрәнәгә лаек кеше түгел икән. Яхшылыкны да бары тиешле кешегә генә эшләргә, ди. Теләсә нинди мохтаж кешегә игелек күрсәтә алмыйсың. Менә шуңа бик аптырадым, аңым кабул итмәде моны, дип сөйләде Максуд. Шунда моңа мөнәсәбәт үзгәрә, бирелә эшләргә холыкфигыле яраклы түгел икәнен сиздерәләр. Алар көенә үзен ипләштерергә тырышып карый Максуд, әмма юк, прокол ясадың, бетте, хушлашырга туры килер, дигән мәгънәне аңлаталар. Тиз генә «Иркеннефть» трестына местком председателе итеп күчерәләр. Горкомда ике ай гына эшләп калды ул. Мин дә андагы үлчәүгә сыя алмам, чөнки күпме тыелсам да миннән дөрес сүз ычкына. Конкрет уйлыйм, һәр нәрсәгә конкрет якын киләм...

Бер жыелышта: «Нишләп Тугаев татарлар белән үз ана телендә сөйләшергә теләми?» — дип сорадылар. Әйе, мин татарча сөйләшмим. Өйләнешкәч тә Рита әйтте, әгәр югары дәрәжәгә ирешәсең килсә, татарчаңны оныт, диде. Мин аны аңладым. Ярый әле, русчам акцентсыз, яшьтән рус мәктәбен үттем. Горкомда русча белмәүче берничә татар ана телләрендә сөйләшмиләр. Рус телен ватып-жимереп русча гына маташалар. Маржаларга өйләнгәннәр, хатыннары имеш, ана телендә сөйләшүдән тыя. Хатыннары гаепле түгел, үзләре шуның белән абруй казанырга исәпләгәннәр. Чөнки татарча сөйләшкәннәргә Беренче кырын карый. Тугаев Беренчегә чаклы ук ана телен «оныткан» иде, русча гына сөйләшү уңай, шик тудырмый. Азчылык халык вәкилләренә житәкчеләр тарафыннан ышанып житмичә карау бар. Дәрәжәгә омтылганда шул киртә булуы ихтимал түгелмени? Адәм баласы жәмгыятьнең һәр тибрәнешен бик яхшы тоя, бик күпкә алдан сизеп эш итә. Житеш тормышка, тәэмин ителгәнлеккә ирешү өчен һәркем көрәшә. Уңны-сулны белми, якын ип-

тәшләренең өстенә басып, таптап үтеп китә. Көрәш өстән генә түгел, астан яшерен рәвештә дә бара. Бер урынга яткач, кемнедер хатыны котырта, ирнең муенына асылынып, колагына кайнар пышылдый. Бу минутта хатынынны тыңламый кара. Моңа эчтән бик нык каршы булсаң да, хатының сүзләрен чынга алмасаң да, барыбер бер-ике тәгъбире колагыңа кереп кала, хәерсез!

Рита мине дә җае чыккан саен теге яки бу кешегә, хәлгә карата итагатьле генә итеп котыртып тора. Менә болай бит ул, тегеләй бит, дип кешеләрнең кимчелекле якларын, хәлләрнең аскы агышларын ачып сала. Мине горкомда итеп бик тә күрәсе килә. Ә мин горкомда эшләргә яраксыз икәнемне беләм, шуңа эчтән әллә ни омтылмыйм. Ә тыштан Ритага омтылган, ләкин киртәләр күп дигән тәэсир калдырам. Хатын алдында икейөзләнергә мәҗбүрмен.

Ул үз өлкәсендә мине дәрәҗәгә күтәрү өчен ниндидер эшләр алып бара. Горкомда эшләүчеләрнең хатыннарын караганда берәр йогынтылысына кирәкле сүз кыстыра, аңа ярарга тырышып, нәрсәдер эшләп ала. Баласы авырса, аңа бик эшлекле киңәшләр бирә. Дефицит дарулар таба. Артык нык игътибарлы була, кайбер хатын-кызларга бу бик ошый. Зур кешенең хатыны булгач, алар үзләрен гайре-табигый затлар итеп, югары итеп күрәләр. Һәм аларга караш та дәрәҗәле булырга тиеш дип аңлыйлар. Андый хатын-кыз мин-минлеге өчен кечкенә нәрсә дә әһәмиятле. Түбәннән кинәт югары күтәрелгән хатын-кыз үзен хаклы рәвештә өстен зат итеп күрә. Ирен иҗтимагый дулкын югарыга күтәрүен, шуның аркасында гына дәрәҗәле бай көнкүрешкә килеп керүен оныта. Болар барысы да аның үзенең казанышлары, матурлыгы, кәттә булуы өчен тиешле бүләкләр, янәсе. Рита түрә хатынының гүзәллеген күпертеп мактый, үзен гүзәл дип йөргән хатын моңа бик тиз ышана. Үзен мактаган кеше ягына кем генә авышмаган... Шуннан соң бүтән мәсьәләләр турында сөйләшергә җай ачыла. Рита җайны кулдан ычкындырмый. Әгәр дә мине ниндидер дулкын горкомга эшкә күчереп куйса, ул әйтәчәк, менә бу минем тырышлык аркасында гына булды, онытма, диячәк...

МинРитаның бу эшләренә уен гына итеп карыйм. Әйдә, уйнасын. Каршы килеп, аңа ни дә булса аңлатып маташуда мәгънә юк. Миндә ике «мин» барлыкка килде. Берсе — Рита стратегиясенә каршы килмәүче. Хатын белән араны бозмас өчен, һәрчак килешүче мин. Икенчесе — минем эчке табигатемнән килеп чыга торган хатын теләкләренә каршы, яшерен мин. Моның асылын хатынга ничек аңлатырга белми аптырыйм. Юкны бар дип, караны ак дип әйтү минем өчен намуска хыянәт итү белән бер. Ялган шаһитлык итү кебек үк авыр. Ә горкомда кайчакта теге әкияттәге кебек корольгә ял-ялангач икәнен күрә торып, күлмәге нинди матур, дип әйтергә туры килә. Чөнки шулай әйтмәсәң, син җүләр саналасың.

Тугаев Бөгелмәгә эш белән барган чакларында Андрей Казанны очраткалый иде. Иптәшләрчә җылы гына сөйләшеп торалар. Казан аны үзләренә чәйгә дәшә. Тугаев исә ашыгуын сәбәп итеп, бер дә керми иде. Үзе дә Казанны чакырмый, килеп чык, дигән җавапсыз сүз дә ычкынмый аңардан. Тугаев хатынына Казан турында ачылган иде. Рита шунда ук арткы исәбен эшләтеп, шикләнеп калды һәм аңлатты: хәзерге катлаулы тормышның бик күп язылмаган законнары бар, диде. Әгәр син заман кешесе, заманга җигелүче булырга телисең икән, андый таплы шәхесләр белән аралашма. Син зур коллективка баш, җитәкче, ә идеология һәр төштә иң беренче хәлиткеч рольне уйный. Син идеология тәрбиячесе, шуны онытма. Башлыкның иң элек шул ягына карыйлар. Аның үзенең идеологиясе ничек, кемнәр белән аралаша, моны һәрчак барлап кына торачаклар. Сталинны пьедесталдан төшерделәр, әмма аның идеологиясе шул килеш. Шул идарә итү, үзгәрмәячәк ул. Теге синең кул астында эшләүче элеккеге танышың — Зәй белән якын мөнәсәбәткә кермә. Әйе,

аптырап, шаккатып карама, үзең өчен әйтәм. Үзеңә буйсынганнар белән эшнәлек коллективта синең авторитетыңны гына төшерә. Шуны да аңламыйсыңмы? Йә, әйт, үзең кебек урта кул нинди дә булса начальникны хөрмәт итәсең син? Әзрәк сине куркытканрагын, усалрагын. Син дә кул астындагылар өчен кырыс һәм какшамас булырга тиешсең. Халык серле булганны ярата.

Ләкин язмыш якты омтылышларың белән санлашып тормый, аның да үз кануннары бар.

Эш шунда, Карабашта нефть чистарту җайланмасы — НСУ төзелә иде. Җиһазларын тулысы белән Австриядән сатып алганнар. Үзенә күрә бер завод ул. Заводны монтажлау өчен Австрия инженерлары һәм эшчеләре килгән. Сызым буенча безнекеләргә күрсәтмәләр биреп торалар. Кайбер узелларны үзләре дә башкаралар.

Аларның яшәү-торулары яңа шәһәр — Акташта иде. Шәһәрнең бер аулак почмагы урманга килеп тоташа. Менә шул төбәктә җиде-сигез фин йорты салынган. Барысына бер котельный, бойлер куелган. Кайнар суына чаклы барча уңайлыклары бар. Йортлар мәйданы тоташ стеналы биек койма белән әйләндереп алынган. Кайбер чит ил белгечләренең хатыннары да төзелештә эшли. Эш урынына махсус «Икарус» алып бара һәм алып кайта.

Төнлә берсенең хатыны авырый башлый. Шул очрак өчен бирелгән номер белән шалтыраталар. Горком кешеләрен карый торган санчасть-ка. Дежурда Рита Халитовна була.

Рита «Ашыгыч» машинасы белән бик тиз килә. Ире яхшы гына русча белә икән. Фамилияләре Фогельсон. Хатыны Инга да русча аңлый, шулай да сөйләшү, авыруны ачыклау ире аша бара. Температура югары, укол ясамыйча ярамый, ди Рита. Коңгырт чәчләрен баш артына төйнәп куйган, киң битле, почык борынлы хатын башын як-якка селки, кирәкмәс! Икесенең дә йөзендә ниндидер ышанып җитмәү кебек чалым бар. Үзләре моны врачтан яшерергә тырышалар. Сүз әйткән саен елмаялар. Рита ФРГ һәм үз илләреннән алынган препаратларны бирә. Инганың йөзе яктырып китә, ул моны көтмәгән. Ире дә даруларны тиз танып ала. Болай булгач, куркыныч юк, терелерсең, дип хатынының күңелен күтәрә.

Һәр көнне иртә-кич килеп, Рита бар булдыклылыгын эшкә җигеп, Инганы дәвалап йөрде.

Инга терелеп эшкә чыга. Бераздан Ритага рәхмәт йөзеннән Фогельсоннар Тугаевларны кунакка чакыралар.

Бер дә көтелмәгән хәл бу. Шуңа күрә аптырап калалар. Барыргамы, юкмы? Болар бит чит ил кешеләре! Чит идеология йөртүчеләр. Теге елларда читләр белән бәйләнешкә кергән кешеләрне халык дошманнары ясап, гаепләп бетерделәр. Кайберләрен утырттылар да. Шуларның шаукымы әчтә утыра, күңелгә курку сала. Ул-бу булмасмы? XX съездан соң бераз иркенлек килгән кебек булды булуын, әмма идеология мәсьәләсендә катылык шул көе әле. Бигрәк тә Беренче үтә принципиаль, шуның аркасында гына урынында тора. Юкса бүтән артык җире сизелми.

Урынга яткач та ир белән хатын тиз генә йокыга китә алмадылар. Мәсьәләнең төрле ягыннан килеп фикер йөрттеләр. Әнә ГДР немецлары белән рәхәтләнеп аралашырга ярый. Беркем кырын карамый. Ә бу австрияклар белән ничек? Шул ук немецлар, безгә каршы сугышкан халык?

— Бармасаң да килешмәс инде,— диде Рита мендәр өстендә мул гына камыр йомарламнарыдай яткан күкрәкләрен җыйгалап...— Органнар тыйган, курыкканнар дип уйлаячаклар... Органнар кушмаган, димәк, ирек юк икән, диячәкләр. Әйе, әйе. Мин барырга каршы түгел, ләкин соңыннан артта пышын-пышын сөйләячәкләр, диде ире. Бәлки безнең австрияклар белән аралашканны көтеп торучылар да бардыр. Төймәдән дөя ясарга. Адәм баласын көнчелек кимереп кенә тора.

Рита эштән карар белән кайтты. Ни булса да миңа сылта, диде. Мине берни дә эшләтә алмаслар. Алмаз һаман икеләнә иде әле. Нәрсә син шул

тикле шүрлисең, дип Рита аны «эшкәртергә» тотынды. Шул эшне һәрчак бик яратып эшли ул. Алмаз башта каршы килеп, кәҗәләп маташты. Әмма барыбер Рита җинә иде.

Алар әйткән вакытка бик төгәл килделәр. Австриякларда да немец төгәллеге, дип сөйлиләр иде алар белән эшләүчеләр. Залдагы өстәлгә табын әзерләнгән иде. Таба, мич ашлары булмаса да кызыл, кара икралар, төрле кыйммәтле балыклар мул куелган иде. Эчемлекләрнең дә төрлесе: «Бренди»дан алып безнең «Столичный»га кадәр бар. Рита мәнне, мәгънәне белә торган хатын: хуҗаларга кечкенә генә булса да бүләк алып килгән. Сусаль алтын чеканка белән эшләнгән кечкенә чәйнек һәм шундый ук нәкышле ике чынаяк... Хуҗалар әйберне бәяли беләләр икән, бик сөенделәр. Әмма чырайларында сизелер-сизелмәс сорау да бар иде кебек. Бу ни хикмәт, без советлар турында ялгыш фикердә булганбыз икән дигән төстә Фогельсоннар бер-берсенә карашып алдылар. Инга сөенечен яшерә алмады, ире исә шактый флегматик күренә иде. Тыенкы гына башын ия биреп, рәхмәтен әйтте.

Хуҗа рюмкаларга эчемлек бүлде. Аяклы хрустальләр, эчемлек салгач, әллә нинди саргылт нур чәчеп торалар. Ир хатынына карап алды да рюмкасының аягыннан ике бармагы белән тотты һәм кунакларга эчәргә ымлады. Австриякларда тост әйтү гадәте юк икән, дип, Алмаз эчтән нидер әйтергә кыбырсып алды, үзен тыйды. Иң элек хуҗа үрнәк күрсәтте, аннан хатыны, кунакларга эчми утыру мөмкин булмады. Алар да рюмкаларын бушаттылар. Фогельсон эчкәч закускага үрелмәде, хатыны да берни капмады. Моны чамалаган Рита өстәл астыннан Алмазның аягына тиеп куйды. Алмазның закускага үрелә башлаган кулы кире төште. Хуҗа тагы рюмкаларны тутырды, тагы эчтеләр. Шуннан соң гына закускаларны капкаларга тотындылар. Кунаклар бик нык тартынып утыралар. Сынатасылары килми. Үзләренең культурадан төшеп калган түгеллекләрен күрсәтергә телиләр. Ике тапкыр капкач та Рита Алмазның тезенә кагылып ала, теге өченче кабымга үрелүдән туктап кала. Фогельсон аны-моны белми, рюмкаларны бренди белән тутырып күтәртә... Болай башка китәр, хәерсез, дип эчтән борчыла Алмаз. Бераз атланмай кабып килергә кирәк булган. Әнә эчемлек башта кайнар елдырым кебек аякларга төшеп китте, ботларны кайнарлатты, хәзер тән буенча башка таба йөгерә. Хуҗаның максаты кунакларны күңелләләндерү иде. Эчемлек бит кулны, аякларны чишә һәм телне худка җибәрүчән.Ританың бит очларына алсулык йөгерде, башына китсә, ул гел көлеп кенә торучан. Теләсә нәрсәдән көлә башлый, дивана кеше шикелле. Шундый хәлгә калмаса ярар иде. Бик тыелып утырганы сизелә сизелүен. Әмма бренди бик мәкерле эчемлек булырга тиеш. Шуңа күрә Алмаз Ритага аягы, ымы белән яшерен сигналлар биргәләде. Әмма теге һич аңларга теләми, һәрвакыттагыча үзем белән мин, дигәнне иреннәрен бөгелдереп-бөгелдереп алуы аша аңлата. Әх, шул үзем беләмлеге! Әмма нәрсәдер сөйләшмичә булмый бит. Телне йотып утыру килешми. Рита исә чаманы белмичәрәк көләргә тотына. Уңайсыз хәлгә калмас өчен Алмаз хуҗаларның хәл-әхвәлләре турында сораша башлады.

— Камрад Фогельсон, төзелештә эшләрегез ничек бара? — диде әңгәмә бозын кузгатып җибәрү өчен. Рита хуҗа хатынга ишарәләр белән нидер аңлатты да шыркылдарга тотынды. Ул шул рәвешле үзенең дәрәҗәсен төшерә иде. Алмаз аңа өстәл астыннан аягы белән каты гына төртеп куйды.

— Кичә бераз гына конфликт чыгып алды, — дип Фогельсон калын чәчләрен учы белән артка сыпыра башлады. Гүя ул шул хәлгә гаепле булуыннан хәзер уңайсызлана иде. — Минем участокта эретеп ябыштыру эшләре бар. Шуңа булышчы сорадым. Инженер әйтте, әнә мастерскойда күп сварщиклар, сайлап ал, диде. Битлек киеп, барысының эшен карап чыктым. Берсе нечкәлекне тоеп, оста ябыштыра. Шуны, мин әйтәм, бирегез. Инженер конторга кереп китте. Бу сварщик турында нидер

белешергә. Чыккач әйтә, ул останы сиңа биреп булмый, эшли торган эше бик мөһим, ди. Минем мөһим участок бит. Теге башын селки. Конторга кереп, начальникка шалтыраттым, аңлаттым. Трубканы инженер алды, сөйләшәләр. Нindидер сер бар. Сөйләшеп бетерде дә, борылды: «Юк, бөтәнне ал, аны — булмый»,— ди. «Нигә, нигә?» — дим. Минем дә минминлегем купты. Инженер минем колагыма килде дә гозерле тавыш белән йомшак кына: «Неужели политиканы әзрәк аңламыйсыз?»...— диде. «Причем монда политика?— дим..— Минем йогынты йогар дип курkасызмы?..— дим аптырагач. Теге дәшми. Дөрес сүзгә җавап юк. Шунда аңладым. Сездә кешене эше буенча түгел, политика бизмәнендә бәялиләр икән! Бу бит һәлакәт! Политика эшкә зыян китерә! Рәзе мөмкин шулай итәргә?! Имеш, ул останың аңы капиталист белән янәшә эшләрлек югары түгел... Ну, көлке дә инде! Ул — оста, һәм вәссәлам. Башта эш, аннары бөтәне...

Ул башын як-якка чайкап торды. Әмма Инга аны бүлдерде, рюмкаларны тутырырга, кунакларны сыйларга кушты. Фогельсон гаепле елмая-елмая эчемлек салды. Инга, рюмкасын тотып, эчәргә ымлап, барысы белән чәкештереп чыкты.

Монысы да әйбәт кенә китте. Алмаз бик нык ашыйсы килүен тойды, әмма астан Рита аягына төртә иде, шуңа күрә үзен тыярга мәҗбүр. Ашказанында бүреләр улый, ичмаса ипине дә бик юка итеп тураганнар. Янәсе, шулай культуралы була. Нәләт! Җитмәсә нindидер сүз әйтә дә Рита көлә, сүз әйтә дә көлә, үзен белми, минем аякка төртергә һич тә онытмый. Фогельсон үзе юньләп ашамый, ул ашаса, аңа карап кунаклар да сыпырыр иде. Эчкәч, хәтта, закуска да капмый. Менә тагы рюмкаларны тутырды. Әллә безне исертмәкче буламы? Бер дә андыйга охшамаган. Эчемлектәнме, болаймы ул шактый җанланып китте шикелле. Авызында сүзе бетми. Хәзер шактый төртгереп сөйли:

— Шуны аңладым,— диде ул, кинаяле тавыш белән,— ни өчен шул тикле күп, әйбәт җирләре була торып, сезнең ил икмәкне читтән сатып ала. Хәтта безнең ише бармак башы чаклы илдән — ике миллион тонна...

— Бездә зур корылык булды шул,— дип аклангандай итте Алмаз закуска алып кабып. Аны эчтән үзебезнең ил өчен уңайсызлану оялу биләп алды. Ләкин бу факт белән берни дә эшли алмаслыгын аңлады. Әкрен-әкрен уңайсызлануы, ояты бетүгә таба авышты. Фогельсонның «шырпы кадавыннан» нindидер начар хис эчтән күтәрелгәндәй булды. Аңа киңәеп безнең ил турында сөйләмәкче, аңлатмакчы итте. Әмма, бөтән төрле уйлый торган кешегә үз фикереңне төшендерергә тырышу әллә ни нәтиҗә бирмәслеген уйлап, ниятеннән кире кайтты.

— Хикмәт корылыкта түгел...— диде Фогельсон фикерен тәмләп дәвам итмәкче булган иде, хатыны Инга аңа нидер әйтеп, кул селтәде.

— Ташла, тиеш түгелне сайрап утырасың,— диде төксе генә карап. Фогельсон шым булды, ничектер утырган җирендә сеңеп киткәндәй итте. Хатыныннан шактый гына шүрләгәне сизелеп калды.

— Әйе, әйе, бетте,— диде гаепле елмаеп һәм хатынының хаклы булуын аңлаткандай аңа таба башын иеп-иеп алды. Бераз уңайсызлану ирләрчә йөзенә дә чыкты. Ул тизрәк рюмкаларны тутырырга ашыкты.

— Каян русча өйрәндегез?— дип кызыксынды Алмаз. Аның рус телен белүен мактап алды. Сезгә тел җиңел бирелә, ахрысы, дип аны тагы да үсендерергә теләде. Ләкин Фогельсон яшь булса да, мактауга битараф икәнен белгертеп кулын гына селтәде. Һәм аңлатты: Без совет зонасында идек. Сезнең гаскәрләр илле бишенче елны гына киттеләр. Безнең йорт янында русларның башлангыч мәктәбе бар иде. Әти сөйләшеп, мине шунда бирде. Биш ел укыдым... Берочтан үзебезнең мәктәпкә дә йөрдем... Аннары минем бабай үндүртенче елны пленда биредәге Письмянка авылында бер байда эшләгән. Күп нәрсәләр сөйли иде.

— Кит әле? Ничек туры килгән, ә?— дип Алмаз шаккатты.

— Тормышта парадокслар була,— диде Фогельсон горурланган төстә.

Тагы вак-төяк, әһәмиятсез нәрсәләр турында сүз жае чыгып, сөйләшенеп алынды. Аннары кунаклар кузгалдылар. Алмаз кайтканда үзенең шактый сәрхүшләнгән булуын тойды. Күңеле дә тынычланган иде, чөнки бренди аңа нык кына кыюлык өстәде, улРитаның төртүләренә әһәмият итмичә, алдагы закускаларны байтак урды. Барыбер хатынга ярап булмас, дип үзен-үзе эчтән дәртләндерде ул.

— Бу татарлар кыргыйлар икән дип уйлаганнардыр инде,— дип ирен шелтәли-шелтәли кайтты Рита. Чишенеп ятакка урнашканда әйтте: «Безнең халык турында начар фикердә калмасыннар өчен үзләрен дә кунакка чакырырга кирәк...» Алмаз аңа каршы: «Ә рөхсәт итәрләрме соң?» — дип, сәрхүш булса да, аек сәяси сагаюын белдерде. «Анысын үзем җайлармын»,— диде Рита, үзем беләм дигән кыяфәтенә кереп.

Алмаз ышанып бетмәгән иде, Рита чынлап сөйли икән. Иң элек квартирага культуралы төс кертергә кереште. Ниндидер осталар табып, кухня диварларына матур бизәкле клеенка ябыштыртып чыкты. Алмаз ике көн Казанга командировкага киткән арада зал ягы, эчке бүлмәләрне бик матур обойлар белән бизәтте. Алмазның командировкасы мач булды, нефтьчеләрнең РСУы базасыннан иң кирәкле, затлы ризыклар юнәтеп кайтты.

Рита татар милли кухнясының җәүһәрләрен күрсәтергә теләгән. Ресторанда эшли торган кызлардан бик күп тәмле ризыклар пешерткән иде. Чәкчәк, кош теле, вак бәлеш, өчпочмак, катлы бәлешләр һәм берничә төрле дирбияле пирожкилар. Эчемлекләр генә ике сорттан: мәшһүр столичный һәм коньяк.

Кунаклар ялындырмыйча килделәр. Гомумән, аларда тартыну ише нәрсә сизелми, үзләрен иркен тоталар. Рита һәр милли ашны авыз итеп карауны, әгәр күңеленә ошаса, шуның белән ризыклануны үтенде. Кунаклар сырланып тормадылар, мул табынга хөрмәт күрсәттеләр. Шушы муллыктан ахры Инганың башында сорау туды.

— Сездә «прожиточный минимум» күпме? — диде ул бавыр фаршы салып пешерелгән пирожкины мактый-мактый ашаганда. Инганың әз генә алсу йөгертелгән озынча йөзе бүген аеруча мөлаем иде. Бу сорауны ул Ритага төбәп әйтте. Тик Рита җавапны белми һәм шуңа карашын иренә күчерде. Алмаз да белми икән, җилкәләрен генә җыерып куйды. Әзрәк уңайсыз булып китте. Шул кытыршылыкны шомартырга теләпме, Алмаз рюмкаларга эчемлек салды, кунакларны эчәргә кыстый башлады. Моны күтәреп, кайнар бавыр пирожкиларын әз генә серкә белән бик яратып ашадылар. Аннары тагы Инга сөйләп китте. Ул бүген ничектер яңа гына теле ачылган бала кебек гел сөйләргә омтылып тора иде. Русчасы начар булса да, бик мәгънәле итеп китереп чыгара, акцентында күңелгә ятышлы мөлаемлек бар.

— Сезнең илне бик күпләр ташлап китә,— диде ул бер дә сер әйтмәгән төстә.— Австрия нейтраль булгач, иң элек алар шунда килеп төшәләр. Шуннан төрле илләргә таралалар. Башта бар яктан тикшерәләр үзләрен, иләктән үткәрәләр. Алар өчен озын бараклардан торган шәһәрчек төзелгән... Ун меңләп кеше, диделәр...

— Алар теге диссидентлардыр, мөгаен,— дип сүз кыстырды Алмаз.

— Бер русны, еврейны безнең русча белгәнне каяндыр ишетеп килгән иде. Озак кына зарланып утырды. Үзе Ленинградтан, яшь язучы, диде. Әсәрләрен бер дә басмаганнар, яшәр әмәле калмаган. Җитмәсә, төрлечә эзәрлеклиләр икән үзен... Без сорыйбыз: ничек инде Ватаныңны ташлап китәргә була? — дип гаҗәпләнәбез. Ә ул кыза: Ватан ул ирек булганда гына Ватан, ирек булмаса, күзгә берни дә күренми дип аңлата. Эзәрлекләгәч, нинди Ватан булсын ул? Ватанга булган бар мәхәббәтеңне әнә шулай итеп бетерәләр. Эзәрлекләсәң, туган урманыннан җәнлекләр дә кача. Минем бер гаебем юк бит, әгәр булса, хөкем итәрләр иде. Бер гаепсезгә эзәрлекләсеннәр, рәнҗетсеннәр әле, ди.

— Ул хак әйтә,— дип Фогельсон сүзгә куәт өстәде.— Ирек булмаса — Ватан да юк. Ирек белән Ватан бер-берсеннән аерылгысыз...

— Туган җирдән торган җир яхшырак, ди татар,— дип куйды Алмаз нигәдер көлә-көлә.— Ватанын ташлаган кеше юньле түгел инде — әтрәк-әләм ул!

— Юк, бик әйбәт намуслылары күпчелек,— диде Фогельсон бик белгән төстә. Чөнки үзе шул эмигрантлар белән бәйле булган эштә эшләгән...

Кунаклар сәгатьләренә карап алдылар да кузгалырга рөхсәт сорадылар. Китәргә җыенганда Инга сумкасыннан алып, хуҗаларга нәфис нәкышлар белән эшләнгән чәйнеккә охшаш кофейник бүләк итте. Рита белән Алмаз каушап кала яздылар. Миңа барыбер нәрсәдер бирергә кирәктер инде дип уйлап, Рита иренә карады. Чөнки кофейник бик кыйбат сыман тоелды... Алмаз бүләкне кулында тотып, кунакларга рәхмәт белдерде һәм очрашуыбыз моның белән генә тәмамланмас әле, дип күңелләргә ниндидер өмет салды, үзе кет-кет көлгән итте. Янәсе, бүләк өчен сөенеп шатлана. Шундый тәэсир калдырырга тели иде.

Ял көнне бик иртә капкадагы звонокка бастылар. Шалтырауга Рита уянды һәм киенеп чыкты. Кемнәр борчуын белә иде. Алмаз өченче көн үк әйткән иде: Казан белән Зәй бер кич конторга икесе килеп кергәннәр. Иске танышлык хакына табигатькә чыгыйк, Ыкка балыкка барыйк, дип үтенгәннәр. Машинаң үзеңнеке, үзең йөртәсең... Алмаз баш тарта алмаган. Ә Рита аны бу сәфәрдән тыйды. Абруеңны төшерәсең, бик простой булып барасың, андый кешене горкомга алмыйлар, диде. Алмаз аның сүзен тыңларга күнеккән иде инде.

Ә Рита аның элеккеге иптәшләрен бик итагатьле рәвештә кире борып җибәрде. Җомга көнне Казанга, командировкага киткән иде, әле дә кайтып җиткәне юк, диде.

Бу вакытта Алмаз торып баскан, һәр көнне иртән ясый торган «чүгәләү-тору» күнекмәсенә тотынган иде. Ул тәрәзәгә эленгән челтәрле туль артында басып тора, аны тыштан күрмиләр, ә ул тыштагыларны күрә: менә ике иптәше башларын аска иеп китеп баралар. Бәлки, хәйләне дә сизгәннәрдер, Рита сүзләренә ышанмаганнардыр. Ә бит икесе дә әйбәт кешеләр! Разведкага бергә ышанып барырлыклар! Ник дөнья кешеләрне бер-берсеннән аера?! Әллә моңа мин генә гаепле ме? Минем дә ниндидер гаебем бар, билгеле! Әгәр шартлар кешечә булса, мин ул иптәшләрдән үземне аерыр идеммени?!.. Алмазның күзләре яшь белән тулган иде.

## IV

Зәй тагы Фалиягә гозерләнеп барды. Йөз ерту аңа бик авыр иде. Әмма бала газаплануына, көн-төн елавына түзеп тору тагы да авыррак. Бала елавында йөрәккә тия торган нәрсәдер бар. Шуңа чыдап булмый иде. Аннары Фалия дә изге зат булып чыкты, һич көтмәгәндә ярдәм кулы сузды һәм бер авырыксыну сиздерми иде. Дөрес, Зәй сөтне болай гына алып китми, барган саен шоколадын, хушбуен дигәндәй кыстыра килә. Шуны биргәндә үзе дә, Фалия дә уңайсызлык кичерәләр.

Килсә, Фалия эштән кайтып, суга чыгарга тора. Зәңгәр трико, кызгылт кофта кигән, саргылт чәч толымнары берсе алда, икенчесен артка ташланган. Зәй форсаттан тизрәк файдаланды: аның чиләкләрен шатлана-шатлана алды да колонкага йөгерде. Кайтуына өстәлгә чәй әзерләнгән иде. Зәй иң кирәклесен күзе белән эзләде: күкрәк сөте тутырылган, тышына сантиметрлар белән сызлар ясалган шешәгә ак салфетка ябып куелган икән!

— Эштән кайткансыңдыр, атны да ял иттерәләр,— ди-ди Фалия аны чәйгә чакырды. Нигәдер йөзенә уңайсызлану төсмерләре чыккан иде. Зәй дә уңайсызланып калды. Фалия бер чокырга спирт салып, аның алдына куйды.

— Мин эчмим бит, Фалия,— диде Зәй эчмәвс белән горурланган төстә. Һәм нигәдер тыенкы гына көлеп куйды. Фалия дә уңайсызлыктан чыгасы килгәндәй ирен кырыйлары белән елмайды. Чөнки ышанмады, моңарчы аракыдан баш тарткан кешене очратканы юк иде. Аның алгы вак кына ак тешләре күренде.

— Әллә син саранмы?— диде елмаюын көлүгә әйләндереп.

— Кешеләргә берничек тә ярап булмый,— дип Зәй тагы көлеп куйды һәм ясаган чәйне эчмичә китү хөрмәт итмәү саналыр дигән уйдан чокырга үрелде.

— Баланың хәле ничек соң? Бераз «смесь» ашый башламадымы?

— Ими сөте булганда, төнлә йоклый болай... Рәтләнерме инде ул бичара?— Зәй чәенә шикәр өстәп, калак белән болгаткалады. Фалия исә нигәдер сүзне икенчегә күчерәсе итте.

— Ә үзеңнең хәлләр ничек?

— Ничек дип, хәл шул балага бәйләнгән инде,— диде Зәй житдиләнеп.— Бер начар, бер яхшы — полоса...

— Ак полоса, кара полоса, ә?— Фалия тар кофтасы эчендә йомры шарлар кебек беленеп торган күкрәкләрен тибрәндереп уфылдап куйды. Аннары нидер исенә төшергәндәй нечкә кашларын матур сындыргалап:

— Сез йөреп өйләнештегезме соң?— диде һәм Зәйгә тутырып күз сирпеп алды. Зәй чокырдагы чәен эчеп бетереп килә иде. Фалия, шуны күреп, янасын ясарга чәйнеккә тотынды. Зәй чокырын учы белән каплады. Фалиянең «йөреп өйләнештегезме?» дип соравы Зәйнең сагаю аңына барып тигән иде. Нигә болай кызыксына, әллә минем кайчак Рамиләнең сөте юклыкка ризасызлык белдерүемнән берәр нәрсә сизәме? Зәй күңеленең кай төше беләндер Рамиләгә туры килүенә яшерен генә үкенә иде. Үткәнне кире кайтарып булмый, язмыш шулайдыр инде дигән юаныч та тапты үзенә.

— Безме?— диде кет-кет көлү артына чынлыкны яшерергә теләп.— Менә су дулкыннары эчендә ике йомычка йөзеп бара, ди. Берсе мин, икенчесе ул. Ниндидер җилдән көчле дулкын кубып, безне бер-беребезгә китереп сылады һәм без...

— Бер-берегезне юньләп белмәгән көеме?— Фалиянең матур каш сызыклары маңгаенарак менде. Ул гаҗәпләнү белдерде. Мондый хәлләрне күреп, белеп торса да үзен акыллы итеп күрсәтәсе килде шикелле. Гомумән, Фалия һәрвакыт үзен акыллы итеп тәэсир калдырырга омтыла иде.

— Көчле дулкыннар бәргәләп торганда аңа җай чыкмый...— дип тагы гаепле кеткелдәде Зәй.

— Йөргән, таныш кызың булгандыр бит? Димәк, кавыша алмагансыз?— Фалия томса, серле күзләре белән Зәйгә сынап төбәлде. Ялганлыймы, әллә чынлап сөйлиме? Ул үз тәҗрибәсеннән һәр сөйләгән сүзгә ышанып җитми карый иде. Зәй аның карашын тойды һәм бу кыз безнең хакта нәрсәдер ишеткән, шайтан алгыры, дип уйлап алды.

— Чегән хатыны кәрт ачканда ничек ди?— Беренче сөйгәнең белән бергә була алмагансың, ди. Һәркемгә шул сүзләрне юллый. Каян белә диген. Борынгы китапларда язылган, ди ул акыл. Тормышта кеше үзенең беренче сөйгәне белән бергә була алмый икән. Һәм бу чынга да туры килә бит, ә?— Зәй хәзер Фалиягә сынап төбәлде. Кызның керфекләре түбән төшкән иде. Йөзендә серләрен белгертәсе килмәү сызыклары аны эчтән елмайган төсле итә.

— Туры килә, туры килә,— диде Фалия сүзнең бу четерекле темага кереп китүенә эчке канәгатьсезлек белгерткәндәй.

— Ягъни син дә беренче сөйгәнең белән аймылыштыңмы, ә?

— Әйем лә, искә төшерәсем килми. Юк, минем башкача... Бездә бер яшь кенә кыз бала тапты. Әтисе кем дибез, белми. «Ромашка»лы уйнаганнар икән. Ирләргә уен, ә бар авырлык хатын-кызларга төшә. Ир-ат халкы да хәзер эткә әйләнде. Берсенә дә ышаныч юк. Ә кызлар

алданалар шул. Чөнки табигатьләре шулай — ышанучан. Кызларның сөеләселәре килә. Табигать аларны сөелергә яраткан. Ә ир-ат исә сөйгәндә кызларны уенчык урынына вата да китә...

— Хатын-кыз да ир-атны вата инде,— диде Зәй, ике як та гөнаһсыз түгел дигәнне, ягъни тормышта булып торган хәлләрне искәртеп.— Минем бер абыйны хатыны гына харап итте. Дөрес, әзрәк эчкәли иде. Күп түгел, чамадан чыкмыйча гына. Хатын ахмак, ирен шуңардан биздерү өчен бер медсестра белән сөйләшеп, аңа антабус биргән. Үзенә белгертмичә. Абый, билгеле, аны-моны шикләнмәгән. Антабустан соң эчемлек ярамый. Ә бу белмәгәч эчкән һәм шуның белән вәссәләм...

— Бу җинаять бит,— диде Фалия, аның томса күзләре зур булып ачылды һәм таң калудан тырпайган керфекләре дерелдәп-дерелдәп алдылар.

— Исбатлап кара, ир белән хатын арасына милиция дә керергә курка...— Зәй урыныннан кузгалды.— Син Фалия, мин әрсез алабайга ачуланма инде.— Ул гаепле елмаеп кызга карый, аның эчендәге уйларын чамаламакчы була иде.

— Һи-и, борчылма,— диде Фалия сөтле шешәне аңа сузып.— Без кемгә булса да булышмый тора алмыйбыз. Сезгә ни, бүтәнгә ни... Шундый эш инде...

— Рәхмәт, Фалия,— дип Зәй тизрәк ишеккә юнәлде. Кыз янында озак юанудан ничектер курыккан шикелле иде. Бердән, әллә нәрсә шунда — Фалия кырында үзен бик киеренке тоя башлый. Әллә намусы киләме? Икенчедән, Рамилә һәм бала каршында читен. Гүя алардан яшереп кенә ярамаган эш эшләп йөри. Әмма үзенең хәрәкәтләрендә тиешсез булмаган нәрсәләр юклыгын белә ул. Шулай да Фалиянең сөйкемлелеге күңеленә тәэсир итә иде. Килгән саен кыз аңа сөт тулы шешә генә түгел, тагы нәрсәдер өстәп җибәрә шикелле. Яктылыкмы, нурмы шунда. Бер уйласаң, гаҗәбрәк тә. Кичә Зәй бер иптәшенең үз артында яманатын сатуын ишетте. Авыр булды. Кинәт күңел төште, кешеләрдән бизү тойгысы җанын биләде. Ә Фалия янына чираттагы баруда күңелне басып торган шул хыянәт ташы кинәт юкка чыкты. Ул җиңеләеп, күңелләнеп китте. Аңа кешеләргә өмет кабат кайткандай булды. Әйтерсең лә дөньяда әзрәк яктылык артты.

Баракның тышкы баскычында Зәйне акшарга буялган фуфайка кигән какча йөзле Сәях хатыны туктатты. Кашларын җимереп:

— Нишләп сез, Сәяхның бергә эшли торган иптәшләре, аңа карата явызлык кыласыз: чиратлап аны эчертәсез? Бетсен, югалсын дисезмени, ә?

— Мин аны эчерткәнем юк,— диде Зәй кешене сыйлауның гаепкә алынуына гаҗәпсенеп. Хатын ярпачланып, Зәйгә ябышыр дәрәҗәдә чәрчәр килә. Һаман Сәяхның иптәшләрен сүгә.

— Беркем дә аның авызыннан тотып салмый бит,— диде Зәй.— Күргәнегез бармы авызына салганнарын? Юк! Димәк, гаеп бары үзендә. Үзе нәфсесен тыйсын...

Бу хатынның яныннан киткәч, Зәйнең башына: бер кемнең дә бурасы буш түгел, берсендә бер бәла-кайгы, икенчесендә бөтенләй башка төрле каза, дигән уйлар килде.

* * *

Буровой эшчесе Әкрәмов Сәяхны җирле комитет утырышына куйдылар. Сәбәбе бик җитди: эчеп, айныткычка эләккән. Аек булганда оялчан кыяфәтле, урта буйлы, какча йөзле, ләкин киң җилкәле, калын күкрәкле бу кеше хәзер бик юашланып, мескен булып калган. Өстәл кырыенда башын аска иеп басып тора.

... Ә өйгә сәрхүшләнеп бик шәбәеп кайта. Герой, күкрәк әтәчнеке кебек киерелгән, баш югары чөелгән. Күзләре пыялаланган. Беркемне дә күрми. Атлаган шәпкә авыз эченнән нидер мыгырдана: мине начальнигым ярата, минем Әкрәмов кебек эшчем юк, ди.

Барак коридорына кергәндә малаеның исемен кычкыра: «Дамир! Дамир! Коридор ярым караңгы, ул ишек төбенә куелган чиләкләргә, бала арбаларына абына-сөртенә атлый. Иң кырыйда аларның бүлмәсе. Ишекне ачып керә. «Дамир, Дамир, син кайда?» — дип, исерек тавыш белән кычкыра. Түрдәге кечкенә караваттан чырадай нечкә аяклар идәнгә төшә, аксыл чырайлы, зур башлы малай торып баса. Хәлсез күзләре белән әтисенә сәерсенеп карый. Йөзе белән борылмый, чөнки әтисенең исерек булуы аның ачуын китерә.

— Улым, Дамир,— дип өзгәләнә сәрхүш.— Мин сине яратам, мин синең өчен җанымны да бирәм. Дамир улым, кил әле, әтиеңне кочакла...— Сәях буялган, тузанлы киемнәре белән малае янына килеп тезләнә...— Йә, йә,— ди исерек ата. Тавышы ямьсез, карга тавышы сыман... Малай эндәшми, кырын карап, чигенмәкче була. Сәях аны каткан бармаклары белән эләктереп ала да үзенә тарта. Малай елый башлый, майлы, тузанлы бармаклар аны ычкындыра. Дамир караватына менеп, башыннан юрганга төренә. Сәях ах-вах килеп тора да ишек катына авыша.

Хатыны Гөлсәгъдә кайтып керә. Аның өстендә төрле буяуларга катып беткән зәңгәрсу комбинезон. Буяучы-маляр икәнен әллә каян әйтеп тора. Озынча аксыл битле, тыгыз, төз гәүдәле, иренең кыяфәтен күргә, йөзе җимерелә.

— Тагы лыкындыңмы, оятсыз! Эчмим дигәнең тукран тәүбәсеме? Йа хода, булса була икән эт әдәмнәр!

— Бетте, бетте, валлаһи, Гөлсәгъдә! Валлаһи, бер генә сум бир, ә? Валлаһи, соңгы тапкыр!

— Бар, күземә күренмә, җир бит! Утынлыкка кер дә ят, айны! Йа, хода, ни өчен миңа шундый җәза бирдең икән? Уф, уф, үләм! — Гөлсәгъдә аңа арты белән борыла.

Гөлсәгъдә бернәрсәгә бик аптырый. Буровойда бушка ашаталар, шуңа күрә ул Сәяхка акча бирми. Ә ул көн саен исереп кайта. Бу нинди әкәмәт? Контор буенча Сәях кебек тотрыксызлар байтак. Эчүчелеккә каршы көрәш бара. Карар чыгардылар: нәфесләренә баш була алмаучыларның эш хакын хатыннарына бирергә... Менә аванс бирәсе көнне эчкечеләрнең хатыннары касса янына җыела. Барысында да таушалган йөз, изелгән кыяфәт. Ник берсенең йөзендә бер нур булсын. Ә хатын-кыз бит нур чәчеп торырга тиеш. Боларның эчке нурлары сүндерелгән, көлгә әйләндерелгән. Өсләренә рәнҗетелгәнлек, таптапып яшәгәнлек чыккан. Эчүчелекнең гаилә өчен нинди зур фаҗига икәнен бу төссез, начар киенгән, касмак төсле көйгән йөзле хатыннар белгертеп тора. Гаиләдә күпме балалар газап чигә. Бәхетле балалык чорыннан мәхрүм ителә! Коточкыч! Шуларны киногa төшереп алып, ир-атларга күрсәтергә иде. Юк, эчүчелеккә каршы көрәш бик формаль алып барыла. Биредә Гөлсәгъдә аңлап җитмәгән нәрсәләр бар. Менә Сәях башта эчемлекне өнәми иде. Ул ялганлый белми. Дөреслекне, гаделлекне ярата. Җыелышта кайбер начальниклар сөйләгәндә ялганын тота торган сораулар бирергә ярата иде. Кыска гына: өч-дүрт җөмлә белән генә хакыйкатьне әйтә ала. Сөйләү сәләте юк. Аны җыелышка катнаштырмау ягын карыйлар, дип сөйләгәннәрен ишеткәне бар. Күпмедер вакыттан Сәях салмыш булып кайта башлады. Әлбәттә, җыелышта катыга утырта торган сораулар бирүе дә бетте. Иптәшләре шулай әйтә.

Ничек исерә бу Сәях, әллә тотып авызына салалармы? Гөлсәгъдә яшеренеп кенә күзәтергә керешә. Эш сәгатенең беренче өлешендә норманы тутырып, иртәрәк китә иде. Сыра ларегы артына бара да сатучы хатын белән уртак тел таба. Тегеләр аны эчкә уздыра. Мичкәләр арасында

кечкенә ситсы пәрдә артыннан күзәтә. Менә Сәях утыз тиенгә бер кружка сыра алды. Шуңа өстәп йөз грамм акны салдырырга акчасы юк, билгеле. Әмма аның артында торган кызыл борынлы берәү Сәяхның җиңеннән тотты. Сәях аңа таба борылып елмайды. Танышы микәнни? Теге үзенең кружкасына йөз грамм салдырганда Сәяхныкын да сузды. Икесенә дә түләде. Кем булыр бу? Ничектер таныш чалымы сизелми. Бөгелмәнекеме әллә? Яңа шәһәр әле зур түгел, бирелдәге кешеләр ничектер бер-берләрен беләләр. Автобуста, вахтада һаман бергә туры киленә бит. Ә бу чит. Ә нигә Сәяхны эчертә ул? Бөтенләй белмәгән кеше сыйлый алмый инде. Күкрәк турысы биеклегендәге түгәрәк стойкага килеп, кружкаларын урт-лап алдылар да куйдылар. Сәях кызыл борынлыга сәерсенеп карый, танымый, исенә төшерә алмый шикелле. Теге нәрсәдер әйткәч, Сәях елмаеп, иягән какты. Таныды, ахрысы. Сыйлаучы ашыга иде, алар кружкаларын тиз бушаттылар. Сәяхка инде булган иде. Бик тиз башына китә, бер дә буена сеңдерә алмый. Исерәм дип эчсә, су эчеп тә исерер, билләһи.

Ә бер көнне Сәяхны малярлар бригадиры Закуан сыйлап тора. Гөлсәгъдә күзләренә ышанмый. Чөнки Закуанны яхшы белә. Беткәнче, саран, карун. Артында сөйлиләр: бер тиен өчен чукыныр, диләр. Хатыннар арасында үзен җәллэтеп сөйләнә. Имеш, хатыны аны кыерсыта, әбәткә акча бирми. Шулай ирсез хатыннар тарафыннан үзен кызгандыра. Теге-ләргә ир-атны карау тансык, сыйлыйлар. Закуан аларга буяуларның яхшырагын, акшарның әйбәтрәген бирә. Саранлыктан хәйләле ул. Дө-рес, хатыны мәчкәй инде, саранның сараны. Юк, Закуанның Сәяхны эчертүе тикмәгә түгелдер. Нәрсәдер бар монда.

Озак «шпионлык» итүләрдән соң, Гөлсәгъдә бик нык уйга калды. Бу нинди хәл, әллә эчүчеләрнең берәр яшерен оешмасы бармы? Сәяхны һәр көн диярлек кем дә булса эчерә. Сыйлаучылар көн дә алмашынып тора. Нәрсә бу? Моны ничек аңларга?

Сәях кайткач аклана: бүген фәлән уңай белән бераз гына кәгеп алдык, ди. Һаман шулай салырга сылтау табып кына тора Сәях. Сыра эчкәндә йөз грамм эләкмәгән көннәрдә утын сараенда берәр хатынның эшен эшли, куян сеткаларын рәтли, тавык кетәкләре ясый яки баз казый. Барыбер үзенең нормасын алмый калмый.

Сылтау-сәбәпләр булмаганда, бар сылтаулар кулланылып беткәндә, көнчелек өянәгенә бирелеп ала. Гөлсәгъдә Сәяхның намусына тиярлек сүзләр әйтеп ташлый. Ир дигән кеше белән сугыша-сугыша тәмам гарык булды. Ичмаса эчендәге намусы кузгалмасмы дип, йөрәгенә кадалырлык сүзләр ычкындыра. Һәм Сәях шунда кузгала. Гөлсәгъдәне гаепләргә тотына. Сезнең бригадирыгыз мир үгезе Закуан анда барыгызны басып чыккан. Бер син генә калмагансыңдыр. Кашларыңны эскәк белән нечкәр-теп, каләм белән сызып... Түшләреңне текә итеп куеп, кәнтәйләнеп... Бу бәйләнгән кешенең үзенә каты итеп ябышу ысулы. Утка каршы ут җибәрә. Эчкечеләр моны яхшы үзләштергәннәр. Алар теләсә нинди алдауга, ялганга яки хыянәтләргә баралар. Оятлары качкан, намуслары беткән.

Гөлсәгъдә горур, баш имәс, сер бирмәс хатын. Туры сүзле, шуңа иптәшләре арасында өнәп бетермиләр. Аксыл шома битле, мөлаем чырайлы. Андый горур, ягымлылар хакында гайбәт чыгарырга яраталар. Күз күргән кешеләр чыгаралар. Гайбәт кемнәрнең генә тормышларын бозмый, ямьсезләми калдырды икән?

Ярый әле Гөлсәгъдә баланы авылга әниләренә кайтарып куйган чак иде. Сәяхны күбрәк эчергәннәр иде, ахрысы. Кайтуга гайрәт чәчәргә, әтәчләнергә тотынды. Салдыру өстенә аны кемдер мактаган, мин-мин-леген кәпрәйтеп җибәргән. Син уңган кеше, алтын куллы, синең кебек үткен кешеләр бик сирәк. Хатының гына синең кадереңне белми, янәсе. Сәях беркатлы утын пүләне шуларның барсына ышана. Ахмак! Һәм бер үзен күрсәтеп ала: «Минме, мин укыган булсам, профессор булыр идем.

Минме? Менә мин кем! Сез чүп кешеләр белән чутлашып та тормас идем...» «Син исерек баш! — дип ачудан чыдый алмыйча әйтеп куйды Гөлсәгъдә.— Беткән баш, өйләнгән булдың, гаиләңне дә карый алмыйсың. Эшләгәнеңне шайтан суы тыгынып бетерәсең! Балаңа да калмый! Эт адәм син, дуңгыз!»..

— Ә син, кәнтәй, анда Закуан барыгызны да!..— дип кычкырды Сәях әллә нинди куркыныч тавыш белән һәм мич арасында яткан балтаны алды да тимер караватның хромланган ак башларына чабарга тотынды. Гөлсәгъдә өйдән чыгып йөгерде. Бер иптәш хатынында кунды. Менә шушыны тормыш дип әйтеп буламы? Ә гомер уза. Шунсы тагы, мондый гаугалы гаиләләр шәһәрдә байтак. Барысы да шул аракы дигән иблис аркасында. Ә авылда үскән татар хатыннары сабыр. Эчүче ирләре изүендә көн итәләр. Аерылып-каерылып китүләрне белмиләр. Андый эш нәселләрендә булмаган. Үзләрен юатып: сабыр иткән морадына җиткән, дип чыдыйлар. Чыдау — иң төп өстенлекләре. Гомумән, татар хатынкызы үзенең гаять сабыр, түзем булуы белән аерылып тора.

Шулай бер тапкыр мул премия алгач, Сәях мастерны сыйламакчы булды. Моңа Гөлсәгъдә дә каршы килмәде. Сәяхның помбур буласы килә иде. Төрле пычрак, майлы эштә йөреп туйган иде. Помбурның эше чистарак. Акчасы да шактыйга артык. Сәях шуңа өмет итә. Тартакиев белән әйбәт утырдылар. Эчемлек пары башына киткәч, Сәях үзенең тел төбен аңлата алды. Тартакиев исә бик хәйләкәр, авыз эченнән нидер мыгырданды да бетерде. Үзеп берни әйтмәде, сүз дә бирмәде. Шаярулы җитди тонда: «Ярар, сыеңны кире костырма!» — дип әйтеп ташлады Тартакиев.

Иртән вахтага Сәях килмәде. Иптәшләре Тартакиевка каш астыннан гына мәгънәле күз сирпиләр. Кичә бергә булганнарын күреп калганнар, ахры. Тартакиев тамагын еш-еш кыргалый, карашын читкә ала. Сәях иптәшләренең нәрсәгә ишарә итүләрен сизенде ул. Берсе һаман Тартакиев алдына килә дә: «Сәях кая? Сәяхка ни булган?» — дип шәрран яра. Тартакиев нарядлар тутыра, путевкалар әзерли. Теге тукынучыларга нуль әһәмият белән карый. Эченнән инде уйлап алды: «Мөгаен айныткычка эләккәндер, шайтан алгыры!» Җыен кара чәчле бораулаучылар арасында, кара җирдә калган солы көлтәседәй Тартакиевның сары тузгак башы әллә каян аерылып тора иде. Ул, вахтаны озаткач, бүлмәдә кеше калмавын чамалады да милициягә чылтыратты. Сәях турында: «Ә-ә, ул безнең үз клиентыбыз»,— дип кенә җибәрделәр.

Тартакиев милиция идарәсенә килде. Сәях айныткычка гына эләкмәгән икән. Хулиганлык эшләгән. Хатынын кыйнаган. Өйдә тавыш купканын ишеткән күршеләре милиция алып килгәннәр. Милиция баракка урам аша гына. Тәртип сакчылары килеп кергәндә Сәях хатынын якалап маташа. Милицияләр шаһит булганнар. Протокол төзегәннәр. Ә бу бик зур документ. «Ике ел»,— диде «дело»ны төзүче яшь кенә лейтенант. Яңа гына эшли башлаган нәрсә. Эшенә ябышып ята. Үзен бик күрсәтәсе килә. Бу инде сөйләшүләргә, үтенеп сорауларга, кеше хәленә керү дигән нәрсәләргә колак та салмаячак. Үгетләүләргә нәфрәтләнәчәк. Аңа кеше хәле түгел, карьера кыйбат. Законның һәр хәрефенә тешетырнагы белән ябышачак... Тартакиев аның белән бераз сөйләште, кылын тарткалады. Һәм нинди зат икәнен чамалады да бүтән сүз озайтмады. Өлкән инспектор янына керде. Бусы элекке таныш. Бер-берсенә эшләре төшкәне бар. Һәрчак уртак тел табалар. Хәзер дә ул Тартакиевны аңлады. Эшкә нокта куймакчы булды. Ләкин яшь лейтенант бик каты рәвештә каршы торды. Икәүләп үзләренең начальникларына кереп киттеләр. Күрше бүлмәдән яшь лейтенантның әтәчләнгәне ишетелеп торды. Эшләр хәтәр икән, дип борчыга төште Тартакиев. Яшь лейтенантның аягына сыер басмаган, гаиләсе дә юктыр, күрәсең. Кара, ничек ярпачлана. Хәер, мин үзем дә аның кебек чакта кызыл авыз идем. Начальник гомерен һәрчак арттырып үти идем. Нинди дурак булганмын. Начальник-

ләр үзләренә эшләттеләр-эшләттеләр дә артыма типтеләр. Алар дәрәҗәгә үрмәләде, мин лайга утырып калдым.

Инспекторлар сугыша торган ике әтәч кебек чәчләре тузып, йөзләре бүртенеп килеп чыктылар. Өлкән инспектор протоколны ертып чүп кәрзиненә атты. Яшь лейтенант: «Мин моны болай калдырмыйм!» — дип ысылдады. Өлкәне Тартакиевка бер язу тоттырды.

Сәях тәмам бетерешкән, суга баткан тавык кыяфәтенә кергән. Болай да кечкенә битләре уч төбе хәтле генә калган, шуңа борыны тырпайган булып тоела. Тартакиев аны үзе йөртә торган «Бобик»ка утыртты да буровойга алып китте. Сәях алгы урынга утырырга кыенсынды, артка посты. Аның дөньяны күрәсе килми шикелле иде.

— Дурак, нишләдең син? — дип Тартакиев рульдә килеш, башын бормыйча гына аны шелтәләргә керешге.— Мин килеп җитмәсәм, утыртып куялар иде үзеңне! Синең белән бер эш итәргә ярамый икән! Нинди чүп әдәм икәнсең! Ничек белмәгәнмен... Уф!

— Ә нигә мине коткарасың, утыртсыннар иде. Шул кирәк миңа! Утыртуларын теләп йөрим. Барыбер утырачакмын...

— Әллә тилердеңме, ни сөйлисең? — дип гаҗәпләнде Тартакиев колакларына ышанып бетмичә.— Нәрсә син мине үртисең? Күпме көч түктем сине йолу өчен. Үтә чыккан дурак!

— Коткарма син мине, иптәш Тартакиев,— диде Сәях еламсыраган тавыш белән.— Кире илтеп тапшыр! Әйе! Әйе! — Үз-үзенә бик зәһәр нәфрәттән эчендә ут уйнаганга шулай әйтте ул.

— Ачуны чыгарма, әдәм түгел син, әдәм тизәге! Кем инде үзенең хатынына кул күтәрә? Тизәк, тизәк! Әнә ата эт бервакытта ана этне тешләми. Бер очракта да тешләми!

— Давай милициягә кире илт! Давай, давай! Югыйсә син үз властеңны күрсәтәсең, властең белән җанга басып...

— Җитте, ычкынган әдәм! — дип башын борып ырылдап бүлдерде аны Тартакиев.— Мин сине кешегә санап йөрим, дурак! Үзең утырган ботакка үзең балта чабасың! — Аның болай да юан муенындагы тамырлар бүртеп чыкты, якасына сыймас хәлгә килделәр. Руль тотып барган куллары да калтыранды һәм «Бобик» каршыга килгән «Урал»га орына язып үтте. Чөнки Сәяхның: «Властең белән җанга басып» дигән сүзләре аның характерындагы яшерен чалымга барып тиде. Эш шунда, Тартакиев бик тә властьлык итәргә ярата. Мактауга мөкиббән китә. Үз көченә үзе сокланып кәпәренә, властьны арттырып куллана. Бу рәсми хупланмаса да, дәшми генә астан юл куялар. Мондый башлыклар эшчеләр тирен нык сыга. Сәяхның болай кирегә сукалап маташуы, тәмам акылсызлануы шуңардан да иде. Мастер үзенә тәлинкә тотучы бер жуликны һәр эшне карусыз эшләп барган, ләкин башбирмәс, тискәре бәндәдән артык күрә. Бу хәлгә күпләрнең бик ачулары килә. Ләкин турысын әйтергә шүрлиләр. Тартакиев эчендә кинә саклаучан. Эштә үзенең култашнары аша сиңа бер-бер кырын китерүе мөмкин. Беркем дә гөнаһсыз түгел. Сәяхның да арты юеш. Бары салмышлыкка бирелүе аркасында. Барысы да үт булып эчкә җыелып килгән һәм хәзер шулай тышка бәреп чыкты. Салырга ярата торганнар белән мастер бер дә әдәп саклап маташмый. Аларның йомшаклыкларыннан файдалана, тупас кылана. Рәнҗетергә, кимсетергә күп сорамый. Шуларга тагы үз-үзенә ачу өстәлә. Кичә эчүгә бүген бик нык үкенү, көчсезлек, гамьсезлек. Үз тормышыңны үзең бозасың. Үзеңне кулга алырга көчең җитми. Шайтан суы белән көрәшәсең, әмма барыбер шайтан җиңә. Ник бу болай? Нишләп мин бу тозакка эләктем? Юк, бүтән якын да бармыйм. Ант итеп бераз торгач, эчтән шайтан тавыш бирә, эчәргә таләп куя башлый. Шундый каты таләп. Бу вөҗүди таләпкә каршы торып булмый. Тагы, тьфү, тагы. Уф, инде нишләргә? Аяклар үзләреннән-үзләре сыра ларегы янына таба атлый. Адымны туктатырга мөмкин түгел. Эчтә шайтан бунт куптара.

Уф, тагы беттем... Сыра ларегы янында эчәргә акча теләнүче алкаш каргана. Ичмаса сугыш чыксын иде, китәр иде дә бетәр иде...

Эчкәннең икенче көнендә Сәяхның махмыры булмый, башы авыртмый иде. Хәзер дә аның башы саф, «шөрепләре» әйбәт эшли. Ул Тартакиевның авырта торган сөяленә басты, шуның белән тегене чыгырдан чыгара язды. Беткән баш беткән, дип уйлады һәм эчендәген беткәнче түгәргә булды.

— Куштан этләреңнән талатырсыңмы, иптәш Тартакиев? — диде аңа һөҗүм иткәндәй. Ачудан ак-караны аермый ахры, «иптәш Тартакиев» дип эндәшә. Әйтерсең лә алар кичә генә кыза-кыза бер-берсенә дуслык сүзләре сипмәгәннәр, күпме вакыттан бирле чәрәшә-чәрәшә бергә тир түкмәгәннәр. Ачуланышмаганнар, аннан дуслашмаганнар. Менә тагы мөнәсәбәтләр өзелде, шайтан алгыры!

— Әтәчләнден дә, инде астыңа кәк итәсеңме? — дип Тартакиев ян казнасы белән генә ырылдап куйды.

Буровойда шәм күтәреп маташалар иде. Сәяхны эш шунда ук йотып алды... Шактый эшләгәч кенә аңа аек акылы кайта башлады. Нишләдем мин, ахмак, дип, эченә пошаман йөгерде. Ул бит Тартакиевны үзенә хәерхаһ итәр өчен ресторанга алып кереп сыйлады. Ул үзен бурильщик ярдәмчесе итеп күтәрүләрен өмет итә. Ике ай укып та кайткан иде. Әмма һаман күтәрмиләр. Буровойда төрле вак-төяк эшләр эшләтеп йөртәләр. Ә күтәрү туры Тартакиевка бәйләнгән. Ул суза да суза. Майламыйча таба купмый дигәннән чыгып, сыйлаган иде. Утырганда шул хакта сүз арасында сиздереп тә алды. Әмма Тартакиев усал, хәйләкәр. Тешен дә агартмады, ишетмәмешкә салышкан сыман итте. Сәяхның чыгымчылавы, үз-үзен бетереп ташлардай булуы моңардан гына түгел. Сыйланып төн урталарында өйгә кайткач, хатын белән чарпалашудан да иде. Барысын шул харап итте. Кайнар кул астына Гөлсәгъдә килеп керде. Күршеләр участковыйны дәшеп куйганнар...

Буровойдан кумасалар бүтән эчмим, ташлыйм, ди-ди, эчтән ант итә-итә багана күк катып тора ул... Җыелыш башланыр алдыннан гына бүлмәгә горком инструкторы килеп керде һәм туры президиумга барып утырды. Ул төскә-биткә чибәр, матур фигуралы, бик затлы киенгән яшьрәк хатын-кыз иде. Местком председателе урынбасары Кәкүшев, юмакайлы елмаеп, аның колагына нидер әйтте дә Әкрәмовка утырырга кушты. Ул утыргач, җыелышның көн тәртибен алдындагы кәгазьдән укып игълан итте. Тагы горком инструкторына ләббәйкә китеп, колагына нәрсәдер пышылдады һәм беренче көн тәртибе буенча сүзне аңа бирде. Яңа ел елкасы кебек бизәнгән хатын торып басты, катыргысын икегә ачып, укырга тотынды. Тынычлык советының «Көньяк Африкага азатлык» дигән декларациясен тикшереп, карар кабул итәргә тиешле икән. Декларация текстында Көньяк Африка апартеидын бик каты гаепләү, дискриминация сәясәтен фаш итү көчле иде. Без, совет кешеләре, беравыздан Көньяк Африкага азатлык таләп итәбез! дигән каттый сүзләр белән тәмамлана декларация... Хатын укып бетергәч, катыргысын япты да урынына утырды. Шунда Кәкүшев: «Кемдә нинди фикерләр булыр, иптәшләр?» — дип, залдагыларга төбәлде. Кешеләр тын калдылар, авызларына су капканнармыни. Юк, кемдер уртадагы рәттән: «Барыбыз да риза», — дип куйды. Икенче берәү: «Принять в целом!» — диде. Кәкүшев: «Димәк, иптәшләр, барыбыз да шушы декларациягә бертавыштан кушылабыз, шулай бит? Каршылар юкмы? Юк. Тавышка куеп тормыйм. Контора эшчеләре Көньяк Африка Республикасына азатлык таләп итәләр...» — Ул горком инспекторына карап алды, аңардан боерык ымы көткән кебек иде. Ләкин хатын ым какмады. Кәкүшевның яңак калкымнарында уч төбе кадәр алсулык пәйда булды. Җыерчык белән бөрешебрәк торган өске ирене җәелә төште, сары тешләре күренеп китте. — Көн тәртибенең икенчесе — персональ эш. Шуның буенча сөйләр өчен сүз контораның культура-масса бүлеге методисты, женсовет председателе

Соня Валеевнага бирелә. Әкрамов, торып бас!» — дип, Кәкүшев үзенең күршесенә карады да урынына чүмәште.

Соня Валеевна калкынды, алдындагы кәгазь битләрен рәтләштерде. Тәбәнәк буйлы, түгәрәк битле, үрдәк борынлы, зур авызлы яшьрәк хатын-кызның тавышы чәрелдегрәк чыга иде. Ахрысы, нервылары бик үк утырып җитмәгәндер. Үзе ир-ат күзенә кererлек итеп киенгән. Түше ярыйсы гына ачык, кофта төймәсе түбән иде. Күптән түгел яңа йорттан фатир алды. Хәзер шуны эше белән акларга тырышкандай, Әкрәмовны эттән алып эткә сала иде. Хәер, безнең кырыс тормышның кагыйдәсе шул: кемне дә булса тәнкыйть итеп кенә син башлыкларга ярый аласың.

Соня Валеевна хаклы һәм урынлы тәнкыйть итә, шайтан алгыры!

— Эчкечелек бик яман чир. Иң әшәке бәла! Ни үзенә рәтле тормыш юк, ни гаиләсенә. Өстәвенә бергә эшли торган коллективның теңкәсенә тия. Үзенең бер әшәке нәфсесенә баш була алмау аркасында. Кем аңа шундый хокук биргән? Әкрамов таза тирә-юнебезне эчеп-исереп пычрата. Өендә җәнҗал чыгара. Күршеләренә дә тынычлык бирми. Менә ничә кеше аның өстеннән язып китерде. Бараклан күчерегез, түзәрлегебез калмады, диләр. Безнең контораның сабырлыгы төкәнде. Әкрамовка күпме ярдәм итәргә теләдек, үгетләдек, иптәшләрчә үтендек. Юк, ул безнең кешелек хисләребезгә төкерде генә, иптәшләр...

— Юк, төкермәдем, дөрес әйтмисең, Соня Валеевна! — дип мыгырданып әйтеп куйды Әкрәмов юаш кына.

— Ә ни өчен эчүдән туктамыйсың? — диде чәтер-чәтер Соня Валеевна. Әкрәмов телгә килгәнгә җанланып, ягъни аның сөйләгәннәре тәэсир итми калмады. Чөнки ул җанга үткәреп сөйли белә шул.

— Фатирсыз интеккәнгә... — Әкрәмовның сүзе авыз яныннан узмады. Җыелыштагылар үзара пышылдашып алдылар. Ишеткәннәре кайсы көлде, кайсы: «Дөрес!» — дип әйтеп куйды.

Игътибар иткәннәр шуны күрер иде: менә кыска эш кожаны, кирза итек кигән ябыграк кешене бик яхшы киенгән, симез, тук адәмнәр талкыйлар. Күзен ачырмыйлар. Урынлы тетәләр. Әкрәмов тир түгеп эшләүче. Ул эшләп чыгаручы. Матди байлык булдыручы. Ә аны талкучылар берсе дә матди байлык арттыручы түгел. Тугыз тир түгеп ил хәзинәсен баетучылар җилкәсендә баручылар. Алар буровой эшчесе Әкрәмовтан бар яктан караганда да әйбәт тормыш белән яшиләр. Яхшы квартирларда торалар. Эш хаклары да югары. Махсус тәэмин ителәләр. Төрле каналлар аша. Әкрәмовта боларның берсе дә юк. Тик аның учларында тояктай каты сөялләр һәм аркасында тир тозы бар. Әмма матди байлыкка өлеш кертүченең әз генә гаебе дә гаять дәрәҗәдә күпертелә. Юк, эчкече Әкрәмовны акларга итеп башка килми мондый уйлар. Просто гаделлекнең тулы түгеллеген күңел искәртә. Күңелдә уңайсызлык барлыкка килә. Эшли торган кешене эшләми торган бәндә хурлаган шикеллерәк хәл бит... Соня Валеевна берләшмәдә генә. Анда күп ир-атларның ястыгы булган, диләр. Бер геологның хатыны аны ире белән тотып, горкомга бик каты язып биргән. Фактларны кире кагарлык булмаган. Шуннан соң Соняны бу конторага китереп сыладылар... Үзе шактый пычрак кеше сине пычраклыкта гаепли. Мәгәр дөрес гаепли ул. Ләкин үзе чистарак кеше гаепләсен иде. Гарьлек булмас иде, сүзләре дә чын, үтемле булыр иде.

— Ялганлама, Әкрәмов, квартира бирсәләр дә эчәчәксең син. Инде ничә тапкыр безнең алда тәүбә иттең, барысы да буш сүзләр генә булды! — Соня Валеевнаның муен тамырлары бүртеп чыкты, ияген, тамак астын көрән таплар каплады. Ул үз сүзләреннәнме, файда итәм дип ышанычымы, тәмам ярсый башлаган иде. Кукләшев аны тыя төшәргә мәҗбүр булды.

Сөйләргә тагы бер конторда эшләүче күтәрелде. Бу үзе дә эчәргә бик ярата. Әкрәмов белән дә стакандаш булганы бар. Хатыны бик усал, бер тиен кулына тоттырмый. Шул хатыны тыюы аркасында гына юньлеләр

рәтендә йөри. Үз хәлен дә аңлап, ул йомшак сөйләде. Бераз төрттереп тә алды: гади эшченең эчкәнен бик тиз күрәләр, ә начальникләрнекен күрмәмешкә салыналар, диде. Мисаллар китерергә курыкты. Югыйсә, мисаллары кырында гына утыралар иде. Әнә, Берләшмә инженеры арт йомшагына капсюль тектергән, хәзер эчми. Гомумән, залда эчми торган кеше бераү дә юк. Хәтта хатын-кызлар да эчемлекне читкә куймыйлар. Аларны гаепләп тә булмый. Авыр эштә эшлиләр. Горкомда берничә татар капсюль белән йөри диләр...

Бер-ике эшче эчүнең нидән килеп чыгуын, аңа этәргән сәбәпләргә ныграк тукталды. Акыл белән сөйлиләр. Болар эчемлек колы булмыйлар инде. Нинди генә җайлы урынга куйсалар да, тотнаклы булачаклар. Әкрәмов йомшак, тотнаксыз шул. Җитмәсә, гаделлек аның тормыш кыйбласы икән. Үткән чыгышында Әкрамов эчен ачкан иде: «Гаделсезлек күрсәм, бик каты ачу килә. Һәм ачуны басу өчен эчәм!» — дигән иде ул. Разве мондый кредо белән яшәп була? Юк, иптәшләр. Юләрлек бу, чеп-чи тилелек!..»

— Ул эчә белми эчә! — дип сүз кыстырды залдан кайсыдыр.

Җыелыш эчүчелекне нәләтләргә, фаш итәргә тиеш җирдән ничектер кешеләрне шул бәлагә китерә торган сәбәпләрне тормыш эченнән чүпләп алуга күчте. Горком инструкторы мона чыдап утыра алмады, сүз алып гайрәт чәчәргә тотынды. Эчүчелек ул капитализм калдыгы, диде. Эчкече безнең арабызда капитализм мәетен йөртүче ул. Аңа безнең тормышта урын булмаска тиеш. Безнең таза эшчеләр сафында капитализм микробы булмасын. Без ул микробка җәелергә ирек бирмәбез. Юк! Кайбер иптәшләр бу җирәнгеч авыру таратучыга җавапсыз карыйлар. Җиңел генә фикер йөртәләр. Эчүчелек ул эшләп чыгару планнарына аяк чала, продукцияне киметүгә сәбәпче була. Шуңа күрә эчүчелек җинаять итеп каралырга, шулай бәяләнергә тиеш аңа. Ә бу коллективта эчүчеләргә тәкәллеф белән карыйлар икән. Биредә Алмаз Борисовичның да демократичный булуы сәбәптер мөгаен. Моны болай гына калдырырга һич ярамый. Капитализм чирен таратучыларны коллективтан берсүзсез куарга кирәк!

— Сорау бирергә ярыймы? — дип бүлдерде аны кемдер. Бу — Алкин икән. Ул җыелыш башында юк иде, соңарак кереп утырган ахрысы.

— Ярар, Алкин, сөйлә, — диде Кәкүшев горком инспекторына карагач һәм аның «сөйләсен» дигән ымын алгач.

Алкин һәрвакыттагыча сүзен рус халкына рәхмәт белән башлады:

— Рус халкына рәхмәт, ул безгә бөек эшләр башкарырга ярдәм итә, — диде һәм фикерен җыеп тынып торды. Житү чәчле башын учы белән сыпыргалап алды. — Менә сез эчүчелеккә капитализм калдыгы, дидегез. Әкрәмов бит совет чорында туып, колхозда тәрбия алган. Каян килеп ябышкан аңа капитализм калдыгы? Бусы — бер. Икенчедән, аның бабасы да, әтисе дә эчмәгән, чөнки ул заманда татар авылларында эчемлек дигән нәрсәнең исе дә булмаган. Аракыны бары 1930 елларда авылларга масса төстә кайтаралар. Тарихчы Биляловның китабын укыгыз. Шуңа күрә Әкрәмовның эчкечелек белән авыруы ничек капитализм калдыгы булсын, ди? Ул социализм чорында эчәргә гадәтләнеп киткән. Шулай булгач, Әкрәмовның чире социализм чире була түгелме?

Президиумда утырган хатынның кабартма битләренә кызыллык бәреп чыкты, алтын алкалы колак яфраклары семофор утыдай яна иде. Ул каушабрак калды кебек, кашлары җыерылган, иреннәре җептәй тартылган, бармаклары алдында яткан кәгазь битләрен тиз-тиз актара. Бу хәрәкәтен үзе дә абайламый кебек. Кәкүшевның коты алынды, торып басты, бу куркыныч хәлдән котылу әмәлен таба алмый аптырады. Горком инструкторын хурлыкка калдыру бик зур скандал тудырачак. Моңа сәяси төс биреп күпертәчәкләр. Аннары йөре җавап тотып. Шулай ыкмык торганда, Куштан ярдәмгә килде.

— Бу дошмани чыгыш, моны болай калдырырга ярамый, — диде бик сизгер һәм белдекле, тәкъва тавыш белән. — Сәяси диверсия. — Куштан

тагы горком кешесенә кәнтәйләнергә иткән иде, ләкин Кәкүшевнең зиһене һәм батырлыгы алга чыкты, ситуацияне үз кулына алырга кирәклеген сизде.

— Бернинди диверсия! — диде ул кәнтәйне бүлдереп һәм хатынга карап-карап алды. Нинди тәэсир бирә аның мондый чыгышы, шуны хатынның йөзеннән укыган кебек итә. — Алкин, бар хәзер үк җыелыштан чыгып кит! Ишетәсеңме, син безгә эшләргә комачаулыйсың! — Кәкүшевнең тавышы катгый, аяусыз иде.

— Эчеп килгән дә, понимаешь! — дип аваз салды кайсыдыр. Кәкүшев дәһшәтле, киеренке, янаулы чырай белән басып тора, Алкинның чыгуын көтә. Хәзер Алкинның иптәшләре аның чыгып китүен үтенә башладылар. Куштан-ялагайлар шау-шу кубардылар. Алкин, ахырда, нидер мыгырдана-яный урындыклар арасыннан кысыла-кысыла ишеккә юнәлде. Ул ишекне япкач, Кәкүшев теге хатынга башын бөгеп, нәрсәдер аңлатты, берничә мәртәбә чигәсенә бармагын куеп алды. Ягъни ычкына башлаганрак, сәер гадәтле кеше. Хатынның бераз кәефе килгәндәй булды, кашлары турыланды, хуплап, ияк каккалап торды. Янәсе, мин барын да аңлыйм. Ул иртәгә горкомда «мнение» тудырмас шәт, дигәндәй Кәкүшев тә бераз тынычланды шикелле.

Җыелыш дәвам иттерелде. Кәкүшев җыелышны йомшаграк эзгә төшерә алды. Каты бәрелүчеләрне тиз туктатты. Җыелыш Әкрәмовны эшендә калдырды һәм соңгы кисәтү ясады...

Кәкүшевның Сәяхны коткарып калуы Зәйдә канәгатьлек тудырды. «Молодец, Кәкүшев!» — дип уйлады ул. Тик башына бүтән уйлар да килде. Алкин аракы турында дөрес әйтте бит, шайтан алгыры. Бер дөрес сүз ычкындырды, шуны күтәрә алмадылар. Куштаннар ябырылып дәррәү кире кактылар. Дөрес сүз әйтергә тамчы да ирек юк. Алайса нигә без «Көньяк Африкага азатлык!» — дип лаф орабыз, өндәмәләр кабул итәбез? Үзебезнең хәлне күрмибез.

Кара, нинди көфер уйлар башка килә. Тьфу, тьфу, телдән ычкына күрмәсен тагы! Ул башына килгән хаклы фикерләрдән куркып калгандай булды. Фикерләрен куып җибәреп, башка нәрсәләргә уен күчереп азапланды. Хаклы фикерләр — үҗәт, тиз генә китмиләр, югалмыйлар иде...

* * *

Байкин Мәскәү Главгеология разведка трестының Бөгелмәдәге филиалы лабораториясендә бүлек мөдире иде. Бораулау конторыларына геологик катламнар картасын сызып-әзерләп бирүчеләр белән җитәкчелек итә. Узган атнада «Акташнефть» берләшмәсендә бик зур киңәшмә булды. Анда Байкин да чакырылган иде. Бораулау конторасы директорлары геология хезмәтен бик каты утка тоттылар. Геологик катламнарның карта-сызымнары бик халтуралы төзелә. Ә катламнарны бораулап тишкәндә бер дә көтелмәгән хәлләргә юлыгасың. Йә обвал, йә йотылуга килеп кабасың. Авария бер дә сәбәпсез булмый. Менә утырасың скважинаң төбендә ясин укып... Геология хезмәте безне аварияләрдән әз булса да аралап ала торган аерым катламдагы ихтимал хәлләрне кисәтерлек карта-белешмәләр бирергә бурычлы. Моның белән бик җитди шөгыльләнергә кирәк, чөнки катлаулы аварияләр миллион сумнарны ашый. Эшчеләрнең матди хәленә дә нык суга...

Лабораториядән халтура чыкканны Байкин яхшы белә. Ул аерым катламдагы токымнарның ничек урнашуларына әһәмиятне юнәлтте. Аерым нефтьле мәйданнарның катламнар кара-сызымнарын шпаргалкасыз төзетергә тырышты. Лабораториядә химик-физик термик һәм бүтән яктан тикшерүләр шкаласына яңа пунктлар өстәде. Тагы башка эшкә файда китерер дип өметләнгән структуралар кертеп карады. Әмма күрә: бернинди яңарыш сизелми. Нилектән бу? Ул керткән төзәтмәләр лабора-

ториядә эшләүчеләргә эш күләмен арттыра иде. Ә беркем дә артык тир түгәргә теләми. Пробирка, приборларны чистартуны эшкә санамыйлар. Артык бер хәрәкәт ясамыйлар. Чөнки эшне яратмыйлар. Ә намус кайда? — дисәң, намус юк ул, намусны ашап бетергәнбез инде, бүтән калмаган, ди-ди телләренә салыналар. Гамәли тормыштан килгән терс, файдалы фикер-ниятләр эшкә кушыла алмый. Читтә калалар. Аларны шпаргалка-шаблон ташкыны агызып алып китә дә йотып бетерә. Һәр җирдә шпаргалка. Шунлыктан производство алга бармый, үзен-үзе кабатлап бер урындарак таптана. Аңа кыю фикер, ният-ачыш, акыл юнәлеше бирелми. Бәла бит бу! Котылу мөмкин булмаган хәл — «шайтан тәгәрмәче» барлыкка килә. Нишләргә? Өстә әзрәк уйлыйлар микән шул хакта?

Тагы шунысы да бар: бораулаучылар җирне тишкәндә без әзерләп биргән катлам карталарына карап та маташмый. Кайсы аны файдасыз дип белә, кайсы андагы билгеләрне рәтләп аңламый...

Киңәшмәдә файдалы фикерләр дә әйтелде. Ләкин ул фикер-ниятләрне әз генә гамәлдә куллана башласаң, шул фикерләрне әйткән кешеләр үзләре үк моңа каршы киләләр. Байкин мондый хәлләрне күп сынады инде.

Байкин залдан Тугаев белән бергә чыкты. Тротуарда тегене-моны сөйләшеп торганда, алар янына әллә каян Андрей Казан килеп басты. Какча гәүдәле, ягымлы чырайлы, сыгылма адымлы, башында искерәк эшләпә, кулында кирза сумка иде. Иң элек Тугаев белән бик якын итеп исәнләште, аннары Байкинга кул бирде.

— Сез танышлармыни? — диде Байкин, аларның дусларча исәнләшүләренә шаккатып.

— Нинди генә танышлар әле! — дип куйды Тугаев мөлаем елмаеп. — Без бергәләп бер пот тоз ашаган кешеләр... — Ул әле Байкинга, әле Андрейга сынаулы карашын төбәде. Андрей шунда ук аңлатты.

— Без Петя белән күршеләр, — диде. — Дөрес, ул фин йортында особнякта тора. Без ике катлы йортта — янәшәдә. Аның әнисе белән минем апа — ахирәт дуслар...

Бередә шунысы кызык чыкты: Тугаев, Байкин — чын татарлар, ләкин татарча белмиләр. Петя, аңласа да, сөйләшергә җөрьәт итми. Тугаев исә принципиаль татарча сөйләшми иде. Армиядә шулай өйрәнгән өчен генә түгел, ә урындагы кеше булганга күрә дә. Татарча сөйләшсәң, үз милләттәшеңне якын иткән, башкалардан аерган кебек була. Аннары татарча сөйләшкәнне өстәгеләр дә өнәми. Тугаев моны хаклы дип саный, бер авыз сүз татарча ычкындырмый. Ә Андрей, чын рус, үзенә әз генә килешле акцент белән саф татарча сөйләп тора.

— Әйдә, алып кайтам, — диде Байкин, аны көтеп торган Газ — 61 машинасына ымлап. — Монда нишләп йөрисең?

— Илаһи эшләр белән, беләсең. 1 — поселокта берәү үзен указлы мулла итеп игълан иткән. Күп садака кереме бар. Кемдер шуның өстеннән шикаять язып, газетага җибәргән. Дин бүлегенә биргәннәр... Ләкин самозванецны таба алмадым. Юлым уңмады... — Аның сүзләрен тыңлап бетермәс борын Тугаев, китәргә ашыкканын белдереп, саубуллашырга кулын сузды. Ничектер карашын читкә ала иде. Икесе дә аның учына бармак очларын кертеп чыгардылар. Тугаевны кемдер ашыктырып дәште. Ул бераз кәкрерәк аяклары белән кызу-кызу атлады, зур башы, алгарак иелгәнгә, җилкәләре эченә чумган шикелле булып тоела иде.

Юлда Андрей исә Тугаев белән кайда, ничек танышуы турында сөйләп кайтты.

— Ул сугышта «смерш»та эшләгән, — диде Андрей, бар сөйләгәннәренә йомгак ясагандай. — Мин аны югары башлык булыр дип уйлаган идем, ничектер артык үрли алмаган... Әллә хатын-кыз аяк чалганмы? Ә?

— Аяк чалучы тагы өченче нәрсә дә бар. Ул чынны яклау, хакыйкать яклы булу, — диде Байкин ничектер мөлаем елмаеп.

— Син үзеңнән чыгып әйтәсеңдер, аңлыйм. Сине шуңа үрләтмәгәннәрдер...
— Шулайрак. Ялганлый алмау минем бәлам...
— Мине дә шул сыйфат кешелектән чыгарды бит. Сөйләгәнем бар...
— Кайберәүләр күрә торып, караны ак дип әйтәләр. Мин шуңа бик гаҗәпләнәм. Яшьләр, әле эт каешына әйләнмәгәннәр шулай икейөзләнүне гадәти хәлгә санныйлар. Менә фаҗига кайда.
— Мәктәптән күреп үзләштерәләр. Кибетче, база директоры, райком, горком кешесе балаларына укытучы бер очракта да икеле куймый. Һәркем аларны яклый. Педагогика чүп ул тормыш кырыслыгы алдында... Бар нәрсә дә бер-берсенә тыгыз бәйләнгән шул...
— Сөйләвең буенча, син татарлар өчен янгансың, ә? — Байкин сүзне кызыклырак эзгә кертергә теләде.
— Юк, чыганакларда татарларның тарихы төрле юллар белән бөтерелә баруына тап булдым. Татармы ул, маримы — миңа барыбер. Ә халык тарихының эзен төрле нәрсәләр белән күмдерү, югалту шул халыкның киләчәгеһ бетерү дигән сүз. Бу эш бик оста, хәйлә-мәкер белән эшләнгән. Нацменнарга карата шовинистик сәясәтне Иван патша вакытында ныклы гамәлгә кертәләр. Мин шул нәрсәне күрдем һәм шуны әйттем. Әмма бу сүзем «орган» кешеләренә ошамады. Өстәп төрле ялалар яктылар һәм җәзага дучар иттеләр...
— Ә бит күрмәскә, белмәскә, белгәнеңне язып чыкмаска булган булыр иде? Шулаймы?
— Мине абындыру өчен шундый чыганаклар биргәннәр, дип тә уйлыйм кайчак. Хәер, татарларны ничек бетерүне язып чыкмасам да, барыбер утыртырлар иде. Әмма татарларга зыян гына эшләдем: миннән соң ул чыганак-язмаларны каяндыр соратып алганнар да юкка чыгарганнар, ди. Төрмәдә бер бик көчле востоковедны очраттым. Миңа тап булган материаллар белән таныш икән...
— Гомумән, татарның тарихы юк инде аның. Шулай бит?
— Русларның татарга карата мөнәсәбәте башкачарак бүтән нацменнар белән чагыштырганда. Шул сизелә, нык сизелә... Ул нәрсә бик нык эчкә яшерелгән, күп нәрсәләргә төрелгән.
— Ә бит әйтәләр: үткәне булмаганның киләчәге дә булмый дип.
— Менә хикмәт тә шунда шул. Татарның киләчәге булмасын өчен, үткән тарихын әкрен-әкрен бетерә барганнар...
— Болай алганда, рус булдың ни, татар булдың ни — барыбер инде?..
— Татарны икенче сорт итеп карауларын син бит беләсең? — Ул, нигәдер йөзе сүнеп, тирән көрсенеп куйды. Тирәнгә керүдән курка иде булса кирәк, аннары һәркемнән шикләнү дә бар аңарда. Байкин аны исәпләде: менә кайсыбер баланс ничек төзелгән — үзенә файдалы булмаган нәрсәләр турында кайгырта. Үзенә зарар гына китерәсен белеп торса да, гаделсезлекне ачып сала. Фидакарьлеккә бара. Һәртөрле геналарына гаделсезлеккә нәфрәт салынган, ахрысы. Ләкин мондый фидакарь җанлы, гали рухлы затлар бик сирәк шул. Күпчелек адәм начарлык, гаделсезлекләр белән килешеп, шуларга җайлашып яши. Мәҗбүриятькә буйсына. Ә мәҗбүрият бик хәтәр, аяусыз. Аның өчен адәм заты бары бер пешка гына. Без барыбыз да пешкалар инде, дөресен генә әйткәндә.

Тормышта гаделсезлекләр булып тора. Күпме гаделлек булса, гаделсезлек шул тикле ахрысы. Гаделлекне кешеләр күрмиләр, шулай тиеш, дип уйлыйлар. Гаделсезлек күренә, һәрчак күзгә төртелеп тора. Байкинны тормыш юлына чыгарган Платон Никитич та хаксызлыкка бик каты каршы килә торган борынгы тәрбия алган зат иде. Андрей Казан белән бергә үскәннәр. Нишләп алар икесе дә намуслы зат булганнар, ә бүтән иптәшләре мөхиткә яраклашуга авышкан? Намусларын таптаганнар. Димәк, намус аларда көчле хис булмаган. Платон Никитич әйтә иде: һәр кискен хәлдә дә намус шансы бар, дип тәкърарлый иде. Ни өчен берәү үз иптәшен сата һәм тыныч йоклый, яши ала, ә икенче берәү исә үзе белән

янәшәдәге хезмәттәше өстенә яла ягуны гаять зур түбәнлек саный, мәҗбүр итсәләр дә, бу эштән баш тарта? Кешеләрнең психологияләре төрлечә булуданмы, әллә тәрбияләнме? Берәүне әйтик, иптәше өстеннән белешмә бирергә кысалар, ул шул кысуга чыдый алмый. Бирәдә ул гаепләме? Халыкара Нюрнберг процессында әйтелде: үтерергә боерык бирүче һәм шул боерыкны башкаручы да гаепле, диелде. Бездә бары боерыкны үтәүчене генә гаеплиләр. Иң элек иптәше өстеннән донос язарга мәҗбүр иткән затны гаепләргә кирәк. Әйтерләр, приказ бирүче ил мәнфәгатен кайгыртып шулай эшли, аның гаебе юк, диярләр. Ләкин Ватан исеменнән кешене җинаять эшкә этәрү — үзе җинаять. Бу бернинди киртәгә дә сыймый. Аңлыйм, Ватан мәнфәгате бар нәрсәдән өстен булырга тиештер, мөгаен. Әмма кешенең кешелек дәрәҗәсен бетерү, изү хисабына сакланырга тиешме ул мәнфәгать? Моның бер дә бүтән әмәле юк микәнни? Әллә бу адәмнәрнең мин-минлекләрен сындыру өчен дә эшләнә микән? Бәлки, бу әле адәмнең үзе өчен дә файдалыдыр?

Юк, шайтан алгыры, баш үз ихтыярыннан тыш уйлый-уйлый әллә нинди урман-чытырманнарга кереп китә һәм әйләнеп чыга да алмый... Иң яхшысы уйламаска, уйламаска...

* * *

Бер-ике көннән соң Байкин нефтьчеләр коммутаторы аша Тугаевка чылтыратты. Үзләштерәсе мәйданнарны карап, рельефын күзәтеп кайтырга иде. Скважина урыннарын билгеләү мөһим. Кайсы скважинадан нинди токым өлгеләре алуны тәгаенләү сорала... Һәм тагы бүтән хәлләр... Тугаев Байкинның ниятенә кушылды. Аның да үзләштерәсе җирләрне күрәсе килә. Ләкин бүтәнноктадан карап. Кайсы вышканы кайсы урынга күчерү җайлырак һәм экономиялерәк булыр? Электр линиясе еракмы — болар бик әһәмиятле. Кайсы вышканы сүтмичә генә өстерәтеп күчерергә мөмкин? Бу нәрсәләрне урынга барып, күреп кенә уңай хәл итеп була... Кыскасы, алар фәлән числода барырга сүз куештылар.

Сөйләшенгән вакытта Байкин машинасы белән 1-поселоктагы Тугаев конторы алдына килеп туктады. Вахталар китеп беткән, гараж ишегалдында бер машина да күзгә чалынмады. Байкин конторга керде. Тугаев юк иде. Запчастьлар юлларга Кләүле станциясенә киткән, диделәр. Без сөйләшкән идек, диде Байкин аңа белешмә бирүче бухгалтерга. Миңа беркем берни әйтмәде, дип, сүзне беткәнгә санап, үз кәгазьләре өстенә кадалды ул. Байкин коридорга чыкты, ишектән Тартакиев кереп килә иде.

— Ул синең машинамы? Тугаев синең белән барырга кушты, — диде ул гөрелдек тавышын күтәрә төшеп. Байкин аптырады да калды. Аның бу бәндә белән бер дә очрашасы, эш эшлисе килми иде. Көньяк Уралда сугыш тәмамланган өзек елларда бергә чиләнергә туры килде. Бер-берсен алар шунда бик нык белделәр. Һәм бер-берсенә бик каты дошман булып беттеләр. Байкинның эчендә Тартакиевка карата бетмәс нәфрәт хисе урнашып калды. Ул заманда Тартакиев чапмаган-юнылмаган тупас холыклы, мин генә дип йөрүче, бүтәннәрне чүпкә дә санамаучы бик гаярь зат иде. Аның өстә кодрәтле терәге бар, шуңа масая, берничдән дә курыкмый, диләр иде... Тартакиев ул чагында яшь, көчле иде. Хәзер бераз үзгәргәндер, билгеле. Тыштан кеше үзгәрсә дә, эче аның, гадәттә, шул килеш кала. Менә юллар тагы очраштырды. Моннан беркадәр вакыт элек буровойда күрешкәч, үзен көчләп кенә бер-ике сүз алышкан иде. Тартакиев исә алар арасында берни дә булмаган, барысын онытккан төсле иде. Аңа шулай булу файдалы, күрәсең. Андыйлар хәзер коерыкларын кыстылар. Чөнки заман әз генә яхшы якка үзгәрә башлады.

— Син мине яратмыйсың инде, шулай да чыдарга туры килер, — диде ул кул биреп, шаярткан һәм барын да уенга борган кыяфәттә. — Бик туры булырга тырыша идең... — Ул әйтеп бетермәсә дә, фикере аңлашыла: әллә кем була алмагансың әле, янәсе.

— Туры барсаң, баш бәреләә, дигәнне син яхшы үзләштергән идең бит? — Байкин да сүзен әйтеп бетермәде, әмма фикере аңлашылды: син дә югары үрли алмагансың...

— Хе-хе-хе,— дип көлде Тартакиев, сүзнең мәгънәсенә төшенеп. Алар, берберсенә шырпы кадаша-кадаша, машина янына бардылар. Тартакиев папирос кабызды. Байкин шофер янына урнашты. Тартакиев папиросын суыра-суыра, ниндидер фикер туплаган шикелле, Байкин белән ничек сөйләшергә дип, уйларын хәтере аша уздыра кебек иде. Ул кереп утыргач, кузгалдылар. Юл уңаеннан колхоз җирләрен нефтьчеләр өчен контрактовать итүче инспекторны алып чыктылар. Ул Фрунзе урамында яши икән. Утыз яшьләрдә булыр, какча гәүдәле, озын буйлы, вак җыерчык челтәре япкан шешенке чырайлы. Сизелеп тора, махмыр, иреннәр чатнаган, башы авырта булыр. Ул кәрә-керешкә өзмәс тарта иде. Бер сүз дә сөйләшми. Әллә Тартакиев аның белән дә бозылышкан, әллә нәрсә. Тартакиевның холык-фигыле бик тотрыксыз иде, хәзер дә шулайрак, ахрысы. Ул кемнең кем булуына, кайда нишләвенә карап тормый, юкка гына ачуы чыга да тузынып китә, аты-юлы белән акырып ташлый. Тартакиев нигәдер аңа бер сүз дә кушмый, аңардан йөзен читкә ала. Алар бит күптәннән бергә эшлиләр булыр? Тартакиев шулай ук Байкин белән дә сөйләшми.

Акташтан чыгып, Бөгелмә юлы белән бардылар. Чаттан борылып, Әлмәт юлына төштеләр. Бераздан кечкенә генә салам түбәле, читән абзарлы Иркен дигән авыл кырыеннан уздылар. Юл әйбәт, машина элдертә генә. Менә сул якта бик зур мәйданга җәелгән газ-бензин заводы. Ләкин бер тамчы бензины да безгә түгел, каядыр туганлаш дип аталган республикаларга озатыла. Бушка диярлек бирәләр икән. Безнең яклы булган өчен генә... Тыштан безнең яклыдыр, ә эчтән...

Әлмәт юлы белән Мактамага җиткәч, машина кырт кына көнчыгыш якка таба борылды. Бу — Әлмәт — Азнакай юлы иде. Юл тәбәнәк таулар итәгеннән уза. Юлның ике ягы да яшел диңгез — бодай кыры чайкалып-дулкынланып тора. Ә шул яшел-кучкыл дулкыннар уртасында анда-санда вышкалар, ак самавыр шикелле биек калпаклар күзгә чагылып үтә. Әле бер скважинада да «качалка»лар юк. Нефть үз басымы белән астан өскә фонтанлап чыгып ята. Бу мәйданнар бик юмарт — бай булып чыкты: тәүлегенә өч йөз тонна бирүче скважиналар бар.

Баручылар тәрәзәләргә төбәлгән: бу матурлыкны күреп, телдән калганнар шикелле иде. Тартакиев исә Байкинга сүз кушып карады, ләкин теге аны өнәмәүдәнме сүзне озайтасы килмәде. Җавап урынына кулын селтәп кенә куйды да бетерде. Инспекторның сөйләшер рәте юклыгы махмырлы чыраеннан, шешенке күз кабакларыннан күренеп тора. Ул арада, машина зур асфальттан борылып, авыл юлына төште. Күп тә үтми, тирән чокырлар, үзәннәр эченә килеп керде. Бу — Ирәч авылы иде. Йортлар, каралтылар чокыр-чакырлар буена салынган. Төзек-туры бер урам да юк иде. Төз кырлар иген игәр өчен калдырылган икән. Борынгы крестьян бер дә уйсыз булмаган. Чокыр-чакырлар эченнән кечкенә инеш агып ята. Аның аша агач күпер. Шул төштә инеш әз генә тугайланып тора иде. Су буенда каз бәпкәләре, ләкин барысы да кара майга буялып каралып беткәннәр. Яр читендә томшыклары белән канат-койрыкларын казыйлар. Бичаралар, нефтьтән чистарынмакчы булалар. Ләкин кая ул! Кара майны әллә нинди сабыннар да алмый. Мескен бәпкәләр, казыну-чистарынуга көчләрен бетереп, үсми калалар, ахырда шулай үләләр икән... Ә нефть белән сак эш итү юк. Кыш көне торбалар ярылып, нефть чокыр-чакырларга тула. Аны бульдозерлар тизрәк кар белән күмдереп яшерәләр. Әмма яз көне карлар эрегәч, бар гөнаһлар өскә чыга. Нефть, ташу сулары белән агып, тугайларны, болыннарны пычратып ташлый. Оҗмахтай җирләр берничә елга гамәлдән чыга.

Күперне үтеп, тәбәнәк кенә үр менгәч, ике яклап йортлар тезелгән урамнан бара башладылар. Ул арада машина ике якка ачылмалы ишек янына килеп туктады. Бу — авыл кибете иде. Шоферның машинаны күләгәгә куюы икән, чөнки кояш шактый гына кыздырырга тотынган иде. Инспектор, зур портфелен тотып машинадан төште дә, каршы яктагы кечкенә болдырлы йортка таба атлады. Тартакиев борчылды: рәис өйдә булса гына ярар иде, диде инспекторның авыр атлавына карап. Байкин аңлады: җирләре контрактовать ителәчәк колхозның идарәсе шушы икән. Тартакиев тә, машинадан төшеп, күләгәдә папирос көйрәтеп җибәрде. Байкинның сөйләшмәве аның эчен кыра кебек иде.

*Дәвамы бар.*



Рәшит
Әхмәтҗан

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

* * *

Малай чакта язган шигырьләрем,
Кайсыгызны кайда ертып аттым,
Күбегезне сезнең утка яктым,—
Яшьле күзем белән утка бактым,
Чәчләремнән көлегезне кактым.

Чормаларда чорнап калдырганга,
Яндырганга — берүк кичерегез! —
Чит җирләргә чөйде туган нигез,
Чүлгә әйләнгәндә үз җиребез,
Ак күбеге итте мине диңгез.

Каргышыгыз төште: суда актым,
Үз-үземне кыяларга аттым,
Балык сыман яр башында яттым,
Кат-кат тагын упкыннарга баттым,
Йөри-йөри чуерташтай каттым.

Ишеттем дә илнең илергәнен,—
Кемнәр елый анда, йә кемнәрем,
Кемдер вата читлек тимерләрен,
Тимерләрне нәфрәт кимергәнен...—
Сизмәдем дә шулар җан өргәнен.

Һәм атылып кайттым үз өемә.
Эзләп таптым исән калганнарын:
Болар — чормалардан алганнарым,
Ут яңадан бирде янганнарын,
Җир мәңгегә упкан ялганнарын...

Малай белән бабай очрашты.
Уян, күңел, сорау булып уян,
Ә рухымны өндәү итеп куям.
Эзләп йөрмә инде әллә каян —
Йөрәгемнән ике нокта уям:

Үлем белән яшәү арасы бар,
Барасы бар әле, барасы бар,
Янасы бар әле, янасы бар,
Шигырьләрнең меңләп яңасы бар,
Берсе белән гүрне ябасы бар.
Тик соңрак. Мин күрәшәм яклап,
Теге чакта миңа җан өргәнне:
Ватам читлек булган тимерләрне;
Җырлыйм — нәфрәт тимер кимергәнне,
Яза йөрәк... илем илергәнне.

*1994.*

* * *

Кемнәр кая китеп бара, кем кала?
Бәхет кемдә, кайгыларны кем ала?..

Менә шундый күзгә моңсу көннәрдә,
Фәкыйрегез яши башлый гөлләрдә.

Сагыш уты сулыйм — гөлләр яшиләр,
Күзләрендә яшь... зарланып дәшмиләр.

Җилфер-җилфер килә-килә җил көлә,
Алда нинди көннәр көтә — кем белә?

Капшый җанны, барлый канны — ни кирәк?
Кит әле, җил, мин гөл түгел, мин — йөрәк!

Алдан сайлап чәчәкләрнең акларын,
Берәм-берәм өзгәли яфракларын.

Күчә зәңгәр чәчәкләргә аннары,
Чират көтеп тирбәлә калганнары...

Уңнан килә, сулдан килә... өзгәли,—
Китәр вакыт җитте инде сезгә, ди.

Беләм: җилләр барын өзеп алачак,
Дүрт-биш яфрак кына исән калачак.

Менә шулай, күзләр килгән көннәрдә,
Өзгәләнеп яши башлыйм гөлләрдә.

*1994.*

* * *

Яшеннәр яңгырашыннан
Ниләрдер көтәм һаман.
Һавалар әйбәт кенә дә,
Бозылды менә заман.

Һавалар әйбәт кенә дә,
Хәтерләр калган никтер.
Узган гомерне тагын бер
Күз алларыңа китер.

Күземнән төсләр югалган —
Калган ак белән кара.
Берсе яшәргә, ә берсе
Каядыр алып бара.

Карасы күгемне каплап,
Кичкырын килә миңа,—
Төн буе имтихан ясый
Җандагы иманыма.

Мөмкин мине яшәтергә,
Мөмкиндер үтерергә.
Курыкмыйм. Мин бит әлегә
Иманым белән бергә.

Тагын таң ата. Бер Аллам,
Аермый мине актан.
Яңгырлар көтәм, кап-кара
Болытлар килгән яктан.

Яшеннәр яңгырашыннан
Сискәнеп куя йөрәк.
Сискәнә... этләр талыйлар —
Исән калырга кирәк.

*1994.*

* * *

Җаныңның гомерлек догасын
Бүген дә кабатлап торасың:

Дөньяда дөреслек калганмы? —
Кайчан соң җиңәрбез ялганны?!

Бутады нәселне, хәтерне —
Кайчан соң җиңәрбез мәкерне?

Өем таш — кермәс дип сөенмә,
Сугар да үтерер өеңдә.

Мәкернең бәйрәме башланыр,
Балаңа, халкыңа ташланыр.

Тор, егет, каршы сук шуларга —
Җиңмәсәң, ник җиргә туарга!

Син күреп торасың: алдашып,
Иманын ыштанга алмашып,

Денсезләр саталар бу илне,
Корабы белән үк Иделне...

Гарьлектән башны хет суга сал —
Сатыша саташкан аксакал.

Үзебез тудырган балалар —
Акыртып җаныңны алалар.

Ә инде ятларны әйтмә дә,—
Без — балык. Тоталар ятьмәдә.

Хурлыкны күтәрми бу халык!
Җир белән, күк белән кузгалып,

Уянып ут белән, су белән,
Мәкергә сугарга өлгерәм!

Кабатлап җанымның догасын,
Яндырам! — илемдә тормасын...

Без — илнең алдагы гомере,
Баскан җир — мәкернең кабере.

Догамның дәвамын күрерсез:
Бу халык барыбер үлемсез,
Бу халык — үлемсез!

*1994.*

* * *

Күңелем — күл. Күлдә йөзә алтын балык.
Ни телисең, дәрвиш бабай, шуны сора.
Тик зинһар әйт: җирдә дә юк, күктә дә юк —
Минем сөйгән асылъярым кайда тора?

Уйларым — җил. Аны эзлим. Дәрвиш бабай,
Унҗиденче җәем, менә, җилдәй уза.
Думбраңа чиртә-чиртә җыр белән әйт:
Сөйгән ярым кавышуны нигә суза?

Күзем — көзге. Көзгеләрдән бер караса —
Җил үтәрлек булмас иде безнең ара.
Кайнар дала җиле белән килә дә ул,
Төшләремә керә дә бер, китеп бара.

Болай булгач, безнең күлләр кибәр инде,
Дәрвиш бабай, юл өйрәтеп җибәр инде!

*1994.*

* * *

Бозлар гына китсен әле, бозлар гына,
Бу дөньяда ни булганын күрерсең.
Белмисеңдер: гөлләр көнгә багу белән,
Сагынышта башлый икән бер-берсен.

Мин гөл түгел, син генә гөл, син генә бел:
Җаным күккә менде бүген тургайда.
Кагына ул, талпына ул, сагына ул:
«Син кайда соң, сөйгән ярым, син кайда?»

Кояш баеп, җырчы тургай җиргә төшсә,
Җаным төнлә тулган айга әйләнер...
«Бозлар гына китсен әле» дию ләрем —
Күз яшенне сөртә торган хәйләмдер.

Язлар тизрәк килсен диеп бу якка,
Бозлар булып агып киттем еракка.

*1994.*

## Уяныр идем әле

Син инде моны үзең дә
Күптәннән беләсеңдер,—
Бергә яшәүләр булмаса,
Бүген үләргә әзер.

Син ерактамы? Бу — соңгы
Сулышта соңгы тавыш.
(Сиңа да соңгы мәртәбә
Ялваруларым, язмыш!)

Айсыз калган аккаен күк,
Күмелдең кара төнгә.
Кайтсаң — бөтен кайгыларым
Күз йомар иде синдә.

Йоклатыр идем. Ә үзем:
Ничек дип моның хәле?—
Тагын бер генә күрим дип,
Уяныр идем әле.

*1992.*

## Әби

Язлар килде. Гөл орлыгы эзлим.
Ярты базар сата — ал гына.
Чәч тә үстер: җитмеш җиде төрен
Әби тезеп куйган алдына.

Бөртекләрен капшый керфекләрем,
Ә карашым барлый, аралый.
Чәчәкләре җанга якыная,—
Юк, боларны алмый ярамый.

Телсез икән әби. Ымлап сата,
Ымлап кына мактый үз малын.
Күреп алды,
анын шул хәленнән
Бер малайның көлеп узганын.

Туктатты да гөл орлыгы бирде:
— Бар, юлыңда бул,— дип ымлады.
Телсез калды малай. Йомарланды.
Гүя кара кайгы йомгагы.

Йомгак сыман тәгәрәде малай,
Бу дөньяның кайсы ягына?—
Үзе... чәчәкләрдән кайлардадыр
Аерылып калган җан гына.

Теләкләрен теләп калды әби:
«Гөлләр сыман, балам, өшемә.
Гөл орлыгы тиде өлешеңә—
Гөлләр керсен бүген төшеңә.

Гөлләреңә кунган сандугачлар,
Иртән сине сайрап уятсын.
Гомереңә язлар килгән саен,
Гөлгә яшер кошлар оясын.

Сөйләр телең—гөлләр теле булсын,
Гөлләр илендә кал—мин үлгәч.
Минем ничек телсез калганымны
Гөлләр сөйләп бирер, гөлләр чәч...

Соңгы балам, соңгы сулышында
«Әнкә-ә-әй!» диеп әйткән мизгелдән,
Җырдан гына торган моңлы телем,
Гомерлеккә инде өзелгән.

Сезнең белән түгел, мин бит бары
Кара язмыш белән сөйләшмим.
Язлар килә, язлар... Бу көннәрдә
Бөтен дөнья белән сердәш мин.

Балам, балам,
дөнья буйлап йөри
Гөлләр башын кисәр хәбәрләр,—
Ул-бу булса, гөлләр башы белән
Синең башың бергә тәгәрәр.

Өйнең-илнең изге туфрагына
Гөл орлыгын инде салдыңмы?—
Якла, балаларын югалтудан
Телсез кала язган халкыңны...»

Гөрли базар. Берәү генә тыныч.
Ымлый гына бары, сөйләми.
Дөньядагы телле телсезләргә —
Тылмач була ала бу әби.

*1992.*

* * *

Дәшәрмен теге дөньядан:
«Без һаман дамы бергә? —
Бергәме?! Үлмә, бәгърем,
Мин кердем синең гүргә».

*1994.*

* * *

Денен сатты. Йөзендәге карасын —
Инде хәзер, әйдә, юып карасын!

Күпме юса да карасын, юк, бетмәс,
Юар өчен Иделнең суы җитмәс.

*1994.*

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

**Бу шигырьләрнең журналда басылып чыгуын, кызганычка каршы, шагыйрь үзе күреп өлгермәде. Талантлы каләмдәшебез, редакция буенча хезмәттәшебез РӘШИТ ХӘНИФ улы ӘХМӘТҖАНОВ гыйнварның бишесендә кинәттән вафат булды. Ул әле илле дүртенче яше белән генә бара иде. Шигърияттә күптән үз урынын тапкан, фәлсәфи-халыкчан лириканың кабатланмас җәүһәрләрен тудырган шагыйрьнең соңгы шигырьләре дә безнең йөрәкләргә һәм мәңгелеккә матурлык үрнәге буларак юл алалар. Әйе, мәңгелеккә — бу турыда хәзер инде бөтен татар гавамына кычкырып әйтеп була. Хуш, дустыбыз; саумы, олуг шагыйрь! — дибез.**

# ЭДУАРД МОСТАФИНГА 50 ЯШЬ



Эдуард Мостафин шигырьгә алтмышынчы еллар азагында килде. Зөлфәт, М. Әгъләм, Х. Әюп, Л. Шагыйрьҗан кебек шагыйрьләр белән бергә, аның шигырьләре дә Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан кебек аксакалларыбыз һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан хупланып, җылы каршыланды. Алар башта «Беренче карлыгачлар» исемле күмәк китапта басылды; аннары шагыйрьнең мөстәкыйль китаплары да («Елның бишенче фасылы», «Туасы көн», «Ут. Кәгазь. Каләм» һ. б.) дөнья күрде. Алар һәммәсе дә Э. Мостафинны үзенчәлекле, лирик-фәлсәфи пландагы кызыклы фикерле шагыйрь итеп танытты: әдәби тәнкыйтьтә дә бу шулай билгеләп үтелде.

Соңгы елларда шагыйрь берничә поэма да язды («Чулман төбәге», «Батырша», «Мин бәләкәй чакларда» һ. б.), иҗади активлыгын да арттыра төште — быел юбилеена аның күләмле сайланма китабы дөнья күрәчәк.

Илле яше белән котлап, бу санда укучыларыбызга талантлы шагыйрьнең бер бәйләм шигырьләрен тәкъдим итәбез.

## Эдуард Мостафин

### ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

* * *

Һәрбер гөләп, һәрбер былбыл саен
Берәр җырчы, берәр шагыйрь бар.
Һәрбер шигырь, һәрбер җыр юлына
Күбәләкләп ява ап-ак кар...

Ә моңнарың — саклап калалдымы
Берәр былбыл, берәр гөләпне?
Бер ярату гына җитә микән
Гел матурны, яки гел акны?

### Гомер кайдан башлана?

Дулкын гомере — җилләрдә,
Җилләр йөри илләрдә.

Таш гомере — тауларда,
Батыр гомере — яуларда.

Ут гомере — учакта,
Үч гомере — пычакта.

Ат гомере — чабышта,
Чишмә гомере — агышта.

Көч гомере — беләктә,
Бәхет гомере — йөрәктә.

Сагыш гомере — буйдакта,
Караның гомере — акта.

Сүз гомере — калыпта,
Шагыйрь гомере — халыкта.

* * *

Ак каеннар сөттәй ак булмаса,
Матур кызлар көлеп тормаса,
Канатында язлар алып килеп,
Пар-пар кошлар оя кормаса,
Тол хатыннар ялгыз юксынмаса,
Чәчкә бер чак кырау кунмаса,
Көз көннәре яфрак саргаймаса,
Салкын сугып гөлләр сулмаса,
Кайдан алыр идек бу моңнарны?!
...Аулак җирдә ярлар тын булалар,—
Ә тын ярны бик тиз ком баса.

## Иң беренче дулкын

Салкыннары белән томалый да,
Бикләп тота кышкы тоткынлык.
Нинди көчләр үзенә туплаган соң
Боз астында булган бу тынлык?..
Асты өскә килеп җимерелер
Дулкыннарны изгән боз-төрмә.
Дулкыннардан, безне сискәндереп,
Калыр давыл, калыр өермә.
Язны көтеп кенә сабыр алар —
Көч туплыйлар озын кыш буе...
Уяныплар бөтен дөнья буйлап,
Уздырырлар азатлык туе.
Алар бар да тигез, бар да бер зат —
Туган алар бар да җилләрдә.
Бер үк телдә — давыл белгән телдә
Сөйләшәләр төрле илләрдә.
Әй, бу ирек, әй, бу көрәш тәме!
Нинди тойгы аннан татлырак?!
Яз тудырган иң беренче дулкын,

Безнең телдә җырла диңгезләрдә:
Чал дулкыннар калсын аптырап.

## Көймә

Көтә көймә үз хуҗасын ярда,
Көнләшәдер аккан саллардан.
Тыныч кына тирбәлә ул шунда,
Как күкрәгән төреп талларга.
...Ташланасы килә давылларга
Акчарлаклар очкан тизлектә.
Шул кошлардай, их, очасы иде!
Канатларны җәеп киңлектә...
Көтә көймә, бәйдәге эт сыман,
Көннәр буе көтә хуҗасын.
Ярны ташлап давылларга чумса,
Онытылыр иде нужасы...
Көч алгандай шунда ярсып куя,
Ишкәкләрен җәя канаттай —
Дулкыннарда дулап йөрер иде,
Үрләр аша атылган аттай.
...Давыл тынды кагып дулкыннарын,
Көймә һаман бәйдә, комлыкта.
Тавыш-тынсыз гына давыл көтә,
Ирек көтә үле тынлыкта.

* * *

Олы җанга — зур кайгылар,
Зур көймәгә — зур сулар.
Кораб кадәр күңелләргә
Диңгез хәтле борчулар.
Ничә баллы борчу була
Күңелләр сынган чакта?
Кораблар да моңаялар
Диңгезләр тынган чакта.

Вак җаннарга — вак нужалар,
Кемдә нинди музалар?

* * *

Еллар белән санаганда
Гомер бик кыска.
Әгәр сәгатьләргә салсаң,—
Ул озын кыйсса.
Кылган яхшылыклар белән
Үлчәсәң аны,—
Сыеп бетмәсме гомергә
Күбәләк җаны.

## Ник аңламый?

Гомер буе кеше ачыш ясый,
Гомер буе эзли, чокына...
Үзе һаман биш намазын укый,
Йә почмакка барып чукына.
Табигатьнең кануннарын яза,
Яңа йолдыз таба күкләрдә...
Кеше өлешенә тигән эшне
Тавык өлгералмас чүпләргә.
Күпне белә кеше, күпне күрә,
Тик аңламый үзен күп чакта.
Утны-суны кичкән гайрәтле зат
Башын жуя ят бер кочакта.
Ә бер заман айнып уяна да
Хыялына чума яңадан.
Үзе ачкан йолдыз — урынында.
Ә шулай да дөнья яңарган.

## Чапмаса да иярләнгән атлар

Дулый-дулый чапты атлар,
Ук сызгырды, сөңге сынды;
Ут ялмады бар тарафны —
Утта калып бар да тынды.

Кара шәлен япты ана...
Ире ятып калды кайда? —
Кулларында елый бала.

Атлар тагын иярләнде,
Ир кулында кылыч сыза;
Туплар актарган жирләрдә
Ут белән кан бергә кыза.

Кара шәлләр ятты ингә...
Ир кайда да, улы кайда? —
Йорт урыны гына илдә.

Кими төшкән атлар саны...
Жирдә, күктә корыч яна;
Күпмесе юк — булганнарның? —
Күктән йолдызларны сана.

Илләр киде кара кием...
Ата, ана, бала кайда?
Ил байлыгы — кара төен.

Атлар ялда йә чабышта... —
Ник тоям соң үлем күзен?
Жир шарында аек Акыл
Әйтер микән соңгы сүзен?

Көн дә кара шәлен яба
Кайсыдыр бер илдә Ана —
Акылыңа кил син, бала!
Кара кием кия Ана.

## Сүгеләләр ирләр

Җыелыштамы, кибет янындамы,
Гаиләдә, мәҗлес-табындамы
Сүгеләләр ирләр,
чәйнәләләр ирләр...—
Кабан күлдә чайкалгандай
пычрак керләр.
Сүгеләләр ирләр ирләр тарафыннан...
Хатын сүгә, түзеп кара шуннан;
Күңел сүнә сүзләр ярасыннан,
Хет төшеп кал тормыш арбасыннан.
Ни файда соң тагын алласыннан!
Ирлегегез бетте мәллә, ирләр?
Сезсез дә яшиме инде илләр?
Кемнәр хәзер эштә бөгә билләр,
Кырлар буйлап иссә зәһәр җилләр?..
Белми генә халык әйтеп йөрми:
«Ир белән ат башы ниләр күрми».
Илләр буйлап, әнә, ялкын үрли,
Кем төрткәнен әллә ирләр күрми!
Этләре дә белми генә өрми.
Сүгеләләр, чәйнәләләр ирләр...
Кырлар буйлап иссә усал җилләр,
Ут эчендә калса-нитсә илләр,
Ирне күтеп бөтен иле чирләр.
Ир җилкәсенә таяныр ирләр.

## Иртәнге урам

Кеше
Уяна да тәрәзәгә карый:
Нинди хәлләр икән урамда?
Гәзитләрдән укып белә инде
Ни бар Европада, Уралда.

Кеше
Уяна да тәрәзәгә карый:
Халык бүген ничек киенгән?
Күз күрә шул, ят ир чыгып килә
Күрше тол хатынның өеннән.

Кеше,
Уяна да тәрәзәгә карый:
Чират бармы икән кибеткә?
Катафалка кемне алып китә
Чык өлгермәс борын кибеп тә.

Кеше
Уяна да тәрәзәгә карый:
Нәрсә күреп халык җыелган?
Урам уртасында көчек ята,
Ә урамда яту тыелган.

Кеше
Уяна да тәрәзәгә карый:
Шау-гөр килеп узды балалар.
Чистарынып калган кебек күңел —
Ярый әле җирдә алар бар.

Кеше
Уяна да тәрәзәгә карый:
Күпме язмыш тик бер урамда!
Күпме урам, күпме тәрәзә бар
Европада яки Уралда...

## Турыдан-туры сөйләшү

Дулкын булып җыр сузармын диңгездә,
Йә таш булып моңаермын тауларда,
Урманнарга кереп шунда калырмын,
Давылларда агач булып шауларга.
Мин чайкалган диңгез кибеп корыгач,
Мин сыенган тау ишелгәч, тетрәп,
Чайрап янгач мин шаулаган урманнар —
Кабат кайтып җитәрмен мин күкрәп.
Диңгез булып җәелермен дулкыннан,
Күтәрелеп чыгармын бер тау булып,
Көлдән калкып урман булып үсәрмен
Һәм кайтырмын давыл булып, шау булып.
Диңгез булып алдансам да түзәрмен,
Таулар булып алдансам да күнәрмен,
Урман булып алдансам да бирешмәм,
Шагыйрь булып та алдансам... үләрмен.

**Радик**

**Фәизов**



# ТЕЛСЕЗ

хикәя

Мин барысын да әйбәт хәтерлим.

Сугыш вакыты бу. Җәйге чиллә — болын, печән өсте. Картлар, карчыклар, хатын-кызлар, без — үсмерләр, бала-чага — барысы да болында. Атлар, этләр, хәтта мәчеләр дә. Бар авыл болында! Инде килеп сыер-сарыклар да якында: әнә, Ашыт суының теге ягында гына утлап йөриләр.

Көн иртәдән үк — чын могҗиза. Зәңгәр күк йөзе уңган килен әле генә юып алгандай чип-чиста. Елга буендагы куакларда очына-очына кошлар сайрый, аллы-гөлле бихисап чәчәкләргә күбәләкләр килеп куна. Их, шушы иркен сәхрада, шушы рәхәтлектә сәйран кылып кына йөрисе иде дә бит. Фани дөньяның матурлыгына, гүзәллегенә сокланып кына. Тик кая ул! Аклы яулыклар, ямаулы күлмәкләр белән чуп-чуар болында, кирәкне биреп кыздырган кояшның кайнар нурлары астында, иртәдән кызу эш. Картлар, анда-санда гына күренгән, әле сугыштан алып кайткан ярасы төзәлеп тә житмәгән ирләр, хатыннар, үсмерләр — көченнән килгән һәркем чалгы селти. Чажыт-чожыт, чажыт-чожыт... Боларга моңлы булып чалгы янаган тавышлар кушыла. Әмма болары аның безнең өчен әллә ни матур музыка түгел. Болындагы халык өчен әмма дә матур, ягымлы музыка исә кояш Әтнә өстенә менеп, төш вакыты житкәч ишетелә башлый. Бу вакытта пешекче Нәгыймә апай үзенең төбе камыр белән ямаулы бик зур, яшел табагын югары күтәрә дә, аның төбен агач кашыгы белән кага башлый. Даң-дон, даң-дон! Ягъни, килегез, килегез! Менә бу инде, ичмасам, безнең кәефләрне күтәреп, талган йөрәкләргә ял биреп җибәрә торган музыка. Ул ишетелүгә, һәркем чалгысының йөзен печән астына яшерә дә җәтрәк Ашыт суы буена ашыга. Барысы да бирегә ашыга! Елга аръягындагы көтүчеләр, басуларда пар жирен сөрүчеләр, тирес чыгаручылар да, хәтта болында үлән арасында үз эшләре белән йөргән этләр-мәчеләр дә.

Ә монда инде, елга ярына уеп ясалган учаклар өстендәге ике зур казанда, аш пешеп өлгергән. Бу эшнең зур остасы Нәгыймә апай үзе пешергән. Һушыңны алырлык тәмле исләр таратып торган, инде иртәдән

бирле зарыгып котелгән аш. Коненә бер генә тапкыр, анысы да әле менә шушы печән өстендә генә эләгә торган, ап-ак токмачлы аш! Ул гынамы әле, ул гынамы?! Казаннар янәшәсенә чирәмгә җәелгән шакмаклы ашъяулыкларда ит калҗалары ята бит. Анысы да аның крәстиянгә җәй көне, шул печән өстендә генә эләгә. Һәркемгә тутырып бер тәлинкә аш, бер кисәк ит тия. Һәркем бу тәлинкәне кадерләп кенә тотып, үзе утырган урынга алып килә. Бисмилласын әйтеп, ашыкмыйча, тәмен татып кына ашый. Эт-мәчеләр исә бер читтә сабыр гына сөяк-санак көтә. Авыл ач булганда анда яшәүче кешеләр генә түгел, барча җәнлекләр дә ачыга бит. Хәтта идән асты сычканнары да.

Әле кешеләр ашап та бетерми, кулына солдат котелогы тотып казан янына көтүче Кәрим абый килеп баса. Кәрим абый — сугыштан контужин булып кайткан кеше, шуның зәхмәтеннән авызы белән сагыз чәйнәгәндәй туктаусыз күшәп тора.

— Допапкашы юкмы монын, Нәгыймә җиңги? — ди ул сакауланып.

Бик олы гәүдәле, үзенең хисапсыз киң күлмәгеннән дә киңрәк күнелле Нәгыймә апай Кәрим абыйның тәбәнәк кенә кеше булса да зур тамаклы икәнен, шушы «допапка»ны өмет итеп ашыгып, бүтәннәрдән уздырып ашаганын белә. Мондый зур тамаклылар өчен казан төбендә аның азрак ашы да калган була.

— Сиңа салам инде, Кәримулла җанашым. Шушы эсседә малларны берүзең көтеп йөргән көнең бит. Ничекләр итеп түзәсеңдер... Сиңа салам инде,— ди ул һәм куанычыннан күшәвен дә онытып торган Кәрим абыйның котелогына ярты чүмеч аш салып җибәрә. Кәрим абый артыннан тагын бер кулы чулакланып, йөрми торган булып калган Солтан абый, аннан бик юан, шадра Мәймүнә апай, тагын берничә кеше казан янына килә. Шул өстәмәне сорап, ояла-кызара гына инде...

Ай, заманалар! Адәм балаларын ярты чүмеч аш өчен шундый хәлгә куйган заманалар... Йа, раббым, башкасы булса булсын, тик алар гына кире кайта күрмәсен!

Аштан соң кешеләр үз кишәрлекләренә таралалар. Әмма эш башланмый әле. Эссе кояш астында төшкә кадәр чалгы селтәп җыелган кургаштай авыр арыганлык печәнчеләрне аяктан бәреп ега. Кем чалгысын җиргә кадап җәймә кора, кем печәннән нәни куыш әмәлли — төштән соң һәркем җиргә ава. Хәзер инде монда йокы патшалык итә, барысы да: печәнчеләр, өстенә ябынган шакмаклы җәймәсе астыннан ямаулы оекбашлары күренеп торган Нәгыймә апай, зур казаннар, озын саплы чүмечләр, теге ярдагы сыер-сарыклар изрәп йоклый... Хәтта атлар да, баскан җирдән ара-тирә койрыкларын гына селтәп, йокымсырый. Бөтен болын, бөтен дөнья тирән йокыда.

Чөнки бик тә авыр! Печән калын, кояшның кайнар нурлары-әлсерәткеч, ачлы-туклы килеш көнозын чалгы селтәүләре бик тә авыр. Һәм шушы авыр дөньяда, шушы кыен заманда, уттай эш өстендә кемнеңдер йөрәгендә мәхәббәт уты янадыр дип кем әйтер? Кемдер дөньясын онытып, шашынып сөядер, татлы газаплар дәрьясында йөзәдер дип кем уйлаган?

Минем чаба торган җирем Сәләхи бабайлар белән Фазыл абыйлар кишәрлекләре уртасында. Сәләхи бабай — какча йөзле, ап-ак түгәрәк сакаллы, башына киң кырыйлы салам эшләпә кигән карт — печәнне үзенең килене Сәгыйдә белән бергәләп чаба. Алар авылның бик хәсиятле, хәлле кешеләре, болынга өсте ябулы кечкенә агач чиләк белән салкын катык, тастымалга төреп ипи алып төшәләр. Ул ипине безнең авылда алардан кала тагын кем генә ашый ала торгандыр, мин моны белмим дә... Сәгыйдә әле яшь килен. Аның ире, ягъни Сәләхи бабайның иң кече улы Хәбибулла — озын буйлы, авылдагы егетләрнең солтаны, бик кызу канлы, бер сугыш чукмары егет иде. Яшьли тимерчелектә эшләде, үзе бик булдыклы, оста иде. Алар туй ясап ике-өч ай үттеме икән, Хәбибулланы сугышка алып киттеләр. Аны эчеп-исергәч, артыгын кыланып, Сәгыйдәгә

кем белән булса сөйләшүне дә тыеп, бик янап киткән икән дип сөйләделәр. Ул заманда хәтта сугышка чыгып китүчеләрнең дә бик сирәге генә эчеп-исереп китә, мондый хәлне авыл халкы бер дә өнәми, юньлегә юрамый иде. Ә безнең авылга Шимбер ягыннан килен булып төшкән Сәгыйдә исә бик тә чибәр: зур зәңгәр күзле, һәрвакыт бит урталарын батырып елмаеп кына тора иде. Өстендәге күлмәге дә күзләре төсле зәңгәр, ак альяпкычы да үзенә бик килешә. Без, үсмерләр, эчтән генә барыбыз да аңа гашыйк идек.

Икенче як күршеләр — Фазыл абыйлар исә өчәү. Фазыл абый үзе инде армия чутыннан чыккан, олы гәүдәле, һәрвакыт төксе, җимерелгән кашлары астыннан сиңа текәлеп, куркытып карый торган, кырыс кыяфәтле кеше. Тагын аның олы улы Хәйдәр һәм кечесе Рәшит. Хәйдәр урта буйлы, киң инсәле, чем кара чәчләре дулкынланып торган күркәм, чибәр егет. Әтисеннән үзгә буларак, аның йөзендә һәрвакыт ниндидер серле, йомшак елмаю, күзләреннән җылылык сирпелә сыман. Печән чабуның, чалгы кайрауның да зур остасы Хәйдәр. Табигать үзенә көч-куәтне дә җәлләми биргән. Тик менә бер ягы бар: шушындый егет тумыштан телсез-чукрак. Ул бернәрсә дә ишетми, бер генә сүз дә әйтә белми. Аның белән өйдәгеләре дә, авылдагы барча халык та кулларын бутап, төрлечә ишарәләп кенә сөйләшә. Мондый чакта Хәйдәр балалар төсле беркатлы елмаеп, үзенең нурлы күзләрен сиңа дикъкать белән теки, сине аңларга теләп көчәнүдәндер инде, «ыггы-ыггы» дип ыңгырашып ала. Янәшәсендә кешеләр җырлый башласа, үзенең дә кушыласы килүдән, ахры, шулай ыңгыраша ул. Әлбәттә инде, Хәйдәр авылдагы бер генә кыз белән дә йөри алмый, кичләрен тау астындагы яшьләр уеннарына төшсә дә, анда катнашмый, бер кырыйда гына тора. Хәер, авылда егетләргә нинди зур кытлык булса да, кызлар үзләре дә аңа нинди дә булса ярату чаткысы белән, өмет баглап карамыйлар, бары тик ничектәр кызганып, курку, шикләнү белән генә күз төшерәләр. Инде өйләнер вакытлары бик җитсә дә, Фазыл абый да аңа үзенә тиң килердәй бер кыз табып бирә алмый, дөньялар бераз рәтләнгәнне көтә, күрәсең. Менә шундый хәл. Фазыл абыйның кече малае Рәшит белән без кордашлар, бер класста укыйбыз. Әмма аларның йорты югары очта, шуңа күрә бергә уйнап та үсмәдек.

Ярый монысы. Беркөн мин төштән соң үземнең кишәрлеккә килеп, инде кибә башлаган печәннән өеп күләгә ясадым да, шунда сузылып яттым. Абау, бүген бигрәк тә кыздыра, бигрәкләр дә бөркү. Әлләни арада бар халык кайсы кая посып бетте, йокыга талды. Кем әйткәндәй, колак төбендә мылтык атып та уята алмаслык йокы бу. Инде мин үзем дә бик тәмләп кенә «куера» башлаган идем. Шунда ниндидер бер кыштырдау ишетеп, сискәнеп киттем. Башымны күтәрергә иренеп кенә тирәякны күзәтәм. Шунда... чү, бу ни хәл бу тагын!? Минем җир аша Хәйдәр шуыша. Нәкъ теге кинодагы дошман тылына үтеп кергән солдат төсле: бик тә саклык белән, бер-ике генә талпына да, башын аз гына күтәреп, тирә-юньне күзәтеп тора, аннан тагын шуышып китә. Сәләхи бабайлар ягына! Никадәр арган булсам да минем йокыларым бердән качты. Күзәтәм тегене шыпырт кына. Якынлаша бу Сәләхи бабайлар кишәрлегенә, менә-менә килеп җитәчәк... Ә анда кара-каршы җиргә кадаган ике чалгыга җәймә корып Сәләхи карт белән аның килене Сәгыйдә йоклый. Бабай үзе түрдәрәк, йөзтүбән ятып башы белән печәнгә күмелгән. Ә Сәгыйдә бераз читтәрәк, аякларын җыйный төшеп яны белән ята. Миңа аның түгәрәк алсу йөзе, йомылган күзләренең озын керфекләре, ак алъяпкычын калкытып торган йомры күкрәкләре, тулы, матур балтырлары аермачык күренә... Шунда мине ниндидер шик, хәвеф куырып алды. Тукта әле, нигә дип шуыша бу телсез егет алар ягына? Нәрсә уйлаган, ни кырмак була ул тагын анда? Сәер бит бу... Мин инде башымны күтәреп Хәйдәргә ым какмакчы идем дә, тегенең йөзенә чыккан ниндидер татлы, шагыйрәнә бәхетле елмаюны күреп, тукталып калдым. Сабыр итим әле бераз, күңелендә начар уй йөрткән кеше болай итеп елмаймас.

Менә Хәйдәр Сәгыйдә янына шуышып килде. Тирә-якны бик җентекләп күзәтте дә, шунда чүгәләп утырды. Саклык белән генә, муенын сузып кына Сәгыйдәнең йөзенә карады. Ул карады... ә мин тетрәнеп киттем. Телсез егетнең яшь хатынга текәлгән күзләрендә, кашлары киң булып җәелеп киткән каратут йөзендә шундый тирәнтен ярату, сөю, ихтирам итү хисләре чагыла иде ки, мин моны сүзләр белән сурәтләп бирә алмам. Менә ничек икән эшләр...

Тәмам гашыйк икән бит бу бичара! Һәм кемгә диген...

Шактый вакыт утырды егет үзенең яратканына шулай текәлеп. Аннары кулын сак кына күтәреп Сәгыйдәнең ачык маңгае, калку күкрәкләре, балтырлары, бөтен гәүдәсе өстендә йөртеп алды. Учын якын китереп, әмма һич тә тидермичә генә. Әйтерсең, Сәгыйдә аның өчен кеше кулы орынырга да ярамаган илаһи бер зат иде. Аннан аз гына йөзенә иелә төште, иреннәрен сузып үбү рәвешен ясады, кат-кат ясады. Менә ул башын арткарак ташлый биреп, чигенә төште. Мин тагын тетрәнеп куйдым. Хәзер инде телсез егетнең йөзендә әйтеп бетерә алмаслык сагыш, үкенеч иде... Шул мәлдә Сәләхи карт яткан җиреннән кымшанып, кузгалып куйды. Хәйдәр моны күреп алды, ахры, шунда ук нәкъ оясына кереп поскан йомран кебек җиргә сеңде.

Икенче мәлдә ул үз кишәрлекләренә таба шуыша иде инде. Үзләренең печән өеме янына килеп җиткәч, ул инде җайлап кына, кулларын башы астына салып, күккә төбәлеп ятты, борылып Сәгыйдәләр ягына тагын бер карап алды. Егетнең йөзендә тагын хыялый елмаю иде.

Мин дә төрле уйлар эчендә ятам. Бар икән бит бу дөньяда хәлләр!.. Ни арада өлгергән бу Мәҗнүн, ни арада гашыйк булган? Шушындый хәлгә килеп... Ярар иде бер кызга яисә тол хатынга булса, алары авылда тулып ята. Әле генә килен булып төшкән яшь хатынга, авылның шөһрәтле кешеләре Сәләхиләр килененә!.. Шушында, печән өстендә күргәндер дә, тәкатьсез булгандыр инде. Ни хәл итәсең, ни ярый, ни ярамый икәнен дә бик аерып бетерми бит ул бичара... Ул миннән берничә яшьләр олы булса да, Хәйдәр белән без балачактан ук дуслыкта. Кулларны ишарәләп аның белән оста сөйләшәм, аның «ыгты-ыгты»ларын да күп тыңладым. Һәм мин бу хәлне беркемгә дә сөйләмәскә, сиздермәскә булдым. Авыл халкы сизеп алса, аннан — бетте! Адым саен төрлечә үртәп, әллә нәрсәләр ишарәләп күзен ачырмаячаклар бичара егетнең. Үзе инде буй җиткереп тә акылы һаман балаларныкы булып калган егетне мин чын күңелемнән җәлли идем.

Тик дөнья бер миннән генә тормый икән шул.

Телсез егетнең сөйгәне янына шулай кешеләр йоклаганда, кача-поса гына барганына, куллары белән кагылмыйча гына аны ничек иркәләгәненә, аның йөзенә текәлеп ләззәтле минутлар кичергәненә мин берничә тапкырлар шаһит булдым. Тик миңа тагын башкаларын да күрергә туры килде шул... Беркөн шулай Хәйдәр үзенең уңышлы сәяхәтеннән соң бик бәхетле төстә үзләренең ял иткән урыннарына кайтып кына җиткән иде, капылт тукталып катып калды. Нәкъ теге, куркыныч күреп кинәт сагайган кәлтә елан кебек башын күтәреп. Карасам, Фазыл абый уянган, үзенең күзләрен Хәйдәргә текәгән. Шелтә, ачу белән тулы күзләрен. Ата белән улы бер-берсенә текәлеп тордылар.

— У-у сине, хәерсез нәрсә! — диде Фазыл абый ярсу белән пышылдап һәм бик хәтәр итеп улына бармак янады.

— Ыгты-ыгты... — диде тегесе башын селкеп. Әллә «мин аңа кагылмыйм», әллә «бүтән алай эшләмәм» диде, монысын инде мин аңлый алмадым. Шулай күндәм төстә үзенекен аңлатты да башын куллары белән каплап йөзтүбән ятты. Әле шунда да Фазыл абый аягы белән тупас итеп улының янтыгына тибеп куйды. Менә шулай. Тәңре үзе җәберләгәнне кешеләр дә өнәп бетерми икән. Хәтта туганнары да. Фазыл абый да үзенең бу телсез улын бик яратмый, аңа бер дә юктан кычкырып, җикереп кенә тора, кул да күтәргәли иде.

Тагын икенчесендә Хәйдәр, шул пластуннарча шуышып, хәвеф-хәтәрсез генә Сәләхи бабайлар кишәрлегенә килеп житте. Инде бәхетле елмаеп Сәгыйдә өстенә калкынган да иде. Шулчак егетебезнең иңбашына таяк килеп төшмәсенме! Сәләхи картның үзеннән калдырмый йөртә торган, бер башы кәкре, нечкә генә, әмма бик нык, җилкәңә төшсә яхшы кашырлык чия таягы! Эшне алдан ук сизеп алган да, күзләп, әзерләктә яткан икән, карт тәре!

— Кыяфер!... Алла үзе каргаган нәрсә... Югал күземнән. Безне рисвай итеп. Югал, кыяфер! — дип җикеренде бабай тәмам каушап, ни эшләргә дә белми аптырап калган егеткә. Тик бабай да эшне белә иде, пышылдап кына җикеренде, таягын да артык күтәрмәде. Ул да эшне зурга җибәрүдән, тирә-яктагылар күреп, бу хәлгә шаһит булып торудан бик курка иде. Ул арада Сәгыйдә дә уянды. Янәшәсендә генә чүгәләп утырган Хәйдәрне күреп, куркып калды.

— Абау... әткәй! Бу егет нишләп йөри тагын монда? Телсез егет түгелме соң ул?

— Син бер дә курыкма, килен... Син ят, ял ит әле. Минем янга, тәмәке сорап килгән ул, — дип тынычландырды киленен бабай һәм астыртын гына Хәйдәргә тагын таяк янады.

Торып китте Хәйдәр. Үзләренең кишәрлегенә түгел. Ашыт суы буена китте ул. Башын иеп, иңнәрен салындырып кына яр буендагы камышлар арасына атлады. Мин исә ул-бу булмагае, егет үзенә бер-бер хәл тартмагае дип, куркынып яттым. Сагаеп тыңладым. Юк, су чупылдаганы да, андый-мондый тавышлар да ишетелмәде. Ул арада йоклап та киткәнмен. Мин уянганда инде Фазыл абыйлар эшкә башлаганнар. Хәйдәр чалгы селти иде.

Шуннан инде хәлләр бераз үзгәрде. Сәләхи бабай ничектер җаен тапты да, бу кишәрлекне калдырып, киленен алып, киң болынның аргы башына ук күченеп китте. Хәйдәргә дә «пластун» булып йөрүнең мәгънәсе калмады. Тик инде йөрәккә бер килеп кабынган мәхәббәт ялкыны алай гына сүнәме, сөю хисләре белән тулган күңел һәртөрле тыюлардан ризалашамы? Хәйдәр дә үзенең Сәләхи килене Сәгыйдәгә булган хисләрен берничек тә яшереп саклый алмады. Төшке ашка җыелалар. Менә таягына таянган, бөкерәйгән Сәләхи карт янәшәсендә үзенең зәңгәр күлмәге, ак алъяпкычы белән күбәләккә охшап, матур балтырларын уйнатып Сәгыйдә килә. Яшь, матур, сөйкемле. Бар халык Сәгыйдәгә карап, ирексездән елмаеп куя. Ә инде Хәйдәр... Үзе кайда гына: аш чиратында яисә чирәмдә табын янында булмасын, аның нурланып торган күзләре Сәгыйдәдә генә иде. Ул аны әллә кайдан ук күреп, каршылап ала. Дөньясын оныта, ахры, «ыгты-ыгты»сы да ишетелә. Әлбәттә инде, моны Сәгыйдә үзе дә сизмичә булмый. Яшь киленнең йөзенә алсулык бәреп чыга, ул ояла, егетнең утлы карашыннан яшеренергә теләгәндәй, йөзен читкә борып, астыртын гына кешеләргә, Сәләхи картка да карап ала. Мин бер-ике тапкыр аның кешеләрдән оялып, Хәйдәрне шелтәләп: «Һай, мәхәббәтсез... кара инде син аны...» — дип пышылдаганын да ишеттем. Һәм, иң гаҗәбе, бу пышылдауда үртәлү юк, ә ниндидер җылылык, җәлләү сизелә иде.

Хак тәгаләдән яшермәгәнне кешеләрдән яшереп буламы соң аны? Телсез егет Хәйдәрнең Сәләхиләр килене Сәгыйдәгә күз атып, утлар йотып йөрүен тиз арада бөтен авыл белеп алды. Минем бик нык гаҗәпләнүемә күрә, бер генә кеше дә егеттән көлмәде, аны үртәмәде, битәрләмәде. Бары тик кызгандылар гына.

— И-и җаныем, күр инде син ул бичара җанны. Ул да ярата белә икән.

— Һай, сөйләшергә телләре булса! Ниндәен чибәр, сөйкемле бит ул. Ниндәен кызларны үзенә каратмас иде. Йөрмәс иде инде базары үткәннәргә күз атып.

— Әйбәт бала бит ул үзе. Алла саклар, андый-мондыйга бармас әле. Бер акылына килер әле...

Авыл хатыннары әнә шулай сөйләштеләр.

Тормыш дигәнең бернигә дә карамый, гел алга бара ул. Колхозда да эшләр берсе артыннан икенчесе өлгереп кенә тора. Печән өсте үтүгә, урак ялганып китте. Аннан инде басудан көлтә кертүләр, әвен сугулар... Авыл билен бөгеп, башын күтәрмичә эшләде дә эшләде. Атна саен диярлек кем дә булса газиз улының ялсә иренең үлгән хәбәрен алып, кара кайгыга баткан авыл... Басуында игеннәр өлгерсә дә, үзе ачлы-туклы яшәп яткан авыл... Комсомоллар, яшьләр әле көнозын басуда эшләгәннән соң да кайчакларын кичке өмәгә чыгалар. Төнлә, ай яктысында көлтә кертәләр, амбар алдында ашлык аералар.

Әйе, тормыш бернигә карамый алга барды. Тик хатыннарның юравы гына юш килмәде. Телсез гашыйк Хәйдәр, тәки акылына килә алмады. Кайда гына: басуда, әвендә яисә амбар алдында булмасын, ул гел Сәгыйдәгә елыша, аның янәшәсендә булырга тырыша, ул күтәрәсе авыр капчыкларны үз иңнәренә сала, елмаюлы карашын Сәгыйдәдән алмый иде. Яратканы белән янәшә булудан, бергәләп эшләүдән, аңа ярдәм итүдән ул үзен чиксез бәхетле хис итә иде, күрәсең. Мондый минутларда Хәйдәр тирә-юньдәгеләргә ничектер үзен өстен куеп карый, болай да киң иңсәләрен киерә төшеп, күкрәген алга чыгарып, бик олпат, житди кешеләрчә дәү-дәү атлап йөри. Тирә-юньдәгеләр аңа ымлап, бер-берсенә елмаеп куялар. Ни хәл итмәк кирәк, зур бер бала инде! Бүтәннәр шулай, тик менә Сәгыйдә үзе генә егетнең бу карашларына, ярату тулы гамәлләренә бернинди илтифат итми сыман. Егеткә җавап итеп бер елмаймый да, ичмасам. Аннан гына әлләни булмас иде бит инде!

Тик шулай да... Тик шулай да мин Хәйдәрнең ялкынлы мәхәббәте бер дә җавапсыз да калмагандыр дип фараз итәм. Һәм моңа саллы гына дәлилем дә бар... Ул көнне көндез яңгыр яуды, кичен комсомоллар, барча яшьләр һәм аларга ияреп без үсмерләр дә өмәгә чыктык. Амбарда ашлык чистартырга. Амбар алдындагы өсте ябулы урында егетләр җилгәрү машинасын әйләндерәләр, кызлар ашлык салып тора. Өмәдә, комсомолка буларак, Сәгыйдә дә бар. Ул булган җирдә инде Хәйдәр дә калмый. Инде төн урталары да җитте, барыбыз да бик ардык, һәркемнең аяк-куллары, бөтен гәүдәсе кургашын тутыргандай авырайды. Һәм һәркем кая да булса урнашып, бераз йоклап алу ягын карады. Инде эш тәмам тынды, комсомол оешмасы секретаре, карчыга күзле Фәризә үзе дә башын капчыкка салган. Мин амбарга кердем, чистартып салган ашлык өстеннән шуышып иң ерак, аулак почмакка кереп яттым.

Инде төнәрә генә башлаган идем, ниндидер бер пышылдау ишеттем. Башымны калкытып карасам, ерактан төшкән зәгыйфь кенә яктылыкта амбар почмагында ниндидер карамчыклар күренә. Күзем бераз ияләнә төшкәч абайлап алдым: Сәгыйдә белән Хәйдәр! Минем йокыларым бердән җилгә очты, ишетү-күрү сәләтем ун тапкыр артты. Тукта, ни эшлиләр болар монда?! Күрәм, әлләни үк эшләмиләр икән... Сәгыйдә аркасын амбар стенасына сөяп ашлык өстенә утырган. Хәйдәр исә янәшә ята, башын Сәгыйдәнең тезләренә салган. Сәгыйдә акрын гына, назлап кына егетнең чәчләреннән, маңгаеннан сыйпый. Үзе пышылдый:

— Юләрем син минем... Акыллым... Чәчләрең синең йомшак. Күзләрең йолдыз кебек нурлы... Бәхетсез кошым син минем...

Бу пышылдау — ярату белән, тирәнтен сагыш, үкенеч белән мөлдерәмә тулы бу кайнар пышылдау — минем күңелемне пешереп алгандай итте. Ничектер үз-үземнән оялып, имәнеп киткәндәй булдым. Бу ике йөрәкнең серен бозасым килмәде. Бик зур саклык белән амбарның аргы башына шуышып киттем. Һәм бу серне, уйлыйм ки, авылда миннән кала бүтән беркем дә белмәде. Мин аны беркайчан да, беркемгә дә сөйләмәдем.

Шуннан бирле мин — кечкенәдән үк бик күзәтүчән, тәэсирләнүчән малай — бик ачык сизендем: бу ике яшь йөрәк арасында бик яшерен элемтә урнашты, нииндидер килешү төзелде. Хәзер инде Хәйдәр дә тынычлана, басынкылана төште. Бергә килсәләр дә Сәгыйдәгә алай ачыктан, әрсезләнеп карамый, эчендәгесен бүтәннәрдән яшерә белә иде. Әмма мин сизенә йөрдем, очрашканда алар бер-берсенә астыртын гына, мәгънәле итеп карап алалар иде. Ә менә яшертен очрашулар тагын дә булдымы икән, анысын төгәл әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, авыл халкы арасында имеш-мимешләр ишетелмәде. Ә авыл халкының күзе-колагы һәм башка әгъзалары да бик үткер, бик сизгер аның. Аннан ни дә булса яшереп, сиздермичә калуы ифрат кыен эш. Алай да Сәләхи бабай Хәйдәрне һаман да күрәлмый, каршысына телсез егет очраса, урамның теге ягына чыга, кулындагы чия таягы белән янап:

«У-у, мур кыргыры! Башың муен астына килгере нәрсә!» — дип, карганып үтә иде. Өйдә киленен дә бик коры тота икән, дип сөйләделәр.

Авылда тормыш шул бер көенә бара, Сәләхи карт белән Фазыл абыйларны борчуга салырлык ул-бу ишетелми иде. Әмма шул көз үтеп кыш керүгә үк хәл бик нык үзгәрде.

Кыш башында Сәләхи бабайның улы, Сәгыйдәнең ире Хәбибулла сугыштан кайтып төште. Без, үсмерләр, капка төбенә чыгып баскан Хәбибулланы күреп шаклар каттык. Аның төймәләнмәгән шинеленнән җиз прәшкәле киң каеш белән буылган солдат гимнастеркасы күренеп тора, бу гимнастеркада ике орден, өч медаль ялтырый иде! Үзе дә болай берни булмаган кебек, карашы элеккечә горур, башы күтәренке, сары чәчләре әтәч кикерегә төсле кабарып тора. Әмма шундый горур карашлы, чибәр бу кеше, авылның оста тимерчесе бөтен түгел иде шул. Аның уң аягы тездән түбән киселгән, тездән түбән ак марляга төрелгән калдык кына. Бу хәл аның бөтен гәүдәсен ямьсезли, фасонын боза. Хәбибулла үзе култык таякларына таянып тора иде. Без аның медальләренә сокланып торгач, күзләребезне ирексездән гарип аягына төшердек. Хәбибулла моны шунда ук сизеп алды.

— Ничего, егетләр... Моның белән җить итәргә була әле. Мин протез куйдырам. Мин тимерчелеккә төшәм әле! — диде ул һәм ирennәрен нык итеп кысып куйды.

Ул заманда, кулын-аягын калдырып, гарип-гораба булып кайтса да, фронттан исән килеш әйләнеп кайта алган һәр кешегә авыл куана иде. Хәбибулланы да шулай каршы алдылар.

— Һи җаным... Зур бәхет инде. Башкайларын исән алып кайта алгач. Ниткән ул...

— Аяк кына нәрсә ул... Аяк башына таяк та куеп була.

— Акылы-фигыле төзек. Ике кулы үз урынында. Тагын ни кирәк дисең...

— Йа аллам, безнекеләр дә шулай кайтсын иде әле, — дип сөйләштеләр авыл хатыннары.

Хәбибулланың сугыштан исән кайтып төшүе авылда тик бер кешене — телсез егет Хәйдәрне бик аптырашта калдырды, тәмам кара кайгыга салды. Ул бичара үзенең бала акылы белән тормыштагы вакыйгалар барышын аңлап та бетермәгәндер инде. Кем белә, бәлки ул авылдан бик елап, җырлап чыгып киткән яшь кешеләр инде кабат әйләнеп кайтмыйлар дип тә белгәндер. Яисә, гөнаһка кереп, нәкъ менә Хәбибулланың кайтмый калуын теләгәндер. Һәрхәлдә, Сәгыйдәнең ире Хәбибулла кайтып төшкәч, Хәйдәр бик кыен, кызганыч хәлдә калды.

Беркөн югары очка менеп барам. Еракган ук күреп алдым, Хәбибулла белән Сәгыйдә капка төбенә чыгып басканнар. Нидер сөйләшәләр, көлешәләр. Хәбибулла кулын Сәгыйдәсенең иңбашына салган. Бәхетле кешеләр... Шунда күрәм, урам буйлап каршыга Хәйдәр төшеп килә. Менә ул тегеләрне күреп алды һәм... барган җиреннән сөрлегеп, тоткарланып калгандай булды. Әмма үз-үзен кулга алды, күрәсең,

бөтенләй үк тукталып калмады. Тегеләргә кат-кат борылып карады, аларны сәламләгәндәй ым какты һәм баруында булды. Менә без каракаршы килдек һәм... мин тетрәнеп киттем. Егетнең галәттә елмаюлы йөзенә кара коелган, күзләрендә шундый да тирән сагыш, күнел ачынуы иде. Ул бу юлы хәтта миңа кулын да бирмәде. Тик, нык кысылган иреннәрен кисәк ачып, «пык!» итеп кенә куйды. Бу аның «барысы да бетте, үлде, юкка чыкты!» дигән ишарәсе. Җаны авырткан кешедәй «ыгты-ыгты» дип ыңгырашып шулай үтте дә китте. Артыннан борылып карадым: егет башын түбән игән, иннәре салынып төшкән, ул бөтенләй бер сырхау кешедәй атлый иде.

Ачык кына әйтә алмыйм: Хәбибулла солдат Хәйдәр белән Сәгыйдә арасындагы мөнәсәбәтләрне, телсез егетнең үз хатынына гашыйк булып, утлар йотып йөргәнен белдеме икән? Бу хакта ана озын телләр житкерде микән? Минемчә, юктыр. Хәйдәрне әләкләргә берсенең дә вөҗданы җитмәгәндер. Бу очракта гайбәтчән авыл халкы зур тыйнаклык күрсәтте бугай. Телсез егетнең бәхетсез мәхәббәтен кешеләр сүз белән пычратырга ярамаган изге, гөнаһсыз бер нәрсә кебек күреп кабул иттеләр. Ә Хәйдәр бичара азаплана иде. Аны тамактан калган, төннәрен йокламый шыншып, ыңгырашып чыга икән, дип сөйләделәр.

Шик тә юк, Фазыл абыйлар йортыннан тынычлык китте. Әмма Сәләхи бабайлар йорты да борчусыз калмады. Авыл хатыннарының Хәбибуллага карата «акылы-фигыле төзек» дигән фаразы дөрескә чыкмады. Эш нәкъ менә шул акыл-фигыльдә иде. Ире кайткач Сәгыйдәнең гөрләшеп яшәүләре, капка төбенә чыгып кеше кызыктырып торулары, бәхетле көннәре бер-ике атнага гына барды. Аннан соң инде Сәгыйдә кибет юлында еш йөри башлады. Кулына үзләренең яшел төстәге зур калай чәйнеген тотып. Аракыга... Ул заманда аракыны кибеттә шешә белән түгел, мичкәдән генә саталар, авыл халкы аны бик сирәк, кирәге чыкканда гына, әнә шулай чәйнеккә, су чүмечена яисә бүтән бер савытка салып алып кайта иде. Инде йөзендәге шатлыклары сүнгән, үзе сулып калган Сәгыйдә кибеткә сирәк түгел, күп йөрде. Чөнки сугышка кадәр дә салгаларга яраткан Хәбибулла баш ташлап эчә башлады. Кем белә, япь-яшь, тап-таза килеш бер аяксыз калу хәсрәтеннәндер, бәлки. Тик бу хәсрәт өйдәгеләр, аеруча үзенең хатыны Сәгыйдә өстенә дә авыр йөк булып төште. Җитмәсә, аек чагында да шактый холыксыз Хәбибулла аз гына эчеп алды исә, үзенә яңа шөгыль, яңа юаныч тапты.

Шулай бер көнне урамнан барам. Кышның ямьсез көне, буранлап та тора. Буран арасыннан каршыма Сәгыйдә килеп чыкты. Шәлен маңгаена ук төшереп бәйләгән, үзе алга йөгенгән, иннәренә бау салып, «уфалла» чанасы тартып килә бу. Ә үрәчәле чанасының түрендә җәелеп, унайлап Хәбибулла утыра. Аның йөзе кызарынган, бүртенгән, өстендәге каптырмалары ычкынган шинеле ачылып, аннан орден-медальләре күренеп тора. Кулындагы таягын югары күтәргән. Мине күргәч, табигый ки, Сәгыйдә тоткарлана төште.

— На... хайван! Ник тукталасың тагын! — дип акырып җибәрде исерек Хәбибулла һәм култык таягы белән хатынының артына китереп төртте.— Менә шулай катать итәбез без хәзер, энекәш! Күрдеңме нинди яхшы атларда. Ха-ха! Без кан койдык... Алар да татысын дөньяны... Менә хатынны шулай тоталар аны! — дип мактанды ул тонган күзләрен миңа күтәреп.

Сәгыйдә үзен мәсхәрә итүдән, кеше алдында шулай түбәнсетүдән тәм тапкан ирен тартып, башын иеп үтеп китте. Мин бу хәлгә шаклар катып басып калдым. Котырынып ачуларым чыкты. Бу Хәбибулланы, бу паразитны, чанадан карга сөйрәп төшерәсем килде. Сугышта яра алган булуына карамастан... Тик чит кешеләрнең гаилә тормышына ничек итеп килеп кысыласың?! Юк авылда андый хәл.

Хәбибулла бу кылануларын куймады. Аны өендә дә әнисе Сылу әби белән әтисе Сәләхи бабайга көн күрсәтми икән, бер-бер сүз катсалар,

киленнәрен якларга итсәләр, кычкырып кына җибәрә икән, дип сөйләделәр. Ә инде хатыны Сәгыйдәне ат урынына җигеп урам әйләнеп йөрүләре гадәти бер күренешкә әйләнде. Бөтен авыл халкының күз алдында яшь хатынга таягы белән төрткәләп, яман әшәке сүгенеп, аны тәмам адәм хуры итеп... Ни хәл итмәк кирәк, адәм баласында анда яхшылык бармы-юкмы, әмма менә әшәкелек, яманлыкның иге-чиге юк. Монысына инде авыл халкы ничек тә булса күнегеп килә иде. Безне яклап ут эченә кергән, кан түккән, газап чиккән бит. Ни кыланмас дип... Тик бу хәл тиз арада тагын да зур драманы, чын фаҗигане китереп чыгарды.

Исерек Хәбибулла, гадәтенчә Сәгыйдәне җигеп, югары очка менеп баралар. Капка төбенә тәмәке тартырга чыккан Хәйдәр бу хәлне күреп ала. Хәбибулла инде, юлында кем дә булса очраса, аңа үзенең хатынын ничек тотканны, аннан ничек көлгәнен күрсәтмичә кала алмый. Хәйдәрне күргәч тә шулай эшләмәк була ул, таягы белән Сәгыйдәгә кизәнә. Тик сугарга өлгерми кала. Егет ике сикерүдә аның янына килеп җитә, таягын кулыннан йолкып ала һәм әллә кая еракка, тирән кар эченә атып ташлый. Башы резиналы, заводта матур итеп ясалган, әнә шул каһәр төшкән таякны! Аннан ике күмердәй янып торган күзләре белән Хәбибуллага чәйнәп ташлардай булып карап, аның өстенә килә. Тик... сугыштан имгәнеп кайткан кешегә аның да кулы күтәрелми. Ул бары бик ачулы, янаулы итеп «ыггы-ыггы!»сын гына әйтеп куя.

Аннары Хәйдәр Сәгыйдә янына да килгән. Үз алласы итеп күргән, бөтен барлыгы белән яраткан кешесе янына. Юк, күкрәгенә кысмаган ул аны. Үзенең сөйгәнен мондый шикле, авыр хәлгә куймаган. Тик яшь хатынның йөзенә, күзләренә карап кына торган. Мәңге исендә калдырырга теләгәндәй. Аннан инде бик авыр ыңгырашып, башын иеп читкә киткән. Сәгыйдә дә, хәтта бераз айный төшкән Хәбибулла да аның артыннан бик сәерсенеп карап калганнар.

Шул китүдән китте шул Хәйдәр. Мәңгегә китте.

Берничә көннән авылда хәвефле хәбәр таралды. Фазыл абыйларның телсез улы Хәйдәр югалган! Аның авыл башындагы юлдан мари авылы Шиншегә таба китеп барганын күргәннәр. Шиншедә Фазыл абыйларның белеше Настә түтәй бар. Хәйдәр кайчак үзе генә чыгып китеп аларга баргалап, утыннарын кисешеп йөри иде. Инде берничә көннәр үткәч, Настә түтәйләргә барып карадылар. Хәйдәрне тапмадылар. Шуннан соң инде чаң суктылар. Кемдер Хәйдәр авылдан чыгып киткән көнне буран күтәрелгәнен хәтерләде. Юл буйларын, авыл читендәге елга-ерымтылар башларын йөреп чыктылар. Милициягә хәбәр бирделәр. Юк, табылмады. Югалды Хәйдәр бу дөньядан. Картайган әти-әнисен, бөтен авылны кара кайгыга салып югалды.

— Җанашым... Буранда адашыплар үлде микәнни?

— Япь-яшь көе төшеп югалды.

— Әллә инде, бичара, үзен-үзе харап итте микән?

Авыл хатыннары күзләрен яулык чите белән сөртеп, әнә шулай сөйләштеләр.

Хәйдәрнең үле гәүдәсен инде язга таба энесе Рәшит табып алды. Юлдан шактый читтәге коры елга башыннан. Рәшит үз абыйсының үле гәүдәсен генә булса да табудан өметен өзмәде, кыш буе авыл тирәли басуларда, елга-ерымтыларда эзләнеп чаңгыда йөрде. Һәм менә бер көнне ул яз кояшы эретә башлаган кар астыннан чыгып торган карамчыкны күреп алган...

Вакыт дигәнең әллә нинди хәлләрне дә рәткә кертеп куя, авыр күңел җәрәхәтләрен дә төзәтә ул. Күп еллар үтте. Авыл халкы инде телсез егет, бәхетсез гашыйк Хәйдәрне күптән онытты. Хәбибулла белән Сәгыйдә дә гомер буена алай булмадылар. Хәбибулла аягына протез куйдырды, гомере буена тимерчелектә эшләде, тагын орден-медальләр

алды. Соңыннан аңа җинел машина да бирделәр. Сәгыйдә белән тату гына яшәп киттеләр, бала-чагалар үстерделәр, оныкларын сөйделәр.

Тормыш дигәнең бернигә дә карамый алга бара бит ул.

* * *

Мин, инде күптән читтә төпләнеп калган кеше, авылга кайттым. Ындыр артыннан гына төшеп киләм. Зират эчендә Рәшит кордаш. Янына кердем. Икебез дә олыгайганбыз инде, үзебезгә шушында килеп ятыр вакытлар җитеп бара...

— Әрвахлар янына кердем әле менә, кордаш. Каберләрен караштырам... Әнә тегесе — әнинеке, тегесе — әтинеке,— дип сөйләнде ул, өсләренә инде зур каеннар үскән каберләргә күрсәтеп.— Ә менә монысы — Хәйдәр абыйныкы. Мин аңа миләш утырттым. Миләш күзләрен саргая... Матур булып, сары булып, сагыш төсле булып...— диде кордашым һәм күрәгенә таянып бераз тын торды. Аннан әйтеп куйды.— Басудан абыйны мин үзем таптым. Адашып үлмәгән ул, юк, адашып үлмәгән. Шул Сәгыйдә апайга булган яратуыннан, шуның сагышыннан төшеп югалды ул. Үлгәндә дә күкрәгенә Сәгыйдә апаның фоторәсемен кысып яткан иде...— диде һәм акрын гына өстәп куйды.— Сиңа сер итеп кенә әйтим, бу кабер янына Сәгыйдә апай үзе дә килгәләп йөрде. Яшертен генә, соңгы елларга кадәр...





Чулпан Зариф шигырьләре сөенеч, ышаныч хисләре уята: мин аларны — һичшиксез, табигать биргән сәләт һәм моңлы күңел кичерешләре, рух эзләнүләре җимеше, безнең шигырьгә тагын бер кызыклы каләм иясе, үзенчәлекле шагыйрә килүдән хәбәр дип кабул иттем.

Чулпан — Арчада туып үскән кыз. Урыс мәктәбендә укыган һәм Казан педагогия институтының рус филология бүлеген тәмамлаган; әмма диплом эшен ул Сәгыйт Рәмиев иҗатына багышлый, уңышлы яклап, татар бүлегенә аспирантурага калдырыла. Диссертация темасы да — шул ук: олуг шагыйребез Сәгыйт Рәмиев иҗаты. Әмма ул инде башка яссылыкта: Көнчыгыш ренессансы, суфичылык һәм Нәсими, Көнбатыш фәлсәфи фикере һәм шигырьдә «демонизм» (Байрон, Ницше, Лермонтов һ. б.), XX гасыр башы гарәп (Ливан) шагыйре Х. Җәбран иҗатлары яктылыгында өйрәнелә... Болардан да яшь шагыйрәнең эрудициясен, кызыксыну объектларын чамалап буладыр. Әйе, Чулпан дөнья, рус шигъриятен, әмма барыннан да бигрәк Шәрекъ әдәбиятын, бөек гарәп, фарсы, төрки шагыйрьләрен өйрәнгән һәм бу аның шигырьләрендә дә чагыла. Шигъри сурәтләрдә, фикер бирелешендә, тел-стиль чараларында, сүз-лексиконда моны тою авыр түгел. Шәкли яктан да матур аның шигырьләре — монда да Чулпанның җитди мәктәп үткәнен тоясың. Мәңгелек тема — мәхәббәт газабын да ул үзенчә ача, тойгы-кичерешләре дә күп вакытта якты сагыш, моң (әмма зар түгел!) аша ачыла. Юк, пессимизмда гаепләмәс идем мин аны: Цветаева, Ахматовалар турында андый уй башка килми бит. Нажар Нәҗми әйтмешли:

Ә ни өчен әле шигырьгә
Гел бер төрле генә булырга?

Гомумән, күңел газаплары, тетрәнүләр, җан эзләнүләре аша шигъри чынлыкка килү — ул югары рухлылар, кыяларга омтылучы көчле шәхесләр эше. Минемчә, яшь шагыйрә дә шул юлда... Мин бу эзләнүләргә уңай карыйм: тирәнтен белем дәрьясы белән табигый интуиция, ходайдан бирелгән хатын-кыз көче, хисе, назы, моңы һәм мәңгелек сере — болар тормыш һәм шигъриятнең дәвамы, гүзәл әхлак һәм әдәп, сөю, милләт һәм дөнья турында матур уйларга этәрә...

Чулпанга мин:

— Хәерле сәгатьтә! — дим.

Рәдиф ГАТАШ

## ЗӘҢГӘР КЫЯЛАР

* * *

Җаным минем, әйтерсең лә, күптән
Таулар арасында югалган.
Салкын җилләр аны шашып үпкән.
Йә, җилләрдән бүген ни калган?..

Карлар явып, күрәсеңме, үткән.
Үзем түгел — эзем югалган!
Тәнемә мин кайнар сулыш бүтән,—
Юк, алмам!...

Гомер төргәгемне, сизәсеңме, сүтәм...
Үткәннәргә юллар югалган.
Ялкын түгел,— салкын! үзәгемә үтә.
Бу учакны, әйтче, кем яга?..

Җаным минем күптән, инде күптән
Таулар арасында югалган.
...Җирдәгесен үтеп, ахры, күккә
Таба юл алам.

* * *

Ах, чәчләрең бигрәк йомшак!
Җил сыйпый — җилдән көнлим.
Сөясеңме? — дидең, каушап.
Сөймичә мөмкин мени!

Килдем — «гаиб ирәннәрдәй...»
Шаһ кызы, йолдыз, дидең.
Күкрәгемә иренеңнән
Гөнаһ таммасмы инде?!..

Яшькелт күзләр, алма битләр...
Онытма үзең генә!
(Сөләйман бит «Бар да үтәр»
дип язган йөзегенә.)

Сөясеңме? — дидең.
Сөйдем.
Әйтмичә түздем генә.

* * *

Мәҗнүнме син, ялгыз — чүлдә ятып калган?
Эссе комга күз яшьләрең әллә тамган,—
Күлмәгеңне тишеп үскән чөнки камыш...
Камыш түгел! Сине җиргә теккән — сагыш.

Ә мин — Ләйләң. Ак дөядә уйга талган.
Бүгеннән соң синсез (ә син — минсез!) калган.
...Күпме гасыр комнар булып агар сагыш?
Чүлдән түгел, — синең аша китеп барыш...

* * *

Караңгы төндә, мәңгелек төндә
Ялгыз ай дәшә, йолдызлар, сезне.
Караңгы төндә, мәңгелек төндә
Җаным — бер үзе.

Тынгысыз җил дә, өзлексез җил дә
Гасырлар буе кемнедер эзли...
Тынгысыз җирдә, ярсыган җирдә
Югалттым кебек үземне үзем...

* * *

Тезләремнән кочып алды салкын карлар...
Үткәннәрдән миңа бүген ниләр калган?

Үкенечләр, рәнҗү... Әллә ваемсызлык?
Алай дисәң, нидән күңел әрни, сызлый?

Үкенечләр, рәнҗү, сөю — бар да ялган.
Күптән узган, күптән әллә кайда калган...

## Сине эзлим

Чит-ят күзләр күрмәгәндә генә, качып,
Битләремне инде күптән кояш үпкән.
Чәчләремдә иртәнге чык тамчы-тамчы,
Иңнәремә болыт алып салдым күктән.

Ай юлыннан йөрим сине эзләп һаман,
Күзләремә җыеп йолдыз сагышларын.
Иңнәремдә кара болыт... киләм санап
Тамчы кебек тамган мизгел агышларын...

* * *

Ярсыз дәрья кебек йөрәк,
Талпына да, бәрелә дә.
Нидән алай, нәрсә кирәк?
Белми дә ул һәм белә дә...

Кара шәүләм, ятып җиргә,
Кызу тәнен карга күмә.

Бу моңны кем миңа биргән? —
Башкаларга бирә күрмә...

* * *

Күзләреңнән үпкән иреннәрем
Хәлсез, сүзсез.
Учларыңны тойган бу иңнәрем
Инде үксез.

Нинди явызлыклар күрдең миннән,
Соң нишләдем?
...Әкрен генә шуа иңнәремнән
Кара шәлем.

## Алмагачтан алма өздем...

Алмагачтан алма өздем,
Көтмәдем кызарганын.
Елгаларда ялгыз йөздем —
Күрмәдең, кызганмадың.

Юлга чыктым кемне эзләп,
Тузгытып чәчләремне?
Инде елап туйды күзләр
Минем күз яшьләремне...

Җаным салып тирбәтергә
Тапмадым бишегемне.
Бер күрергә тилмергәндә
Какмадың ишегемне...

Алмагачтан алма өздем,
Көтсәмче кызарганын!
Белмәс идем җир йөзендә
Барлыгын моң-зарларның.
Безгә Мәхәббәтнең күкләр
Биргән иде олысын.
Инде нәрсә әйтим? Үткән
Онытыла мыни соң!..
Сулар үргә акмый, диләр,
Таулар имәс башларын...
Күңелемнән генә көйләп,
Сиңа җыр багышладым.
Алмагачтан алма өздем,
Көтмәдем кызарганын...
Гаепледер, ахры, үзем —
Беркемнән дә зарланмыйм.

* * *

Чиксез бәхет иде... Әллә күктә очтым,
Әллә йөрдем синең белән бакчаларда.
Ярларыңны аккош булып килеп кочтым,
Камышларда качам хәзер дошманнардан.

Ике канат биргән аллам, ак пар канат!
Салкын-салкын җилләр исә... тик нишләргә?
Сине генә эзләп, диңгез аша кабат
Оча алмам инде башка чит җирләргә.

Белсәм иде, нинди яңгыр, нинди томан,
Нинди таулар кисте икән юлларыңны?
Салкын җилдә боз бәрелә канатыма,
Камышларга гына сөйлим моң-зарымны.

Тик, табылыр, кайтыр әле, дигән өмет
Саклый һаман серләремне башкалардан.
...Канатлары каерылган аккош кебек,
Мин адашып калдым көзге бакчаларда.

* * *

Бусагаңда узды ярты гомерем
Коштай куныл. Башка борчымам.
Үлде дисәләр, син һич ышанма,
Бусагаңнан гына очтым ла!..



# ДРАМАТУРГИЯ



**Туфан Миңнуллин**

# ХУШЫГЫЗ!

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМА

**Катнашалар:**

Миләүшә
Галимулла
Рәфис
Фәһим
Нурислам
Шәһит
Рөстәм
Сажидә
Эльмира

## Беренче пәрдә

**Миләүшәнең фатиры. Җиһазлар юк диярлек. Тормышта иң кирәкле әйберләр генә. Ул фатир ялгыз ирләр яшәгән фатирны хәтерләтә. Миләүшә шәл бөркәнеп тирән креслога кереп чумган. Күренми дә диярлек. Кресло янындагы бәләкәй өстәл өстендә магнитофон. Аннан кайчандыр яшь Миләүшә җырлаган җыр ишетелә:**

Җитәр инде, тургай, моңайма,
Минем моңсу чагым болай да.
Моңаймасаң килеп каршыма,
Урын беткәнмени тугайда.
Моңаюым түгел, көйләвем,
Тургай теле белән сөйләвем.
Сәлам алып килдем дустыңнан,
Шуны тапшырырга теләвем.

**Җыр җырланып беткәч, Миләүшә магнит тасмасын кирегә әйләндереп яңадан шул җырны җырлата. Ишектә звонокны ишетеп, магнитофонны туктата, авырлык белән генә урыныннан торып ишеккә бара. Аннан Галимулла белән керәләр. Галимулла пөхтә итеп авылча киенгән. Үз яшенә караганда шактый ук өлкән күренә. Гомере буена купшаяны эшләп изелгән авыл кешеләренә тыйнак. Ләкин мокыт түгел. Күңеле тулы җырланмаган җыр,**

әйтелмәгән сер. Галимулла ишек янынннан узмыйча гына күзләре белән фатирны тикшереп чыга.

Миләүшә *(кулларын Галимуллага сузып)*. Йә инде, хәзер әйбәтләп күрешик. Ике куллап. Авылча булсын. Исәнме-саумы, Галимулла.

Галимулла. Болай ярыйсы гына. Көчкә эзләп таптым. Шәһәргә гел килеп булмый бит. Эш тә эш, эш тә эш. Бу телеграмманы син биргәнсеңдер бит? Әллә берәрсе юри шаяртканмы?

Миләүшә. Мин, Галимулла, мин. Үзем. Аптырап калдыңмы?

Галимулла. Булды инде бераз. Көтмәгәндә бит... Кем уйлаган... Синнән бит...

Миләүшә. Әйдә уз. Менә бирегә утыр. Уз инде, тартынма *(Галимулла ишек янындагы утыргычка утыргач)*. Юк, менә бирегә уз. *(Үзе элеккеге урынына барып утыра)*. Кил, бирегә. *(Галимулла узып утыргач)*. Бигрәк оялчан икәнсең, кызлар кебек. Танымый тордың мине, әйеме?

Галимулла. Әйе.

Миләүшә. Күрешмәгәнгә дә бик күптәннән. Соңгы тапкыр авылга кайчан кайткан идем икән? Унбиш еллап бардыр.

Галимулла. Унөч ел ярым.

Миләүшә. Анда күрештекме соң без?

Галимулла. Юк. Мин генә сине күрдем.

Миләүшә. Әйе, шулайдыр. Кайгылы көннәр иде. Әтине җирләгән чак... Нихәлләрдә яшисең соң, Галимулла?

Галимулла. Яшәлә инде. Авылда анда нәрсә... Шул инде... Кем әйтмешли, җәен көтү көтәм, кышын гуляйт итәм.

Миләүшә. Көтү көтәсең, әйе?

Галимулла. Юк. Болай гына әйтүем. Тракторда идем, хәзер мастерскойда буталам шунда.

Миләүшә. Нигә чакыртканны белмисең инде син, әлбәттә.

Галимулла. Ничек беләсең. Онытылган кешене.

Миләүшә. Чакыргач, димәк, онытылмаган... Димәк, онытылмаган, Галимулла. Телеграмманы алуга ук юлга чыктыңмы? Тиз килеп җиттең.

Галимулла. Тиз килеп җитәргә кушылган бит.

Миләүшә. Кушылмаган ла инде. Прошу диелгәндер ич.

Галимулла. Анысы бар, әйе. Транспорты бит аның безнең якта...

Миләүшә. Рәхмәт, Галимулла. Соңламадың. Ашыйсың да киләдер инде синең.

Галимулла. Түзәрлек.

Миләүшә. Бар чәйнекне газга куеп кил, Галимулла. Син инде эш кушканга үпкәләмә. Мин сиңа барысын да аңлатырмын. *(Галимулла кухняга кереп киткәч төзәтенә, өстәлдән көзге алып карана. Галимулла чыккач)*. Булдымы, Галимулла? Кил инде утыр, басып торма.

Галимулла. Минем бераз күчтәнәч бар иде.

Миләүшә. Әллә балмы?

Галимулла. Анысы да бераз...

Миләүшә. Китер тизрәк. Әтидән мин һәрвакыт бал алып килүен үтенә идем. *(Галимулла өстәлгә куйган банкыны кулына алып)* Ач тизрәк. *(Галимулла ачып биргән банкадагы балны комсызланып исни)* Ай, рәхмәт! Рәхмәт, Галимулла. Беләсеңме кайдан җыелган бал бу. Әй, онытылган да инде. Карамалыга барганда сул якта бар бит әле болынлык... Онытылган... Рәхмәт, Галимулла...

Галимулла. Болынга чыккач, чәчәкләрне иснәп йөрергә ярата идең бит.

Миләүшә. Онытмадың, әйеме? Онытмагансың, рәхмәт. Мин бит сине төшемдә күрдем, Галимулла. Әтиең Әһлиулла абыйны да күрдем. Шуннан инде сине чакырдым. Фамилиягезне онытканмын. Көчкә искә төшердем. Дөрес язылганмы? Хәлиуллин бит, әйеме?

Галимулла. Шулай.

Миләүшә. Ә беләсеңме, мин сине нигә чакырдым, Галимулла? Ләкин син аптырап калма, ярыймы? Юри генә сөйли дип тә уйлама. Мин чынлап. Мин сине хушлашырга чакырдым, Галимулла. Мәңгелеккә хушлашырга. Шулай... Мин инде бу дөньядан китәм, Галимулла. Бүген, йә иртәгә, йә берсекөнгә. Шуннан да соңга калмыйм.

Галимулла. Ничек инде алай?

Миләүшә. Шулай, Галимулла. Артыгын сорашма. Ике-өч көн вакытың булыр бит мине озатырга?

Галимулла. Ничек инде алай?

Миләүшә. Сорашма дидем. Бөтен тормышымны уйлап-уйлап утырдым да синнән дә якын кешем булмаган икән минем, Галимулла. Әйе, әйе, сиңа сәер тоеладыр минем сүзләр. Әмма син миңа ышан, кыланып сөйләшергә вакытым юк минем. Мин бик үтенеп сорыйм синнән, бер-ике көнгә бу өйгә хуҗа бул. Үтенеп сорыйм.

Галимулла. Ничек?..

Миләүшә. Үтенеп сорыйм. Теләмәсәң, хәзер үк кайтып китә аласың. Килүеңә рәхмәт.

Галимулла. Юк, мин китәм димим лә, шулай да... Болай итеп сөйләшкәнне ишеткәнем юк. Ничек инде ул алай була? Кешедән көлгән кебегрәк килеп чыга болай итеп сөйләшкәч.

Миләүшә. Мин чынлап, Галимулла. Әле син миңа ышанмыйсыңмыни?

Галимулла. Ышанырлык булмагач.

Миләүшә. Ант итимме?

Галимулла. Итимме дип... *(Миләүшәгә текәлеп карап тора)*.

Миләүшә. Чынлап, Галимулла, чынлап... Мин үтенеп сорыйм синнән. Чынлап, дип әйтәм ич инде, нигә һаман ышанмыйсың. Хәер, ышанмаска хакың бар, кайчандыр алдаган идем мин сине. Хәтереңдә дә юктыр инде.

Галимулла. Син онытмаган ич, нигә мин онытыйм ди.

Миләүшә. Оныткан идем, исемә төште. Кинәт кенә барысы да искә төшә икән ул. Барысы да, барысы да. Искә төшә, үкенләрә, үзгәртеп булмый. Уйлап-уйлап утырдым да — бу дөньяда мине чын-чынлап яраткан бер генә кеше булган икән дигән нәтиҗәгә килдем. Ул — син булгансың кебек тоелды. Нигәдер шулай тоелды. Менә әле син миңа төбәлеп карадың да тагын бер кат

барысы да күз алдыннан узып китте. Ничек мин шуны аңлап бетермәгәнмен, ничек бәяли белмәгәнмен?.. Минем болай сөйләшүемә игътибар итмә, Галимулла, бәлки сатașамдыр да. Минем әле сиңа сөйлисе сүзләрем бик күп. Әгәр дә тыңларга теләсәң, әлбәттә. Без бит синең белән бер елда, бер көндә туганнар... Шулай бит, әйеме?

Галимулла. Шулай...

Миләүшә. Нигә яшь инде безгә? Илле бишме? Күп инде, әйеме?.. Нигә дәшмисең, Галимулла?.. Галимулла, нигә дәшмисең?.. Гафу ит. Мин күп сөйлим бугай. Сөйләп калдырасым килгәндер шул, гафу ит. Сөйләп калдырасым килә, сөйләр кешем юк. Ялгыз бит мин, Галимулла. Япаялгыз. Бер кешем юк. Ике тапкыр кияүгә чыктым, тирә-ягымда кешеләр мыжлап торды һәм менә... Ялгызлыкның ни икәнен беләсеңме син, Галимулла? Әйт инде, берәр сүз.

Галимулла. Нәрсә?

Миләүшә. Син әллә мине тыңламыйсыңмы?

Галимулла. Нишләп... Тыңлыйм...

Миләүшә. Тыңлагач, нигә син бер сүз дә әйтмисең?

Галимулла. Нинди сүз? *(Телефон шалтырый. Миләүшә телефон трубкасын алмый. Телефон шалтырый-шалтырый да туктый).*

Миләүшә. Шалтыраталар... Кызыксыналар... Ә мин алмыйм... Шнурын өзеп үк ташламакчы идем дә, кире уйладым. Шалтыратсын, үзенә күрә иптәш... Аптырап карап торасың миңа, әйеме? Бу дөньяны шаккатырырга җыенган Миләүшә Нигъмәтҗанова теләгенә иреште. Авыл егете Галимулла Хәлиуллин аңа аптырап карап тора. *(Күлә башлый да кинәт туктап кала. Галимулла, хәленең җитдилеген төшенеп, Миләүшә тирәсендә бөтерелә.)*

Галимулла. Миләүшә, Миләүшә...

Миләүшә. *(Өяногә узып киткәч, хәлсезләнеп, кресло аркасына башын салып, елмаеп Галимуллага карап тора).* Исәнме, Галимулла.

Галимулла. Син ятып тор, болай уңайсыздыр ич...

Миләүшә. Зарар юк, әлегә үтеп китте. *(Тагын телефон шалтырый).* Ал, Галимулла. Кемгә бик кирәк булдым икән.

Галимулла. *(Трубканы алып тыңлый. Миләүшәгә)* Федор Ивановичны сорый.

Миләүшә. Куй, Галимулла... Шул Федор Ивановичны сорасалар гына инде... Галимулла, алып бир әле теге рәсемне.

Галимулла. *(Стенадагы рәсемгә карап)* Кемнәр бу, Миләүшә?

Миләүшә. Алар минем яшьлек дусларым, Галимулла. Шуларның икесенә кияүгә чыктым. Икесе белән дә аерылыштым... Алып бир әле. *(Галимулла алып биргән рәсемне күрсәтеп)* Монысы — беренче ирем Шәһит, монысы — икенче ирем Нурислам. Болары Рәфис белән Фәһим. Монысы — мин. Дуслар. Бик тә, бик тә якын дуслар. *(Рәсемне өстәл тартмасына салып куя).*

Галимулла. Нигә?

Миләүшә. Ятсыннар шунда, Галимулла.

**Ут сүнә. Ут янганда Рәфисләр фатиры. Сәҗидә көзге каршында бизәнә, малайлары Рөстәм магнитофон колакчыныи колакларына киеп креслода утыра. Сәхнә шартлары күпме мөмкинлек бирә, ул шул чаклы бай итеп бизәлгән. Кыскасы, байлык аңкып тора.**

Сәҗидә. *(Рәфиснең кайтканын тоеп)* Кайттыңмы, әтисе?

Рәфис. *(Ул баштанаяк заманның яшьләре киенә торган киемгә киенгән һәм ул кием аңа килешә дә, яшәртеп күрсәтә)* Кайтмадым, үтеп кенә барышым.

Сәҗидә. Минем белән рәтләп сөйләшер көнең булыр микән синең.

Рәфис. Чәй куй һәм йөз грамм коньяк чыгар.

Сәҗидә. Кәефең шәп күренә, берәр этлек эшләп кайттың мәллә?

Рәфис. Кайтмыйча. Берьюлы ике марҗаны кочаклап кайттым. Менә мондыйлар.

Сәҗидә. Хәсрәт. *(Кухняга кереп китә).*

Рөстәм. *(Әтисенә таба борылып.)* Не дразни ее, опять начнете. Неужели не надоело ругаться...

Рәфис. Иләшкән инде... *(Кесәсеннән газета чыгарып)* Карале, улым, укы әле. Әтиең турында нәрсә язганнар монда. *(Үзе укып)* «Минем өчен иң кызганычы — Рәфис Хатипның поэзиядән китүе булды. Талантлы шагыйребезне югалттык. Аның шигырьләрендә моң бар иде». Аңлыйсыңмы, улым?

Рөстәм. А чего там непонятного. *(Елмаеп)* Приятно, да, читать?

Рәфис. Ничек инде!.. Минем турыда бит. Димәк, хәтерләүчеләр бар Рәфис Хатип шигырьләрен. Тыңла әле, улым, ничек ди бит.

Рөстәм. Ну, хватит, хватит... Читайте с мамой.

Рәфис. Аңлыймыни синең әниең шигъриятне... Шигырьләремдә моң бар иде, ди. Син, улым, беләсеңме моның ни икәнен?

Рөстәм. Знаю, знаю. Какой ты большой ребенок, эти. Все еще живешь какими-то иллюзиями. Поэзия... Моң... Ну пора уж вылечиться. Никому они не нужны твои стишки.

Рәфис. Шулай инде анысы, шулай. Китап кибетенә кергән идем. Өелеп ята шигырь китаплары. Менә дигән шагыйрьләрнеке. Шулай да менә язганнар бит. Мине онытмаганнар. Хәтерлиләр. Их!.. *(Газетага сокланып карап тора)* Молодец!.. Җәүдәт Мансуров язган... Кем икән бу Җәүдәт Мансуров? Белмим дә.

Рөстәм. Найди и пригласи в гости.

Рәфис. Чакырам, чакырам.

Рөстәм. Кстати. Что-то давно вы не ходите в гости. Раньше бывало, возвращались поздно, до утра спорили с мамой, ругались. Она вечно ревновала. Интересно было.

Рәфис. Картаеладыр инде.

Рөстәм. Кстати. Я был в больнице, где главврачом мой друг. У него лежала ваша Миляуша. В общем, у нее дела не важны.

Рәфис. Миләүшә?

Рөстәм. Да. Может другая Миляуша есть — певичка.

Рәфис. Ни булган аңа?

Рөстәм. С сердцем что-то. Так что ваша подруга может и умерла. А ты тут моң... моң...

Рәфис. Туктале, улым. Ничек инде Миләүшә? Без бит...

Рөстәм. Вот и без бит, без бит... Друзья... Собирались... Клятвы разные...

Рәфис. Нигә соң аны әйтми йөрдең?

Рөстәм. Что, у меня других забот нет. Вы же клялись, не я. Вы же изучали моральный кодекс...

Рәфис. Туктале син... Ничек соң әле Миләүшәнең телефон номеры?

Рөстәм. Звони главврачу. Тридцать восемь, тридцать шесть, тридцать шесть.

Рәфис. *(Шалтырата. Трубканы алучы булмагач, Саҗидәне чакыра)* Саҗидә, Саҗидә!..

Саҗидә. Ни булды, нигә үкерәсең тагын?

Рәфис. Син Миләүшәнең телефон номерын хәтерләмисеңме?

Саҗидә. Каян исеңә төште әле ул Миләүшә?

Рәфис. Чирләгән ди.

Саҗидә. Чирләсә — терелер. Алтмышка житкәндә кеще чирләмичә тормый. Менә минем дә йөрәгем чәнчеп тора.

Рәфис. Хәтерлисеңме телефон номерын, юкмы?

Саҗидә. Каян белим. Көне-төне сез шунда ята идегез. Мин каян белим. Оныткандыр дисәм...

Рөстәм. *(Әнисенә)* Хватит... Помнишь — скажи.

Саҗидә. Соң, улым... Инде акылга утырды дисәм, нишли бит...

Рөстәм. Она больна... Ты соображаешь? Она больна. Они — друзья.

Саҗидә. Беләм мин аларның дуслыкларын. Хатынының хәлен белү юк. Миләүшә кирәк булган.

Рәфис. Ахмак!

Саҗидә. Кем ахмак?

Рәфис. Мин...

Саҗидә. *(Рөстәм янына атылып барып)* Улым, Рустик, ишеттеңме, ишеттеңме, әтиең миңа нәрсә ди. *(Үкереп җылап җибәрә).*

Рөстәм. Началось. *(Әнисен кочаклап)* Ну ладно, ладно. Успокойся.

Саҗидә. Нигә ул мине мыскыл итә. Гомере буе шулай. Бөтен ачуын миннән ала. Мин аңарга нинди начарлык эшләгән. Мин булмасам, әллә кайчан алкаш була иде. Шул Миләүшәләр белән йөреп. Дуслар дигән булып. Пәриләр белән саташалар. Җыен разгилдәй.

Рөстәм. Ну, хватит, хватит... (Әнисен житәкләп кухняга кертеп чыга). Ну, чего ты дразнишь ее? Неужели не надоело. Ну, ты же мужчина. Ну, чего?.. Ты же видишь, ты же поэт, она же дура.

Рәфис. Ул синең әниең.

Рөстәм. Ну, әни, әни... Еще чего? Ты эти. Ну и что? Оба вы кретины. Ну, скажи ей что-то ласковое, чего тебе жалко что ли? Ну не вышел из тебя большого поэта, чего ты всю обиду на нее валишь? Чего, тебе плохо живется? Чего вам не хватает? Этой макулатуры? *(Кесәсеннән акчалар чыгарып идәнгә сибә)* Ну, берите, хапайте. Только не орите.

Саҗидә. *(Бүлмәдән чыгып акчаларны җыя)* Бирмә аңа, нәрсә син аңа да аңа.

Рөстәм *(Саҗидәне күтәреп торгызып)* А ну, уйди в свою комнату. Я вам дом построил. Полтыщи квадратных метров. Неужели не умещаетесь?

Саҗидә. Ул башлады.

Рөстәм. Ул башлады, ул башлады... Оба вы... Из-за вас жениться боюсь. Вы же загрызете любое живое существо. *(Әнисенә)* Ну иди, иди, говорят. И не покажись, пока он дома. *(Саҗидәне этеп диярлек бүлмәсенә кертеп җибәрә. Рәфискә)* Чего тебе, номер телефона нужен? Вот справочник. Смотри и звони.

Рәфис. *(Белешмәләр китабыннан карап шалтырата).* Кем бу? Нигъмәтҗановалар фатиры? Кем сез?.. Нинди Галимулла? Нинди авылдашы? Миләүшә өйдәме? Бирегез әле трубканы Миләүшәгә. Рәфис... Рәфис диегез... Якын дусты мин аның. Аңлыйсызмы? Бирегез диләр трубканы. *(Трубканы куеп)* Нәрсә бу?

Саҗидә *(күренеп)* Нәрсә булсын, сөяркәсе белән утыра.

Рәфис. Ничек телең әйләнә? Илледән узган хатынга.

Саҗидә. Сез бит унсигез яшьлекләр кебек кыланасыз.

Рәфис. Булды, булды... Нишләргә соң әле... Әллә ничек кенә килеп чыкты бит әле. *(Рөстәмгә)* Улым.

Рөстәм. Еще чего?

Рәфис. Трубканы алмый Миләүшә апаң.

Рөстәм. Ну съезди. Для чего машину подарил. Катайся на удовольствие.

Саҗидә. Мин дә барам.

Рөстәм. Конечно. Без тебя же он не может.

Рәфис. Кая барасың?

Саҗидә. Син кая барасың, шунда.

Рәфис. Ну бар инде, бар.

Саҗидә. Тышта салкын микән?

Рәфис. Мең градус.

Саҗидә. Бу хәтле дә яратмагач яратмыйсың икән. Күңелең булсын — бармыйм. Кара аны, әйбәт кенә йөр. Мин әйткәннәрне Миләүшәгә сөйләмә тагын. *(Рәфиснең яңагыннан үбеп ала).*

**Ут сүнә. Сәхнә яктырганда Галимулла трубкадан сөйләшә.**

Галимулла. Әйе. Нигъмәтҗановлар фатиры. Галимулла. Миләүшәнең авылдашы. Өйдә. *(Миләүшәгә)* Рәфис, ди. Сине сорый.

Миләүшә. Әйт, Галимулла, ул беркем белән дә сөйләшергә теләми диген.

Галимулла *(Трубкага)* Ул беркем белән дә сөйләшергә теләми. Мин каян белим... Әйттем... *(Миләүшәгә)* Бир Миләүшәгә трубканы, ди.

Миләүшә. Куй. Һәм бүтән алма.

Галимулла. Нигә алай, Миләүшә?

Миләүшә. Шулай, Галимулла. Минем беркемне дә күрәсем килми, берәү белән дә сөйләшәсем килми. Минем янымда син бар. Миңа беркем дә кирәкми. *(Тагын телефон шалтырый.)*

Галимулла. (Трубканы алып) Әйе... Ул беркем белән дә сөйләшергә теләми... Галимулла... Авылдаш... Әйттем ич инде... *(Миләүшәгә)* Эльмира, ди.

Миләүшә. Алма трубканы дидем мин сиңа.

Галимулла (трубканы куя) Эльмира ди бит.

Миләүшә. Булсын.

Галимулла. Нигә сөйләшмисен соң? Әйтәсе сүзе бардыр бәрәр.

Миләүшә. Минем әйтәсем сүзем юк, Галимулла. Әйтәсе сүзләр күптән инде әйтелгән. Ничаклы мәгънәсез сүз сөйләнелгән.

Галимулла. Кырт кисеп сөйләшә торган гадәтеңне ташламагансың икән.

Миләүшә. Холык үзгәрми диләр бит, Галимулла. Шул холык шушы көнгә калдырды да инде. Яраклаша белмәдем шул, һәрвакыт үземнекен тукыдым. *(Галимулланың урыныннан торганың күреп)* Китмә, Галимулла, утыр. Син беркая да китмә. Килгәнсең икән, янымда гына утыр.

Галимулла. Чәй диден бит. Пешкәндер. *(Кухнядан чынаяклар алып чыга, чәй ясый)* Шулай ярыймы? Күе түгелме?

Миләүшә. Миңа барыбер, Галимулла. Шулай да миңа рәхәт, янымда син...

Галимулла. Радиодан элек гел жырлаталар иде, хәзер сирәкләттеләр. Телевизордан да күрсәтми башладылар.

Миләүшә. Картайдым бит инде, Галимулла.

Галимулла. Барыбер дә синең кебек жырлаучы юк.

Миләүшә. Жырлаучы юк иде диген, Галимулла. Бар иде, Галимулла, бар иделәр. Бар идек. Онытылдык кына. Беркемгә дә кирәгебез юк инде. Ул чакта да кирәкмәгәнбез.

> «Бармыни бездә, гомумән,
> чын кеше кадрен белү?!
> Без аны кайдан белик,
> мескин үлеп аңлатмагач?!»

Без инде үлеп тә аңлата алмыйбыз, Галимулла бәгырькәем.

Галимулла. Барыбер юк... Теге жырны жырлат әле...

Миләүшә. Кайсы жырны?

Галимулла. Мин килгәндә жырлый иде. Ишек төбендә тыңлап тордым.

Миләүшә. Мин аны үзем генә, качып кына тыңлыйм шул, Галимулла. Ачуланма инде. Телисеңме, мин сиңа бүтән жырларны жырлатам.

Галимулла. Миңа син жырлаганнар кирәк.

Миләүшә. Бүтәннәрне тыңламыйсыңмы?

Галимулла. Тыңлыйм да.

Миләүшә. *(Елмаеп)* Мин бөтенесеннән дә әйбәтрәк жырлыйм, әйеме?

Галимулла. Әйе.

Миләүшә. Рәхмәт! *(Бер кассета алып)* Менә шуларны тыңлап кара әле син, иптәш Хәлиуллин. *(Магнитофонны кабыза, жыр яңгырый)*.

> Бу дөньяда яшәп карап шуны белдем —
> Хак дигәнем барысы да ялган икән:
> Ак дигәнем, пакь дигәнем корым булып
> Йөрәгемә, бәгыремә ягылган икән.
>
> Бу дөньяда яшәп карап шуны белдем —
> Ант итүләр хәйлә икән, мәкер икән:
> Тугъры диеп, туры диеп йөргәннәрем
> Туры түгел — бөкре һәм кәкре икән.
>
> Бу дөньяда яшәп карап шуны белдем —
> Чын дигәнем мәзәк кенә, уен икән:
> Очрашулар, күрешүләр, көлешүләр —
> Барысы да бары пәри туе икән.

Миләүшә **(Магнитофонны туктатып)** Ничек?

Галимулла. Ничек дип...

Миләүшә. Ошамадымы әллә? Мин жырладым бит. Хәтта көйнен үзен дә, шигырен дә үзем яздым.

Галимулла. Радиодан ишеткәнем булмады.

Миләүшә. Мондый жырларны радиодан жырламыйлар, Галимулла.

Галимулла. Дөрес эшлиләр икән анысын болай...

Миләүшә. Нигә, Галимулла?.. (Ишектә звонок) Ачма, Галимулла.

Галимулла. Бәлки, йомышы бардыр.

Миләүшә. Нинди йомыш? Хәзер инде миңа берәүнең дә берниндн дә йомышы юк, Галимулла *(Звонок кабатлана)*.

Галимулла. Тиккә генә килмәгәннәр инде кеше. (Тышта «Миләүшә!» дигән тавыш ишетелә).

Миләүшә. Рәфис тавышы.

Галимулла. Ачыйммы?

Миләүшә. Кирәкми. *(Тышта Рәфиснең: «Миләүшә, ач, беләм бит — син өйдә», — дигән тавышы ишетелә.)*

Галимулла. Керсен.

Миләүшә. Кирәкми *(Тышта Рәфиснең: «Миләүшә, син исәнме? Әйт, син исәнме?.. Әй, Галимулла, син өйдәме? — дигән тавышы ишетелә.)*

Миләүшә. Әйт, Галимулла. Өйдә диген. Миләүшә исән-сау диген. Берәүне дә күрергә теләми диген.

Галимулла *(ишек янына барып)* Миләүшә исән-сау. Ул берәүне дә күрергә теләми. Нәрсә?.. *(Галимулла Рәфис белән ишек аша сөйләшә.)*

Рәфис. Ач әле ишекне.

Галимулла. Миләүшә ачарга кушмый.

Рәфис. Син кем?

Галимулла. Галимулла дидем ич.

Рәфис. Монда нишләп йөрисең?

Галимулла. Миләүшә чакырып китерде.

Рәфис. Каян?

Галимулла. Авылдан.

Рәфис. Миләүшә авылыннанмы?

Галимулла. Шуннан.

Рәфис. Исемең кем дидең әле?

Галимулла. Галимулла дидем.

Рәфис. Мин Рәфис атлы булам, агайэне. Миләүшәнең якын дусларының берсе. Ничек анын хәле?

Галимулла. Әйбәт.

Рәфис. Ничек әйбәт?

Галимулла. Шулай әйбәт.

Р ә ф и с. Рәтләбрәк сөйләш әле минем белән. Хәле ничек дим бит.

Г а л и м у л л а. Әйбәт дим.

Р ә ф и с. Больницадан кайчан чыкты?

Г а л и м у л л а. Белмим. Мин килгәндә өйдә иде.

Р ә ф и с. Мин килгәнне беләме ул?

Г а л и м у л л а. Белә.

Р ә ф и с. Кертмәскә кушамы?

Г а л и м у л л а. Әйттем ич инде.

Р ә ф и с *(кычкырып)* Миләүшә, бу мин, Рәфис. *(Җавап ишетелмәгәч)* Өйдәме соң ул?

Г а л и м у л л а. Өйдә булмый кайда булсын.

Р ә ф и с. Минә әкәмәт. Ә сине нигә чакырды?

Г а л и м у л л а. Белмим.

Р ә ф и с. Ә син аның кеме?

Г а л и м у л л а. Авылдашы.

Р ә ф и с. Элек нигә бер дә күргәнем булмады?

Г а л и м у л л а. Монда килгәнем булмады.

Р ә ф и с. Хәзер килдеңме?

Г а л и м у л л а. Әйтеп торалар ич, Миләүшә чакырып китерде.

Р ә ф и с. Син тарпаймый гына сөйләш әле, ярыймы, аңлат миңа. Ул мин килгәнне беләме? Рәфис килгәнне беләме?

Г а л и м у л л а. Белә дим ич.

Р ә ф и с. Белгәч нигә?..

Г а л и м у л л а. Берәүне дә күрәсем килми, диде.

Р ә ф и с. Мин бит берәү түгел, мин бит Рәфис. Аның якын дусты. Аңлыйсыңмы? Без ничә еллар бергә... Аңлыйсыңмы?

Г а л и м у л л а. Нигә миңа кычкырасыз? Минем ни гаебем бар.

Р ә ф и с. Син бит ишек төбен саклап торасың.

Г а л и м у л л а. Миңа Миләүшә кушты...

Р ә ф и с. Ә бәлки, кушмагандыр. Бәлки, син... Ач ишекне, Бурзай.

Г а л и м у л л а. Син сүзеңне үлчәп сөйлә, ярыймы. Күрсәтермен мин сиңа бурзаеңны.

Р ә ф и с. Мин киттем, Миләүшә. Ризабәхил түгел.

М и л ә ү ш ә. *(Ишек төбендә басып торган Галимулла янына килә)* Берни дә аңламыйсыңмы Галимулла? Аңлама, Галимулла, кирәкми... Нигә килдем дип үкенәсеңме? Шулаймы?

Г а л и м у л л а. Үкенүен үкенмим дә... Әллә ничек...

М и л ә ү ш ә. Уенга охшаган, әйеме?

Г а л и м у л л а. Кем белә инде. Мин бит...

М и л ә ү ш ә. *(Галимулланы бүлдереп)* Тик зинһар мескенләнмә, яме! Беләсең, мин мескеннәрне яратмадым һәм яратмыйм. Бөтенесен дә аңлыйсың, барысын да беләсең син. Сине табигать акыллы итеп яраткан. Син минем сүзләремә ышанмыйсың, Миләүшә нииндидер уен уйный, дип уйлыйсың. Ләкин мин уйнамыйм. Уйнамыйм, уйнамыйм! Сиңа шулай тоела гына ул. Безнең бөтен тормышыбыз уенга охшаган. Әти әйтмешли, ат кәмите... Әгәр дә миңа ышанмасаң, кайтып китә аласың.

Г а л и м у л л а. *(Миләүшәгә ниндидер кырыс сүз әйтергә теләп)* Миләүшә...

М и л ә ү ш ә. Кирәкми, Галимулла... Аптырама, син безнең барыбыздан да өстен.

Г а л и м у л л а. Мин үземнең кем икәнлегемне беләм, Миләүшә.

М и л ә ү ш ә. Юк, белмисең, Галимулла. Мин дә үземнең кем икәнлегемне белмим. Берәү дә белми. Беләм дип уйлыйлар гына. Беләм дип уйлап ничаклы гомерне әрәм иттем. Син дә гаепле, Галимулла. Җибәрмәскә иде мин ахмакны авылдан. Нинди бәхетле хатын була идем бит мин. Өй тулы бала-чагалар... Хәзер инде оныкларыбыз ничаклы була иде. Кем инде мин? Ни өчен яшәдем инде? Юк, беркемне дә күрәсем килми, Галимулла. Мин гомер буе ялгыз булдым. Шәһит безгә әйтә иде: өч тиенлек эшегез юк, сукыр бер тиенлек акылыгыз юк, дия иде. Хаклы булган. *(Кинәт көлеп)* Әшәке кеше мин, әйеме, Галимулла? Әйт әле дөресен генә, нинди кеше мин? Әйт инде Галимулла.

Г а л и м у л л а. Ничек әйтим. Сине күрмәгәнгә...

М и л ә ү ш ә. Бала чакта, үсмер чакта, яшь чакта еш күрешә идек. Хәтта үбешкән чак та булды бугай. Син хәтерлисеңме? Бакалы күл янына барган идек. Ни өчен барган идек әле, хәтерлисеңме?

Г а л и м у л л а. Син алып бардың, анда төнбоеклар үсә иде.

М и л ә ү ш ә. Әйе, әйе. Мин сиңа төнбоеклар өзәргә куштым. Йөз илле төнбоек өзеп миңа бүләк итсәң, мин сине яратырмын, дидем. Син ничәне өздең әле?

Г а л и м у л л а. Йөз илле бишне.

М и л ә ү ш ә. Әйе, әйе. Нинди олы күлне актарып чыктың. Суның салкыныннан күгәреп каттың. Миңа бер олау төнбоек тоттырдың. Ә мин: «Миңа йөз илле биш төнбоек кирәкми, йөз илле генә төнбоек кирәк»,— дип, төнбоекларны җиргә сибеп кайтып киттем. Син мине куып җиттең. Беләгемнән кысып тоттың. Мин сиңа кычкырдым. «Нишлисең, җүләр. Җибәр, кулны авырттырасың диләр бит».

Г а л и м у л л а. Әйдә.

М и л ә ү ш ә. Кая?

Г а л и м у л л а. Төнбоекларны җыеп ал.

М и л ә ү ш ә. Бик кирәкләре бар.

Г а л и м у л л а. Алайса, нигә өздердең?

М и л ә ү ш ә. Кем сиңа йөз илле бишне өзәргә кушты. Миңа йөз илле генә кирәк иде, җибәр кулны, җүләр. Кая алып барасың? Җыймасам нишләтәсең?

Г а л и м у л л а. Шушы күлгә батырам.

М и л ә ү ш ә. Батырып кына кара.

Г а л и м у л л а. Батырам, кире тәре.

М и л ә ү ш ә. Син мине батырсаң, әти синең үзеңне батыра.

Г а л и м у л л а. Мактанма әтиең белән, ярыймы. Җый төнбоекларны.

М и л ә ү ш ә. Җыймыйм.

Г а л и м у л л а. Җыясың!!!

М и л ә ү ш ә. Барыбер җыймадым бит, Галимулла. Их, шунда батырып кына үтергән булсаң. Җинә алмадың шул мине, җинә алмадың кире тәрене. Төнбоекларны тәки үзеңнән җыйдырттым. Аның караны, без анда үбештек. Үз гомеремдә беренче тап-

кыр бит. Уналты яшемдә. Аннан соң ничаклы мин сиңа күренергә оялып йөрдем. Яратканмындыр мин сине. Яратмасам, үбешмәгән булыр идем. Аннан соң Бакалы күл янына еш бара башладык. Бакаларга кушылып җырлый идек. Хәтерлисеңме, Галимулла?

Исәпсез, хисапсыз йолдызлар сибелгән
Галәмнең киңлегенә,
Ә без җирдә синең белән икәү генә,
Икәүдән-икәү генә,
Икәүдән-икәү генә.

*(Җырга Галимулла кушыла)*

Хисапсыз авазлар моң булып коела
Болыннар иңлегенә,
Ә без һаман синең белән икәү генә,
Икәүдән-икәү генә,
Икәүдән-икәү генә.

*(Көй әкрен генә дәвам итә. Шул көй ритмында Галимулла белән Миләүшә сөйләшә.)*

Миләүшә. Әгәр дә мин очып китсәм, нишләрсең, Галимулла?

Галимулла. Синең арттан очармын.

Миләүшә. Әгәр дә мин егылып төшсәм, нишләрсең, Галимулла?

Галимулла. Ә мин сине тотып калырмын.

Миләүшә. Әгәр дә мин югалсам, нишләрсең, Галимулла?

Галимулла. Эзләрмен.

Миләүшә. Табалмасаң нишләрсең?

Галимулла. Көтәрмен.

Миләүшә.

Билгесез киләчәк кул изәп чакыра.
Хыялым илләренә:
Сукмаклар, юллар күп, ә без икәү генә,
Икәүдән-икәү генә,
Икәүдән-икәү генә.

Ышанасыңмы син миңа, Галимулла?

Галимулла. Мин сине яратам гына.

Миләүшә. Ышанмыйча яратмыйлар.

Галимулла. Ә мин яратам. *(Телефон шалтырый)*

Миләүшә *(кычкырып)* Алма! Алма, Галимулла!..

**Фәһимнәр фатиры. Фәһим креслога чумган да карашын билгесез бер ноктага төбәп утыра. Берничә көн инде кырынмаган. Эльмира кайтып керә.**

Эльмира. Һаман утырасыңмы? Көннәр буе. Ничек оча сөягең тишелми. Кибеткә чыгып керер идең, ичмасам.

Фәһим. Акча юк.

Эльмира. Ничек булсын. Күпмегә җитә ул минем пенсиям.

Фәһим. Эшкә керергә кушасыңмы?

Эльмира. Нидер эшләргә кирәк, ләбаса. Болай утырып булмый бит инде, Фәһим.

Фәһим. Була ич, күреп торасың.

Эльмира. Бетәсең, харап буласың болай булса.

Фәһим. Ә мин шуны көтеп утырам да.

Эльмира. Нәрсәне?

Фәһим. Тизрәк бетәргә иде дә, котылырга иде...

Эльмира. Фәһим, ни сөйлисең, бәгырькәем?

Фәһим. Яшәсем килми минем бу дөньягызда. Фәхешханәдә миңа кызык түгел. Ул яшьтән узган мин.

Эльмира. Кешеләр яши бит.

Фәһим. Кешеләр? Нинди кешеләр? Кешеләр бетте. Кайда ул кешеләр? Ике аяклы күшәүче хайваннар һәм аларны ашаучы ике аяклы ерткыч җанварлар гына калды.

Эльмира. Йа, алла...

Фәһим. Алла да юк...

Эльмира *(кычкырып)* Фәһим!..

Фәһим. Китте ул. Җиргә, кешеләргә кулын селтәде дә китте, кайтмаска китте ул. Җиргә Иблис хуҗа.

Эльмира. Кешеләргә ни ачуың бар? Син үзең дә адәм баласы.

Фәһим. Юк. Адәм балалары үлеп бетте алар. Иблис токымы гына калды.

Эльмира. Синең яза алмавыңа кешеләрнең гаебе юк. Син язмый дип дөнья туктап тормый. Яңа көйләр туа тора, аларны җырлап торалар.

Фәһим. Көй? Нинди көй? *(Кинәт сикереп торып пианино янына бара, ун бармак белән клавишларны кыйнап алып)* Шушы булдымы көй? Кемнәр җырлый? Нәрсә җырлый? *(Клавишларны кыйный-кыйный җырлый)*

Сиңа шундый җыр кирәкме?
Сиңа шундый җыр кирәк?
Шундый, шундый, шундый, шундый
Шундый, шундый җыр кирәк.
Җыр кирәк,
Җыр кирәк,
Җыр кирәк,
Җыр кирәк,
Җыр, җыр, җыр, җыр, җыр, җыр,
Кирәк, кирәк, кирәк, кирәк, кирәк.
Яратам, яратам, яратам
Яратам...

Сиңа шундый җыр кирәкме? Зәйнуллалар, Сәйфуллалар җыры кирәкме? Яза алмыйм мин мондый җыр. Язарга теләмим мин мондый җыр. Мин — композитор. Мин профессионал композитор. *(Паузадан соң)* Тимә миңа, Эльмира. Кыйнама минем җанымны.

Эльмира. Син үз җаныңны үзең кыйныйсың, бәгырькәем. Үткәннәр белән генә яшисең. Элеккеге даның комачаулый. Һаман да мактау көтәсең.

Фәһим. Ә нигә мин аны көтмәскә тиеш? Нәрсә, мине мактарлык музыка язмадыммыни? Нәрсә, мин утыз ел трай тибеп йөрдеммени? Нигә әле мине җиңел генә онытырга тиешләр? Нәрсә, минем ашарга акчам юклыгын белмиләрмени? Нәрсә, тамак хакы да эшләмәдеммени мин? Нәрсә, тамагымны туйдыру өчен тамаклык язып утырыйммы бүген?

Кулыма гармун алып чатка чыгып басыйммы? Тимә миңа. *(Креслога кереп чума. Тынлык. Телефон шалтырый.)*

Эльмира *(Трубканы алып)* Әйе... Әйе, мин. Исәнме, Рәфис. Әле син дә исәнмени. Ходаем жаным! Әй, Рәфис, Рәфис... Ничек оят түгел сиңа? Шалтыратып хәлебезне дә белмисең. Аерылмас дуслар идек бит. Фәһимме? Өйдә, өйдә... *(Фәһимгә)*, Фәхим, Рәфис шалтырата.

Фәһим. Нәрсә кирәк булган?

Эльмира. Сине сорый.

Фәһим. Сөйләш үзең генә.

Эльмира. Алай итмә инде, Фәһим. *(Фәһим кузгалмагач)* Рәфис, син кереп чык әле безгә. Беләсең бит Фәһимнең холкын, бер киреләнсә... Кереп чык әле, бәгырькәем. *(Трубканы куя)*

Фәһим. Нигә чакырдың син аны?

Эльмира. Чөнки үземнең генә көчем житми. Юк, болай итәргә хакың юк синең. Бөтен дусларыңны жыям, күрсеннәр.

Фәһим. Нинди дуслар? Ни сөйлисең син?

Эльмира. Мәңге дуслар булырга антлар итешмәдегезмени? Нәрсә, Миләүшә дус түгел идемени? Нурислам дус түгел идеме? Гайнулла, Шәһит дус түгелләр идеме? Юк, барысын да жыям. *(Шалтыратып)* Алло, Нигъмәтжанова квартирасымы? Миләүшәне бирегез әле? Ничек алмый. Сез кем? Галимулла? Нинди Галимулла? Бирегез Миләүшәне. Эльмира сорый диегез... Ничек инде? *(Трубканы куеп)* Миләүшә трубканы алмый, ди. Галимулла, ди. Әллә үпкәләгәнме Миләүшә? Үпкәләве дә бар. Шалтыратып хәлен дә белгәнебез юк.

Фәһим. Аның бармы соң? Минем хәлемне кемнең белгәне бар? Кем кемгә кирәк бу дөньяда?

Эльмира. Галимулла... Галимулла... Таныш исем. *(Телефоннан шалтырата да тыңлап торгач трубканы куя)* Гайнуллалар дәшми. Нурисламның телефоны юк.

Фәһим. Шул алкоголиктан минс тәрбияләтмәкче буласыңмы?

Эльмира. Рәтлерәк сүз белмисеңме әллә. *(Шалтыратып)* Шәһит, синме? Мин бу, Эльмира... Фәһимнең хатыны инде алайса... Шәһит, син безгә килә аласыңмы? Нигә дәшмисең? Нигә дип... Сагындым... Күрәсем килә... Гафу ит инде алйса. *(Трубканы куя.)*

Фәһим. Нәрсә инде син... Кем кемгә кирәк бу заманда...

Эльмира. Шулайрак шул, шулайрак, ахры. Ләкин мин синең бу кыяфәтеңә карый алмыйм. Син бит композитор. Син бит кешеләр жырласын өчен көй иҗат итүче. Әгәр композиторы шушы хәлдә булгач, халкы нинди булырга тиеш. *(Каяндыр тальян гармун табып алып килә)* Мә, ичмасам, гармун уйнап утыр. Эчең пошканда алып уйный идең. *(Гармунны Фәһим алдына куя, каешларын кидерә)* Уйна әле, «Авыл көен» — яраткан көеңне. *(Фәһим теләр-теләмәс кенә гармун телләренә баскалый да кирәк, «Авыл көе»нә күчә)*.

**Ишектә звонок. Эльмира барып ача. Рәфис белән керәләр.)**

Рәфис. Ха, монда мәжлес икән. *(Уйнаудан туктаган Фәһимгә)* Сәлам, картлач.

Фәһим. Үзең нихәл?

Рәфис. Хәлләр — хәләвә, башлар — галава, мунча — баня, хатын — баба.

Эльмира. Рәфис! Нәрсә булды сезнең белән? Элек бергә жыелып утыра идек. Көлешә идек... Кайгы-шатлыкларны уртаклаша идек. Таралдык бит. Кара әле, дустыңның кыяфәтенә. Көннәр буе шулай утыра.

Рәфис. Тик утыруы рәхәттер. Утырсын.

Фәһим. Мин син түгел. Жыр язуымны ташлап акча артыннан кушаяклап чаба белмим.

Рәфис. Өйрәтермен.

Фәһим. Мин өйрәнергә теләмим. Типкәләсеннәр, үтерсеннәр, иманымны алыштырмыйм.

Рәфис. Кем сина алыштырырга куша.

Фәһим. Син! Син алыштырдың.

Рәфис. Син сүзеңне үлчәп сөйлә, агайэне. Иман сүзе белән авыз чайкама. Минем иманым минем йөрәгемдә. Тимә аңа. Мин аңа үзем дә кагылырга куркам. Ләкин мин кемнәргәдер ачу саклап жылап та утырмыйм. Кемгә ачу сакларга? Өстәгеләргәме? Алар барыбер безне күрми. Кешеләргәме? Нишләтәсең инде аларны. Заман нинди — кешеләре шундый. Йөрәк үлде, корсак кына калды кешедә. Нәрсәсенә үпкәләргә. Төкердем бер лач итеп. Корсак икән корсак, миндә дә корсак бар. *(Фәһимгә)* Тор, нәрсә жылап утырасың? Киттек таларга. Таларга икән таларга. Безгә бит композиторлар кирәкми, талаучылар кирәк. Әллә без бүтәннәрдән кимме.

Фәһим. Мин талый белмим. Минем бармакларым кесәгә керер өчен жайлашмаган.

Рәфис. Жайлашырлар. Дөнья өйрәтә ул. Миләүшәсе утыра анда бикләнеп. Берәүне дә күрәсем килми дигән булып...

Эльмира. Мин аңа шалтыраткан идем, нинидер Галимулла сөйләште. Миләүшә трубканы алмый, ди.

Рәфис. Ә мине өенә дә кертмәде. Үпкәләгән, күрәсең. Үпкәләрлек тә... Больницада ятып чыкканын да белмәдек.

Фәһим. Миләүшәме?

Рәфис. Миләүшә шул. Малай башка сугып искә төшерде. Дуслар идегез, ди. Чыннан да, дуслар идек бит. Әйдәле, Фәһим, тор, юын, кырын. Берәр нәрсә уйлап чыгарыйк әле. Оят булып китте. Әйдәле, тор әле. *(Фәһимне куллрыннан тартып торгыза.)*

**Ут сүнә. Ул Миләүшәләр фатирын яктырта.**

Галимулла. Миләүшә, бер сүз сорасам, ачуланмыйсыңмы?

Миләүшә. Бик кызык... Ашыйсың киләдер инде синең.

Галимулла. Ашыйсы килсә, пешерәбез дә ашыйбыз аны, Миләүшә брат.

Миләүшә. Ничек диден, Галимулла? Миләүшә брат. Искиткеч! Син миңа шулай гына эндәш, ярыймы.

Галимулла. Эндәшәбез аны, нигә. Мин бит, Миләүшә, авылда яшим дигәч тә мокыт түгел. Боегып та яшәмим. Көләсен көләм, жырлыйсын жырлыйм.

Миләүшә. Чыннан да, мине көтеп өйләнмәдеңме син, Галимулла?

Галимулла. Көтмәдем. Җуләр түгел ич мин булмаганны көтәргә. Бүтән белән өйләнсәм дә тора алмый идем. Нигә кешене бәхетсез итәргә.

Миләүшә. Берәр хат язып салсаң шунда.

Галимулла. Баштарак яздым, җавап килмәде. Аннары инде аңладым.

Миләүшә. Әшәке шул мин. Шулаймы?

Галимулла. Андый сүз әйтмә. Ямьсез сүз.

Миләүшә. Аның каравы дөрес.

Галимулла. Түгел. Билгеле инде, фәрештә дип тә әйтеп булмый инде. Җайсыз кеше син.

Миләүшә. Ничек, ничек?

Галимулла. Җайсыз, көйсез. Ләкин аңа син гаепле дә түгел инде. Талантлы кешеләр җайсыз булалар алар. Безнең авылның Рәшитне онытмадың микән. Балта остасы. Аның кебек оста дөньяда юк. Ә шуны көйли алмый җан чыга. Әнә бит үйнаучылар скрипкәне дә күпме көйлиләр. Шулай ул, Миләүшә брат.

Миләүшә. *(куанып)* Сөйлә, сөйлә, туктама, Галимулла.

Галимулла. Авыл мужигыннан нинди сүзләр чыга дисеңме?

Миләүшә. Нигә инде син, Галимулла?

Галимулла. *(Миләүшә янына тезләнеп аңа карап тора)* Шулай, Миләүшә брат. Очраштык диген?

Миләүшә. Соңладым шул.

Галимулла. Зыян юк. Терелтәм мин сине. Мин дә бит үҗәт кеше, Миләүшә. Көттем. Күңелем сиздә. Мине эзләп табаячагыңны сиздем.

Миләүшә (кинәт кенә) Галимулла, син нинди төсне ошатасың?

Галимулла. Нигә?

Миләүшә. Сорауны мин генә бирәм. Син, Галимулла, уйлап-нитеп тормыйча җавап бир. Килештекме?

Галимулла. Карап карыйк. Уенмы?

Миләүшә. Уен. Димәк, нинди төсне ошатасың?

Галимулла. Ак белән яшел.

Миләүшә. Кайсы ризыкны яратасың?

Галимулла. Пичкә тәгәрәткән бәрәңге.

Миләүшә. Нинди кешеләр күбрәк ошый?

Галимулла. Сабыр итә белүчеләр.

Миләүшә. Ниндиләрен яратмыйсың?

Галимулла. Кешеләрне каргаган кешеләрне.

Миләүшә. Төнне яратасыңмы, көнneме?

Галимулла. Таң аткан чакны.

Миләүшә. Йөрәгенә ышанасыңмы, башыңамы?

Галимулла. Йөрәк ышанычлырак.

Миләүшә. Кайсы яхшы: җәйме, кышмы?

Галимулла. Көз.

Миләүшә. Әчене яратасыңмы, төчене ме?

Галимулла. Сине.

Миләүшә. Ә син шаярма.

Галимулла. Шаярмыйм. Сине генә яратам. Бары тик сине генә. Һәм үткәннәр өчен сине гаепләмим. Үпкәм дә, рәнҗүем дә юк, Миләүшә. Язмыш. Ходай мине сиңа тиң итеп яратмаган. Ә үзе сине яраттырган. Син өстә, мин түбәндә. Йөрәк шуны аңламый интегә. Синең бер җырың бар иде. Егерме еллар элек җырлый идең. Авыл көенә. Мин җырларга тиешле җырны син җырлый идең.

Һай, җаныем, син бит миңа,
Син бит миңа тиң түгел.
Тиң түгеллеген дә беләм,
Өзелеп сөя яшь күңел.

Миләүшә. Хәтерләмим дә инде.

Галимулла. Җырчының җырын җырлаучы үзе хәтерләми инде. Тыңлаучы хәтерли аны.

Миләүшә. Галимулла, бәгырькәем... Син чынлап та тракторист идеңме? Гафу ит, зинһар. Мыскыл итеп әйтүем түгел.

Галимулла. Мыскыл иткәнгә дә түзәбез. Безне бит мыскыл итмәгән кеше юк. Без үстергән икмәкне ашый-ашый безне мыскыл итәләр. Зыян юк, Миләүшә. Аның каравы... Юк, ярый инде.

Миләүшә. Сөйлә инде, Галимулла.

Галимулла. Юк, кирәкми.

Миләүшә. Үтенеп сорыйм.

Галимулла. Юк, әллә нәрсә сөйләмим инде. Төнге сменада эшләргә ярата идем мин. Әллә нинди акыллы уйлар килә төнлә. Көндез баш эшләми. Төнлә баштагы шарикларны чистартып куялармы. Кайвакыт шулай айлы төндә барасың айга каршы, нинди генә уйлар килми. Менә ул уйларны язып баручы машина булса иде ул. Беләсеңме, Миләүшә, ай минем өчен кояшка караганда кадерлерәк. Кояш, билгеле, кирәгрәк. Кояш булмаса, җир дә, ай да булмый. Ә ай менә күңелгә якынрак. Кояшка бит туры да карап булмый, күзне чагылдыра. Ай андый түгел. Ай белән күзгә күз карап сөйләшеп була, аңа җаныңны ачып күрсәтергә була. Серләреңне аңа сөйләгәч, ничектер җиңеләеп китәсең. Сөйләр сүзләрем күп иде минем. Бик күп иде. Кешеләргә сөйләргә курыктым.

Алмачылар алма сата,
Алма яшнигә белән.
Тиң түгеллеген дә беләм,
Сөйдем яшьлегем белән.

Миләүшә. Галимулла... син мине кичерә күр инде. Мин сине оныткан ук идем бит. Әле дә ярый төшемә керден. Менә хәзер бөтен гомерем искә төшә. Киләчәк турында инде мин уйлый алмыйм, дөнья белән мине бары үткәннәр генә бәйләп тора. Ничаклы үкенеч, яңадан барысын да кире кайтарып яшәп булмый шул. Әмма миңа бүген җиңел. Җаным тормышның чүп-чарларыннан арынып калды. Даны да, шөһрәте дә, сәясәте дә, сәяхәте дә — берсе дә кирәкми инде миңа. Миңа бары тик мөмкин булганча аруланып кына китәргә кирәк. Күпме гөнаһ җыелган. Гөнаһларымның беразын гына кичер дип ходайга ялварыр идем, бер

генә дога да белмим. Догасыз калган буын. Тәһарәтсез буын.

Галимулла. Алай димә, Миләүшә. Күпме кеше сиңа рәхмәт әйтте.

Миләүшә. Кем? Кем әйтте, Галимулла?

Галимулла. Синең җырлавыңны тыңлаганнан соң бик күпләр рәхмәт укый иде.

Миләүшә. Алдама. Ичмасам, син алдама инде, Галимулла?

Галимулла. Мин үзем дә...

Миләүшә. Син миңа ләгънәт укырга тиеш идең.

Галимулла. Нигә мине яратмаган өчен мин сиңа ләгънәт укырга тиеш.

Миләүшә. Ә бәлки, яратып та хыянәт иткәнмендер. Көтүче Әһлиулла малае Галимулланы председатель Харис кызы Миләүшә тиң күрмәгәндер. Яратмаска үзен үзе мәҗбүр иткәндер. Мәхәббәтен таптап үтеп данга ирешеп бәхетле буласы килгәндер. Һәм менә дөнья куласасында әйләнә торгач, янадан шул Бакалы күл янына килеп төшкәндер. Менә бу өстәлнең тартмасында, Галимулла, конверт бар. Анда минем васыятем язылган. Зинһар, төгәл үтә. Хәзер бит кешенең исән чагында — фикеренә, үлгәч васыятенә колак салмыйлар. Үтенеп сорыйм: авылга алып кайт, әти белән әниемнең аяк очларына җирлә. Хәзер үк алып кит дип әйтер идем, беренчедән, барыбер исән-сау кайтып җитә алмыйм, икенчедән, гайбәтчеләрне бәхетле итәсем килми.

Галимулла. Үлем турында сөйләшмибез, дидең бит.

Миләүшә. Әйтеп калдырасы сүзләремне әйтәм дә туктыйм... Мине авылча итеп җирләгез, ярыймы? Бөтен йолаларын китереп.

Галимулла. Кабернең тирәнлеген ничә метр итәргә?

Миләүшә. Ничек инде ничә метр?

Галимулла. Сине күмәчәк каберне ничә метр итеп казырга?

Миләүшә. Син ни сөйлисең, Галимулла?

Галимулла. Шуны сөйлим. Син сөйләгәнне сөйлим. Нигә син һаман... саен... Мин монда кабер казырга килмәдем ләбаса.

Миләүшә. Ә син миңа нигә кычкырасың?

Галимулла. Мин кычкырмыйм...

Миләүшә. Кычкырасың. Бар кайтып кит.

Галимулла. Әллә китмәс дисеңме? Минем дә үз акылым үзем белән.

Миләүшә. *(Озын паузадан соң)* Үпкәләдеңме, Галимулла?

Галимулла. Юк.

Миләүшә. Нигә алайса бер сүз дә дәшмисен?.. Тукта... Тукта... Таныш сүзләр бит болар. *(Хәтерләргә тырышып)* Нигә алайса... бер сүз дә... дәшмисең... Бу сүзләрне кайчандыр мин сиңа әйткән идем ич. Әйе, әйе, авылдан китәсе көннең алдагы кичендә... «Әллә үпкәләдеңме, Галимулла?»

Галимулла. Юк.

Миләүшә. Нигә алайса бер сүз дә дәшмисең?

Галимулла. Нәрсә дип дәшим.

Миләүшә. Мин сине сагынырмын диген. Син мине сагынырсыңмы дип сора.

Галимулла. Сагынмасыңны беләм ич мин.

Миләүшә. Каян беләсең?

Галимулла. Беләм инде. Син сагына белмисең.

Миләүшә. Ничек инде белмим?

Галимулла. Син ярата белмисең. Ярата белмәгән кеше сагына да белми.

Миләүшә. Менә сиңа кирәк булса. Я әйтеп бетер инде, әйтеп бетер.

Галимулла. Син үзеңне генә яратасың. Үзен күп яраткан кеше бүтәннәрне ярата белми.

Миләүшә. Әбүгалисина булдыңмыни? Бөтенесен дә белеп торасың. Шуларны әйтергә дип мине озатып килдеңмени? Бар кайтып кит.

Галимулла. Сау бул.

Миләүшә. Әллә чынлап китәсеңме?

Галимулла. Кугач нишлим.

Миләүшә. Бигрәк. Бер сүз дә әйтергә ярамый. Үзе әллә ниләр әйтә дә. Ярата белмисең, имеш. Син үзең беләсеңме соң? Мин иртәгә китәм. Сагынырмын дип тә әйтми. Кочакламый да. Сагынырсың әле, мин булмам. *(Галимуллага карап)* Нишлисең, ә? Әллә җылый инде. *(Көлеп)* Әй, бәби, бәби... Егет башыннан җылап тора. Мин дә җылыйммы, Галимулла... *(Борылып киткән Галимулланың каршына чыгып муенына сарыла)* Китмә, китмә, Галимулла. Мин сине сагынырмын, Галимулла. Яратам бит мин сине, Галимулла. Әйт бер сүз, китмә, Миләүшә, диген. Мин синең яныңда калам.

Галимулла. Әтиең сине барыбер җибәрә.

Миләүшә. Ә мин аны тыңламыйм.

Галимулла. Сиңа авылда калырга ярамый диделәр.

Миләүшә. Мин сине барыбер дә сагынырмын.

Галимулла. Мин дә... Мин дә сагынырмын, Миләүшә. *(Каяндыр ерактан төрле яклардан җыр яңгырый. Миләүшә белән Галимулла җырның каян ишетелгәнен эзлиләр.)*

Кош булып күккә очарсың,
Очарсың — кагынырсың,
Утлар булып учакларда
Үрләрсең — кабынырсың.
Яратсаң сагынырсың,
Яратсаң сагынырсың.
Күбәләкләр генә булып
Гөлләргә кагылырсың,
Таңда искән җилләр булып
Талларга сарылырсың.
Яратсаң сагынырсың,
Яратсаң сагынырсың.
Оныттым дип юанырсың,
Югалып табылырсың,
Исемнәрен йөрәгеңә
Уярсың — табынырсың.
Яратсаң сагынырсың,
Яратсаң сагынырсың.

Миләүшә. Гафу ит син мине, Галимулла. Кичерә алсаң, кичер.

Галимулла. Ни өчен, Миләүшә?

Миләүшә. Барысы, барысы өчен дә. Син белгән һәм син белмәгән гөнаһларым өчен.

Галимулла. Гөнаһларыбызны бер ходай гына кичерә.

Миләүшә. Кичерер микән, Галимулла?..

Галимулла. Юк, юк синең гөнаһларың, Миләүшә. Күңелеңдәге моңын кешеләргә өләшкән кеше ничек гөнаһлы булсын. Кешеләргә матурлык бүләк итүче гөнаһлы була ала димени.

Миләүшә. Әкрен, Галимулла. Кешеләр ишетеп шаркылдап көлмәсеннәр.

Галимулла. Акыллылар көлмәс. Ә акыллылар бар әле бу дөньяда.

Миләүшә. Бу дөньяда шулайдыр, ләкин мин инде бу дөньяда түгел.

*Пәрдә*

# Икенче пәрдә

**Шәһитнең остаханәсе. Мольбертта Миләүшәнең язылып ята торган портреты. Шәһит, уйланып, шул портрет каршында утыра. Ишектә звонок. Шәһит ишетсә дә башта ишекне ачарга җыенмый. Звонок кабатлана. Шәһит портретны киндер белән каплый да ишекне ача. Рәфис белән Фәһим керәләр. Шәһит аларның килүенә сөенмәгән. Гаҗәпләнебрәк калган.**

Рәфис. Очрашкач исәнләшергә кирәктер инде, әйеме Шәһит Фәйзрахманович. Исәнмесез-саумысыз, Шәһит Фәйзрахманович.

Шәһит. Исәнмесез.

Рәфис. Түргә узырга чакырмыйсыз әллә, Шәһит Фәйзрахманович. Әллә комачауладыкмы?

Шәһит. Әйе.

Рәфис. Шундый инде без. Гомеребез буе эшләгән кешеләргә комачаулап йөрибез. Әйеме, Шәһит Фәйзрахманович?

Шәһит. Әйе.

Рәфис. Ә бит кайчандыр аерылмас дуслар идек, әйеме Шәһит Фәйзрахманович?

Шәһит. Әйе.

Рәфис. Шуннан син бездән аерылдың.

Шәһит. Әйе.

Рәфис. Кемнәр иде әле безнең компаниядә? Син, без икәү, Нурислам. Тагын кем әле?

Шәһит. Сезгә ни кирәк?

Рәфис. Ачуыңны китерә башладык, әйеме?

Шәһит. Әйе.

Рәфис. Гафу, гафу... Без сиңа куанычлы хәбәр алып килдек бит әле.

Фәһим. Рәфис, тукта...

Рәфис. Шәһит ул ни җитте кеше түгел, салып җибәрергә дә күп сорамас дисеңме? Ярый, алайса, кан коюларсыз гына сөйләшәбез. Сез ничек уйлыйсыз, Шәһит Фәйзрахманович?

Шәһит. Шулай уйлыйм.

Рәфис. Безнең Миләүшә исемле дустыбыз бар иде. Безнең арада хатын-кыз затыннан булган берләнбер җан иясе иде. Без барыбыз да аңа гашыйк идек. Ләкин син алданрак өлгереп, аны бездән тартып алып хатын иттең, икегезне ике якка тормыш дулкыны какты. Һәм син рәхәтләнеп, тынычланып калдың, әйеме?

Шәһит. Әйе.

Фәһим. Җитте! Мин мондый сөйләшүне тыңлый алмыйм.

Рәфис. Курыкма, Фәһим. Без бит яратып кына шулай.

Фәһим. Алайса, миннән башка гына яратышыгыз. Шәһит, гафу ит. Рәфисне син беләсең инде. Шундый инде ул.

Шәһит. Әйе, шундый.

Рәфис. Нинди?

Шәһит. Шундый. Ә хәзер сау булыгыз, минем эшем бар.

Рәфис. Тагын бер лауреат буласың киләме?

Шәһит. Тагын бер лауреат буласым килә.

Рәфис. Болай да инде синең картиналар белән дөнья тулган.

Шәһит. Хәзер синең өчен эшлим.

Рәфис. Менә монысын шәп әйттең. Бир бишне.

Шәһит. *(Кулын сузып)* Мә.

Рәфис. Кулың көчле.

Шәһит. Синең ише әтәчләр белән генә сөйләшә алабыз әле.

Фәһим. Йә, булды, булды, егетләр. *(Кулларын аера)* Хәлләр ничек соң, Шәһит?

Шәһит. Сез нәрсә, минем хәлемне белергә килдегезме? Әллә бүтән бер йомышыгыз бармы? Хәлемне белергә килсәгез, өйгә рәхим итегез. Монда минем эш урыным, монда мин эшлим.

Фәһим. Кыланма инде, Шәһит. Бүгенге заманда эш эшләп буламыни?

Шәһит. Заманга ни булган?

Фәһим. Ахырзаман бит.

Шәһит. Булса ни. Эшлик әле, бәлки, башына караганда ахыры хәерлерәктер.

Фәһим. Ярый да эшләгән эшегезнең кемгә дә булса кирәге чыкса.

Шәһит. Анысын бүтәннәр әйтер. Әлегә алар минем үземә кирәк.

Рәфис. Үз рәхәтем рәхәт!..

Шәһит. Әйе.

Рәфис. Эшлә инде алайса, эшлә... Ә без менә гуляйт итеп йөрибез.

Шәһит. Итегез.

Рәфис. Безнең белән барасыңмы?

Шәһит. Юк.

Рәфис. Кая икәнен әйтмәдем ич әле.

Шәһит. Минем өчен барыбер.

Рәфис. Без Миләүшә янына барабыз.

Шәһит. Барыгыз.

Рәфис. Без барыбыз да анарда җыелырга сөйләштек.

Шәһит. Җыелыгыз.

Рәфис. Миләүшә сине сораса, ни дип әйтик?

Шәһит. Хушыгыз.

Рәфис. Сорауга җавап бирмәдең.

Шәһит. Хушыгыз.

Фәһим. Шәһит. Миләүшә...

Рәфис. Май кап. Шулай диярбез. Хушыгыз дип әйтте диярбез. Хушыгыз, Шәһит Фәйзрахманович.

Күгәрчен гөрлидер
Баласын уйнатырга:
Әле дә ярый дусларым бар
Күңелне юатырга.

Дуслар диген... Дусларым дус ишләрем... Килгән килгән эшләгән эшегезне дә күрсәтегез инде. Нинди биеклекләргә ирештегез икән. *(Мольберт янына бара.)*

Шәһит. *(Юлына аркылы төшеп)* Якын киләсе булма.

Рәфис. Ярамыймыни?

Шәһит. *(Усал)* Ярамый. Барыгыз, чыгып китегез.

Рәфис. Әллә шаярып сөйләшкәнне дә аңламый башладыңмы?

Шәһит. Аңламыйм.

Рәфис. Хуш алайса. Киттек, Фәһим. Килергә уйласаң, Миләүшәнең адресы шул ук. *(Чыгып китәләр. Шәһит мольберттагы портретны ачып «Миләүшә»гә карап тора. Ут сүнә.)*

**Миләүшә фатиры. Галимулла Миләүшә бүлмәсенең ишегенә карап тора.**

Миләүшә. *(Ишектән башын тыгып)* Хәзер, хәзер, Галимулла. Бизәнмичә сәхнәгә чыгарга ярамый. Кием дә сайлыйсы бар. Аз гына көт. *(Югала. Бераздан халат киеп, кулына бер чәчәкле күлмәк тотып чыга.)* Галимулла, таныйсыңмы? Бу нәрсә?

Галимулла. Синең күлмәгең.

Миләүшә. Әлбәттә, минеке. Хәтерлисеңме, кайчан кигән идем мин аны?

Галимулла. Киткәндә.

Миләүшә. Ә мин аны сакладым. Мин әпчи карчыклар шикелле бит, Галимулла. Мин бөтенесен дә саклыйм. Син дә саклап|ларсың аларны, ярыймы? Кара нинди булганмын, әйеме? Бу миңа сыймый да инде хәзер.

Галимулла. Син үзгәрмәгәнсең. Киткәндәге шикелле.

Миләүшә. Ну, Галимулла! Кара нинди комплементлар әйтәсең. Үзгәрдем, Галимулла. Әле дә ярый үзгәргәнмен. Югыйсә, адәм көлкесе булыр идем.

Галимулла. Ә син киеп кара ул күлмәкне.

Миләүшә. Юк, Галимулла, юк. Мин хәзер бүтән бер күлмәк киеп чыгам. Мин бик тиз. Сәхнә артында артистлар бик тиз киенәләр алар. Син әзер булып тор, ярыймы. *(Галимулланың ос-башына карап)* Юк, болай бармый. Миләүшә Нигъмәтҗанова концертын алып баручы болай булырга тиеш түгел. Хәзер. *(Грим савыты алып чыгып Галимулла битенә грим сала. Галимуллага бу уен ошый, авызын ерып елмаеп кына тора. Миләүшә грим салып бетерә дә сокланып Галимуллага карый)* Менә ичмасам бу конферансье. Хәзер сиңа бабочка да кирәк бит инде. Хәзер табабыз аны. *(Бер ялык алып чыгып Галимулланың муенына бәйли)* Карале көзгегә, ничек?

Галимулла. *(Көзгегә карап)* Председатель Гыймадиев күрсә ни әйтер иде икән. *(Артист булып кыланып)* Хөрмәтле тамашачылар!..

Миләүшә. Искиткеч! Алайса, син репетиция ясый тор. Мин хәзер киенеп чыгам.

Галимулла. *(Уен белән мавыгып китеп, көзге каршында әйләнгәли)* Хөрмәтле тамашачылар! Хәзер сезнең алдыгызда мәхшүр җырчыбыз...

Миләүшә. *(Ишектән күренеп)* Беренчедән мәхшүр түгел, мәшһүр. Икенчедән, бернинди мәшһүр дә кирәкми. Миләүшә Нигъмәтҗанова гына.

Галимулла. Өйрәтмәвегезне сорыйбыз. Хөрмәтле тамашачылар! Хәзер сезнең алдыгызда мәшһүр җырчылар арасында иң мәшһүре Миләүшә Нигъмәтҗанова җырлый *(Миләүшә бүлмәсенең ишеге янына килеп)* Миләүшә, хәзер оваларны әйтеп тормыйлар бит. Миләүшә Нигъмәтҗан дип әйтимме?

Миләүшә. Теләсәң нишлә. Барыбер мин әйткәнне тыйламыйсың.

Галимулла. Чыгасыңмы?

Миләүшә. Әйдә.

Галимулла. Хөрмәтле тамашачылар! Җырлый Миләүшә.

Миләүшә. *(Чыгып тамашачыларга баш ия. Галимуллага)* Нигә кул чапмыйсың?

Галимулла. *(Кул чаба)* Миләүшә сезгә «Тургай җыры»н башкара. *(Магнитофонны кабыза. Анда Миләүшәнең спектакль башында үзе генә тыңлап утырган җыры яңгырый. Җыр беткәч, Галимулла магнитофонны туктата да кул чаба).* Магнитофонсыз гына җырла әле, Миләүшә.

Миләүшә. Юк, Галимулла. Булдырып булмый инде. Телисеңме, мин сиңа үзем язган шигырьне сөйлим. Тик көлмә, ярыймы.

Галимулла. Хөрмәтле тамашачылар! Хәзер сезгә Миләүшә Нигъмәтҗан шигырь сөйли.

Миләүшә.

Мактанма яшьлегең белән,
Бездән үткән яшьлек ул —
Төшләрне төшләргә куеп
Без дә ул сөйләштек ул.
Мактанма яшьлегең белән,
Салма йөрәккә яра.
Менә минем яшькә җиткәч
Бер гашыйк булып кара.

Шәп бит, әйеме, Галимулла, мин язган шигырь?

Галимулла. Шәпнең аръягында аягын салындырып утыра.

Миләүшә. Шулай ул Миләүшә апаң. Шундый ул. Кемгә гашыйк булдың дип нигә сорамыйсың?

Галимулла. Кемгә булсын, минадыр инде.

Миләүшә. Мактанчык син, Галимулла. Ә син нигә минем күлмәккә сокланмыйсың? *(Күлмәген Галимуллага күрсәтеп)* Сәхнәгә беренче тапкыр киеп чыккан күлмәгем. Бүгенгедәй хәтеремдә, сәхнә артында дерелдәп басып торам. Юк, сәхнәгә чыкканым бар иде инде. Җырлаганым да, кул чапканда баш игәнем дә бар иде. Ләкин бу бит, беләсеңме, профессионал җырчы буларак

чыгуым. Зур концерт. Кемнәр генә юк анда. Күз алдына китерәсенме? Куркасыңмы, диләр. Куркам дип әйтергә телем әйләнми. Баш кагып кына җавап бирдем. Курыкма, диләр, бу дөньяда миннән дә көчле җырчы юк дип уйла, диләр. Әйтүе генә җиңел. Җырның да бит әле, җүләр түгел диген, ниндиен сайлаганмын. «Тәфтиләү» *(Әкрен генә «Тәфтиләү» җыгырый башлый)* Фамилиямне әйттеләр. Чыгып киттем сәхнәгә. Юк, чыгып киттем, дип хәзер генә әйтәм, чыкканымны хәтерләмим дә. Җырлаганымны да хәтерләмим. Сәхнә артына чыккач кына исемә килдем. Кемнәрдер котлый. Кемдер әле колагыма пышылдый, кемнеңдер борынына чирттең, ди. Юк, мин берәүнең дә борынына чиртергә теләмәдем. Минем бары тик җырлыйсым гына килде. Син халыкка хезмәт итәргә тиеш диләр. Мин аңламыйм, нинди халыкка. Ни өчен хезмәт итәргә тиеш. Минем җырлыйсым гына килә, бары тик җырлыйсым гына килә. Хезмәт итү бит ул икенче төрлерәк буладыр. Халыкка хезмәт итәргә тиеш дигәнне миңа бүтәннәр дә бик күп тапкырлар әйттеләр. Мин бары тик җырладым гына. Миңа кул чаптылар, чәчәкләргә күмделәр, рәхмәт укыдылар. Халыкка хезмәт итүнең ни икәнен мин соңыннан гына аңладым. Җырлаудан туктагач кына аңладым. Чөнки минем беркемгә дә кирәгем юк иде. Күпләр танымадылар. Таныганнары гайбәтемне саттылар. Әгәр дә җанымны кисәкли-кисәкли телгәләп җырламыйча, хезмәт кенә иткән булсам, бу чаклы ук авыр булмаган булыр иде. Юк, Галимулла бәгырькәем, мин беркемне дә гаепләмим, язмышыма гына үпкәлим. Нигә, нигә кирәк иде.

Очты дөнья читлегеннән,
гарсынып күңелем кошы,
Шат яратса да җиһанга,
ят яраткан раббысы.

Нигә соң мин беренче җырым итеп шушы җырны сайладым. Аны бит миннән яхшы җырлаучылар бар иде. Ләкин минем намусым чиста, вөҗданым саф, Галимулла. Мин җырыма хыянәт итмәдем. Мин беркемгә дә хыянәт итмәдем. Мин бары тик беренче мәхәббәтемә, сиңа гына хыянәт иттем. Анысын да үзем аңлап түгел. Гафу ит мин тиленe, Галимулла. *(Галимулла каршына тезләнә.)*

Галимулла. Миләүшә...

Миләүшә. Син мине гафу итәсенме, Галимулла?

Галимулла. Минем алда бер гаебең дә юк, Миләүшә.

Миләүшә. Алдашма, Галимулла. Минем дусларым болай да гомер буе алдаштылар. Мин дә алар белән бергә алдаштым. Син алдашма. Болай да дөнья тулы ялган. Безне бай дип сөйлиләр, безнең сәхнәгә тагып, асып чыккан тәтиләрне алтын дип уйлыйлар. Алар да ялган. Бөтенесе ялган. *(Хәле бетеп, туктап кала)* Галимулла, мин тора алмыйм. Ярдәм ит. *(Галимулланың кулларына тотынып тора)* Галимулла, кертеп яткыр мине үз бүлмәмә. *(Галимулла саклапып кына аны озата. Миләүшә туктап кала)* Галимулла, мин тамашачыларга баш имәдем бит әле. *(Залга карап башын ия)* Рәхмәт, хөрмәтле тамашачылар. Бәхетле булыгыз, улларыгыз, кызларыгыз тәүфыйклы булсын. Кул чабыгыз, хөрмәтле тамашачылар. Киттек, Галимулла.

**Ут сүнә. Ут янганда сәхнәдә Нурислам фатиры. Фатир хуҗасы өстәл тирәли үзенең автопортретларын тезеп куйган. Алар төрле жанрда, әмма ашык-пошык кына язылган. Һәр портрет алдына рюмка куелган. Үзенең кулында да рюмка.**

Нурислам *(тантаналы кыяфәт белән басып тора)* Рөхсәт итегез, хөрмәтле Нурисламнар, сезнең хөрмәткә шушы чәркәне күтәреп куярга. Тост кирәк дисезме? Әйтәбез аны. Бер урманның аланында пәриләр яши икән. Шул пәриләр һәр җомга саен туй ясыйлар икән. Туйда бөтенесе бергә «Чәршәмбе! Чәршәмбе!» дип биләр икән. Ни өчен эчәбез? Җомга көнне чәршәмбе дип кычкырган пәриләр өчен эчәбез. *(Эчеп куя)* Йә, ничек, иптәш Нурисламнар? Йә, хәзер кайсыгыз тост әйтә? *(Беренче портрет янына барып баса, тавышын үзгәртеп)* Миңа әйтергә рөхсәт итәсезме? Рәхмәт, рәхмәт, хөрмәтле иптәшләр. *(Түшен киереп җырлый)*

Илем минем — көрәш җиңү иле,
Башлап гадел дөнья төзүче.
Шушы көрәш, җиңү юлында без
Иң беренче булдык, беренче.

*(Кул чаба. Беренче портрет алдындагы рюмканы күтәреп эчә)* Молодец, Нурислам. Хәзер кайсыгызның чираты? *(Икенче портрет артына барып баса)* Мин?.. Ә нигә мин? Әйтергә була инде анысы. Ни инде... ярый инде... Соң инде... Була инде ул. Эчик инде... *(Эчеп куя да өченче портрет артына килеп баса)* Эчәсез, ә? Мин дә әйтәм. Әллә әйтмәс дип белдегезме? Гады вы! Барыгыз да сволочьлар! Мин сезне ненавижу! Сезнең барыгызны да берәм-берәм сытарга кирәк. Кандаланы сыткан кебек сытарга кирәк. Нәрсә карап торасыз? Әллә Нурисламны күргәнегез юкмы? Менә ул Нурислам. Сез Нурислам түгел. Сез гаунюклар! Сезнең белән эчмим дә мин. Үзем генә эчәм.

Эчеп җибәр салганны,
Сорама кайдан алганны.
Эчеп җибәрсәң салганны,
Баса йөрәк янганны.

*(Бер кулына портретны, икенчесенә рюмканы тотып бүлмә буйлап йөри. Ишектән кергән Фәһим белән Рәфисне күреп)* А-а-а, ахирләр! Ә сез нигә кеше өенә шакымыйча керәсез?

Рәфис. Ишегең шар ачык. Тавышың урамга ишетелә.

Нурислам. Чын кешеләрнең ишекләре ачык булырга тиеш. Сез генә ул барыгыз да кереп бикләндегез. Икешәр кат ишекләр куясыз, ә? Ә менә минем ишек ачык. Минем урлатырлык нәрсәм юк. Бер чебенем бар иде. Ашарына таба алмагач, ул да коридорга чыгып китте.

Рәфис. *(Портретларны карап)* Нәрсәләр бу?

Нурислам. Алар минем дуслар. *(Кулындагы портретны да тегеләре янына куеп)* Алар Нурисламнар. Менә дүрт Нурислам гулять итәбез. Менә бу Нурислам, философ, ни өчен пәриләр җомга көнне чәршәмбе дип кычкыралар дип баш вата, монысы мескен Нурислам, мокыт, монысы... Әйдә, утырыгыз безнең янга. Ләкин закуска юк. Чебен ашарлык та юк.

Рәфис. Син исерекме, Нурислам?

Нурислам. Мин һәрвакыт исерек *(Фәһимгә күрсәтеп)* Әнә ул һәрвакыт аек. *(Рюмкаларга аракы сала.)*

Рәфис. Туктале, Нурислам, сабыр ит әле.

Нурислам. Берәрне тотабыз, аннары сабыр итәм. *(Кулларына рюмка тоттыра)* Закускам юк, гафу итүегезне үтенәм. Йә, кадерле вә гыйззәтле вә хөрмәтле дуслар! Яшәсен Франция короле Людовик уналтынчының якты истәлеге.

Юллар да бер, уйлар да бер,
Теләкләр дә бер.
Дәрәҗәле итте безне
Данлыклы дәвер.

Ә сез нигә җырламыйсыз? Ничек, иптәш композитор, мин чыгарган көй? *(Рәфискә)* Мин язган шигырь ничек, иптәш бывший поэт?

Фәһим. Әйдә, Рәфис, киттек.

Нурислам *(шаркылдап көлеп)*. Куркасыз, ә? Алай-болай булса, Нурислам белән бергә безне дә алып китәрләр дип куркасыз?

Фәһим. Ахмак син.

Нурислам. Мин — ахмак *(портретларны күрсәтеп)* Алар кем?

Рәфис. Нурислам, җилкенмә, утыр әле.

Нурислам. Юк, башта сез әйтегез, сез акыллымы?

Рәфис. Без дә ахмак. Утыр әле син, сөйләшәсе бар.

Нурислам. Сөйләшәсе бар? Кызык? Утырабыз һәм тыңлыйбыз.

Рәфис. Син җитди итеп сөйләшерлек хәлдәме?

Нурислам. Сез ничек уйлыйсыз соң? Хәлдәме мин, хәлдә түгелме?

**(Портретларны җыеп алып бер читкә ыргыта) Ычкыныгыз моннан, комачаулыйсыз, алкоголизмның куркыныч чир икәнлеге турында лекция башлана.**

Рәфис. Ул турыда түгел. Миләүшә турында.

Нурислам. А-а-а, Милашка турында. Әллә янадан кавыштырасыз? Юк, барып чыкмаячак ниятегез. Закон нигезендә аерылыштык.

Саескан, саескан
Түшен түштән алышкан.
Ходай кушкан — аерылышкан,
Безгә кем икән дошман.

Салкын ул сезнең Миләүшәгез. Аны хәтта минем мәхәббәтем дә җылыта алмады. Йөрәге боз аның.

Рәфис. Миләүшә бик каты чирләп больницада ятып чыккан.

Нурислам *(Кинәт җитдиләнә. Паузадан соң)* Кайчан?

Рәфис. Өченче көн чыккан.

Нурислам. Ә нигә сез аны миңа әйтмәдегез?

Рәфис. Табып буламыни сине. Үзебез дә яңа белдек.

Нурислам. Нәрсә, йөрәкме?.. Хәзер хәле ничек?

Рәфис. Өенә кертмәде. Бикләнеп утыра.

Нурислам. Ни өчен?

Рәфис. Мин каян белим.

Фәһим. Берәүне дә күрәсем килми, дип әйтә ди.

Нурислам. Чираттагы капризы. Больницада ятканын әйтмәдегез, ә? Дуслар...

Рәфис. Барыйк бергәләп өенә.

Нурислам. Шуннан?..

Рәфис. Син булгач... Ул сине ярата.

Нурислам. Әйтмәгез әле шул сүзне. Ярата, ярата... Шул да булдымы сүз. Миләүшәнең больницага керүе — начар. Аның больницага кергәнен дә белмәү — дуңгызлык. Чыккач, нишләп йөрисең инде анда. Акланыр өченме?

Фәһим. Белергә кирәк иде инде.

Нурислам. Белергә? Белүдән ни файда. Больницага диген, ә? Аңлашыла. Шулай булырга тиеш тә иде ул. Арыган. Милашка да арыган. Ял итсен, тимәгез кешегә. Больницага кергәнен белмәү — дуңгызлык. *(Рюмкага аракы салып эчә)* Хәер, дуңгыз дуңгызлык кылырга тиеш тә инде ул. Дөньясы — дуңгыз абзары булгач...

Рәфис. Сал әле миңа да...

Нурислам *(бер рюмка салып, Фәһимгә)* Сиңа?

Фәһим. Юк, кирәкми.

Нурислам. Мәйлең. Әйтмәк бар бу дөньяда, көчләмәк юк. Көчләмәк бит, әйеме, кадерле дуслар? *(Эчеп куеп)* Сез, димәк, Миләүшә янына алып барырга кердегез?

Рәфис. Аптыраганнан инде. Таралыштык бит. Төрлебез төрле якка таралыштык. Җыеласы иде. Картаеп барабыз. Аерылмас дуслар идек. Нинди генә хәлләрдә дә бергә булырга сүзләр бирешкән идек.

Нурислам. Бирешкән идек... Алышкан идек...

Алган да ди салган ди,
Тагын алып салган ди,
Калганы чын ялган ди.

Фәһим. Нишлибез? Югыйсә, миңа өйгә кайтырга кирәк.

Нурислам. Миңа анда барырга ярамый. Мине бу кыяфәттә күрсә, Миләүшә шунда ук йөрәге ярылып үләчәк. Больницаны белмәү — дуңгызлык. *(Ут сүнә. Ут янганда Миләүшә фатирында Галимулла гына). (Рәфис, Фәһим, Нурислам керәләр).*

Рәфис. *(Галимуллага)* Кайда Миләүшә? *(Галимулла дәшмәгәч)* Нәрсә булды, нигә дәшмисез? *(Миләүшә булмәсенә үтмәкче була.)*

Галимулла *(аның юлына аркылы төшеп)*. Ярамый.

Рәфис. Нәрсә син, канса да кансов?

Галимулла. Миләүшә юк.

Нурислам *(ул шде исерек).* Миләүшә кайда?

Рәфис. Ахир. Сабыр. Туктагыз, әле, туктагыз. Сабыр гына, сабыр... *(Галимуллага)* Галимулла бит әле?.. Миләүшә кайда?

Галимулла. Ул юк.

Рәфис. Ю-ук? Ничек?

Галимулла. Шулай.

Фәһим. Сез чынлап сөйлисезме?

Нурислам. Кайда Милашка?

Рәфис *(Галимуллага).* Нигә анда керергә ярамый?

Галимулла. Сез Рәфис бит? *(Бер магнитофон кассетасын алып бирә)* Моны сезгә бирергә кушты. Менә бу язу да сезгә.

Рәфис *(язуны укыгач).* Кайчан язды?

Галимулла. Белмим. Мин килгәч тә бирде.

Фәһим. Нәрсә анда?

Рәфис. Мә, укы.

Нурислам. Нәрсә сез анда? Кайда Милашка? Дунгызлык...

Рәфис. *(Нурислам янына килеп, аның тәмам мәлҗегәнен күреп)* Хәзер, хәзер, ахир. Син утырып тор, ярыймы? *(Нурисламны җайлап утырта. Тегесе шуны гына көткәндәй йокыга да китә.)*

Фәһим. Инде нәрсә?

Рәфис. Галимулла туган... Нишлибез?

Галимулла. Мин аны иртәгә авылга алып кайтып китәм.

Рәфис. Димәк, безгә аны күрсәтмисең?

Галимулла. Анда ничек язылган — шулай.

Рәфис. Алай булмый бит инде ул. Туктале, нәрсәдер эшләргә кирәктер ич инде. *(Фәһимгә)* Бир әле язуны. *(Кабат язуны укып)* Саҗидә... Ни өчен Саҗидә? Берни аңламыйм. *(Фәһимгә)* Алайса мин Саҗидәне алып киләм... Безгә шалтырат әле, җыена торсын. *(Чыгып китә.)*

Фәһим *(телефоннан шалтыратып)* Саҗидә ханыммы? Фәһим бу. Миләүшәләр фатирыннан шалтыратам. Хәзер Рәфис кайта, киенеп урамга чыгып торыгыз. *(Трубканы куеп Галимуллага карап тора)* Безне күрергә теләмәгәнен теле белән дә әйттеме?

Галимулла. Нишләп инде миңа ышанмыйсыз?

Фәһим. Ачуланмагыз. *(Телефон шалтырый)* Сез алачсызмы?

Галимулла. *(Трубканы алып)* Әйе... Ул юк... Әйе, мин... Ул юк... Бүген... Әйе... *(Трубканы куеп)* Сез миңа үпкәли күрмәгез тагын. Мин сезнең көйләрне яратып тыңлый идем. Ләкин миңа Миләүшә үзе кушты. Кушканын үтәмәсәм, бәхил булмыйм диде. *(Миләүшә бүлмәсенең ишеге янына урындык алып барып шунда утыра. Ишекне ачып Миләүшәгә карап тора.)*

Фәһим *(телефоннан шалтырата)* Эльмира. Миләүшә вафат. Әйе, мин анда. Яхшы. *(Галимулла янына бара. Галимулла ишекне ябып куйгач)* Алай ярамый ич инде.

Галимулла. Үпкәләмәгез. Мин Миләүшәнең сүзеннән кире кайта алмыйм. Күзләрегез белән укыдыгыз. Кем ул теге исерек?

Фәһим. Нурислам...

Галимулла. Шәһит тә шалтыратты.

Фәһим. Сезгә карап торсаң, берни дә булмаган кебек. Шундый тыныч.

Галимулла. Тыныч булмый нишлисең. Әгәр дә Миләүшәне якын итсәгез, иртәгә машина табарга ярдәм итегез.

Фәһим. Машинадан башка да, әллә ничә справка кирәктер әле.

Галимулла. Аларны да карагыз инде.

Фәһим. Әллә ничек кенә булды бит әле бу. Димәк, сез?..

Галимулла. Әйе шул, Галимулла... Шул Галимулла... Шул да түгелдер инде.

Фәһим. Бәлки, ул исәндер.

Галимулла. Кем?

Фәһим. Миләүшә.

Галимулла. Ничек инде ул исәндер?

Фәһим. Миләүшә шаяртырга ярата иде. Кунакка дип барыбызны да чакыра иде дә үзе ишеген бикләп чыгып китә иде. Ишегенә, гафу итегез, мине кунакка чакырдылар, дип язу элеп китә иде. *(Ишектә звонок. Галимулла барып ача. Шәһит керә.)*

Шәһит. Дөресме?

Галимулла. Әйттем ич инде.

Шәһит. Үз бүлмәсендәме? *(Миләүшә бүлмәсенә юнәлә.)*

Галимулла *(аның юлын бүлеп)* Ярамый.

Шәһит. Туктагыз әле, ничек? Гафу итегез. *(Галимулланы читкә этеп үтмәкче була.)*

Галимулла *(Шәһитнең беләгеннән тотып)* Ярамый.

Шәһит. Җибәрегез кулны, авырттырасыз.

Фәһим. Ярамый диләр бит. Миләүшә язу калдырган. Мәете өстенә беребезгә дә керергә рөхсәт ителмәгән. Саҗидәгә генә рөхсәт ителгән.

Шәһит. Нинди Саҗидә?

Фәһим. Рәфис хатыны.

Шәһит. Ни өчен ул? Һәм нигә ул гына?

Фәһим. Белмибез. Әнә язуы өстәл өстендә.

Шәһит *(язуны алып укый)* Әйе, бу аның язуы. Ничек соң әле болай. *(Нурисламга күрсәтеп)* Ә бу нәрсә, исерекме? Нигә аны өенә алып кайтып ыргытмыйсыз? Нигә әле болай?..

Галимулла. Әкренрәк.

Шәһит. Мин аны күрергә тиеш.

Галимулла. Нишләтим соң мин.

Шәһит. Миләүшә еш кына үзенең ни эшләгәнен дә белми иде. Соңыннан үкенә иде. Бу язуны да ул кызып китеп, ниндидер бер депрессия вакытында язган булырга тиеш. Ничек инде ул берәүгә дә күрсәтмәскә? Алай булмый. Аның гәүдәсен театрга куярга кирәк, ул бит артистка, билгеле артистка, җырчы.

Галимулла. Ул үзен авылда җирләргә кушты.

Шәһит. Ничек инде авылда? Аңлыйсызмы, ул — артистка, танылган җырчы.

Галимулла. Беләм. Ләкин үзе кушты бит.

Шәһит. Ул ни әйтмәс? Кеше ни әйтмәс. Миләүшә кебек кешеләр... *(Ишектә звонок. Галимулла ача. Рәфис белән Саҗидә керәләр.)*

Рәфис. Нигә ул ишекне бикләп куясыз?

Сажидә *(кабаланып)* Кайда ул?

Галимулла. Сез Сажидәме?

Сажидә. Әйе лә инде. Менә сина кирәк булса. Кая, мондамы? *(Галимулла белән Миләүшә бүлмәсенә кереп китәләр. Шәһит тә иярмәкче була да, аны Фәһим туктата.)*

Фәһим. Әйткәнне аңламыйсыз мәллә?

Шәһит. Болай булмый бит.

Рәфис. Исән чакта кирәк иде. Нигә хәзер...

Шәһит *(аның каршына килеп)*. Син!.. Син нәрсә беләсең? *(Күз яшьләренә тыгылып, урындыкка утыра)* Их, Миләүшә... Нигә инде?.. *(Фәһим белән Рәфискә)* Их сез... Тәки башына җиттегез? Дуслар... *(Галимулла белән Сажидә Миләүшә бүлмәсеннән чыгалар)*.

Сажидә *(җылап)*. Йокыга киткән кебек кенә ята, бахыр.

Рәфис. Бәлки, йокыга гына киткәндер.

Сажидә. Мондый чакта нишлиләр соң әле. Мин бит рәтен дә белмим. Аны үзен генә яткырырга ярамыйдыр инде.

Галимулла. Без икәү.

Сажидә. Кара син, ә... Рәфис, авылга алып кайтам ди бит әле бу кеше. Рөстәмгә әйт, машина кирәктер. Ичмасам... йоклаган кебек ята. *(Галимуллага)* Әйдә, әйдә, ялгыз ятмасын. *(Галимулла белән кереп китәләр. Калганнар тын гына утыралар. Нурисламның гырлаганы гына ишетелә.)*

Шәһит *(Йөрәгенә чыдый алмый кычкырып)* Туктатыгыз шул хәшәрәтне.

**Ут сүнә. Ут янганда Рәфисләр фатиры. Анда Рәфис, Сажидә, Фәһим, Эльмира, Нурислам, Шәһит магнитофоннан Миләүшәне тыңлыйлар.**

Миләүшә тавышы: Исәнмесез, дусларым! Сезне күрергә һәм күренергә теләмәгән кешенең дусларым дип эндәшүе сәеррәк тоелса да, дусларым дим. Гомернең бик күп өлешен бергә уздырдык һәм бер-беребезгә дуслар дип эндәшә идек. Шәһит, әлбәттә, бездән аерылды. Хәер, анысын кем белә, бәлки ул түгел, без аңардан аерылганбыздыр. Һәрхәлдә, мин аны да дус дип саныйм. Яшьлегебез бар иде бит. Яшьлектә Шәһит бар иде. Аны ничек итеп сызып ташлыйсың. Бәлки, бу язманы ул тыңламас та. Очрашканда әйтегез, Миләүшә сина дустым дип эндәште, диегез. Дусларым, мин беләм — сезнең барыгызны да бер сорау борчый. Ни өчен Миләүшә соңгы көннәрендә безне күрергә һәм бу дөньядан киткәч тә күренергә теләмәде, диесездер. Аның әллә ни сере юк. Арыдым мин, дусларым. Туйдым. Дуслар булып, бер-беребезне алдашып яшәүдән туйдым. Беләм, без нинди дә явыз ният белән алдашмадык. Без үзебезнең булдыксызлыгыбызны, мәгънәсезлегебезне, куркаклыгыбызны, мескенлегебезне яшерер өчен алдаштык. Бер-беребезне мактадык. Заманында бер тапкыр дөреслекне әйтеп чистарынырга уйлаган идек тә тагын курыктык. Мин беребезне дә гаепләмим. Бәлки объектив сәбәпләр булгандыр. Безнең яшәвебез каһәр төшкән заманга туры килгәндер. Ләкин болай дип әйтү акланырга тырышу гына. Чын кеше, чын шәхес теләсә нинди шартларда да кеше булып калырга тиештер. Без кеше булып кала алмадык, үзебез була алмадык. Безнең арада үзе булып кала алган бердәнбер җан иясе — Сажидә. Аның гына эчендәге тышында иде. Чөнки ул... Юк, минем аңарга авыр сүз әйтәсем килми. Ул шулай булуы белән бәхетле дә. Мин Сажидә була алмаганыма үкенәм. Дусларым, сез мине барысы өчен дә кичерә алсагыз, кичерегез. Соңгы минутларымда үзем булып каласым килде. Үзем булып калырга сез комачаулый идегез. Алдаша башлый идек. Хәтта үле гәүдәмне күрсәгез дә алдаша идегез. Чөнки без алдашмыйча яши белми идек инде. Кичерегез. Арыдым мин, туйдым. Дөньясыннан, үземнән, сездән туйдым. Ярый әле, ходай миңа мәрхәмәтле булып терелә алмас авыру җибәрде. Югыйсә, яшәүдән дә туйган идем. Боларны мин бер ялгызым үз фатирымда утырганда яздым. Тулы акылымда. Авылдан Галимулланы чакыртып телеграмма суктым. Килсә, бу язманы сезгә ул бирер. Килмәсә, табып алырсыз, өстәлем тартмасында. Васыятемне әйтеп язу да язып калдырам, васыятемне төгәл үтәвегезне үтенәм. Зинһар өчен дип ялварам. Тагын бер кат үтенәм: зинһар өчен. Хушыгыз, дусларым. Хуш, Рәфис. Дөнья арбасы кай якка тәгәри — утыр да кит, егылып кына төшә күрмә. Сажидәңне култыклап утыр һәм сакла. Ул синең өчен генә туган хатын. Хушыгыз, Фәһим белән Эльмира! Эльмира, сакла Фәһимне. Аңа синең акылың җитми. Фәһим, ачуланма. Хушыгыз, Шәһит белән Нурислам. Мин сезнең хатыныгыз буларак, сезне бәхетле итә алмадым, ләкин сез дә бит мине бәхетле итә алмадыгыз. Бәхетсез илдә бәхетлеләр була алмый. Нурислам, үтенәм, эчмә. Күпме әйттем — үзеннән үзен эчеп кенә качып котылып булмый. Сүзләрем бетте, дусларым. Җырланмаган җырларым гына калды. Шуларның берсен җырлап калдырам. Тавышым юк инде, кичерегез. Элеккеге Миләүшә элеккегә тавышы белән җырлый дип кабул итегез.

Китәм инде, китәм инде,
Китсәм кайталмам инде.
Сынды сабыр канатларым —
Сабыр итәлмәм инде.

Китәм инде, китәм инде,
Китсәм кала шәлләрем.
Бер ходаем гына белә
Җаннарымның хәлләрен.

Китәм инде, китәм инде,
Кайтмаска китәм инде.
Сызланып янган шәмнәр кебек
Янып(л)ар бетәм инде.

Рәфис *(магнитофонны туктатып, паузадан соң)*. Менә шулай.

Шәһит *(урыныннан торып)*. Ярый, хушыгыз.

Рәфис. Кая ашыгасың?

Шәһит. Тыңладым, ишеттем, аңлашылды.

Рәфис. Бөтен нәрсәне бик тиз аңлыйсың да инде. Каян килгән мондый башлы кеше.

Шәһит. Нигә син миңа һаман саен бәйләнәсең?

Фәһим. Туктагыз әле, егетләр. Утыр әле, Шәһит. Бергә җыйналганбыз икән... Әллә тагын бергә җыелырбыз, әллә юк. Ичмасам, хушлашып аерылышыйк... Бүген беребез, иртәгә икенчебез...

Шәһит. Мина бәйләнмәслек булсагыз гына. Югыйсә, эчеп аласыз да мина бәйләнергә тотынасыз. Син фәлән идең, фәлән булдың. Миләүшә алдында минем намусым чиста. Әйе, бәхетле итә алмадым. Рәхмәт Миләүшәгә дә, дөресен әйтеп калдырган, ул да бәхетле итә алмады. Язмыш, күрәсең. Язмыш талантсыз художникны талантлы җырчы белән кавыштырган.

Рәфис. Ничек талантсыз?

Шәһит. Сез шулай дисез бит. Сез бит һәрвакытта да хаклы. Ярый, мин талантсыз ди, сез талантлылар. Менә барыбыз да ярык тагарак янында калдык.

Сажидә. Үзең бәйләнмәгез дисең, үзең бәйләнәсең. Утырыгыз әле матур гына итеп.

Нурислам. Ничек була ул матур гына утыру, Сажидә ханым?

Сажидә. Аерылган хатының үлгәндә исереп йоклап утыру кебек булмый.

Рәфис. Сажидә...

Сажидә. Кактырып-суктырып утырмасын.

Эльмира. Хәтерегездәме, Миләүшәнең беренче концертыннан соң җырлашып безгә кайткан идек. Барыбыз да яшьләр. Бөтенебездә дә чәчәкләр. Шатлыгыбыз эчебезгә сыймый. Мин әле сезнең компания белән яңа танышкан идем. Мина кызык. Иҗат кешеләре шулай җүләрсымак булалардыр инде дип аптырап утырдым. Ул хыяллар!.. Хыяллар!.. Кайсысы бөек художник, кайсысы мәшһүр шагыйрь, кайсы атаклы композитор...

Нурислам. Пшик килеп чыктымы?

Эльмира. Нурислам, кәефең булмаса дәшмә. Нигә инде?

Нурислам. Ялгыша Миләүшә. Без алдашмадык. Безне алдарга мәҗбүр иттеләр. Алдашмый яшәр өчен син яшәгән җәмгыятьнең дөреслеккә корылган булуы кирәк. Ә без ялганга, алдашуга корылган җәмгыятьтә үстек. Ялгыша Миләүшә. Ул һәрвакыт ялгышты. Нәрсә, шулай гына утырабызмыни? Татарча мескен булып яшәдек, поминканы да татарча гына үткәрәбезме?

Сажидә. Бу поминка түгел. Әллә оятсызланып эчеп утырыр идеңме?

Нурислам. Аек килеш оятсызланып утырганчы, эчеп оятсызлану әйбәтрәк, минемчә...

Фәһим. Нәрсә, Нурислам, эчмичә тора алмыйсызмыни?

Нурислам. Әйт әле үз гомереңдә берәр акыллы сүз.

Фәһим. Әгәр сөйләшү болай барса, без кайтып китәбез. Дәшми-тәшми торгач та. Һәрнәрсәнең чамасы бар.

Нурислам. Дөресен әйтеп сөйләшергә күшкан Миләүшә.

Рәфис. Чыннан да, егетләр. Әллә соң берәр чәркә тотып куябызмы?

Сажидә. Юк, рөхсәтем юк. Бу урыс өе түгел.

Нурислам. Татар өендә балалар татарча сөйләшкәннәр.

Сажидә. Минем улымда эшегез булмасын. Үзегезне тикшерегез. Икегезгә бер бала калдыра алмадыгыз. Миләүшә мескен ялгызлыктан тилмереп үлде. Гомерегез буе шулай булдыгыз. Аракыдан башка сөйләшә алмадыгыз. Шунарга күрә сезне күрәсе килмәде Миләүшәнең.

Рәфис. Булды, Сажидә, җитте.

Шәһит. Миләүшәнең пластинкалары бармы? Тыңлыйк әле шуларны.

Рәфис. Пластинкасы бар, радиола юк.

Нурислам. Сездә дә юк бер нәрсә бар икән. Бизнесменда шул да булмагач...

Рәфис. *(Нурисламга каршына очып барып)* Туктыйсыңмы син, юкмы? Болай да нервылар... Бер-беребезгә җылы сүзләр әйтәсе урынга. Кешенең үлеме дә тәэсир итми башладымы әллә? Бизнесмен, бизнесмен... Әйе, ташладым шигырь язуны, әйе, ташладым филологияне. Кемгә кирәк? Кемгә кирәк бүген шигырь! Кемгә кирәк синең рәсемнәрең? Шәһит рәсемнәре кемгә кирәк? Без беребез дә беркемгә кирәкмәдек тә, кирәкмибез дә. Эт оясы кыегына сандугач кунып сайрамый. Без пароходка ияреп очучы теләнче акчарлаклар гына. Хөкүмәткә кирәкме без? Ю-ук. Аңа чиновниклар кирәк. Барып кара берәр министрга, кабул итәрме ул сине. Әнә гәҗитләргә язып ярлы артистларның тишек кесәләрендә актарыналар, акчаларын саныйлар. Халыкка кирәкми? Кайда ул халык? Кәмит күрсәтмәсәң, сүгенеп театрыңны ташлап чыгып китә. Әнә китаплар, тау-тау өелеп ята, кем ала? Акчалары юкмы? Ә аракыны күпме бәягә алалар? Без беркемгә кирәкмибез. Миләүшәнең фаҗигасе бездә түгел, шунда. Безгә рәнҗемәде ул, әнә шул гаделсезлеккә рәнҗеп китте. Юк, мин алай булмыйм. Мин үземне рәнҗеттермим. Сезгә бизнесмен кирәкме, әфәнделәр? Рәхим итегез. Мин үземә алтын табут эшләтәчәкмен. Алтын табут эчендә елмаеп ятачакмын. Күрсеннәр ярлы шагыйрьгә кул бирергә оялганнар, табутым каршыннан баш иеп үтсеннәр. Ияселәре килмәсә идерерләр.

Сажидә. Рәфис, Рәфис, узынма.

Рәфис. Тик тор!.. Бизнесмен, имеш... Миләүшәне күреп калырга өегездән берәмләп җыеп йөрдем. Без барыбыз да моның өчен җавап бирәчәкбез. Язмышыбыз бездән сорау алачак һәм хөкемен чыгарачак. Без барыбыз да җинаятьчеләр. *(Нурисламга)* Син нәрсә әтәчләнәсең? Син беләсеңме кем? Бар чыгып кит өемнән. Эч тә әнә урам чатында ятып үл. Бик кызганырлар. Хахылдап көләрләр.

Эльмира. Рәфис!.. Рәфис, кирәкми.

Рәфис. Гафу ит, Эльмира. *(Тыела алмыйча җылый башлый)* Гафу ит, Миләүшә җанкисәгем. Безне оештырып торучы син бар идең. Синең янында бер юаныч таба идек. *(Урыныннан торып ишеккә таба баручы Нурисламның изүеннән эләктереп алып)* Кая барасың? Мин сине менә шушы кулларым белән буып үтерәм. *(Шәһит белән Фәһим аларның араларына төшеп аералар.)*

Сажидә. Рәфис, җаным, Рәфис, йә инде. *(Рәфисне кочаклап тынычландыра.)*

Рәфис. Без барыбыз да мескеннәр. Халкың мескен хәлдә калдырылгач, аның талантлы балалары да мескен була инде.

Эльмира. Гаепләмә халыкны! Гаепләмәгез халыкны!

Рәфис. Мин гаепләмим. Мин аны кызганам гына.

Эльмира. Кызганмагыз да. Ул аңа мохтаҗ түгел.

Рәфис. Кызганам. Чөнки ул үз кадерен үзе белмәде, белми һәм белмәячәк.

Фәһим. Тынычлан, Рәфис. Нигә кирәк инде болар?

Рәфис. Кирәкмимени? Нигә мәете өстенә дә кертмәде соң Миләүшә? Сезнең өчен, бәлки, бу бер мәзәк кенәдер. Минем өчен моңардан да зуррак фаҗиганең булуы мөмкин түгел. Безнең бәябез шуның гына хәтле.

Шәһит. Башлагансың икән, әйдә бу мәсьәләгә нокта куйыйк. Үзебезгә хөкем карары чыгарырга ашыкмыйк. Әлбәттә, беребез дә әүлия түгел. Начар якка үзгәргәнбез. Ләкин Миләүшә мәсьәләсендә бөтен гаепне безгә генә сылтау дөрес үк булмас. Онытмагыз, Миләүшә эгоист иде. Әгәр дә аныңча булмаса, бер чиктән икенчесенә ташлана иде. Авыр туфрагы җиңел булсын, әмма дусларына карата алай миһербансыз булу. Үзе турында гына уйлады ул.

Эльмира. Бүтәннәр сине онытса, үзең турында гына уйлый башлыйсың.

Шәһит. Аны берәү дә онытмады. Бәлки, мин читләшкәнмен, аның билгеле сәбәпләре бар. Ә сез? Бигрәк тә Рәфис. Беребезне кертмәсә дә Рәфисне кертергә тиеш иде. Дөресен генә әйткәндә, Рәфис Сәҗидәгә караганда Миләүшәгә игътибарлырак булды. Дөресме, Сәҗидә?

Сәҗидә. Булса булгандыр инде.

Шәһит. Эгоист иде Миләүшә.

Нурислам. Ә кем эгоист түгел? Синме? Минме? Мөхәммәтәминме? Барыбыз да үләчәкбез. Нәрсә фәлсәфә корып маташабыз. Без инде күптән тере мәетләр. Без туганда ук үле туганбыз. Туган җирең каберстан булгач, нигә әпипә биеп маташырга. Иртәгә мин үләм, берегезгә дә килергә рөхсәт итмим. Һәм берегезгә дә бармыйм да. Ну, мәңгелеккә хушлашыр алдыннан эчик берәр рюмка. Теге дөньяда исәпләшербез. Оҗмахка эләксәк — хур кызлары белән, тәмугка эләксәк — кисәү башы белән... Бирмисезме? Алайса, хушыгыз. *(Чыгып барган җиреннән туктап)* Ә шулай да Миләүшә җитми. Дөньяның тагын бер чите кителде. *(Ишектә Рөстәм белән очраша)* О-о, Рустам Рафисович! Здравье желаю, Рустам Рафисович.

Рөстәм. Ну, ладно, ладно... Голова что-ли болит? Скажи там, моему шоферу, пусть нальет.

Нурислам. Спасибо, Рустам Рафисович.

Рөстәм. Рәхмәт диген, художник. *(Нурислам чыгып китә. Рөстәм бүлмәдәгеләргә карап тора)* Исәнмесез, иҗат әһелләре. Һаман да әле әтәчләнәсезме? Дөньяны матурларга җыенасызмы? Кеше күңелен камил итәргә җыенасызмы? Кызганыч кешеләр сез. Бүгенге дөньяга сыймаган кешеләр. Шулай да сез миңа ошыйсыз. Чөнки сез җүләрләр, тиләләр. Ә җүләрләрсез, тиләләрсез кешеләр яши алмый... Татарча дөрес сөйлимме мин, әти?

*Крутушка — Мәрәтхуҗа — Казан.*
1992.



# КЫЯДАГЫ ЧӘЧӘКЛӘР

Минем үземнең кыядагы чәчәкләрне күргәнем юк. Язмыш шактый гына алкыса-талкыса да, алай кырыс-хәтәр кыяларга илтеп ташламады мине. Укыган-ишеткәннәремнән генә беләм: искиткеч матур диләр ул чәчәкләрне. Ышанам, шулайдыр. Табигать кыенлык-мәхрүмлекләрне кыю җиңеп чыгучыларга матурлыкны мулдан бирә. Андыйларга Ходайның рәхмәте дә киң.

Тукта, мин әйтер сүземне иң ахырыннан тотыпмы, әллә уртасыннан әләктереп алыпмы сөйли башладым бугай. Сүзем — «Кыядагы чәчәкләр», «Батырша» романнары, «Өлешемә тигән көмешем», «Девон хәбәрчесе», «Тәвәккәл таш яра» һәм башка повестьлар, күп хикәяләр, йөзләгән очерклар авторы Җәмит Рәхимов турында. Язучы турында сөйлисең икән, аның туган ягы, балачагы, яшьлеге, хезмәт юлы турында әңгәмәдән башлау мәхкүл.

Алтмыш яшьләрен тутырып, хәзер берәм-берәм пенсиягә китүчеләрнең балачаклары авыр сугыш елларына туры килә. Җәмитнең сабый җилкәсенә дә бик мулдан куна андый нужа йөге. Йөк авыр, ә инде сугышның беренче көннәреннән үк яу кырына чыгып киткән әтисенең мәңгегә шунда ятып калуы турындагы кара хәбәр кайгысы бернинди бизмәннәргә дә сыймый.

Ләкин балачакның үз хасияте хасият. Йөк-хәсрәт никадәр авыр булмасын, сабый күңелендәге хыял-фаразларны баса-сыта алмый ул.

Һәр сабыйның үз хыял канатлары. Язмыш ул канатларны һәр сабыйга үзенчәрәк бирә. Алар авылы — Иске Шөгер — халык күңелендә легенда булып йөргән Шандор тавына сыенып утырган. Шунда, Җәмитләрнең бәрәңге бакчасы артында гына, «нефтеразведка» дигән биек вышка көне-төне гөрләп утыра. Татарстанның зур нефтенә юл ачкан беренче тарихи буровой бу.

Әнә кайдан көч-куәт ала нәни Җәмитнең хыял канатлары!

Хыялына таба беренче адымнарын да бик иртә атлый ул. Бер көнне олылар сөйләшүеннән шуны белеп ала: җир асты хәзинәсенә катламнар тишеп төшүче абыйларының эше тоткарланыбрак тора, имеш. Бораулары хутлырак эшләсен өчен үзле балчык кирәк икән, андый балчык ерак та түгел, Баллы үлән тавында бар, ди. Тик шуны алып кайтырга атлар, кешеләр генә җитми икән. Иртәгесен төрле зурлыктагы әрҗәләр утыртылган кул арбалары кәрваны шунда кузгала. Җәмит тә үзләренең күпне күргән «уфалла»ларына яңа бушап калган каз оясын утырта да, озын кәрванга килеп кушыла.

Хыял һәм эш. Гомер юлында болар икесе тыгыз үрелеп барганда гына максатчан көчкә әверелә. Җәмит Рәхимовның язучы булу хыялы кайчан тугандыр, әйтүе кыен. (Үземнән беләм: андый хыял башта бик зәгыйфь һәм кыюсыз туа). Ә менә нефтьче булу хыялын Җәмиткә язмыш үзе бирә.

Алар бакчасы артындагы әлеге буровой, ниһаять, Девон хәбәрчесе булып, җир асты хәзинәсенә кадәр төшеп җитә. Мәгълүм ки, шушы көннәрдән башлап

Татарстанда нефть чыгару эше искиткеч тизлек һәм киң колач ала. Җәмитне дә бөтереп кенә ала бу көчле өермә. Урта мәктәпне тәмамлауга, ул Әлмәт промыслында нефть чыгару операторы булып эшли башлый. «Кара алтын» чыгаруның серләренә ныграк төшенү өчен Лениногорскидагы кечке нефть техникумына укырга керә. Илленче еллар ахырында тырыш һәм инициативалы егетне комсомолның Шөгер райкомы беренче секретаре итеп сайлыйлар.

Ә язучы булу хыялы? Кече яшьтән үк китапларга, әдәбиятка мәхәббәттән туган бу хыял аз гына да сүрелми, дөрләгәннән-дөрли генә бара. Бу хыялына таба да кыю адымнар атлый ул. Казан дәүләт университетының филология факультетына читтән торып укырга керә. Әлбәттә, каләмен дә сынап карый. Район газетасында аның шигырьләре, нефтьчеләр тормышыннан кызыклы язмалары күренә башлый. Ә Шөгер һәм Яңа Писмән районнары берләшкәч, аны яңа ачылган шәһәр газетасына эшкә чакыралар. Монысы да әдәбиятка таба яңа зур адым.

Нефтьче дуслары, якын танышлары турындагы очерклары республика газета-журналларында бер-бер артлы күренә башлый, әдәби конкурсларда бүләкләр ала.

Җәмит Рәхимовны язучы итеп таныткан беренче әсәре «Өлешемә тигән көмешем» повесте булды. Әсәрнең гаять тормышчанлыгы, үзен яхшы белгән, даими аралашып йөргән кешеләрдәй җанлы образлары, халыкчан теле мине чынчынлап әсир иткәнлеген яхшы хәтерлим. Ул елларда әле «соцреализм» дигән нәрсә язучыны туктаусыз камчылап тора, ә инде «партия житәкчелеген күрсәтү» дигән әдәбияттагы каттый таләп каләменне ирексездән фальш юлына этәреп тора иде.

«Өлешемә тигән көмешем» әдәбиятыбызда мондый богаулардан азат булган әсәрләрнең берсе иде.

Тормышның үзеннән каерып алынган бу хак әсәрне әдәби тәнкыйть күрмәмешкә салышса да, укучылар аны яратып кабул иттеләр, үз иттеләр.

Җәмит Рәхимов — эзләнүчән язучы, армас каләм иясе. Аның шуннан соңгы һәр әсәре әдәбиятта әле аз чагылдырылган яки бөтенләй таныш булмаган яңа образлар алып килә, яңа географик киңлекләр ача. Бу яктан аның «Кыядагы чәчәкләр» романы бик характерлы. Әсәрдә без ерак Себер жирендә, бик авыр шартларда нефть магистрале салып йөрүче якташларыбыз тормышын күрсәк, «Сагыш» повестенда ачы язмыш тәкъдире Әфганстан жиренә үк илтеп ташлаган милләттәшебез Галләметдин картның фажигасе белән тетрәнәбез. «Тәвәккәл таш яра» повестенда укучыга яхшы ук таныш булган нефть чыгаручылар турында сүз барса да, аның геройлары яңа яклары белән ачылалар. Биредә беренче чиратта әхлакый-вөждан сыйфатлары алга куела.

Яңа образлар, яңа географик киңлекләр, дидек. Шушы урында кылт итеп язучының яңа романы «Батырша» искә килеп төшә. Бу роман исә укучыны тарихи тирәнлеккә алып китә. Юк, соңгы елларда яңгырдан соңгы бөреләр сыман шытып кына торган Болгар-Казан ханлыгы чорын чагылдырган әсәрләрдән түгел бу. «Батырша» — XVIII йөз урталарында татар һәм башкорт халкын милли-азатлык өчен көрәшкә күтәргән каһарман турында. Моңарчы без Батыршаны сирәк-мирәк тарихи язмалардан гына укып белә идек. Җәмит Рәхимов милли каһарманның тарихи һәм милли шартларда туган жанлы образын күрсәтеп биргән. Моның өчен никадәр эзләнү, күпме архив материалларында казыну кирәклеген күз алдына китерү кыен түгел. Шунысы характерлы, язучы үз героеның дини, фәлсәфи нигезләрен күрсәтеп бирүдә дә шактый уңышка ирешкән.

Сүзебезне кырыс-хәтәр шартларда чәчәк аткан кыя чәчәкләреннән башлаган идек. Күргәнебезчә, Җәмит Рәхимовның барлык әсәрләре дә әнә шул авырлыкларны кыю жиңеп чыгучыларга багышланган. Миңа калса, Җәмит Рәхимовның үзен дә мин, геройлары кебек, кырыс-матур кыя чәчәгенә охшатыр идем.

Авыр юлларың яңадан-яңа иҗат шатлыклары алып килсен, кадерле каләмдәшебез!

**Рафаил ТӨХФӘТУЛЛИН**

**Искәрмә.** Бу сүз башы — талантлы өлкән каләмдәшебезнең соңгы язмаларыннан берсе.

**Җәмит**

**Рәхимов**

# ЭСКЕРТТӘГЕ ЭНӘ

ЭССЕ

Аксакаллар белән очрашу-сөйләшүләр мине еш кына тарих чытырманлыкларына илтеп ташлый. Әйтик, әңгәмәдәшләремнең күбесе Батырша исемен телгә алдылар: мулла, диләр, ахун хәзрәт, диләр. Кайсылары аны әүлия дип тә атады. Үзлегеннән күп укыган, бик тәрәккый агайларның берсе исә: «Батырша галим булган, халыкка ниткәндер хатлар, өндәмәләр дә язган»,— дип әйтте.

Алай да кем булган соң ул Батырша? Безнең төбәктә, Тайсуган мәктәбендә укыган икән, димәк ки, шушы ук тирә-як авылларның берсендә туып-үскән. Әмма алары хакында берәү дә тәфсилләп сөйләп бирә алмый, ә Казанда басылып, минем кулга төшкән кадәр тарихи китапларның берсендә дә андый исем аталмый.

Әнә шул инде барысы диярлек мәрхүм картлар белән очрашкан 50 нче еллардан башлап Батырша дигән серле дә, тылсымлы да исем һич кенә дә тынгылык бирмәде миңа. Аның турында күп уйланып йөри торгач, бервакыт исемә килеп төшмәсенме! Тукта, мин бит аның исемен ниндидер китапта очраттым. Ялгышмасам, башлангыч мәктәпләр өчен урыс телендә язылган тарих китабы иде бугай. Шуннан инде юлларымда туры килгән һәм китапханәдә тарих дәреслекләре актаргалый башладым, ниһаять, эзләгәнемне таптым! Чыннан да, урыс мәктәпләренең 3 нче класслары өчен 1953 елда басылып чыккан тарих дәреслеге иде ул һәм анда Батырша хакында тулы бер җөмлә язылган — 1755 елда Башкортстанда Батырша җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесе булып уза. Чү, XVIII гасырда һәм XIX йөзнең беренче яртысында безнең Бөгелмә төбәге дә Уфа провинциясенә кергән бит. Бәлки, әлеге китапта әйтеп үтелгән восстание безнең як авылларында да дөрләгәндер?! Алай дисәң, нишләп әле галимнәр бер дә тын тартмый? Исемен генә дә телгә алмыйлар бит ичмасам.

Минем Батырша турында тапканым һәм белгәнем әнә шул 3 нче класслар дәреслегендәге бер җөмлә белән төкәнде. Күп еллар буе тарихи китаплар укысам да, ни урыс, ни татар авторларының хезмәтләрендә аның исемен очратмадым һәм инде Батырша турында оныта ук башлаган идем.

Мәскәү архивына бару ниятем Батырша исемен хәтер төпкеленнән кабат калкытты. Бәй, әнә шундый илкүләм шанлы архивта әлеге серле шәхес хакында да материаллар булуы бик мөмкин ләбаса! Бу фикер мине ашкындырып җибәрде, йөрәк кагарга тотынды — Мәскәүгә бару мәсьәләсен ашыктыра башладым.

Мәскәүгә килеп төшүгә, каршыма очраган беренче агайга мөрәҗәгать иттем, борынгы актлар үзәк дәүләт архивына ничек барырга икәнен сорадым. Ул, джунглидан килгән кыргыйны күргәндәй, миңа карап-карап торды да үз юлы белән китеп барды. Аннан соң туктаткан ун-унбиш кешедән дә рәт чыкмады, андый учреждение турында ишеткәннәре юк икән.

— Анда нишлиләр, нәрсә саталар соң? — дип, соравыма сорау белән җавап бирде арадан берсе.

Кулымны селтәп китеп барудан башка чара калмады. Тукта, зур калаларда белешмәләр бюросы дигән киосклар була торган иде бит. Егерме тиененне түлә дә, җаның теләгәнне сора. Бәхеткә, бюро дигәнең ерак та түгел икән. Ун минут та үтмәде, аксыл сары пумала чәчле кыз миңа бер кәгазь кисәге тоттырды. «Большая Пироговская, 17» дип язылган иде анда.

Бихисап транспорт чараларына бер менеп, бер төшеп күпме уралганмындыр, бервакыт инде мин исеме телемдә шомарып беткән архивның пропусклар

бюросы янында басып тора идем. Дөньядагы бөтен төрле буяуларга буянып, чыршы уенчыгын хәтерләткән маржа ханым минем буталчыграк аңлатуымны тыңлап бетермәде, тик:

— Документы! — дип кенә куйды.

Аларны инде башта ук кул очына алган идем. Ашыга-кабалана амбразурага паспортымны, хәтта партия билетын төрттем, безнең белән шаярырга ярамаганлыгын сиздереп, соңыннан гына язучылар һәм журналистлар союзы билетларын суздым. Маржам исә аларны юньләп карамады да.

— А письменные документы, письмо?! — дип миңа төбәлде.

Ык-мык килдем, кабат йомышымны аңлатып маташкан булдым, безнең кебек берлек әгъзаларын шушы таныклыклар белән теләсә кая кертәләр, дип тә ялганладым. Сүзләрем акшарланган маржага аз гына да тәэсир итмәде, ичмасам.

Туксан тугыз бәла белән меңнәрчә чакрым җир килеп, сине шушы кадәр ваемсыз каршыласыннар әле! Ачудан кызарып чыктым, ана очып-очып кунганнан соң да берни чыгара алмагач, аны башкачарак шүрләтәсе иттем, очып диярлек икенче катка, архив директоры янына менеп киттем.

Директорның исә СССР дигән зур империянең төрле почмакларыннан килгән минем сыман авыл гыйбадларын беренче күрүе түгел иде, ахыры. Ул тәкәллеф белән генә урын тәкъдим итте һәм һич иренмичә, тыныч кына архивка керү тәртибен, аның өчен кайсы да булса оешмадан фәнни эшнең темасы, эзләнүләрнең кайсы гасырга каравы һ. б. күрсәтелгән рәсми хат кирәклеген аңлатты — сабырлыгы һәм әдәплелеге белән мине бөтенләй коралсызландырды.

Архив бинасыннан башымны салып чыксам да, мин инде бераз тынычланган идем. Кулыма алган сигаретларны сындыра-изә үзе бер чакрым чамасы сузылган баш бина янәшәсендәге тротуарда йөренергә тотындым. Кирәк бит, шуннан ары кил дә, берни тоҗыра алмый кайтып кит, имеш. Мәгәр берни эшләр чараң юк. Суынып җитмәгән мунча ташым белән, Бөгелмәгә билет алырга дип, тимер юллар кассасын эзләп киттем. Бөгелмәгә кайту билетлары бүген-иртәгегә генә юк, тагы өч көннән соңга гына табылды. Башкалада вакытны бушка уздырмаска, бөтен илебездә күз өстендә каш булган Ленин исемендәге иң зур китапханәгә сугылырга ниятләдем. Монда инде юлым уңды, бернинди ыгы-зыгысыз уку залына керү таныклыгы алдым. Китапханәнең хезмәткәрләре дә бик тә мөләүәтле, зыялы кешеләр икән, теләгемне ярты сүздән аңлап, ихлас күңелдән ярдәм иттеләр.

Сүз бара торган китапханәдәге гыйлем байлыгын, күреп түгел икән, ишетеп булса да, һәркем күз алдына китерәдер, дип уйлыйм. Ул — тулы бер рухи диңгез. бер уку залындагы шкафларга тезелгән төрледән-төрле белешмә-энциклопедияләр генә дә «аһ» итәрлек. Монда мин 1864, 1883, 1900 һәм 1910 елларда Петербургта һәм Самарада басылып чыккан Россиянең халык яши торган урыннары хакындагы белешмәләрдән үзебезнең төбәк авыллары турында бик бай мәгълүмат сөзеп алдым: торак пунктлардагы йортлар һәм халык саны, аларда яшәүчеләрнең милләте һәм социаль хәле, теге яки бу авыл янынан ага торган елга-инешләрнең ул замандагы төгәл исемнәре, өязләр һәм волостьләр, авылда ничә мәчет яисә чиркәү, ничә су тегермәне, андагы базар һәм ярминкә, мәктәпләре, урәтник һәм урманчылары хастаханәләре һәм ям станнары, торак пунктның ничә дисәтинә җир биләве һ. б. һ. б. — кыскасы, тулы бер хәзинә. Дөрес, мәгълүматлар, нигездә XIX гасырга һәм XX йөз башына гына карыйлар. Әмма инде болары да чиксез зур табыш һәм мине тагы да дәртләндереп эшләтәчәк көч иде. Архивка кереп, XVIII гасыр документлары белән танышып булмаса да, табылган кадәр материалларга мин гаять шат идем. Мине тагы да канатландырганы шул: илнең үзәк китапханәсендә Батырша эзенә төштем. Баксаң, революциягә кадәр басылган китапларның кайберләрендә аның турында мәгълүматлар бар икән, хәтта совет чорындагы бер-ике китапта Батырша хакында язылган. Аларның барын укып чыгарга, кирәкле битләреннән күчермәләр алырга вакыт җитмәде җитүен, әмма аларның исемнәрен, авторларын, басылып чыккан елларын куен дәфтәренә теркәп куйдым. Әнә шуларның сөенеченнән мин инде жиде кат күккә ашкан идем. Шулай булмыйни, мин бит ул китапларны барыбер табачакмын һәркайсын укып ләззәтләнү бәхетенә ирешәчәкмен! Янә дә килеп, Мәскәү качкан җир түгел, кабат әйләнербез, башкаланың архив-китапханәләрен тагы да урарбыз.

Икенче кат Мәскәү сәфәренә җыенганда, мин инде акыллы идем. Архив директоры әйткән теге хатларны берне түгел, биш-алтыны әзерләдем, хәтта берничә бит тугралы һәм фирмалы чиста бланклар да юнәттем. Язып килгәннәрен ошатмыйлар икән, Мәскәүдә үк башкасын әмәллибез аның!

Ләкин әлеге хатлар, чыннан да, «дело»га тегеп кую өчен генә кирәкләр иде, ахыры. Архивта минем тырышып-тырмашып «ижат» иткән һәм шактый зур түрәләр имзасы куелган хатларымны бу юлысында укып торучы да булмады, паспортка карап махсус таныклыклар тутырдылар да вәссәлам. Мин, кәләш куенына керергә жыенган кияү сыман, тәэсирләнеп архивның икенче катындагы уку залына менеп киттем. Киттем дип әйтүе генә ансат. Югарыга алып менә торган баскыч янына килсәм, махсус пост кырыенда ике милиционер басып тора. Алар миңа портфелемне һәм, әгәр дә бар икән, башка әйберләремне шушында калдырырга куштылар. Портфелемне суздым, өй ачкычларын һәм документларымны чыгарып салдым. Милиционерларның сакал-мыегы булмавына караганда хатын-кыз икәнен чамалап була торганы көлеп жибәрде, портфельне алып күп киштәле шкафка куйды, ачкычлар белән документларны кире бирде.

Шуннан инде икенче катка һич тоткарлыксыз үтсәм дә, эчемә шом йөгергән иде. Нишләп әле фәнни учреждение ишеге төбендә коралды милиционерлар тора? Алай-болай ялгыш сүз ычкындырсаң, алып китүләре дә бар бу каһәрләрнең. Әлеге сорау миңа көнозын тынгылык бирмәде. Ниһаять, тәмәке тарту бүлмәсенә чыккач, үзем сыман гадирәк киенгән, мәгәр кыяфәтенә караганда, монда инде азау ярган кеше икәнлеге күренеп торган ир-аттан теге милиционерлар турында сорамый түзмәдем. Ул исә моны бик гади аңлатты. Имештер, Ватаныбызга үчле ниндидер бәндәләр чит илдәгеләр күзенә һич кенә дә күрсәтергә ярамый торган кайбер документларның күчермәләрен алып чыкканнар да чик аръягында бастырганнар. Шулай итеп, безнең марксистик идеологиягә зур зыян салганнар. Менә шуңа да ишек төбендә хокук сакчылары тора. Уку залында махсус штамп сугылмаган бер генә күчермә дә алып чыга алмыйсың моннан!

Бу кадәресе тагын күңелгә шом салды. Ләкин кабат уку залына узгач, әлеге шик-шөбһә юкка чыккандай булды. Нигә дисәң, бирелдәге хадимнәр пропусклар бюросындагы теге ханым кебек таш сыннар түгел, ягымлылар, илтифатлылар, кешегә мөгамәләләре искиткеч яхшы. Алай да биредәге тантаналы тынлыктан, каядыр якында гына гасырлар серен саклаучы кәгазьләр өелеп ятуын тоюдан тын кысыла, йөрәк ашкынып тибә, тизрәк-тизрәк әнә шул саргайган кәгазьләр эченә кереп чумасы килә. Тик аңа ирешү әле ансат кына түгел икән. Йомышымны, ниндиерәк уй-ниятләр белән килүемне аңлатып биргәч, урта яшьләрдәге ягымлы ханым мине бер өстәл янына алып килде һәм алдыма байтак кына кенәгәләр тезеп куйды. «Тасвирлама» дип аталган бу кенәгәләрдә архивтагы бөтен кенәгәләрнең исемнәре, саклау берәмлекләренең саннары, кыскача гына эчтәлекләре язылган икән. Болардан инде син үзең теләгән губерна, өяз, хәтта волость турындагы мәгълүматларның теләсә кайсы гасырга, елга караганнарын таба аласың. Калын-калын тасвирламаларны актарып, үзеңә кирәк булуы ихтимал томнарның, фонд, саклау берәмлеге саннарын язып алу, аннан инде заказ-заявка бирү бер хәл, махсус саклагычлардагы әлеге кенәгәләрне эзләп табуларын һәм китереп бирүләрен кимендә ике-өч тәүлек көтәсе бар икән. Монысы инде тагы газап, йөрәгең кагып янә көтү.

Әмма миңа гасабиланырга туры килмәде. Уку залындагы күп санлы киштә-шкафларда моңа кадәр төшемә дә кермәгән белешмәләр, энциклопедияләр, Россия империясенең законнары жыентыгының бихисап томнары, без — авыл гыйбадлары гомер исемнәрен дә ишетмәгән тагы әллә ни кадәр хәзинә тезелеп тора. Ач, укы, үзеңә кирәкле мәгълүматларны язып ал. Инде акчаң бар икән, махсус службада ксерокүчермәләрен алдыр. Эш буа буарлык — вакытың гына житсен!

Әнә шул кадерле китапларны актарып, берничә көн узып та китте. Бүген минем заказларны китерәчәкләр! Архивларда даими эшләүче галим-голәмә мондагы төрле хәлләргә күнегеп беткәндер, әлбәттә. Ләкин минем сыман шундый бай архивка үз гомерендә беренче аяк баскан кешене адым саен сюрприз көтә икән биредә — дүрт тәгәрмәчле арбага төяп китерелгән кәгазь тавын күргәч, егылып китә яздым. Тасвирламалар актарганда, мавыгып китеп, заявкаларны күбрәк биреп ташлаганмын күрәсең. Без үземә бер олау документ! Ә бит әле, әйтүләренә караганда, болары мин сораганнарның барысы да түгел, аларын соңрак китерәчәкләр икән. Йа хода, бу кадәр кәгазьне ничек карап-актарып чыгармын?!

Йә, ярар, күз курка кул эшли. Калын гына (идәнгә куйсаң, артсыз урындык биеклеге булыр) бер фолиантны алып, актара башладым. Ләкин бу эш бик уңайсыз булып чыкты. Утырып эшләсәң, язылганнарны укырга буй житми, басып торуы да читен, аяклар тала. Аптырагач, идәнгә газет жәеп, фолиантны

шуның өстенә куйдым да, үзем утырып актарына башладым — тирә-яктагылар, моны күреп, авызларын ердылар.

Аяныч ки, эшемнең рәте булмады: томнар берсеннән-берсе ымсындыргыч, аларның һәрберсеннән борынгылык исе аңкып тора, житмәсә, бөтенесендә дә миңа кирәкле мәгълүматлар бар сыман. Мин кенәгәләрнең берсен куям, икенчесен алам, әле монысын, әле тегесен актарам, күзәмә Бөгелмә төбәге чалынган битләр арасына кәгазьләр кыстырам. Аннан инде шөгылемне ташлап, борынгы кәгазьләргә сокланып карап торам. Өстәвенә, «минеке»ләр төсле иске китаплар уку залындагы һәр өстәлдә, алар өстенә яше-карты иелгән. Күршеләремне күзәтүе дә кызык, үземә дип китерелгән томнар да ымсындыргыч, киштә-шкафлардагы исәпсез-хисапсыз белешмәләр дә үзләренә тарталар, архив хезмәткәрләре утырган бүлмәдәге стеллажлар тулы иске кәгазьләр төпләмнәре дә эчне кытыклап ала. Кабаланам, актарынам, язам, ул да түгел, борынгы китаплар тулы шкафлар яныннан урап киләм. Аннан инде тәмәке тартырга чыгып китәм, юлымда очраган хезмәткәрләргә сораулар биреп йөдәтәм. Шулай урала торгач, аларның берсе белән дуслашып киттем. Ул мине «контрабанда» юлы белән борынгы кәгазьләрне саклагычларның берсенә алып керде. Анда һушым китеп ава яздым. Идәннән алып бик биек түшәмгә кадәрге киштәләрдә томнар, фолиантлар, кенәгәләр! Ә бит, әлеге хезмәткәрнең әйтүенә караганда, бу бина тугыз катлы булып, аларның һәркайсы иске документлар белән тулы, имеш. Алтынчы фонд дип йөртелгән бер Пугачев фонды гына да хәрби крейсер кадәр тугыз катлы бер бинаны алып тора, ди. Андый биналар исә архив карамагында тулы бер шәһәрчек икән. Менә син, әй, ничек саташып бетмиләр икән бу архив хезмәткәрләре!

Ул төнне мин Мәскәүдәге фатирымда йоклый алмадым. Сизелерлек файдалы эш башкармаган көнемне жәлләп йөрәк сыкрады, күз алдыма үзем күргән һәм теге фәнни хезмәткәр сөйләгән архив таулары килеп, бәгырьне ярсытты. Менә кайда икән ул жан азыгы — тулы бер дәрья! Бу бит әле Мәскәүдәге бер архивта гына шулай. Ә алар әллә ничәдер башкалада. Петербургта Казанда, Уфада, Оренбургта, Самарада һәм башка калаларда күпме тагын. Бәй, архивларда икән гыйлем ганимәте, шушылар икән Әбугалисина мәгарәсы! Әлеге саргайган кәгазьләрнең барын бергә жыйсаң, океан хасыйл булыр иде, мөгаен. Кая ул океан гына, тулы бер галәм тәшкил итәрләр сыман алар. Мин жүләр, илләр-халыкларның әллә ничә гасырлык тарихларын сыйдырган әнә шул миллионнарча кәгазьләр арасыннан үзебезнең печтеки генә Бөгелмә төбәге турында мәгълүматлар жыймакчы. Бу бит... бу бит салам эскертеннән энә эзләү белән бер! Йә хода, булса да булыр икән интеллектуал байлык! Шушы яшемә кадәр яшәп, мондыен ганимәтне төшемдә дә күргәнем, хыялымда күз алдыма китергәнем дә юк иде. Алар хакында укытучылар да сөйләмәделәр бит ичмасам. Хәер, ул мескен авыл укытучылары каян белсеннәр инде ошбу хәзинәне?!

Хуш, без — авыл гыйбадлары болардан хәбәрдар булмыйк та, ди. Ә галимнәр, безнең тарихчылар файдаланалар микән соң бу архивлардан? Бер дә сугылмыйча булмаслар — кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен материалларны түшәмнән алып язып булмый ла. Алай да бер нәрсә шиккә салды бүген мине. Көндезен үзем актаргалаган, тотып-тотып караган кырык-иллеләп томның (димәк, архивтагы бөтен кенәгәләрнең) титул бите алдыннан чиста кәгазьләр ябыштырылган. Анда шушы документларны укып-танышучыларның исем-фамилияләре, кем булулары һәм кайдан килүләре языла икән. Болай эшләү һәркем өчен мәжбүри, имеш. «Шул мәгълүматларны язмый торып, томнарны кабул итмибез»,— диделәр миңа. Димәк, әлеге кәгазьдә шул кенәгәне алып караган һәркемнең имзасы кала. Карыйм: икешәр-өчәр генә фамилия, алары да гел урысларныкы диярлек, безнең татар галим-голәмәсе эзе күренми. Кем белә, бәлки татар вәкилләреннән беренче булып актарамдыр мин бу документларны. «Ачыш»ым тагы да дулкынлануга һәм жаваплылык хисен арттыруга сәбәп булды.

Галим әфәнделәрнең хәтерләре калмасын иде. Мин аларны эшсезлектә, ялкаулыкта гаепләргә жыенмыйм. Тарихчыларыбызга хөкүмәт тарафыннан тиешле шартлар тудырылмавын гына ассызыклап әйтәсем килә. Әле әнә шундый мескен хәлдә булуларына карамастан, Сәлам Алишев, Миркасыйм Госманов, Булат Солтанбәков, Альфред Халиков, Равил Фәхретдинов һәм башка кайбер галимнәребез, ничектер жаен чыгарып, моңа кадәр берәүнең дә күзе төшмәгән документларны эзләп табалар һәм халкыбыз тарихындагы «ак таплар»ны киметә торалар. Алай да...

Җитмешенче елларда безгә, Татарстанның бер төркем журналистларына, Көнбатыш Себернең нефть районнарында семинарда булырга туры килгән иде. Тубылга килеп төшүнең икенче көнендә семинарга катнашучыларны шушы иксез-чиксез киңлекләрдәге бердәнбер чал кремль буенча экскурсиягә алып киттеләр. Мин шушы борынгы истәлекнең үзәк мәйданында басып калдым. Чөнки, экскурсияне күтәргә сабырлыгым житмичә, кремль диварларын карап, кичә кичке буйда әйләнгән идем. Җимерек стеналарны реставрацияләүче эшчеләр һәм галимнәр белән сөйләшкәләп тә алдым. Беравык торгач, иптәшләрне көтеп ялыкмас өчен, шунда ук урнашкан архивка сугылып чыгарга булдым. Ни генә димә, Тубыл революциягә кадәр Себердә бердәнбер губерна үзәге бит, димәк, архивы да бай булырга тиеш. Дөрес, мөмкинлек чыккан бер-ике сәгать эчендә генә архивта эшләү мөмкин түгел. Шулай да танышып чыгу ярый. Йокымсырап утырган маржа түтәйләрне сискәндереп, бәләкәй-бәләкәй тәрәзәле борынгы монастырьга килеп кердем. Сизәм: бирегә керүче-чыгучы сирәк икән, архив хезмәткәрләре мине гаҗәпсенеп каршыладылар, ул да түгел, сораулар белән күмделәр. Үземнең кемлегемне, нишләп йөрүемне сөйләп бирдем, аларга бер генә соравым барын әйттем: Тубыл архивында гарәп графикасы белән язылган кәгазьләр бармы? Хәдимнәрнең иң өлкәне — ап-ак чәчле юан әби мине тар һәм лабиринтны хәтерләткән коридорлар буйлап элек монахлар яшәгән хөҗрәләргә алып китте. Гаҗәеп буталчык аралыклардан шактый озак баргач, бер ишекне ачты, кулларын белән кармаланып ут яндырды. «Менә, карап сөенегез, барысы да борынгы төрки телдә язылган»,— диде ул, бихисап саргайган кәгазьләргә ишарәләп. Гомер бакый урыс губернасы саналган Тубылда бу кадәр татарча документ барын күреп исем китте. Әмма монысы әле баласы гына булган икән. Әбекәй тагы берничә бүлмәне ачты, ут кабызды. Капшап та карадым, кулыма алып актаргаладым да — барысы да гарәп хәрефләре белән язылган борынгы документлар — хәзинә мәгарәсе! Бу кадәр гыйлем байлыгы күргәч, икенче соравым үзеннән-үзе атылып чыкты: «Килүчеләр, өйрәнүчеләр бармы боларны?» Җавап мин көткәнчә булды: «Мин белгәннән бирле (ә ул гомере буе шунда эшләгән) ни Мәскәүдән, ни Петербург белән Төмәннән, ни Казаннан килеп бу кәгазьләрне кулына алып караган кеше булмады». Авыр, бик авыр иде мондый сүзләр ишетүе. Татарлар турында нинди генә серләр, без белмәгән мәгълүматлар ятмыйдыр бу ганимәт өемендә. Аяныч ки, алар бер файдасызга ауный бирә, ул гынамы, акрын-акрын сафтан чыга, һәлак була. Ул чакта мин татар тарихчыларының эш шартлары турында хәбәрдар түгел идем. Шуңа да бик рәнҗедем, үпкәләдем аларга. Һәм менә монда, Мәскәүдә дә шундый ук хәл диярлек.

Укучылар мине энәдән дөя ясый, бер-ике факттан гомумиләштереп чыгара, дип гаепләргә ашыкмасыннар. Әнә шул башкалада тәүге тапкыр зур архив ишеген шакыганнан бирле, миңа Мәскәү, Санкт-Петербург, Оренбург, Самара һәм Уфа архивларында шактый гына, кайберләрендә исә кабат-кабат эшләргә туры килде. Һәм мин аларда татар тарихчылары салган сукмакларны абайламадым. Хак, аларның хәлен аңлыйм анлавын. Мәгәр күңелемнән галимнәребезне аклый алмыйм. Соң бит Хөсәен Фәезханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхретдинов, Һади Атласи, Зәки Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин кебек галимнәребезгә дә эшләү өчен берәү дә оҗмах бакчалары әзерләп куймаган. Алар исә әнә нинди тарих катламнарын актарганнар. Әй, нигә әле үткән заманнарны искә алып торырга?! Бүгенге көннән бер мисал — язучы Вахит Имамов фидакарьлеге. Мин аның 1994 елда Чаллыда басылып чыккан «Сәет батыр» китабын күздә тотам. Профессионал тарихчы булмаса да, ул 500 бит чамасы бу хезмәте белән тарихчыларыбызга әйткән: архивларда һәм тарихи чыганакларда менә шулай казыналар аны, галим әфәнделәр, дигән. Хак аның хезмәте дә төгәлсезлекләрдән хали түгел. Мәгәр бу инде чын тарихи хезмәт, чын фәнни фидакарьлек! Вахитның Пугачев явын яңача, үзенчә бәяләве генә дә ни тора!

Галим-голәмәләребезнең, безне юкка гаепliләр, бөһтан сүз әйтәләр, дип сукранасыларын алдан ук сизеп торганга, тагы бер мисал китерәм. Батырша эпопеясының төп чыганагы — аның падишаһка язган хаты тексты белән төрки телдә мин беренче тапкыр Башкортстан галиме Гайса Хөсәеновның «Агыйдел» журналының 1970 елдагы 10 нчы санында чыккан мәкаләсеннән, шул ук авторның «Заман, әдәбият, әдип» (Уфа, 1978) һәм «Башкорт әдәбиятының текстологиясе мәсьәләләре» (Уфа, 1979) китапларыннан танышкан идем. Ниһаять, 1984 елда Казанда «Татар әдәбияты тарихы»ның 1 томы басылып чыкты. Мине, беренче чиратта, XVIII йөз татар әдәбияты, бигрәк тә Батыршаның хаты кызыксындыра иде, әлбәттә. Ашыга-кабалана шул битләрне эзләп таптым һәм, бер сулыш белән, «Батыршаның патшага язган хаты»н укып чыктым. Мәкаләдәге җөм-

ләләр, хаттан китерелгән өзекләр, сөземтәләр бик тә таныш булып тоелдылар миңа. «Чәлдергәннәр»,— дигән ямьсез уй үтте башымнан. Әмма билгесез авторга мондый гаеп такканчыга кадәр мәсьәләнең төбенә төтен салып бетерергә кирәк иде. Өтәләнеп эчтәлекне ачтым һәм Батырша хаты турындагы мәкалә авторының фамилиясен карадым,— Г. Б. Хөсәенов. Алай икән, Казан хәтле Казанда Батырша турында язарлык, аның мәшһүр хатына анализ ясарлык галим табылмаган икән. Сүз дә юк, филология фәннәре докторы Гайса Батыргәрәй улы Хөсәенов гаять эзләнүчән һәм тик тормаучан галим. Мин моны кемнән дә булса ишетеп яисә аның хакындагы мәкаләләрдән күчереп язуым түгел. Аның югарыда телгә алынган хезмәтләрен, «Батырлар кыйссасы (Уфа, 1986) китабын һәм башка әсәрләрен укыган, галимнең үзен күреп сөйләшкән кеше буларак әйтүем. Г. Хөсәенов мәкаләсенең «Татар әдәбияты тарихы» томына кертүенә күпсенүем дә түгел бу. Белеп һәм тәфсилләп язылган хезмәте өчен рәхмәт кенә аңа. Г. Хөсәеновның мәкаләсендә миңа тагы шул нәрсә ошады: ул безнең кайбер галимнәр сыман, аннан-моннан ишеткәнгә таянып, Батыршаны башкорт диме, аны һәм аның хатын ныклап өйрәнүче буларак, героебызның мишәр мулласы икәнен басым ясап әйтә. Алай да Г. Б. Хөсәенов, Башкортстан галиме буларак ,үз ягын каера, 30 нчы елларга кадәр башкорт телендә бер генә әдәби әсәр язылмаса да, әлеге хатын «башкорт әдәбияты ядкәре» дип исәпли. Әйе, Г. Хөсәеновта ул чир шактый көчле, аныңча күп кенә татар әдәбияты истәлекләре — башкорт әдәбияты әсәрләре, мөселман исем-фамилиясе йөрткән күп кенә атаклы кешеләр (мәсәлән, татар рудапромышленнигы Исмәгыйль Тәсимов h. б.) — башкортлар булып чыга. Бернинди фәнни дәлилләргә ия булмаган шушы фикерен ул еш кына тарихи хезмәтләрендә дә кертә. Дөрес, «Татар әдәбияты тарихы»ндагы мәкаләдә аның болай дип расларга тырышуы үз кулы беләнме, редакторлар тарафыннанмы алынган. Мәгәр Батырша хатының татар әдәбиятының гүзәл бер ядкәре икәнлеге дә әйтелмәгән. Димәк, татар әдәбияты турында саллы хезмәтне төзүчеләр Батырша һәм аның хаты хакындагы сүзне татар галимнәренә бирергә тиешләр иде. Аяныч ки, Казан галимнәре арасында үзебезнең милли героебыз һәм аның әдәбилекне дәгъвалаучы хаты белән шөгыльләнүче булмаган. Автор белмәгәнен яза һәм татар галимнәрен юкка битәрли, дигән сүзләр булмасын өчен әйтеп үтик. Хак, Мәсгут Гайнетдинов үзенең 1972 елда ясаган докладында Батырша хатын телгә алып үткән иде. Бер елдан соң ул ИЯЛИнең фәнни журналында басылып та чыкты. Шунысы кызганыч, гади укучы мәкаләне уку түгел, андый журналның бары-югын да белми. Мөхтәрәм галимебез Сәлам Алишев та Батырша исемен халыкка җиткерүдә кайбер эшләр (1976 елда чыккан «Каһарман бабайлар» дигән китабындагы «Абдулла Галиев — Батырша» һәм «Казан утлары» журналының 1986 елдагы 2 нче санындагы «Батырша батырлыгы» очерклары) башкарды башкаруын. Әмма алар гадәти информация бирүдән узмадылар. Яшь тарихчы галим Искәндәр Гыйләҗевның инде күп еллардан бирле Батырша хатының бүгенге графикага күчерелгән текстын күтәреп йөрүе хакында да ишеткәнем бар. Ләкин портфельдән чыкмаган, халыкка барып җитмәгән хезмәттән ни мәгънә?! Кыскасы, татар тарихчыларының Батырша турында, гомумән, XVIII гасырда Кама аръягы һәм Уфа провинциясендә булып узган канлы вакыйгалар хакындагы хезмәтләре «юктан кодагый» дәрәҗәсендә, юк дип тутырып әйтсәң дә арттыру булмас. Шулай булмаганда, әлеге вакыйгалар 1970 елда Казанда басылып чыккан «Татарстан АССР тарихы»ның 138 битендәге «Башкортстанда 1705—1711 елларда, 1735—1740 елларда һәм 1755 елда барган хәрәкәтләрдә татар халкы актив катнашты» дигән бер җөмлә сыймас иде. Бу урында ничек инде язучы Вахит Имамовны һәм аның «Сәет батыр» китабын тагын искә төшермисең. Ярый әле, татар тарихының Казан галимнәре күз дә салмый торган өлкәсендәге кара пәрдәне ул һәм кайбер башка һәвәскәр төбәкчеләр ачып күрсәтәләр.

Чытырманлыкка кереп баттык бугай. Безнең бит әле эскерттән энә эзлисе бар. Икенче көнне мин җиң сызганып эшкә тотындым. Алдымда — 1719—1725 елларда үткәрелгән Беренче ревизия документлары, гасырлар тузанынннан саргаепкөеп, читләре ашалып беткәнлектән, калын картон кәгазьгә сеңдерелеп реставрацияләнгән кадерле истәлекләр. 350 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 4644 нче китап. Мин инде анда Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы авыллар хакында табышлар булачагын кичә үк сизенгән идем. Шунысы начар, документлар иске славян хәрефләре белән төрлесе-төрле писарь тарафыннан язылган — укуы кыен. Әмма башыңа төшкәч, башмакчы буласың, дигәндәй, тырышасың-тырмашасың. Алай да урыны-урыны белән һич кенә дә теш үтмәслек сүзләр гыйбарәләр килеп чыга. Ярый ла, миңа кирәксез мәгълүматлар булса, калдырып киттең һәм вәссәләм. Ә

минә нәкъ безнең төбәктәге торак пунктлар турындагыларын дөрес итеп, һич ялгышмый укыйсы һәм күчереп аласы иде. Хак, эшли торгач, мин инде борынгы славян язуын (ул бүгенге урыс графикасыннан бик нык аерылмый) шактый гына сукаларга өйрәндем, хәтта ялгышмыйча ерып чыга башладым. Ләкин болар моннан 270 еллар элек язылган кәгазьләр ләбаса, аннан мин аларны кабат карый алмавым да бик мөмкин бит. Димәк, һәр документны бик дөрес укырга һәм төгәл күчереп алырга кирәк. Юк, кемне дә булса ярдәмгә чакырмый булмас. Гажизләнеп як-ягыма каранам. Әнә, тәрәзә янындагы өстәл артында ыспай гына киенгән, каракучкыл чырайлы чибәр егет утыра. Нәрсәсе беләндер ул минем кан-кардәшем сыман тоела. Шулай булып чыкты да. Ул Саратов университетыннан килгән татар егете икән. Элеккеге Кырым ханнары белән Мәскәү патшалары арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләрне өйрәнә, шул хакта диссертация язмакчы. Алдындагы хатларның кайсы гарәп графикасы белән, кайсы иске урыс имлясы белән язылганнар. Сизелә: һәр икесен әйбәт белә бу. Чыннан да, егет мин шөбһәләнебрәк торган берничә документны шартлатып укып бирде. Шуннан без тәмәкечеләр бүлмәсенә юнәлдек.

— Архивка күпмегә килдегез сон? — дип сорый миннән егет.

Бу юлысында мин Мәскәүдә бер ай рәткә эшләргә дип килгән идем. Шуны әйтеп, шаккатырырга исәп моны. Тик тавышымда горурлык-мактанчыклык була күрмәсен.

— Тулы бер айга, — дим, тыйнак булырга тырышып.

Егетем көлеп җибәрде. Мин, аның нигә шаркылдавын аңламыйча, сәерсенеп тордым.

— Бер айда архивта ни генә тожырырсың икән соң? — ди бу, мине кызгангандай.

Баксаң, ул инде биредә берничә мәртәбә эшләп киткән икән. Бу юлысында исә алты айга килгән. Егет әйтеп бетермәсә дә, аңладым: тема өстендә менә шулай эшлиләр аны, диюе иде аның.

Шул сөйләшүдән соң, тәмам пошаманга төштем. Берни дә чыгарып булмас микәнни? «Юк, шалиш, брат», — дип эчемнән генә Саратов егете белән бәхәсләшәм. Бер ай — бер ай әле ул, вакытны дөрес файдалансаң, ни дә булса майтарып булырга тиеш. Шуннан инде мин көненә уникешәр сәгать эшли башладым: архив ачылганчы ук килеп җитәм, аннан соңгы кеше булып чыгам. Ярый әле, буфет-ашханәләр архивның үзендә, чират юк — ашау-эчүгә унбиш минут вакыт җитә. Минем үҗәтлекне күреп, архив хезмәткәрләре дә ярдәмгә ашкынып торалар: кайсы фондтан нинди томнарны алырга кирәклеген әйтәләр, минем башыма да килмәгән борынгы китапларны китереп торалар. Өстәлне сытардай булып өелеп яткан архив документлары янына революциягә кадәр басылган күпсанлы китаплар да өстәлде. Шунысы куанычлы, мин иске урыс язуын һич авырсынусыз укыйм. Ышанычлырак булсын өчен аларны тагы берәрсеннән укытасы иде дә бит. Һай, монда һәркем үз эшенә баткан шул.

Залда бер тегеләйгә, бер болайга карт кына ак чәчле бер әби йөреп тора, кемнәргәдер нидер алып килә, кайберләре янына тукталып, ниндидер киңәшләр бирә. Сөйләмәсә дә билгеле: гомере буе шушы архивта эшләп, шушында картайган маржа бу. Мин аңа бер-ике мәртәбә мөрәҗәгать итеп тә карадым. «Время, сынок, время», — ди дә, китеп бара. Мин исә ничек кенә бу әбинең хәерхаһлыгына ирешергә, дип баш ватам.

Шунысын да әйтим, эш белән йөргәндә хатынымны ияртүне җенем сөйми минем. Үземнең генә дә түгел, җитди урынга башкалар чәчбиләрен ияртеп килсәләр дә ачуым чыга. Бу юлысында исә, гонаһ шомлыгына каршы, хатын да Мәскәүгә килде бит. Беркөнне кичен кайтканда әйтә бу миңа: «Карале, теге әбигә бер-ике кило яхшы конфет алып бирергә кирәк», — ди. Андый эшнең башыма килгәне дә, үз гомеремдә туры килгәне дә юк иде — дәшмәдем. Хатын исә үз сүзен иткән, ниндидер конфетлар алган. Өстәвенә, ишек төбендәге милиционерлар да хатын-кыз кулындагы сумкаларга ул кадәр бәйләнмиләр икән. Кыскасы, уку залына алып кергән бу конфетларын. Һы, шулаен шулай да, кешегә ничек бирәсең ди аларны? Ул моны үзен кимсетүгә санаса, залда, дистәләрчә кеше алдында тавыш чыгарса?! Юк, булмый. Алла сакласын! Документларны үзем белгәнчә сукалармын, әйдә.

Гадәтемчә, саргайган кәгазьләр дөньясына кереп чумдым. Бервакыт янымда гына пышылдашуларына башымны күтәрсәм, кырыемда әлеге әби белән хатын: йөзләре шатлыклы, әйтерсең, җәннәттә булып чыкканнар. Ул да түгел, әбием зур кысалы күзлеге белән минем алдагы кәгазьләргә иелде:

— Каяле, нәрсә аңлашылмый сезнең монда?

Четереклерәк документларның берсен күрсәтәм дә, үзем хатынга карыйм. Ул бармагын яный: тс-с-с, шаулама, янәсе. «Конфетларын тэрткэн»,— дип уйлап алам һәм, бу хакта онытырга тырышып, өстәл өстенә иеләм.

Шул көннән башлап әбекәй минем яннан китмәс булды. Мин моның сәбәпләре хакында уйлап тормыйм, ярдәмче табылуга шатланып яңадан-яңа документлар күчерәм. Баксаң, хатын аңа көн саен йә әфлисун, йә алма алып килә икән.

Сүз шушы хакта бара икән, тагы бер нәрсә турында әйтмичә узып булмый. Архивның бер бүлмәсендә ксерокопия хезмәте кызлары урнашкан. Белештем: аппаратларына калын-калын фолиантлар сыймаса да, нәзегрәк томнардан, китаплардан күчермәләр алырга мөмкин. Менә бит, бәхет өстенә бәхет. Минем бит ак кәгазьләр кыстырган, ягъни күчереп алырга дигән документ-өземтәләрем әнә ни кадәр — тулы бер олау. Бер ай димим, ике-өч айда да күчереп бетерерлек түгел. Ксерокопия дигәнең хәзинә инде мондый очракта. Кесә саекса саегыр, бирергә кирәк заказларны. Бәй, менә тагы бәла: ун биттән дә артыгракка заявка алмыйлар икән. Карап-күзәтеп тордым: безнең кебек гади үлемдарларга түгел, профессорларга да унбиш биттән арттырмыйлар. Кычкырып еласаң да, артыгы юк. Тагы уйга калдым: көн саен ун бит күчермә алдырганда да, сайлап куйганнарымны аппарат аша үткәрү өчен йөз көннәр кирәгер, мөгаен. Җитмәсә, анда чират, көн саен бәхет елаюы ай-һай. Өстәвенә, кайту вакыты да якынлашып килә. Шулай хафаланып утырганда, янымa хатын килеп җитте.

— Кая, кайсыларын бирергә?

Мин аны-моны дәшкәнче, бер кочак кәгазь күтәреп китеп тә барды. Тик теге су буе чират тезелгән «амбразура» янына түгел, каядыр караңгы коридорга. Чирек сәгать тә үтмәде, суынырга да өлгермәгән күчермәләр белән килеп чыкты бу — утыз-кырык битләр чамасы. Аннан тагы һәм тагы юллады, янә өем-өем күчермәләр алып килде. Ах, шайтан ялчысы, тагы теге кәнфит-әфлисуннарын эшкә җиккән бугай!

Нәкъ шулай иткән икән. Бу эшне өнәп бетермәсәм дә, дәшмәдем. Кадерле документларның күчермәләре үз аяклары белән килеп торалар лабаса. Тик аларны алып чыгасы да бар бит әле. Ә рөхсәт штампы ун биткә генә басалар. Карап-күзәтеп торгаладым: ишек төбендәге милиционерлар чыгучыларны тентемиләр үзе, кәгазьләрдә штамп барын-югын гына карыйлар. Димәк... Тартучылар бүлмәсенә йөгереп төштем һәм рөхсәт ителгәннән артык күчермәләрне чалбар каешы эченә тыгып, өстән күлмәк чабуы белән каплап куйдым. Тәвәккәл тәгалаллаһи! Шөкер, монысы да барып чыкты, төргәк-төргәк күчермәләр фатирдагы чемоданга күчә торды. Моны язудан әйтәсе килгәнем шул: эш белән йөргәндә дә хатыннарыгызны читкә тибәрмәгез, егетләр, алар шайтанның үзен саташтырырлык та нәрсәләрне беләләр икән.

Бу сәфәрем шактый уңышлы килеп чыкса да, соңгысы булмаган икән. Башта абайламаганмын, тарихның гамәли билгеләре булган иске архив кәгазьләре гаҗәеп үзенчәлеккә ия икәннәр ич. Алар, әйтерсең лә, Гомер поэмасындагы сихерче, үзләренең искиткеч тавышлары, тылсымлы җырлары белән сәяхәтчеләрне юлдан яздыручы канатлы кызлар — сиреналар гел генә үзләренә тартып, чакыртып торалар. Инде араларына бер кереп баттыңмы, ул саргайган кәгазьләр чоңгыллы баткакка әвереләләр, сине һичкая чыгармыйча, һаман эчкә, тирәнгә суыралар. Аларның әнә шул хасияте мине дә ырымлады, кальбемне сихерләде. Акча һәм вакыт дигән ике тышау аякларга бик нык уралсалар да, мин инде җай чыккан саен, зур архивлар урнашкан калалар ягына каера башладым. Сылтавы да чыгып тора бит әле аның. Революциягә кадәр үткәрелгән ун ревизия документларының бары өчесе генә Мәскәүдәге архивта булып чыкты, калганнарыныкы һәм 1897 елда уздырылган патша заманнарындагы беренче һәм соңгы бөтен халык санын алу материаллары Санкт-Петербургтагы Үзәк дәүләт тарих архивында имеш. Димәк, Нева буендагы борынгы пайтәхеткә барып чыгу да зарур. Соңрак исә, һәр ике башкаланыкыннан тыш, Самара, Оренбург, Уфа архивларында казынырга кирәклеге дә ачыкланды. Кыскасы, эш җитәрлек, тик менә юл чыгымнарын финанслаучы гына юк. Аннан да битәр, казна эше кулны тота, кеше кешесе булгач, исеңә төшкән саен теләгән җиреңә китеп бара алмыйсың.

Теләк булса, калганы акрынлап җайлана икән. Башкала һәм бүтән шәһәрләрнең архивларына бару өчен һәр елны бирелә торган ялларымны файдаландым. Чынлап-чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, бер тапкыр миңа «Лениногорскнефть» идарәсенең ул вакыттагы начальнигы Виталий Федорович Лесничий тулы бер айга командировкага рөхсәт итте. Вакытын да бирде, чыгымнарын да каплады. Баштарак мин аның бу юмартлыгына сәерсенгән идем. Соңрак белдем: әлеге командировканы райбашкарма рәисе Ринат

әфәнде Каюмов юллаган икән. Ничек кенә булмасын, һәр икәвенә рәхмәт кенә. Командировкаларның башкаларына, әйткәнемчә, чираттагы отпускларым һәм үземнең хәләл акчам исәбенә барырга туры килде. Ул чакта юкка гына сукранганбыз, теләсә кайсы транспортка билет бәяләре шалкан бәһасы, кунакханәләр бушлай диярлек булганнар икән дә, билләһи. Бүген менә бар, үз кесәңнән башкалаларга ешлап кара! Беренче сәфәреңдә үк акылыңнан язарсың, тиле.

Тегермәнче кайчан гына бармасын, тегермәннән ана он ияреп кайта. Шуның шикелле, архивта эшләгән кешегә дә һәр сәфәрендә ни дә булса йога. Чөнки башкалада бер архив белән генә дә чикләнмисең бит әле. Ничек кирәк алай җаен табып, зур китапханәләргә дә сугыласың. Әйтик, Санкт-Петербургта эшләгәндә мин еш кына Салтыков-Щедрин исемендәге үзәк китапханәгә, атаклы Тау институты китапханәсенә һәм башка гыйлем йортларына да барып йөргәләдем. Мәскәүдәге Ленин исемендәге китапханәдәге рухи байлыклар турында югарыда аз-маз телгә алынды инде. Санкт-Петербургтагы Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәдә, Мәскәүдәгесеннән баерак булмаса да, хәзинәсе муллыгы ягыннан аңардан ким түгелдер. Нинди генә бүлекләр юк та, безнең истә-конда булмаган нинди генә мәдәни байлыклар ятмый монда! Бирелә бердәнбер нөсхәдәге кульязма китапларны да, бик сирәк очрый торган хезмәтләрне дә табарга мөмкин. Китапханә бүлекләрендә миңа Бөгелмә төбәгенең 1755 елда төшерелгән беренче картасын, үзебезнең яктагы урыс авылларында төзелгән чиркәүләрнең сызымнарын, смета-проектларын һәм башка шуның кебек һич уйга да килмәгән әллә нәрсәләрне күреп-карарга да туры килде. Алар, әйтерсең, киштәләргә былтыр гына куелганнар. Әлеге китап сараендагы искитмәле хәзинә турында артыгын җәелмәстән, бер генә мисал китерәм. Россия империясе законнарының тулы җыентыгы белән, әйткәнемчә, Мәскәүдә үк танышкан идем. Алар Петербургта да бар, әлбәттә. Әмма Нева ярындагы кала китапханәсенең уку залында тагы бер күптомлы, гүзәл белешмә күреп сокланырга мөмкин булды. «Адрес-календарь» дип аталган бу белешмәләр XVIII гасыр ахырыннан чыгарыла башлап, ел саен басылып килгәннәр. Аннан инде илдә халык саны арту, губерналар күбәю, сәнагать, авыл хуҗалыгы, сәүдә, мәдәният һәм мәгариф нык тәрәккый итү нәтиҗәсендә, моңа охшашлы китаплар «Памятная книга» (һәр елны губерна үзәкләрендә басыла башлаганнар. Сүз бара торган белешмәләрдә патша әгъзам хәзрәтләренең һәм аның якыннарының тәрҗемәи хәленнән башлап, әллә кай җәһәннәмдәге аулак өязләрдә, мәсәлән, Бөгелмәдә, яшәүче ат духтырына (ветеринар) кадәр мәгълүматлар бирелгән. Телефон номерларын да язган булырга иде дә, анысы булмаган ул елларда. Ул белешмәләрне аларда һәр төбәк хакында тарихи мәгълүматларның күп булуына исем-акылым китеп карап утырдым, күп кенә нәрсәләрне язып та алдым.

Кайчакта бер-бер сәбәп белән өстәлемә өеп куелган күчермәләргә карап, уйга батам. Мин бит архивларда һәм китапханәләрдә чагыштырмача күп эшләмәдем, алай да никадәр гыйлем хәзинәсе җыелган әнә. Нигә дисәң, зур калаларның гыйлем йортларында булганда, мин бер авыллар тарихы белән генә шөгыльләнмәдем, татарларга караган һәм нәрсәгә (әлбәттә, кулыма эләккән кадәренә) игътибар итәргә тырыштым. Менә бит тупланган материаллар гына да дистәләп диссертация язарга җитәрлек: төбәк авыллары тарихы, Уралны үзләштерүдә татарлар, Оренбург краеның тарихы, Шәрекъ белән сәүдәне җайга салуда татарлар, татарларны көчләп чукындыру, татар рудопромышленниклары, сәүдәгәрләре һәм сәнагатьчеләре, татарлар һәм башкортлар, Татарстан территориясендәге борынгы заводлар, Рәсәй тарихында татар диңгезчеләре. Идел буе нефте һәм башка һәм башка темалар. Мин, әлбәттә, диссертация якларга җыенмыйм. Мәгәр, гомер булса, алар хакында эсселар, әдәби очерклар язарга ният бар. Мактану дип кабул ителмәсен, минем ул темаларга караган кайбер язмаларым (рудопромышленник Исмәгыйль Тәсимов, Нәдер волосте старшинасы, Рәсәйдә беренче керосин заводы салдырган Нәдер Үрәзмәтов, диңгезче, беренче ранг капитаны Исхак Исламов һ. б. турында) басылып та чыктылар. Бигрәк тә Бөгелмә (Шөгер) төбәге авыллары хакындагы язмаларның байтагы дөнья күрде. Революциягә кадәр үткәрелгән ун ревизия документларына нигезләнеп язылган әлеге очерклар аерым китап булып та чыгарлар, дигән өмет яши. Инде кабат ревизияләрне телгә алганбыз икән, алар хакында да үземнең фикерне әйтеп үтим. Ревизияләрнең байтак материалларын (билгеле инде, барысын да түгел) шактый җентекләп карап чыгучы буларак, кистереп әйтә алам: Петр Беренче заманыннан башланган әнә шул ревизияләрнең документлары күп кенә төбәкләрнең тарих-

ларын ачыклау өчен беренчел һәм иң ышанычлы материаллар алар! Аяныч ки, бүгенгә кадәр чын фәнни нигездә өйрәнелмичә яталар.

Мәскәү, Петербург һәм башка шәһәр архивларындагы борынгы кәгазьләргә таянып язылган очеркларның укучыларда зур кызыксыну уятуы да күп нәрсә сөйли. Әлмәттә яшәүче Сәгыйть Минһаҗев һәм Карабашта торучы Солтан Асыловларның миңа адресланган ачык хатларның газеталарда басылуы, күп кенә укучылардан минем үземә килгән хатлар исә нәкъ менә халыкның үз тарихына битараф булмавы хакында сөйли. Билгеле, ул тарихи язмаларда кайбер төгәлсезлекләр, ашыгыбрак чыгарылган нәтиҗәләр юктыр, димим. Югарыда алынган хатлар, яшь галим Таһир Кәримовның «Мирас» журналының 1994 елгы 4 нче санында басылган һәм минем үземә атап язган хатлары әнә шундый уйларга урын калдыра. Тарих фәннәре кандидаты Таһир Кәримовның (соңгы вакытта аның авыллар тарихына караган мәкаләләре матбугатта күренгәли башлады) кайбер фикерләре белән килешкән хәлдә, форсаттан файдаланып, аңа һәм, кызым сиңа әйтәм... дигәндәй, башка яшь галимнәргә бер-ике сүз әйтеп китәсем килә. Сезнең, Таһир туган, «Мирас»тагы хатыгызда кайбер шик-шөбһәләрегез «алай түгелдер, болай түгелдер» дигән кебегрәк язылган. Әйдәгез, фән булгач, без инде «дыр-дер»ләргә урын калдырмыйк. Шигегез бар икән, сезнеңчә, дөресе ничек? Һәм, әлбәттә, аргументларыгызның яңа табылган тарихи документлар белән раслануы зарур. Мач килмәгән картаны каплау өчен козырь кирәк. Ә сездә хәзергә алары юк бугай. Янә дә килеп, мин үзем профессионал тарихчы түгел, яшь галимнәребез бик акырын кыймылдагач кем дә булса селкенергә тиештер иң, дигән нияттән чыгып кына тотындым бу эшкә. Ә безнең яшь галимнәребез, язучы Марсель Галиев әйткәнчә («Шәһри Казан», 1994 ел, 28 июнь), чыннан да, «нәрсә изеп йөриләрдер» Казан университеты тирәсендә?! Зур калаларның архивларына ешрак юлласалар, барган саен бер диссертация күтәреп кайтырлар иде ләбаса. Диссертация үзмаксат түгел анысы, халкыбыз алардан чын татар тарихы турында кызыклы, төпле, нигезле китаплар, очерклар, мәкаләләр көтә.

* * *

Алдарак бәян ителгәнчә, саллы архивларда һәм зур китапханәләрдә татарлар хакында ымсындыргыч мәгълүматлар, «әскерттәге энә»ләр биниһая күп булса да, аларга йөргән елларымда мине гел генә алгысытып торган төп тема берәү генә иде дисәм, хакыйкатьтән ерак китмәмдер, мөгаен. Күңелне даими борчыган, хафаландырган, җилкеткән һәм дәртләндергән, ниһаять, газаплаган нәрсә — ул Батырша язмышы иде. Дөрес, мин әле аның хакында ни дә булса язу хакында хыялланмыйм, андый уй башка да килми хәтта. Әмма бу каһарман шәхеснең шактый серле язмышы, аның әле революциягә хәтле дә юньләп телгә алынмавы, ә совет чорында бөтенләй архив тузанына күмелүе, әлбәттә инде, татарлыгы һәм безнең милләт кешеләреннән берүзе диярлек иң коточкыч, иң әшәке кальга — крепость Шлиссельбург зинданына ябылуы, бу исә тереләй кабергә күмелү белән бер, тиңе булмаган шартларда аягүрә горур үлүе һич кенә дә тынгы бирми иде. Тарихтан билгеле, Шлиссельбург зинданнарына теләсә кемне япмыйлар, анда үтә хәтәр сәяси тоткыннар гына гомерләренең соңгы көннәрен кичерәләр. Димәк, Батырша — патша Россиясе өчен бик тә куркыныч сәясәтче, башбирмәс узаман. Менә шуңа да барган бер җиремдә аның хакындагы «энәләр»не бөртекләп җыйдым каһарманның бөтен тормышын, кылган гамәлләрен, тарихтагы урынын күз алдына китерергә тырыштым.

Ул бөек зат белән әүвәл борынгы китаплардан таныштым. Һич уйламаганда-көтмәгәндә, революциягә хәтле басылган әдәбиятта аның турындагы мәгълүматлар шактый булып чыкты. Шул җәһәттән караганда, хәрби тарихчы Н. Ф. Дубровинның «Пугачев и его сообщники» (Санкт-Петербург, 1884) белән В. Н. Витевскийның «И. И. Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г.» (Казан, 1897) дигән күптомлы китаплары аеруча бай эчтәлекләр. Мәсәлән, Батыршаның Идел белән Урал арасындагы барлык төрки халыкларга язган «егетләмәк вә кыздырмак» хатларының татарча тексты бүгенгә кадәр табылганы юк. Ә В. Н. Витевский китабында ул тулысынча китерелгән. Дөрес, монда мөрәҗәгатьнең урысчага тәрҗемә ителгән варианты китерелә. Алай да бу инде бөтенләй булмаган ише түгел.

1755 елгы халык күтәрелешенең идеологы һәм җитәкчесе турында С. М. Соловьев («История России с древнейших времен»), Н. Н. Фирсов («Инородческое население прежняго Казанского царства в новой России до 1782 г.

и колонизация Закамских земель»), П. И. Рычков («История Оренбургская» һәм «Топография Оренбургская»), А. И. Кривощеков («Историческая судьба Оренбургского края» (С. В. Ешевский) «Очерк царствования Елизаветы Петровны» (Джанур «Странички из истории русско-башкирских отношений») һәм башка хезмәтләрдә дә Батырша турында кызыклы гына мәгълүматлар бар.

Сүз революциягә кадәр урыс телендә басылып чыккан китаплар хакында бара икән, аларның үзенчәлеген әйтми китә алмыйм. Борынгылык исе аңкытып торган бу томнар үзләренең ихласлыклары, объективлыклары белән хәтердә калалар. Патша заманнарында иҗат иткән авторлар, гәрчә аларның күбесе бөекмилләтчелек чире белән интексәләр дә, совет чорындагы галимнәр һәм язучылар сыман, боргалап-сыргалап маташмаганнар. Аларда инде «колонизация» — урыстан башка халыкларга ярдәм алып килү түгел, бәлки аларны коллыкка төшерү, «басып алу» — ирекле рәвештә Россиягә кушылу түгел, бәлки бүтән халыкларның җирләрен, байлыкларын тартып алу. Әлеге иске китаплар әнә шулай туры сүзле булганнары өчен кыйммәтлеләр дә. Бүген аларны кабат бастырып чыгару һәм халыкка җиткерү бик әйбәт булыр иде.

Эзләнә торгач, мәгълүм булды: Совет власте елларында бастырылган бер-ике хезмәттә дә Батырша телгә алынган икән. Шулардан, әһәмиятлерәкләре дип, Уфа галиме Н. А. Чулошниковның «Восстание 1755 г. в Башкирии» (М. Л. 1940) һәм М. Н. Гернетның «История царьской тюрьмы» (Мәскәү, 1951) китапларын күрсәтергә мөмкин. Үзебезнең төрки телләрдә басылып чыккан әсәрләр югарыда телгә алынды инде.

Кыскасы, Батырша турында әдәби әсәр язарга ниятләгән кешегә әнә шул китаплардагы мәгълүматлар да әйләнеп чыккан иде. Ләкин минем бу юл белән барасым килмәде, исәп — ничек кенә булмасын, атаклы болачы хакында архивларда сакланып калган кәгазьләрне үз күзләрем белән күрү. Сүз архив материалларын кул белән капшап карау турында бармый, әлбәттә. Хикмәт ана мөнәсәбәтле документларны, беренче чиратта, каһарманның падишаһка язган хатын үзең укып, үзеңчә бәяләүдә. Чөнки, сизенүемчә, Батырша һәм аның мәшһүр хаты турындагы мәкаләләрдә бик үк төгәл булмаган урыннар җитәрлек, кайбер эпизодларны каһарманның кайсыбер гамәлләрен бик тә беркатлы аңлатулар, хәтта бозып күрсәтүләр бар. Монысы бер булса, үзебезнең иске татар телен шул заманда яшәгән кешенең «үз авызыннан ишетү» — бу инде язучы өчен күк капусы ачылу белән бер. Максатка ирешү өчен, билгеле ки, хатның төп нөсхәсе, ягъни татарча тексты кирәк.

Мәскәүгә чираттагы командировкамның берсендә инде укучыга таныш архивның Мәгълүматлар һәм документларны фәнни файдалану бүлеге мөдире С. Р. Долгова янына кердем. Кыскача гына теләгемне аңлаттым һәм, ишетүемчә, Батырша хатының элеккеге «Дәүләт архивы» фондында булырга тиешлеген әйттем.

— Әйе,— диде мөдир ханым ансат кына, әйтерсең, сүз өстәлендәге телефон белешмәсе хакында бара,— 7 нче фондта (шул ук «Дәүләт архивы» фонды икән) 1781 санлы дело бар. Аның беренче кисәгендәге 376—437 һәм икенче кисәгендәге 420—488 битләрдә башкорт восстаниесе юлбашчысының хаты саклана.

Мин утырган урынымда сикергәләп куйдым, аны ничегрәк карау мөмкинлеге һәм күчермәсен алу турында сорау бирергә дип, авызымны ачтым, ләкин өлгерә алмый калдым.

— Ләкин анысы хатның урыс теленә тәрҗемә ителгән тексты гына,— диде бу мөлаем ханым. Гүя башыма китереп сукты!

Минем кинәт кенә боегып, үзгәреп китүем чыраема чыкты бугай мөдир, юатырга теләгәндәй, ашыга-ашыга сүзен дәвам итте:

— Сез борчылмагыз, шул ук делоның беренче һәм бишенче кисәкләрендә гарәп хәрефләре белән керештереп язылган байтак кына кәгазьләр дә ята. Бүлек хезмәткәрләре арасында гарәпчә графиканы танучы юк. Шунлыктан аларның нинди документлар икәнен әйтә алмыйм.

Җиңел сулап куйдым, әлеге кәгазьләрне карарга теләгем барын белдердем.

— Заказ языгыз, иртәгә үк уку залына китертү чарасын күрербез,— диде ул, һаман да шул тынычлыгын саклап.

Бер кергән-кергән, фотокүчермә мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк иде, сүзне шуңа таба бордым.

— Анысы бераз катлаулырак,— диде мөдир, хәлемә кереп.— Документларның фотокүчермәләрен алуга лимит билгеләнгән — утыз сурәт, шуннан артык түгел. Сезгә хатның тулы тексты кирәктер бит?!

— Әлбәттә.

— Алайса болай итегез: хат табылган тәкъдирдә, аңардан микрофильм эшләтегез. Андый мөмкинлек бар безнең.

Ханымның тәкъдименә шатланып ризалаштым, рәхмәтемне әйтеп, уку залына ашыктым, заказ бланкларын тутыра башладым.

Бар бит дөньяда әйткән сүзендә тора белүче эшлекле кешеләр! Иртәгәсен инде күңел бик тансыклаган 1781 нче кенәгә мине көтеп тора иде. Кадерле томны кочагыма алдым, шатлыгымнан кая басканны белми, «үз» өстәлем янына томырылдым, урыныма утырыр-утырмастан актарынып, гарәп хәрефләре белән сәйләнләнгән битләрне эзли башладым.

Чү, менә ул! Алдымда моннан 240 еллар элек шөһрәтле Батырша кулындагы каурый каләм белән тигез итеп язылган (минем инде аның шулай икәненә иманым камил иде) юлларны күргә, әллә нишләп киттем. Әйтерсең лә тарих дигән нәрсә тере һәм ул күзләрен мөлдерәтеп миңа карап тора. Ирексездән, маңгаема чыккан тирне сөртеп алдым һәм, бераз тынычлану нияте белән, күзләремне йомдым. Тукта, мин бит әле бу кәгазьләрдә нәрсә язылганын белмим. Бәлки, алар Батырша хаты түгелләрдер дә. Җитмәсә, минем гарәп имлясы белән язылганнарны укуым энә белән кое казуга тиң. Бу залда исә иске татар язуын укырлык кеше табылуы, ай-һай. Сөенечем көенеч белән алмашынды. Алай да башны салырга исәп юк, гарәп шрифтлары белән басылган китапларны акрынлап булса да укыйм ла.

Бөтен гайрәт-дәрманымны туплап, зурайткыч пыяламны тылсымлы юллар өстеннән шуыта башладым. Бик озак маташа торгач, беренче сүзнең хәрефләрен бүгенге тамгалар белән билгеләдем: «Г... и...з...з...ә...т...л...ү». Уңышым миңа өр-яңа көч-куәт өстәде, җан талашып эшемне дәвам иттем.

Вакыт, хәтта тәмәке дигән нәрсәләрне дә онытып күпме утырганмындыр, ниһаять, алдымдагы чиста кәгазьгә үз кулларым белән төшерелгән заманча хәрефләрне җыя-укмаштыра, ошбу җөмләне укыдым: «Гиззәтлү дәүләтлү падишаһымыз газими хәзрәтләренә кем тәхет вилайәтендәдүр рус мәмләкәте вә һәм гайреләр вә һәм гайреләр вә һәм гайреләр». Бу сүзләрне атаклы Батырша хатының башы икәненә иманым камил булса да, арткарак күчеп тагы берничә урыннан сукалап карадым. Шик калмады — бу Батырша хаты иде!

Ул атнада нинди дә хыялый дөньяда очынып яшәдем — бәһасез табышка юлыгу шатлыгы зур иде. Әмма бу уңайдан сызланасы мизгелләр дә булган икән. Анысы атна узып, кадерле кенәгәне кире тапшыргач булды. Кабат таныш бүлмәләргә кереп, хатның микрофильмын эшләргә заказ яздым. Аны архив хезмәткәренең кулына тапшырганда минем йөз-кыяфәтемдә Берлинны алган солдат чалымнары булгандыр, мөгаен. Кулыма счет бланкы китереп биргәч кенә суга төшкән тавык хәлендә калдым: анда күрсәтелгән сумма шактый зур иде, ә минем кесә ягы шактый сыек. Нишлисең, Мәскәү маржалары алдында сер биреп булмый бит инде, кайту юлына дип аерым куйган акчаны чыгарып салдым. Әйдә, хәерле булсын, өйгә кайту өчен Мәскәү хәтле Мәскәүдә бурычка акча табып булыр әле.

Бу хәл кәефемне шактый гына кырса да, гомумән алганда, күңел күтәренке иде. Узган бер атнада Батырша хатының урысча текстын укып чыктым, теге кенәгәдәге башка язулар белән таныштым. Мине иң сөендергәне шул булды: Батырша үтерелгән елны, ягъни, 1762 елда Шлиссельбург кальгасының коменданты булып торган полковник Бередниковның каһарман үлеме хакындагы хәбәре дә шушы ук томга төпләнгән иде. Минем исә шул доклад язуын бик тә күрәсем, аны үзем укып карыйсым килеп йөргән вакыт. Хикмәт шунда, М. И. Гернет үзенең «Патша төрмәсе тарихы» китабында Батыршаның һәлак булуы хакында: «Аның үлеме сугыш кырында булды», — ди, икенче бер урында исә аның патша ялчылары белән соңгы бәрелешен «романнарга торышлы соңгы кыю адымы» дип бәяли һәм, комендант Бередников рапортына таянып, бола башлыгының каһарманнарча дөньядан китүен тасвирлап бирә.

Әлеге китапта крепость коменданты докладының эчтәлеге генә китерелгән, безнең татарлык бар бит әле — тотып карамыйча ышанып булмый. Һәм менә әллә кайчангы канлы вакыйганың шаһиты үзе кул куйган иске кәгазь минем алда. Саргайган документлардан күренгәнчә, диварларыннан кошлар да очып керә алмаслык шушы крепостька Батырша 1757 елның урталарында китерелә. Рәсәйнең иң әшәке зинданында биш ел газапланганнан соң, тәмам рухи төшенкелеккә бирелгән каһарман 1762 елның 24 июлендә, сакчының йоклап китүеннән файдаланып, бу коточкыч тәмугтан качмакчы була һәм шул көнне патша җәлладлары белән тигезсез көрәштә һәлак була. Крепость коменданты полковник Бередников пайтәхеткә моны түбәндәгечә хәбәр итә (язманың шул еллардагы

рухын саклау өчен, текстны документтагыча китерәбез): «Оной колодник взял принесенный солдатом Хомутовым топор, по одиночке у капрала Никитина тем топором голову разрубил на двое; у солдата Хомутова головы левую сторону разрубил и правый висок проломил: у Лазарева в двух местах брюхо пропорото: у Епифанова, который был на часах, в двух местах голову разрубил же. Оной колодник Батырша и сам умер без всяких язв и побой?)».

Үз жанын саклау өчен кеше нәрсә эшләмәс тә, ни алдамас. Батыршаның кыйналмыйча гына үлеп китүенә тарихчы-тикшеренүчеләрдән берәү дә ышанмый, әлбәттә. Тик канлы вакыйганы үзең күреп тормагач, шушы саргайган кәгазь кисәге белән канәгатьләнергә туры килә. Доклад язуыннан без Батыршаның крепость дивары артындагы чокырга күмелүен дә һәм сакчылардан каһарман балтасына эләкми калганнарының исән икәнлекләрен дә беләбез. Комендант исә, һич оялмый-тартынмый, дөмекми калган ике сакчыны судка бирмәскә боеруын хәбәр итә.

Саргаеп-көеп беткән бу документның эчтәлеге таш бәгырьле кешене дә сыкрандырырлык, әлбәттә. Мин дә күзләремне йомып, башымны иеп байтак утырдым. Бу искиткеч шәхес турында роман язу теләге минем күңелдә нәкъ шул мизгелдә туандыр, бәлки.

Инде кабат хат күчермәсенә килгәндә, өйгә кайткач миңа аның белән озак мәшәкатьләнергә туры килде. Ничек итеп микрофильмны уку өчен аппарат эзләвемне гарәп хәрефләре белән язылган текстны ныгытып аңлау өчен төннәр буе утыруларымны язып тормыйм. Алай да бу эшләрнең моңа хәтле басылган хезмәтләрдәге шактый гына төгәлсезлекләрдән, төрлечә бозулардан арынырга ярдәм итүе турында бер-ике мисал китерү артык булмас, дип саныйм. Мәсәлән, хатның төп нөсхәсен укыгач, мин Батыршаның восстание бастырылганнан соң кайсы авыл мәчете базында яшеренеп ятуын ачыкладым. С. Алишевның «Казан утлары»нда басылган язмасында әлеге авыл «Иски дигән авыл» дип бирелә. Г. Хөсәенов китабында исә ул «Иске авыл» дип күрсәтелә. Боларның һәр икесеннән әлеге авылны һич ачыклап булмый. Батырша хатының төп нөсхәсен укыгач, мәсьәлә бик ансат ачыклана. Чөнки анда «Нәдер старшинаның иске авылы» дип бик ачык әйтелгән. Ә бу авыл — бүген Татарстанның Лениногорск районына керә торган Сугышлы авылы. Гомумән, төп нөсхә Батыршаның 1755 ел көзендә, кышында һәм 1756 елның язында Бөгелмә төбәгендә яшеренеп йөргәнен белергә ярдәм итә. Монысы инде безнең өчен вак мәсьәлә түгел.

Янсә тагы бер мисал: Г. Хөсәенов Батыршаның туган авылы Карышбаштан урманга китүе хакында болай яза: «... Төрле төбәкләрдә кабынган восстаниегә житәкчелек итәр һәм бердәм хәрәкәткә әверелдереп жибәрер урында, үзен көтеп торган кораллы якташлары — гаиләләрне ташлап, урманга качуны хәерлерәк күрә. Батырның бахырга әйләнүе шушыннан башлана... Капыл азап калган халык Батыршаның әмеренә һәм житәкчелегенә мохтаж кырку мәлдә, башлыкка үз башы аяулырак булып чыга шул.» Гомумән, авторның мәгълүм мәкаләсендә Батырша восстаниенең иң кызган вакытында коты очып качкан, житмәсә, бер тартынусыз гаиләсен ташлап калдырган куркак жан итеп бирелә. Каһарманның иң мөһим вакытта каушап калуы хак анысы. Әмма аның үз кулы белән язган хатын жентекләбрәк укысаң, узаманның һич кенә дә куркып калмавын, бәлки урманга китүнең шул көннәрдәге хәлләр мәжбүрияте (тирә-як карат отрядлары белән урап алынган) икәнен аңлыйсың. Хат текстыннан күренгәнчә, урамга жыелган кораллы халык та гаиләләр түгел, бәлки Батыршаны тотарга килүчеләр. Әлеге яугирләр узаманга чиксез хөрмәт саклау йөзеннән генә аны исән-имин үткәреп жибәрәләр. Аның берничә каршылыксыз гаиләсен ташлап качуы да ышандырмый. Батырша үзенең хатын падишаһка аклану өчен яза ич. Димәк, ул хәйлә-ялганга барырга, кайбер ситуацияләрне аңлы рәвештә матурлабрак күрсәтергә мәжбүр. Тикшерүче галим бу мөһим нәрсәне күз уңында тотарга тиеш иде.

Батырша хатының төп нөсхәсен үзең укып чыгу хажәтлеге һәм байтак кына нәрсәләрне ачыклауда ярдәм итүе турында мисалларны күп китерергә мөмкин. Әмма китерелгән кадәресе дә бу эшнең тәжеллеген бик ачык күрсәтә. Нәтижә ясап шуны әйтергә була: әлеге хатны үзең жентекләп һәм кат-кат укымый торып, бөек шәхес турында ихлас һәм риясыз әсәр язуны күз алдына китерүе дә кыен.

Батырша турында архив материаллары мин күргәннәр белән генә чикләнмиләрдер, әлбәттә. Кайдадыр аңардан сорау алу беркетмәләре, тагы әллә нинди документлар тузан жыеп яталардыр әле. Әнә бит В. Н. Витевский тапкан: үзенең китабында ул Батыршаны тотып бирүче татар старшиналарының (Сөләйман Дивеев, Яныш һ. б.) язмышларын, аларга нинди бүләкләр тапшырылуын, ул

бүләкләрне ясаучы осталар, хәтта һәр бүләкне әзерләү өчен күпме затлы металл, асылташ китүенә кадәр тәфсилләп яза. Димәк, безнең фараз дөрес, узаман ир турында башка мәгълүматлар тагы кайлардадыр ауный. Кызганыч ки, безнең хәерчелек озын-озак эзләнүләр алып бару мөмкинлеге бирми.

Урысларның Козьма Прутковка сылтанган бик әйбәт әйтемнәре бар: кочаклап булмастайны кочаклый алмыйсың. Табылган кадәренә канәгать булыйк. Батырша хакында җыелган материаллар аның шәхесен, акылын-фигылен, гыйлем-тәррәкыятен, уй-фикерләрен, халык алдындагы базары-абруен, кыюлыкгаярьлеген, үз халкына, иманына тугрылыгын һәм башка сыйфатларын күзалларлык, аның якты образын гәүдәләндерерлек. Алай да Петербург хәтле Петербургка килеп, ничек инде ул газап чиккән җир өстендәге тәмугны, ул соңгы сулышын алган зинданны күрми, якынча булса да билгеле каберен зиярәт кылмый китәсен. Болай да сузылган командировкамны тагы бер-ике көнгә озайтып, исеме мәктәп эскәмиясеннән үк телебездә шомарып беткән Шлиссельбург кальгасын карарга ният иттем.

Бәхеткә, каладан житмеш чакрым ераклыктагы ул утрау-крепостька туристлык теплоходлары йөреп тора икән. Без дә, бер төркем туристлар белән, кояшлы иртәдә Нева буйлап сәфәр чыктык. Болыт булып акчарлаклар озата барган теплоход палубасына басып, тирә-яктагы яшел киңлекләрне карый-карый, уйга бату үзе бер хозурлык. Кайсы якка гына бакма, анда яткыллар, сазлыклар. Бүген да йөрәккә шом салырлык ул сазлыкларда Нева ярындагы яңа пайтәхетне салырга килгән меңнәрчә бабаларыбызның сөякләре ятып калган. Әнә тегендәрәк, аз гына калкуланып торган җирдә, Гитлер явыннан саклануччыларның оборона сызыгы булган, диләр. Шул тирәләргә күмелгән ата-бабаларыбыз да чутсыз. Уйлап карасаң, Рәсәй өчен күпме кан түккән дә, күпме гомерләр корбан иткән татар! Ә үзе Рәсәй кулыннан, Рәсәй казнасыннан ни алган соң? Анысына җавап, гади генә итеп, авылча әйткәндә, шымытыр.

Яр буйларында авыллар, ниндидер торак пунктлар күренеп-күренеп кала. Шуларның кайсындадыр 1773 елның көзендә Оренбургның беренче губернаторы, ата колонизатор, Батырша явын бастыруга һәм аның җитәкчесен тотып бирүгә күп көч куйган Неплюев дөнья белән бәхилләшә. Гаҗәп инде бу дөнья, җиңүче Неплюевның да, җиңелүче Батыршаның да сөякләре Нева буеның дымлы җирендә янәшә диярлек яталар.

Уйлана торгач, килеп тә җиткәнбез. Чыннан да, бик шәп урынга салынган икән бу борынгы Орешек — нәкъ Нева елгасының Ладога күленнән агып чыккан җирендә. Дошман корабларына уңнан да, сулдан да узышлы түгел, кальга диварындагы туплар аларны чәкеп кенә торачаклар. Хәер, монда инде хәзер бернинди туплар да юк, музей булып калган утрау-крепостьта тыныч моңсулык.

Озын һәм бормалы итеп салынган такта күперчекләрдән утрауга узабыз. Алай, биргән икән немец бу Шлиссельбургның кирәген — бөтен җирдә хәрабәләр, кирпеч ватыклары. Мәгәр тарихи крепостьның дәһшәтен күз алдына китерерлек. Диварларының биеклеге ундүрт, киңлеге җиде сажин. Немец самолетлары, кальга өстенә үк төшеп, аны айлар буе бомбага тотканнар, ләкин таш диварларны ишә алмаганнар. Шушы бәләкәй генә ныгытма дошманга бирелмәгән. Әмма да нык зыян күргән крепость — күп кенә урыннарда диварлар умырылып-умырылып төшкән. Утрау өстендә немец очкычлары мыжлап торган ул көннәрдән бирле 45 елга якын вакыт үткән, тик Совет хөкүмәте диварларны төзәтергә акча тапмаган, крепость кичә-бүген генә азат ителгән кебек. Аерым оешмалар, фидакарь җаннар тырышканнар тырышуын: исән калган биналарны тәртипкә китергәннәр, шуларның берсендә музей ачканнар, берничә урында элеккеге зиндан камераларын реставрацияләгәннәр. Әмма алар инде чын зиндан түгел, күбрәк сәхнә декорациясен хәтерләтәләр. Мәгәр шул көенчә дә җанны өшетерлекләр. Кыскасы, монда карап йөрерлек әллә ни юк, ләкин, яхшы экскурсовод булганда, тыңлар нәрсә бихисап. Кызганыч ки, без экскурсоводтан уңмадык. Гәүрәтен капларлык кына кыска юбка кигән, кофтасы кендегенә кадәр ерылган бу яшь марҗаның сөйләвендә рәт юк. Ул әйләнә-тулгана да, Ленинның зинадан туган абыйсы хакында сөйли башлый, Александр асылган урынны сантиметрына кадәр төгәллек белән күрсәтә. Туристлар сорау биргәләгәч, Батырша белән бергә бер үк вакытта тоткынлыкта яткан император Иван Алтынчы, язучы һәм журналист Николай Новиков, ниндидер алхимик Беликов һәм башка кайбер шәхесләр турында да мәгълүматлар биргәләде бу, тик безнең якташыбыз турында ләм-мим. Түзмәдем, сорау бирдем:

— Монда татар-башкорт восстаниесе җитәкчесе Батырша да утырган, диләр?

Ханым миңа канәгатьсез караш ташлады, иренеп кенә әйтеп куйды:

— Андый сүзләр бар-барын.

— Ул яктан хөҗрәне, һич югы хөҗрә урынын күрсәтә алмассызмы? Бәлки, аның кабере билгеледер?

— ?

— Ни хикмәттер, музейда Батырша турында экспонатлар юк. Ә архивларда аның хакында кызыклы гына мәгълүматлар бар, диләр. Монысын ничек аңларга?

Акшарлы ханым миңа шундый итеп карады ки, эчкә салкын йөгерде хәтта. Ата шовинистларның әнә шундый зәһәрле карашларын Себердә бер тойган идем инде мин. Хәтердә: Тубылга килеп төшкәч, партиянең шәһәр комитеты секретаре семинарга килгән журналистлар белән очрашты. Себерне басып алган юлбасар Ермакның каһарманлыгы, шәһәрдәге предприятиеләр, алардагы социалистик ярыш турында бик озак сөйләде бу. Аннан инде мәгълүм булганча сораулар. Без, Татарстан журналистлары да, ана үзебезнең сорауларны әзерләп куйган идек. Берәм-берәм басып, аларны шәһәр башлыгына бирдек: Тубыл районында күпме татар яши? Аларның милли мәктәпләре бармы, китапханәләре ни хәлдә? Шәһәрдә чыга торган татар гәзите нигә ябылды? Педагогия институтының татар бүлеген ни өчен бетердегез? Шулвакыт залда купкан тавышны ишетсәгез иде сез: «Татарстан делегациясе провокация оештыра!», «Милләтчеләр!» һәм башкалар. Ә Рәсәйнең төрле төбәкләреннән килгән каләмдәшләребезнең күзләре нәкъ шушы маржаныкы кебек нәфрәт белән яна иде...

«Мәсьәләне төшенеп, телемне тешләдем һәм, төркемнән аерылып, крепость диварына менеп киттем. Батырша кайдарак күмелде икән соң дип, биек диварлар буйлап озак әйләндем, алар артындагы вак ташлы яр буйларын карадым. Әмма аяусыз вакыт дигәнең атаклы шәхес кабереннән эзен дә калдырмаган иде. Кыскасы, Шлиссельбург миңа Батырша хакында сынар мәгълүмат тә өстәмәде. Алай да бу кырыс кальганы, кайчандыр мәхбүсләр яткан диварлар төбендәге чокыр-хөҗрәләрнең урыннарын якыннан күрү бик кирәк иде миңа.

Петербургтан мин шактый тынычлап кайттым. Уф-ф, монысы Батырша эзләренә салынган сәфәремнең соңгысы бугай. Инде булдыра алган кадәр материал җыелды. Аларны башымда «кайнатып» тәртипкә китерәсе, «татар Пугачевы» турында язылачак әсәремнең кысасы, композициясе, сюжеты, образлары һәм башкалары хакында уйланасы бар. Әйе, сәфәрләр тәмамланды кебек, ә башта уй-исәпнең очы-кырые юк. Әнә шул рәвешле көне-төне кабат дөньяга туачак каһарманым белән хыялланып йөри торгач, бервакыт исемә килеп төшмәсенме: Тукта, мин бит аның туган авылында, ул гомер сөргән якларда булмадым. Дөньяга Батырша кебек каһарманны биргән төбәкнең табигате, бүгенге кешеләре нинди? Карышбаш авылында (хәзер — Югары Карыш) аның токымы калмаганмы, атаклы авылдашлары турында риваять-истәлекләр белүчеләр юкмы? Кем белә, бәлки анда музей бардыр, анысы булмаса, Батырша туган өйнең, ул торган мәдрәсәнең урыны билгеледер — һәрхәлдә, туган төягендә олуг шәхеснең эзләре бөтенләй җуелмагандыр?!

Болай күрәзәлек итүдә мәгънә юк иде. Каләмдәшләр мине аңларлар, ярдәм итәрләр дип, Башкортстанның Балтач районы газетасы редакциясенә хат яздым. Күп тә үтмәде, «Җиңү байрагы» (соңрак — «Азатлык») газетасы фирмасы басылган кәгазьдә мөхәррир М. Шәрипов имзасы куелган җавап килеп төште. Мөхәррир әфәнде минем хат белән Югары Карыш урта мәктәбенең тәрбия буенча директор урынбасары Наил Хаҗиевны таныштыруын хәбәр итә. Наил әфәнде, үзе математика укытучысы булса да, төбәкчелек белән бик кызыксына, газетага тарихи темаларга мәкаләләр дә язгалап тора икән. «Ул Сезнең адресыгызны алды һәм Батырша мулла турында булган мәгълүматларны һәм кайбер башка киңәшләрен язып җибәрергә, дип ышандырды»,— дип дәвам итә Шәрипов әфәнде.

Ике-өч көннән соң яңа танышым Наил Хаҗиевтан хат килде һәм барысы да урынына утырды. Ул Балтач якларында юлларның начар булуын хәбәр иткән һәм кышка каршы (язышу кара көз айларында) юлга чыкмау мәслихәтлеген әйткән. Наил әфәнде язган кадәреннән шунысы да мәгълүм булды: Югары Карышта, гомумән, ул төбәктәге, Батыршаның нәсел-нәсәбе калмаган, шулай ук аның турында истәлек-риваятьләр дә сакланмаган диярлек. Булган кадәр бер-ике риваять «Башкорт халык иҗаты» китабына кертелгән. Шунысы күңелгә хуш килде, Наил әфәнде буш сүз сөйләүчеләрдән булмыйча, эш кешесе икән. Хатында ул Батырша хакында Башкорстанда чыккан нинди китаплар һәм газета-журналлар укырга мөмкин икәнен киңәш итеп кенә дә калмаган, бәлки үзенең район газетасында басылган «Батырша турында чынбарлык һәм легенда» дигән очер-

кын, «Агыйдел» журналының 1970 елгы 10 нчы санын һәм 1956 елда ук урыс телендә басылган «Башкортстан АССР тарихы буенча очерклар» китабының 1 нче томын җибәргән.

Шуннан инде Наил әфәнде белән безнең арада даими язышу башланды. Мин аңардан әледән-әле алып торган хатлардан Балтач районы һәм Югары Карыш авылы, ул якларда яшәүче мишәрләр, төбәкнең табигате һ. б. турында бик күп мәгълүматлар, эшем өчен кирәкле киңәшләр алдым. Без инде, язышa торгач, тормыш-көнкүреш, тарих-әдәбият хәлләрен генә түгел, гаиләләребез белән дә танышып беттек. Кыскасы, Наил әфәнде Хаҗиев, һич кенә дә иренми торган тынгысыз җан, минем өчен чын хәзинә иде — мәгълүмат-киңәшләре, китап-журналлар белән даими ярдәм итү өстенә, ул мине зур эшкә рухландырып торды. Бу хакта сүз озайтмастан, аңа рәхмәтемнең чиксез икәнен генә әйтеп үтәм.

Мәгәр мин кайчан да булса ул якларга барып чыгасымны белеп яшәдем. Вакыйгалар агышыннан алгарак китеп булса да, әйтим, бервакыт моңа форсат та килеп чыкты. 1992 елның ноябрь аенда халык депутатларының Балтач район Совет һәм җирле хакимият исеменнән күренекле җәмәгать эшлеклесе, фикер иясе, язучы, 1755—1756 елларда колониаль изүгә каршы көрәшнең идеологы Абдулла Галиевның (Батырша) тууына 275 ел тулуга багышланган тантанага чакыру алдым. Ерак юлга ничегрәк чыгу хакында уйлап бетермәдем, халык депутатларының район Советы рәисе җирле хакимият башлыгы Рәшит әфәнде Исламов исеменнән телеграмма килеп төште.

Уфадан без Тәтешлегә бара торган автобуска утырып киттек. Уфа — Пермь юлы бик әйбәт, көне дә начар түгел — кәефләр яхшы. Бер килсә, килә бит, юлыбыз Батырша язмышына бәйле Борай районы аша үтә икән. Уң яктагы юл күрсәткеченә «Азяково» дип язылган (ишлисең, Рәсәй бит, татар авылларының үз исемнәрен дә белеп булмый). Тукта, бу моннан 236 ел элек Батырша тотылган Әҗик авылы түгелме соң? Сораша торгач, аның нәкъ әнә шул авыл икәне ачыкланды. Ул олы юлдан шактый читтә булса да, Әҗик турыннан башымдагы бүрегемне салып үттем.

Балтачта һәм Югары Карышта без район һәм авыл белән танышып кына калмыйча, анда яшәүчеләрдән тыш, шушы төбәктә туып-үскән күп кенә галимнәр, артистлар, рәссамнар, Социалистик хезмәт каһарманнары һәм башка могътәбәр кешеләр белән дә очраштык. Шунысы гына күңелне борчыды: Россия Федерациясенең һәм Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Айрат Гали улы Арсланов кына, ни сәбәпледер, туган ягына кайта алмаган иде. Ул кайтса, Татарстаннан икәү буласы икәнбез. Хәер, болай да ямансыларга туры килмәде.

Олуг затның ошбу зур юбилеен Татарстанда да билгеләп үтү кирәклеген дәлилләп, мин үзебезнең тарихчы галимнәребезгә һәм кайбер рәсми оешмаларга хатлар да язган идем. Берсеннән-бер җавап кына да алмадым ичмасам.

Башкортстанда уздырылган дүрт көн хакында үзенә бер китап язарга мөмкин. Сүзне озынга җибәрмәс өчен, бер генә нәрсәне билгеләп үтәсе килә. Мәшһүр Батыршаның туган яклары турында сөйләгәндә мондагы халыкның искиткеч кунакчыллыгы хакында дәшми калу мөмкин түгел. Батырша юбилеенә багышланган тантаналар барган өч-дүрт көн буе җирле хакимият башлыгы, аның урынбасарлары, югары Карыш мәктәбе укытучылары һәм башка иптәшләр кунаклар янында тәүлек әйләнәсенә китмәделәр диярлек. Юбилейга килүчеләрне (алар исә җиде дистәдән артык!) ашату-эчертү мәшәкатьләрен җирле хакимият һәм Югары Карыш авыл Советы үз өсләренә алды. Ә табыннар чын мәгънәсендә нигъмәтләрдән сыгылып тора иде. Анда татар халкы пешерә торган аш-суның бөтен төре дә булгандыр, мөгаен. Хәтта бик тә тансык балан бәлеше белән чөгендерле катыкка кадәр куелган иде өстәлләргә.

Район үзәгендә һәм Батыршаның туган авылында үткәрелгән кичәләр аларда катнашучыларның биниһая күплеге, халыкның тамаша залларына гына сыешмыйча, фойеларга бөялүләре белән аерылып торды. Анысы бер булса, сүз алып сөйләүчеләре кемнәр диген: абруйлы галимнәр, министрлар, республика җитәкчеләре, язучылар, артистлар, рәссамнар... Ишләптер сәхнәдә урыннарыбыз гел янәшә килеп торган Европа һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие Шәйхел-Ислам Тәлгать Таҗетдинны гына алыйк. Мин аның эчтәлекле, төпле, акыллы чыгышларын һәрчак сокланып тыңлыйм. Ул, безнең кайбер галимнәр һәм муллалар сыман, диннең мифик ягы белән мавыкмый, бәлки аның дөнья белән бүгенге тормыш-көнкүреш, фән-мәдәният белән бәйле, диннең әхлак тәрбия чарасы икәненә басым ясый. Бу юлысында да ул «мулла булып муллаларны кулларына кылыч алырга җиткергән заман» турында, Батырша рухы, аның

кылган изге гамәлләре хакында бик матур сөйләде. Башка ораторларның да сүзләре гаять саллы иде. Әнә шундый шартларда ничек итеп чыгыш ясарга? Өстәвенә, минем сөйләвем дә бик әйбәттән түгел. Татарстаннан килгән бердән-бер кунак һәм каһарман турында беренче роман авторы буларак, дәшми калу да ярамый. Кыскача гына «Батырша» романының язылу тарихыннан берничә сүз әйтәм, аннан инде Батырша традицияләрен саклау, аның идеяләренең бүген дә яшәве һәм актуальлеге, татар һәм башкорт халыклары бердәм булганда гына Батырша хыялларының чынга ашачагы, ниһаять, һәр ике халыкның мөстәкыйльлек алачаклары хакында сөйлим. Артыгын тәэсирләнә идем бугай, үземнең чыгышларымнан канәгать калмыйм. Тик район үзәгендәге чыгышымнан соң Башкортстан Министрлар Советы рәисе урынбасары Мансур әфәнде Әюпов кулымны кысып: «Рәхмәт, бик матур сүз әйттегез»,— дигәч кенә күңел булды.

Мин рәсми чыгышларымда гына түгел, аш мәҗлесләрендә дә сикереп төшмим, күбрәк тыңлап утырырга тырышам. Моның үзенә күрә сере бар. «Батырша» романы, без монда килгәнчегә кадәр үк, «Казан утлары»нда басылып, укучылар арасына таралырга өлгергән иде. Шул уңайдан Башкортстан матбугатында берничә мәкалә чыгуы һәм кайбер «башкортчы»ларның, Батыршаның татарлыгын кычкырып әйткән өчен, мине бик каты сүгүләрен белә идем. Романны язганда кайбер мәсьәләләрдә ярдәм сорап, Башкортстанның берничә галименә һәм Язучылар берлегенә язган хатларымның җавапсыз калулары да исемдә. Гомумән, татар-башкорт мәсьәләсе...

Батырша юбилеена барачагым тәгаенләнгәч, Башкортстанның административ-территориаль бүленеше турындагы китапка күз салдым һәм, инде әлбәттә, беренче чиратта Балтач районын карадым. Мондагы авылларның барысы да «башкорт» авыллары дип язылган. Мин әлегә ул якларны белмим, шулай да Югары Карыш авылында яшәүчеләрнең чыкылдап торган мишәрләр икәне миңа мәгълүм. Шулай ук Балтач районында чыга торган «Азатлык» газетасының саф татар телендә басылуын үз күзләрем белән күреп беләм. Ничек болай килеп чыга соң әле? Белешмәгә караганда, районда гел башкортлар яши, район газетасы исә татарча чыга. Янә дә килеп, гел мишәрләрдән торган Югары Карыш авылы ничек әле башкорт авылына әверелгән? Әнә шундый сораулар миңа һич кенә дә тынгы бирмәде. Юлга чыкканчы да, поезда да һәм автобуста да шулар хакында уйланып бардым һәм килеп төшүгә әнә шуларга җавап табарга тырыштым.

Хәер, җаваплар автобуста барганда ук табыла башлады. Балтачка һәм Тәтешлегә кайтучыларның барысы да диярлек саф татарча сөйләшәләр иде. Балтачка килеп төшкәч тагы да хәйран калдым. Монда бөтен җирдә, шул исәптән җирле хакимият бинасында да гел татарча сөйләшәләр. Тагы да гаҗәбе — җитәкче хезмәткәрләр арасында юри генә дә бер урыс кешесе юк, башкортча сөйләшүчеләре дә күренми. Җаен чыгарып, җирле хакимият башлыгының мәдәният һәм сәнгать буенча урынбасары Рәфкать Хәкимҗан улы Әхкамовка район халкының милли составы хакында сорау бирдем.

— Бездә,— диде Рәфкать әфәнде,— халыкның 80 проценты чамасы татарлар, үзләрен башкорт дип яздыручылар да башкортча сөйләшә белмиләр, чөнки тумышлары белән татарлар. Моннан тыш, районда биш мең чамасы мари һәм удмурт яши. Тик алар да татарча сөйләшәләр.

Шулай булгач, нишләп соң әле теге мин караган белешмәдә районның бөтен халкы «башкорт» дип язылган, мондый ялган кемгә кирәк булган? Хәл менә болайрак булган икән: 70 нче еллардагы халык санын алуда, кемнең кем булуына карамастан, барын да «башкорт» дип язганнар, шул исәптән Югары Карыш авылы мишәрләре дә башкортка әверелгәннәр. Ул еллардагы шаукымнан көлеп, җирле хакимият башлыгы Рәшит әфәнде Ислам болай ди:

— Мин үзем бер төн эчендә бүтән кеше булдым да куйдым. Югары партия мәктәбенә укырга китәсе булгач, төн чыкканчы паспортны да, партия документларын да башкортка әйләндерделәр дә куйдылар.

Югары Карышта мин элек гөрләп торган татар мәктәбендә урысча укытуларына шаккатып, шул хакта сорамый булдыра алмадым. «Башкортча укытуны көчләп тага башлагач, лутчы урысчага күчик, дип уйлаштык»,— диделәр миңа педагоглар. Печән өстендәге эт мисалын тагы кайдан эзлисең.

Дөрес, соңгы еллардагы ирек һәм демократия чалымнары хәлне шактый үзгәрткән. Соңгы переписьта күпчелек үзен «татар» дип яздырган. Әмма дөньялык турында күбрәк уйлаучы байтак кына кеше һаман да башкорт булып калган, тик алар башкорт телен дә, аның гореф-гадәтләрен дә белмиләр икән. Әнә шуңа да, районның кайсы гына авылына барып төшмә, урамда, мәгариф-мәдәният учреждениеләрендә, административ биналарда татар рухы өстенлек итә, төрле

кичәләр һәм концертлар гел татар телендә бара. Әле күптән түгел генә Казан радиосыннан ишетелгән яңа җырларның мондагы сәхнәләрдән яңгыравы гадәти хәл.

Гомумән, Балтачта уздырылган көннәрдә безгә урыс телендә дә, башкорт телендә дә (Уфадан килгән берничә кешене исәпләмәгәндә) бер генә сүз дә ишетергә туры килмәде. Үзебезнең туган Татарстаныбызда көннәр буе тел сындырып, урысча сөйләшеп йөргән кешеләр өчен бу хәл гайре табигый иде. Кыскасы, без Балтач районында татар теленә, аның мәдәнияте, тарихына һәм гореф-гадәтләренә булган ихтирамга хәйран калдык.

Очрашулар, чыгышлар вакытында миңа шактый гыйбрәтле бер риваять ишетергә туры килде. Хәзер җирле хакимият башлыгының беренче урынбасары булып эшләүче Хәләф әфәнде Гәрәйшин, әтисе үлем түшәгенә егылгач, мулла чакырткан. Тегесе исә ясин чыгарга керешкән. Әмма замана мулласы ясинны шактый хаталы укый икән. Аны тыңлап торган Хәләф Вәсвиевич түзмәгән: «Туктале мулла абзый, ясинны аны менә болай укыйлар» — дип, атасына ясинны үзе чыккан. Дөрес, моның өчен аңа нервысын байтак кына талкырга туры килгән. «Әһә, син әле ясин укый беләсеңмени?!» — дип партиядән чыгарырга да булганнар. Әмма гарасат ничектер узып киткән.

Яисә менә икенче бер мисал. Миңа җирле хакимият башлыгы Рәшит әфәнде Исламовның үз куллары белән язган татарча чыгышының тексты белән танышырга туры килде. Ник кенә бер орфографик хата булсын да, стилистик чатаклык сизелсен. Кайбер журналистлар да ана телендә бу кадәр камил итеп яза алмыйлар. Әйе, чын зыялы кеше әнә шулай һәр яктан белемле булырга тиештер инде ул! Әнә шундый татар теленә, мәдәниятенә, тарихына һәм гореф-гадәтләренә игътибарлы җитәкчеләр эш иткәндә, бередә телнең, диннең, мәдәниятнең саклануы һич гаҗәп түгел. Шунысын да әйтик, тирә-күршедәге Тәтешле, Аскын, Караидел һәм башка районнардан килгән хакимият башлыкларының да татарчалары төзек, чын әдәби. Димәк, Башкортстанның төньяк-көнбатыш районнарында гел татарлар яши дигән сүз дөреслеккә туры килә.

Үзеннән-үзе шундый сорау килеп туа. Ничек соң, бу яклардагы халыкның үз телен, үз мәдәниятен үстерүе Башкортстанда ризасызлык, каршылыклар китереп чыгармыймы, татарлар белән башкортлар арасында салкынлыкка юл куелмыймы? Дөресен генә әйткәндә, мондый сорау, шик-шөбһәләр гади халыкның, гади эш кешеләренең башына да килми. Ә менә башкорт зыялылары арасында Башкортстанда татар теле, татар мәдәнияте саклануга ризасызлык белдерүчеләр турында ишеткәнебез бар. Башкорт галимнәренең, татар телен башкорт теленең көнбатыш диалекты ул, дип раслаулары, ул гына да түгел, бу хакта байтак кына «фәнни» хезмәтләр бастырулары үзе генә дә ни тора! Күп кенә укымышлы кешеләрнең Башкортстанда яшәүче бер миллион 200 мең татарның телен, урыс һәм башкорт телләре белән рәткә, дәүләт теле итүгә каршы чыгулары да бик гыйбрәтле. Кыскасы, ничек кенә булмасын, Башкортстанда (кайбер зыялылар арасында) татар-башкорт проблемасы яши, ике халык арасына салкынлык өрүче көчләр дә байтак.

Болар бит әле сүз генә, берминди дә документ түгел, диярләр бәлки кайберәүләр. Башка укучылар да әнә шундый фикердә калмасыннар өчен «Идел-Урал» демократик фиркасы һәм Уфадагы татар мәдәнияте мәркәзе газетасы булган «Идел-Урал» да басылып чыккан «Урал» башкорт халык үзәгенең Башкортстан Югары Советы һәм Министрлар Советы карамагына кертkән тәкъдимнәреннән берничә өзек китерәм: «... Рус телен милләтара аралашу теле итеп таныган һәм Башкортстанда яшәүче башка халыкларның телләрен үстерү өчен кирәкле шартлар тудырган хәлдә, башкорт теленә дәүләт теле статусы бирү турында закон кабул итәргә. Шул ук вакытта «Урал» башкорт халык үзәге республикадагы татар иҗтимагый үзәгенең татар теленә дәүләт теле яисә рәсми тел статусы бирү хакындагы урынсыз дәгъвасын кире кага».

Яисә «Матбугатның милләтне туплаучы көч булуын исәпкә алып, киләчәктә республика масштабында татарча газеталар һәм китаплар чыгаруга юл куймаска. Киләчәктә татарча басмалар чыгуын Башкортстанда татар теленә дәүләт теле статусы бирү белән бер дип санарга. БАССР Югары Советының татар теленә дәүләт теле статусы бирү хакында законы юк ләбаса. Татар телендә китаплар чыгару һәм тарату — Татарстан эше».

Әлеге «тәкъдимнәр»дә татар теленә һәм татарларга каршы болардан хәтәррәк нәрсәләр дә бар.

Хак, Батырша юбилеена багышланган тантаналарның рәсми өлешләрендә мондый нәрсәләр сизелмәде, киресенчә, сүз һәр ике милләт дус-тату яшәгәндә,

бердәм эш иткәндә генә һәр икесе мөстәкыйльлеккә ирешәчәге хакында барды. Тантаналар башланыр алдыннан без, Татарстаннан һәм Башкортстаннан килгән татарлар, бу темага кагылмаска, провокацион чыгышлар булган тәкъдирдә дә, дәшми калырга, дип килешкән идек. Һәм ул шулай булды да. Хәтта Уфада һәм Казанда үзенең кайнар чыгышлары белән танылган Кәрим әфәнде Яушев та биредә гаять тотнаклы итеп сөйләде, андый-мондый кинаяләргә юл калдырмады.

Әмма республикада татар-башкорт проблемасы шулай катлауланган, күрәсең, әлеге мәсьәлә табын янында әледән-әле калкып, үзен сиздереп торды. Уфадан килгән дуслар ошбу борынгы башкорт җирләрендә башкорт теле өстенлек итсә иде, дигән теләк белдерсәләр, татарлар монда Батырша телендә сөйләшү тиеш, һәр халык үз телендә сөйләшсен, диделәр, башкортча сөйләшүне көчләп тагучыларга үпкәләрен белдерделәр.

Уфага кайту юлында мина Агропромышленность комплексы кадрларының белемнәрен күтәрү һәм аларны әзерләү институтында укытучы булып эшләүче Самат әфәнде Гатин республикада татар-башкорт проблемасының көннән-көн катлаулана баруы хакында сөйләп кайтты. Биредә инде җитәкче урыннарга эшкә башкорт телле һәм шәрыкъ чырайлы кешеләрне генә ала башлаганнар, ә татарларга урынны бусага төбеннән күрсәтәләр икән. Шунысы гыйбрәтле: әнисе татар, әтисе башкорт булган Самат, татарча сөйләшсә дә, Уфага барганчы үзен чын башкортка санаган һәм моңа чын күңеленнән инанган. Инде Уфага килеп, монда татарларны кысу-кимсетүләрнең шаһиты булгач, үзе дә шул шаукымнан зыян күргәч, татар-милли хәрәкәтенә кушылып киткән...

Әйе, хәлләр катлаулы. Менә шуна да мин монда һәркайда дәшми утыруны кулай санадым. Хәлләр әнә шундый булуга карамастан, бу якларда яшәүче татарларның үз ана телләренә, үз мәдәниятләренә, тарихларына һәм диннәренә тартылуы көннән-көн көчәя бара. Шунысына куанырга туры килә хәзергә.

Батырша юбилеена мин зур бүләкләр алып бара алмадым. Романның «Казан утлары»нда басылган вариантын Наил Әфәнде Хажиевка җибәреп өлгергән идем инде. Ярый әле китап басылып бетте, ул кибетләргә чыгарга өлгермәсә дә, бүләккә бер экземпляр табылды. Монысы гына бик аз тоелгач, Мәскәүдә эшләнгән Батырша хаты микрофильмын да портфельгә тыктым. Бу тыйнак бүләкләрем бик ярап куйдылар тагы. Югары Карыш мәктәбенең бер бүлмәсендә Батырша музее оешып килә икән. Бүләкләрем анда Уфа рәссамы Мэлс Вафинның бик тә зәвыкълы язылган Батырша портреты (аның репродукциясе «Казан утлары» журналының 1992 елгы 7 нче саны тышлыгында басылган иде) янына урнаштылар.

Тукта, мавыгып китеп алгарак сикергәнбез икән. Мин бит романны яза башлавым хакында сөйләмәкче идем. Әйе, Батырша турында материаллар, нигездә, җыелып бетте. Ләкин әле бөек шәхес язмышын бәян иткән хикәятне әдәби итеп сөйләп бирәсе, аның язмышында өзелгән чылбырларны ялгау өчен иҗади хыялланасы, фараз итәсе, укучыны мавыктыргыч хикәяләү формасы табасы, иң әһәмиятлесе — каһарман образын тудырасы һәм тавык та чүпләп бетерә алмаслык тагы әллә ниләр эшлисе бар. Боларның барысына да ирешү өчен исә тел кирәк. Анысы да теләсә нинди тел түгел, бәлки шул заманны чагылдыручы һәм шул чорда яшәгән кешеләрнең сөйләшенә хасы. Анысы бу җәһәттән озак баш ватарга туры килмәде: романның рухына туры килә торган тел итеп Батыршаның патшага язган хатындагы үз телен файдаланырга ходай кушкан дисәк тә була. Билгеле инде, үзем белгән кадәр борынгы сүзләр дә бик ярап куячак. Алай да тел мәсьәләсендә төп чыганак — инде без күп тапкыр кабатлаган хат. Чөнки анда безнең иске татар теле тулы куәтенә чагыла, әлеге язма истәлектә авторның үзенә генә хас стиле, тел бизәкләре, шул чорның җөмлә төзелеше һәм фигыль формалары, инверсияләр парады. Батырша үз башыннан кичкәннәрне, дөнья хәлләрен һәм таныш-белешләре сөйләгәннәрне бәян иткәндә хәл-вакыйгаларны тәфсилләп күрсәтә, аерым хикәя, новелла сыман сюжетлар кертеп җибәрә, диалогларны киң куллана, халык сөйләмен, аның тел үзенчәлекләрен оста файдалана. Болар исә хатны чын әдәби әсәр дәрәҗәсенә күтәрә. Хак: хат, беренче чиратта, социаль-тарихи, документаль ядкарь, тел-мәдәният истәлеге. Шул ук вакытта ул каһарман «мажараларының кызыклы хикәясе» (С. М. Соловьев). Кыскасы, Батырша хаты сәнгатьчә әсәр поэтикасында язылган кыйммәтле документ ул. Әнә шул ягыннан карaганда, әлеге хатка тарихчылар гына түгел, тел галимнәре, әдәбият галимнәре башлап ябышырга тиешләр иде. Ләкин безнең тел-әдәбият галимнәре, кайбер тарихчы галимнәр кебек үк, татлы йокыда, тәнкыйтьчеләребез исә «урындагы» түрә язучыларны мактаудан бушаганнары юк.

Шулай итеп, романның теле мәсьәләсе чагыштырмача ансат хәл ителде. Тик менә төп каһарман Батыршаны ничек гәүдәләндерергә? Беркатлы-наи дусларымнан кайберәүләр: «Син аңардан Пугачев яса, кулына кылыч-тәпәч алсын, дошманнарны чапсын-киссен, ассын-үтерсен — хәзер инде вакыйгаларның чынын кем белә», — дип «акыллы» киңәш бирүчеләр дә булмады түгел. Болай эшләү әсәр авторының үзенә дә кулай, билгеле — акыллы идеологка карафанда, Ермак, Степан Разин, Емельян Пугачев һ. б. кебек явыз башкисәрләрнең, гаярь бунтарьларның образларын сурәтләү күпкә ансатрак һәм отышлырак. Мәгәр тарихи чынбарлыкка да хыянәт итеп булмый. Батырша ул яуның кулына чукмар-кылыч тоткан гамәли узаманы түгел, бәлки татар-башкорт халыкларын милли һәм дини изүнең соңгы чигенә җиткән тарихи бер мәлдә, көрәш мәйданына кулына кауры каләм һәм Коръән алып чыккан изге җан. Каһарман мөселман халыкларына автономия (гәрчә ул заманда әле бу сүз булмаса да), ул гына да түгел, тулы мөстәкыйльлек алу, мулла Морат кебек үк, Болгар дәүләтен торгызу идеяләре белән янган фикер иясе, идеолог. Маркс һәм Ленин кебек идеологлар турында язылган әсәрләрдән беләбез ки, андый китапларның авторларын (әйтик, Галина Серебрякова) уңышсызлык көтә. Чөнки андый фикер ияләрен хәрәкәттә (талаукөчләү, асу-кисү, яндыру-үтерү) күрсәтүе бик авыр, алар бит күбрәк каләм белән эш итәләр. Батырша хакында да укучыларның күңелен җәлеп итәрлек әсәр тудыруы җиңел булмаячак. Мин боларны белдем, Батырша образын гәүдәләндерүе кыен булачагын да, роман басылып чыккан тәкъдирдә, Баулыдан Зөфәр Абдуллинныкы кебек («Батырша берни дә эшләмәгән икән») беркатлы хатмәкаләләрнең матбугатта басылу ихтималын да чамаладым. Мәгәр тарихи чынбарлыкка хыянәт итә алмадым. Минем Батырша, тарихта тирән эз калдырган Абдулла Галиевнның үзе кебек үк, башкисәр дә, юлбасар да, явыз атаман да, канга сусаган яу башы да түгел, бәлки кулына Коръән, кауры каләм тоткан дин әһеле булырга тиеш. Хак, яу башланып, ул кызып барганда бөтен болачыларны берләштереп, аларны колонизаторлар өстенә әйдәүче гайрәтле бер узаман табылмаганлыктан, Батырша восстание белән җитәкчелекне дә үз кулына алырга мәҗбүр була. Мәгәр бу дөньяда һәркемнең үз эше: итекче пылау пешерә башласа, эшнең ни белән бетәсен күз алдына китерергә мөмкин. Батырша да яуның гамәли җитәкчесе биеклегенә күтәрелә алмый. Бу аның фаҗигасе. Әсәремдә мин шуны күрсәтергә тырыштым да.

Ничек кенә булмасын, мәсьәләнең болай хәл ителүеннән үзем канәгать идем. Ләкин Батырша эпопеясенең моннан да катлаулырак ягы бар иде әле. Мин бу бөек шәхес турында материал җыя башлаганда, Мәскәүдә, яисә Петербургта булмасын, шактый ук укымышлы, акыллы кешеләр, фән кандидатлары, беравыздан диярлек, мондыйрак киңәш бирделәр: «Ташла син аны, төкер, Батыршадан барыбер каһарман ясый алмассың. Ул бит җиһад игълан иткән кеше, урысларга каршы яу чапкан ата милләтче!». Инде татар дусларым һәм танышларым турында әйткән дә юк, милләттәш зыялыларның сүзләре бер: «Булмастайны кузгатма!», «Батырша хакында авызыңны ачма!», «КГБ кармагына кабасың килмәсә, аның турында чокынма!». һәм башкалар. Мин Батырша темасын кузгатканда әле 70 нче еллар, «перестройка» дигән ыгы-зыгыга шактый ерак, коммунистик администрация-команда җитәкчелегенең шау чәчәктә чагы икәнен дә онытмыйк. Ул елларда милли мәсьәләләрдә казынган күпләрнең язмышы барыбызга да мәгълүм. Һәрхәлдә, куркырга җирлек, тупланган материалларга кул селтәргә сылтау җитәрлек иде.

Шул ук вакытта Батырша миңа бик тә якын, аның язмышы, эш-гамәлләре, идеаллары җанга һич кенә дә тынгылык бирми. Чөнки аның ният-омтылышлары минекенә туры килә, уй-исәпләре минем милли мәсьәләдә фикер йөртүләремә тәңгәл диярлек. Менә шуңа да мин Батыршага артым белән борыла алмыйм, киресенчә, олуг остазның рухын-идеалларын яшь буынга җиткерәсем килә.

Ялгыз башым уйлануларда атналар, айлар үтә торды. Ниһаять, мин халык улы Батыршаның эш-гамәлләре, хыял-омтылышлары чынлыкта ничек булса, аларны шул хәлендә яктыртырга кирәк, дигән карарга килдем. Нигә дисәң, минем ышануымча, Батырша — халыкны җиһадка өндәүче дини фанатик та, шовинизм дәрәҗәсенә җиткән милләтче дә түгел, бары тик татар-башкорт халкын чамасыз милли һәм дини изүгә, аларның җирләрен, ул гынамы, җаннарын басып алучыларга каршы көрәшкә өндәүче изге зат. Дөрес, аның халыкка атап язылган «егетләмәк вә кыздырмак» хаты массаны изге сугышка — җиһадка чакыру булып яңгырый. Анда Батыршаның һәр фикере дингә барып тоташа, сүз һәрвакыт дини татулык һәм туганлык турында. Аның һәр җөмләсе диярлек динебезне мәсхәрәләүдән саклауны, урысларның башка халыкларны чукындыру

сәясәтенә нәфрәт тәрбияләүне күздә тота. Менә шуңа да Гайса Хөсәенов һәм башка кайбер галимнәр аның хатын, урысларга каршы изге сугышка чакыру, дип шәрехлиләр дә. Ләкин алар бу очракта В. И. Ленинның, дини кабык астында сәяси протест чыгышы бер Россиягә генә хас түгел, бәлки үзләренең билгеле стадияләрендә барлык халыкларга хас булган күренеш ул, дигән күрсәтмәсен онытып җибәргәннәр бугай. Чыннан да, тарихның буеннан-буена булып торган восстаниеләрдә аларның юлбашчылары халыкны көрәшкә һәрвакыт диярлек дин исеменнән күтәргәннәр ич. Нишләп әле Батырша, акыллы, гыйлемле һәм тәрәккый кеше буларак, мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга тиеш ди. Ул да татар-башкорт халкын яуга дин исеменнән һәм исламны яклау өчен әйди башлый. Алай да аның хатында китергән мисал-аргументларыннан һәм тел төбеннән социаль гаделсезлеккә каршы милли-азатлык хәрәкәтенә чакыруы сизелеп тора. Восстание барышында Батырша явының нәкъ әнә шул ягы калкып чыга да. Бу урында мин 1755 елгы халык күтәрелеше хакында тулаем сөйләргә җыенмыйм, мәгәр укучыларның бер генә фактка игътибар итүләрен сорыйм. Боларның башында ук татар старшиналары, татар түрәләре үтерелә, соңыннан исә Батыршаны тотып патша яраннарына тапшыручылар да — татар аксөякләре. Хак, восстание барышында, гаскәриләрдән тыш, урыс түрәләреннән дә бер кеше — Брагин юк ителә. Ләкин ул һич кенә дә урыс булганы өчен түгел, бәлки иң әшәке, иң кабахәт (кызларны аларның ата-аналары алдында көчли!) кеше буларак Талкыш күлендә тончыктырыла. Шулай булгач, кая соң монда урыска каршы яу чабу, кая соң монда җиһад?!

Боларны ачыклау мине тагы да рухландыра һәм кабат каләмемне кулыма алам. Әмма эш бер Батырша мәсьәләсен хәл итү белән генә бетми бит әле. Роман икән, анда төп каһарманның дуслары, якыннары, сөйгәне, авылдашлары һәм, әлбәттә инде, дошманнары да булырга тиеш. Аларның байтагы тарихи чыганаклардан ук билгеле, ә менә кайберләрен уйлап чыгарырга да туры килә. Каһарманның ирлек чоры, социаль гаделсезлекләр белән көрәш еллары тарихи документларда һәм фәнни хезмәтләрдә шактый яктыртылган. Ә менә аның үсмер һәм егет чагы, Тайсуган һәм Ташкичү мәдрәсәләрендә шәкертлек вакыты, гаилә хәлләре, тормыш-көнкүреше турында мәгълүматлар юк диярлек. Димәк, уйланырга да уйланырга, эзләнергә дә эзләнергә. Бу исә янә йокысыз атналар, айлар...

Романны яза башлауга, тагын бер нәрсә ачыкланды: материал туплау, образларны күзаллау, форма, стиль һәм башкаларын табу белән генә дә эш бетми икән ич. Тәүге битләрне язганда ук, мин, күп кенә тарихи материалдан тыш, әллә никадәр «вак-төяк» тә кирәгенә инандым. Әйтик, язу процессында ат дагалауны телгә алырга туры килде һәм шунда ук башка уй төште: ә татарлар атларын дагалаганнармы ул елларда, гомумән, ат дагалау кайчан һәм кайда башланган? Тарихка хилафлык кылмас өчен, тау-тау белешмә-энциклопедия актарырга туры килде. Чәй, тәрәзә пыяласы, бодай һәм башка бихисап «вак-төяк» хакында җентекле белү кирәклеге дә үзен сиздерде. Кыскасы, әнә шундый без тормыш вaклыклары дип уйлый торган күп кенә мәсьәләләрне өйрәнү тарихи материал туплаудан ким түгел икән. Болар исә вакытны ала, әсәрне язу сузылганнан-сузыла.

Алары бер хәл булса, еш кына «акыллы башлар» әйткән сүзләр (ташла, күзгатма!) искә төшеп җәфалый. Андый чакларда каләмен тортелеп, шик-шөбһәгә бирелүеңне сизми дә каласың. Ә бәләкәй генә эчкәре шәһәрдә сөйләшеркиңәшер кеше юк, булганнары исә синең кәефне кырырга сәләтлеләр генә. Әнә шулай аптыраган-йөдәгән мәлләрнең берендә, бөтен эшемне ташлап, Казанга китеп бардым. Анда килеп төшүгә университетка, могътәбәр тарихчыбыз һәм әдибебез Миркасыйм әфәнде Госманов янына киттем. Ул мине игътибар белән тыңлады, минем шикләнүләремә карата фикерләрен әйтте. Миркасыйм әфәнде үзе Батырша җитәкчелегендәге татар-башкорт күтәрелешен махсус өйрәнмәгән, мәгәр тарихыбызның ул «ак табы»на битараф түгел икән. Галим вакытын кызганмады, без аның белән байтак сөйләшеп утырдык. Университеттан мин яңа дәрт, илһам белән рухланып чыктым. Чөнки Миркасыйм әфәнде миңа бернигә карамый эшне дәвам итәргә киңәш бирде.

Олуг галим белән аннан соң да еш очраштык. Ул романның ничек язылуы белән гел кызыксынып торды, төпле киңәшләр әйтте, мине эшкә дәртләндерде, рухландырды. Алгарак китеп шуны да әйтим: Батырша турындагы романның 35 табаклы кульязмасын әүвәл укып чыгучы, әсәргә беренче бәяләмәне язучы һәм «Батырша» басылып чыккач, аның турында башлап җылы сүз әйтүче дә Миркасыйм Госманов булды. Олы җанлы кешегә рәхмәттән башка тагын ни дисең?!

Ижатка вакыт казна эшеннән соң гына калганлыктан, роман озак язылды. Кәгазь битләре өстендә күз нурын түгеп утыра торгач, айлар, еллар үтте. Шунысы куанычлы, эш төртелеп тормады. Ил өстендә җылы җилләр исә башлавы миңа тагы да кыюлык өстәде, уңышка ышанычымны арттырды. Бүлек артыннан бүлек әдәби кысага керде, алар арасындагы күперләр ныгытылды. Алдан ук ниятләгән образлар акрын-акрын үзләренең «төс-кыяфәтләрен» алдылар, язу процессында әсәргә аларның һич көтелмәгәннәре дә килеп кергәләде. Менә Батырша кулга алынды, Мәскәүгә, аннан Петербургка озатылды. Алда — башта ук ниятләгән бәхәс бүлеге. Менә шунда житкәч, минем эшләр бөтенләй туктады да калды.

Батыршаның Петербургта, дәһшәтле Петр-Павел чиркәү-кальгасында урыс миссионеры белән бәхәскә керүе мәгълүм факт. Бу хакта архив документларында әйтелгән, тарихи чыганакларда телгә алынган. Хәтта бәхәсләшүче попның исеме дә билгеле — Стефан Левицкий. Кулга төшкән кадәр материаллардан әлеге бәхәснең ни турында баруын да чамаларга була. Урыс авторларыннан кайберәүләр бу хакта: «Батырша гомеренең соңгы көннәрендә саф дингә — христиан диненә күчәргә булган, чын христиан булып үләргә ниятләгән», — дип язарга яраталар. Ләкин, минемчә, эш бөтенләй башкада — исән калу өчен тартышуда. Хикмәт шунда ки, ул замандагы законнар буенча, бүтән диндәге халыклардан иң явыз җинаятьче дә үз теләге белән муенына «тавык тәпие» такса, ягъни чукынса, ул бәндә иң хәтәр үтерүче булса да, гафу ителгән, аңа яшәү мөмкинлеге бирелгән. Әнә шуннан файдаланмакчы була да инде Батырша: имеш, насарә диненең исламнан өстенлеген исбатлый алсагыз, мин христиан диненә күчәм.

Стефан Левицкий белән Батырша арасында сөйләшү ни рәвешле баргандыр, анысын берәү дә белми, чөнки бәхәс беркайда да теркәлмәгән. Шунысы хак: Европаның атаклы дини семинариясен тәмамлаган укымышлы поп, никадәр генә сандугач булып сайрамасын, аңа күп нәрсәләр, хәтта тормыш вәгъдә итмәсен, Батырша христиан динен кабул итми, иманлы мөселман булып дөньядан китә. Димәк, урыс миссионеры аңа үз диненең өстенлеген исбатлый алмаган, киресенчә, тоткын болачы попка мөселман диненең хак дин икәнен анлаткан. Ничек кенә булмасын, Батырша иманын сатмый, саф мөселман килеш тормыш белән бәхилләшә. Бу инде аның әхлакый җиңүе!

Шулаен шулай да, бу ике дин вәкиленең бәхәсен әдәби әсәрдә ничек бирергә? Сүз дә юк, аны ни рәвешле генә китереп чыгарсаң да, иң элек һәр ике диннең асылын белергә кирәк. Без, Сталин чоры пионерлары исә, башка диннәрне түгел, үзебезнең ата-бабаларыбыз тоткан пакь исламны да адәм рәтле белмибез. Шул ук вакытта яңа бүлекне язмыйча да булмый. Әгәр дә язылмый кала икән, Батырша образы ачылып җитми дигән сүз. Анысы гынамы, әлеге бәхәс төшеп калганда, роман, гомумән, оттырачак.

Минем көймә комга терәлде. Әмма ул төпкә утырды дип, кул кушырып тору да ярамый. Һәр ике дин хакында, гомумән, диннәр турында китаплар җыя башладым. Аларны кулга каләм тотып, төннәр буе уку гадәткә кереп китте. Шундый көннәрнең берсендә миңа төп эшем буенча озак вакытка Уралга командировкага барырга кирәклеген әйттеләр. Командировка икән, зур корсаклы портфелеңә запас күлмәк-ыштан, сөлге, оекбаш ише әйберләр, юыну-кырыну әсбаплары саласың да, чыгасың да китәсең. Бу юлысында исә мин чемодан алырга булдым. Чөнки диннәр турындагы китапларым портфельгә генә сыешлы түгел. Чиләбедә, Екатеринбургта һәм башка үзем йөргән кала-салаларда алары янына башкалары өстәлә торды — чемоданым инде таш тутырган сандыкны хәтерләтә иде.

Казна эше буенча командировкага барасың икән, көннәрең инде үзеннеке түгел. Аның каравы, беркем белән дә уртак булмаган төнең бар. Ходайның рәхмәтедер инде, Чиләбедә дә, Екатеринбургта да бүлмәдәшләрем һич кенә дә кунакханәдә кунмый торган затлар булып чыктылар. Кышкы озын кич-төннәрдә аулак бүлмәдә япа-ялгызым. Күрше бүлмәләрдә сәрхүшләр акырышуы, исерек маржаларның әшәке итеп чыелдаулары, хәтта вакыты-вакыты белән килеп безнең бүлмә ишеген дә дөмбәсләүләре күңелгә тия тиюен. Әмма төн урталарында алары да тына.

Җылы, иркен бүлмәдә ялгызың уйга батып ятудан да хозурлык юктыр бу дөньяда. Ә башта бары бер нәрсә — диннәр, аларның охшашлыклары һәм аермалары. Мин әле Батырша булам, әле Левицкий, бүлмәдә дапы-дөпе йөренәм, үзалдыма сөйләнәм. Бәхәс куера, бәхәс кыза...

Болай өстән караганда, мөселман һәм христиан диннәре арасында бернинди аерма да юк кебек. Аны әле һәр ике дин хакында күп кенә китаплар укыгач та

сизмисең. Алар, әйтерсең лә, игезәкләр: максатлары уртак — халыкларны буйсынуда тоту, пәйгамбәрләр шул ук, исемнәренең әйтелешләре генә төрлечәрәк. Дөнья яратылу, беренче кеше барлыкка килү, җир өстен туфан басу, оҗмах һәм тәмуг, башкалар — барысы да һәр ике диндә бертөсле. Алланың барлыгы һәм берлеге мәсьәләсендә дә бәхәс юк сыман. Дөрес, христианнарда ул өч шәхес буларак — бер: алла-ата, алла-ул һәм изге рух. Шуңа карамастан, христианлык монотеистик ягъни бер аллага ышана торган дин. Вакыты-вакыты белән, хәтта, бу диннәрнең бер аермасы да юк икән, дигән фикергә килеп бетә язасың.

Урыс әйтә: урманга кергән саен, утын күбәя, ди. Мин дә һәр ике дин турында күбрәк укыган саен, аларның аермаларына төшенә башладым, аңлаган кадәрен кәгазьгә төшердем. Биредә мин ул аермаларны санап чыгарга җыенмыйм, алай да берсенә, минемчә иң мөһименә тукталып үтәм. Әйтик, дөнья булгач, берәү дә гөнаһ кылмый гына яшәми. Аңлы рәвештәме, аңсызмы — анысы башка мәсьәлә. Дини өйрәтүләрдән мәгълүм булганча, гөнаһлы кешегә оҗмах ишекләре ябык. Шулай булгач, гөнаһны йә бөтенләй кылмаска, йә кылган кадәреннән арынырга кирәк. Тормыш шундый катлаулы нәрсә ки, гөнаһ кылмый гына дөньяда яши алмыйсың, ул һәр кешедә бар. Димәк, икенче юл кала — аңардан котылу, тәүбәгә килү. Христианнарда бу бик ансат хәл ителә: исерек попка аз-маз акча төртәсең, ягъни хәер бирәсең дә, санаулы минутлар эчендә ул синең гөнаһларыңны кичерә. Чиркәүдән чыкканда, син инде сөттән ак, судан пакь, нарасыйдай гөнаһсыз кеше! Кылган гөнаһларыңнан бик тиз котылды бит әле бу, димәк, тагы гөнаһка батарга була. Теге исерек поп исә барыбер кабат ярлыкаячак. Кыскасы, христиан динендә кеше гөнаһ кыла да, шунда ук тәүбәгә килә. Янә кыла, тагы тәүбә итә. Ягъни үз гомерендә ул мең тапкыр һәм аннан да күбрәк начарлык эшли ала һәм алардан бик җиңел котыла. Бу бит гөнаһ кылырга нәсара дине үзе куша дигән сүз. Менә шуңа да христиан динендәгеләр эчү-исерү, зина кылу, кыйнашу-җәберләшү, вату-ут төртү, талау-үтерү хәлләрен чүпкә дә санамыйлар — бер сүз белән әйткәндә, бу дин бәндәләрне әхлаксыз, миһербансыз, кешелексез итеп тәрбияли...
Мөселманнарда исә гөнаһ кичерелми, мөслим һәм мөслимәләр үз гөнаһларын ошбу фани дөньядан киткәнче үзләрендә йөртәләр. Әле теге дөньяда да кичереләме ул, юкмы. Әнә шул хәл аларның вөҗданнарын газаплый, кешеләрне тагы да гөнаһ кылудан тыеп тора. Мөселманнарда тәүфыйклылык, инсафлылык, тыйнаклык, оялу хисе, абруй саклау кебек сыйфатлар табигый санала һәм ихтирамлана.

Күрәсез, бу инде зур аерма һәм шуңа охшаш аерымлыклар ике дин арасында байтак икән. Алар табылган саен, минем кунакханәдәге төнге «бәхәсләрем» кыза төште. Нәтиҗәдә, Уралдан кайтканда минем башта бәхәс бүлеге «язылып» беткән иде инде. Өйдә аны кәгазьгә төшерәсе генә калды.

Романны язганда эзләнүләр, гасабиланулар, йокысыз төннәр турында тулы бер китап язарга мөмкин. Ләкин сүзебез болай да озакка китте, вакытында нокта куя белергә дә кирәк.

Татарның моңа кадәр күләгәдә яткан бөек шәхесе турында материаллар җыю, аларны эшкәртү һәм әдәби әсәр язу өчен ун елга якын вакыт китте. Ул елларның хафа-газапларын үземнән башка берәү дә белми һәм аларны белү башкаларга кирәкми дә. Ниһаять, 1992 ел миңа берьюлы ике шатлык алып килде: роман башта «Казан утлары»нда басылды, ел ахырында ул аерым китап булып дөнья күрде. Тагы ике елдан соң, укучыларның сораулары буенча, аның тулыландырылган варианты басылды.

Гыйбрәтле бер деталь: тышлыгына минем фамилия язылган кирпеч калынлыгы китап дөнья күргәч, беркатлырак танышларымнан кайберәүләр очрашканда кинаялерәк сүзләр әйтә башладылар: янәсе, син инде бер олау каләмхак алдың, миллионер булдың — бу дөньяга төкереп тә бирмисең. Андый сүзләрне мин, әлбәттә, уен-көлке белән үткәреп җибәрәм. Алай да ялгызым калгач, тегеләрнең кинаяләп сораулары күңелгә килә бит һәм мин хыялымда әңгәмәдәшләремә җавап бирергә ашыгам: әйе, ун еллык хезмәтем өчен мин, ул вакыттагы исәп белән, күршемдәге нефтьче егетнең ике атналык эш хакы күләмендә гонорар алдым. Үкенечле хәл, гаделсез дөнья, билгеле. Әмма мин андый чакларда да зарланмыйм-сукранмыйм, бары тик Мәскәү архивында микрофильм алдырган өчен кайту юлыма дигән акчамны түләвем һәм, билетка дип, аны бурычка эзләп йөрүем искә төшә. Менә шунда йөрәк сыкрап куя да инде...



**Сәгыйт Хафизов**

# БАШКОРТСТАНДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Татар әдәбиятының бай сәхифәләрен, зиннәтле бизәкләрен төрле өяз һәм өлкәләрдән үсеп чыккан талантлар иҗаты тәшкил итсә дә, фәндә «әдәби төбәк» төшенчәсе актуаль булмады һәм күренеш буларак та җитди өйрәнелмәде. Милли гамьдә булмагач, бинһая кызганыч, ни татар әдәби-мәдәни мәркәзе саналган Казан, ни Рәсәй киңлекләренә таралган татар диаспоралары әдәби төбәкләрнең язмышы турында анык кайгырту галәмәте күрсәтмәделәр. Совет империясенең корткыч сәясәте белән һәлак ителгән Арал диңгезе сыман, аларның да бик күбесе зәгыйфьләнде, хәтта корыды, кипте.

Хәлбуки, географик мөхит, мәгыйшәт, гореф-гадәт үзенчәлекләре һәм аерымлыклары, шулай ук, тел-фикерләү төсмерләре милли әдәбият өчен зур хәзинә. Әдәби төбәкнең шул күперенке чагылышлары, бердән, кызыклы, колоритлы әсәрләр язылуга сәбәпче булып торсалар, икенчедән, алар язучыларда оригиналь идея-эстетик омтылышлар һәм хәтта аерым әдәби юнәлешләр оешуга да этәргеч бирергә мөмкин.

Әйтик, Эстәрлетамак өязеннән килеп Казандагы әдәби хәрәкәткә катнашып киткән яшь Галимҗан Ибраһимов үз заманында татар әдипләренә карата бик кискен дәгъвалары белән танылa.

«Безнең бик күп мөхәррирләребез авыр вә үлтереп язалар,— ди ул 1911 елдагы усал тәнкыйть чыгышларының берсендә.— Күбесе бер бәхетсез каһарманны колагыннан тотып ала да, шуның ялгызын хикәясенең буена өстерәп йөртеп, татар тормышында булуы мөмкин күренгән һәрбер пычракка илтеп чумдыра, батыра... Анларда буяу аз, анларда действие булмый. Анлар чын мәгънәсендә үлек кыйсса ясап чыгаралар».

Кешегә яраган, халыкка ошаган нәрсәләр дә яшь каләм иясенең зәвыген канәгатьләндерми. Хәер, кем кем, тик моңлы сазы белән гавәм күңелен яулаган, аның үз шагыйре булып киткән Габдулла Тукайга моның тел-теше тияргә тиеш түгел иде кебек. Әмма юк, 1913 елда бастырган «Татар шагыйрьләре» китабында ул күп мәгънәләр аңкытып туктаусыз тәкърарлый: «Тукаев шагыйрьме, түгелме?» Шик өчен үзенчә мантыйк юллый юллавын. Янәсе, гавәм ничек кенә зурламасын, танымасын, Тукай да «салкын вәгазьләр, үгет вә фәлсәфәләр... караңгылыклар» тарафдары булып кала. «Аның «мәнә мин» дип аерырлык җан вә йөрәге юк».

Бу катгыйлык, берьяклылыгы белән зәвык тәмам объективлыгын югалтты, замандашлары Ибраһимовны Тукайга каныга, үчегә дип гоман иттеләр. Фән,

билгеле, интрига белән чикләнә алмады. М. Хәсәнов кебек галимнәр «Татар шагыйрьләре»н Г. Ибраһимовның хатасы, аерым алганда, реалистик эстетикадан читләшеп, модернистик «сәнгать — сәнгать өчен» лозунгысына бирелүе, кумиры Белинский йогынтысына төшүнен күнелсез бер нәтиҗәсе дип аңлаттылар. Монда оч — очка ялганган кебек булды. Ләкин эстетика кебек үтә нечкә, нәзакәтле тойгылар дөньясын, каныңда, иманыңда булмаса, читләр йогынтысы гына тәзи, оештыра алырмы икән? Шуның өстенә Г. Ибраһимов иҗатка китапханәдән, кабинеттан түгел, ә кайнар хәятнен үзеннән килде. Димәк, Г. Ибраһимовның асылын тулысынча аңлыйк, төшеник дисәк, аның туган җиренә, Башкортстанга бару зарур. Әдип зәвыгын, хикмәтләрен иң элек ул үскән төбәктән, шуның табигый, социаль рухи шартларыннан һәм, әлбәттә, булачак иҗатының үз шәхесеннән эзләргә кирәк.

«Кызыл чәчәкләр» повестенда Октябрь зилзиләләренә кадәрге авылның биш социаль катламы чагылыш табуын хәтерләсәк, хикәяләүче Солтан аша Г. Ибраһимовның — игенче Гыйрфан карт малаеның — үз хәленә, психологиясенә дә шактый зур ишарә ясавына төшенербез. Солтан — әсәр авторының социаль идеалы. Мохтаҗлык, кысынкылыкка карамастан, яктыга, ямь һәм иминлеккә һич тә өметен кисмәгән романтик рухлы Солтанны язучы бик тә үз итә. Бу үзенчәлекле крестьян тибы дөньяга буш өмет, хыял итүләр, төрле иллюзияләр аша карамый, бәлки тир, хәләл көч, хәтта йөрәк канын түгеп тормышны ипләргә, көйләргә тырыша. Булдыклылык, иҗтиһад бар аңарда. Һәм тырышканда, үҗәт булганда, басу тутырып иген үстергән кебек, дөньяны да гаделлек һәм матурлык канүннарыннан чыгып корырга, үзгәртергә була, дип гөман итә бугай ул. Җирдән, табигать дөньясыннан килә торган оптимизм бу типны көчле дә, тәвәккәл дә, шактый гына шапырынкы да һәм кайчак катлаулы кешеләр дөньясы каршында беркатлы, фаҗигале дә ясый.

Бу тип — язучы һәм иҗтимагый эшлекле, революционер Г. Ибраһимовның үз шәхесендә ята.

Уфадагы татар галиме, профессор Суфиян Поварисовның «Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү» китабыннан алынган юллар да мәгълүм талант иясенең төбәген һәм үзен аңларга ярдәм итәләр:

«Г. Ибраһимов — башкорт җирендә туып, аның бай, матур, күркәм табигатен ниндидер эчке бер дулкынлану, кайнар хис белән бөтен йөрәктән, ихлас күңелдән яратып үскән язучы. Аның әсәрләрен укыганда, үзең дә сизмәстән, киң далаларны гизеп хозурланасың, чәчәкле болыннар аша үтеп, бөдрә таллар арасында кояш нурлары белән уйнап шатланган зәңгәр күлләргә барып чыгасың, калын, серле, моңлы урманнар эчендә йөреп илһамланасың. Бай табигать аңа бай тел, матурлыкның эчке серләрен зирәк сиземләрлек олы тойгы, алар хакында зур фикерләр белән язарлык тирән акыл, илаһи бер маһирлык, көч-куәт биргән».

Шулай итеп, әдәбият мәйданына атылган яшь Галимҗан Ибраһимов хакында әйтергә мөмкин ки, кешеләргә ул ничаклы гына укымышлы, зыялы зат булып күренмәсен, аңарда әле иң элек иркен, мул, кояшлы җир рухы — Башкортстан крестьяныннан чыгу психологиясе ята иде. Туган төбәге мәгыйшәтнең күп төрле чагылышлары белән Галимҗанда матурлыкка хирыслык, зәвык, иҗтиһад стихиясе, рәссамлык тәрбияли. Кояшка тартылган үсемлек сыман, үзенең дә туктаусыз белемгә омтылуы, мәгърифәтле тәрбия күрүе аркасында булачак каләм иясенең тойгылары анык эстетик омтылышлар һәм таләпләр рәвешенә керә. Ибраһимовның үткен, тере күзләре башкалар шәйләмәгәнне күрә, сизгер зәвыгы бүтәннәр тоймаганны тоя, сәнаигълы күңеле күпләр күнеккән җирдә ипсезлек сизә... Ул холкына, табигатенә ятканны дәртләнеп яклый, яратмаганың исә кайнарланып кире кага. Фикерләр көрәшендә, зәвыклар бәрелешендә нәрсәгәдер ирешә, ә кайбер чакта кире кагыла, үзе җайсыз, ипсез бер хәлгә дә төшә ул. Әмма ахыр чиктә, барыбер, әдәбият ота. Талант үз әсәрләрен гаять үзенчәлекле идея-эстетик омтылышлар, төсмерләр белән сугарып, милли иҗатны яңа принциплар, хисси-эмоциональ һәм романтик юнәлеш белән баетты.

* * *

Күрenә ки, катлаулы, серле иҗат дөньясында төбәктән килә торган башлангычлар роле кечкенә түгел. Башкортстанда формалашкан башка бик күп татар язучыларын күзәтә-тикшерә китсәк тә, әдәби төбәк факторының кыйммәте үсә, көчәя баруын күрер идек. Җирне ландшафт, рельеф, экзотика дип кенә кабул иткән кеше, һичшиксез, ялгыша. Җирнең рухы, холкы бар аның.

һәр төбәк, туфрак тик үз табигатенә туры килә торган чәчәкләр балкыткан, агач-үсемлекләр калкыткан, чишмәләр саркыткан шикелле, үзенчә уйлый, фикерли һәм гамьләнә белә. Хәтта үз тойгыларына яраклашкан көе, аһәңе, вәзеннәре дә бар аның. һәм, әлбәттә, җир үзенең кайнар, яралырга тиешле гамь-тойгыларын иң хисле, иң сизгер балалары — шагыйрьләр аша ачып сала. Җир үз серләрен әдипләргә тапшыра.

Разил Вәлиевтагы түбәндәге юллар әлеге карашның татар поэзиясендә дә нык урын алганын раслый:

Мин мин түгел әле — мин уйламыйм,
Минем аша җир бу — җир уйлый.

Юккамы Башкортстанның Дим буеннан чыккан шагыйре Мифтахетдин хикмәтле арба ясап төрле җирләр гизә?! «Мин үзем бер дәрдемәнд диванәмен, кайда бер тәхкыйк (хакыйкать иясе — С. Х.) күрсәм, куанамын» — дип казах даласыннан чын, тугры хикмәтләр, жыр-моңнар җыеп йөри. Бисмилла урынына «сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән...» дип назым башлаган тугры сүзле, белекле дала гидаен халык олылап Акмулла дип йөртә. Акмулла катнашкан төркемнә карап үзен, йә казах, йә башкорт итеп таныта. Әмма Г. Ибраһимов якташын «татар-казакъ шагыйре» итеп санады һәм милли әдәбиятыбызның «яңа уйгану хәбәрчесе» итеп атады.

М. Гафури, Ш. Бабич, Г. Ибраһимов, С. Кудаш кебек язучылар да гидай якташлары сукмагын таптап, үз әсәрләре аша татар әдәбиятында, Тукай әйткән «казах даласы исе»н сиздерделәр.

Башкортстанның яңа бер шагыйре Дәрдемәнд болар сыман гидайлык кылмаган. Шулай да ул үзен Акмулла кебек «кайгылы, моңлы» зат — дәрдемәнд дип атый. Миллионер Рәмиевләр баласы Закирга ни житмәгән? «Рәмиевләрнең алтын казыту эшләре уңышлы чыккан,— дип язган Дәрдемәнднең замандашы Фатих Кәрими.— Аларның егермедән артык приискалары булган. Анда яхшы йортлар салдырганнар, яхшы атлар җиккәннәр, байлыкка, рәхәткә чумганнар». Тик җир бу шагыйрьгә байлык, аристократлык кына бирмәгән, бөтенләй ят, көтелмәгән гамьнәр дә салган шул:

Исә җилләр, күчә комнар... бетә эз...
Дәриигъ, мәхзун күңел, без дә бетәбез!

Хәер, нишләп ят, көтелмәгән булсын? Тамак тук, өс-баш бөтен, ирек бар... Без ул — мәдәниятле мәгыйшәттән мәхрүм адәмнәр — ач, борчалы, хуҗасыз этләр өере сыман, теләсә кай тарафка карап өрәбез, теләсә кемгә өзгәләрдәй булып ташланабыз, йә бер дә юктан шыңшыйбыз. Әмма дөньясы һәрьяктан житеш тормышка ирешсә, кеше үз кулыннан килмәгән бер нәрсә барлыгын аңлар. Бу — вакыт, гомер котылгысызлыгы. Байлык, көч белән дә, зиһен белән дә тота алмыйсың гомер агышын...

Дәрдемәнд әнә шундый фикерләү дәрәҗәсенә ирешкән. Барлык кешеләрнең дә мәгыйшәте аныкыча булса, мөгаен, поэзиядә дә гомер, мәхәббәт, сагыну турында гына татлы-сагышлы тойгылар туар, фәлсәфәләр корылыр.

Дәрдемәнднең нәфис төшенке фәлсәфи-лирик поэзиясен Гали Халит төрек поэзиясе һәм шәрыкның пантеистик идеяләре белән бәйли. Әй, безнең теориячел галимнәр, эрудиция колы булып кая гына сугылмыйлар алар! Әллә галимне шигырьдәге ком тәшвишләндерәме. Дәрдемәнд гомер кичкән төбәктә фәлсәфәгә сәләтле ком юк, дип уйлаумы бу? Соң алтын тапкан кеше комга кагылмыймы? Алтын ком белән аралашаласа... Гадел фикер, һичшиксез, шагыйрь Сибгат Хәкимдә:

«Дәрдемәнд шигырьне җилгә, яңгырга, суларның агышы, тал-тирәкләрнең шавына колак куеп яза шикелле. Табигатьнең үзенә, төрле өн-авазларга, чит-ят моңнарга, дөресрәге, җирнең, җиһанның сулышына, мәңгелекнең агышына колак куеп яза. Дәрдемәнднең үзенең туган җире, туфрагы бар».

Бу җир, туфракта шагыйрь үзенең анык милли рухы, идея-эстетик дөньясы һәм чыгышы белән танылды:

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше үз исменә инкяр итәрме.
Татарлыкта татар угълы татармын
Татар түгел димә — башың ватармын.

Татарлыкны Мәҗит Гафури Дәрдемәнд кебек болай катгый белдерми. Ләкин өч дистә елдан артыкка сузылган иҗат дәверендә бу шагыйрь татар әдәбияты

традицияләренә, рухына гаҗәп тугры булды һәм үзе дә аны якташы Г. Ибраһимов кебек мул төсмерләр белән сугарды. Нәкъ шуңа күрә, 1923 елда, 20 еллык иҗат юбилее белән котлап язган хатларында Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов бу әдипне «Син икенче дәвер татар әдәбиятының бүген исән булган шагыйрьләренен иң карты, иң күп эшләгәне һәм мәсләгең буенча тарихның яңа әмәлләренә килеп ирешкәне»,— дип олылыйлар.

М. Гафури үз вакытында төбәктәге татар мәдәнияте, әдәбияты, гомумән, татар рухының якты балкышы булды. Ләкин җөмһүрияттә милли әверелешләр башлангач, башта «татар-башкорт шагыйре», ә аннары «башкорт язучысы», хәтта «башкорт халык әдибе» ясап, аны рәсми даирәләр Салават Юлаев шикелле үк милли символга әйләндерделәр. Рус, украин, латыш, эстон, литва, мари, мордва һәм башка бик күп халыклар телләренә тәржемәләрдә Г. Тукай каләмдәше башкорт поэзиясенең сокландыргыч вәкиле булып күрсәтелде. Дөрес, «минем балалык елларым тулысынча башкорт җире белән бәйләнгән» дип язган чуваш шагыйре Я. Ухсай мондагы нечкәлекләрне яхшы белә, татар, башкортны бутамый. Нәкъ шуңа «Мине татарга саныйлар» шигырендә М. Гафурины үзенең бер остазы итеп күрсәтә. Әмма, халыкның бик күп вәкилләре «пропаганда машинасы»на алданып, «Кояшлы Башкортстан шагыйре»н башкорт ясадылар. Шулай итеп, татар шагыйре М. Гафури тирәсендә байтак сәяси трюклар һәм гаделсезлекләр ясалды. Ләкин аңларга кирәк, М. Гафури үз иҗатының байтак дәверен Башкортстан дип аталган җөмһүрияттә түгел, ә Рәсәй губернасының бер мәркәзе саналган Уфада яшәп үткәрде. Октябрьгә кадәр бу төбәк өчен татар-башкорт бүленеше сәяси, иҗтимагый әһәмият алмады. Ләкин шулай булса да, М. Гафури һичвакыт милли чыгышына битараф булмаган һәм аны бутамаган да. Моңа аның иҗаты шаһит. Шагыйрь бик еш «халкым», «милләтем» дияргә ярата. Һәм өзлексез әлеге милләт, халыкның да, үзенең дә «татар» икәнен әйтеп, белдертеп килә. 1905 нче елда «Йә татар, вакыт житте кузгалырга» («Тәрәккый») дисә, 1906 нчы санәдә «Иншә алла инде татар карап ятмас, җәһаләт чокырына инде батмас» («Ничә йөз ел») дип әйтә ул. 1910 елдагы «Татар хатыны», 1920 елда иҗат ителгән «Татар егетенә» шигырьләрендәге геройлар да, автор шәхесе дә анык — татар. Гафуриның соңгы чордагы әсәрләренә, аерым алганда, «Эшче» либреттосына, «Кызыл йолдыз» пьесасына карата да шул ук сүзне әйтергә кирәк.

М. Гафури үз әсәрләрен бервакытта да, хәтта башкорт теле гамәлгә кергән егерменче елларның икенче яртысында да, башкорт телендә язмады.

Рухы, идея-эстетик фикерләве, теле, милләте һәм мәсләге белән татар булган әдипнең башкорт әдибенә әверелүе һич тә гаделлеккә туры килми. Бу — үз вакытында Башкортстанда булган ямьсез, бозык милли сәясәт чагылышы.

Хәер, илдәге яңа сәясәт уңае белән дә М. Гафури иҗатына карата сүз-гапь күчәеп китәргә мөмкин.

М. Гафури үз иҗатында заман, вакыт җилләре белән илгә килгән яңалыкларны, зур социаль, рухи үзгәрешләрне гәүдәләндерде. Тормыш күренешләренә карата шагыйрьдә ихлас, садә гаҗәпләнү, хәтта таң калу бар. Әсәрләрендә бик еш актив, эмоциональ тойгыга — әче нәфрәткә яки шатлык-сөенечкә әверелеп китә бу. Шуның өстенә М. Гафурида якташлары Г. Ибраһимов, Ш. Бабичка хас кайнарлык та, ашыгучанлык та бар. Натурализмга тартым репортажлык шагыйрьгә фәлсәфи-этик, әхлаки мәгънәләр турында уйлануларны чикли. Әлеге башлангычлар бергә үрелеп, халык, заман каршында шагыйрь иҗатын актуаль иттеләр. Гафури халыкчанлыгына галимнәр дә зур бәя бирделәр.

Ләкин тормыш күренешләренә карата репортажлык, актив, кайнар мөнәсәбәт — пафос, җилгә каршы пинҗәк ачу кебек, хәтәр шөгыль. Калкуың да, батуың да бар. Монда язучыны Демьян Бедный фаҗигасе сагалый. Авторлык позициясен, субъективлыгын яшерә төшеп, объективлыкка художниклык осталыгын ныграк эшкә җигүгә ни җитә!.. М. Гафуриның совет чоры иҗатына карап, менә шул хакыйкатьне искә төшерәсең. Чөнки шагыйрьнең «Кызыл байрак», «Хөррият иртәсе», «Юктырсың ла алла» шигырьләренә янсә «Кара йөзләр», «Тормыш баскычлары» кебек күләмле әсәрләренә шик белдерүчеләр бар. Халык мәнфәгатеннән бигрәк фирка сәясәтен, яманатлы партиялелек принцибын алга сөрмиме Гафури?..

Халык шагыйренең ачык, калку сыйнфый нигезгә корылган халыкчанлыгы бүгенге укучы каршында бәхәсле сыйфат булып китүе дә мөмкин.

Хәер, матур әдәбиятта бер мәктәп, бер тәҗрибә дә югалмый. Илдә хәзер базар шаукымы көчәйгән чак. Ә үз вакытында М. Гафури «Базарга чыктым» шигырен язып, бер якта хәер сорашучылар, ач-ялангачлар, өметсезләр торуына, икенче якта «сатсаң фәкыйрь ун ел ашарлык» кыйммәтле аргамакларга утырып,

кәеф-сафа чигүче байлар булуына чын йөрәктән әрнеде. Әнә шундый фаҗигале базар контрастлары кочәеп, халык бөлсә, фәкыйрьләнсә, татар әдәбияты Гафури традицияләренә игътибар итмәс, дип кем әйтер?

М. Гафури кебек колачлы талантлар яклауга да, ипләү-сипләүгә дә мохтаҗ түгелләр. Ә инде фальсификация турында сүз дә булмасын. Чөнки Гафурида тарих шәүләләнә. Тарих — зур нәрсә. Аны ошау-ошамауга карап, яисә сәясәт мәнфәгатьләренә туры китереп үзгәртмиләр, бозмыйлар. Кыскасы, туган җир һәм тарих — М. Гафуриның таяныч нокталары. Болар әдипне олы язмышлы итте.

Ә Шәехзадә Бабичта нинди хикмәтләр бар? Ул татар әдәбиятына Башкортстан төбәгенең нинди уй-хисләрен, гамьнәрен китергән? Күлсә дә, авыр шагыйрь Бабич Г. Ибраһимов «аның күлүләре күз яше эченнән көлү булып чыгалар», ди.

Ник болай бу? Ш. Бабичның революцион болганышлар дәверендә, «ураулар вакытында һәлак булган» фаҗигале шагыйрь икәне күпләргә мәгълүм. Әмма шулай булса да, күп әдәбиятчылар шагыйрь дөньясын төзек, актив мәсләкле һәм ахыр чиктә эзләгәнен тапкан кеше рәвешендә күрергә телиләр. Хәтта Г. Ибраһимовка ияреп, Бабичны «татар-башкорт гаммәсенең революцион шагыйре» итеп күзаллау да яши. Юк, Ш. Бабич шәхесе гаҗәп үзенчәлекле, каршылыклы. «Үз маягымны үземчә кадап, үз сабагымны үземчә аңлап юллар ясармын, шулай яшәрмен» дигән шагыйрь гомер буена фикри томан, таркау уйлар, икеләнү, бүлгәләнүләр эчендә кала:

> һич тотар хәл юк күңелнең тезгенен,
> һич белер хәл юк фикернең төзлеген.
> һәр минутта мең түгел, миллион теләк,
> Белә алмыйм кай теләкнең үзлеген.

С. Рәмиевка һәм һ. Такташка караганда да бунтарьрак, Дәрдемәндтән дә фатальрак Бабич. Ибраһимовча әйтсәк, «кичә табынган идеалны бүген утка ягу, кичә аяк астына салып таптаган мәгъбүдне бүген күккә күтәрү фаҗигасе», кыйбласызлык һәм алласызлык трагедиясе ята Бабичта.

Бердән, каны, икенчедән, поэтик рухы белән татар һәм башкортка барып тоташкан Ш. Бабичны әле булса башкорт һәм татар әдәбиятлары вәкилләре үзләренә тарткалыйлар, бүләләр. Юк, тарткалашмыйк, «Бабичта булган татарлык, башкортлык, «уң»лык, «сул»лык дулкыннарын» (Г. Ибраһимов сүзләре — С. Х.) берләштерә торган әмәл бар. Бабич төрле милли, социаль теләкләр, төрле башлангычларны үзендә кушкан чарасыз, зарлы шагыйрь, башкорт татарларының шагыйре булып калсын! Хәер, «Башкортстан татарлары әдәбияты» төшенчәсе гамәлгә кермәсә, без Акмулла, М. Гафури, С. Кудаш, И. Насыйри, Г. Хәйри һәм башка бик күп әдипләр тирәсендә барган мирас бүлү гаугасыннан мәңге котыла алмаячакбыз.

Башкортстан суын эчеп, һавасын сулап балигъ булган татар халык әдибе Әмирхан Еникиның әсәрләре, аеруча «Әйтелмәгән васыять» шедевры үзенең сагыш-моңы белән бу җирләргә килеп тоташа. Хикмәт башкорт Баязит Бикбайның язучыга Акъәби турында язар өчен тема бирүендә генә түгел, билгеле. Язучы дала тормышын, мондагы агышны тирәнтен тоя. Шовинистик рус сәясәтен гамәлгә ашыручы Нуриевлар, Шакировлар төркеменең милләтләрне бууларын, борынгы гореф-гадәтләрнең юкка чыгуын, рухи афәтләр якынлашуын белә ул. һәм шуңа күрә фаҗигале хакыйкать Башкортстан белән ассоциативлаша. Язучы хикәя героен урманда, кырда, болында да түгел, ә тымызык, киң, иркен башкорт даласында, әбиләрнең ак чәчләрен хәтерләтүче, борынгы истәлекләр көйләп сызланучы кылганнар арасында булырга тиешлеген яхшы тойган. Дала киң, анда кеше дә, хакыйкать тә уч төбендәге сыман ачык ята. Нәкъ шул хасиятләр аркасындадыр, монда кеше күзәтүчән, игътибарлы, еractан күрүчән, тирәнтен тоючан... Казан төбәгендәге байтак әдипләр нефть, төзелешләр, фән темалары белән җенләнеп, колхоз рәисләренә дан язып ятканда, Башкортстан төбәгеннән килгән язучылар иллюзияләр белән алданмадылар. Байтагы тарихи, рухи, мораль проблемаларга, милли тел мәсьәләләренә таба кыю юнәлеш тоттылар. Ә. Еники, Х. Сарьян, Н. Фәттах, З. Мансур, З. Насыйбуллин исемнәрен атасам да җитәр шәт. Соңгысы «туган тел» язмышы хакында чаң сугып, барыбызны сискәндерде:

> Сиңа тел тидергәннең дә
> Телен син ачкан идең.
> Ана булып бишегенең

Янына баскан идең,
Сина кырын караганның
Күзен син ачкан идең...

Утлы тойгылар, Акъәби турындагы уйлар шикелле үк, башкорт даласыннан, татар белән башкорт яшәгән җирдән килә иде...

Башкортстанда формалашып, татар әдәбияты белән алыш-биреше булган яки турыдан-туры бу әдәбият вәкиле саналган язучылар иҗатында төбәктән килә торган үзенчәлекләр һәм төсмерләрне барлап булмыймы? Табигать культы, хисси-лирик, романтик стиль, ихласлылык, рухи-әхлаки сизгерлек, халыкчан, садә тел һәм пластик сурәткә тартылу — болар, һичшиксез, безнең төбәк вәкилләрендә ачык сиземләнгән гомум сыйфатлар. Бу төбәк гамьле, уйлы, хисле, тойгылы төбәк булганга «Әдәби җимешне» дә мулдан бирә. «Шәһри Казан» газите, мәсәлән, 1994 елның 19 февралендә болай дип язды: «Бүген Татарстан Язучылар берлегенең яртылабын Башкортстаннан килгән язучылар тәшкил итә».

Шушы олы традицияле, бай төсмерле, җимешле әдәби төбәк үзе ничек яши соң?

* * *

Әрессен әйтергә кирәк, Башкортстандагы татар әдәби төбәге бүген тапталган, корыган бакча яисә туздырылган кош оясы хәлендә. Кем туздырган аны, ничек корытканнар — бу катлаулы, озын һәм гаугалы тарих. Хәер, туздыручылар да, корытучылар да юк. Бары тик халыкларга совет мәдәниятләре төзеп бирүче «эшлекле» фиркәчеләр, шул мәдәниятләрне үзара керештерүче космополит интернационалистлар һәм тагын көн каһарманы булып пьедесталга күтәрелгән мәмлүк язучылар гына бар. Мәкер үзенең чирканчык асылын яшереп, битлек, төче сүзләргә капланып килә бит... «Без, — диде Ленин — башкорт массаларына Рәсәйнең эчендә автономияле республика оештырырга мөмкинлек бирдек. Без һәр халыкның үзаллы, иркеле үсүенә, һәркайсының үз ана телендә әдәбияты үсүенә һәм таралуына бөтен яклап ярдәм итәбез». Ә Башкортстандагы рәсми идеологларның берсе — Даут Юлтый, үз чиратында «Әдәбият һәм әдипләр турында» дигән мәкалә белән чыгыш ясап, «Мәскәү ни әйткәнне» тыңларга чакырды.

Фаҗигаләрнең тамырын, һичшиксез, Мәскәү — Өфе «альянсыннан» эзләргә кирәк. Хәер, монда тагын башка көчләр дә кушылгандыр...

«Революциягә тиклем, — дип яза Уфа әдәбиятчысы Суфиян Сафуанов «Дуслык, туганлык сәхифәләре» (1976) китабында — милли матбугатта «башкорт әдәбияты» дигән төшенчә бөтенләй диярлек кулланылмады». Чынлап та, бу фактны бүгенге башкорт зыялылары ничек кенә танырга теләмәсеннәр, хәтта совет чорында да җөмһүриятгә матбугат, китаплар татар телендә басыла иде. Шуңа күрә егерменче елларда монда «татар-башкорт әдәбияты» гамәлдә була. Һәм ул тугандаш халыкларның әдәби көчләрен бергә берләштерә. Әмма егерменче еллар уртасында бу интернациональ, ясалма атама үз асылын җуя, «башкорт әдәбияты» төшенчәсе ныгый. Шулай да рәсми телдә «Башкортстанның татар язучысы» исеме йөри әле. Мәсәлән, Мәҗит Гафури, Сәйфи Кудаш, Имай Насыйри, Гариф Гомәр, Сәгыйть Рәмиев, Нәкый Исәнбәт, Хәбибулла Ибраһимов кебек язучыларны шулай диләр. Шул елларның рәсми матбугаты да, хәзерге әдәбият тарихчыларының аерым хезмәтләре дә боларны «башкорт җирлегенә таянып башкорт халкы тормышы хакында татарча язып килүчеләр» итеп атый. Монда инде сәясәт аңкый: әйтерсең, җөмһүриятгә татар дигән зур халык, аның мәгыйшәте юк. Бары тик, ходай белсен, әллә каян килеп төшкән татар телле язучылар — «марсиннар» гына бар...

Егерменче еллар азагында әдәби сәясәттә татар әдәбиятын тәмам кысрыклаучы янә бер адым ясала. Башкорт әдәбиятының ике телгә — башкорт һәм татар телләренә хокукы барлыгы турында сүз йөртә башлыйлар. Монда аеруча сәерсендергәне шул: әлеге идеягә чүпрәне татар ягы сала. Казандагы «татар Белинские» Галимҗан Нигъмәти Уфага сәяхәтләрен ешайтып, урындагы әдәби хәрәкәт белән кызыксына, язучылар каршында доклад, чыгышлар да ясый. 1929 елда «Безнең юл» (№ 3—4) журналында аның «Яңа башкорт әдәбияты» исемле мәкаләсе басылып чыга. Монда ул аерым мәсьәләләр белән бергә, башкорт әдәбиятының ике теллелеге идеясен куя һәм Башкортстандагы әдип татарча язса да, аны башкорт язучысы итеп исәпләргә кирәк, ди.

Искәртергә кирәк, тел, әдәбият теорияләре өлкәсендә «бөек ачышларны» безнең татарлар ясады. 1923 елда Уфада әлегә кадәр бердәм булган башкорт, татарның милли бүленүе башлангач, Ж. Вәлиди кебек затлар мәсьәләне тирәнтен уйлап хәл итәргә чакыралар. Әмма Казандагы Гыйльми Үзәк житәкчесе Г. Ибраһимов «тел — тел өчен, әдәбият — әдәбият өчен түгел», «телнең нинди халыкныкы булуы һич әһәмиятле түгел, иң мөһиме пролетар мөндәрижә — эчтәлек, халыкны яктыга чыгару» кебек беркатлы фикерләр белән матбугатка чыга. Ул татар әдипләрен, зыялыларын башкортча матбугат, әдәбият тудыруда ярдәм итәргә өнди. Бу — Ленинның бер мәкаләсендә татарлар башкорт халкына тел, әдәбият үсешенә ярдәм итәргә тиеш, дигән таләбенә иярү, анык эш күрсәтү булгандыр инде.

Ярар, социализм хакына милли мәнфәгатьләрне — телне, әдәбиятны корбан итү ул — коммунист-интернационалистларның саташуы дип карыйк. Ләкин дистә еллар буена ленинчыл сәясәтнең, башкортлашуның нәтижәләрен татып авызы пешергә тиешле татар да шуны ук кабатлый бит: «Төп хикмәт — аларның (әсәрләрнең — С. Х.) нинди телдә иҗат ителүендә түгел, ә гомум культурага нинди идеяләр һәм художество байлыгы өстәүдә». Бу юлларның иҗатчысы Суфиян Сафуановның татар жанлы кеше икәнен беләм. Татар мәдәниятен, мәктәпләрен яклап матбугатта да тавыш бирде. Әмма түбәндәге теоретик декларациясеннән соң галимнең гәзит чыгышлары стенага борчак сибү генә түгелме? Сафуановның Мәскәүдә «Наука» нәшриятында чыккан «Межнациональные связи башкирской литературы» (1979) китабын карадым. Монда башкорт вариантында булган әлеге жөмлә юк. Акыллы кешеләр авторның башкорт рәсми даирәсенә генә хуш килерлек «гыйльми тезисын» төшереп бик дөрес эшләгәннәр. Чөнки тел милли әдәбиятның иң зур, иң мөһим өлеше, чагылышы, хәтта жаны ул.

Уфада башкорт язучыларының XI съезды барган көннәрдә, бер төркем язучылар «татар телле башкорт язучысы» төшенчәсен гамәлгә кертү идеясен күтәреп йөрделәр. Теле, рухы татар булган язучы башкортка нигә кирәк? Тормыш болай да манкортлар, мәмлүкләр, метис адәмнәр белән тулган бит инде. Нигә дөньяны тагын болгатырга?

Татар ягында рухи спекуляция булгач, башкорт тарафы да әрсезләнә, төрле мантыйклар, җай корып, үз мәнфәгатьләрен кайгырта башлый. Үз вакытында башкорт әдәбиятчылары татарның борынгы әдәби мирасын үзләштерделәр. Ә хәзерге чорда мондагы бер төркем телчеләр Башкортстан татарлары телен «башкорт теленең көнбатыш диалекты» дип ышандырырга тырышалар. Бу гыйльми идея гамәлгә керсә, жөмһүрияттәге татар мәктәпләрен янә «башкортлашу» көтә. Дөресме, әллә ясалма гыйльми идеяме бу? Бер-икесеннән гайре ник бүтән татар телчеләре, бигрәк тә Казан галимнәре эндәшми?

Без, татарлар, тегендә-монда ярашып ник бүлгәләнәбез? Ник тирәнгә, еракка карап милли мәнфәгатьләребезне кайгырта белмибез? Гаделсезлеккә һәм баскынчылыкка каршы нигә тау булып күтәрелмибез икән без?..

Хәер, егерменче еллар азагында Г. Нигъмәти кебек фикерләүчеләр артып, татар белән башкорт арасында милли бүлгәләнү экспансив рәвеш алгач, матбугатта бәхәс, хәтта гауга куба. Низагка кичекмәстән Татарстан, Башкортстан өлкә комитетлары килеп кысыла, үзара рәсми кәгазьләр йөри, документлар кабул ителә һәм «интернациональ дуслык мөнәсәбәтенә тап төшерүчеләр» каты гаепләнә. Ә инде 1930 елның жәендә рәсми структуралар оештырган «Җидегән» интригасы хакимнәргә аерым актив язучыларны тәмам бастыру, хәтта төрмәгә үк утырту әмәлен бирә.

Тагын шулай туры килә: Уфадагы «Җидегән» яшерен идән асты оешмасы»н фаш итүдә иң шаулы як Казан тарафы, шул ук Г. Нигъмәти, татар совет язучылар идарәсе рәисе К. Нәжми булды. Матбугат, хәтта 1934 елдагы СССР язучыларының I съезды трибунасыннан торып, болар жидегәнчеләрне иң яман идеологик хыянәтләрдә гаепләде. Мондый фактларны истә тотканда, Мәскәү— Өфө альянсына рәсми Казан да килеп кушылгандыр дигән гөман туа. Хәер, фиркачыларның корткыч сәясәте Башкортстанда татар мәдәнияте учакларына, китапханәләргә, мәктәпләргә, матбугатка аяусыз инквизитор һөжүме жәелдергәч тә, рәсми Казан дәшмәде бит. Ә дәшмәүне рус килешү галәмәте, ди... Кыйсьмән, кояшлы жөмһүрияттәге татар диаспорасының мәдәни-әдәби һәлакәтендә Өфө— Казан фиркачыларын гаепләү әдәби фикерләүгә дә иңгән. Уфа шагыйре Фәрит Габдрәхимнең «Җинаятькә чик куй!» исемле популяр шигырендә әйтелгәнчә: татар белән башкорт арасындагы «очрашулар, кунак йөрешүләр — рөхсәт белән, махсус карар белән» үтә. Ләкин шагыйрь тасвирынча, «сәхнәдәге рәсми үбешүләр фәкать ерагайтты араларны».

Өфө — Казан рәсми «Әпипә»гә,
Рәсми «Карабай»га бии — күрче!
Башкортстан татарынын гүя
Бәгырендә бии ике күрше.

Мәгәр табигый, цивилизацияле формадан ерак торган милли кыланышлар, әверелешләргә намуслы, мәдәниятле башкорт зыялысы да кул чапмады, «афәрин!» кычкырмады. Чөнки «башкортлашу» үз чиратында «татарлашу» белән бәйле. Төтен ул үз морҗасыннан чыкмаса, тишек, ярыклардан пыскырга мәҗбүр бит. Җөмһүрияттәге «татар энергиясе» дә башкорт япмасы астында томаланып кала алмый, үзенә юл ярып, әверелешләр тудыра иде. «Башкортлашу» сан, күләм кебек күз алдагыч рәвеш булса, «татарлашу» асыл, төшне бозучы, рухны эчтән таркатучы хәтәррәк процесс иде. Милли башкорт фикерләве бу афәтне үз психологиясенә ныклап беркетте. Утызынчы еллар башында Уфадагы «Октябрь» журналында «Нимә ул башкорт әдәбияты?», «Кемне башкорт язучысы дип әйтәбез?» кебек мәсьәләләр калка. Фикерләшүчеләр арасында Габдулла Амантай үзенең төпле, практик карашлары белән аерылып тора. Ул «Милли әдәбиятны билгеләү принциплары» *(«Октябрь», 1934 № 4)* арасында әһәмиятлесе итеп «язучының милли хәле һәм аның үзен тануы»н саный. Шулай итеп, Амантай милли билгеләнеш мәсьәләсенең, ягъни татар яки башкорт язучысы булуның тирән рухи, әхлаки-этик эчтәлектәге язучы сайланышы икәнен үз вакытында ук искәртте. Еллар үтеп, Нажар Нәҗминең каләмдәше Мостай Кәримгә төбәп: «без ике телле шигырьчеләр, икебезнең дә ана телебез татар теле, шигырь телебез башкорт теле»... дип әйткән сүзләре дә шул хакта уйлануны көчәйтә. Күрәмсең, язучы шәхесендәге бүленү үзен һәрчак искәртеп тора, җан тынгылыгы бирә алмый...

Ләкин «кешеләр рухының инженерлары» булсалар да, мондый нечкәлекләрне абайламаган иҗатчылар да байтак. Әйтик, егерменче еллар азакларында Башкортстанга олы түрә сыйфатында Афзал Таһиров килә. Моңарчы ул байтак вакыт Үзбәкстанда партия эшен башкарган була. Үзбәк телендә аның исеме белән китаплар да чыккан икән. Таһиров яңа урында да язучы икәнен тиз таныта, тик хәзер инде ул әсәрләрен башкорт телендә яза. Ул югары хезмәт урыныннан файдаланып үз тирәсенә әдәби төркем җыя, А. Фадеев, М. Горький кебек мәшһүр язучылар даирәсенә үтә һәм баш әйләнгеч карьералар ясый башлый. 1932 елның 22 ноябрендә Мәскәүдә СССР Язучыларының оештыру комитеты А. Таһиров иҗатына багышлап кичә уздыра. Монда ул сәләтле башкорт язучысы дигән ат ала. 1934 елдагы I Бөтенсоюз Язучылар съезды исә аны СССР Язучылар союзының идарә составына сайлый һәм мондый танылган «лидерны» башкорт язучылары да үзләренең Союз идарәсе башлыгы итәләр. 1934 елда, 25 еллык иҗат юбилеенда, А. Таһировка нинди генә мәдхияләр яумый: Башкорт әдәбиятының атаклы язучысы... Горький, Тукай, Ибраһимовка тиң әдип...

Ә башкорт язучысы дигәнең, тирәнгәрәк баксаң, Татарстанда Бөгелмә белән Чистай арасындагы чеп-чи татар авылы Габдрахманда туган. Әлмәттә Һади Атласов ачкан җәдит мәктәбендә укыган һәм иске белән яңа тормыш алмашынган болгавыр татар әдәбияты дәверенең урта кул, хәтта «кыйналган» бер вәкиле булып танылган. Башкортстанда башкорт телендә чыгарган «Иген фабрикасы», «Комсомол», «Машиналар каны» повестьлары, «Солдатлар» кебек романнары да, чынлыкта, шул дәрәҗәдән узмавы турында сөйли — коры публицистика, схематизм... Башкорт рухының боларда әсәре дә юк. Киресенчә, космополит, интернационалист каләмендә халык мәнфәгатьләренә ярашмаган, хәтта каршы килгән сыйфатлар байтак. Җөмләдән, А. Таһиров романнарында Зәки Вәлидине, вәлидовчылыкны хурлап, сәяси карикатура дәрәҗәсенә төшереп тасвирлау шул турыда сөйли.

Башкорт милли әдәбияты нәрсә отты бу язучыдан?

Таһиров — Г. Амантай да, Г. Сәләм дә, А. Карнай да, З. Биишева да түгел. Шулай ук, Рәми Гарипов та түгел. Таһиров башкорт әдәбияты өчен күз буяу, коры ялган, юаныч кына. Таһировчылыкны, бер яктан, рухи гарип, мокыт, әрсез зыялылар тудырса, икенче яктан, аны талымсыз һәм принципсыз башкорт әдәби мохите ясады. Татар, башкорт җирлегендә бу күренешне фиркачылар сәясәте барлыкка китерде һәм, кызганычка каршы, һаман яши әле ул. Татар гәзите «Кызыл таң» да эшләп идеология эше буенча өскә үрләтелгән татар коммунист-функционерның башкортча язган әдәби әсәрләренә «Таһиров» псевдонимын куюы очраклы хәл генә түгел икән шул... Таһировчылыкны безнең көннәрдә кәсепчелек дәвам итә. Әйтик, минем эш буенча бер хезмәттәшем татар авылында туып-үскән, татар гыйлеме буенча институт, аспирантура тәгәлләгән. Студент-

ларга ул татар мәдәнияте, татар теленең байлыгы, «рухи энҗе-мәрҗәннәр» турында лекцияләр укый. Әмма өенә кайткач, башкорт тормышы хакында башкорт телендә повестьлар, романнар яза. Басалар, зыянсыз урта кул әсәрләр килеп чыга. Тик татар нәрсә ала да, башкорт ни таба бу язучыдан? Әлбәттә, гомум кешелек проблемалары да бар. Ләкин аларны язучы үз теле, милли фикерләве белән сурәтләсә дөресрәк бит.

Таһировчылык — татар өчен начар, әмма башкорт өчен яманрак күренеш ул. Башкортстандагы бер татар газите, дөнья дилбегәсе әле партия функционерлары кулында чакта, кыюлык итеп болай дип язды: «Татар халкы тудырган, үстергән, тел биргән шагыйребез башкортча шигырь яза. Шундый ук композиторыбыз аңа «башкортча» көй яза. Шундый ук үзебез үстергән җырчыбыз аны башкортча җырлый. Үзебезнең миллионнан артык халкыбыз аны башкортча тыңлый».

Һиндстан шагыйре Рабиндранат Тагор һәр милләт рухи байлыкларны үз исәбенә тудырырга тиеш. Югыйсә, ул милли сәнгать була алмый, аның кадере дә булмый һәм бу милләт башкалар исәбенә яшәүчегә әйләнә, дигән иде.

Башкортстанда үзен төп халык итеп исәпләгән башкорт мондый милләт булырга һич теләми, әлбәттә. Рухи дөнья тирәнлекләрен ачкан әдәбият-сәнгать әсәрләре һәм үз иҗтиһады белән ирешкән идея-эстетик ачышлар гына милли фикерләүне, димәк ки, милләтне яшәүчән итә. Башкорт халкының таһировчылыкка хаҗәте юк. Шөбһә калмый, «бүлгәләп хакимлек итәргә» ашкынган ленинчыл милли сәясәт, фирка идеологиясе бер генә халыкка да, шул исәптән татар һәм башкорт халыкларына да бәхет, иминлек яшәү перспективасы китермәде. Шуна күрә геноцид рухындагы сәясәт ахыр чиктә үзе дә җимерелергә, таркалырга тиеш булды.

Башкортстан татарларының мәдәни-әдәби хәрабәләренә бик якын торган кеше булarak, мин әлеге хакыйкатьләргә тирән төшенәм һәм болай уйлыйм: бу төбәкнең милли рухы терелергә тиеш! Аның бай бизәкләре халыкның үз җырчылары, үз композиторлары, үз галимнәре иҗатында ачылган кебек, үз әдипләре әсәрләрендә тасвирланыр. Башкортстан татарларының киләчәктә дә сәнгати югарылыкка һәм рухи камиллеккә омтылган югары зәвыклы әдәбияты булыр.

Бу өмет, бу юану коры фараз итүләрдән генә тормыйча, заман үзгәрешләренә, яңарыш рухына таяна. Мин төбәгебездә Йосыф Гәрәй, Айдар Хәлим кебек милләтпәрвәр затларның эшләрен дәвам итүче Кәрим Яушев, Фәрит Габдрәхим, Радик Сибагат, Кадерле Имаметдинов, Муса Мөлеков, Әкълимә Әхмәтшиналар ныклыгына ышанам. Үз җиребездә мөстәкыйль татар язучылар Берлеге оештырабыз, көчләрне бергә туплыйбыз дигән идеяләр белән канатланып, шулар өчен көрәшеп йөрүче Рәиф Әмиров, Марис Нәзиров, Фәнил Мансуров, Рим Идиятуллин, Салават Рәхмәтулла, Дилә Булгакова, Альберт Кутуев сыман иҗатчылар төркеме булу әлеге ышанычка ныклы нигез бирә. Болардан шедеврлар күтәп ала алмасак, иншалла, Дүртөйледәге Венера Карамова, Кушнаренко районы Әхмәт авылында Нәҗибә Әминева кебек фидакарь татар теле, әдәбияты укытучылары гаскәре тәрбияләгән яшь буын үсеп килә. Бер миллионнан артык татар халкының иҗтиһадлы рухы нигә талантлы әсәрләрен бирмәс, күрсәтмәс икән? Монда да өмет, ышаныч бар. Ахыр чиктә якташ әдип Г. Ибраһимовка ышанам мин. Хәтерләсәгез, аның «Кызыл чәчәкләр» повестенда шундый пролог бар. Хикәяләүче, дөресрәге язучы кеше, бакчасына гөлләр чәчә, алар матур булып шытып чыга, үсә башлый. Ләкин бакчаны таптыйлар, пычраталар, гөлләр харап була яза. Тирестән, пычрактан вакытында аралаган кеше генә аларга гомер һәм балкыш бирә. Килешегез, бу бакча — Башкортстан татарларының әдәбият бакчасы!

# АЛТЫН УРДА ӘДӘБИЯТЫ

**Мин 1964 елда, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, Сарман районына эшкә җибәрелдем. Өч елдан артык мәктәптә һәм кайбер башка урыннарда эшләгәч, мине үзем укыган университетның татар әдәбияты кафедрасына эшкә чакырдылар. Килдем. 1967 елның ноябрь азакларында кафедрада миңа нинди курслар бирү, нинди фәнни проблема өстендә эшләү хакында сүз булды. Кафедра мөдире профессор Хатыйп ага Госман шунда болай диде: «Менә Алтын Урда чорында Сәйф Сараи дигән шагыйрь яшәгән. Шуны махсус өйрәнергә иде». Риза булдым. Әмма дөресен әйтим, мин, ягъни югары белемле филолог, татар әдәбияты хакында берничә мәкалә язган кеше, Сәйф Сараины бөтенләй диярлек белми идем; Алтын Урда хакында да күзаллаулар шул «СССР тарихы» дәреслегендәге кадәр генә иде. Шушындый ук хәл, могаен, башка сабакташларымда да булгандыр. Хәзер генә ул Алтын Урда хакында иркенләп сөйләргә, язарга мөмкин. Элегрәк тарихи үткән, аеруча Урта гасыр белән шөгыльләнүчеләрне «олы агайлар» «кайгыртып» кына торалар иде...**

**Шулай итеп мин 1967 елның азакларында Алтын Урда тарихын, әдәбиятын өйрәнә башладым. Төрле кыенлыкларга да карамастан, 1972 елда Сәйф Сараи иҗаты хакында кандидатлык диссертациясе якладым. Аннан соң Котб, Сәйф Сараи, Әхмәт Үргәнҗи, Бәркә Фәкыйһ һәм Урта гасырның кайбер башка әдипләре хакында мәкаләләрем һәм китапларым дөнья күрде. Татар әдәбиятының Шәрекъ классикасы белән бәйләнешләрен тикшерүгә багышланган докторлык диссертациямнең дә зур өлешен Алтын Урда язма мәдәнияте тәшкил итә. Соңгы вакытта басылган хезмәтләремдә дә бу чор әдәбияты игътибар үзәгендә тора.**

## I

Болгар, хәзәр, кыпчак, татар һәм кайбер башка этник компонентларны үз эченә алган татар халкы озын тарихи юл үткән, гыйбрәтле язмыш кичергән. VII гасырларда Азак-Дон буйларында, IX йөзләрдә Урта Иделдә төзелгән Болгар мәмләкәте, VII—X гасырларда Идел-Җаек төбәген, Төньяк Кавказ, Кырымны үз эченә алган Хәзәр каганлыгы, монголлар һөҗүменә кадәрге кыпчак сәяси-административ берләшмәләре татар дәүләтчелегенең нигезен, тәүге баскычларын тәшкил итәләр. Ә инде Алтын Урда — халкыбыз тарихының ике гасырлык гадәти тарихы гына түгел, ә татарны татар иткән тиңдәшсез бер чор да ул. Әлбәттә, бу реаль хакыйкатьне бөекмәмләкәтчел сәясәтчеләр, шовинист тарихчылар һәм алар янында тәлинкә тотучылар яхшы белгән һәм шуңа күрә дә төрле юллар һәм чаралар белән Алтын Урданы каралтып күрсәтергә, аны татар халкының тарихыннан аерып куярга омтылган һәм шактый дәрәҗәдә үз максатларына ирешкәннәр дә. Әле хәзер дә, әгәр социологик тикшерү уздырсаң, татарның күпчелеге Алтын Урданы төрлечә хурлаячак һәм аны милли тарихыбызга бөтенләй мөнәсәбәтсез бер мәмләкәт рәвешендә күзаллавын белдерәчәк. Кызганыч, «без татар түгел, болгар!» — дип күкрәк сугучылар да әле арабызда җитәрлек. Урыс милләтен карагыз: ул ничәмә-ничә төрле этник төркем, кавем кушылудан барлыкка килгән. Ә аларның тарихи оешкан, укмашкан милләтләрен төрлечә вакларга, элеккеге исемнәр белән йөртергә тырышканын күргәнегез бармы? Юк! Ә безнең һаман татар түгел, ә болгар, мишәр, нугай, башкорт, керәшен, типтәр һәм тагын әллә кемнәр буласы килә. Шунысы гаҗәп: милләтне

болай эчтән җимерү, тарату эшенә аерым телчеләр дә үзләреннән зур «өлеш» кертә. Алтын Урдада хәзерге кайбер угыр-фин, төрки, кавказ, славян халыкларының да әби-бабалары яшәве мәгълүм. Мәсәлән, Җаек буйларында башкорт кавемнәре күчмә тормыш алып бара. Генетик яктан хәзерге казакъларга барып тоташкан аерым кабиләләр дә Урал — Каспий — Арал буйларында күченеп йөри. Әмма Алтын Урдадагы күпчелек халыкның, бигрәк тә утрак төбәкләрдә, шәһәрләрдә яшәүчеләрнең төп өлешен хәзерге Казан, Уфа, Сембер, Сарытау, Әстерхан, Оренбург, Пенза, Чиләбе, Себер, Кырым... татарларының әби-бабалары тәшкил итүе тарих белән азмы-күпме таныш булган кешегә көн кебек ачык. Русия, элекке СССР дәүләтләрендәге урыс теле кебек, Җучи мәмләкәтендә дә татар (дөресрәге — иске татар, төрки-татар) теле киң таралган, төп аралашу теле була. Гарәп, фарсы, монгол, төрки телләрен яхшы белгән, гомеренең шактый өлешен Сәмәркәндтә, Сарайда, Әстерханда, Кырымда уздырган, төрек солтаны Беренче Мөхәммәт сараенда Алтын Урда белән ике арадагы рәсми язышулар өчен җаваплы булган Ибне Гарәпшаһ (1388—1450) үзенең билгеле хезмәтләрендә һич кенә дә Идел-Урал буе «татарларын» башка төркиләр белән тәңгәл куймый. Дәшти-Кыпчак халкы,— ди ул,— бары тик татарлардан гына тора. Алга таба автор төрки телләр арасында аларның теле иң аһәнле, иң яңгырашлы тел булуын искәртә[1]. Шул вакыттагы урыслар, европалылар да Алтын Урда халкының үзен дә, телен дә «татар» дип йөрткәннәр. XIV йөздә Идел-Урал буйларында яшәгән һәм иҗат иткән Котб, Мәхмүт Болгари, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи әсәрләренең теле Утыз Имәни, Шәмсетдин Зәки, Һибәтулла Салихов шигырьләре теленнән йә кайсы ягы белән аерыла!? Алар арасында уртаклык аермалыкка караганда бермә-бер артык. Әмма шуңа да карамастан, аерым телчеләр чагыштырмача бер бөтен система булган иске татар телен, кайбер хосусый үзенчәлекләргә карап, болгар, кыпчак, угыз, уйгыр, карлук кебек элементларга таркаталар да ташлыйлар. Ә кабат торгызу, җыю юк. Нәтиҗәдә җанлы тел процессы, бөтенлек бозыла, хакыйкатькә хилафлык кылына. Бу уңай белән шунысы да мәгълүм булсын: күп кенә чыганаклар, фактлар, Алтын Урда төзелгәнче үк, кыпчак һәм болгар кавемнәренең үзара бик якын, хәтта тел ягыннан тәңгәл дә килүен искәртәләр. Мәсәлән, Владимир кенәзе Всеволод, болгарларга каршы сугышка җыенганда, 1183 елда Киев кенәзе В. Святославка болай дип яза: «... Половцев кыпчак — Х. М.) же призывать не хочу, ибо они с болгары язык и род един, опасаяся от них измены, ... прошу у тебя, да пришлешь мне в помощь достаточное войско, сколько сам заблагоразсудишь»[2].

* * *

Гаять зур мәйдандагы табигый байлыкларны биләү, мөһим сәүдә юлларын үз кулында тоту, күпчелек халкының этник яктан чагыштырмача бер төрле, үзара якын булуы, күп кенә чит илләр һәм халыклар, аеруча Мисырдагы мәмлүкләр хакимияте белән тыгыз бәйләнешләр Алтын Урданың икътисади һәм мәдәни үсеше өчен уңай шартлар тудыра. Идел-Җаек төбәгенең элеккеге тәрәккыяте дә бу процесста мөһим роль уйный. Илдә шәһәрләрнең күп булуы, кала тормышының алга китүе матди һәм рухи культура үсешенә көчле йогынты ясый. Кыскасы, Алтын Урдада шул дәвер дөнья казанышларын шактый дәрәҗәдә үзенә туплаган фән, мәдәният барлыкка килә һәм бу рухи байлык югары дәрәҗәдә торуы белән сыйфатлана. Сарай — Җучи улусы кебек зур дәүләтнең башкаласы гына түгел, ә Урта гасыр фәненең һәм мәдәниятенең мөһим үзәгенә дә әверелә.

Алтын Урда яшәгән вакытта ук аның хакында гарәп, фарсы, урыс, латин, кытай һ. б. телләрдә күпсанлы хезмәтләр язылу үзе генә дә бу ил белән дөнья җәмәгатьчелегенең нык кызыксынуын, Идел-йортның икътисадта һәм мәдәнияттә югары торуын, Җучи мәмләкәтенең халыкара тормышта мөһим роль уйнавын ачык күрсәтеп торалар.

Шунысын да әйтик: Алтын Урдага һәм гомумән татар тарихына мөнәсәбәтле чит ил язма истәлекләрен безгә тиешле аңлатмалар белән татар телендә чыгара башлау вакыты күптән өлгереп җитте.

---

[1] В. Тизенгаузен. Сборник материалов... Т. I. С.-Петербург, 1884. 458—459 бб.
[2] Татищев В. История Российская. 7 том. М.—Л.: Наука, 1964. Т. 3. 128б.

Жучи улусындагы күпчелек халыкны мөселманнар тәшкил итә, ислам билгеле бер дәрәҗәдә рәсми дин вазыйфасын да үти. Әмма аннан тыш Алтын Урдада будда, мәҗүси, христиан, яһүди динен тотучылар да була. Чыганаклар, мәсәлән, Сарай, Азак шәһәрләрендә, Кырымда, мәчетләр белән берлектә, чиркәүләрнең, синагогларның да эшләвен телгә ала. Аерым хосусый фактларны исәпләмәгәндә, илдә тулы дин ирекe, вөҗдан ирекe хөкем сөрә. Бу яктан Алтын Урда Хәзәр каганлыгы традицияләрен дәвам итә. Мәгълүм ки, тел ирекe, дин ирекe — җәмгыять, мәдәният үсешенә уңай йогынты ясаучы мөһим факторлар.

## II

Моңа кадәргe сүз сөрешенең төп нәтиҗәсе шул: Алтын Урдада, аеруча Идел-Урал, Кырым төбәкләрендә язма мәдәниятнең үсүе өчен тиешле җирлек, чагыштырмача уңай шартлар булган. Һәм чыннан да бу дәвер язма әдәбияты шактый тәрәккыяткә ирешкән дә. Кызганыч ки, төрле сәбәпләр аркасында (Аксак Тимер һәм урыс илбасарларының һөҗүмнәре, янгыннар, ваба авыруы, эчке ыгы-зыгы һ. б.) Алтын Урданың шәһәрләре генә түгел, күпчелек язма истәлекләре дә юкка чыккан. Исәннәренең дә тик бер өлеше генә туган ватаннарында сакланып калган. Бүтәннәре, еш кына газаплы, урау юллар үтеп, чит ил китапханәләренә барып эләккән. Хәзер аларны, галимнәребезнең тырышлыгы нәтиҗәсендә, туган илгә кайтару, өйрәнү, укучыларга җиткерү эше бара. Әмма бу эшне бик нык көчәйтү сорала.

Алтын Урда заманының бүгенгә килеп җиткән, бар булган язма истәлекләре дә бу дәвер әдәбиятын билгеле бер система итеп карарга, аңа хас аерым сыйфатларны билгеләргә мөмкинлек тудыра.

«Котадгу белек» (1069), «Кыйссаи Йосыф» (XIII йөзнең беренче яртысы) әсәрләрендә үк мөселман Көнчыгышына борылган төрки, шул исәптән болгар-татар мәдәнияте Алтын Урда дәверендә төп кыйбла итеп тәмам гарәп-фарсы рухи дөньясын ала. Бу хан ярлыкларында да, сүзлекләрдә дә, әдәбият һәм сәнгать истәлекләрендә дә ярылып ята. Татар теленә гарәп-фарсы сүзләре, гыйбарәләре күпләп керә. Төрки-татар каләм әһелләре тарафыннан гарәп теленең фән теле рәвешендә ныклап кулланылуы да мәгълүм. Хәрәзминең, Сәйф Сараиның аерым әсәрләре фарсы телендә иҗат ителгән. Гарәп классик әдәбиятының иң бөек ядкәре «Коръән», андагы фикер-сурәтләр, сюжет-мотивлар, кагыйдә буларак, һәр әдипне диярлек иҗатта азыкландырган, тукландырган. Гомумән, бу изге китапның татар рухи дөньясындагы роле искиткеч зур һәм бу мәсьәлә киләчәктә үзен төрле яктан җентекле өйрәнүне көтә.

Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» (1310), Мәхмүт Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» (1358) әсәрләрендәге күпчелек сюжет-мотивлар Шәрекъ чыганакларына, шул исәптән «Коръән»гә барып тоташа. Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» поэмалары фарсы классиклары Низами һәм Сәгъди әсәрләренә мөнәсәбәттә туган.

Шунысы кызыклы: Урта гасырларда «тәрҗемә» төшенчәсе дә үзенчәлекле. Дини, юридик, гыйльми текстларны бер телдән икенче телгә күчергәндә, кагыйдә буларак, чагыштырмача төгәллек, оригиналга мөмкин кадәр якынлык, тугрылык күзгә ташлана. Ә инде әдәби текстлар белән эш иткәндә, гадәттән тыш төрлелек хөкем сөрә. Бер үк әсәрдә без еш кына төгәл тәрҗемә үрнәкләрен дә, оригиналь юлларны да, нәзыйрә янсә охшатма алымын куллануны да, йогыннан ычкынган иҗади иркенлекне дә очратабыз. Шуңа күрә бу чорның «Хөсрәү вә Ширин», «Гөлестан бит-төрки» кебек тәрҗемә әсәрләре дә чагыштырмача мөстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия булган ядкярләр рәвешендә карала.

Шәрекъ классикасы белән тыгыз бәйләнеш жанрлар системасында, шигырь төзелешендә һәм поэтиканың башка тармакларында да ачык күренә. Мәсәлән, гарәп-фарсы әдәбиятлары өчен хас булган гаруз, мәснәви формасы, газәл, кыйтга, «тартмалы композиция» кебек жанрлар Алтын Урда әдәбиятында да ныклы җирлек ала.

Әмма Дәшти-Кыпчак әдәбияты, аңа Шәрекъ классикасы никадәр көчле йогынты ясаса да, иң беренче чиратта, ул борынгы төрки, кыпчак, болгар-татар фольклор традицияләре һәм казанышлары нигезендә, илнең эчке рухи ихтыяҗларына җавап рәвешендә формалаша һәм үсә. Ә инде гарәп-фарсы һәм төрки-татар әдәбиятларындагы күп кенә охшашлыклар, аерым уртаклыклар үзара йогынты нәтиҗәсеннән бигрәк, тормыш-көнкүрештәге, психологиядәге, образлы

фикерләүдәге якынлыклар белән дә аңлатыла. Мәсәлән, хикәяләүдә һәм тасвирлауда антитеза, күпертү алымнарын еш куллану, сыйфатны сан аша бирү гомумән Урта гасыр әдәбиятлары өчен хас. Аларның нигезе һәр халыкның үз фольклорында, үз мифологик фикерләвендә.

Алтын Урда әдәбиятының үзәгендә кеше, аның эчке дөньясы, эш гамәле, җәмгыять һәм табигать белән бәйләнешләре. Ул, гадәттә, мөселман, аллага ышанучы зат. Әмма авторлар, иң беренче чиратта, аның нинди диннән булуына түгел, ә әхлакый йөзенә, холык-фигыленә игътибар итәләр. «Котадгу белек», «Һибәтел хакаик» традицияләрен дәвам итеп, Алтын Урда әдипләре белемлелек, әдәплелек, итагатьлелек, шәфкатьлелек, сабырлык кебек сыйфатларны кеше идеалының мөһим өлешләре итеп саныйлар. Болардан аеруча юмартлык, киң күңеллелек күз уңына куела.

Хисам Кятиб «Җөмҗөмә солтан» әсәренең (1369) ахырында, үз укучысына дәшеп, болай ди:

> Мохтасар (кыскасы.— Х.М.) будыр, и адәм угланы:
> Һәр кем ирсә нә иксә - ургай аны.

«Ни иксә — ургай аны» — бу без күнеккән «ни чәчсәң, шуны урырсың» мәкаленең борынгы бер төрдәше. Ул Урта гасыр, шул исәптән Алтын Урда әдәбиятының да девизы, персонажларны бәяләүнең төп әхлакый маддәсе (статьясы). Ягъни кеше үзенең сүз-фикере, эш-гамәле өчен үзе җаваплы. Яхшылыгың да, яманлыгың да иртәме-соңмы кире үзеңә кайтачак. Шуңа күрә авторлар үз укучыларын игелекле булырга, үзгәләргә ярдәм итәргә чакыралар.

Тәрбияви максатны күздә тотып, Рабгузый, Мәхмүт Болгари, Хисам Кятиб кебек әдипләр теге дөнья күренешләрен тасвирлауга да игътибар юнәлтәләр. Җәннәткә, тәмугка эләгү синең бу дөньядагы тормышыңа, яшәү рәвешеңә, эш-гамәлләреңә бәйле. Бу шартка да «нә иксә — ургай аны» мәкале туры килә.

Алтын Урданың каләм әһелләре кешене төрле юллар белән зурларга, сакларга омтылганнар, аны кимсетүгә, түбәнсетүгә кискен каршы чыкканнар. «Гөлестан бит-төрки»дә мондый юллар теркәлгән:

> Тере ирне иңән асан (бик ансат.— Х.М.) орып ук берлә үлтермәк,
> Вәликин бер үлене мең кем ирсә тергезә белмәс.
> Әйа, ук аткучы, яхшы сагышлап (уйлап.— Х.М.) элек, аннан ат:
> «Белерсән, ук качан ядән (җәядән.— Х.М.) чыгар булса, йәнә килмәс.

Шунысы мөһим: кешегә теләктәшлек, ярдәм кылырга чакыру, гомумән, Урта гасыр татар әдәбияты өчен хас. Мөхәммәдьярда хәтта бу мотив Сәйф Сараи кулланган аерым сурәтләр ярдәмендә белдерелә:

> Кем егылганда кулын тот моңлының,
> Ул тәкый (шулай ук.— Х.М.) тоткай кулың бер көн сәнең...

Алтын Урда әдипләренең кешегә мөнәсәбәтләре аеруча хатын-кыз образларын бирүдә ачык күренә. Котб әсәреннән Ширинне алып карыйк. Ул гүзәл, зирек, акыллы, укымышлы һәм кыю зат. Олуг мәхәббәткә, ташларны да балавыз итәрлек сөю хисләренә ия. Ширинненң шәхси сыйфатлары, эчке дөньясы мәхәббәттә генә түгел, ә иҗтимагый-сәяси эш-гамәлләрендә дә ачык гәүдәләнә. Апасы Мөһинбану үлгәч, ул тәхеткә килә, илдә гаделлек, иминлек, тәртип урнаштыра:

> Улус-ил гадле берлә шад булды,
> Камуг (барлык.— Х.М.) зинданлылар ул көн азад булды...
> ... Аның гадлендә бүре берлә куй су
> Эчеп йөрерләр ирде хуш янәшү...

Йосыф Баласагунлы, Кол Гали кебек, Алтын Урда әдипләре дә бәхетле, имин тормышның алшартын, нигезен мәгърифәтле, кешелекле, гадел хөкемдарга бәйләп карыйлар. Ширин — нәкъ әнә шундый «ил-хан» (ил башы). Аның бөтен эш-гамәле, уй-нияте «рәгыййәть», ягъни халык турында кайгыртуга юнәлгән.

Сәйф Сараи поэмасындагы Гөлдерсен образы да типологик яктан Ширингә аваздаш. Ул да гүзәл, зиһенле, кыю. Аның үз сөйгәне Сөһәйлне әсирлектән коткаруы — зур батырлык, фидакарьлек. Автор хатын-кызларны тугрылыклы дус, ярдәмчел иптәш дип атый һәм аларны хөрмәт итәргә, сөяргә чакыра («Аңа дуст бул, аны сәүгел, күңел бир»). Харәзми исә, гомумән, хатын-кызны илаһилаштыра, аның гүзәллеген космик сурәтләр ярдәмендә тасвирлый:

Әгәр көн (кояш.— Х.М.) тугмаса һәм, якты кылгай
Йөзең нуры бу дөньяның сараен...

XIV йөз әдипләренең хатын-кызны бу рәвешле зурлап, ихтирам белән тасвирлаулары шактый дәрәҗәдә алар яшәгән җирлек белән дә бәйле. Чөнки, Әл-Гомәри, Ибне Батута һәм Урта гасырның бик күп кенә башка авторлары язуынча, Алтын Урда хатын-кызлары тормышта зур хокукларга, хөрмәткә, югары дәрәҗәгә ия булганнар.

Гыйльми китапларда, аеруча дәреслекләрдә элеккеге әсәрләр хакында сүз барганда, аларны дини (дини-суфыйчыл), дөньяви төрләргә аеру, аларның беренчесенә тискәре, икенчесенә уңай мөнәсәбәттә тору киң таралган. Мондый бүленештә, әлбәттә, хаклык бар. Әмма өлешчә генә. Чөнки элеккеге заман кешеләренең, шул исәптән, әдипләренең фикерләвендә, күзаллавында дини карашлар мөһим урынны алып тора. Бу — бер. Икенчедән, дин шәхес, аның эчке дөньясы, әхлагы, кешеләрнең иҗтимагый мөнәсәбәтләре белән аерылгысыз бәйләнгән. Мәсәлән, дини-дидактик әсәр дип йөртелгән «Нәһҗел-фәрадис» китабында гомумән тормыш, кешеләр хакында гаять кызыклы гуманистик фикерләр уздырыла. Ата-ананы хөрмәт итү, хәрам мал җыймау, юмартлык, нәфесенә хуҗа булу, хәмер эчүдә бөтен начарлыкның чыганагын күрү, ялганламау, фәкыйрьләргә ярдәм итү һ. б.— әнә шундыйлардан. «Кисекбаш» китабы да кимсетелгәннәрне яклау, хатын-кызны коткару, гаиләне бәхетле итү рухы белән сугарылган. Шуңа күрә элеккеге әсәрләрне дини, дөньяви дип аеруның берьяклы, чагыштырмача шартлы күренеш булуын, аларның берсен хурлап, икенчесен мактап йөртүнең нигезсезлеген һич тә хәтердән чыгарырга ярамый. Хикмәт әсәрнең тематикасында гына түгел, ә идея-эстетик кыйммәтендә, кешегә мөнәсәбәтендә, аңа ни рәвешле һәм ничек тәэсир ясавында.

Урта гасыр әдәбияты, гомумән, билгеле сюжетлар, теге яки бу дәрәҗәдә эшкәртелгән материаллар белән мөгамәлә кылуны өстен күрә. Бу күренеш Алтын Урда чоры әдәбияты өчен дә хас. «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Гөлестан бит-төрки» китапларындагы күп кенә сюжетлар, образлар, мәсәлән, төрле чыганаклар аркылы инде укучыларга таныш. Әмма шуңа да карамастан, бу төр әсәрләр укучыларның игътибарын җәлеп итә. Ни өчен? Чөнки авторлар билгеле материалны үзләренчә эшкәртәләр, өстәмә факт-мәгълүматлар, шигъри детальләр белән баталар. Нәтиҗәдә гомуми танышлык эчендә гаҗәп күп төрле үзгәлекләр, яңа идея-эстетик күренешләр барлыкка килә. Мәсәлән, Хисам Кятиб Шәрекъ дөньясында киң таралган «Кисекбаш» сюжетын файдаланып, фәлсәфи яктан тирән эчтәлекле, әдәби яктан искиткеч камил әсәр тудыруга ирешкән. Аның дастаны өчен вакыт һәм пространствоны колачлап эш итү, тарихи киңлек хас. Котб аерым детальләр, күренешләр ярдәмендә Хөсрәү вә Ширин тарихын Дәшти-Кыпчак җирлегенә якынайта төшкән.

Алтын Урда мәдәниятендә без соңрак, реалистик әдәбиятта өстенлек алачак аерым күренешләр белән дә очрашабыз. Аларның берсе — әдипләрнең тормыш, чынбарлык материалы белән турыдан-туры эш итүе. Котб, мәсәлән, Алтын Урда ханы Тенибәккә багышлап мәдхия яза. Харәзми әсәрендә Мөхәммәт Хуҗа исемле хөкемдар мактала. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасындагы вакыйгалар шул чор тормышындагы тарихи хәл белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Әхмәт Үргәнҗинең бер шигырендә замандашы Аксак Тимернең явызлыклары фаш ителә. Бәркә Фәкыйһ әсәре автобиографик белешмәләргә бай булуы белән сыйфатлана. Әмма әле бу төр «реализм» Алтын Урда әдәбиятында өстенлек итми: романтик, дидактик фикерләүгә буйсындырылып, нигездә, традицион поэтик кысаларда гәүдәләнә. Бу аеруча XIV йөз язма әдәби казанышлары белән тыгыз бәйләнештә туган «Идегәй» дастанында ачык күренә. Аның нигезенә моңа кадәр сүз сәнгатендә юньләп эшкәртелмәгән материаллар салынган. Дастандагы Идегәй, Туктамыш, Аксак Тимер, Кадыйр Бирде һәм башка затлар, алар белән бәйләнешле вакыйгалар — Алтын Урда тарихында булган реаль күренешләр. Әмма «Идегәй»дә алар дастан жанры кануннары нигезендә эшкәртелеп, традицион поэтика ярдәмендә бирелгән. Нәтиҗәдә төп каһарман Идегәйнең шактый идеаллаштырылган образы туа. Туктамыш исә, киресенчә, каралтыбрак сурәтләнә. Тарихи Туктамыш, югыйсә, таралып барган Алтын Урданы янә бер бөтен иткән, илнең куәтен арттыруга үзеннән зур өлеш керткән зат.

Әзәрбайҗан халкының мәшһүр әдибе Мөхәммәд Фөзули (1494 — 1556) фәнсез шигъриятне нигезсез дивар белән тиңли. Аның бу фикере Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятларына хас мөһим бер үзенчәлекле синкретизмны гәүдәләндерә. Фән һәм матур әдәбиятның үзара тыгыз мөнәсәбәтләрдә торуын без Алтын

Урда чоры язма әдәбиятында да ачык күрәбез. Бердән, бу дәвер язма әдәбиятында гыйльми хезмәтләр һәм матур әдәбият арасында кискен чик юк. Алар еш кына үзара керешеп, гомумән, әдәбият, язма мәдәният төшенчәләрен дә тудыралар. Мәсәлән, «Нәһҗел-фәрадис» китабын гыйльми һәм эстетик башлангычларның кушылмасы, синтезы дип атарга мөмкин. Икенчедән, аерым әсәрләрдә, төп идея-эстетик проблемага буйсынулы рәвештә, әдәби чаралар ярдәмендә үз дәверенең гыйльми казанышлары, дөнья турындагы күзаллаулар бәян ителә. Аеруча фәлсәфә, җәмгыять төзелеше, хокук, космогония, медицина кебек фәннәрдәге мәгълүматлар иркен файдаланыла. Мәсәлән, Котб, Сәйф Сараи әсәрләрендә галәм төзелеше, тән һәм җан берлеге, мәмләкәт идарәсе хакында кызыклы фикерләр бар. Хисам Кятиб үз поэмасының нигезенә кешенең туфрактан туфрак булу фикерен салган. Сәйф Сараи идарәчелектә варислыкны түгел, ә «ирдәмлек»не (кешелелекне, сәләтлелекне) яклый.

Эстетик һәм гыйльми башлангычларның үзара керешкәнлеге Урта гасыр, шул исәптән Дәшти-Кыпчак әдәбиятының сүз сәнгате белгечләре өчен генә түгел, ә башка фән ияләре өчен дә мөһим чыганак булуын күрсәтеп тора.

Алтын Урда язма әдәбиятының поэтикасы өчен жанрлар төрлелеге, шигъри формаларның һәм чараларның гаҗәеп байлыгы хас. Авторлар сүзләрдәге күпмәгънәлелек күренешен, сөйләмдәге фонетик һәм синтаксик мөмкинлекләрне әдәби максатларга оста җигәләр. Борынгы төрки әдәбияттагы һәм фольклордагы хикмәтле сүз әйтү традициясе уңышлы дәвам иттерелә. Шигъри һәм чәчмә юллар берлегеннән торган әсәрләр язу да киң тарала. Сөйләмдә сорау — җавап, эндәш, кабатлау алымнарын еш куллану язма истәлекләрнең тәэсир көчен арттыруга булыша. Алтын Урда әдипләре аеруча шигърият өлкәсендә көчле. Аларның фикер-кичерешләргә бай шигъри юллары — поэтик камиллекләре, гармоник яңгырашлары белән классик әдәбиятыбызның матур үрнәкләре.

* * *

Алтын Урда әдәбиятына кыскача гына күзәтү ясау да шуны күрсәтә: бу чор язма мәдәнияте үзенең үсеше, идея-эстетик байлыгы, поэтик дәрәҗәсе белән дәверенең алдынгы әдәбиятлары югарылыгында торган. Ә инде XIV йөздә ул төрки дөньяның әйдәп баручы үзәгенә әверелә. Госманлы әдибе Әхмәдигә, үзбәк шагыйре Лотфыйга, әзәрбайҗан классигы Нәсимигә Алтын Урда әдәбиятының шифалы тәэсире үзе үк күп нәрсә хакында сөйли.

Урта гасыр Шәрекъ дөньясында кызыклы бер процесс күзәтелә: XIII гасыр урталарында ерак Мисырда мәмлүкләр хакимияте урнаштырыла. Андагы төп көчне Идел — Урал төбәгеннән киткән кыпчаклар, ягъни төрки-татарлар тәшкил итә. Мәмлүк солтаны Бәйбарсның Урта Иделдән, төгәлрәк әйткәндә, хәзерге Пенза төбәгеннән чыгуы хакында да фикерләр бар. Мәмлүкләр мәмләкәтендә, Алтын Урда белән тыгыз бәйләнештә, төрки-татар теле киң тарала, әдәбият, сәнгать көчле үсә. Сәйф Сараи, Мәхмүт Сараи Гөлестаный, Бәркә Фәкыйһ һәм Идел-йортның башка күп кенә әдип-галимнәре үз гомерләренең ахырын Мисырда уздыра. Алтын Урда таркалганнан соң да, аның шактый гына традицияләре мәмлүкләр илендә дәвам иттерелә. Биредә XV йөздә — XVI гасыр башында да күпләгән төрки галимнәренең, шагыйрьләренең яшәве, иҗат итүе мәгълүм. Мәмлүк солтаннарының үзләре арасында да әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр була. Мәсәлән, Әл-Әшраф Сәйфеддин Кайтбай (1468 — 1469 елларда идарә итә), Әл-Әшрәф Кансу әл-Гаури (1501 — 1517) h. б. Шунысы мөһим: Татар Гали әфәнденең (ягъни Шәриф Гамидинең) атаклы «Төрки шаһнамәсе» (ул 1501 — 1510 елларда иҗат ителә) нәкъ менә солтан әл-Гаури заказы буенча языла да.

Ике китаптан (1507, 1510 елларда төгәлләнәләр), берничә дистә мең бәеттән (бераз чәчмә юллар да бар), кульязмада 1170 биттән гыйбарәт атаклы «Төрки шаһнамә» фарсы классикасы белән эш итүнең Котб, Сәйф Сараи кулланган тәрҗемә принциплары, нәзыйрә казанышлары уңышлы дәвам иттерелә. Әсәрдә без, нәкъ «Хөсрәү вә Ширин», «Гөлестан бит-төрки»дәге кебек, төгәл тәрҗемә ителгән юллар белән беррәттән, оригиналь, ирекле тәрҗемә үрнәкләрен дә очратабыз. Татар Гали Әфәнде үз язмасына яңа факт-мәгълүматлар да керткән. Алар арасында ерак тарихка, мәмлүк мәмләкәтенә карый торганнар да шактый. Бу аңлашыла да. Чөнки «Төрки шаһнамә» — Мисыр төркиләренең конкрет иҗтимагый, эстетик ихтыяҗларына җавап рәвешендә туган күренеш.

«Төрки шаһнамә»дә Алтын Урда әдәбиятына аваздаш, охшаш яклар шактый.

«Төрки шаһнамә» — борынгы рун истәлекләреннән, «Котадгу белек»тән Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи иҗаты аша тупланып килгән мәдәни казанышларын үзләштереп, баетып, алдагы буын әдипләргә житкерүдә мөһим бер баскыч ул. Бер генә мисал китерик. XI—XIV йөз әдәби ядкәрләрендә тәнне читлек («кафәс»), җанны кош белән чагыштыру еш очрый. Бу сурәтләр «Төрки шаһнамә»дә («Бу җан кошларына тәнләр кафәсдер»), Мөхәммәдьярда («Җан кошыга мескен адәмдер кафәс») һәм алардан соңгы шагыйрьләрдә традицион образ буларак иркен кулланыла.

Алтын Урданың таркалуы, бераздан аңа нигезләнеп туган татар ханлыкларының да бетерелүе Идел-йортның мәдәниятенә коточкыч зур зыян китерде: элеккеге казанышларның күпчелеге юкка чыкты, яңаларын тудыру өчен шартлар житмәде. Әмма шуңа да карамастан, борынгы төрки, болгар чыганаклары белән азыкланган, гарәп-фарсы әдәбиятыннан көч-куәт алган Алтын Урда мәдәни традицияләре тәмам өзелмәде: кара, авыр еллар аша сакланып, баетылып, үстерелеп, Утыз Имәни, Кандалый, Акмулла, Исхакый һәм Тукайларның тууына җирлек булды.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
**филология фәннәре докторы.**

---

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

# Кәрим Җаманаклының тууына 90 ел

Кәрим Җаманаклы — кырым татары вәкиле. Шагыйрь, әдәбият белгече һәм фольклор галиме.

Әмма ул безнең әдәби мохитебез өчен дә якын, үз кеше иде. Чөнки аның иҗат эшчәнлегенең егерме елы Татарстан туфрагында тамырланды.

1945 елда Кәрим Җаманаклы безнең якларга күчеп килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр Алабуга дәүләт педагогия институтының рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасы мөдире булып эшли. Нәкъ шул елларда ул «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының даими авторына әверелә. Герой шагыйрь Муса Җәлил иҗатын өйрәнеп, аның турында монография бастыра. Г. Тукай, Г. Ибраһимов иҗатларына багышланган күләмле фәнни хезмәтләре мәйданга килә.

Кәрим Җаманаклы (Кәрим Рәшид улы Рәшидов) 1905 елның 21 гыйнварында Таврия губернасының Кизләү өязендә (хәзерге Кырым өлкәсенең Евпатория районы) Җаманак авылында атаклы йөземчеләр гаиләсендә дөньяга килә. Революциягә кадәр дүрт сыйныфлы авыл мәдрәсәсендә белем ала. Симферополь педагогия техникумын, институтын тәмамлый. Тарих-филология факультетын уңышлы тәгәлләп, аспирантурага калдыралар. 1937 елда Кырым татар әдәбияты классигы Хөсәен Шамил Туктаргазыйга багышланган хезмәте нигезендә Казан дәүләт университетында диссертация яклый. Филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

Бу елларда ул бер-бер артлы «Әдәбият һәм әдәбиятны өйрәнү терминнары», «Әйтешләр һәм бию җырлары», «Шагыйрь Гомәр Ипчи», «Хикәятләр» кебек китапларын бастыра. Сугыш алдыннан аның Кырым татар әдәбиятына багышланган дистәләгән фәнни хезмәтләре дөнья күрә. Берничә шигырь китабы басылып чыга.

Татарстан фәннәр академиясендәге өлкәннәр аны бүген дә хөрмәт белән искә алалар. Алабуга аны бүген дә юксына. Андагы педагогия институтын тәмамлаган йөзләгән шәкертләре үзләренең эшләрендә аны үрнәк дип саныйлар. ■



**Гомәр Саттар-Мулилле**

# ОНОМАСТИКА ҺӘМ ЭНЦИКЛОПЕДИЯ

Хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясе һәм Республикабызның башка гыйльми оешмалары галимнәре, тулаем җәмәгатьчелек алдында торган гаять мөһим һәм зур колачлы бурычларның берсе — «Татар энциклопедиясе»н төзү. Бу өлкәдә без элекке СССРда союздаш республика статусына ия булган һәм кимендә ярты гасыр әүвәл үз академияләрен барлыкка китергән халыклардан чирек гасырга артта калдык.

Моның төп сәбәбе — Татарстанның 1990 нчы елның 30 августына кадәр автономияле республика кысасында гына яшәвендә, юридик һәм икътисади хокук һәм мөмкинлекләренең ифрат тар һәм чикләнгән булуында, әлбәттә.

Автономиянең кысалары, фәннең гомум үсеш дәрәҗәсе һәм югары квалификацияле галимнәр белән тәэмин ителеше ягыннан байтак кына союздаш республикалардан югарырак баскычта торсак та, Татарстан Фәннәр академиясен төзергә мөмкинлек бирмәде. Җөмһүриятебезнең 1990 елның 30 августы Декларациясе нәтиҗәсендә генә Татарстан Фәннәр академиясе төзелүе мөмкин булды. Бу — республикабызның зур бер казанышы. Татарстан ФА президенты М. Х. Хәсәнов хаклы рәвештә әйткәнчә: «Академия югары фән оешмасы буларак, суверен дәүләткә хас, мөстәкыйль дәүләтнең бер атрибуты шикелле югары фәнни оешма, мөстәкыйль фәнни оешма. Шуңа күрә аның хокуклары, мөмкинлекләре бөтенләй икенче» («ВТ»), 7.IV.1993).

Татарстан Фәннәр академиясе президиумы каршындагы Татар энциклопедиясе бүлегенә (табигый ки, унбер кеше эшләгән бу бүлек энциклопедия кебек гыйлем мөхитен колачлый алмый иде) күптән түгел Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән фәнни институт статусы бирелүе әлеге хокук һәм мөмкинлекләрнең гамәли бер гәүдәләнеше. Бу институт (директоры — академик М. Х. Хәсәнов) хәзер аякка басып килә, тик әлегә анда әзерлекле белгечләр, галимнәр җитми.

Татар энциклопедиясенең бик күп проблемаларын фәнни нигездә хәл итәргә кирәк. Шундый җитди мәсьәләләрнең берсе һәм гаять әһәмиятлесе — Татарстандагы барлык төр торак пунктлар (шәһәрләр, поселоклар, авыллар, тимер юл станцияләре һ. б.) турында анкета-белешмәләр тутыру һәм республикабыздан читтәге татар торак пунктлары турында кирәкле мәгълүматлар тупланган картотеканы (топонимик, тарихи, географик, демографик-статистик, этник, икътисади, социаль-мәдәни, биографик банкын) булдыру зарур. Татар энциклопедиясе өчен Татарстан торак пунктлары турындагы мәгълүматлар түбәндәге маддәләрдән гыйбарәт аерым анкета-сораулыкларга тутырыла: 1) торак пунктның рәсми һәм

---

САТТАРОВ Гомәр Фәез улы (1932) — *галим, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, күп санлы китаплар һәм фәнни хезмәтләр авторы. Казанда яши.*

рәсми булмаган исеме; 2) кайсы районга, авыл советына каравы; 3) атамасының мәгънәсе, салыну-нигезләнү вакыты һәм, гомумән, тарихыннан кыскача мәгълүматлар; 4) географик ориентирлары (кайсы елга буена һ. б. урнашкан); 5) 1992 елга халык саны, этник составы, шулардан күпмесе татар; 6) хәзерге вакытта хуҗалык итүенең төп төрләре; 7) торак пунктның социаль-мәдәни характеристикасы (мәктәбе), мәдәният йорты, китапханәсе, мәдәни-тарихи биналары һ. б.; 8) бу торак пункттан чыккан атаклы кешеләр.

Республикабыз торак пунктлары буенча бу эш тәмамланып килә инде. Әмма аныклыйсы, ачыклыйсы нәрсәләр дә байтак әле. Татарстаннан читтәге татар торак пунктлары (башлыча авыллары) турында анкета-мәгълүматлар тутыру, ягъни аларның энциклопедик картотекасын булдыру эше башланмаган диярлек.

Милли энциклопедиябезне торак пунктлар турында тиешле мәгълүматлар белән хәзерге заман таләпләре югарылыгында тәэмин итүдә татар ономастикасы фәненең тулысынча формалашып үсеше гаять зур әһәмияткә ия. Ономастика энциклопедияләр өчен гомумән кирәкле бер фән тармагы. Мисалга, Россия Фәннәр академиясе 2000 нче елга 50 томлык итеп чыгарырга планлаштырган «Урыс энциклопедиясе»нең төрле тармак белгечләрен үз эченә алган, 52 секциядән гыйбарәт редакциясе оештырылды. Шулардан 14 е — тел белеме секцияләре, шуның берсе — урыс ономастикасы секциясе.

Ялгызлык исемнәренең тарихи-мәдәни, этнографик һәм ономастик мәгълүматлар бирүдә тоткан мөһим роле яхшы билгеле. Хәлбуки, алар элекке энциклопедияләрне һәм энциклопедик сүзлекләрне төзүчеләр тарафыннан, ономастиканың тиешенчә эшләнмәве һәм галим-ономатологларның житәрлек үсмәве аркасында, ифрат аз файдаланылды.

Якын киләчәктә шулай ук күп томлы итеп чыгару планлаштырылган «Энциклопедия российских деревень» басмаларында да ономастик мәгълүматларга киң урын бирү күздә тотыла. Русиянең гамәлдәге җанлы ономастик дөньясын бөтен тулылыгы белән туплап чыгару, моңа кадәр сүзлекләргә бөтенләй диярлек кертелмәгән гаять зур һәм бай лексик катламны фән казанышына әверелдерү максат ителә. Моңа ирешү исә ономастиканың алга табан үсеше өчен мөһим нигез-этәргеч булу белән беррәттән, фәндә яңа, әлегә кадәр теркәлмәгән һәм тикшерелмәгән тел фактлары ачылганга, бөтен лингвистиканың үсешенә дә зур йогынты ясаячак.

Барлык төр ялгызлык исемнәренең килеп чыгышын, үсешен, ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән тел белеменең ономастика (грекча «исем кушу сәнгате») дигән махсус тармагы шөгыльләнә. Топонимика белән антропонимика ономастиканың ике иң мөһим һәм зур бүлекләрен тәшкил итәләр. Топонимика барлык төр географик атамаларны (топонимнарны) өйрәнә. Топонимиканың су чыганаклары исемнәрен — гидронимнарны тикшерә торган бүлеге гидронимика дип, ландшафт атамаларын өйрәнә торган бүлеге — оронимика, торак пункт исемнәрен тикшерә торган бүлеге — ойконимика, жирле, зур булмаган географик объект атамаларын өйрәнә торган бүлеге микротопонимика дип атала.

Һәрбер телдә кешегә эндәшү, мөрәҗәгать итү өчен хезмәт итә торган билгеле бер антропонимик категорияләр бар. Антропоним — (грекча антропос — «кеше» һәм онома — «исем») кешеләрне атауда кулланыла торган исем, кушамат, псевдоним төшенчәләрен аңлата һәм билгеле бер телдә адәм балаларын конкрет атау өчен хезмәт итә (мәсәлән, Закир — исем, Куштан — кушамат, Шакирович — ата исеме, Бакиров — фамилия токымат), Тиктормас — псевдоним... Кешегә эндәшү атамаларының килеп чыгышын, төзелеш-ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын ономастиканың антропонимика дигән бүлеге өйрәнә. Антропонимия — теге яки бу телдәге кеше исемнәре, кушаматлар, ата исеме һәм фамилияләрнең тулаем җыелмасының аталышы. Моны икенче төрле антропонимикон яки ономастикон дип тә атыйлар.

Ономастика фәненең шактый нык үсеше нәтиҗәсендә, хәзерге вакытта ялгызлык исемнәрен тикшерүнең теоретик ономастика, тарихи ономастика, гамәли ономастика һәм шагыйранә ономастика кебек фәнни юнәлешләре барлыкка килде.

Ялгызлык исемнәренең этимологиясен, этнолингвистик катламнарын, структур-семантик һәм ясалыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәрешләрен, таралыш-кулланылыш хасиятләрен өйрәнүнең тел һәм халык тарихы, этнография, этногенез өчен гаять зур әһәмияте бар. Чөнки кеше исемнәре, кушаматлар, фамилияләр (токымат), жирле географик атамалар үзләрендә телебезнең борынгы сүзләрен, грамматик күренешләрен консервацияләп мул саклаганнар. Боларда халыкның

борынгы теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, матди һәм рухи культурасы эзлекле чагыла.

Хәзерге вакытта ономастика фәне кызу темплар белән үсә. 1990 елда Финляндиянең башкаласы Хельсинкида XVII халыкара ономастика конгрессы үткәрелү, ЮНЕСКО каршында ономастика фәннәренең халыкара комитеты оештырылу, безнең илдә ономастика мәсьәләләренә багышланган төбәк, зона һәм ил-күләм конференцияләрнең шактый еш үткәрелүе, тюркологлар комитетында «Төрки ономастика» секциясе оештырылу шуны раслый.

Шунысы да игътибарга лаек, ономастика күзлегеннән караганда, Татарстан — гаҗәп кызыклы һәм үзенчәлекле төбәк. Ул кимендә биш этник дөньяның: төркиләрнең, борынгы иран кабиләләренең, фин-угыр, монгол һәм славян халыкларының «аралашу мәйданы». Менә шул кабилә һәм халыкларның тел стихиясе чал тарих дәвамында Татарстан топонимиясе, антропонимиясе, антропотопонимиясе, этнопонимиясе һәм ойконимиясенең этнолингвистик катламнарын тудырган, аларның үзара ныклы керешүләрен, бер-берсенә сизелерлек йогынтысын китереп чыгарган.

Татарстан топонимиясе һәм татар антропонимиясенең тарихи катламнарын ачу, аларны җентекле итеп өйрәнү исә татар тел белеме бурычларының гаять мөһиме дип карала. Мисал өчен, махсус тикшерүне көтеп ята торган кичектергесез мәсьәләләрдән татар, башкорт, чуваш һәм башка төрки халыкларның кеше исемнәрен, кушаматларын, фамилияләрен өйрәнүне, Идел буе топонимиясенең төрле төрки телләргә караган барлык катламнарын аеруны, фин-угыр топонимиясен тикшерүне һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Борынгы татар теленә хас булган фонетик, лексик һәм грамматик күренешләрне чагылдырган язма истәлекләр безнең көннәргәчә аз сакланган. Татар теленең тарихи лексикологиясе әлегә аеруча аз эшкәртелгән. Шуңа күрә татар теле тарихын, бигрәк тә тарихи лексикологиябезне өйрәнү, борынгы тел күренешләрен ачу өчен ономастика фәненең роле ифрат зур.

Татар исемнәрен, топонимиясен, Татарстан ойконимиясен өйрәнүнең тел тарихын, башка ономастик берәмлекләрнең килеп чыгышын, Урта Идел-Урал, Көнбатыш Себер җирлегендә яшәүче фин-угыр халыклары аерата, татар һәм башка төрки халыкларның этногенезын ачыклау, татар, фин-угыр, урыс телләренең антропонимия, ойконимия тармакларында бәйләнешләрен, үзара йогынтысын аныклау өчен гаять зур әһәмияте бар.

Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Котлыбөкәш авылы атамасының килеп чыгышы хакында җирле халык телендә ике төрле риваять йөри. Аларның беренчесендә: «Безнең авыл исеме Бөки яки Бөкихан дигән кеше исеменнән алынган»,— дип сөйләнә. Икенчесендә исә: «Шомбыт елгасы борылыш ясаган урынны элекке халык «елга бөгеше» дип атап йөрткән. Шул урынга утырганга, безнең авыл Бөгеш исемен алган»,— диелә.

Бу риваятьләрнең беренчесе игътибарга лаек булса да, атаманың Котлыбөкәш дигән тулы формасының килеп чыгышы һәм мәгънәсе бәян ителми. Риваятьләрнең икенчесе дә Котлыбөкәш атамасының асылын ачмый.

Котлыбөкәш авылы атамасының нигезендә Котлыбөкәш дигән борынгы төрки-болгар кеше исеме ята. Бу исем ике сүз кушылып ясалган: котлы + бөкәш.

Борынгы төрки телдә кутлуг сүзе «бәхетле», «уңыш» мәгънәсендә кулланылган. Аңа нигезләнеп Кутлуг, Кутлуг бәк, Кутлуг бука, Кутлуг бөрт һ. б. исемнәр ясалган. Котлыкыя — «Идегәй» дастанының бер каһарманы исеме.

Кутлуг сүзенең «г» авазы төшеп калган кутлу, татар телендә котлы («бәхетле») варианты байтак кына борынгы татар (Котлыбай, Котлызаман, Котлыкай, Котлыбикә, Котлысылу...) һәм башкорт кеше исемнәрен ясауда актив катнашкан.

Борынгы төрки телдә бөгә сүзе «герой, көчле кеше, баһадир» мәгънәсен белдергән. Бөгә будрач, Бөгә йаугушы һ. б. кебек кеше исемнәре булган. Бөек төрки каганат ханнарыннан берсе Бөке-хан («герой, көчле, кодрәтле хан») исемен йөрткән.

Бөгә сүзенең бөкәш варианты болгарларның Котлыбөкәш исемендә урын алган һәм «бәхетле баһадир, герой» дигән мәгънәгә ия булган. Бөкәй-бүкәй («баһадир, герой») сүзе болгар бабаларыбызда мифик образ, герой төшенчәсендә кулланылышта йөргән. Казан татарларында елый торган баланы елаудан туктату өчен: «Елама, Бүкәй килә, Бүкәй алып китәр» (Тау ягы сөйләшләрендә «Муки килә»), дип куркыту гадәте бар. Бүкәй безгә болгар бабаларыбыздан күчкән мифик образ, кодрәтле көч, мәҗүси каһарман булып чыга.

Бүкәй сүзе борынгы заманнарда татарлар арасында кеше исеме булып та йөргән. Пермь татарларында Букаев фамилиясе бар. Мәҗүси чуваш исемнәре тезмәсендә Мукай, Мукей исемнәре очрый. Бүкәй, Букай, Мукай, Мукей исемнәренен семантикасы шулай ук «көчле кеше, көрәшче, баһадир» (чагыштырыгыз: монгол телендә бөке — «сугышчы, көрәшче, атлет», чыгтай телендә бөкә — «көч», кыргыз телендә пөкө — «көчле», «кыю», якут телендә бөгә — «нык», «ныклык» һ. б.) мәгънәсенә ия.

Шулай итеп, Идел-Кама болгарларының Котлыбөкәш исеме «бәхетле герой, баһадир» мәгънәсен белдерә икән һәм ул, кеше исеменнән авыл атамасына (ойконимга) әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган.

Богырыслан — Оренбург өлкәсенең борынгы шәһәре санала. Аның атамасы бога һәм арыслан дигән борынгы төрки кабиләләрнең исемнәре (этнонимнары) кушылып ясалган төрки кеше исеменнән алынган. Әлеге шәхес нигез салганга, бу торак пунктка аның исеме кушылган. Бога сүзе борынгы төрки телдә «үгез» дигән мәгънәне белдергән. Себер татарларының бер тармагын тәшкил иткән тара татарлары хәзер дә үгезне «бога» диләр. Шушы мәгънәсендә бога сүзе борынгы мажар теленә кабул ителгән. Урыс телендәге «бугай», «бык»,та бога — букадан килеп чыккан. Бога арыслан исеме кеше белән хайваннарның килеп чыгышлары уртак дип карау-ышануга нигезләнгән борынгы тотемистик инануга барып тоташа. Борынгы төркиләр әтисе арыслан ыруыннан, әнисе бога ыруыннан яки киресенчә булган ир балага Богаарслан дигән исем бирелгән. Богаарслан исеме хәзерге антропонимиконыбызда урын алмаса да, фамилиягә (мәсәлән, Татарстанның Зеленодол районы Татар Танае авылында Богырыслановлар бар) һәм ойконимга (Богырыслан шәһәре атамасына) әверелеп, безнең көннәргәчә сакланган.

Этнонимга (ыруг-кабилә, халык исеменә) нигезләнеп барлыкка килгән торак пункт атамаларына мисаллар китерик.

Актаныш һәм Кукмара районнарындагы Адай дигән татар авыллары атамасының асылында адай дигән борынгы төрки этноним (ыруг-кабилә исеме) ята. Бу этнонимның барлыкка килүе исә Адай дигән борынгы кеше исеменә нисбәтле. «Борынгы төрки сүзлек» тә (Л., 1969, 8 б.) adaj сүзенең: 1) кошчык; 2) күчерелмә мәгънәдә «бала», «кошчык» мәгънәләрендә кулланылуы күрсәтелгән. Adaj, Adaj tutus кебек кеше исемнәре булу теркәлгән. «Кошчык» (күчерелмә мәгънәдә «бала») төшенчәсен белдергән адай сүзе башта дөньяга яңа туган ир балага иркәләп эндәшү-мөрәҗәгать итү сүзе буларак кулланылган, аннан соң кеше исеменә әверелеп киткән. Адай исеме «бала» төшенчәсен белдерә торган сүздән ясалган төрки кеше исемнәре белән бер синонимик оя тәшкил итә: Адай, Балакай, Балабәй (шуннан Бәләбәй шәһәре исеме), Балаәмир, Балаиш, Балаш; Чыгатай (чага — «бала» тай — иркәләү-кечерәйтү кушымчасы), Чагакай, Чагай (шуннан Чагаев фамилиясе) һ. б. Татар теленең көнбатыш диалектында чыга сүзе хәзер дә «бала» мәгънәсендә кулланыла. Татар әдәби телендәге жыйма эчтәлекле бала-чага синонимик парлы сүзе урта һәм көнбатыш диалект лексемаларыннан ясалган.

Башкөртларда һәм казакъларда адай ыругларының булуы билгеле.

Биектау районында Кондырлы дигән татар авылы бар. Кондырлы авылының исеме Кондырлы елгасы (Ф. Г. Гарипова. Татарстан гидронимнары сүзлеге. Казан, 1984, 71 б.) атамасыннан алынган. Кондыр (кондыз) күп булганга, болгар бабаларыбыз әлеге елганы Кондырлы дип атаганнар. Проф. А. П. Ковалевский «Чуваши и булгары по данным Ахмеда ибн Фадлана» (Чувашгосиздат, 1954, 16 б.) дигән хезмәтендә хәзерге Самара өлкәсенең төньягындагы бер елганың Кундурча («Кундузча») дип аталуын болгар теленә хас булган ротацизм («з» урынына «р» әйтү) күренешенә бер мисал итеп китерә. Шуны күздә тотып, Татарстанның хәзерге Биектау районындагы Кондырлы елгасы һәм авылы исеменең килеп чыгышы болгар теленә нисбәтле дип әйтә алабыз. Әлеге елганы һәм авылны татарлар Кондызлы дип атарлар иде. Мари теленә дә умдыр («кондыз») сүзе болгарлардан кергән. Болгар телендә кундыр, мари телендә умдыр (кундыр»умдыр), чуваш телендә хантар, татар телендә кондыз (р-з тартык авазлары тәңгәллеге җирлегендә кондыр кондыз). Кондыз сүзе болгарларга кундыр әйтелешендә гарәпләр белән сәүдә итү, алтынга бәрабәр булган кондыз тиреләрен башка әйберләр алмаштыру, алтын акчага сату нәтиҗәсендә килеп кергән булырга тиеш. Кыйммәтле кондыз җәнлеге күп булган инешләргә, елгаларга болгар бабаларыбыз Кондырлы, Кондырча исемнәрен кушканнар.

Татар телендәге «кондырлы кодачасы» фразеологик әйтелмәсенең килеп чыгышы да элекке заманнарда Кондырлы авылыннан Казанга кодаларына

утырмага килгән кунак кызының (кодачаның) үзен көйсез тотуына, каприздлануына мөнәсәбәтле. Мәгълүм ки, татарларда кондырлы кодачасы тәгъбире юкка көйсезләнүче хатын-кызга карата әйтелә.

Татарстанда атамалары составында кә, кәү, кау, кү сүзләре (тамыры) урын алган берничә татар авылы бар. Мәсәлән, Иске Кәшер, Яңа Кәшер (Әлмәт районы), Зур Кавал, Кече Кавал, Ташлы Кавал (Биектау районы), Комлы Кавал (Лаеш районы) һ. б. Чувашстанның Ормар районында Кавал дигән чуваш авылы бар. Бу авыл турында К. Насыйри болай дип яза: «Кавал авылы — Чабаксар өязендә бер авыл бардыр, хәзердә базарлы авыл; чуваш авылыдыр. Татарча Кәвәл дип әйтелә, урысча Ковали диерләр. Иске заманда мөселман авылы булгандыр».

Әлеге кә, кәү, кау, кү топокомпонентларының килеп чыгышы фин-угыр телләре белән бәйләнешле: фин телендә kivi, эрзя-мордва телендә kev, мари телендә кү, ханты телендә kew — «таш». Коми-зырян телендә дә ки сүзе кайчандыр «таш» мәгънәсендә кулланылган (хәзер бу телдә «таш» мәгънәсен из сүзе белдерә). Моның шулай булуын Түбән Вычегда бассейнындагы Кишер («Кишор) елгасы һәм Яреньга елгасының кушылдыгы Киваж атамалары раслый. Кишор — «ташлы елга», ә Киваж — «ташлык кушылдык» дигән мәгънәне аңлата. (Общее языкознание. Методы лингвистических исследований. М., 1973, 98 б.). Моңа таянып, республикабызның Сарман районындагы Иске Кәшер, Урта Кәшер, Әлмәт районындагы Яңа Кәшер авылларының исеме «ташлы елга» (алар чыннан да Кәшер дип аталган ярлары ак ташлы елгачык буена утырганнар), Арча районындагы Күшәр, Күңгәр, Күәм авыллары атамаларының, мари теленә нисбәтле рәвештә, баштагы икесе «ташлы елга», «ташлы елгачык», ә соңгысы «ташлы» мәгънәсен белдерә дип әйтә алабыз.

Безнең карашыбызча, Кавал (дөресрәге Кәвәл) топонимы фин-угыр телләрендәге kev яки kew «таш» — борынгы болгар-татар телендәге эл ил «авыл» сүзләре кушылып ясалган гибрид атама тәшкил итә һәм «ташлы авыл», «таш авыл», ягъни «ташлы ярлы су (елгачык) буена утырган авыл» мәгънәсен белдерә. Ташлы Кавал авылы атамасында бабаларыбызның фин-угыр кабиләләре телендәге кау (kaw) сүзен татар теленә «ташлы» рәвешле төгәл тәрҗемә итеп, Ташлы Кавал «ташлы — ташлы авыл» формасында кулланылышка алулары, һичшиксез, игътибарга лаеклы. Чагыштырыгыз: Ташсу (Биектау районы), Таш Чишмә (Арча районы), Ташкичү (Арча, Баулы, Тукай районнары), Ташлыяр (Мөслим, Саба районнары), Таш елга (Кукмара, Мөслим, Тукай районнары), Ташлы (Баулы районы), Ташлык (Түбән Кама районы) — республикабыздагы татар авыллары, Каменка — Азнакай районындагы урыс-татар авылы, Каменка — Әлмәт районындагы урыс авылы, Каменный Починок (Ташлы) — Мамадыш районындагы урыс авылы һ. б.

Балтач районындагы Сосна авылы атамасының килеп чыгышын (этимологиясен) шулай ук фин-угыр телләре материалында аңлатып була.

Фин-угыр телләренең угыр тармагына карый торган манси телендә (угыр тармагына тагын мажар һәм ханты телләре керә) сос шош гидрографик номенклатура термины «инеш», «кечкенә елга» төшенчәсен белдерә,— на — әйбернең булуын, барлыгын белдерүче кушымча. Димәк, Сосна атамасы «инешле» дигән мәгънәне аңлата. Түбән Сосна авылы янында Сосна дип аталган инешнең агып ятуы әлеге фикерне куәтли. Чагыштырыгыз: Шошма (мансича шош сос «инеш»,— ма-на — әйбернең булуын белдерүче кушымча) — Балтач районындагы елга, Нократ елгасының уң кушылдыгы.

Борынгы заманнарда ике кабилә кушылу нигезендә, бер үк географик объектны бердәй төшенчә белдерә торган кушма төзелешле гибрид атамалар (аерата «елга» + «елга» яки «инеш» + «инеш» төзелешен тәшкил иткән) белән исемләү топонимиягә хас күренеш. Мәсәлән, Суслонгер (мансича сосла сосна «инешле» — марича эңгер «елгачык, инеш») — Марий илдәге елга һәм шәһәр, Чайшур (борынгы төрки телдә чай сай зәй «елга» — удмурт телендә шур «елга») — Саба районы территориясеннән агып уза торган Мишә елгасының уң кушылдыгы һ. б. Мишә елгасы атамасын борынгы төрки телгә фарсы теленнән кергән бешә-мешә «урман» сүзенә бәйләп аңлаталар (М. З. Зәкиев. Татар халкы теленең барлыкка килүе. Казан, 1977, 170 б.). Бу гидронимны угыр телләреннән манси телендә сакланган меша «бөгелешле елга» (извилистая река») гидрографик терминына бәйләп тә аңлатып була. Саба районында Оет дигән татар авылы бар. Манси теле җирлегендә аңлатканда, бу атама «болын» дигән мәгънәне белдерә.

Татарстан җирлегендә, аерата аның Казан арты җирлегендә, байтак кына географик атамаларның, башлыча елга һәм авыл исемнәренең, этимологиясе

фин-угыр телләре жирлегендә ачыклануы бер дә гаҗәп түгел. Чөнки Урта Идел-Кама регионы күпчелек археологлар, тарихчылар һәм телчеләр тарафыннан фин-угыр кабиләләре дә формалашкан мәйдан булып санала.

Археологик, топонимик һәм этнонимик мәгълүматлар Татарстан жирлегендә мажар кабиләләренең яшәвен дә хәбәр итә. Бик борынгы заманнардан алар Урал, Идел буйларында, Төньяк Кавказ далаларында, Дунай буйларында гадәти төрки телле кабиләләр һәм халыклар белән аралашып яшәгәннәр. Мажарлар VII гасырлардан алып IX гасыр урталарына кадәр (830 елга чаклы) хазарларга буйсынып яши, хазарлар составында болгарлар да була.

Мажарларның безнең жирлектә әр әрә әри «елга, елгачык» компонентлы гидронимнар торып-сакланып калган. Татар әдәби телендә «төрле агач, куаклар һәм кыяк-камышлар, үләннәр белән капланган урын, елга үзәне» төшенчәсен белдерә торган әрәмә (русча урема) сүзе мажар теленнән килә торган әрә «елгачык» тамырына төрки телләрдә сүз ясагыч -мә кушымчасы кушылып ясалган.

Шушы яссылыкта караганда, Лаеш районындагы Татар Сараланы, урыс Сараланы авыллары атамасы составында урын алган саралан компоненты «сары алан» дигән мәгънә аңлатмый, бәлки «саз аланы», «сазлы алан» дигән мәгънә белдерә булып чыга. Куе урман эчендәге сазлыклы аланга урнашкан Саралан авылы атамасының «саз аланы» яисә «сазлы алан» дигән мәгънә белдерүе чынбарлыкка (бу очракта географик реалийга) туры килә.

Димәк, шушы мисалларга таянып, Татарстан топонимиясендә мажар калдыклары бар дип әйтә алабыз. Бу мәсьәлә мулрак тарихи-лингвистик фактлар нигезендә тагын да жентеклерәк тикшеренүне сорый, әлбәттә.

Татар энциклопедиясенең тарихи-географик һәм топонимик проблемаларын фәнни жирлектә хәл итү өчен академик М. З. Зәкиевнең «Татар халкы теленең барлыкка килүе» (Казан, (1977), филология фәннәре докторы Ф. Г. Гарипованың «Татарстан гидронимнары сүзлеге» (Казан, 1990), «Исследования по гидронимии Татарстана» (М., 1991), шушы юллар авторының «Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики» (Казань, 1970), «Татар исемнәре сүзлеге» (Казан, 1981), «Татар антропонимикасы» (Казан, 1990) дигән басмалары, өч томлык итеп төзеп бастыру күздә тотылган, 100 меңнән артык жирле географик атаманы үз эченә алган «Татар теленең топонимик сүзлеге» картотекасы һ. б. мөһим фәнни чыганак булып тора. Шушы җәһәттән безнең җитәкчелектә язып якланган кандидатлык диссертацияләреннән Ф. Л. Мәжитованың «Татар фамилияләренә тарихи-лингвистик анализ» (Казан, 1986), А. Ю. Фильскованың «РСФСРның төрки чыгышлы шәһәр атамаларына тарихи-лингвистик анализ» (Алма-Ата, 1989), Р. И. Куряеваның «Урта Идел буе урыс ойконимиясенең төрки катламы» (Казан, 1992), Е. Б. Акиндиковның «Ростов өлкәсенең төрки топонимиясе» (Казан, 1992), З. Ф. Әхәтованың «Татарстанның Түбән Кама буе топонимиясе» дә әһәмиятле.

Татарстан ФАнең Татар энциклопедиясе институтында төбәкләр (авыллар) тарихын өйрәнү бүлеген ачуның зарурлыгын матбугат урынлы күтәрә. Төбәкләр, авылларыбыз тарихын өйрәнүне һәвәскәрчелектән гыйльми нигезгә салыр вакыт житте, әлбәттә. Бу эшкә галимнәрдән тыш, шулай ук университет, педагогия институты студентлары да зур өлеш кертә алыр иде. Казан университетының элекке татар филологиясе бүлеге, хәзерге татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты студентлары 1965 нче елдан башлап дәвамлы рәвештә мондый хезмәтне башкарып килә. Татарстандагы һәм аннан читтә татарлар зур күпчелекне тәшкил иткән төбәкләр, авыллар тарихын, ойконимиясен (исемнәрен) һәм микротопонимиясен өйрәнүгә йөзгә якын диплом эше язып якланды инде. Әлеге диплом эшләренең татар авылларының тарихын, исемнәренең килеп чыгышын һәм микротопонимиясен өйрәнүдә билгеле бер фәнни өлешләре, кыйммәтләре бар, әлбәттә.

Чал һәм бай тарихлы татар халкының XX һәм XXI гасырлар аралыгында беренче мәртәбә Татар энциклопедиясен төзеп бастыру мөмкинлеге туды. Аның сыйфатлы булып дөньяга чыгуы өчен, һәр галимнең үз белгечлеге өлкәсендә тиешле фәнни өлеш кертүе, фидакарьләрчә хезмәт итүе кирәк.

■ ■ ■



# ТАТАРНЫҢ ТАНЫЛМАГАН МӘШҺҮР ЗАТЫ

«Танылмаган» дип язып куйдым да, бүгенге бик тә гыйлем иясе булып кыйланган надан укучыбызны искә төшердем. Ни хәл итәсең, бирегә, бәлки, ул да гаепле түгелдер. Үзенең нәсел-нәсәбен оныту аны да әллә кая — еракка алып бармагандыр шул. Ул, ни хәл итәсең, бүген 24 яшендә һәлак булган бөек шагыйре Шәехзадә Бабичка 100 яшь икәнен дә онытырлык хәлгә китерелгән икән. Бүгенге күп кенә укучыларыбызның (алар без фәкыйрегезне гафу итсен) инде бу бөек затның әсәрләре кайсы газета-журналларда басылганын да ишеткәне юктыр, мөгаен; ул газета-журналлар булганнар, безнең ата-бабаларыбыз октябрь фетнәсенә кадәр, хәтта соңрак та аларны укыганнар... Укыганнарын ерак еллар аша — фаҗигале еллар аша безнең чорга алып килеп җиткергәннәр. «Аң», «Шура», «Кармак», «Акмулла» журналлары, «Тормыш», «Сүз», «Ирек», «Чулпан» газеталары аларны басма матбугатта ташка басылган хәлдә саклап калганнар. Бабич безгә әнә шул ташка басылган чыганаклар аша килеп җиткән. Әлбәттә, кулына каләм алган затның үз эшләрен китап итеп күрергә теләмәве гайре табигый булыр иде. Бабич та моңа омтылган. 1912 елны китап та төзегән булган. Үзенчә, нечкә юмор белән, йөгертеп кенә аңа сүз башы да язган. Казакъ далаларында укытып кайтканнан соң 17 яшьлек шагыйрь болай ди:

«...Әй, тыңдәшләр! Мин бу җырларны казакъта чагымда, мужик әйткәндәй, тик ятканчы «бер этлек» булсын дип кенә язган идем. Боларны ташка бастыру ягы, ичмасам, хәтеремә кереп кенә дә чыкмаган иде. Бәй, илгә кайткан идем, иптәшләрем миңа чат ябышты: «Әй-йәй! Шигырьләрең бик шәп икән, бастыр гына иптәш»,— диделәр, йөдәтеп бетерделәр. Мин аларга: «Бу төссез сүзләрне ничек итеп бастырмак кирәк! Бастырсаң да бер ай да булмас, бәлки үземне әллә ниләр белән тиргәрләр генә» — дидем дә, ни бер дә колакларына кермәде шул. «Әй иптәш! Юкка гына шикләнәсез икән, җырларыңа ия бетәсе булмас әле, үзебез шикелле татарча сукалый белә торган малайлар беткән дисеңмени? Китапчыкларда синекеннән дә алама шигырьләр, көйле китаплар бар бит! Аларга караганда, синең биш артык», кебек сүзләр белән үз уйларын иплн генә бирделәр.

Шуннан соң алар белән күп җинешеп булмас вә тарткалашып хәтерләрен калдырасым килмәде — тоттым да бастырдым (ни булса булыр, дидем дә бастырдым).»

Кызганыч, бу мәҗмуга ташка басылмыйча, кульязма хәлендә калган. Шөкер әле, югалмаган. Югыйсә, шагыйрьнең беренчел дип аталган «И китаб!» шигырен дә җуйган булыр идек:

Ап-ачык тор һәрвакытта, и китаб! Баксам сиңа,  
Чын, асыл нигезле җирдән күп белемнәр бир миңа!  
И китаб! Мин аңгыраны төз юлга күндерсәнә!  
Мине баскан «җәһел» утын су сибеп сүндерсәнә!  
Син җуаткыч, син — уяткыч, син миңа чын-чын атам:

Булмасаң син, мин сине сагнып кына чирләп ятам.
И китабым, и китаб! Мина кыл син хитаб!
Син генә башымдагы чуп-чарны алырсың утап.

*1910.*

Бабичка 15 яшь. Тугыз елдан ул фаҗигале дөньядан китәр. Иң куркыныч үлем белән — ат койрыгына тагылып — Мәңгелеккә... Әмма халык йөрәгенә китәр. Егерме дүрт яшендә.

* * *

Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы Бабич 1895 елның 15 гыйнварында Башкортстанның Дүртөйле районы (элеккеге Уфа губернасы Бөре өязе) Әсән авылында дөньяга килә. Безгә билгеле булганча, инде ниһаять, шагыйрьнең авылдашы, күренекле әдәбият галиме Галимҗан Гыйльманов төзегән «Зәңгәр җырлар» исемле китаптагы кереш сүзгә нигезләнеп, катгый әйтергә мөмкин: Бабичлар нәселе борынгы нәсел. Нәсел агайлары Мохтар баба Казан ягыннан килеп (Саба ягыннан булырга тиеш), тирә-якта дан тоткан башкорт гүзәленә өйләнә. Нәсел шәҗәрәсен кузаллар өчен «Зәңгәр җырлар»га мөрәҗәгать итә аласыз. (Сүз уңаенда гына әйтеп үтим, гомумән, бу китап Тукай, Такташ, Җәлил томнарыннан соң, татар шигъриятенә куелган иң зур китаби һәйкәлләрнең берседер; әйткәнемчә, бу очракта шагыйрьнең авылдашы, галим, язучы Галимҗан Гыйльманов алдында баш иярга кирәктер.) Чөнки шигырь теле белән әйтсәк:

Кайчагында киреләнеп
Теләмисең баш иярга...
Баш болай да иелә шул
Баш иярдәй кешеләргә.

Шагыйрьнең әтисе Мөхәммәтзакир мулла гомерендә өч тапкыр өйләнә. Унҗиде баласы була. Унбере исән үсә. Ике хатыны үлеп, өченчегә өйләнә. Өченче хатыны Бибисаҗидәбанудан баш бала булып Шәехзадә туа.

Рәхәтлектә үсә. Теләгәнчә уйный, теләгәнчә укый. Аның балачагы — уенкөлке, җыр-бию. 13 яшендә аны ата-бабаларының нигезләнгән авылы, Кыйгызытамакка мөгаллим-хәлфә итеп җибәрәләр.

Әнә шуннан башлана инде. Бу җәһәттән Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең яшүсмерлегендә булган вакыйга искә төшә. Шиһаб хәзрәтнең балачагы, күпмедер дәрәҗәдә, Бабичныкын да хәтерләтә. Ул да 13—15 яшьләрендә бабасын һәм әтисен акыллы-зирәк сораулар белән борчый торган була. Ә аны әтисе — бабасына, бабасы — әтисенә җибәрә. Имеш, бабаң дөнья күргән кеше, ул күбрәк белә. Бабасы, үз чиратында, җавап бирә: «Әтиең яшьрәк кеше, ул күбрәк белә». Шулай ике арада йөреп арган Шиһабетдин әйтергә мәҗбүр була: «Икегез дә җавап бирә алмагач, мине ник дөньяга китердегез!». Һәм шуны сәбәп итеп, Бохара якларына китеп бара.

Шәехзадә белән дә шундыйрак хәл булырга тиеш. Ул да әти-әниләренә әйткән булса кирәк: «Сез мине укырга-язарга өйрәттегез. Белем бирдегез. Әмма мужик хезмәтенә өйрәтмәдегез. Бу һөнәрдән башка биредә мин яши алмыйм. Китәм!»

Әйе, мәсьәләнең нәкъ шулай куелган булуы ихтимал. Чөнки халык белән аралашып яшәргә хөкем ителгән шәхес, авылда мөгаллимлек иткәндә, бервакыт бөтенләй эшсез кала. Чөнки мужик балалары әти-әниләре, ягъни бөтен гаиләләре белән кырга китәләр. Ә аның андый мөмкинлеге юк. Ул бу хезмәткә өйрәнмәгән. Гарьлек.

Шәех бу бәхәстә әти-әниләрен җиңә ала. Ул үзен дә җиңә. Беренчедән, матди мөстәкыйльлеккә ирешә. Икенчедән, үзе теләгән китап дөньясында яши алу мөмкинлеген ала.

Ниһаять, әйткәнебезчә, ул 15 яшендә казакъ даласына укытырга китеп бара. Беренче баруында Кустанай өлкәсенең Тургай тирәсендәге Дүсәнбай авылында хәлфәлек итә. Бу хакта аның шигъри юллары да калган:

Белмәсәң, минем кояшым илдәге мәктәп иде,
Һәр кызык анда иде, бу туң күңел майдай иде.
Ә хәзер күңелем минем боздай туңган таштайката,
Чөнки йөргән җирләрем тик кап-кара Тургай җире.

Тургай жире... Казан даласы... Тукайның «Валлаhи» шигырен генә искә төшерик. Бабичның даладан туганнарына язган хатында да бу халәт, «муллакә» булып, күкрәк киереп, шатланып йөрү сизелеп тора (1911):

«...Казакъ теленә баргач та өйрәнеп алдым. Мин аларның укытучыларын да укытам. Казакъча шигырьләр язам, җырлыйм, тамашалар корам. Казакълар авызларын ачып, шаккатып, эчләрен тырный-тырный тыңлыйлар.

Авылны, сезне бик сагынып кайтыр идем. Казакъларым: «Китмә гуй, җибәрмибез гуй»,— дип җибәрмиләр, үзем дә аларга бик ияләштем. Ташлап китсәм бик җәл калалар...»

Казакъ даласы Бабичка тагын бер гаҗәеп шигъри дөньяны ача. Ул да булса — Абай. Тукай, Абай иҗатлары аша шагыйрь урыс әдәби дөньясына — Пушкинга, Лермонтовка чыга.

* * *

**Ш**ул 1911 елны шагыйрьнең тормышында тагын яңа бер борылыш була. Ул да булса, «Галия» мәдрәсәсендә уку. Дөресен әйткәндә, Галия — ул дәрелфөнүн, ягъни татар-төрки университеты. Биредә ул артист буларак та, шагыйрь буларак та, шәхес буларак та киерелеп ачыла. «Кармак» исемле әдәби журналның мөхәррире була, соңрак аны — мәгънәле ич! — киләчәктәге күренекле галим булачак Галимҗан Нигъмәтигә тапшырып китә.

Бабич сәхнәдә... Бу сүз озакламый Уфа татарларын магнитка тартылган тимер кисәге хәленә китерә. Ул танылган җырчы Газиз Әлмөхәммәтов белән дә, әйтүләренә караганда, мәшһүр Габдулла Кариев белән дә концертлар алып бара. Үз шигырьләрен укый, мандолинада уйный. Үзе моңга әверелмәгән кеше түбәндәге шигъри юлларны яза аламы? Бу үзе бер музыка ләбаса!

И үзәк өзгеч тавышлы, моңлы, зарлы мандалин,
Килче, моңланчы өзеп бер, мин дә тынлап моңланыйм.
.................................................................................
Сине тыңлап, һәммә таптан, һәммә кердән сафланаи,
Сафланам да, пакъланәм дә — алла, алла, алла! дим.

*1914.*

Бабич сәхнәдә...

Бу җәһәттән, ул татар, башкорт эстрада сәнгатенә нигез салучыларның берсе саналырга хаклы.

* * *

**«Г**алия» чоры шагыйрьнең иң иҗатлы, иң бәхетле чоры. Ул вакытта биредә Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш, Галимҗан Нигъмәти, Солтан Габәшиләр, казакъ халкының булачак бөек шагыйре Җомабай белем ала. Зыя Камали, Галимҗан Ибраһимовлар укыта.

«Галия»нең ун еллыгына язылган «Бер тәмсил» әсәрендә шагыйрь болай дип яза:

Бакча бар, умарта шәп, эшләр җайда;
Бакчада чәчәк баллы, яхшы файда.
Ел саен җиткән кортлар, аерылып,
Һәр якка таратыла билгеле айда.

*1916.*

«Изге җан». Бабич хакында әйтелгән бу сүзләр — Нәкый ага Исәнбәт тарафыннан әйтелгән сүзләр. Остаз болай дип сөйли иде:

— «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган чагым. 1913 елның яз башлары иде. Безгә бер казакъ дусты белән Бабич килде. Каләм тибрәткәнемне белгәч, шигырьләр бәйләмемне алып киттеләр. Берәр ай чамасы вакыт үткәч, шагыйрь яңадан пәйда булды. Кульязмамны кире кайтарып бирде. Анда мондый юллар бар иде:

Мин сине тәбрик итәм шигърең белән, Әхмәт Нәкый.
Бик шат улдым, мәмнүн улдым мин сиңа, рәхмәт Нәкый.
Мин өметлемен сиңа, истикъбалең парлак синең:
Һәм булачак (иншә алла) мәртәбәң «чарлак» синең!

*Ихтирам илә кардәшеңез Ш. Бабичев.*

«Изге жан» димичә, кем дисен. Күрәзәчелек кодрәтенә ия булган «изге зат». «Истикъбалең парлак синең», ягъни, киләчәгең ачык, якты; «мәртәбәң чарлак синең», ягъни булачак урының ил-йортның түбәсендә — чарлагында.

Остазсыз бер генә талант та вакытында үз кыйбласын таба алмый. Остазың күрсәткән тугры юл — гомерең буена житә. Бу очракта Бабичның бәхете бар. Үзенең «Замандашларым» китабында шагыйрь Зариф Бәшири Бабичның остазы Галимжан Ибраһимов турында болай дип сөйләгәнен искә ала: «Ул укый башлагач та мин үземдә кискен борылыш ясалганын сиздем. Аңа чаклы миндә дә, матур әдәбиятта, бигрәк тә шигырьдә, гарәп-фарсы сүзләрен куллану кирәк, дигән бер караш бар иде. Шул унай белән бервакытны Галимжан агай миннән сорый: «Син киләчәктә яктыга таба баруыңда кемгә, нәрсәгә таянасың?» — ди. «Билгеле,— мин әйтәм,— халкыма»,— дим. «Шулай булгач, ди, Галимжан агай әйтә,— синең әдәби телең дә үз халкыгызның теле булырга тиеш түгелме?» — ди. Шуннан соң мин халык телен актарып, аның җәүһәрләрен эзләргә керештем».

Зариф Бәширинең бу истәлекләрендәге сүзләрнең хаклыгын Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш авызыннан ишеткәннәрем дә дөресләп тора. Шулай ук шагыйрьнең төрле елларда көйләр тарихына мөрәҗәгать итеп торуы да бу хакта анык сөйли. Тукай юлыннан китеп, «Тукайга тәкълид» рәвешендә басылган «Авыл җырлары» да үзенә бер хезмәт ич. Галимжан Гыйльмановның югарыда телгә алынган «Зәңгәр җырлар» китабындагы искәрмәләре үзләре генә дә ни тора!

Ни генә дисәк тә, барыбер, Бабичның башы — Тукай.

Урысның шигъри вулканнары Пушкин илә Лермонтов булса, татарның (ә бәлки гомум төрки дөньясының да?) Тукай илә Бабич. Җәя эчендә әйтелгәннәрем казакъ туганнарыма үпкәләрлек булмасын өчен әйтеп китәм, алар да яңа чор әдәбиятын Абай илә Җомабай дип беркетә алалар. Ә Җомабай Бабичлар белән аркадаш — Галимҗан агайлары шәкертләре ләбаса!

Бу аларның «Галия» чоры.

* * *

Пушкин илә Лермонтов...

Үз дәүләте булган, үз сәяси вә әдәби юнәлеше булган урыс туганнар бу бәйләнешне шундый биеклеккә күтәрделәр ки, ниһаять, бөтен империя балалары бу күренешне бербөтен итеп, дәвамлы чылбыр итеп күзаллый башладылар. Инде килеп, без Пушкинның, йә Лермонтовның кайсы көнне кайсы балда, кайсы кичне кайсы княгиня янында әңгәмә корып утырганын да беләбез. Ышанмасагыз, Ираклий Андрониковның «Лермонтов» хезмәтен генә укып карагыз.

Абай илә Җомабай...

Казакъ халкы озак еллар Җомабайның шигырьләрен көйләп, җыру итеп әйтеп йөрсә дә, бу берлекне барлыкка китерә алмый интекте. Өфедән Сәйфи Кудаш, Казаннан Хәсән Туфаннар Абай бәйрәме саен Кунаевка кереп, хатлар язып аңлатсалар да, барып чыкмады. Ниһаять, казакъ халкы: төп хакыйкатькә килә бара. Үз дәүләтен булдыру аңа ярдәм итәчәк.

Хәтеремдә, Ләбибә апа Ихсанова «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе булып эшли иде. Журналда минем шигырьләр бәйләмем чыгып килә.

> Афәтләр узып та, мәхшәрләр узып та
> Үз-үзен югалтмас шәхесләр бар ич:
> Хәзрәте Пушкин,
> Хәзрәте Тукай,
> Хәзрәте Лермонтов,
> Хәзрәте Бабич.

— Мөдәррис,— ди Ләбибә апа,— әгәр шигырьне төшереп калдырсак, журналның бер табагын әр-яңадан җыярга кирәк. Ярдәм ит!

Әгәр дә шагыйрь кеше яки ир кеше булса, кемгә дә булса бер бөртек зыян эшләгән зат булса, бер генә сүз әйтер идем: «Тавыгыгыз, чебешегез...»

Бу очракта үзем хөрмәт иткән шагыйрьнең (Шәрәф Мөдәрриснең) терәге булган җанга, сабырлык иясенә каршы килү хакында уйламадым да, шигырь мөмкинлегенә карап, рифмаларны болай үзгәрттем:

«...шәхесләр булыр»

.............................................

*«Хәзрәте шигырь».*

Шулай чыкты да...

Вакыйга әле моның белән генә бетмәде. Дөньяви остазым Хәсән Туфан, Аккош күлендәге иҗат йортына баргач, миңа — ризалашканым өчен, үпкә белдерде.

1974 елның көзе иде. Әнә шунда — Хәсән аганың ябык болдырында — «Замандашым монологы» дигән җавап балладасы язылды. Тулысынча озын, шуңа күрә дә башыннан өзек кенә китерәм:

Акылыннан яза-яза,
Бөтен халык яза;
Яза алмыйм... Бүген сине
Уйлыйм Шәехзадә.

Килде хәбәр: тагын килеп
Кагылганнар сиңа...
Кагылганнар... Димәк тә ки
Илем ярасына.

Шул ук «зат»лар. Йөрәк кинәт
Чәнчеп алды мине.
Эт тә үрчи. Аларның да
Өреп йөргән көне.

Ни хәл итим. Йөзләрендә
Битлек тә юк хәттә:
Эчеп тамак туйдырганнар —
Сүгеп баш төзәтә.

Шәехзадә Бабич өчен бик тә рәнҗеп йөргән еллар иде бу.

* * *

Пушкин илә Лермонтов...

Тукай илә Бабич...

Без Лермонтов иҗатын дәреслекләрдән «Шагыйрь үлеме» әсәре аша өйрәнә башлыйбыз. Аңа кадәрге чорда Михаил Юрьевич әйтерсең лә булмаган да.

Әгәр без дәреслекләрдә Бабич иҗатын да «Тукай үлеменә» шигыреннән өйрәнә башласак?!. Әйбәт булыр иде... Хәзергә әле, безнең бер генә дәреслектә дә Бабич иҗаты өйрәтелми. Ә кызганыч! Югыйсә, Тукайҗан исән чагында, 1911 елда ук, Шәехзадә гаҗәеп бер шигырь язган:

Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь Габдулладай;
Ул — караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай.

.............................................

Бакыр эчендә көмешләр ялтырап яткан кебек,
Ап-ачык, ап-ак булып, тик ак күбек аккан кебек.
Гали зат Габдулланың хәзер Казанда мәскәне,
Ул уяткыч, ул юаткыч, ул терелткеч хәстәне.

Әгәр дә киләчәктә Тукайга багышланган шигырьләрдән төзелгән китап чыгарыла калса (ә ул шулай булырга тиеш тә), әлеге китап, һичшиксез, шушы шигырь белән ачылырга тиештер.

* * *

Бабич хакында күпме генә сөйләсәң дә сөйләп тә, гәпләшеп тә бетереп булмас иде. Шагыйрьләрнең аңа багышланган шигырьләре күп — Г. Афзал, Н. Нәҗми, С. Кудаш һ. б. һ. б. дистәләгән шагыйрьләрнең шигырьләре.

Шулар арасында Зөлфәтнең яшьлегендә язган шигыре дә бар. Бабичка — үлгәндә 24 яшь. Ә Зөлфәтнең бу шигыре дә 24 яшендә язылган. Һәм ул шигырь «Бабичны юксыну» дип атала.

Бөек шагыйребезнең 100 еллыгын йөзгә кызыллык китермәслек итеп уздырсак иде дигән теләктә калып, каләмдәш дустым Зөлфәтнең шигырен тыңлап карыйк.

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМ.**
*30 ноябрь 1994.*

▶

## Зөлфәт

### Бабичны юксыну

Шәехзадә — бөек яшьтәшем син!
Легендага, тукта, күчми тор,
Үз җырыңны тыңла тау битендә,
Җилләр булып җанга исми тор.

Болай гына аңлап бетермәслек
Моңнар яши курай теләндә.
Мең «Исемнәр бакчасы»на сыймас
Гүзәл кызлар синең илеңдә!

Нинди горур, нинди дәртле икән
Бөркетләрнең канат җилпеше...
Тыңла, дала, газиз улкаеңның
Җырлар җырлап үтеп китеше.

Әй, бөркетләр таңда канат җилпеп,
Күтәрелә Урал ягыннан,
Алар да бит азат очышларны
Нәкъ халыклар кебек сагынган!

Яшәү авыр, җанда моң күп булса,
Моңлы җаннар җырчы булалар,
Иртә яуган кардай саксыз алар,
Умырзая сыман сулалар.

Синең янга сөйләшергә менәм,
Тукта, Бабич, таудан төшми тор,
Тулган күңел түгелмәсен берүк,
Җилләр булып җанга исми тор.

Күпме кылган синең далаларда...
Күпме бөркет кыя ташында...
Сөйлим сиңа — күпме кайгы йөри,
Күпме шатлык — халкың башында...

*1971*

## Шәехзадә Бабич

### Халкым өчен

Ап ак алтын җырларымны
Җырламыйм данлык өчен,

Жырлаем алтын илемчөн[1],
Үз туган халкым өчен.

Саф көмештик жырларымны
Жырламыйм алтын өчен,
Жырлаем тик саф көмештик
Саф йөрәк халкым өчен.

Чәчкә төсле жырларымны
Жырламыйм зәүкым өчен,
Жырлаем тик чәчкәдәй
Кызларга бай халкым өчен.

Дәртле кайнар жырларымны
Жырламыйм дәртем өчен,
Жырлаем тик мәңге шат,
Дәртле, көләч халкым өчен.

Егъламыйм мин көннәрем
Сыргак, суык, салкын өчен,
Егълаем тик ярлы, мескен,
Кызганыч халкым өчен.

Яшь чагым, алтын чагым,
Ялкын чагым булсын фида
Халкым алдында минем
Биргән таза антым өчен.

## Бер минут

Бер минутта ташты күңлем, бер минутта булды ут,
Бер дә янды, бер дә туңды — бары да булды бер минут.

Бер минут — бар дөньясын каргап кабынды утларым,
Янды, көйде, парча-парча булды мескен күкрәгем.

Әйе, янды күкрәгем... Тик юк, ләкин мескен түгел,
Бу йөрәк — утлы йөрәк, үткен күңел, кискен күңел.

Ул яна, тик кайгырып янмый, яна шатлык белән!
Ул яна, бу дөньяны күрмәк булып аклык белән!

Ул яна... чү, сипмәгез су, әйе, ул янсын әле!..
Янган утлар күзләремнән яшь булып тамсын әле!..

Там, минем күз яшьләрем, там, там, тамып тор мәңгегә,
Ян, минем ак күкрәгем, ян, ян, янып тор мәңгегә.

* * *

Айга мендем, ай нуры белән коендым, уйнадым,
Күп сөендем, сөенеч белән туендым, туймадым.

---

[1] Илемчөн — илем өчен.

Туймадым, айдан узып, мендем кояшка ашкынып,
Юк, шулай да булмады ташкын күңелне бастырып.

Шул барыштан барышма киттем ходайның гарьшенә,
Унсигез мең галәме артымда калды барысы да.

Ни өчендер, тапмады күңелем карар гарьшендә дә,
Көрсине күрсәм дә хәтта, тынмадым анысында да!..

## Әйдә, милләт!

Йөк авыр, юл болгавыр булса да, милләт, әйдәле,
Алда рәхәт кадрене белмәккә михнәт файдалы;
Якты, нурлы көннәрең алдында — бу хак вәгъдәсе,
Әнә күренә кыйбла яклап бик матур ак шәүләсе...

## Актык зарым

Валлаһи, син чәнчелеп кит, тончыгып үл, бет, калал,
Шунда да һичкем дә күрмәс, валлаһи, бер эт кадәр.

Нишлием соң? Әйтче, зинһар! Чәнчелимме? Ни эшлим?..
Чәнчелеп, чәчрәп чыгыйммы?.. Нишләсәң дә эш кыен!..

Нишлием соң? Зәкъкумле хәсрәтләр белән күңелем яна,
Нишлием соң?.. Мәлгунь иблисләр төкергән дөньяга...

## Яшәсен кыйммәтчелек!

«Әй, ару булды, ару булды, мәгыйшәт[1], айкалып!
Яшәсен кыйммәтчелек!» — дип сикерә, ыргый бай халык.

Мин дә җир ертып: «Яшә!» — дип, сөенә-сөенә кычкырам,
Юкса, бик кәнтәйләнеп киткән иде маэмай халык!..

Бер заманны ярлылар да чәй эчәйде май кабып,
Инде бер шакмак шикәр юк, чәй алалар пай салып.

Бер заманны без буа торган идек иттән буа!
Инде булмый бер кадаклап итне дә унай табып.

Бер заманны күктә йолдызда фикер йөрткән хавас[2]
Инде тоз дип, чәй-шикәр дип, аһ итәләр чайкалып.

Бер заман әгъля читек кигән аякка инде бак:
Нинди мескенкәйләнеп киткән чабата бәйләнеп!..

[1] Мәгыйшәт — тормыш.
[2] Хавас — сайланмыш халык, өстен кешеләр.

Бер заман саф суда иркенләп тыныч йөргән балык
Инде хәлсез, әлсерәп ул төште чалкан әйләнеп.

Нәкъ шуның күк бер заманны дөньясын типкән халык
Инде алҗып тик йөридер, сызгырып, ай-хай салып!

Кемне күрмә: «Йа ходай, сакла үзең!» — дип зар елый,—
Бар иде торган заманнар җиргә күктән [май] тамып!

Бар иде арзан заман, сәйран[1] заман, хәйран заман...
Үттеләр шул, үттеләр шул... булмый инде кайтарып!

Булмаса булмас... Тәвәккәл: яшәсен кыйммәтчелек!
Актарылсын, куптарылсын, дөнья бетсен айкалып!

Әһле зыйндыйк[2] шаккатып торсын, бозылсын интизам[3]...
Әй, кояш! Син төнгә кал да әйдә көндез, ай, калык!!

## Матур сыннар

Матур сыннар, матур кызлар, матурсыңнар,
Әйткән чакта исемеңез дә матур чыңлар.
Сезне күреп, ямьгә чумып, киттем эреп,
Гакылсызлар: «Гакылсыз!» — дип, бакырсыннар!

Карап карыйк: гакыллылар нишләр икән,
Бар гакылны көрәшергә чакырсыннар,
Карап карыйк: бер сылуны җиңәр микән,
Сихри күздән сихри уклар атылсыннар.

Кызыл ирен бер елмайса, ходай шаһит,
Бөтен фикер әсир төшәр, гакыл шүрләр;
— Ике тәңре: әүвәле — алла, икенче — кыз! —
Димәсәгез, билләһи, кяферсеңнәр!

Көчегезгә иман итеп мин багындым,
Йөрәгемә мәхәббәт сал, матур сыннар!

## Язгы җыр

Утырдым мин тауның күкрәгенә;
Җырлар язам, җилкәй, исми тор!
Чишмәкәй! Тын! Әкрен!.. Чү! Шаулама!
Үткән гомерем, искә төшми тор!

Челтерәп аккан чишмә буйларында,
Аһ, мин йөрдем былтыр кем белән?

---

[1] Сәйран — күңел ачып йөрү
[2] Әһле зыйндыйк — алласызлар, имансызлар төркеме.
[3] Интизам — тәртип.

Шул чакларны, чишмә, алып актың...
Калдым сыкрап авыр моң белән!..

Җырлар язам тауның күкрәгендә;
Зинһар димен, җилкәй, исми тор!
Йомыл, гөлкәй, йомыл бер минутка —
Минем күзләремә төшми тор!

Аһ, чәчәкләр, былтыр сезне өзеп,
Кемнең күкрәгенә кададым,
Кемгә кадап, кемгә моңлы карап,
Күзләреннән җавап арадым?[1]

Ни диде ул күзләр? Әй чәчәкләр,
Күрдеңезме серле күзләрен?
Кем иде ул, тетрәп хозурында,
Ак кулларын сорап тезләндем?...

Җырлар язам тауның күкрәгендә:
Кодрәтле җил! Әкрен, исми тор!
Сандугачкай! Назлым, куй, сайрама!
Сайрап, яшь бәгыремне кисми тор!

Исеңдәме, былбыл, үткән язда
Син сайраган агач төбендә,
Кем иде ул шунда — кочагымда
Ай балкыган язның төнендә?

Котлы булсын айлы төннәр диеп,
Син бит безне котлап сайрадың;
Син бит шунда, сикереп, ботак саен
Кунар өчен урын сайладың.

Син идең бит аның күкрәк серен,
Сайрап-сайрап, миңа белдергән;
Ул кайнаткан минем күкрәк җырын,
Сайрап-сайрап, айга мендергән...

Кем иде ул шунда — ай битеннән
Минем җырларымны укыган?
Кем, тирбәнеп минем күкрәгемдә,
Уянып торды таңда йокыдан?

Җырлар язам тауның күкрәгендә;
Тау күкрәге серем белсен дип,
Гөлләр сирпеп язган җырларымны
Күкрәгендә саклап торсын дип.

Тыңлаңызчы, кошлар, җырларымны,
Тыңласагыз, сезгә җырлармын!
Сез сайрарсыз, соңра мин тыңлармын,
Тыңлап, үксеп-үксеп егълармын!...

---

[1] Арадым — көттем.

# ОЛУГ ИСЕМЕҢНЕ ЗУРЛЫЙЛАР



«...Нинди зур, онытылмаслык эшләр башкарып китте Шәйхелислам абый! Ул иҗат иткән әсәрләрне халык һаман да яратып укый. Ә бу — мәңге яшәү, мәңге үлемсезлек, дигән сүз. Без, менә бүгенге көндә исән җәлилчеләр, зур ихтирамыбызны белдереп, Шәйхелислам абыйга мең-мең рәхмәтләр укыйбыз. Аның «Муса» романы Җәлилнең һәм башка иптәшләребезнең кылган батырлыкларын, рухи ныклыкларын халкыбыз күз алдына бөтен тулылыгы белән диярлек китереп бастырды... Шәйхелислам абыйны без беркайчан да онытмабыз!»

Бу юлларны безгә ерак Үзбәкстанның Каршы шәһәреннән каһарман Фәрит ага Солтанбәков язып җибәргән иде. Анда, бер тамчы суда Кояш чагылган кебек, Шәйхи ага Маннур иҗатына халык тарафыннан бирелгән бәһа ярылып ята.

Чыннан да, татар әдәбиятының күренекле вәкилләренең берсе — шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров) — мәдәниятебез һәм җәмгыятебез тормышында якты эз калдырган олуг шәхес. Ул 1905 елның 15 гыйнварендә элекке Казан губернасының Мамадыш өязендәге Тулбай авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1921 елның җәендә, ачлыктан качып, аның әтисе Фәрхулла абзый, бөтен гаиләсе белән Кузбасстагы Анжерка-Судженка шахталарына күчеп китә. Шунда 16 яшьлек Шәйхелисламның хезмәт юлы — «тормыш университетлары» башлана. 1923 елда Шәйхелисламны Свердловск Халык мәгарифе институтына укырга җибәрәләр...

Әдипнең биографиясен сөйләп чыгу өчен генә дә аерым бер китапчык язарга кирәк булыр иде. Свердловск, Тобол, Новосибирск, Донбасс, Днепрогэс, Мәскәү, Казан — ул укыган, эшләгән, аркылыга-буйга гизеп чыккан шәһәр һәм төбәкләрнең кайберләре генә әле бу. Шунысын да әйтеп китик: Ш. Маннур «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының җаваплы сәркатибе булып та эшли.

Шәйхи Маннурның әдәби мирасы, эшчәнлеге зур һәм күпкырлы. Үзе исән чагында аның дүрт дистәгә якын китабы дөнья күрә.

Әдәби хезмәтләре, Бөек Ватан сугышы фронтларында күрсәткән батырлыклары өчен, ул хөкүмәтнең күп кенә орден һәм медальләре белән бүләкләнә.

Без түбәндә әдипнең васыятьнамәсен урнаштырабыз. Ул матбугатта беренче тапкыр басыла. Шул уңайдан, васыять хатында исемнәре телгә алынган дүрт язучының истәлекләрен дә укучылар игътибарына тәкъдим итәбез. Олуг эшләрең калса, олуг исемең дә халык күңелендә саклана икән — әлеге язмалар шушы хакыйкатьне раслый.

## Шәйхелислам ага васыяте

Хөрмәтле Гомәр ага Бәширов! Хөрмәтле энекәшләрем Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Хисам Камалов!

Күп дусларым арасында Сез минем иң якын күргән дусларым.

Шуңа күрә мин Сезнең өскә бик авыр эш йөкләргә батырчылык итәм. Сез инде мине гафу итегез.

Бер дә көтмим...
Ләкин ул көн килер,
Суык кулын бирер,
Әйдә, диер,
Күзләреңне бәйлә, диер,
Җитәклим дә алып китим,
Яна фатирыңа илтим...

1. Менә шул көнне инде Сез минем бу хатны ачып укыгыз да гәүдәмне Тулбайга алып китегез, шау-шулы мәрасимнәр булмаса да ярый. Анда ике урын булыр. Берсе зиратта, анам кабере янында (белүчеләр бар: Галимҗан Җиһаншин һ. б.). Икенчесе — китапханә бакчасында. Кайсын сайлау Сезнең һәм авылдашларның ихтыярында.

2. Кабер өстенә таш утыртып, чардуган корылса һәм берничә сүз яздырсагыз яхшы булыр иде.

Синең бар җиреңсөекле,
И Тулбаем — моң илем,
Бул бәхетле, бул ирекле —
Бар теләгем шул минем,—

дигән юллар бар. Ләкин күңелдәгенең барын да әйтеп бирә ала микән? Бәлки, Сез шагыйрь дусларым, үзегез матуррак сүзләр табарсыз?

3. Алып китү, китап-архивлар күчерү һәм күмү вакытында тотыла торган барлык чыгымнарны каплау өчен билгеләнгән биш мең сум акчам бар. (Касса № 15, счет № 036411.) Моны алу юллары сезгә мәгълүмдер.

4. Өйдәге бөтен кульязма архив һәм барлык китапларны (домашн. биб-ка) Тулбай китапханәсенә тапшырырсыз.

5. Барлык иҗат әсәрләремә һәм архивыма Тулбай китапханәсе юридик хуҗа (варис) булсын.

6. Гомумән, Тулбайдагы ул китапханәне сүндерми яшәтәсе иде. Шундый ерак һәм бәләкәй авылда мәдәни-әдәби бер учакның әзме-күпме якты сибеп торуы начар булмас иде кебек. Моның өчен Сез, дусларым, комиссия члennары буларак, союз белән берлектә рәсми карар чыгарып, китапханәне Литфонд карамагына тапшыру һәм анда ышанычлы кеше тоту мәсьәләсен куйсагыз, ничегрәк булыр икән?

7. Үзем исән чакта сайланма әсәрләр җыелмасын чыгара алмадым бугай инде. Ичмаса, миннән соң Сез, язылганнарның барысы эченнән җыеп, биш томлык сайланма әсәрләр чыгара алмассыз микән? (шигырьләр ике том, балалар өчен язылганнар бер том, «Муса» бер том, башка проза, публицистика бер том).

8. Болардан килгән гонорар күпмедер вакытка китапханәнең җитди материаль нигезе булып, андагы китап фондын баетырга, эшләрне киңрәк куеп, халыкка күбрәк мәгърифәт таратырга, бинасын тәзек тотарга ярдәм итәр иде шикелле. (Тыйнаксызлык булса да әйтим әле: варислык чоры унбиш ел бугай. Бу вакыт эчендә сайланмаларны ике тапкыр чыгарып та булыр иде, бәлки.)

9. Бөтен чыгымнарны каплаганнан соң саклык кенәгәсендә акча калса, ул сумманы да китапханәгә тапшыру кирәк булыр дип уйлыйм.

10. Өйдә калган башка вак-төяк нәрсәләргә, әгәр мин үлгәндә янымда тормыш иптәшем булса, ул хуҗа булыр.

11. Минем Хөршитбану исемле туган апам бар, әгәр ул исән булса, саклык кенәгәсендә акча булган сурәттә, аңа өч мең сум күләмендә ярдәм күрсәтсәгез яхшы булыр иде.

Сезне мәшәкатьләвем өчен чын күңелдән гафу үтенеп, һәркайсыгызга иҗат уңышлары, бәхет һәм куанычлар, озын гомерләр теләп, актык сәламнәремне юллап:

**Шәйхи МАННУР.**

**Казан. 12.01.70.**

Озын-озак гомерем юлымда минем бергә эшләгән иптәшләрем дә, дусларым да аз булмады. Әмма шулар арасыннан гомерләренең соңгы көннәренә кадәр җан дусларым булып калучылар өчәү генә иде. Хәсән Туфан, Хәмит Ярми (фольклор галиме Хәмит Ярмөхәммәтов) һәм шагыйрь Шәйхи Маннур. Бу аерылмас дүртлекнең дуслыгы һич үзгәрмичә, озак еллар дәвам итте. Һәр дусның туган көне һәркайсыбызның бәйрәме булып саналды. Мәсәлән, 15 гыйнвар көнне, без Ш. Маннурның өч дусты тантаналы җыелышка баргандай, киенеп-ясанып нәкъ кичке алтыда Шәйхинең Галактионов урамындагы бер бүлмәле кечкенә генә фатирына барып керәбез. Кулларда — чәчәкләр, бүләкләр. Шәйхелислам сугыштан соң ялгыз гына яшәгән иде. Ул юмартлардан саналмый, чыгымнарын бик саклык белән генә тотучы кысмыр кешеләрдән иде. Әмма без аның туган көненә килгән саен табынының муллыгына хәйран кала идек. Нинди генә затлы милли ризыклар бизәми иде аның аулак өстәлен! Ниндидер остадан махсус пешертеп алган чәк-чәк, кош теле, бавырсак, тозлы каз ите, тагын әллә ниләр! Төрле шәрапларны, җимешләрне әйткән дә юк!..



*Җан дуслар: беренче рәттә Х. Туфан, Г. Бәширов, икенче рәттә — Х. Ярми, Ш. Маннур. Казан. 1979 ел.*

Мондый милли ризыклардан күп еллар аерылып торырга мәҗбүр булган Хәсән Туфан, өстәлгә күзе төшүгә, кулларын угалап, баш чайкый, хуҗага мәдхия сүзләре яудыра башлый:

— Ну, энекәш, оста да инде син кунак сыйларга! Кара бу җәннәт нигъмәтләрен! Моның өчен сиңа үзең шикелле үк уңган, фәрештәдәй саф күңелле гүзәл зәүҗә[1] насыйп булсын!

Без, билгеле, аның сүзен куәтләп, кул чабып алабыз. Бәйрәмчә киенгән, галстук таккан хуҗа кеше, бил бөгеп, кулын күкрәгенә куя һәм, кечкенә күзләре белән елмаеп, безне түргә, табын янына өнди:

— Олы абый (Хәсән Туфан), син иң түргә, менә монда рәхим итәсең! Дәү абый (монысы мин), син аның янына! Уртанчы абзый (Хәмит Ярми), минем янга!..

Ни хикмәттер, мондый чакта кеше психикасының нинди нечкә кыллары хәрәкәткә килгәндер, әмма шундый ягымлы, чын күңелдән әйтелгән самими дәгъвәттән соң без үзебезне дуслар гына түгел, бәлки якын туганнар кебек тә хис итә башладык.

Дуслар мәҗлесе әнә шулай башланып китә дә, гадәттә, төнге уникеләргә, хәтта берләргә кадәр дәвам итә. Әмма бу кичләрнең берничә үзенчәлеге була иде. Бердән, анда гаилә әгъзаларыннан бүтән беркем дә катнашмый, гайбәт сөйләнми, зар-интизарлар телгә алынмый иде. Өстәл тулы тәмле-татлы ризыклардан, Хәсән әйткәнчә, «аз да түгел, күп тә түгел, чамасын белеп кенә» авыз иткәннән соң, җанлы әңгәмә зуррак бүлмәгә күчә иде. Билгеле, ул елларда без дүртебез дә карт чыпчыклар идек бит инде. Безне вак-төяк җим генә һич канәгатьләндермәгәндер, телгә алынган теге яки бу вакыйга, башыбыздан узган хәлләр, ишеткән-белгәннәр, күңелне дулкынландырып торган серләр безне иң-иң тирән, иң-иң сихри кичерешләргә, фикер чоңгылларына алып кереп китә иде...

... Ул кичәләрнең уздырылмый башлавына байтак еллар узды инде. Әмма мин аларны әле хәзер дә сагынып искә алам. Чөнки бу экзерсез, дусларча аңлашып утыру, һичбер регламент белән чикләнмәгән һәр әңгәмә зур залны тутырган җыелышларга, һәртөрле конференцияләргә караганда җан азыгын күбрәк бирә, һәркайсыбызның иҗатын үстерүгә ярдәм булып чыга иде.

[1] Зәүҗә — хатын

Кыскасы, бу дуслык кичәләрен «эстетика дәресләре» дип тә аңлатып булыр иде. Чөнки ул елларда без инде беребез — галим, башкаларыбыз танылган каләм осталары булганлыктан, телгә алынган һәрбер тормыш вакыйгасына әдәби яктан да бәя бирелә иде...

**Гомәр БӘШИРОВ,**
Татарстанның халык язучысы.

## Тулбай ае хәтерләтә Сине...

Минем уйны, хисне, омтылышны
Аңлар диеп уйлыйм күбегез.
Үлгәч, мине туган авылыма —
Тулбаема илтеп күмегез.
Авылдашлар сезгә ярдәм итәр:
Әнкәм яткан җирне табыгыз,
Өсләремә йомшак юрган итеп,
Туган туфрагымны ябыгыз.
Өлкәнәйгән саен чишмәләрнең
Челтерәүләре үзенә тарттылар,
Актык сулышымда юллар мине
Тагын сиңа алып кайттылар.
Гәүдәм калсын туган җиркәемдә:
Казан аңлар диеп беләм мин.
Бөтенләйгә, китмәскә, дип кайттым
Авылдашлар, сезнең белән мин...

Бу — Шәйхи ага Маннур васыятенең минем күңелемдә туган шигъри чагылышы.

1971 елның августында ул мине, Татарстан Язучылар союзы коридорында туктатты да: «Менә шуны ал әле», — дип, кулга бер конверт тоттырды. Үзе, берни дә аңлатмыйча, китеп тә барды. Конвертның тышына: «Соңгы сәгать суккач, укырсың...» — дип язылган иде. Мин моның васыять икәнен аңладым. Шәйхи аганың шифаханәдә вафат булуын ишеткәч, ачып укыдым. Бу — 1980 елның 10 июне иде. Васыятендә әйткәнчә, аны туган авылына — Мамадыш районының Тулбай авылына илтеп җирләдек. Авылдашы, дусты, «Чулпан» колхозы рәисе Галимҗан ага Җиһаншин васыятьтә әйтелгән урынны әзерләп куйган иде инде.

1980 елны Язучылар союзы идарәсе утырышында Ш. Маннурның мирас комиссиясе төзелде. Аңа Гомәр Бәширов, Хисам Камалов, Шәүкәт Галиев, Хәмит Ярми, Рәис Даутов, Лирон Хәмидуллиннар кертелде. Рәислек вазыйфасын миңа тапшырдылар. Соңыннан, секретарь буларак, Шаһинур Мостафин өстәлеп, ул эшебезне тагын да җанландырып җибәрде.

Шәйхи аганың, васыятендә язылмаса да, үзе исән чакта телдән әйткән тагын бер изге теләген үтәдек. «Чулпан» колхозы, Олыяз авыл Советы һәм Татарстан Язучылар союзы идарәсе балалар әдәбияты буенча елның иң яхшы әсәренә, яшь авторның теләсә кайсы жанрдагы күренекле әсәренә Шәйхи Маннур исемендәге бүләк бирү турында карар чыгардылар. Шулай ук бу бүләкне ел дәвамында иң югары хезмәт күрсәткечләренә ирешкән колхозчыларга да тапшыру кирәк, дип табылды. Жюри членнары итеп язучылар ягыннан Гомәр Бәширов, Илдар Юзеев (рәисе), Рашат Низамиев билгеләнде. Бу бүләкләрне һәр елны шагыйрьнең туган көнендә — 15 гыйнварьда тапшыру инде матур бер традициягә әйләнде. Бу көнне без һәр елны остазыбызның туган төбәгенә барабыз һәм искә алу кичәсе үткәрәбез. Шул кичәләрдә Ш. Маннур премиясе дипломын алган язучыларыбызның исемнәрен атап китү урынлы булыр:

**1982 ел.** Шагыйрь Зөлфәт һәм язучы Ринат Мөхәммәдиев.
**1983 ел.** Шагыйрь-рәссам Габил Сәгыйров һәм язучы Марсель Галиев.
**1985 ел.** Прозаик Нәбирә Гыйматдинова һәм тәнкыйтьче Мөдәррис Вәлиев.
**1991 ел.** Шагыйрь Рафаил Газизов һәм прозаик Зиннур Хөснияр.
**1992 ел.** Шагыйрь Газинур Моратов, язучы Рашат Низамиев, Ш. Маннур әсәрләрен русчага тәрҗемә итүче Светлана Гыйльметдинова.

**1993 ел.** Прозаик Нәзифә Кәримова, шагыйрьләр Рафис Корбан һәм Рөстәм Сүлти.

**1994 ел.** Шагыйрьләр Ләбиб Лерон һәм Рәниф Шәрипов, балалар язучысы Вәкил Ахунҗанов...

**1982—94 елларда** Ш. Маннур исемендәге олы бүләккә колхозның үзеннән дә утызлап кеше — төрле һөнәр ияләре дә лаек булды. Алар арасында атаклы авылдашының васыятьләрен тормышка ашыру өчен күп көч куйган искиткеч олы җанлы кеше — 37 ел буе «Чулпан» колхозын җитәкләгән күренекле шәхес, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Галимҗан ага Җиһаншин (ул 1994 елның 8 октябрендә вафат булды — авыр туфрагы җиңел булсын...), хуҗалыкның данлыклы тракторчысы һәм тимерчесе, хәтәр авыру нәтиҗәсендә ике аягыннан мәхрүм калса да, үзендә яшәү һәм эшләү өчен зур рухи көч тапкан үзебезнең татар Маресьевы — Габделхак ага Вилданов, Тулбай авылы китапханәсе мөдире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Васыйга Зәйнетдинова, атказанган киномеханик Юрис Мөхлисов (хәзер — Олыяз авыл Советы башкарма комитеты рәисе), танылган укытучы-рәссам Азат Һадиев (бүгенге көндә — хуҗалык рәисе урынбасары), Мамадыш районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары Риваль Гыйззәтуллин һәм башкалар бар. Биредә Р. Гыйззәтуллинга аерым тукталып үтәсем килә. Берара, кайбер матди кыенлыклар нәтиҗәсендә, Ш. Маннур исемендәге премияләрне бирү тукталып торган иде. Заманында шушы төбәктә Г. Җиһаншин белән бергә иңгә-иң торып, күп кенә җитди мәсьәләләрне уңышлы хәл иткән Риваль Гыйззәтулла улы, район хакимиятенә эшкә күчкәч, Шәйхи агага бәйле матур гадәтне яңадан тергезеп җибәрде. Аннан инде эстафетаны хуҗалыкның белемле, тынгысыз яңа җитәкчесе Фәрит Хисмәтов күтәреп алды. Теләк булгач, яхшы эшкә акчасы да табылды. Баштарак Ш. Маннур исемендәге премия өчен, шагыйрь үзе васыять иткәнчә, ул калдырган акча бүленде. Соңрак бу эшкә колхоз да кушылды. Аның да көче җитмәгәндә, спонсорлар, аерым алганда, Татарстан Җөмһүриятенең Ислам-тиҗарәт үзәге (генераль директоры — Илдар Хәмидуллин), Татарстан йон эшкәртү акционерлык җәмгыяте (президенты — Әгъмалетдин Шәрәфетдинов) зур булышлык күрсәтте. Бу җитәкчеләрнең һәр икесе дә Шәйхи ага Маннурны тирән ихтирам итә. Беренчесе — шагыйрьнең якын дусты, Мамадыш төбәгеннән чыккан атаклы җәлилче, «Муса» романындагы төп геройларның берсе саналган Фәрит ага Солтанбәковның кияве, икенчесе — тумышы белән үк Шәйхи аганың якташы, «Татарстан Республикасының атказанган җиңел промышленность хезмәткәре», гармунчыларның Фәйзулла Туишев исемендәге конкурсы дипломанты...

Инде Шәйхелислам ага васыятенә яңадан әйләнеп кайтыйк. Шагыйрь әйткәнчә, аның кабере өстенә чардуган һәм язулы ак мәрмәр таш куелды. Үз акчасына салдырган Тулбай авылы китапханәсе киңәйтелде һәм яңартылды. Хәзер ана дәүләт музее статусы бирелде. Бирегә атаклы рәссам-сынчы Бакый ага Урманченың Шәйхи агага багышланган бюсты да куелгач, музей-китапханә тагын да ямьләнеп китте.

Ш. Маннурның музей-китапханәсен оештыруда Татарстан дәүләт музее хезмәткәрләре зур фидакарьлек-өлгерлек үрнәге күрсәттеләр. Биредә аеруча өлкән фәнни хезмәткәр — музейдагы экспозицияләр авторы һәм фәнни җитәкче саналган Дания Баһаутдинованы беренчеләрдән мактап телгә аласы килә. Рәсәйнең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исемен йөртүче бу ханым 2 ел дәвамында шушы эш белән күңел яктысын, җан җылысын биреп шөгыльләнде һәм исән чакта ук Шәйхи ага Маннурга биргән нәзерен үтәде. Шагыйрьнең архивын музейга кайтару буенча да зур тырышлык күрсәтте ул.

Татарстан дәүләт музееның фәнни-методик бүлек мөдире Роза Гарифҗанова, ирле-хатынлы рәссамнардан Сергей һәм Эльвира Матвеевлар, фоторәссам Владимир Канищевларның да хезмәтләре җимешле булды...

Гомумән, васыятьтә әйтелгән теләкләрнең күбесе үтәлде. Кызганыч, безгә бәйләнмәгән сәбәпләр аркасында, Ш. Маннурның томнарын басып чыгару мөмкинлеге юк. Туксан еллык юбилеен әнә шулай буш кул белән каршыларга мәҗбүрбез инде. Алла бирсә дип, йөз еллыгына өмет багларга кала.

Иҗатта да, тормышында да кыю кеше иде Шәйхи ага. Шул елларны җәлилчеләр эзеннән Көнбатыш Германиягә баруы, тынгысызлыгы нәтиҗәсендә яңа мәгълүматлар табып кайтып, «Муса» романың язуы батырлык түгелмени?!

Үзенчәлекле прозасына да, балалар әдәбиятындагы эшчәнлегенә дә тиешенчә бәя һаман да бирелмәгән. Фәннең, тәнкыйтьнең әллә кулы, әллә көче җитми...

Шәйхи абый кебек кабатланмас олы шәхесләр, үзләре белән бергә, безгә мәңгә бүген кирәк булган асыл сыйфатларын да алып киттеләр. Дөрес, күпләр аны «бик

усал иде» дип искә алалар. Җыелышларда утырганда, әсәрләр тикшергәндә, мин нәкъ шул сыйфатын сагынам. Сикереп торыр иде дә, йөзенә карап, туп-турысын әйтер дә бирер иде. Иске академия театр бинасында балалар әдәбиятының торышы тикшерелә. Докладчы — өлкә комитетының идеология секретаре, бик кызып кына сөйләгәндә, Шәйхи Маннур сикереп торды да: «Дөрес сөйләмисең!» — дип кычкырып, сигаретлы мөштеген авызына кабып, залны ташлап чыгып ук китте. Секретаребыз каушап калды, докладын чак-чак кына очлап чыкты. Дөрес, мина да бәйләнгәләде остазым. Цхалтубода ял иткәндә, үзенә кунакка чакырып кертте. Һәм: «Нигә син ипине болай түгеп-чәчеп ашыйсың?» — дип, ачуланып алды. Ә иҗатка килгәндә, ул мине әллә ничә тапкыр урынсыз бәйләнүчеләрдән йолып алды. Минем «Фәрит-Фәридә» поэмасына ябырылганнар иде. Шәйхи ага яклады. Әнә шундый берничә яклаучың булмаганда яшь авторга үсү бик авыр булыр иде.

Иң яратмаганы — үзе эшләгән редакциядә үзенең житлекмәгән озын язмаларын бастырып утыручы кәсепчеләр иде. Башкалар әйтергә уңайсызланалар, куркалар, ә Шәйхи ага, олы трибунага чыгып, кәсепченең тетмәсен тетә. Берсен шулай, комиссия төзетеп, тикшертеп, эштән үк алып ташлатты. Сәләтле яшьләрне шунда ук күреп ала, аларга гел ярдәм итеп тора, уңышсыз әсәр чыгарса, бер генә сүз әйтә: «Халтура!»

Сагынырлык остазлар иде алар! Үземне аның васыяте алдында бурычлы санап, һәр елны Тулбайга барам...

Тагын килдем әле, Шәйхи абый,
Туган Тулбаеңа.
Төнен озак-озак карап тордым
Күккә, тын Аена.
Күнел тулгангадыр, Тулбай Ае
Хәтерләтә сине...
Синең йөзең дә бит үзе кырыс,
Үзе тулы иде.
«Ул да минем карый иде», — диеп,
Әйткән кебек ул Ай...
Без дә бер китәрбез бу Дөньядан,
Шәйхи абый, шулай.
Мәңге-мәңге күктә тын Ай йөзәр,
Агымсулар агар...
Безне сагынып һәм юксынып, кемнәр
Тулган Айга карар?..

**Илдар ЮЗЕЕВ,**
Татарстанның халык шагыйре.

## Кара болытлардан — салават күперенә чаклы...

Васыять тарихы минем өчен 1971 елның 25 августында башланды. Шул хакта кусн дәфтәренә теркәп куйганмын: «Илдар Шәйхи Маннурдан хат китереп бирде, үземне очратмагач, аңа калдырган икән. Язучылар союзы конвертын ачсам, тагын бер конверт. Таныш почерк:

«Шәүкәт дус!
Хәзергә сер булып торсын.
«Сагать суккач...»
Ачып укырсың.
Яратып: Шәйхи абыең»

Илдар Юзеевкә дә шундый ук аманәт икән. Васыятедер, дип уйладык... 11 июнь, 1980 ел. Иртән кайгылы хәбәр — кичә Шәйхи ага Маннур вафат... Васыятен ачып укыр көн килде. Машинкада басылган, дүрт кешегә адресланган. Язылган көне — 12 гыйнвар, 1970 ел.

Язучылар союзында М. Хәбибуллин үзе генә калган икән. Мәрхүм белән хушлашуны оештырып йөри. Яңа Бистәдәге зиратка тәгаенләгәннәр. Мөсагыйт

ашыга — хәл кылу өчен обкомга барасы. Көннәре дә бит 30 градус эссе... Мин васыять турында әйттем. Бүтән каләмдәшләр юк иде, исбатлау өчен тиз генә өйгә кайтып килдем. Васыятьне бирәсе килмәгән иде дә, обкомны ышандырасы бар. Мәрхүмнең соңгы ихтыяры үтәлсен — мәшәкатьле булса да, туган авылында җирләү зарур.

12 июнь, 1980 ел. Актерлар йортында Шәйхи Маннур белән хушлашу... Мин дә сүз әйттем:

— Сугыш чорын кичергән кешеләр өчен июнь — мәңгегә озату, бәхилләшүләр ае булып хәтердә калган. Июнь кердисә, күңел сискәнә. Быелгы июнь дә шулай булды — беренче көнендә үк Мирсәй ага Әмирне югалттык, инде менә Ватан сугышында катнашкан тагын бер күренекле, өлкән әдибебез белән хушлашабыз...

Шәйхи Маннур әдәбиятта туган илебезнең шигъри елъязмасын тудырышты, аның әсәрләрен дәреслекләрдән үк ятлап ничә буын балалар чын кешеләр булып үсте. Бүген моңлагән укучылар яраткан язучыны моңаешып соңгы юлга озаталар... Ул иҗат иткән Гайҗан бабай исән, Гайҗан бабай сөйли — Гайҗан бабайлар булып халык күңелендә шагыйрь Шәйхи Маннур рухы, иҗаты бик-бик озак яшәр...

...Мәрхүмне Мамадыш районының Тулбай авылына — туган авылына озата киттек. Машиналар кузгалганда яман каралып болыт килде, тополь мамыклары кар сыман очты... Мамадыш юлының яңа салына торган урыннары күп — читләп үтү өчен шактый урап чыгарга туры килде. Алты сәгать бардык.

Шагыйрь үзе салдырган китапханә алдында кызыл комач япкан өстәл, авылдашлары, укучы балалар җыелган. Гомәр ага Бәширов митингны ачты. Илдар Юзеев, Рәис Даутов, Фәннур Сафин да сүз әйттеләр. Яңгыр сибәләп торды. «Шәйхелислам яңгыр алып кайтты... — диде кордашлары, — игеннәрне коткарыр бу явым». Илдар, миңа ымлап, хикмәтле фал дигәндәй, салават күперен күрсәтте. Кызарып баеган кояшка карап, зират ягына киттек. Оркестр уйный, тирә-якта яшел уҗым, күктә якты болытлар. Матәм гамәлләре шомлы булмады, якташлары мәхәббәте өстен чыкты. Казандагы караңгы болытлардан соң салават күпере балку илаһи ишарә сыман иде — шагыйрь тормышында болытлар аз булмады, әмма шигърияте халык күңелендә балкып калды.

Авылдашларына карыйм. Шушы кешеләр — минем дә халкым, мин хезмәт итә торган, гомеремне, хыял-өметләр, иҗатымны багышлаган халкым бит, дип, кинәт үзәк өзгеч якынлык тоеп алдым. Таныш булмаган кешеләр шулхәтле кадерле икән, югалтырга туры килсә, һәркайсын шагыйребез сыман бәгыреңнән өзеп алу булыр иде... Кайгыдан күңел нечкәреп шушы хакта уйландым.

16 июнь, 1980 ел. Кич белән Шәйхи абыйның Галактионов урамындагы бер бүлмәле фатирында искә алу — җидесе. Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Хәмит Ярми, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Рәис Даутов килдек. Хәсән абый «Агыла да болыт агыла» шигырен укыды. Моңаеп, сүзсез генә утыра.

> ...Яланаяк килдем дөньяга,
> Шулай гына, бәлки, китәрмен...
>
> .......................................................
>
> Зират бит ул сабантуй түгел,
> Нигә анда киенеп китәргә?

Гомәр абый «мальчишник» дип, дүртәүләп туган көннәргә җыелуларын искә төшерә. Шәйхи абыйның нәкъ еллыгы көнендә Хәсән абый да дөнья куяр дип кем уйлаган?.. Килер елның көзе дүрт дусның тагын берсе — Хәмит ага өчен дә соңгысы буласы икән. Агыла да болыт агыла...

...Мин монда шагыйрь васыятенең бер шарты — бакый йорты туган авылында булсын, дигән өлешен үтәү турында гына яздым.

Васыятьнең миңа адресланган нөсхәсе кире кайтмады... М. Хәбибуллин ничә эзләп тә, обкомда калгандыр дип, очына чыга алмады. Бик тә үкенеч, әмма күрсәтмәсәм, ул васыятьне үтәп тә булмый иде. Журналыбызга рәхмәт, ташка басып калдыру — саклауның иң ышанычлысы.

**Шәүкәт ГАЛИЕВ,**
Г.-Х. Андерсен исемендәге
Халыкара бүләк лауреаты.

Шәйхи Маннур барча гомерен әдәбиятка гына биргән кеше иде. Шуңа аның шәхси тормышы булмады диярлек. Әдәбиятка хезмәт итүне үз мәнфәгатьләреннән өстен йөртте. Бүтәннәр дә әдәбиятны кайгырталар, әмма үзләрен һич онытмыйлар иде. Шәйхи Маннур үзен онытып, тормыш рәхәтлекләреннән ваз кичеп эшләде...

Ватан сугышын исән-имин узып, һаваланып яшәп ятканда кинәт Шәйхи абый аяк астында җир тетрәп куя, язмыш зигзаг ясый. Сәбәбе «Тартай арбасы» дигән гөнаһсыз бер шигырь икән. Чын суд башлана... Татар бер-берсен чакмый гына яши белми. Сүз җае туры китереп, сорый идем: «Сезне кем сатты, дошманыгыз бар идеме? — дип.— Сезгә хөкем карары укыган теге шагыйрь түгелме?».. «Юк, аңа кушканнардыр»,— ди иде ул һәм сатылуның сәбәпләрен аңлатырга тотына: «Татарның барча гомере, тормышы, көнкүреше кеше кулында. Ул ничә гасырлар хезмәтче булып, җан асрап килгән. Ә хезмәтченең психологиясе — башлыкларга ялагайлану, ярарга тырышу...»

Гомерен, талантын сарыф итеп, Шәйхи Маннур «Муса» романын язды. Татар әдәбиятында катлаулы язмышларны тасвирлаган героик әсәр. Ләкин бу көчле әсәрне күтәреп алмадылар. Әле басылганчы ук эшчән авторны тирән борчуга салды. Театр янында уздырыла торган шигырь бәйрәменә сирәк кенә килеп чыга иде ул. Тукай бүләге лауреатларын котлап алкышлар яңгырый, шигырь тезмәләре һаваны тыгызлый. Шәйхи абый бер читтән, агачлар ышыгыннан гына карап тора. Бераздан мөштеген чыгарып, аңа папирос куя һәм ут элдерә. Аннары, канатлары салынган кыяфәттә, алга таба бөкрәя төшеп, Ленин бакчасына таба юнәлә. Чал башын игән, бер җыерчыксыз йөзенә моңсулык коелган төстә, үпкәләгәндәй, дөньядан да китеп барды ул...

Ә инде васыятьтә аның иң якын күргән дусларының берсе буларак телгә алынуыма килгәндә, шуны әйтергә була: ул миңа, фронтны үткән кеше буларак, хәерхаһ карый иде, китапларының редакторы вазифасын үтәвем сәбәпле, күңелендә ышаныч төене төйнәлгәндер. Аның белән фикерләребез дә килешә иде...

**Хисам КАМАЛОВ,**
Татарстан Республикасының
Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

*Зөфәр БӘШИРОВ фотолары*

Китап күзәтү

# ШӘРКЫЙ РУХЫБЫЗ ТАМЫРЛАРЫ

Иҗтимагый фикер үсеше һәм шул исәптән әдәбият тарихына мөнәсәбәтле карашлар да әкренләп үзләренең табигый эзенә, юнәлешенә төшә бара. Табигый юнәлеш дип нәрсәне әйтергә телим? Әлбәттә, галимнәрнең тарихи дөреслеккә тугры булып фикер йөртүләре турында сүз бара. Фикер ияләрен кысып торган идеологик тышауларның шактые чишелү бүген фән даирәсендә хезмәт итүчеләр эшчәнлегенә шифалы сулыш өрде. Яңа шартларда һәм ихлас язылган фәнни хезмәтләрне уку, авторларның фикер агышын күзәтү гаҗәеп кызыклы. Казан университеты профессоры Х. Миңнегуловның «Татар әдәбияты һәм Шәрык классикасы» (КДУ, 1993) дигән исемдә рус телендә чыккан монографиясе белән танышу миндә тирән канәгатьлек калдырды. Бары тик бер мең данә генә басылган бу олы хезмәт шунда ук сирәк китаплар исемлегенә керде. Чынлап уйлап карaганда, ул бүген фән әһелләре, зыялылар, укытучылар, студентларның һәммәсенең кулында булырга тиешле. Аны укыгач, бүгенге кешенең ерак һәм якын үткәннәребезгә карашы ачыклана, укучы үзен борчыган байтак сорауларга җавап таба. Димәк, әлеге хезмәт әдәбият тарихын өйрәнү җәһәтеннән генә түгел, бу эшне алып баруда кайбер методологик фикерләре белән кызыклы. Хезмәткә кереш сүз язган профессор М. Госманов та бу мәсьәләләрдә кулланма булырдай нигезле уйланулары белән уртаклаша.

Х. Миңнегуловны, галим буларак, байтак еллардан бирле күзәтеп киләбез. Г. Таһирҗанов, Ә. Нәҗип, Х. Госман, Ш. Абилов, Н. Хисамов, Ә. Шәрипов, К. Дәүләтшин, М. Әхмәтҗанов, Н. Исмәгыйлов, Җ. Зәйнуллин һәм башка фән әһелләребез белән бергә урта гасырлар татар әдәбиятын бөртекләп өйрәнеп килүчеләребезнең берсе буларак, аның хезмәтләренә хөрмәт белән карыйбыз. Котб, Сәйф Сараи кебек борынгы шагыйрьләребез иҗатларына багышланган монографияләре ярдәмендә ничә буын студентлар үзләренең белем хәзинәләрен арттыралар. Әлеге хезмәт фәнни тикшеренүләр алып бару өчен кемнәргә генә таяныч булмады? «Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. Поэтика һәм әдәби бәйләнеш мәсьәләләре» исемле китабы (КДУ, 1988) шулай ук әдәбият фәнендә җегәрле яңа сүз булды. КДУ доценты Ш. Садретдинов белән берлектә әзерләп бастырган «XIX йөз татар әдәбият ядкярләре» (КДУ, 1982), «XIX йөз татар хрестоматияләре» (КДУ, 1982) китаплары шулай ук күптән көтелгән хезмәтләр иде. М. Гайнетдинов бу соңгысының «мәйданга чыгуы, андагы олы казанышлар халкыбызның культура тормышында нәтиҗәле һәм күренекле факт булып калачак» дип бәяләгән иде («Казан утлары», 1985, № 2). Шулар өстенә, вакытлы матбугатта дөнья күргән күпсанлы фәнни мәкаләләрне исәпкә алсаң, әлбәттә, бу галимебездән әдәбият белеменең әлеге өлкәләре хакында җыеп әйтелгән бер җитди сүзне көтү табигый иде. Менә ни өчен сүз бара торган монографияне галим-голәмә зур кызыксыну белән кулына алды.

Биредә Х. Миңнегуловка гына түгел, гомумән, татар әдәбиятының борынгы чорларын өйрәнүчеләрнең уртак тырышлыкларына рәхмәт әйтеп, зур бәя биреп китәсе килә. Галимнәребезнең аерым-аерым хезмәтләрендәме, әллә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан әзерләнгән «Борынгы татар әдәбияты» (1963), «Татар әдәбияты тарихы» (1984, 1 том) кебек фәнни тупланмалардамы — аларда халкыбызның үткән олы һәм катлаулы юлы шактый тулы яктыртылды. 1944 ел, 9 августтагы мәгълүм карардан соң татар халкы тарихын дөрес итеп өйрәнү тыелгач, бу карар шаукымы яшәп килгән унъеллыкларда да әдәбият галимнәре үткәннәребезне мөмкин кадәр яктырта килделәр. Университетта һәм пединститутларда борынгы татар әдәбияты курсын тыңлаган студентлар татар

халкы тарихыннан да мәгълүматлы булып чыктылар.

Әйе, халык язмышы һәм аның әдәбияты бер-береннән аерылгысыз. Әдәбият бай булсын өчен халык тормышы да бай булырга тиеш, дип әйтүче Х. Миңнегулов хаклы. Шәрык халыклары арасында борынгы дәверләр татар әдәбияты үзәк урыннарның берсен алып торган икән, димәк, аның ул вакытлардагы чынбарлыгы да шуңа бәрабәр булган. Менә ни өчен Х. Миңнегулов хезмәтенең беренче бүлеге «Татарлар һәм Шәрык» дип атала да. Татарларның Шәрык дөньясындагы урынын билгеләмичә торып, аның әдәбияты турында фәнни сүз алып барып булмый. Хәзергә татарларның элгәрләрен болгар белән генә чикләргә азаплану, аларның тормыш мәйданын АССР кысалары белән киртәләү фәнни караш була алмый. Дөрес, бу мәсьәләләр хакында соңгы елларда байтак хезмәтләр пәйда булды, бәхәсләр куерды. Әмма Х. Миңнегулов нәтиҗәләре алар янында үзенең төзеклеге, гаять күп чыганакларга нигезләнүе белән игътибарны җәлеп итә. Минем уемча, бу бүлек аерым фәнни кыйммәткә ия, аны күп тираж белән татар һәм рус телләрендә бастырып тарату лязем.

Әлбәттә, хезмәттә куелган төп бурыч — ул да булса урта гасырлар татар әдәбиятын Шәрык классикасы белән үзара бәйләнештә карау. Автор моның тарихи алшартларын, әлеге мөнәсәбәтләрнең кануни якларының һәм вакытка бәйләнешле үзенчәлекләренең асылын барлауны максат итә. Бу мәсьәләләр 1917 елгы борылышка кадәр Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинев, М. Бигиев, Ф. Кәрими, егерменче елларда Г. Рәхим, Г. Газиз, Җ. Вәлиди һәм башкалар тарафыннан мәгълүм дәрәҗәдә өйрәнелгән иде. Ләкин, дөресен әйткәндә, инде ул хезмәтләр үзләре шактый ерак тарих булып калды. Х. Миңнегулов бу мөхтәбәр галимнәребез һәм башка бик бай чыганакларга таяна. Егерменче гасырның бөек галиме Л. Н. Гумилев карашларына игътибарлы булуы да аңа моңача бәхәсле булган күп кенә мәсьәләләрне дөрес чишәргә ярдәм итә.

Хезмәттән килеп чыга торган кызыклы фикер сөземтәләренең берсе шул: илләр белән илләр, милләт белән милләтләр үзара мөнәсәбәтләрдә ирекле булырга тиеш. Моны икенче төрле итеп, аралашуга булган табигый ихтыяҗ дип атарга кирәк. Фарсы, гарәп, төрки халыклар һәм аларның әдәбиятлары белән нык керешеп яшәгәнбез икән, бу берничнди көчләүсез булган. Мәҗбүр итү исә беркайчан да ихлас аралашуга китерми. Күреп торабыз, Чыңгыз хан һәм аның варислары болгар, кыпчак, хазарларны янача яшәргә мәҗбүр итә алмаганнар. Киресенчә, үзләре биредә төрки телне үзләштерергә һәм ислам динен кабул итәргә мәҗбүр булганнар. Татарларның (болгар, кыпчак, хазар һәм башка компонентлары) Шәрыкка (болай Көнчыгыш түгел, бәлки ислам Көнчыгышы күздә тотыла) тартылуы аларның эчке омтылышларыннан килеп чыга. Дин берлеге (хазарлар 737, болгарлар 922 елда рәсми төстә исламны кабул иткәннәр), язу берлеге, яшәү рәвеше («Коръән» таләпләре буенча яшәү, һичшиксез, тормыш-көнкүрештә дә бер-беренә якынайта), сәүдә итешү, хаҗ кылу вакытларында нык аралашу һәм башка сәбәпләр безнең борынгы ата-бабаларыбызны, әниәбиләребезне үзара тансык иттергән. Ә 1552 елдагы канлы фаҗигаләр һәм шуның нәтиҗәсендә халкыбызның рус дәүләте эчендә яшәргә мәҗбүр булуы — гайре табигый хәл. 1917 елдан соңгы рәсми идеология безгә Шәрык ягына арт белән борылырга кушып килде. Алай гына да түгел, Алтын Урда чорының бөек халык әсәрен — үз иҗат җимешебез «Идегәй» дастанын уңай яктан телгә алу да рөхсәт ителмәде. Димәк, табигый булмаган юл күрсәтелде. Табигый булмаган әйбер — ялганнан гайре нәрсә була алмый. Х. Миңнегулов хезмәте безнең сүз сәнгате тарихын чын асылына кайтаруда ышанычлы адым булып кабул ителә.

Аңлашыла ки, автор мәсьәләне шактый киң итеп, ягъни татар әдәбиятының Шәрык классик әдәбияты белән бәйләнеше рәвешендә күтәрсә дә (дөрес, беренче бүлектә һәм йомгаклау өлешендә сүз, чыннан да, шулай колачлы бара), яхшы аңлый: бу — бер хезмәттә генә хәл ителә торган бурыч түгел. Шуңа күрә аерым бүлекләрнең төгәл итеп «Низами һәм Котб», «Гөлстан бит-төрки», «Башка авторлар турында», «Әл-Мәгарри һәм татар әдәбияты» дип аталулары һәм галимнең шушы беренче караштa «тар» мәсьәләләргә игътибар туплавы яхшы аңлашыла. «Тар» сүзен куштырнаклар эченә алу белән әйтергә теләгәнем шул: беренчедән, болар үзләре гаять зур мәүзуг һәм тикшерү өлкәләре, икенчедән, аларның һәрберсен аерым-аерым өйрәнү өчен киң һәм тирән гыйльми нигезгә таянып торырга кирәк. Нәкъ менә шундый нык җирлек Х. Миңнегуловка әтрафлы итеп фикер йөртергә һәм ышанычлы сөземтәләргә килергә ярдәм итә. Мина калса, Шәрыкның Сәгъди, Низами, Әбүл-Галя әл-

Мәгарри кебек бөек шагыйрьләренең татар әдәбиятына ясаган тәэсире аеруча эзлекле һәм җентекле яктыртылган. Шул ук вакытта төрки әдәбиятларның үзара йогынты ясашулары хакында кызыклы гына күзәтүләр бар. Әлбәттә, татар әдәбиятының үз чиратында Шәрыкка билгеле күләмдә унай тәэсир итүе кебек өлкәсе дә тикшеренүне сорап тора. Алтын Урдадан Мисырга киткән мәмлүкләрнең бу ил тарихында никадәр тирән эз калдырулары хакында хезмәттә шактый тәфсилле сүз алып барыла. Бу турыда тикшерергә алынучыларга уйланырлык нәрсәләр бирелә шактый гына. Борынгы дәвер татар әдәбиятын өйрәнүчеләргә Х. Миңнегулов үзе үк кайбер мәүзугларны атый. Ул тәкъдим иткән «Ф. Гаттар һәм татар әдәбияты», «Әл-Мәгарри һәм татар әдәбияты (һәм иҗтимагый фикере)» кебек мәүзугларны фәнни өйрәнү генә дә никадәр яңа ачышларга китерер иде.

Х. Миңнегуловның әлеге хезмәттә тарихи дөреслеккә тугры булуы әйтелгән иде инде. Шәрык илләре тарихы һәм алар белән мөнәсәбәтләргә бәйләнешле хакыйкатьне әйтү бер нәрсә, ә менә XIX гасыр Рәсәй идарәчеләренең татар халкына карата алып барган сәясәтенең асылын ачу бары тик 1985 елдан соң гына мөмкин булды. Оренбургтагы Неплюев уку йорты турындагы бүлек укучыларда аеруча кызыксыну уята. Татар әдәбиятыннан хрестоматияләр төзегән М. Иванов, С. Кукляшев, М. Бикчурин исемнәре һәм аларның игелекле эшчәнлекләре автор тарафыннан зурлап бәян ителә.

Дөрес, китапта сирәк булса да, кайбер кытыршылыкларга да юлыгасың. Мисал өчен, «Татар ханлыклары Россиягә кушылды» дигән җөмлә (72 бит) элеккеге язмаларны хәтерләтә. Ә менә бу тәгъбир мине тәгәлсезлеге белән җәлеп итте: «Кол Гали Фирдәүсигә нисбәт ителгән фарсы поэмасы «Йосыф вә Зөләйха»га еш кына мөрәҗәгать итә» (97 бит). Ни өчен «Фирдәүсигә нисбәт ителгән» генә? Әлеге әсәрнең Фирдәүсинеке булуына шикләнерлек бирәр чыганак бармы әллә? Шундыйрак фикер тагын да очрый. Мәсәлән, С. Сараиның тормыш юлы турында сүз барганда «С. Сараи Мисырда солтанның кятибе булган» дигән фикер кистереп әйтелә дә (65 бит), бераздан соң (131 биттә) «күрәсең, «кятиб» булып эшләгән» диелә.

Котбнең «Хөсрәү вә Ширин» әсәренең жанры турында да бер фикергә киләсе иде. Ә. Нәҗип аны 1966 елда «шигъри роман» дип атаган иде. Х. Миңнегулов үзе дә «Котб иҗаты» исемле хезмәтендә (1976 ел) шушы фикерне яклаган иде (69 бит). Ә менә сүз бара торган хезмәттә (116) ул аны поэма дип әйтә. Дөрес, 127 биттә моннан унсигез ел әйткәннәрен тагын кабатлап куя. Рифкать Әхмәтҗанов та әсәрне роман дип атый (Мирас, 1992, № 5, 31 бит). Әлбәттә, бу Х. Миңнегулов колагына гына әйтелгән сүз түгел. Урта гасырлар әдәбиятыбыз хакында сүз алып барганда әле ачыклыйсы, уртак фикергә киләсе нәрсәләрнең иге-чиге юк.

...Шәрык һәм татар әдәбиятлары бу халыклар арасында элек тә игелекле күпер булган, хәзер дә шулай. Киләчәктә дә шулай булса иде. Күренекле шагыйребез Нури ага Арслан әйткәндәй:

> Шушы күпер миңа хәзер дә ипле,—
> Шушы мәктәп мине зур юлга илтте.

Шагыйрь әйткән зур, әхлаклы юлга изге Коръәнебез, халыкларыбызны якты күңелле итеп тәрбияләүче әдәбият хәзинәләребез тәэсирендә генә баса алабыз. Галим Х. Миңнегулов та укучыны шуларга инандыра.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
филология фәннәре кандидаты.

# ФИКРИ ЮЛ

ЯХЬЯ АБДУЛЛИН — ФӘЛСӘФӘ ТАРИХЧЫСЫ



Мәшһүр философ Һегель: «Иң асыл нәрсә — юл...» — дип язып калдырган. Юл, тормыш юлы, кеше узган рухи эзләнүләр сызыгында шәхеснең үз йөзен иҗат итүе никадәр хәерле, бәрәкәтле булса, аның ирешкән уңышы да шулкадәр мәртәбәлерәк була.

Аның тормыш юлы Теләче төбәгендәге Олы Кибәхуҗа авылыннан башлана. Авылда, крестьян гаиләсендә туып үскән Яхъяның беренче хезмәт адымнары да 1936 елда Теләче район газетасы редакциясендә ясала. Бераз соңрак — Алабуга политмәгариф мәктәбе студенты, Брянскида урнашкан хәрби-сәяси училище курсанты. Икенче бөтендөнья сугышы кеше язмышларын шаулы диңгездәге йомычка кебек бөтереп йөрткән заман була бу. Яхъя Абдуллин Сталинград фронтының 62-армиясе составында сугыша, яраланып госпитальгә эләгә. Савыгып та житмәстән, ул тагын — бу юлы Ленинград блокадасын өзү өчен кораллы бәрелешләрдә, Балтыйк буе, Польшаны алу өчен һәм, ниһаять, Берлинны штурмлау һөҗүмнәрендә катнаша. Аның күкрәгендәге «I дәрәжә Ватан сугышы» һәм ике «Кызыл Йолдыз» ордены — шул сугыш гарасатларда кыюлык күрсәтү истәлеге. Шулай итеп, 25 яшендәге егет, сугыш җәһәннәменең газаплы юлларында кырыс тәҗрибә туплап, туган җиренә кайта.

Сугыштан соңгы 1945—1959 елларда Я. Абдуллин КПССның райком, аннары Казан шәһәр комитеты секретаре вазифасын башкара, район һәм шәһәр советына депутат итеп тә сайлана. Шул ук вакытта Казан юридик институтында һәм Ижтимагый фәннәр академиясенең (Мәскәү) аспирантурасында югары белем ала. 1957 елда «Каутскийның дәүләт теориясен тәнкыйтьләү» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Моңа кадәрге чорда булачак фән эшлеклесе әле тулысы белән диярлек язмыш сукмагыннан бара. Шуның белән бергә әкренләп үз хезмәтенең асылына төшенүгә табан юнәлеш тота.

Тормыш исә Я. Абдуллинны үз урыны хакында эзләнүләр сукмагына илтеп ташлый. 1959 елдан ул Казан ветеринария институтында фәлсәфә укытуга күчә, доцент дәрәҗәсен ала. Монда да укыткан фәннең үзе омтылган хезмәткә ераклыгын тоерган саен ачыграк тоя ул. Бу уйлар аны соңга калыбрак булса да көчен-сәләтен халкыбызның тарихын, мәдәниятен өйрәнүгә багышларга кирәк, дигән фикергә этәрә. Бу җәһәттән 1965 ел борылыш елына әверелә. Шул рәвешчә, 45 яшьлек галим ныклап татар иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүгә керешә. Үзе эшләгән фәнни өлкәдә максатларны билгеләүдә шикләнү-борчылулар, төрле каршылык-кыенлыклар белән очрашса да, уңышсыз адымнарга юлыкса да, төп фәнни һәм мәгънәви юнәлештән тайпылу булмаганын бөтен күңеле белән тоеп эш итә ул.

Шул вакыттан бирле Я. Абдуллин күпкырлы һәм күләмле фәнни һәм оештыру эшләрен башкара. 1971 елда Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына өлкән фәнни хезмәткәр булып эшкә килүе аның кыйбласын

билгеләүдә төп этәргеч була. Монда килүенең төп сәбәбе дә күптән күңелендә ныгыган нияте — татар фәлсәфи фикере тарихының өйрәнелмәгән, хәтта тыелган сәхифәләреннән XIX йөз фикер ияләренең, беренче чиратта, бөек Ш. Мәрҗанинең фәлсәфи мирасын халкыбызга ачып салу иде. Бу катлаулы фәнни мәсьәләне чишү барышында татар халкының рухи тарихын борынгы гасырлардан башлап фәлсәфи күзлектән үзләштерү зарурлыгы ныгый бара. Шул максатта галим әкренләп үз тирәсенә бер фәнни төркем туплый башлый.

1975 елда Я. Абдуллинның турыдан-туры тырышлыгы белән, элеккеге автономияле республикаларда беренче буларак, милли иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү бүлегенә нигез салына. Шул чорда галимнең татар мәгърифәтчелек фикере тарихы буенча гыйльми эзләнүләре докторлык диссертациясен уңышлы яклап чыгарга мөмкинлек бирә. 1981—1982 елларда Я. Абдуллин институтта директор урынбасары, 1982—1986 елларда директор вазифаларын үти, зур фәнни коллективның татар мәдәнияте һәм тарихын өйрәнү эше белән җитәкчелек итә. Нәкъ шушы елларда аның оештыру эшчәнлеге нәтиҗәсендә институт галимнәре алдында татар халкының тарихын, рухи мирасын өйрәнүдә ясалма административ-мәйданый кысалардан чыгып, милли-тарихи киңлектә һәм бербөтенлектә өйрәнү буенча беренче адымнар ясала. Моның өчен татар халкының тарихын язу буенча тәҗрибәле галимнәрдән махсус иҗади төркем төзелә.

Я. Абдуллин татар фәлсәфи һәм иҗтимагый фикер тарихын тикшерүгә баштан ук яңалык алып килә. Бу аның беренче зур хезмәте булган «Татар мәгърифәтчелек фикере» (1976) дигән күләмле монографиясендә аермачык күренә. Автор XVIII—XIX йөз мәгърифәтчеләре Г. Утыз-Имәни, Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, И. Хәлфин, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Ш. Күлтәси һ. б. идея-фәлсәфи мирасын халкыбыз үткән рухи үсешнең аерылмас кисәге буларак күз алдына китереп бастыра. Галим: «Мәгърифәтчелек хәрәкәтенең тәгаенләнүе (формалашуы) милләт булып оешу барышы белән бергә туры килә»[1],— дип саный.

Дөрес, татар мәгърифәтчелегенең кайбер мәсьәләләре, аеруча әдәбият-мәдәният өлкәсенә караганнары, инде моңа кадәр дә тикшерелеп килә. Ул хезмәтләрдә төп методологик принцип итеп вульгар-социологик күзлектән кичерелгән сыйнфый бәяләмә бирү алына иде. Я. Абдуллинның әлеге хезмәтендә исә мәгърифәтчелек хәрәкәте бербөтен социаль-фәлсәфи күренеш төсендә тасвирлана. М. Акъегетзадә, Ф. Халиди, З. Бигиев кебек әдипләрнең иҗаты да шул идея яссылыгын тулыландыруы ягыннан игътибарга алына. Шуның белән ул күренекле фикер ияләребезнең карашларына сыйнфый-пролетар бәя бирү чикләнгәнлек, берьяклы анализ булуын белдерә. Галим татар мәгърифәтчелегенең идея мирасын алгы сафка чыгара, аның мөстәкыйль үзкыйммәте булуын күрсәтүгә ирешә. Гасырлар буена халыкның сыену урыны вазифасын үтәп килгән ислам динен заман таләпләреннән чыгып күзаллау, аңа яңа төсмер бирү, мөселман фәлсәфәсе төшенчәләре нигезендә үзенчәлекле фикри система барлыкка китерүнең милләтне яңарышка илтү юлында этәргеч булуын ачып сала. Бу яктан аның хезмәтләрендә Ш. Мәрҗани кебек күренекле философ, дин галиме һәм тарихчыбызның фикри байлыгын халкыбызга кайтарып бирүне дәлилләү аеруча игътибарга лаек эш иде. Күп кенә фикер ияләренең иҗтимагый-фәлсәфи карашларын өйрәнүгә яңалык алып килү белән бергә, тикшеренүченең каләме белән Ш. Күлтәси кебек эшлекләребезнең иҗаты беренче тапкыр фәнни тасвирлауга алынды.

«Татар мәгърифәтчелек фикере»ндә үк инде Я. Абдуллин үзенең төп фәнни принципларыннан берсен кулланып, идея мирасын халкыбызның тарихи яшәеше, тормыш итү рәвеше, милли мәдәнияте белән бәйлелеген отышлы фактик материал нигезендә күрсәтә алды.«Татар мәгърифәтчеләренең үз халкының мәдәни мирасын яклавы һәм пропагандалавы,— дип яза автор,— аның милли мәнфәгатьләрен кайгыртуы ачыклана»[2]. Бу уңайдан АКШта чыга торган «Slavie Review» журналы хезмәтнең әчтәлеген «этник үзенчәлекне яклау өчен язылган»[3], дип бәяләде. Ул гына түгел, хәтта шул замандагы сыйнфый-материалистик фәлсәфә тарафдарларының югары интеллектуаль даирәсендә дә китап «авторы тарафыннан мәгърифәтчелек идеологиясенең милли үзаң уянуындагы роле тулы ачылган»[4], дип танырга мәҗбүр булдылар.

Монда монографиянең иҗтимагый торгынлык һәм идеологик басымчылыкның чәчәк аткан заманында, татарлар арасында фәлсәфи фикернең булу мөмкинлеге һәм аның кирәк булуын күпләр күз алдына да китерә алмаган бер вакытта басылып чыгуын искәртү әһәмиятле. Шуңа күрә ул башка кайбер яңалыкны яклаучы басмалар рәтендә хаким пролетар идеологиягә мөкиббән киткән күп зыялыларга һәм иҗтимагый даирәгә, әдип Г. Ибраһимов сүзләрен кулланып әйткәндә, «көтелмәгән бер кисәтү, бер хезмәт булды». Әлбәттә, яшәп килгән

тоталитар система кысаларында Я. Абдуллинга да өстенлекле марксизм-ленинизм идеологиясен читләтеп узарга яки ана каршы чыгарга мөмкин түгел иде. Киресенчә, бу дәвердә тикшерелүчеләрнең коммунистик схоластикага теге яки бу мөнәсәбәте аларның рухи кыйбласын билгеләүдә күрсәткеч булып санала ала. Берәүләр татар милләтенең үзкыйммәткә ия яшәеше һәм рухи тарихы булуын бөтенләй онытканда, икенчеләре фәлсәфи мирасыбызның аерым өлешләрен кыек көзгедә чагылдырыр, иҗтимагый фикер тарихын большевистик идеологиягә терәк рәвешендә кулланса, «Татар мәгърифәтчелек фикере»ндә исә без коммунизмга карата мәгънәви яктан житлеккән либераль бер мөнәсәбәт күрәбез. Авторның империя-дәүләт идеологиясе «казанышларыннан» читкә тайпылуын искәртеп «Problems of Communism» (Вашингтон) басмасы: «Публикация СССР милләтләренең тарихын объектив өйрәнү тенденциясе дәвам итүгә өметләндерә»[5],— дип белдерде. Мондый караш кайбер очракларда схоластиканың үзен милли җирлек өчен «эшләтергә» кушуга кадәр барып житә иде.

Бу җәһәттән Я. Абдуллинның күп заманнардан бирле каралтылып киленгән җәдитчелек хәрәкәтен яклап чыгуы нәкъ шушы юнәлештә барганын искәртергә кирәк. Автор аның «Җәдитчелек, аның социаль табигате һәм эволюциясе» (1979) дигән күләмле мәкаләсе үзенә күрә житди фәнни кыюлык үрнәге дә. Аерым бер тикшеренүчеләр тарафыннан җәдитчеләрне «реабилитацияләү» максатында аларның прогрессив, пролетариат эшенә этәргеч бирердәй ан-белем таратуларын калкуландырулар инде булган хәл иде (бу яктан И. Нуруллин һ. б. тырышлыгы аерым игътибарга лаек). Ләкин бу очракта галимнең җәдитчелекне «панисламчылыгыннан», «пантөркичелегеннән» сакларга, пролетар-сыйнфый, империячел дәүләт идеологиясе калыпларыннан гына чыгып бәяләргә теләмичә, аны бербөтен идеологик агым итеп күрсәтергә алынуы яңалык иде. «Аерым алганда,— дип яза автор,— җәдитчелек, панисламчылык кебек үк, милли изүгә каршы протест һәм гасырлардан килгән артталыкны бетерүгә омтылышны гәүдәләндерде»[6]. Берьяклы карашлы галимнәр үз вакытында ук әлеге мәкаләнең үзенчәлеген нәкъ шул яссылыкта билгеләп үттеләр дә[7]. Дөрес, монда да галимнең җәдитчелекне объектив бәяләүгә омтылышы үз чорына хас рәвештә шактый каршылыклы кала бирә, аның 1905 ел инкыйлабыннан соңгы чордагы урынына караштa чикләнгәнлек тә юк түгел. Хезмәтнең әһәмиятен үзебездә киңрәк фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан аңлау шулай да бераз соңрак кына мөмкин булды. 70-елларда җәдитчелек хакында дөреслекне әйтеп бирү җәһәтеннән «Звезда Востока» (Ташкент) журналының: «Татар философы Я. Г. Абдуллинның «Җәдитчелек, аның социаль табигате һәм эволюциясе» дигән хезмәтен аерым билгеләп үтәргә кирәк»[8], дип язуы юкка гына түгел. Мондый фикри казаныш элеккеге Русиянең төрки халыклары тарихында тирән эз калдырган җәдитчелек идеологиясен Урта Азиядә һ. б. тарафларда да объектив бәяләүгә зур этәргеч бирде.

Шулай итеп, 70—80 елларда татар иҗтимагый фикере тарихын өйрәнүдәге яңа методологик карашларның өлгерүендә Я. Абдуллинның роле зур булды. Милли фикер тарихын системалы тасвирлау, аны бөтен тарихи үсешендә күрсәтүгә омтылыш әлеге хәрәкәтнең бер ягы итеп танылырга хаклы. Бу мөнәсәбәттә галимнең күпьеллык фәнни күзәтүләре нигезендә язылган «Мәгърифәт нуры ачар...» (1987) исемле китабы халкыбызның рухи тарихын киң колачлавы белән аерылып тора. Әмма бездә татар фәлсәфи һәм иҗтимагый фикер тарихын тулысы белән яктырткан хезмәт һаман язылганы юк. Һәм бу эшне Я. Абдуллин тарафыннан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында оештырылган иҗтимагый фикер тарихын һәм исламны өйрәнү бүлеге максат итеп куя. Әлеге зур проблеманы чишүгә ул башлангыч биреп кенә калмыйча, остаз буларак, үзенең шәкертләрен дә бу эшкә юнәлтергә тырыша. Аның җитәкчелегендә бу өлкәдә фәнни мәктәп барлыкка килде: М. Йосыпов, Ф. Солтанов, Р. Әмирханов, Р. Мөхәммәтшин, Т. Камалов һ. б. бу яңа методологик юнәлештә нәтиҗәле эшләп киләләр. 1985 елдан соңгы чорда татар иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүнең тирәнәюе һәм киңәюе дә 70—80 елларда ук мәгърифәтчелек, җәдитчелек һ. б. милли фикер тарихы проблемалары, шулай ук ислам диненең татарлар арасында тоткан урыны кебек мәсьәләләрне кую һәм тикшерү аркасында мөмкин булды. Бу фәнни мәктәпнең 80 еллар ахыры — 90 еллар башында калкып чыккан тәэсирле сәяси-милли агымга да этәргече шактый зур икәнлеген әйтергә кирәк. Милли иҗтимагый тормышның җанлануы шартларында Я. Абдуллинның шәкертләре Ф. Солтанов, Р. Әмирханов, Р. Мөхәммәтдинов, Ә. Мәхмүдовлар татар милли-сәяси оешмаларын башлангыч оештыру дәверендә җитәкчеләр һәм идеологик яктан әйдәп баручылар арасында булдылар. Остаз үзе дә, хакимлек итүче идеологик кысалардан чыкмастан, милли рух белән сугарылган фәнни иҗатын янарыш чорында ихлас күңел һәм тулы канлылык белән үстерә, милли хәрәкәткә кушылып китә алды.

Татар иҗтимагый фикере тарихын өйрәнү өлкәсендә заман, билгеле, биегрәк үрләр яулауны таләп итә, чөнки шунсыз 70-елларда ук башланган яңарышларның эзлекле рәвештә алга баруы мөмкин түгел. Иҗтимагый фикер тарихын һәм исламны өйрәнү бүлеге бүгенге көндә шул мәсьәләгә тартылган да. Монда фәнни тикшеренүләр ике төп юнәлештә бара. Аларның беренчесе борынгы заманнардан алып хәзерге көнгәчә милли иҗтимагый фикер тарихын фәнни тасвирлау максатын куйса, икенчесе исламның татарлар арасында таралуы, иҗтимагый роле һәм үзенчәлекләрен ачуны бурыч итә. Бу эштә фәнни кадрларның җитенкерәмәве әле үзен бик нык сиздерә. Чөнки әлеге проблемаларны яңабаштан карап чыгу, иҗтимагый фикернең бөтенләй өйрәнелмәгән якларын ачу (мәсәлән, урта гасыр иҗтимагый фикерен тикшерү яки гарәп телендәге фәлсәфи мирасыбызны барлау) белгечләребезнең ишәюен таләп итә.

Әлбәттә, рухи мирасыбызны өйрәнү һәм аны халкыбызга кайтарып бирү төп максатка — татар милләтенең бүгенге фикри җегәрен ныгытуга хезмәт итәргә тиеш. Күпьеллык идея мирасыбызны өйрәнүгә алыну белән бергә, аның дәвамчанлыгын тәэмин итүдә катнашмау һәм халкыбызның иҗтимагый тормышын сурәтләмәү хата эш булыр иде. Шуңа күрә бездә исламчылык, төркичелек, милләтчелек h. б. иҗтимагый һәм фәлсәфи күренешләргә заман күзлегеннән чыгып бәя бирүнең һәм аларның хәзерге фикри үсештәге урынын ачыклауның гыйльми тикшерү объектына әйләнүе зарур. Татар халкының бүгенгесе, киләчәге белән бәйләнгән мәсьәләләрдә фикри төплелек булмавы аның сәяси, иҗтимагый, мәдәни проблемаларын чишүне, милли-этник оешуын тоткарлый. Хәзерге милли үсеш һәм аның аерылгысыз өлеше булган идеологик процессны инде күптән фәнни анализларга вакыт. Бу җәһәттән, мәгариф, мәдәни-әдәби үсеш, милли үзаң хәрәкәте, дини яшәеш кебек иҗтимагый өлкәләрне тикшерү, аларның милли максатларыбызга туры килгән асыл сыйфатларын ачу һәм заман таләп иткән биеклеккә күтәрелү юнәлешен фәлсәфи яктан ачыклау гаять әһәмиятле бурыч.

Я. Абдуллин башлаган эшләрен ачык күзаллый һәм аларны үтәүдә бөтен гыйльми һәм оештыру сәләтен эшкә җигәргә омтыла. Ул бу хактагы уй-фикерләрен АКШта (1988), Төркиядә (1989), Согуд Гарәбестанында (1991) узган халыкара конгрессларда да, фәнни һәм милли җәмәгатьчелек алдында да олпат галимнәргә хас рәвештә, ипле итеп җиткерә килә. 80 еллар ахырында — 90 еллар башында галимнең яңа хезмәтләре язылды, аларда халкыбызның рухи тарихында исламның роле, мәгърифәтчелек, җәдитчелек, суфичылык h. б. социаль-фәлсәфи феноменнарның эчтәлеген ачуга яңа өлеш кертелә. Татарстанның чын бәйсезлегенә ирешү, телебезне, мәдәниятебезне йотылудан саклау, аларны үстерү нигезендә халкыбызны алга җибәрү дә аның игътибар үзәгендә.

Фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Яхъя Габдулла улы Абдуллинның 75 яше тулу көннәрен фикердәшләре, хезмәттәшләре һәм шәкертләре арасында ихтирам казанган хәлдә каршылавы куанычлы. Бүгенге көндә ул татар халкының тарихында исламны өйрәнү буенча оешкан фәнни төркемгә җитәкчелек итә. Ислам диненең региональ үзенчәлекләрен, аны яңарту юлындагы фикер ияләребезнең эшчәнлеген ачып бирү, мөселманлыкны дини-әхлакый система буларак милләтнең тормышына кире кайтару турында уй-фикерләрен, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Баруди, М. Биги, С. Максуди, Һ. Максуди кебек шәхесләребезнең мирасын бастырып чыгару хакында теләк-омтылышларын җәмәгатьчелегебез хуплап каршы алды.

Я. Абдуллинның тормыш һәм хезмәт юлы яңа фәнни мәктәп һәм иҗтимагый-фикри агымга башлангыч бирде. Әлеге мәктәп 70-елларда ук татар иҗтимагый фикерен өйрәнүдә сәламәт рухлы милли-демократик юнәлешне яңадан торгызды һәм аның чаткылары тәэсирле булды. Бу фикри хәрәкәт халкыбыз рухи куәтенең эчке агымын сафландыра һәм аңа тартылган зыялыларның, уңга-сулга тайпылмыйча, милли мәнфәгатьләрне өстен куеп җитди хезмәткә алынуы аркасында, әлеге юнәлешнең киләчәге дә өметле. Ә бу исә Яхъя Абдуллинның юлы дәвам итәчәк дигән сүз.

**Тәфкил КАМАЛ,**

**Рашат ӘМИРХАН.**

---

1. Абдуллин Я. Г. Татарская просветительская мысль. Казан, Таткитнәшр, 1976. 48 б.
2. Шунда ук. 224 б.
3. Slavic Review. 1982. Том 40, № 4. 635 б.
4. «Вопросы философии». Ж. 1977. № 2. 184 б.
5. «Problems of Communism» Ж., 1979, Том 28, № 5—6. 28 б.
6. Из истории татарской общественной мысли. Казан, Таткитнәшр, 1979. 95 б.
7. Batunsky M. Resent Soviet Jslamalogy. «Religion» Ж., 1982, № 12. 370 б.
8. «Звезда Востока» Ж., 1990. № 9. 141 б.

Марат Әмирхан

# ЧЕЛЛӘ БАБАЙ ФАТИХАСЫ

Яңа ел якынлашкан саен, Әбелмәлихнын йөзе чытыла гына барды. Халык бәйдән ычкынган эт кебек кибеттән-кибеткә чаба, шампанын, ризыкнигъмәтен хәстәрли, уенчык-чыршы юнәтә, ә ул, әнә, тиресенә сыеша алмыйча йөри. Җыенысы пешмәгән бәрәңге, җыенысы томана, җә, ни дип куана инде бу татар, дип, бөтен милләтне селкеп салды Әбелмәлих. Яңа ел, имеш, Раштуа, имеш. Чеп-чи көфер гамәлләре ич алар. Җитмәсә, Сафурасы... Арыпалҗып эштән кайтып кергән иде, сарылыпмы-сарыла муенына. Бүләк мәсьәләсен кузгатмакчы инде бу, дип фаразлады Әбелмәлих. Чөнки үтенече төшкәндә генә хутка җибәрә ул әлеге хәйләләрен. Мәгәр бүләк дигәндә егылып китә инде, шундый да маһир булыр икән.

Һәм ялгышмады Әбелмәлих. Әнә, ни ди бит Сафурасы:

— Әтисе, Муллый Яңа елга Хафизасына чәшке тун бүләк итә икән, би-ик, би-ик матур, йошмакның да йомшагы, ди, йомарласаң учка сыя да бетә, ди.

— Ахирәтеңә әйт, тунын чучка тиресеннән тектерсен!

— Ә-әтисе...

— Минем «әтисе» булганга ун ел инде,— дип дөрләп кабынды Әбелмәлих.— Мөселман-мөслимә башыгыз белән дуңгыз елын бәйрәм итәр идегез әллә?

Китте кызып, китте кызып! Сафура бүлмәсенә кереп бикләнергә мәҗбүр булды. Нияте бөредәге килеш сүнде.

Ай-һай, серкәсе су күтәрми. Шаштылар бит болар, кем икәнлекләрен дә оныта башладылар. Дуңгыз елында кәеф-сафа корып йөрерләр иде тәки. Нибуч, ирек бирмәбез! — Шулай тузынды Әбелмәлих.

Яңа ел мәрәкәсе Әбелмәлихнын төшендә дә дәвам итте. Имеш, ул карурман ешкынлыгында япа-ялгыз адашып калган. Буран. Котырынган мәрхәмәтсез җил агач ботакларын кибәргә эленгән кер шикелле йолкый, ботарлый. Йөзәр еллык нарат-чыршылар сыкрана, ыңгыраша. Зилзилә бер генә секундка тынып торган арада бүре улаган тавышлар ишетелеп китә, тагын ниндидер шомлы авазлар яңгырап ала. Кая барырга, кемгә елышырга? Хәер, тау чаклы кар көртләрен ничек ерып узмак кирәк? Ләкин күрәләтә катып үләсе дә килми ич инде.

Шулай да, ничек килеп капты соң әле ул бу капкынга? Кибет тота ләбаса ул, мануфактура сатып көн күрә. Урманга да, мондый куркыныч юлларга да һичниндй катнашы юк. Рэкетчылар эше дияр идең, ул аларга ай саен тиешлесен түләп бара, аралары көйле шикелле.

Чарасызлыктан күзләре яшьләнде Әбелмәлихнын, Сафурасы исенә төшеп күңеле тәмам нәүмизләнде. Тиешсезгә рәнҗетүләре исенә төште. «Их, хатынкаем, бу бәлаләрдән котылсам, уч төбемдә генә йөртер идем, өрмәгән җиргә утыртмас идем үзеңне»,— дип антлар итте.

Әллә теләге фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килде инде, бермәлне агачлар арасыннан тычкан күзе чаклы гына ут шәйләнеп киткәндәй булды. Әбелмәлих шатлыгыннан кычкырып ук җибәрде. Димәк, әле өмет бар! Мөгаен, урман каравылчысы йортыдыр. Әбелмәлих шикелле адашкан бәндәләргә юл күрсәтү өчен фонарен кабызып элгәндер. Дөньяда бар бит ул мәрхәмәтле кешеләр!

Әбелмәлих алга омтылды. Дөресрәге, кузгалырга чамалап карады. Ләкин бер карыш җир дә китә алмады. Ахыры, тәгәрәп карарга дыр, дигән фикергә килде. Шул рәвешле агач кәүсәләренә бәргәләнә-суккалана тәгәри торгач, ниндидер бер

ышык урынга килеп чыкты. Монда жил дә исми, буран да котырынмый. Ут дигәне дә каравылчы агач ботагына элгән фонарь түгел, зур бер учак иде. Учак яны мыж килеп тора. Кемнәрдер бәйрәм итә, шаярыша, бакырыша...

Әбелмәлих тә сөенеченнән кәжә бәтие шикелле сикергәли-сикергәли шул якка ыргылды. Ыргылды да янә киселеп төште, чалгыга эләккән үлән курасы диярсең.

Тукай бабайның «Кәжә белән сарык» әкиятенә килеп эләктем ахрысы, дип хафаланды ул. Чөнки учак тирәсендә чуалышкан гәүдәләр адәми заттан түгел иде. Ярый ла, кәжә белән сарыкның биштәр-капчыкларында бүре башы булган, ерткычлар шуннан шөлләп, үзләре үк учак яныннан шылганнар. Ә бу афәтләрдән ничек котыласы. Ичмасам, янында Сафурасы да юк. Ул булса, әмәлен тапмый калмас иде.

Әбелмәлих тизрәк шылу ягын карады. Тик ниятен башкара алмады, чөнки көлтәдәй зур башлы, колаклары әрекмән яфрагы шикелле шәлперәйгән шешәборынлы хәшәрәт зат юлына аркылы төште. Күтәрелеп караса, йә Хода, чучка ләбаса!

Юк, Тукайча түгел, бөтенләй башка әкияттән. Тукта, тукта, «Унике ай» дигән әкият ич бу! Юк, анда айлар кеше кыяфәтендә. Хәер, болары да Кыш бабай киеменнән бит.

Ул арада чучка аны учак янына өстери башлады.

— Менә шушы инде ул теге татар аламасы,— дип мыгырдады учакташларына чучка.— Хәзер күрмәгәнен күрсәтәм мин аңа, мырык-мырык...

— Бишаяклап разый, ау-һау,— дип өрде Эт.

— Мырык-мырык, үзебезнең янга шуның өчен китерттем дә инде аны, их...

Кайсы әкияттән соң әле бу хәшәрәтләр?—дип үрсәләнде Әбелмәлих, тик башын ничек кенә кашымасын, хәтеренә төшерә алмады.

— Юкка башыңны ватма,— дип ысылдады Елан бабай,— бу яңа әкият. Марат әфәнде әкияте, моннан чыгу юлын белсә, фәкать ул гына беләдер... ыс-с-с-с...

Шунда гына төшенде Әбелмәлих, ул Көнчыгыш календаре патшалыгында икән ич! Бу җанварлар ел образлары: Эт, Елан, Маймыл...

Чучка һаман каударлана, имеш, син мине ихтирам итәргә тиеш, яратырга, 1995 ел — минем ел! Алай бик нервымны кузгатсаң, чурту-матер, чукындырдым куйдым үзеңне, йөрерсең аннары Иван Иваныч булып. Сез, татарларны, юлдан яздыру мина сукыр бер тиен дә тормый. Кубегез, әнә, телегездән ваз кичте, кызларыгыз кияү сайлаганда башка диндәге жегетләрне мәгъкульрәк күрә. Үзегез әйтмешли, «Шалт, Мөхәммәтҗан!» И һәм дә, бетте-китте вәссәлам, здрасте, Иван Иваныч!

Чучка шулай азынды ки, Әбелмәлихны чиркәүгә үк өстери башлады. Әбелмәлих аякларын терәп каршы килеп карады, юк, бу ит бүкәненә адәмнең көчкуәте житәрлекмени?

Чучка аны нишләткән булыр иде, анысы билгесез, кылт итеп Еланның ысылдаган сүзләре исенә төште. Әлеге патшалыктан чыгу әмәлен бу әкиятне уйлап табучы гына белә дигән иде түгелме? Әйе, әйе! Әбелмәлих, ниһаять, бөтен белгән догаларын укып, ошбу әкиятне язучыга мөрәҗәгать итте. Һәм, син күр дә, мин күр, аны ниндидер өермә бөтереп алды да, «эһ» дигәнче якты, кояшлы аланга китереп төшерде.

Үз күзләренә үзе ышанмый торды Әбелмәлих. Нәкъ алан уртасында унике кыз. Уникесе бер кашык су белән йотарлык. Бер битләрендә — кояш, икенчесендә — ай нуры. Иреннәре — чия, күзләре — шомырт. Озын кара толымнары Дөлдөл ялы сымак ялык та йолык килеп тора. Башларында — ак калфаклар. Һәммәсе чәчәкле-чуклы шәл бөркәнгән. Аякларында чигүле нәфис читек. Җитәкләшкәннәр дә җыр җырлыйлар:

> Кулымдагы йөзегемнең
> Исеме Әбелмәлих...

Бәрәч, минем хакта ич бу, дип, Әбелмәлих колакларын үрә торгызды. Ләкин җырның ахырын абайлап бетермәде, кызлар чир-чу килеп юл ягына таба йөгерделәр. Ә анда өстенә яшел чапан, башына кырма бүрек кигән баһадир гәүдәле бер бабай басып тора иде.

— Хуш киләсең, Чиллә бабай, Ходай озын гомер, саулык-сәламәтлек насыйп итсен!—дип, кызлар бабайны уратып алдылар.

Бабай кызларга затлы-затлы бүләкләр өләште. Калфак, чулпы, дисеңме, камзул яисә комганмы — барысы да күзнең явын алырдай чын милли бүләкләр.

Чиллә бабай соңыннан дога укып, җыелган кешеләргә изге теләкләрен ирештерде.

— Мөхтәрәм кардәшләр,— диде ул,— сезнең барыгызны да кышкы Нардуган бәйрәме белән котлыйм, бер-берегезгә мәрхәмәтле булыгыз, ярдәмләшеп, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен тоеп-белеп яшәгез. Кышкы Нардуган, милади исәп белән исәпләгәндә, Яңа елга туры килә. Ходай шулай насыйп иткән, күрәсең, без шул исәп белән көн күрәбез. Кайсыдыр ки, ул да безнең бәйрәм. Чучка сурәтенең монда бер катнашы да юк, балалар, ул мәҗүсиләрдән калган ырым-шырым гына.

Әбелмәлих шундый куанды бу хәлләргә, хәтта йокысыннан ук уянып китте!

Сафура, гадәтенчә, тигәнәк кебек телефонга ябышкан иде инде. Ире йоклый, ишетми дип уйлый, ахрысы, ахирәтенә аның гайбәтен сата:

— И, безнең бәләсен инде, Хафизәкәем, җыен тузга язмаганны аннан көт. Инде Яңа елны каршы алмыйбыз, мөселман башым белән Чучка елы өчен бокал күтәрер хәлем юк, ди.

— Шалишь, хатын,— дип кычкырды Әбелмәлих,— Чучка елы түгел, прусты Яңа ел, кышкы Нардуган! Бәйрәмгә ныклап әзерлән, Чиллә бабай үзе фатихасын бирде!

•

## Җәләл Нурани,

әфган язучысы

# МӘКЕРЛЕ КӨНДӘШ

ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ

Гаилә бәхетенең сере нәрсәдә? Бу сорау миңа күптәннән тынгылык бирми. Ни өчен гаиләләр таркала? Мин әнә шушы галәмәт тә четерекле сорауларга җавапларымны алдан ук әзерләп кую, үземне тормышның хәтәр сынауларына чыныктыра тору максатыннан, яңа өйләнешүчеләр өчен язылган китапларны, газит-журналларда чыга килгән мәкаләләрне җентекләп укып бара башладым. Безгә кунакка килгән, тормыш тәҗрибәсе зур булган кешеләрне төрле сораулар биреп аптыратучы да — мин. Кайсылары мине аңлап, житди җавап бирә, кайсылары исә уен-көлке белән котыла. Мондый вакытларда әни миңа күз кырые белән карап-карап куя, мәгәр үзе кеше алдында ачуланмый. Кунаклар таралышкач кына битәрләргә тотына:

— Оят түгелме сиңа, кызый?— ди.— Кешенең әллә ни уйлавы бар лабаса...

Мин акланырга тырышам:

— И әни, миңа да кияүгә бер чыгасы бит,— дим.— Кызыксынуның ни гаебе бар?

— Әниеңне кеше алдында оятлы итү гаеп түгелмени? Инде болай да, бу кызый кияү куенына керергә ашкынып тора икән, дип уйлыйлардыр...

Әни белән сүз көрәштереп торуның файдасызлыгын белгәнгә, бүтәнчә дәшмим. Әйдә, ачулана бирсен, эчен бушатсын. Барысын да аңа ничек аңлатасың?!

Гаилә бәхетенең серләре мәктәптәге дус кызларны да кызыксындыра. Алар белән серләребез килә килүгә. Әмма ләкин аларның да бу четерекле мәсьәлә хакында гыйлемнәре әллә ни түгел шул. Аларның да киңәш бирер кешеләре юк. Бер ахирәтемнең әнисе, кызын тәүфыйклы итеп үстерү өчен, кирәкмәгән нәрсәләр турында сөйләшмәскә куша, икенче дустымның әнисе юк...

Ниһаять, быел урта мәктәпне тәмамладым. Ә көзгә таба мине сорап, димчеләр килә башлады. Мин әнидән берәүгә дә вәгъдә бирми торуын үтендем. Җәй бар, кыш бар, ашыгып ни эш бар, дигәндәй, җан теләгән яр табу ул — шахмат уйнар өчен пар табу ише генә түгел.

Шахмат дигәннән, бу нәрсәнең минем тормышымда никадәр мәшәкать-борчулар китереп чыгарасын кем белгән ул вакытта! Шахмат җене кагылган күрше егете Сәрвәрнең кайчан да бер минем ир-кәмәшем буласын кем белгән...

Мәктәптә яхшы укыганы өчен Сәрвәрне әти белән әни миңа һәрвакыт үрнәк итеп куялар, шуңа җен ачуларым чыга иде. Безнең гаиләләр үзара дус булып, бер-беренә кунакка йөрешеп яши. Әмма Сәрвәрләр гаиләсе бер көнне калага күченеп китте. Шулай да алар безне онытмадылар, кунакка кайткалап йөрделәр. Инде мин күрше малаен ачуланып түгел, сагынып искә ала башладым.

Еллар үтте. Быел Сәрвәрнең әнисе кайтып, улының югары уку йортын тәмамлавы турында сөйләп торды. Ә берничә көннән соң, Сәрвәр үзе дә кайтып төште. Аны күргәч, башта танымый тордым, танығач, «аһ» итеп, артыма утыра яздым. Озын-ыспай гәүдәле, күркәм кыяфәтле бу егетне элеккеге күрше малае дип кем уйлар? Сәрвәр дә мине, ничектер, сокланып-сәерсенеп күзәткәндәй тоелды.

Әниләр үзебезне генә калдырып чыгып киткәч, мин каушадым, бер кызардым, бер бузардым, сөйләшер сүз табылмады. Каядыр йөгереп качасым килде. Сәрвәр, хәлемне аңлагандай, аркамнан сөйде дә, берни булмагандай, хәл-әхвәл сораша башлады...

Икенче көнне без, балачактагыча кулга-кул тотышып, чишмә, әрәмә буйларында, урман аланнарында йөри идек инде... Һәм үзебезнең балачактан мәхәббәтле яшьлегебезгә аяк атлавыбызны сизми дә калдык шикелле. Сәрвәр эшне кызу тотарга ярата икән, атна-ун көннән безгә яучы җибәрде. Яшерен янып, көтеп алынган көн иде бу минем өчен. Йөрәгем әлегә исемнәре дә табылмаган хисләрдән шашынып тибә, күңелем иләс-миләс иде. Ярый әле әти белән әнигә аны-моны аңлатып торасы булмады, минем хәлне күреп-сизеп торалар иде. Фатиха бирделәр, рәхмәт яугырлары. Бу юлы инде үзем дә никахны сузуны кирәк санамадым...

Мин, тормыш итә башлагач, яңадан гаилә һәм никах турындагы китапларны укуга хирысланып киттем. Тиздән үземне гаилә тормышының нечкәлекләрен яхшук беләмдер сыман хис иттем.

Безнең яшь гаиләбез тормышы баштарак чыннан да ипле генә барды шикелле. Әмма тора-бара гаҗәеп бер ачыштан аптырап калдым: мин Сәрвәрнең бердәнбер мәхәббәте генә түгел икәнмен ләбаса. Әйе, әйе, ул миннән дә артыграк итеп... шахматны ярата икән бит! Җүләр димә инде мине, кияүгә чыгуымның беренче көннәрендә шул шахматының һәр фигурасын кадерләп-сөртеп куйдым бит әле. Әмма Сәрвәрнең шахмат уенына хирыслыгы торган саен җен ачуларымны чыгара башлады. Шулай булмыйни, көн саен диярлек эштән дусларын ияртеп кайта да, шахмат тактасына багынып утыра. Дуслары да үзе сыман: шахматтан башканы күрмиләр дә, ишетмиләр дә. Мине димим инде, хәтта тырышып-тырышып әзерләгән табыныма да илтифат итмиләр, билләһи. Тәкатем беткәч, тыныч булырга тырышып, тамак кыргалыйм:

— Ашап алмыйсызмы соң, чемпионнар, пылау суына бит!

Миңа җавап:

— Шах!

— Атың белән капла!

— Фил белән йөрсәң, ак сакаллы карт була идең, малай!

— Мат!

Шулай итеп, мин мәкерле көндәшем — шахмат шаһинәсенә каршы торырлыгым юклыгына төшендем. «Бар белгәнең шахмат синең!..» — дип чәпчүләремнең дә файдасы тимәде. Сәрвәр елтырап торган фигураларының башыннан сыйпаштырып:

— Шахмат минем юанычым, мин ансыз торалмыйм... — дип кенә куйды.

Ә тора-бара ул минем битәрләүләремнән туйды булса кирәк, еш кына шахматын култык астына кыстырып, дусларына китә, шунда озаклап уйнап кайта башлады. Мин шахматларын пыран-заран китердем, ишек алдына чыгарып аттым, тик моның да файдасы тимәде. Киресенчә, Сәрвәрнең йөзе тагын да караңгылана гына төште.

Ачу акыл китәрә, дигән сүзне исемә алып, сабыр гына уй-фикер йөртеп карарга булдым. Бу бәладән котылу юлы булырга тиештер ләбаса. Шахмат аркасында аерылышмабыз бит инде, тьфу-тьфу, әйтмәгәнем булсын!

Әйбәтләп уйлаганнан соң, мәкерле көндәшем — шахмат шаһинәсе белән килешүгә барырга булдым. «Дошманыңны яхшылап белми торып, аны җинеп булмый», — дигәнне дә ишеткәнем бар иде. Миңа да шахмат уйнарга өйрәнергә кирәк! Әйе, әйе, шахмат уйнарга. Кем өйрәтер, дип баш ватасы юк, үз абыем да оста шахматчы. Ул еш кына Сәрвәргә дә «мат» куя. Мине өйрәтергә ни тырышты, үземнең әлегәчә теләгем генә булмады.

Киттем бер көнне абый янына... Өч айлап өйрәндем абыйдан шахмат серләренә. Гажәп, шундый хикмәтле уенны элегрәк ничек яратмаганмын?! Абый үзе дә шаккатты минем сәләтемә. Өч ай дигәндә, көтелмәгән йөрешләр ясап, «остазымның» үзен дә ота язып калдым.

Ниһаять, Сәрвәр алдында да сюрприз ясарга җай чыкты. Бер кичне «ахириләре» белән бик бирелеп, шахмат уйнап утыра бу. Карыйм, картымның хәлләре шәптән түгел, шаһинәсенә һәлакәт яный. Уендашы озын Әхмәтнең йөзе яктырганнан-яктыра бара, болай да зур авызы колагына җиткән. Үзе әледән-әле:

— Абзагызның кем икәнен күрдегезме инде хәзер? — дип сөйләнә.

Минем ачуым чыкты.

— Картымны җиңсәң, мин үзем сиңа мат куям, «абзый кеше»! — дидем.

Әхмәт, афишага баккан кәҗәдәй, сакалын күтәреп, миңа текәлде. Минем сүзне уенга алып, Сәрвәр борын астыннан гына елмаеп куйды. Ул бит минем уйный белүем турында хәбәрдар түгел иде. Шулай да торып, урынын миңа бирде.

Үземә тигән кара фигураларны тыныч кына тезеп куйдым. Уендашым илтифатсыз гына елмаеп, ике пешкасын берьюлы алга күчерде. Мин җавап йөреше ясадым. Ышанасызмы, биш-ун минут та үтмәгәндер, тегеңә матны сыладым бит! Барысы да озын Әхмәттән бот чабып көләргә тотынды. Уендашымның өстенә көтмәгәндә бер чиләк бозлы су койдылармыни, теле тотлыга башлады:

— Син... син, ни, теге... чыннан да, беләсең икән бит! Мин ... юри генә дип торам. Әйдә, бу юлы чынлап, тагын бер тапкыр...

— Батыр ике көрәшми! — дидем мин горур гына һәм «чемпионнар»га кофе әзерләргә дип, кухняга чыгып киттем.

Шуннан соң ни булды, дисезме? Шул көннән башлап, Сәрвәремнең кәефе яхшырганнан-яхшыра башлады. Ул, элеккечә, эштән кайтышлый шахматны кемнәрдәдер качып уйнаудан туктады. Ахириләрен дә сирәгрәк алып кайта хәзер, чөнки бит аның белән уйнарга өйдә лаеклы пары бар. Икәү уйныйбыз шахматны. Гаиләбез күгендәге җыела башлаган кара болытлар да әкренләп таралды.

Мин әледән-әле китап киштәсенә күз салгалыйм. Анда «Никах һәм гаилә» дигән җыентык белән янәшә «Шахмат уйнарга өйрән!» дигән китапчык та бар. Алар — минем гаилә бәхетемне табарга булышучы акыллы һәм тугры дусларым.

**ШАМИЛ МАННАПОВ** тәрҗемәсе.

### ТАТАРСТАН БМОГА ЯКЫНАЯ

26 ноябрьдә Казан Кремлендә Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль секретаре урынбасары — дөньякүләм танылган сәясәтче һәм дипломат Джозеф Вернер Ридны һәм БМОның ассоциацияләшкән әгъзасы — Халыкара Мәгълүматлаштыру академиясе җитәкчеләрен кабул итте.

Очрашуда катнашучылар Татарстан белән БМОның хезмәттәшлек итү перспективаларын тикшерделәр. Аерым алганда, Казанда БМОга булышлык итү ассоциациясе төзү мәсьәләсе каралды. Рид әфәнде фикере буенча, әлеге оешма аша безнең республика белән БМОның даими эшләүче органнары һәм махсус учреждениеләре арасында элемтәләр, иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә кирәкле мәгълүматлар алмашу җайга салыначак.

### ТАТАРСТАН ЮГАРЫ СОВЕТЫ СЕССИЯСЕНДӘ

Айдан артыкка сузылган тәнәфестән соң, 23 ноябрьдә Татарстан Югары Советының XXII сессиясе эшен яңадан җанландырып җибәрде һәм ул 30 ноябрьгә кадәр дәвам итте. Сессия утырышларында күп кенә мөһим мәсьәләләр каралды. Татарстан Республикасының 1992 елның 6 ноябрендә кабул ителгән Конституциясенә байтак кына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелде.

Бу сессиядә «Татарстан халык депутатларын сайлаулар турында» Закон кабул ителде. Киләсе сайлаулар, шуңа нигезләнеп, 1995 елның 5 мартында үткәреләчәк. Дәүләт Советы (алдагы сайлаулардан соң, Югары Советның исеме шулай дип үзгәртеләчәк) 130 депутаттан торачак. Территориаль округлардан сайланган депутатлар вазифаларын төп эшләреннән аерылып башкарачаклар.

Югары Совет сессиясендә шулай ук «Дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнары турында», «Вәкиллекле җирле хакимият органнарын сайлаулар турында», «Җирле үзидарә турында» законнар кабул ителде.

### ИЧКЕРИЯ ЯЛГЫЗ ТҮГЕЛ!

11 декабрьдә (1994), якшәмбе көнне, Россиянең эчке һәм регуляр гаскәрләре, бронетехникасы, хәрби вертолетлар сагы астында, бәйсез Чечен Республикасына — Ичкериягә бәреп керде. Әлеге империячел сәясәткә тискәре мөнәсәбәтен белдереп, Татарстан Югары Советы Президиумы шундук тиешле карар кабул итте. Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев та, Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин да әлеге агрессияне, Россия Федерациясе Конституциясен тупас бозу, дип бәяләделәр, мондый әхлаксызлыкка, вәхшилеккә карата үзләренең кискен каршы булуларын белдерделәр. Татарстан Республикасыннан Россия Дәүләт Думасына сайланган бер төркем депутатлар да, мәгънәсезгә кан түгүне туктатуны, чечен кризисын тыныч сөйләшүләр аша чишүне таләп итеп, махсус белдерү белән чыктылар.

14 декабрьдә исә мәркәзебезнең Ирек мәйданында, Тукай һәйкәле янында, Татарстан халкы, Ичкериядәге канлы вакыйгалар уңаеннан, чечен халкына — теләктәшлек, басып алучыларга нәфрәт митингысы үткәрде. Татарстан халык депутаты М. Мөлеков алып барган әлеге митингта Ш. Мәрҗани исемендәге җәмгыять президенты, язучы-галим З. Зәйнуллин, «Суверенитет» комитеты рәисе, шагыйрь Ә. Мәхмүдов, академик-язучы Ә. Кәримуллин, җырчылар Г. Сафиуллина, В. Гыйззәтуллина һ. б. чыгыш ясады.

### КИТАП БӘЙРӘМЕ

Республикабыз мәдәни тормышы декабрь аенда юбилейларга бай булды. Казан дәүләт сәнгать һәм мәдәният институты үзенең 25 еллыгын, курчак театры 60 еллыгын билгеләп үтте. Татарстан китап нәшриятына исә 75 ел тулды — шул уңайдан «Казан» милли-мәдәни үзәгендә зур тантана үткәрелде. Бәйрәм кичәсен нәшрият директоры Харис Әшрафҗанов ачты һәм татар китабы үткән данлы юл һәм үзе җитәкләгән коллективның бүгенге икътисадый кыен шартларда да галиҗәнап басма сүз хакына зур түземлелек белән эшләве турында сөйләде.

Бәйрәм тантанасына килгән мөхтәрәм ветераннарны, мөхәррирләрне, язучыларны, полиграфия хезмәткәрләрен, кунакларны Татарстан Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кайнар котлады һәм китап нәшриятына Татарстан Республикасының Мактау грамотасын тапшырды. Шундый ук бүләккә һәм «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә коллективның бер төркем хезмәткәрләре дә лаек булды.

### ТӨРКИ ДӨНЬЯ ЯЗУЧЫЛАРЫ КОРЫЛТАЕНДА

8—10 декабрь көннәрендә Төркиянең башкаласы Анкарада Төрки дөнья язучыларының II корылтае булып узды. Аңа җир шарының 40 тан артык иленнән килгәннәр иде. Корылтайда Татарстан Язучылар бер-

леге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев белән Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы, язучы-галим Тәлгат Галиуллин да (икесе дә — «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзалары) катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Корылтай кабул иткән документларга мөстәкыйль дәүләтләрнең язучылар берлекләре рәисләре, шул исәптән Татарстан вәкиле дә, кул куйды.

Корылтай эшендә Төркия Президенты Сөләйман Дәмирал һәм башка рәсми җитәкчеләр катнашты.

## КАЛӘМДӘШЛӘР АРАЛАША

7 декабрьдә Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов Венгрия Республикасыннан килгән бер төркем журналистларны кабул итте. Ике арада матбугат чараларының бүгенге хәле, чит илләрдә бара торган теге яки бу вакыйгаларны яктырту ысуллары, полиграфия мәсьәләләре турында кызыклы һәм файдалы сөйләшү булды. Эчкерсез дуслык шартларында үткән әңгәмәдән һәр ике як та канәгать калды.

## «ЯШЬ ЯЗУЧЫ» СТУДИЯСЕНДӘ

Үткән елның 12 октябреннән башлап, «Казан утлары» журналы редакциясе каршында «Яшь язучы» студиясе (җитәкчесе — Мансур Вәлиев) эшли. Әдәбият мәйданында үз көчләрен сынап карарга теләүче яшь каләмнәргә иҗади ярдәм итү максатыннан оештырылган иде ул. Студия утырышларына башкалабызның югары уку йортлары студентлары, эшче яшьләр, хәтта өлкәннәр дә бик теләп йөри. Педагогия институтының (хәзергечә әйтсәк, университетның) «Илһам» әдәбият-иҗат берләшмәсе җитәкчесе Ләйлә Әхмәдиева һәм аның шәкертләре тыңлаучыларны үзенчәлекле шигырьләре, нәсер-парчалары, хикәяләре белән сөендерде. Университет иҗатчылары һәм эшче яшьләр арасында да өметле каләмнәр байтак. Шулар арасыннан Гөлүсә Закирова, Резеда Сәгъдуллина, Равил Гомәров кебек студентларның, Казан авиация заводы фрезерчысы Тәлгать Хәйретдиновның иң яхшы дип табылган язмалары матбугатка тәкъдим ителде инде.

Студия утырышлары айга ике мәртәбә, чәршәмбе көннәрендә, 16 сәгатьтә редакция бинасында (Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2, Матбугат йорты, 10 кат, телефон: 49-36-63) үткәрелә. Безгә рәхим итегез, яшь каләмдәшләр! Биредә сезне танылган шагыйрьләр, әдипләр, драматурглар белән кызыклы очрашулар да көтә. Студиягә йөрүчеләр алдында «Казан утлары» журналының шигърият бүлеге мөхәррире, күренекле шагыйрь Рәдиф Гаташ һәм Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев чыгыш ясарга өлгерде инде.

## ИСЕМНӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

11 декабрьдә Мәскәүдәге татар зыялыларының Интеллектуальләр клубында «Синең исемең һәм аның чыгышы-мәгънәсе» дигән темага кызыклы сөйләшү-очрашу оештырылды. Әлеге кичәгә олы кунаклар сыйфатында «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, күренекле галим Марсель Әхмәтҗанов, Казан дәүләт университеты профессоры, исемнәр буенча танылган белгеч Гомәр Саттаров-Мулиле чакырылган иде.

Галимнәрнең беренчесе шәҗәрәләр һәм аларның татар этник тарихына мөнәсәбәте турында тәфсилләп сөйләсә, икенчесе күпсанлы тыңлаучыларны татар исемнәренең килеп чыгышы һәм мәгънәсе белән таныштырды. Аннары сорауларга җаваплар бирелде.

Кичәдә атаклы җырчыбыз Зөһрә Сәхәбиеваның һәм Санкт-Петербургтан килгән кунакларның җырлаулары-уйнаулары һәркем күңеленә хуш килде.

Кичәне Интеллектуальләр клубы директоры — язучы Нәзифә Кәримова алып барды.

## ТАТАР-ГАРӘП ДУСЛЫГЫ КИЧӘСЕ

13 декабрьдә «Иман» мәркәзе (җитәкчесе — Винерулла хаҗи Ягъкуб) Казан дәүләт университетының «УНИКС» тамаша-спорт залында «Әссәламу галәйкүм!» исемле татар-гарәп дуслыгы кичәсе үткәрде. Иорданиядән килгән җырчылар, Казанда эшләүче һәм укучы сириялеләр, алжирлылар, иранлылар һәм башка илләр вәкилләре сәхнәдә осталыкларын күрсәттеләр. Үзебезнекеләр дә (алар арасында Зөһрә Сәхәбиева, Гөлзадә Сафиуллина, Миңгол Галиев кебек танылган артистлар бар иде) татар халкының җыр сәнгатендә йолдыз булып балкуларын тагын бер мәртәбә расладылар.

## ҮЗБӘКСТАНДАГЫ МИЛЛӘТТӘШЛӘР ЯНЫНДА

Татар халкының бөек улы Гаяз Исхакый исемендәге бүләк лауреаты — танылган шагыйрь, Татарстан радиосының баш мөхәррире Әхмәт Рәшит күптән түгел генә Үзбәкстанда, милләттәшләребез янында булып кайтты. Ул, Ташкентның милли-мәдәни үзәгендә һәм Алмалык шәһәренең Металлурглар мәдәният сараенда чыгыш ясап, Татарстанның суверенлык юлыннан атлавы, милли-азатлык хәрәкәтендәге хәлләр, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары турында сөйләде, үзенең яңа шигырьләрен укыды.

Үзбәкстан радиосының татарча тапшырулар редакциясе һәм Ташкент телевидениесе шагыйрь турында махсус сәхифәләр оештырды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, язучы Альберт Барый улы Хәсәновка «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

# ДАЛА — ХӘТЕР

Татар галәме республика чикләре белән генә билгеләнми. Сәнгать кешеләре дә мәркәзебез Казанда гына яши дип уйласак ялгышырбыз. Кара дингез, Карпат, Белорусь төбәкләреннән алып, Татар Бугазына кадәр киңлекләрдә яшәгән милләттәшләребез җәмгыятьнең һәр тармагында үз югарылыгында өлеш кертәләр. Бүгенге көндә, тоталитар үзәк төшенчәсе үзгәрә барган саен, без әллә кай төбәкләрдә яшәүче, иҗат итүче яңа талантларны отыры күбрәк ача барабыз. Алар инде хәзер Казан ишекләрен кыю кагалар, үз эшләрен күрсәтергә дип кыю килеп керәләр.

Без бүген Мәскәү, С. Петербург, Оренбург, Ташкент, Әстерхан, Уфа һәм башка шундый шәһәрләрдә яшәүче милләттәшләребездән танылган рәссамнарның иҗатлары белән күреп-танышып торабыз.

Сүзебез — шундый сәләт ияләренең берсе Индус әфәнде Дәүләтев хакында. Ул (1939 елда туган) Свердловск рәсем училищесын тәмамлаган, бүгенге көндә Уфада яши. Аның монументаль эшләре Ишембай, Туймазы, Нефтекамск, Уфа шәһәрләрен бизәп тора.

Әлбәттә, монументаль сәнгать әсәре олы символларны калку итеп, экспрессив хәрәкәтне бер мизгелгә тәэсирле туктатып, тамашачыны җәлеп итә, көтелмәгән чилешләр белән аңына йогынты ясый. Әмма кичерешләрне уята алмаска мөмкин. Рәссам моны сизә, шуңа күрә монументаль сәнгать төре белән генә шөгыльләнеп калмый, ә башка жанрларга да «тарала». Индус Дәүләтевнең икенче канаты — нәкышле сәнгать. Йөрәк хисләрен, дөнья, тарих, халык язмышы турындагы гоманлы уй-фикерләрен ул төсләр сонатасы аша, майлы буяулар белән ясаган картиналарында чагылдыра. Һәм аның шәхси галереясы портрет, пейзаж, натюрмортлар белән елдан-ел байый бара. Аңа ачык, аңлаешлы реализм теле хас. «Дала» дигән картинасы табигать манзаралары арасында аеруча үзенчәлекле. Төрки татарларның гаярь җайдаклары узганда тояклар тупырдавы астында тетрәп торган япан даланың тузаны басылган, авазлар тынган инде. Төпсез күк гөмбәзе белән каймаланган бөек дала гүя безнең йокыга талган тарихыбыз. Ләкин өметсез бушлык түгел, төсләрнең бер-беренә үрелеп күчеше шуңа ишарә. Учак урыннары әкрен искән җилдән уяныр да, сүнгән күмерләр, күзләр кабынып, очкыннары йолдызларга ашар шикелле.

Рәссамның тагын «Замандашлар» дип исемләнгән сурәте бик үзенчәлекле. Уртада — куе ботакларын як-якка тараткан карт тирәк. Шуның астыннан яулык бәйләгән ике татар карчыгы узып бара. Мизгеллек кеше гомере һәм мәңгелек җилгә кочагын ачкан тирәк... Бу картинаның эченә «керә алган» һәрбер тамашачы, аны җыр кебек кабул итә, күңелендәге эчке моң аша тойгылы фикерләргә киләдер.

Егерменче гасырда гына сурәтле картиналар ясала башлаган татар сәнгате ныклы адымнар белән үз мәйданын дөнья арасында яуларга омтыла. Кабатланмас үз йөзе булган һәрбер рәссам да кадерле. Вакытында игътибар.итәргә, илһамына канат куя белергә генә кирәк.

1994 елда Индус Дәүләтевнең әсәрләре Казанда үткәрелгән «Төрки дөньясы» күргәзмәсендә куелган иде. Сания Җамал җитәкчелегендәге «Алтын Урда» берләшмәсе оештырган бу олы күргәзмәдә Дәүләтевнең иҗаты лаеклы бәя алды. Яңаданяңа уңышлар телик аңа.

**Диләрә ВӘЛИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Индус Дәүләтевнең «Замандашлар» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Габделхәй Сабитов.

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




ГОСМАНОВ МИРКАСЫЙМ. **Каурый каләм эзеннән:** *археограф язмалары.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.—463 бит. Тиражы — 7000 данә.

Күренекле галим һәм танылган Әдип Миркасыйм Госмановның бу китабы дистәләрчә еллар буе эзләнүләр, өйрәнүләр һәм уйланулар аша туган гыйльми әдәби тупланма. Ул татар тарихы, гасырлар кичә-кичә үсә барган татар әдәбияты белән кызыксынучы һәркем өчен файдалы белем чыганагы булып тора.

Бу китапта шулай ук автор турында Рәис Даутов тарафыннан хәзерләнгән белешмә дә урын алган.

САДРИЕВ ФОАТ. Таң җиле: роман.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.— 256 бит. Тиражы — 20.000 данә.





Романны әдәби җәмәгатьчелек тә, гади укучылар да яратып кабул иттеләр һәм бертавыштан, авторның гына түгел, ә бәлки соңгы еллар татар прозасының да казанышы дип бәяләделәр.

Нилектән шулай килеп чыкты соң әле? Югыйсә, хәзер — укучылар детектив рухлы язмалар өермәсендә адашып калган бер чорда — көндәлек вакыйга-күренешләргә нигезләнеп иҗат ителгән әсәр турында «бердәм уңай тавыш бирү» гайре табигый хәл ич! Җавап бер генә: кешеләр изгелеккә, мәрхәмәтлелеккә сусады; ә «Таң җиле» — һәркемне тормыш-яшәешнең асылы, әхлак вә гореф-гадәтләр, күңел пакьлеге кебек изге кыйммәтләр турында уйландырырлык лирик-фәлсәфи әсәр ул.

Бәясе 1100 сум

Индекс 73210



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог